«Татары казаки», где была рассмотрена история казачества и роль татар в формировании яицкого казачьего войска.

Была проведена презентация книги нашего земляка краеведа Рустама Анильевича Вафеева «Господин издатель». Книга рассказывает о жизни и деятельности Камиля Тухватуллина – издателя первых татарских газет и журналов, первого татарского эстрадного певца. В книге рассказано об Уральске времён жизни в нём Габдуллы Тукая. Книга составлена на материалах периодических изданий издававшихся в Уральске: «Уральские войсковые ведомости», «Уралец», «Уральский дневник». Рустам Вафеев сейчас живёт в Санкт Петербурге и в библиотеках и архивах города изучает газеты издаваемые Уральске на рубеже веков. У нас к сожалению сохранились лишь единичные экземпляры.

С работником вашего института Мухамедшиным Зуфаром эфенди была проведена работа в областном архиве, где были изучены метрические книги мечетей города и области. В последствии им была написана статья, о Татарах Уральска увидевшая свет в Казани, и впервые озвученная на конференции в Уральске.

Музеем велась активная работа с другими музеями:

– областным историко-краеведческим музеем;

– народным музеем «Старый Уральскъ»;

– Национальным музеем Республики Татарстан;

– музеем квартирой Назиба Жиганова;

– музеем Галии Кайбицкой.

Например, совместно с Музеем Н. Жиганова, Казанской государственной Консерваторией им. Жиганова, областной филармонией в октябре 2011 года были проведено празднование 100-летия со дня рождения Н.Г. Жиганова.

Не раз мы откликались на предложения и приезжали в Казань на различные мероприятия.

Тесную связь я до сих пор поддерживаю с Президентом фонда Тукая Гилемхановым Риманом Султановичем.

Я помог напечатать и провести презентацию книги «Господин издатель», нашего земляка, краеведа Рустама Анильевича Вафеева. Книга создана на материалах периодических изданий конца XIX – начала XX века, выходивших в Уральске. В ней рассказывается о Камиле Тухватуллине – издателе первых татарских газет и журналов. Некоторые выдержки из этой книги, с разрешения автора я включил в статью, за что я ему премного благодарен.

Были организованы несколько туристических поездок в Татарстан, мы возили молодёжь по местам известных татар, связанных с Уральском: Казань, Кырлай, Большие и Малые Кайбицы.

## ТУКАЙ ШИГЫРЬЛӘРЕНЕҢ РИТМИК-ИНТОНАЦИОН ТӨЗЕЛЕШЕ

***Бакиров М.Х.***

В основе ритмико-интонационного строя стихов Г. Тукая лежат два вида стихосложения: 1) квантитативный стих – аруз, который активно использовался в тот период в классической поэзии и 2) слогосчетный или силлабический стих – «бармак», являющийся основным типом народного стиха. Арузные стихи свои поэт читал по канонам метрики нараспев на различные мелодии или же речитативом и, главным образом, употреблял разносложные варианты метра-бахра рамаль (– ◡ – – ) и хаджаз (◡ – – –). Вместе с тем он первым ввел в письменную поэзию самый ходовой силлабический размер десяти-девятисложник – 10–9.

Г. Тукай шигырьләре шагыйрь яшәгән заманның иң мөһим мәсьәләләрен күтәрүләре, халык мәнфәгатьләрен гәүдәләндерүләре ягыннан гына түгел, ә художество-сәнгати эшләнүләре, шул исәптән шигъри камиллекләре белән дә аерылып торалар. Икенче төрле әйткәндә, алар, идея-эчтәлекләре белән социаль яңгырашлы, демократик һәм халыкчан булулары өстенә, поэтика, шигъри эшләнешләре ягыннан да югары, классик кимәлдә.

Белүебезчә, шигырь төзелеше дә, поэтика-структура өлкәсенә карый. Шигырь төзелеше ул – ритмик яктан оешкан һәм метр-үлчәмгә салынган тезмә (шигъри) сөйләм системасы. Ул тел закончалыкларына, бигрәк тә телнең фонетик үзенчәлекләренә һәм эстетика, ритм-метр кануннарына нигезләнә. Төрки халыкларда, шул исәптән татарларда иң киң кулланылган шигырь төзелеше – силлабик яки саниҗек шигырь (көнчыгышта кулланыла торган термин белән әйтсәк, «бармак вәзененә» нигезләнүче шигырь төзелеше). Ләкин шигъриятнең күп гасырлык үсеш тарихыннан күренгәнчә, теге яки бу телнең структур нигезендә бер генә түгел, ә берничә шигырь төзелеше өчен җирлек бар. Мәсәлән, төрки халыкларның поэтик иҗатында аллитерацион шигырь, сүз-стопа шигыре, көчәйтелгән басымлы шигырь, төрки гаруз, силлабика-бармак шигыре, ирекле шигырь дип аталучы шигырь төзелешләренең кулланылганлыгы мәгълүм.

Тукайга килсәк, аның поэзиясендә кулланылган төп шигырь төзелешләре – гаруз һәм силлабика. Әмма, Октябрь инкыйлабына кадәрге чорда яшәгән классик шагыйрь буларак, аның шигъриятендә шул чор төрки поэзиясе өчен хас булган гаруз системасы өстенлек итә. Гарәп-фарсы классик поэзиясе йогынтысында формалашкан әлеге шигырь төзелеше, татарлардан һәм өлешчә башкортлардан тыш, заманында янә үзбәкләрдә, уйгырларда, әзербайҗаннарда, төрекмәннәрдә һәм төрекләрдә актив кулланылып килгән. Һәм бу язма поэзиядә музыканың, көйләп уку традициясенең киң таралган чоры булган. Менә шуңа күрә дә классик шагыйрьләр үзләренең иҗатында музыкаль шигырь төре булган гарузны, төрки җирлегенә яраштырып, бик теләп кулланганнар.

Тәрҗемәи хәленнән һәм истәлекләрдән күренгәнчә, Г. Тукай гаруз теориясен Уральскида мәдрәсәдә укыган вакытында ук үзләштерә. Мотыйгулла хәзрәт үткәргән шигърият һәм гаруз дәресләренә ул булачак журналист һәм җырчы-артист Камил Мотыйгый белән бергәләп йөри. Соңыннан шагыйрь гарузның үз иҗатында нинди роль уйнаганлыгын, язарга дәртләндергәнлеген ассызыклап, бер шигырендә хәтта болай дип язып чыга:

Дәм бәдәм илһам идәр дәрдең бәңа, гыйльме гаруз,
Нә кадәр язсам да, яздым җөмлә илһамыңлә бән.

Гаруз ритмын үлчи торган шартлы сүзләрне – аерым афаил модельләрен шагыйрь хәтта турыдан-туры әсәр текстына кертеп җибәрә, димәк, шигырьләренең үлчәмен шул модельләр белән билгеле:

Фагыйлатын, фагйыйлатын, фагыйлат,
Пишкадәм остазыбызның рухы шат.
(«Кечкенә генә бер көйле хикәят»)

Фагыйлатын, фагыйлатын, фагыйлат,
Ну, Печән базары халкы күңле шат.
(«Печән базары, яхут яңа Кисекбаш»)

Шул ук вакытта Г. Тукай, истәлекләрдән һәм аерым әсәрләренә үзе язып калдырган искәрмәләрдән күренгәнчә, күп шигырьләрен, гаруз таләбенчә, көйләп укыган [1, б. 32, 75, 120]. Мәсәлән, «Туган тел», «Өзелгән өмет», «Сүнмәс дәрт», «Бәйрәм бүген», «Тотса мәскәүләр якаң» кебек шигырьләре моңа исал була ала. Аларның кайберләрендә, атап әйткәндә, «Тәфтиләү» көенә җырланучы «Өзелгән өмет» һәм кайчандыр «Сәлим бабай көе» дип йөртелеп көйгә җырланучы «Туган тел»дә көй белән гаруз ритмы шактый тәңгәл килеп тора, ягъни аларда озын (ябык) иҗекләргә – озын тавыш һәм кыска (ачык) иҗекләргә кыска тавыш туры килә.

Гарузның музыкаль табигате көйләп укылуга гына кайтып калмый, ә шигырь ритмы озын һәм кыска иҗекләр чиратлашуына да нигезләнә. Төрки гаруз шигырьләрендә үлчәмнең (афаил яки бәхернең) озын иҗекле урыннарына күпчелек очракта тартык авазга тәмамланучы ябык иҗекләр туры килә, үлчәмдәге кыска иҗекләр исә сузык авазга тәмамланучы ачык иҗекләр белән белдерелә. Басым ясап әйтергә кирәк, ябык иҗекләрнең ачык иҗекләргә карганда озынрак әйтелүе яки укылуы эксперименталь тикшеренүләр белән дә раслана. Ә инде шигырьнең, гаруз кануны таләп иткәнчә, афаил – буын («стопа – такт») чикләрен сиздереп, ярым көйләп һәм ярым такмаклап (скандировкалап) укылуы ритмга өстәмә куәт бирә, үлчәмне бозмыйча сакларга ярдәм итә.

Үзенең иҗатында Тукай яратып кулланган гаруз үлчәмнәре икәү: рәмал – ◡ – – (ритмик моделе – фА́илАтун) һәм һәзәҗ ◡ – – – (ритмик моделе мафА́Илун). Ритм схемасында һәм моделендә озын иҗекләр сызык (– ) һәм баш хәрефләр (А,И) белән, кыска сузыклар исә фигуралы җәя ( ◡ ) һәм юл хәрефләре (и) белән күрсәтелә. Һәр шигъри үлчәм югарыда гәүдәләндерелгән дүртәр иҗекле ритмик кисәкләрнең («буын» – афаилләрнең) өч яки дүрт мәртәбә кабатлануы нәтиҗәсендә барлыкка килә. Соңгы буын бер иҗекккә ким дә булып килә ала. Тагын шуны искәртергә кирәк: гаруз шигырьләрен скандировкалап укыганда рәмәл үлчәмендә һәр афаилнең беренче иҗегендә (–́ ◡ – – ), ә һәзәҗ үлчәмендә һәр афаилнең икенче иҗегендә ( ◡ –́ – – ) музыкаль басымнар калкып чыга һәм алар кырт кисеп түгел, ә сузыбрак укыла. Мондый басымнарның сүз басымнары белән тәңгәл килүе мәҗбүри түгел.

а) Рәмәл үлчәменә (–́ ◡ – – ) Тукай шигырьләреннән мисаллар:

И́ **ту**ган тел! | һә́р**ва**кытта | я́рд**ә**мең бер=**лә́н** синең,
Ке́ч**ке**нәдән | а́ң**ла**шылган | ша́т**лы**гым кай=гы́м **ми**нем.
(«Туган тел»)

Кө́з**ге** төн, ямь=се́з, **ка**раңгы... | Өй **тү**рендә | җи́л **җы**лый;
Җи́л **хә**бәр ул | а́ч **ү**лемнең | ку́р**ку**сыннан | и́л **җы**лый.
(«Көзге җилләр»)

И́ **мө**катдәс, | мо́ң**лы** сазым! |У́й**на**дың син |ни́к **бик** аз?
Си́н **сы**насың, | ми́н **сү**нәмен, |а́й**ры**лабыз | ах**ры**сы.
(«Өзелгән өмид»)

б) Һәзәҗ үлчәменә ( ◡ –́ – – ) мисаллар:

**Гү**зә́лсең сән, | **зө**бә́рҗәтсең, | **лә**гы́льсең;
**Вә**ли́ сән җир | **кы**зы́ төсле | **дә**ге́лсең.
(«Хур кызына»)

**Та**та́р бәхте | **ө**че́н мин җан | **а**та́рмын
**Та**та́р бит мин, | **ү**зе́м дә чын | **та**та́рмын
(«Үз-үземә»)

Тукайның күпчелек шигырьләре, өч буынлы (11–11, 12–12) яки дүрт буынлы (15–15, 16–16) итеп, шушы ике үлчәмдә иҗат ителгәннәр. Аларның күпчелек бәйт-строфаларында, төрки гарузга хас булганча, цезуралар (тураклар) саклана. Шул ук вакытта мондый строфа-бәйтләр, урыны-урыны белән, цезуралары сүз белән каплап үтелгән строфалар яки аерым юллар белән дә аралашып киләләр. Әмма мондый очракларда шагыйрь цезура туры киләсе урынга һәрчак ике янәшә тартык аваз китерә. Һәм бу алым ике тартык арасында ярым пауза ясарга, афаил-буыннарның чиген-бүленешен сиздереп, квантитатив ритмны сакларга мөмкинлек тудыра.

Чы́к**чы**, и фик=ре́м **ко**яшы! | Ки́т**сен** өстең=нә́н **бо́**лыт,
Бу́ **ү**лек вөҗ=да́н**ны** җанлан=ды́р, **җы**лың бер=лә́н **җы**лыт!
(«Өмит»)
Ә́й**тә** иртән=ге́ **на**мазга | би́к **ма**тур, моң=лы́ **а**зан;
И́ **Ка**зан! Дәрт=ле́ **Ка**зан! Моң=лы́ **Ка**зан! Нур=лы́ **Ка**зан!
(«Пар ат»)

Г. Тукай иҗатында кулланылган икенче төрле шигырь төзелеше силлабика яки бармак шигыре, дидек. Башлап фольлорда туган бу халык шигыре төзелеше язма поэзиядә, Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәреннән тыш, янә «Ана вә угыл» дастаны, «Бәдавам» китабы, Кол Шәриф, Мәүла Колый, Габди һәм башка кайбер шагыйрьләр иҗаты аша XXйөз башы шигъриятенә килеп тоташа. Бу чор классик поэзиядә ничәмә гасыр буена өстенлек иткән гаруз системасыннан (күренекле тарафдарлары Котб, Харәзми, Хисам Кятиб, Сәйф Сараи, Мөхәммәдъяр, Утыз Имәни, Кандалый, Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Дәрдмәнд һ.б.) силлабик шигырь төзелешенә юнәлеш алган чор була. Һәм ассызыклап әйтергә кирәк: заман сулышын тоеп яшәүче бөек Тукай бу процесста үзәктә торып катнаша. Аерым алганда, ул баштарак төрле бармак вәзенендә язылган берничә шигыренә өстәп, 1909 елда 10-9 үлчәмендә атаклы «Милли моңнар» әсәрен иҗат итә. Халык лирикасында күптәннән эшләнгән һәм Уральскида яшәгән чагында үзе төзегән «Җырлар дәфтәре»ндә дә урын алган бу традицион үлчәмне язма поэзиягә әлеге шигыре аша беренче булып Тукай кертеп җибәрә. Фикеребезне раслау йөзеннән мисалга шул дәфтәрдәге халык җырыннан һәм Тукай шигыреннән берәрә строфа китерик.

Сәрмәсән дә | буе | киртләч-киртләч, (10)
Киртләчләре | китәр | боз киткәч; (9)
Ир балалар | кайта | берләр киткәч, (10)
Кыз балалар | кайтмый | бер киткәч. (9)
(«Сәрмәсән буе»)

Ишеттем мин | кичә | берәү җырлый (10)
Чын безнеңчә | матур, | милли көй; (9)
Башка килә | уйлар | төрле-төрле, – (10)
Әллә нинди | зарлы, | моңлы көй (9)
(«Милли моңнар»)

Силлабик система кануннары буенча, мондый шигырьләрнең метр-үлчәме юлларда үзара тәңгәл булып килүче иҗекләр саны һәм цезураларның кайлардан үтүе, тезмәләрне нинди тиңдәш ритмик буыннарга бүлгәләве белән билгеләнә (4+2+4=10, 4+2+3=9). Иҗекләрнең ачык яки ябык, озын яки кыска булып килүе, сүз басымнарының кайда төшүе исә исәпкә алынмый, димәк, андый берәмлекләр үлчәм тудыруда катнашмый.

1910 елда «Шәрык» клубында халык иҗаты турында сөйләгән лекциясендә Тукай силлабик шигырь мәсьәләсенә аерым рәвештә туктала һәм Миргазиз Укмаси, Сәгыйт Рәмиевнең берәр әсәрен һәм үзенең әле генә телгә алынган шигырен мисалга китереп, әдәбиятта күренә башлаган мондый шигырьләрне «соңгый җырлар» һәм «соңгый

шигырьләр» дип атый. «**Бу “соңгый җырлар” халыкның үз рухынча, үз формасынча, үз вәзене белән язылганнардыр**» ди. Шуннан чыгып, ул поэзиянең алгы көндә нинди юнәлештә үсеп китәчәгенә гаҗәеп дөрес прогноз да бирде: «**Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятыбызга, бер дә шөбһәсез, нигез булачактыр**» [2, б. 197, 199] – дип белдерде (ассызык безнеке. – *М.Б.*). Һәм шулай булып чыкты да: шигыриятебез XX йөз башында силлабиканы куллану һәм үстерү юлыннан китте. Ассызыклап янә шуны әйтергә кирәк: **бу ритмик-метрик яңарыш көйләм шигыреннән, ягъни гаруздан силлабик төзелешкә нигезләнгән сөйләм шигыренә күчеш хәрәкәте белән бергә туры килде.**

ӘДӘБИЯТ


1. Тукай турында замандашлары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. 293 б.
2. Тукай Габдулла. Халык әдәбияты // Сайланма әсәрләр. 2 том. Казан: Татар.кит.нәшр., 2006. Б. 189–204.
3. Бакиров М.Х. Закономерности тюркского и татарского стихосложения в свете экспериментальных исследований: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1972. 75 с.
4. Бакиров М.Х. Шигърият дөньясына сәяхәт. Фольклордан язма шигырьгә күчеш тарихыннан. Казан: Сүз, 1999. 238 б.


## Г. ТУКАЙ ИҖАТЫНДА ҺӘМ ҖИРЛЕ СӨЙЛӘШЛӘРДӘ МИФОЛОГИК ПЕРСОНАЖЛАР
### («Шүрәле» һәм «Былтыр» эзеннән)


***Баязитова Ф.С.***



«Шурале» и деревенский смекалистый парень «Былтыр» – самые популярные мифологические персонажи в творчестве Г. Тукая. Они были широко известны в народе. В настоящее время эти образы еще больше обогатились местными верованиями, народной фантазией, переплетаясь лингво-фольклорно-мифологическими вариантами и уникальным диалектным языком. Об этом свидетельствуют многочисленные экспедиционные материалы, собранные нами в последние годы.

Shurale and a sharp-witted village boy Biltir are the most popular mythological characters in the works of G. Tukay. They were widely known among the people. Currently these images have been further enriched with local beliefs, folk imagination interwovening by linguistic and folkloric-mythological versions and unique language dialect. This is evidenced by numerous expeditionary material collected by us in recent years.


**Шүрәле –** Г. Тукай иҗатында һәм гомумән татар халык мифологиясендә иң популяр образ. Г. Тукай иҗаты һәм татар мифологиясе турында күп хезмәтләр язылган, сәнгать әсәрләре иҗат ителгән. Мәсәлән, К. Насыйридан башлап, Ф. Урманчеев, М. Бакиров, Л. Җамалетдинов, С. Гыйләҗев, С. Шәмси, Р. Әхмәтҗанов, Г. Гыйльманов, Б. Урманче, Ә. Фәтхетдинов һ.б. хезмәтләрен күрсәтергә мөмкин. Ф. Яруллинның «Шүрәле» балеты үзе генә дә ни тора!

Г. Тукай Шүрәле образын халык иҗатыннан күтәреп алган. Шүрәле һәм аңа кардәш булган мифологик персонажлар бүгенге көндә халыкта ни дәрәҗәдә саклана? Мифларның төп яшәү һәм сакланып калу урыны бары тик телдә, сөйләмдә генә. Иҗат ителү һәм төп яшәү формасы тел белән бәйләнгәнлектән, хикәяләүгә корылган мифлар халык иҗатының иң борынгы катламы булып исәпләнәләр.

Мифологиянең нигезендә борынгы фикерләү формалары ята. Шуңа күрә буыннан-буынга күчеп, бүгенге көннәргә килеп җиткән мифологик образларны төрле яклап өйрәнүгә телчеләр дә зур игътибар итәләр. Диалектологик экспедицияләр вакытында без халыкның тормыш-көнкүреше белән тыгыз бәйләнештә торган, аның борынгы ышанулары, тел байлыгы, халык иҗаты үрнәкләренең чагылышы булган мифологик информацияне мөмкин булган дәрәҗәдә, татар халкы яшәгән барлык төбәкләрдән магнитофон тасмасына яздырып туплап, җирле сөйләш үзенчәлекләрен саклаган хәлдә кәгазьгә төшерә бардык.

Мифлар (грекча *mythos* – сүз, хикәят) борынгыларның дөнья, тирәлек турындагы фантастик күзаллаулары һәм хыялда туган фантастик образлар, персонажлар хакындагы хикәяләр. Мифология дигән төшенчә исә мифлар җыелмасын белдерә. Әлеге төр хикәятләрне өйрәнү белән шөгыльләнә торган фәнне дә мифология дип йөртәләр.

Татар халкында мифологиянең русча былички (нем. Dämonologische Sagen) дип аталган жанрга туры килә торган репертуары зур урын алган. Биредә төп үзенчәлек – мифологик персонажларны, әкиятләрдән аермалы буларак, яшәгән ди, булган ди дип, кайчандыр булган хәл итеп түгел, чынлап та ышанып, үзем күрдем, яки энем, бабай яки туганым сөйләде дип, чын хәл дип сөйләүдә. Мифологик хикәятләрнең сюжеты кешенең төрле мифологик затлар: *су анасы, шүрәле, өй ийәсе, бичура, җен-пәри* һ.б. белән очрашуын тасвирлауга корылган була. Мифологик хикәятләрнең сәнгатьчә эшләнеше дә сөйләүченең тел осталыгына бәйле була.

Мифологик персонажларны фәндә «югары» дәрәҗәдәге образлар һәм «түбән» дәрәҗәдәге образларга бүлеп йөртәләр. «Югары» дәрәҗәдәге образларга кешедән өстен торучыларны – аллаларны кертәләр (мәсәлән, рус мифологиясендә Ярила, Перун, Велес). «Түбән» катламдагылар – болары һәртөрле демонологик образлар: өй, су, кыр, урман ияләре, җен-пәриләр, убырлар һ.б. Безнең борынгы бабаларыбыз мифологик персонажларны, төрле рухи затларны өй һәм каралты тирәләрендә, аннан читтә, табигатьтә дә яшиләр дип күз алдына китергәннәр. Атамалары да күп очракта шуңа бәйле рәвештә килеп чвккан.

Тукта! Бүгенге көндә хөрмәтләп искә алына торган сөекле шагыйребез Г. Тукай әйткәнчә: «Сүз башы бит Шүрәле!»

Г. Тукай иҗатындагы Шүрәле портретының образлы тасвирламасын искә төшерик: Нәрсә бу? Качкынмы, җенме? Я өрәкме, нәрсә бу? Коточарлык, бик килешсез, әллә нинди нәрсә бу! Борын кәп-кәкре бөгелгәндер – тәмам кармак кеби; Төз түгел куллар, аяклар да ботак-тармак кеби; Ялтырый, ялт-йолт итәдер, эчкә баткан күзләре, Кот очар, күрсәң әгәр төнлә түгел – көндезләре. Яп-ялангач, нәп-нәзек, ләкин кеше төсле үзе; Урта бармак буйлыгы бар маңлайында мөгезе. Кәкре түгелдер моның бармаклары – бик төз төзен, Тик килешсез – һәрбере дә ярты аршыннан озын.

*Шүрәле* сүзе һәм аңа караган мифологик хикәятләр әле бүгенге көндә халыктан табылып тора. Бигрәк тә казан арты сөйләшләрендә Шүрәле һәм безгә бик таныш Былтыр образлары янәшә куелып, гади авыл кешесенең күңелендә, аның сөйләмендә урын ала.

**Шүрәле һәм Былтыр**

Кукмара районы Адай авылы, Мөхәммәтшина Диннәwаз әби сөйли
(экспедиция, 2012 ел):

– Шүрәле булған ич инде ул. Китапқа да йазғаннар, сөйлиләр ийе. Менә без дә китапка йазганны сөйлибез.

Урманчы барған ич урманга. Шүрәле чыққан.

«Кетекләп үтерәм мин сине», – дигән. Урманчы бүрәнәне кисеп йата икән. шуны йарган да йарыққа чөй тығып қалдырғанмы, балтасын тығып қалдырғанмы, балтасын тығып қалдырғанмы.

«Әйдә, син шул йарықтан тот, алып ташлыйбыз бу бүрәнәне. Андары син минем белән кети-кети уйнарсың», – дигән ич шул урманчы.

Шүрәле шул йарыққа қулын тыққан да урманчы тиз генә балтасын алған инде. Қысылып қалған ич бармағы. Менә қычқырып тора икән шүрәле, ә урманчы китәргә дип қузғалған.

«Синең исемең кем?»

«Былтыр», – дигән урманчы.

Шүрәлеләр килгән тегенең җанына. «Нигә қычқырасың, қачан шулай булдың?» «Былтыр қысты, былтыр қысты».

«Нигә былтыр қысқанға быйыл қычқырасың инде», – дигәннәр шүрәлеләр.

Шүрәленең татар халкы яшәгән ерак төбәкләрдә кардәшләре, ягъни урманда аңа ошаган затлар, җирле сөйләшләрдәге атамалары булуы кызыклы.

**Йарымтык һәм Былтыр**

**Йарымтык** – урманда яшәүче, ярым кеше формасындагы мифик персонаж. Аның турында сөйләгән текстларны без Пермь өлкәсендә күп еллар авылларда экспедицияләрдә йөреп туплап бардык. Соңгы елларда язып алынган этнолингвистик-диалектологик-мифологик текстларда Йарымтык белән Шүрәле образларының күп кенә уртак сыйфатлары булуы ачыла төшә, Былтыр образы да Г. Тукай иҗатында һәм казан арты сөйләшләрендәге таныш авыл егете булып урманга утын кисәргә йөрүен дәвам иттерә.

**Йарымтық турында қәртнәй** (әби) **сүләгән экийәт**

(Барда районы, Күчтәнти авылы, Рангулова Фагыйлә, 85 яшьтә)

– Йарымтықны аны йазғаннар қый. Хәзер аны Шүрәле дип сүләгән булалар балаларга.

– Йарымтық ул кеше қыйәфәтле, ди. Маңгайында берәү генә мөгезе бар ди, берәү генә күзе бар ди.

– Бармақлары озын ти, шүрәленеке кебек ти. Айақлары маймул кебек ти.

«Аhаhай, қыт'и-қыт'и уйныйқ әле, қаттым», – тип қычқырған ти, қыш көне булған. Йарымтық килеп чыққан қый қаршысына.

Утын кисүче йегет хәйләкәр булған, аныңа, Йарымтыққа әйткән:

«Кил әле, шушы ағачны арбаға салыйқ», – дигән. Утынға килгәч мә? Йарымтықны йардәмгә чақырған теге йегет.

«Қыт'и-қыт'и уйныйсың килсә, булышың мийа», – дигән, утын йарығына бармағын тығарға қушқан.

«Әйдә, тот, шушында йарыгы бар». Утын йарыгына бармагын тыгарга қуша.

«Әйдә, бүрәнәне күтәрмәгә булышың мийа», – дигән. Ә үзе қайан кәрәк, шуннан тота.

Урманда утын кискән йегет бүрәнәне җарып қуйған булған, чү тыгып. Йарымтық килеп чыққан қый қаршысына.

Бүрәнә йарығына бармағын тыққан иқә, теге хийләкәр йегет йарықтан чүне алған да бармағы қысылып қалған «шап» итеп. Йегет ағачнықы чүwен суғып төшергән дә бармағы қысылып қалған йарымтықнықы. Балтаны тартып алған.

«И-и, йегет, қотқарың мине, аwырта».

Ай-ай, қысты, аwырта.

Син ни атлы, йегет?

Кем қыстырды мине, атың кем синең?

Былтыр минем атым, – дигән дә китеп барған йегет.

Бу алмаша (акылсыз, тиле) йарымтық булган инде.

Иртәгесен дус йарымтықлары килеп:

«Кем қыстырды, қачан қыстырды? – дип сораганнар.

«Былтыр қыстырды мине».

«Былтыр қыстырғанға нәмә быйыл қычқырасың? – дип әйткәннәр дә киткәннәр ди дус йарымтықлары.

**Пичен, пицен һәм Былтыр**

**Пичен, пицен –** себер диалектларында: урманда яшәүче, ярым кеше кыяфәтле мифик персонаж.

Казан ханлыгы чоры язучысы Мөхәммәдъяр иҗатында *бичин* сүзе маймыл мәгънәсен белдергән. Борынгы ташъязмаларда «бичин елы» – маймыл елы. Борынгы төрки телдә *bicin*, монг. *бич*, *мәч* – маймыл.

**Пичен – урманда утын кискәндә күренә.**

– Әwәл сатқалы утын кисәтегәннәр ийе. Пиченне күргән Таштимер әкәләр[1]. Утын кискәндә болар ағач төбенә түгәрәк бөргәгәннәр[2] дә йатып йоқлағаннар. Төннең буйы қытықлаған ул бабаны. Сүләгән ул баба.

– Урманға утынға барған, қоры ағач йығатыған булған. Пичен килеп чыққан. Қышлаңқылыққа[3] утын кискәле барған.

«Син, лычық аwыс, ике баламны эткә ашаттың», – тип йөгереп йөри, ти *(Туғыс).*

**Пиценнең бармағын кыстырып калдырганнар.**

– Бер геше утынға барған игән төскә[4]. Аңа пицен килеп цығыпты.

«Миңа булышың әле, утын кискәле булышың», – тийән йегет.

Пиценгә ошлатып[5] қуйа пүрәнәне. Пицен қулын тығып қуйган игән, қулы қысылып қалыпты (*Абаул*).

---

[1] *Әкә* – ага, абзый

[2] *Түгәрәк бөргәгәннәр* – шалаш ясаганнар

[3] *Қышлаңқылыққа* – кышка, кыш өчен

[4] *Төс* – урман

[5] *Ошлатып* – тоттырып, учлатып

«Ай, синең исемең кем?»

«Пылтыр[1] минең исемем».

Шалай исемен сурапты пицен.

«Пылтыр қысты, пылтыр қысты», – тигән.

«Пылтыр қыстырғанны нәк пыйыл қыцқырасың?» – тип әйтептеләр пиценнәр.

Шалай йомақ шигелле гәпләйтеләр ите. Ағацны йыққан игән дә йарық йасап қуйған агацқа.

«Шал йарықтан ошлап күтәрерсең», – тигән пиценгә.

Шалай қыстырып қуйыпты пиценнең қулын *(Абаул)*.

– Пиценгә әйткән:

«Пармағыңны тыгып тор түңгәк йегенә». Аннан соң пушатқан йектән палтаны алып. Йуwан, йара тоған түңгәккә қыстырып қуйыпты.

«Исемең кем?» тип сурайты пицен.

«Исемем Пылтыр» титте, атына ултырып қайтып китте.

Иртәңгесен пиценнәр ийылып килептеләр.

«Кем қыстырты пармағыңны?»

«Пылтыр қыстырты».

«Пылтырны инте пыйыл эстәмәйпес» тиде.

Әшкәрә оста гәпләйтеләр үлгән өннәмәләр. Өннәм миңә йәшен биргән. Мин сыңар күс ир бала, мин оллатама ошапмын саңгырау *(Тураwыл)*.

**Пицен – урманда цал йарганта** (агач каерысы төшергәндә) **килеп чыга. Аның бармагын кыстырып калдырганнар.**

– Перәү цал йарғанта[2] урманта пицен цығыпты. Пы пиценгә әйтәте:

«Монта тиде бармағыңны тығып тор».

Порнағылар[3] беләте ғуй. Пицен бармағын тыққан игән, пы геше балтаны бушатып йиган игән, түңгәккә қысылып қалган игән. Бағыра[4] игән пицен. Пиценнәр ийылып гилепте.

«Кем қыстырды?» – «Пылтыр», – тигән.

«Пыйыл булса пес аны табыр ыйық, пылтырғыны пелмәйбес», – тип әйтептеләр пиценнәр, ицнимә итмәптеләр[5].

Ул йегет исемен «Пылтыр» тип китеп барыпты *(Тоболтура)*.

Шал урманта цал йаратылар йақшы қарағайтан. Ул цалны ишәтеләр үсләре бауға. Күл итәктә[6] ишеп ултыратылар, қолачлап-қолачлап цал ишеп ултыратылар.

Цал йаратыған қарт:

«Пармағыңны тығып тор» тип әйтепте, Ул тығып торғанда бушатқан да қуйған балтаны йуwан, утын йара торған түңгәккә. Ийылышып килептеләр биценнәр.

«Исемең кем», – тип сорапты пицен.

«Пылтыр» дийепте.

Шаны гәпләйтеләр. Әшкәрә оста башлы ғарт булған. Үлгән оннамнар[7] алай гәпләйтеләр. Тоғомым[8] кән[9] ғуй. Миңә йәшен биргән булыр оннам. Мин оллатама[10] ошапмын *(Кыртйүгән)*.

**Пичен – кешене қытыклый.**

– Биченнәр булған монда, чәче таралмаган, баласын ийәртеп килгән. Мытлығын[11] чыгарып атқан. Бичен ул мәлғунме[12], шайтанмы, ире йөргән йоқ, хатын йөргән. Кеше булып йөреп қытықлаған кешене. Кеше аwыруға сабыша *(Шагир)*.

Җирле сөйләшләрдә, диалектларда мифологик образлар, аларның атамалары гаять бай. Биредә без укучыларның игътибарын урмандагы мифологик персонажлар:

[1] *Пылтыр* – былтыр

[2] *Цал йару* – агач каерысы төшерү

[3] *Порнагылар* – борынгылар

[4] *Багыра* – кычкыра

[5] *Ицнимә итмәпте* – берни дә эшләмәде

[6] *Күл итәк* – кул буе

[7] *Оннам* – әбием

[8] *Тогом* – токым, нәсел

[9] *Кән* – күп

[10] *Олатам* – бабам

[11] *Мытлық* – мылтык

[12] *Мәлгун* – җен, усал зат.

*Шүрәле, Йарымтык, Пичен//Пицен* һәм алар белән янәшә авыл егете *Былтыр//Пылтыр* булган вариантларына гына юнәлттек.

Күренекле язучы, тарих белгече С. Шәмси Шүрәледәге «былтыр кысты» мотивын борынгы грек легендаларындагы «Беркем түгел мине харап итте» мотивы белән бәйләп, аның бик тирәннән килүен, татарларның бабалары болгарларга борынгыдан, Кара диңгез буенда яшәгән чорда ук кергән булу ихтималы турында яза.

Безнең соңгы елларда тупланган материалларда исә Г. Тукай иҗатындагы «Шүрәле» белән «Былтыр» һәм аның хәзерге заманда халыкта сакланган вариантлары арасында ике яклы бәйләнеш барлыгы сизелеп тора. Халкыбыз Г. Тукай иҗатындагы «Шүрәле» белән дә таныш булган, китаплардан укып бер-берсенә, балаларына сөйләгәннәр. Шунлыктан бу образ һәм аңа якын башкалары да үзенчәлекле төсмерләр белән баетылып, яңартылып тора, халыкныкы халыкта саклана дигән тәэсир кала. Без аларны җирле сөйләш үзенчәлекләрен, тел байлыгын саклаган хәлдә язып калдырырга, киләчәк буыннарга тапшырырга тиеш.

ӘДӘБИЯТ

1. Ахметянов Р.Г. Общая лексика духовной культуры народов Среднего Поволжья. М., 1981.
2. Баязитова Ф.С. Пермь өлкәсе татарларының традицион йолалары һәм йола сүзләре // Пермь татарлары турында. Барда, 2000. Б. 39–63.
3. Баязитова Ф.С. Себер ареалы татар диалектларында этнокультура лексикасы (Йола һәм мифология текстлары яссылыгында). Казан, 2009. 736 б.
4. Замалетдинов Л.Ш. О мифологической основе сказки «Шурале» // Габдулла Тукай. Материалы научной конференции и юбилейных торжеств, посвященных 90-летию со дня рождения поэта. Казань, 1979.
5. Кун Н.А. Легенды и мифы Древней Греции. М., 1957. С. 37.
6. Тукай Г. Әсәрләр: Дүрт томда. 1 том. Казан, 1975. Б. 100.
7. Урманче Ф. Татар мифологиясе: энциклопедик сүзлек. Казан: Мәгариф, 1–3 т., 2008–2011.
8. Шәмси С.С. Татар мифологиясенең популяр образы // Борынгы татар фольклоры мәсьәләләре. Казан, 1984. Б. 142–154.

## ИСКЕ ТАТАР ТЕЛЕ: Г. ТУКАЙНЫҢ БАШЛАНГЫЧ ЧОР ИҖАТЫ

***Бәширова И.Б.***

В конце XIX – начале XX века татарский литературный язык функционировал в трех вариантах. В зависимости от адресата и содержания текстов, одни и те же писатели-просветители оформляли свои произведения: а) традиционным старотатарским с преобладанием арабо-персидских заимствований; б) традиционным старотатарским с преобладанием огузо-турецких слов и словоформ; в) старотатарским близким к татарскому разговорному языку. Все классики татарского народа, в том числе и Г. Тукай, в теоретическом плане отрицали традиционный тюрки, а в практическом плане, на начальном этапе творчества, продолжали традицию писать на старотатарском тюрки. В статье анализируются первые (изданные в 1905–1907 гг.) произведения Г. Тукая, которые были написаны на варианте старотатарского языка с преобладанием арабо-персидских заимствований, а не на турецком языке, как утверждают некоторые наши ученые.

In late nineteenth – early twentieth century, the Tatar literary language functioned in three versions. Depending on the recipient and the content of the texts, the same writers filled their works with: a) the traditional Old Tatar with a predominance of Arab-Persian borrowings; b) the traditional Old Tatar with a predominance of Oguz and Turkish words and phrases; c) the Old Tatar close to the spoken language. All the classics of the Tatar people, including G.Tukay, in theory rejected the traditional Turki, but in practical terms, at the initial stage of their writing, continued the tradition of writing in the Old Tatar Turki. This article analyzes the first (published 1905–1907.) works of G. Tukay that were written in the Old Tatar language version with a predominance of Arab-Persian borrowings, rather than the Turkish language as some of our scientists claim.

XIX гасыр ахыры XX йөз башында беренче әсәрен яза башлаган классикларыбызның барысының да, шул исәптән, Габдулла Тукайның да, иске татар телендә иҗат итүләре мәгълүм. Без аларның әсәрләрен хәзерге татар әдәби теленә күчереп укыйбыз. Бу юнәлештә, катлаулы мәсьәләләрне аңларга һәм аңлатырга кирәк булуы күренә. Җөмләдән берсе – классик әдипләрнең иҗатына татар язма әдәби теле тарихының бер дәвере итеп карау зарурлыгы. Болай итеп караганда, хәзерге татарларның, төрки гаиләнең бер вәкиле буларак, VI–VIII гасырларда рун язуыннан башланган, XI–X гасырлардан гарәп

графикасында дәвам ителгән язмачылык тарихы булуы, VIII–XIV йөзләрдә Урта Идел Болгар дәүләтендә кабер ташларындагы штамп-текстларының язылуы [25, б. 47–48], XIII гасырда Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф поэмасы иҗат ителүе [26, б. 10] билгеле булганга, иске татар теленең (борынгы) иске төрки теленә нигезләнүе ачык күренә. «Языки мира. Тюркские языки» дигән энциклопедик басмада, төрки гаиләдә 15 борынгы һәм хәзерге вакытта яши торган 39 телнең, язма тарихы V–VI, VIII–IX, X–XII йөзләрдә башланып, XII–XIII гасырдан язма истәлегенең язылу датасы билгеле булган иске язулы (старописьменные) телләр дигәндә, әзербәйҗан, төрек, төрекмән, уйгур, үзбәк телләре белән рәттән, татар теле дә истә тотыла [27, с. 160, 395, 413, 427, 438, 358].

Этносның барлыкка килүен билгеле бер датага бәйләп караган кебек [8, с. 26], әдәби телнең языла башлавын белдерә торган чыганакны да конкрет бер датага бәйләп карарга кирәк булу игътибар үзәгенә куела. Датага бәйле рәвештә истәлекнең язылу урыны, ягъни кайсы дәүләттә-төбәктә иҗат ителүе дә төгәл күрсәтелә. Шуның белән бергә, (борынгы) иске язулы әдәби телнең асылы-табигате дигәндә, истәлекнең кайсы кабилә теленә нигезләнүе, авыз иҗатына мөнәсәбәте, стиль вариантлыгы, жанр үзенчәлеге истә тотыла һәм аларның таралыш ареалына игътибар ителә. Менә шушы билгеләргә ия булган телләр генә (борынгы ) иске язулы дип санала ала [20, б. 35–46]. Иске язулы телләр әдәби язма нормага нигезләнә, норманың традициясе дәвам ителә. Язма норма әлеге максат өчен файдаланыла торган график билгеләр системасы һәм аларның график-орфографик тәртибендә чагылыш таба [1, с. 533]. Димәк, иске татар теле дигәндә, V–X гасырларда борынгы төрки, X–XV гасырларда урта төрки, XV–XX гасырларда яңа төрки дәверләрдән [27, с. 35–159] килә торган язмачылык тарихына нигезләнгән күренеш булуы истә тотыла.

Иске язулы телләрнең барысы да гарәп графемаларын файдалана, гарәп вә фарсы алынмалары, ислам диненең чаралары дип кабул ителгәнгә, катгый рәвештә үз чыганак теле кагыйдәсенә буйсынып языла [6, б. 55]. Лексик һәм грамматик алынмаларның күплеге исә язма норманың тотрыклыгын барлыкка китерә. Һәр халык язма истәлекне үз төбәкләрендәге кабилә телләренә хас булган әйтелешкә туры китереп укый ала. Шуның белән бергә, һәр автор үзе яшәгән даирәсенең сөйләмә формаларын әдәбиләштереп (кирәк сүзне сайлап ала, кабатлый, мәгънәсен катлауландыра һ.б.) файдалана. Нәтиҗәдә, гомумтөркидән килә торган язма традиция аерым төбәкнең сөйләмә сүз, сүзформалары белән баетыла бара. Иске телдә язылган истәлекне тикшерә башлаганда, язма традицияне күзаллау белән бергә, аерым төбәккә хас булган сөйләмә формаларның ни дәрәҗәдә файдаланылуын һәм аларның нинди мәгънәләре белән ничек итеп язылуын билгеләргә кирәк була.

Иске татар телендә иҗат ителгән / басылган истәлекләрне тикшерүчегә, үз төбәкләрендәге җанлы сөйләмә диалект теле дигәндә, асылда, кыпчак һәм угыз телләренең мөнәсәбәте истә тотыла. Әлеге бәйләнеш-мөнәсәбәтнең ни дәрәҗәдә булуы М. Кашгариның гарәп теле кагыйдәләренә туры китерелеп төзелгән «Диване лөгатет-төрек» сүзлегендә (1070–1072) күп санлы мисаллар белән аңлатыла (2005). «Диван» да түрк-төркиләрнең егерме кабиләсе санала, башкаларга караганда угыз кабиләсе турында күбрәк мәгълүмат бирелә. Автор төрки телләрне тел / сөйләмнәренең чисталыгы ягыннан карап һәм фонетик-морфологик билгеләре буенча ике төркемгә бүлә, угыз һәм кыпчак телле төркиләр һәрвакыт бергә санала. Шулай булуга карамастан, филологик хезмәтләрдә, угыз һәм кыпчак телләре һәр даим берсе икенчесенә каршы куела, XIX гасыр – XX йөз башы татар җәмгыятендә әлеге каршылык сәясәткә бәйләнеп китә.

XI гасырдан XIX йөзнең ахырына кадәр иҗат итүче авторларның барысы да диярлек, әсәрләренең төрки телдә язылуына, ягъни гарәп яисә фарсы телендә язылмаганлыгына, басым ясап, кат-кат искәртә баралар. (Мөхәммәдъярның «Нуры содур» поэмасында бу фикер ун мәртәбә кабатлана). Әднаш Хафизның «Сиражел-колуб» (1554) әсәрендә, төрки төшенчәсе Казан ханлыгында яшәүче халыкларның язма теле дигән мәгънәдә тәгаенләнә. Шуның белән бергә, авторның кайсы укучыны күздә тотып, аңа әйтергә теләгән фикеренең нинди булуына карап, төрки телдәге берәмлекләрнең махсус сайланып файдаланылуы нәтиҗәсендә, төрки тел дигән күренешнең бер генә төрле булмаганлыгы күренә. «Татар әдәби теле тарихы» (2015) хезмәтен язу барышында, әдәби истәлекләрнең, дәверләр, чорлар буена параллель килә торган, берсе-икенчесенә бәйле булган, асылда, ике төрле төрки телдә язылганлыгы мәгълүм булды. Әлеге аерымлану «Котадгу Белек» һәм «Диван-и хикмәт»ләрдән башлана. Йосыф Хаҗ Баласагунлының төрки дөньяда ислам идеологиясен аңлату һәм тарату максаты күздә

тотылган беренче мәшһүр әсәрендә (1069), үзеннән-үзе аңлашылганча, гарәп һәм фарсы алынмалары мул кулланыла, Орхон язмаларыннан килә торган югары стильдәге региональ төрки архаик сүз һәм сүзформалар файдаланыла. Галимнәр билгеләгәнчә, бу әсәр Караханилар империясендә (840–1212), ханнар ханы булган Кара Бограхан хөкем сөргән вакыттагы аристократ язма әдәби тел белән иҗат ителә [13, с. 502]. Әхмәд Ясәвинең (1091–1166) «Диван-и хикмәт» ләрендә аять белән хәдиснең мәгънәсен аңлату өчен төрки теленең муафикъ булуы белдерелә, ягъни алынмаларны куллану билгеле бер дәрәҗәдә азая. Төрки тел дигәндә, таралып яшәгән төркиләрнең диалектларындагы күбесе өчен уртак булган сөйләмә сүз һәм сүзформалары әдәбиләштерелгән халыкчан язма тел истә тотыла. Әлеге ике төрдәге (стильдәге) төркине файдалану, авторларның максатына ярашкан хәлдә, аерым урынчалыкның сөйләмә формалары белән төрлечә баетыла барып, гасырлар буена дәвам ителүе мәгълүм.

Әйтелеп үтелгәнчә, бу авторларның барысы да әсәренең телен төрки тел дип ассызыклап белдерә, әлеге әсәрләрне тикшерүчеләр төрки тел дигән атаманы, аерым регионда яшәүче халыкның төбәге-дәүләте атамасы белән «Болгар төркисе, Алтын Урда төркисе, Казан төркисе, Идел буе төркисе» дип тәгаенли [24, с. 812]. Шуның белән бергә, махсус әдәбиятта, Идел буе төрки тел дигән төшенчәнең, тагын: иске төрки, язма әдәби төрки телнең Урал-Идел варианты, Идел буе һәм Урал төркисе, Урал-Идел төркисе, иске татар Идел буе төркисе, иске татар төркисе, иске татар әдәби теле, иске язулы татар теле, Башкортсан һәм Казакъстандагы иске татар язма теле һ.б.дип, файдаланылуы мәгълүм [27, с. 126]. Аңлашылганча, бу очракта төрки тел дигән төшенчәнең, традицион нигезе һәм регионы атамасы сакланганы хәлдә, шул төбәктә яшәүчеләрнең сөйләмә теленә якынлыгы ягыннан анykланып та кулланыла. Димәк, иске татар теле дигәндә, гомумтөркидән, ягъни угыз, уйгур, карлук, кыпчак, чыгтай телләренә нигезләнеп килә торган язма традициянең, Идел буендагы Болгар, Алтын Урда, аеруча Казан ханлыгында яшәүче болгар-кыпчак-татар дип атала торган халыкның сөйләмә сүз, сүзформалары һәм авыз иҗаты формалары белән баетылып дәвам ителүче варианты истә тотыла. Эзлекле рәвештә бара торган әлеге юнәлеш, объектив чынбарлыкка туры килгәнгә күрә, Болгар һәм Алтын Урда дәверендәге язма телне иске татар теленең аерым чорлары икәнлеге истә тотылганы хәлдә, ХУ гасыр һәм аннан соңгы гарәп графикасындагы әсәрләрне, төгәл терминлаштырылып, иске татар телендә язылган дип әйтергә кирәк була. «Иске татар телемез» дигән атама, беренче мәртәбә, «Нур» газетасында «Әдәби телемез нә делдер?»дип бара торган фикер алышуда, газетаның мөхәррире Г. Баязитов тарафыннан кулланыла («Нур», 1905. № 11).

Иске язмалы телләрдәге истәлекләр филологик юнәлештә фәнни тикшерелсә һәм укытылса, алар классик телләр дип атала [1, с. 196]. Иске татар телендә язылган истәлекләр татар филологиясендә махсус тикшерелгәнгә һәм укытылганга күрә, иске татар телен классик иске татар теле дип атарга мөмкин булуы аңлашыла. Шул ук вакытта, классик иске татар теле, XVI–XVII–XVIII–XIX гасырлардагы катлаулы иҗтимагый-сәяси хәлләрне, төрки-татар халкының рухи байлыгын, төрле жанр-стильләрдәге әдәбиятта чагылдыра һәм теркәп калдыра торган төп чыганак буларак, татар (милли) язма әдәби теленең барлык тармакларына хас булган нормаларының ничек итеп ныгуын күрсәтә ала торган чара булып санала.

Гасырлар буена «төрки телдә язам» дип белдерелгәндә, төрки телнең бер генә төрле булмавы: а) аерым әсәрләрдә гарәп вә фарсы алынмалары һәм архаик төрки сүз, сүз формаларының мул файдалануы, ә) башкаларында халыкчан гомумтөрки уртак сөйләмә сүз, сүзформаларының ешрак кабатлануы, гарәп һәм фарсы алынмаларының билгеле бер дәрәҗәдә чикләнүе истә тотыла. Мондый аерымлануның күләме, авторның чынбарлыкка карата мөнәсәбәте, темасының нинди булуына, кайсы укучыны күздә тотуына, әсәр языла торган чордагы иҗтимагый вазгыятькә бәйле була. Әлеге мәсьәләләрне, әдәби процесс җентекләп тикшерелә торган «Татар әдәбияты тарихы» хезмәтенә (2014) нигезләнеп аңлатырга мөмкин.

Аристрокат-абруйлы төрки нигезендәге классик иске татар телендә, ягъни гарәп вә фарсы алынмаларының, сөйләмә-диалекталь сүз, сүзформаларына караганда, күбрәк кулланылып язылган әсәрләр дигәндә, XV–XVI гасыр уртасына кадәр Казан ханлыгында: Өмми Камалның шигырьләре, Максудиның (Мөхәммәд Әминнең) «Могҗизнамә» һәм «Мансур Хәлләҗ кыйссасы» әсәрләре, Мөхәммәдъярның поэмалары, Кол Шәриф иҗаты, Әднаш Хафизның «Сиражел колүб» әсәре; XVI гасыр ахыры – XVII йөздә

проза жанры үсеш алуы сәбәпле, бу мәсьәлә шактый катлаулана. «...Тәгаен билгеле иҗтимагый-сәяси вакыйганы әкиятләштереп» язылган «Җәмигыт-тәварих» [17, б. 205] һәм «...халык хыялы күзаллаган тарихи хәл» буларак язылган «Дәфтәре Чыңгызнамә» («Дастаннар китабы») [17, б. 207] әсәрләренең телендә авыз иҗатына хас җанлы сөйләмә формаларның чагылышы табигый булып кабул ителә. Фарсы телендә иҗат ителгән әсәрен төркиләштереп язган Суфи Аллаһиярның «Сөбател-гаҗизин» теле, әлбәттә, абруйлыгын саклап, халыкчан сөйләмә тел әдәбиләштерелеп язылган Мәүлә Колыйның «Хикмәтләр»е теленнән аерымлана; XVIII йөз – XIX гасырның беренче яртысына кадәр дәвердә, Батыршаның «Гарызнамә»се, Т. Ялчыголның «Рисаләи Газизә», Г. Утыз-Имәни, Ә. Каргалый, Һ. Салихов, Ш. Зәки, бераз соңрак язылган Г. Чокрыйның тезмә әсәрләре, гарәп-фарсы алынмалары һәм гомум төрки архаик формалары мул кулланыла торган аристократ төркидә иҗат ителүе мәгълүм.

Абруйлы классик иске татар телендәге әсәрләр белән рәттән, шул ук вакытларда, **халыкчан юнәлештәге классик иске татар телендә,** ягъни җанлы сөйләмә-диалекталь сүз, сүзформаларының гарәп вә фарсы алынмаларына караганда күбрәк кулланылып язылган әсәрләр параллель бара. XV–XVI гасыр уртасына кадәр: Хәсән Кайгы, Дусмәмбәт, Казтуган һ.б. шагыйрь-җыраулар иҗаты; XVII гасырда Мәүлә Колыйның «Хикмәтләр»е, билгеле бер дәрәҗәдә авыз иҗаты үзенчәлекләре файдаланып язылган «Җәмигыт-тәварих», «Дәфтәре Чыңгызнамә» кебек тарихи истәлекләрне дә бу урында искә алырга тиешлек күренә; XVIII гасыр буена иҗат ителә килгән «Илаһи бәет»ләр, авторлар үзләре искәртә барганча, Болгар-Казан шивәсенең, җанлы сөйләмә һәм авыз иҗаты үзенчәлекләре белән баетылган халыкчан иске татар телендә иҗат ителә, «Сәяхәтнамәләр»дә дә халыкчан сөйләмә тел өстенлек итә һ.б.

Төрле авторларның төрле әсәрләрендә параллель килә торган ике төрле төрки-иске татар теле, XIX гасыр урталарында бер үк авторның иҗатында файдаланыла башлый. Г. Кандалыйның беренче поэмаларының теле, аның шигырьләре һәм соңгы поэмалары теленнән шактый аерылуы мәгълүм. XIX гасырның икенче яртысыннан, асылда, татар халкының сөйләмә формалары активлаша, әмма жанр-стиль таләбе белән аерымлану алга чыга. Шуның белән бергә, XX гасырның беренче унъеллыгында да, классик иске татар телендә, параллель килә торган төрки-татар теле мөмкинлеген файдалану бөтенләй юкка чыкмый. Бер үк автор, адресатына карап, төрле әсәрендә, параллель юнәлештәге төрки телне куллану зарурлыгын аңлый. Г. Тукайның Җаек чоры иҗаты бу хәлнең классик үрнәк булып санала.

XX гасырның беренче бишъеллыгында татар халкының даһи шагыйре Г. Тукай иҗат итә башлый: Ник йоклыйсың, мужик? Яз җитде һәм үсте / Чирәмнәр йортыңда, Тор, уян, күтәрел! / Үз-үзеңә кара: Кем идең, кем булдың? / Нәрсә бар милкеңдә? / Ындырда юк орлык, Иген юк урырлык, / Атың бар бик начар, Өч тәңкә торырлык... [22, б. 3]. Кайда китде цензуралык / Коллык, тарлык, ким-хурлык? / Артка карасак борлып, / Йырак анлар калдыя... [22, б. 6]. Күренгәнчә, шәкертлек чорындагы беренче шигырьләрен яшь автор халыкның сөйләмә телендә кулланыла торган сүз һәм сүзформаларны әдәбиләштереп иҗат итә башлый [14, б. 54–58]. Бу иҗатны татар язма әдәби теле тарихының бер дәвере итеп караган вакытта, Г. Тукай, XII гасырда Ә. Ясәвинең «Диван-и хикмәтләр»е, XV–XVI йөздә шагыйрь-җыраулар иҗаты нигезендә, XVIII гасырлардагы «Иляһи бәет»ләрдән, XIX йөзнең икенче яртысындагы Г. Кандалый, Ә. Уразаев-Кормаши, М. Акмулла, Я. Емельянов әсәрләре белән килә торган традицияне дәвам итә дип әйтә алабыз [19, б. 90–130].

Шуның белән бергә, 1905 елда, Уральск шәһәрендә Камил Мотыйгый тарафыннан «Әлгасрел-җәдид» дигән журнал чыгарырга хәзерлек уңае белән тәкъдим ителгән программада «Голүмең бакчасында...» дигән шигыре басыла:

Голүмең бакчасында дулашалым, идәлем сәйран,  
Сәгадәт бәхтемезгә калсын инсе, җинниләр хәйран.  
Татарлар рифгате, шаны сикез кат күкләрә китсен,  
Әбәд-сәрмәт бу милләтне Ходаем бәхтияр итсен.  
Борынгы уйкуларны дөшенүбән улалым надим,  
Тәрәкъкый вә Тәгали йулларына улалим кадим…

Гыйлемле, белемле булыйк, Ходаем татарларны мәңге сәгадәт-бәхетле итсен, дөньяда болгарларның барлыгына ышандырыйк, төрле журналлар күбәйсен, милләтнең

яшь каһарманнары кулында каләм булсын, йоклап ятмыйк, мәгариф мәйданында ат уйнатыйк...

Шушы ук тема авторның 1906 елда «Шәкерт, яхуд бер тәсадеф», «И каләм», «Фикер» газетасына гына махсус түгел», «Пушкинә», «Газета мөрәттипләренә» һ.б., 1907 елда «Хөрриятә», «Тәрбиятел-этфальгә» һ.б. шигырьләрендә дәвам итеlә. Гыйлемгә-белемгә омтылу фикеренең бөеклеге, «Котадгу белек»тән башланып, болгар төркисе – иске татар телендә язылган «Кыйссаи Йосыф»тан соң гасырлар буена тасвир ителә килеп, XVIII гасыр ахыры – XIX йөзнең беренче яртысында Г. Утыз-Имәни, Ә. Каргалый, Һ. Салихов, Ш. Зәки һ.б.иҗатында, иҗтимагый шартлар таләбенә җавап бирү юнәлешендә, тагын да югары күтәрелә. Әлеге авторлар үзләренең әсәрләрен укымышлы кешеләргә багышлап, традицион гомумтөрки нигезне саклаган хәлдә, гарәп вә фарсы алынмаларын мул кулланып иҗат итәләр. Яшь Тукай да, Аллаһы Тәгалә, Коръәне Кәрим сүзләре белән куәтләнеп, гыйлем-мәгърифәтле, затлы-зыялы булып, халыкка хезмәт итүнең зарурлыгы тасвирлана торган шигырьләр, нәкъ шул әсәрләрнең теле кебек язылырга тиеш дип аңлый һәм шулай яза. Димәк, Г. Тукай, бу юнәлештә ниндидер яңалык ача дип әйтә алмыйбыз, гасырлар дәвамында гамәлгә куелган язма ысулны дәвам итә. Шуның белән бергә, ул әлеге ысулның эчтәлеген киңәйтә:... «бу милләтне Ходаем бәхтияр итсен...» дип, Аллаһыга инану белән башланган фикер, һәр шигырьдә милләтне гыйлемле итүнең тагын башка чаралары булуын белдерә торган тасвир белән киңәйтелә: «тишек пима, тишек бишмәтле», «җир йөзендәге фәрештә» шәкертнең «тәрәкъкый күкләрнең баскычы», «милләтнең һәр эштәге өмете» булуы; «Каләм»нең наданлыкның начарлыгын, агу икәнлеген аңлатырга» мөмкинлегенә күрә, «милләткә мәрхәмәт ит, зинһар хурлыкка калдырма» дип мөрәҗәгать итәргә кирәклек; «Фикер» газетасы басыла башлагач, аның халыкны таркату җилләрне истермәс, милләтнең берләшү юлларын кистермәслегенә ышану, язма әдәби сүзнең көчле корал булуына инану; шагыйрьләрнең дә «күңелгә хушлык, җанга яктылык» китерә торган «Тиңдәшсез Пушкин Александр кебек якты кояш төсле шигырьләр язып», милләтне укымышлы, гыйлемле, аңлы, бәхетле итүнең мөмкинлекләре сурәтләп күрсәтелә. Шулай итеп, Г. Тукай иҗат итә башлаганда, гомумтөрки нигездәге Болгар-Казан иске татар теленең: а) халыкчан сөйләмә һәм авыз иҗаты әсәрләренә якын булган, ә) гарәп-фарсы алынмалары һәм традицион язма формалары мул кулланыла торган мөмкинлеген дәвам итә була. Параллель булып килә торган ике төрле төркинең, Г. Кандалый, Г.Чокрый иҗатындагы кебек, бер үк авторның төрле әсәрендә файдаланылуы тагын да ачыграк чагылыш таба.

Г. Тукайның беренче тәнкыйтьчеләре әлеге мәсьәләне күз уңында тота. Ф. Әмирхан «Габдулла Тукаев шигырьләре, 3 дәфтәр» җыентыгы басылып чыгу уңае белән язылган мәкаләсендә: «...Мәҗмугада “Шүрәле”, “Пар ат”, “Теләнче”, “Кемне сөяргә”, “Дөньяда торыйммы? дип киңәшләшкән дустыма”, “Туган җиремә” дигән шикелле шигырьләр һәр җәһәтеннән тәкъдир ителергә шаяндыр (лаекдыр, хаклыдыр)», – дип, Г. Тукайның саф сөйләмә телендә язылган шигырьләрен югары күтәреп мактый.

Шунда ук: «Бу мәҗмугада Габдулла әфәнденең халис татарча – һәр татар рәхәтләнеп укырлык язылган бик гүзәл шигырьләре вә халис татар мәгыйшәтеннән алынган тасвирлары янында, иске төрек теле белән язылып, гарәпчә, фарсыча, азәрбайҗанча, тагы әллә нәрсәчә телләреннән корылган шигырьләре дә күптер... Габдулла әфәнде кеби табигате шигъриятле кешеләрнең иске вә яңа төрек әдәбияты тәхте тәэсиренә төшеп тә, татар шагыйре урынына – үзләрендән мөтәкәллиф төрекләшкән шагыйрьләр ясаб чыгарулары татар теле вә әдәбияты ноктаи нәзарыннан гөнаһдыр. ...гарәп сүзләреннән татарча төзелеп ясалган бәетләрнең татар шигырь мәҗмугасында торулары – бөтенләй урынсыздыр», – дип укучыга авыр аңлашыла торган шигырьләр «иске төрек телендә» язылган һәм алар татар теле вә әдәбияты карашыннан гөнаһ эш дип белдерә. Дөрес, бу төрдәге шигырьләрнең дә «гүзәл чыгуы» искәртелеп үтелә: «Болардан башка төрек әдәбияты тәхте тәэсирендә язылган шигырьләрендә дә Габдулла әфәнде мөстәкыйль вә гүзәл тасвирлар дәреҗ итәдер», – дип, «Хур кызына» һ.б. берничә шигырьдән өзекләр китерелә, кайбер тәрҗемәләренең дә «телләрен истисна белән», ягъни телен искә алмаганда, бәхак (чыннан да) гүзәл чыкканнар, – дип бәяли [2, б. 11–14]. Ф. Әмирханның икенче мәкаләсендә дә әлеге язмада чагылыш тапкан фикерләр дәвам итеlә: «Моннан соң Габдулла әфәндедән халис татар телендә язылган озын-озын поэмалар көтәмез. Татар теленең (дикъкать итеңез – төрек түгел!) аз булса да алга атлавы өчен, мотлак куәи шигърияле затларымызның тәсанныгсыз (табигый)

татар булып калулары ляземдер» [2, б. 22–23]. Шулай итеп, Г. Тукайның шигырьләре татар халкының саф сөйләмә телендә һәм иске төрек телендә язылган дигән фикер мәйданга куела. «Иске төрек теле» дигән төшенчә, гарәп, фарсы, азәрбайҗан телләре белән бергә бәйләп әйтелгәнгә, әлеге тәгъбирне гомум төрки дигән мәгънәдә аңларга да була кебек. Г. Тукай үзе дә җыентыкларының «...Ул мәнзумат вак-вак диваннарга тәдвин ителеп, төрек-татар галәменең һәр ягына таралган...», – дип язганда, төрек сүзенең тулаем гаилә исеме булган төрки мәгънәсендә кулланылуы аңлашыла [23, б. 185]. Берничә еллар үткәч, Җ. Вәлиди М. Кашгариның «Диване лөгатет-төрек» хезмәтенә нигезләнеп [4, б. 237–243] һәм «Йолдыз» белән «Вакыт» газеталарының телен тикшерү уңаенда [5, б. 159–163] төрки – төрек – татар төшенчәләренең үзләренә хас булган мәгънәләре булуына игътибар итә һәм болай дип белдерә: «...Төрекчә бар, төрки бар, болар – бер-берсенә башка нәрсәләр. Төрекчә дигәне – госманлыча дигән сүз. Төркия дигәне, гомумән, төрек теленчә дигән сүз. Димәк ки, татарча язылган китап төрекчә булмый, бәлки төрки була. «Төрки» ул – гарәпчә һәм фарсычага каршы куелып йөртелә торган классик бер тәгъбир...» [5, б. 161).

Әмма Г. Тукай иҗатына карата язылган мәкаләләреннән аңлашылганча, Җ. Вәлидинең әле төрки һәм төрек төшенчәләрен аерымламыйча куллануы күренә: «Мөхәммәдгариф угълы Тукаев» дигән хезмәтендә: «...Тукаевның беренче (шәкердлек) дәверендә госманлычарак язган шигырьләре эчендә, тәрҗемәләре юк диярлек дәрәҗәдә аз иде» (б. LXI), «...ул хәзер мөстәкыйльрәк хис итә, аның телендә, өслүбендә дә госманлылыктан татарлыкка таба бер сафлану вә истикъляль күренә» (б. LIX), «...Фатих әфәнде Тукаевның госманлыча язылган шигырьләренең тел җәһәтен яратмый һәм «Шүрәле», «Алтынга каршы» кеби татарча шигырьләренә бик зур кыйммәт бирә иде»,- дип белдерә (б. XXXIX) (Вәлиди, 1914), ягъни Ф. Әмирхан мәкаләсендә «иске төрек теле» дигән төшенчә-атама, госманлы дәүләтендәге халыкның теле дигән мәгънәсендә тәгаенләнеп кулланыла.

Г. Ибраһимов та шушы ук фикерне кабатлый: «...Тукай кебек шагыйрьләр (башлангыч «Мөхәммәдия» дәвере) байтак вакытлар ярым «Тәрҗеман», ярым госманлы тәэсирендә бардылар. Ләкин тормышның төбендән табигый рәвештә күтәрелеп килгән халык хәрәкәте әдәбиятны, матбугатны үзенә корал иттерергә тели иде. Боның өчен җанлы халык теле лязем иде» [11, б. 38].

Аңлашылганча, Г. Тукайның беренче тәнкыйтьчеләре тарафыннан, шагыйрьнең башлангыч чор иҗатына, үзенчәлекле рәвештә мөнәсәбәт белдерелә, халыкчан телдә язылган шигырьләре санап күрсәтелеп мактала да, гарәп-фарсы алынмалары мул файдаланылган шигырьләре төрек телендә язылган дип ассызыклана. Бу төрдәге әсәрләренең кыйммәте, халыкның сөйләмә теле яктылыгына куеп тискәре бәяләнә һәм озак еллар буена кабатланачак, Г. Тукайның беренче шигырьләре госманлы-төрек телендә язылган дигән, фикер ныгытыла. Шагыйрьнең иҗатына иске татар әдәби теленең тарихы булуына бәйләп игътибар ителми.

*Биниһая, бихисаптыр, **гаскәри Чыңгыз кеби***
(Шүрәле).

Таким образом, рассмотрев средства репрезентации категории компаративности и их функционирование в произведениях великого поэта, мы пришли к выводу, что компаративные конструкции отражают эстетические, философские взгляды Г. Тукая, являются средством создания точности высказывания и служат цели выражения авторского отношения к изображаемому.

## ТУКАЙ ТЕЛЕНДӘГЕ АЛЫНМА СҮЗЛӘР ҺӘМ ҖИРЛЕ СӨЙЛӘШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

***Булатова М.Р.***

В данной статье рассматриваются языковые особенности произведений великого татарского поэта Г. Тукая, приводятся многочисленные примеры. Анализируется употребление заимствований как арабско-персидского языка, так и русского, а также диалектизмы.

This article discusses the language features of works of the great Tatar poet G. Tukay, the numerous examples are provided. The author analyzes the use of borrowings as an Arab-Persian, as well as the Russian, also dialectal words.

Г. Тукай телен өйрәнгән галимнәр фикеренчә, иҗатының башлангыч чорында шагыйрь иске татар язма әдәби теленә хас сүзләр һәм гыйбарәләрне шактый күп куллана, әмма тора-бара аның теле гади укучы өчен авыр аңлаешлы гарәп-фарсы

алынмаларыннан арына. Г. Тукай иҗатының халыклашуы, ягъни халыкчанлыгы арта бара, соңга таба әсәрләрендә иске татар язма әдәби теленең күпчелек сыйфатлары күзәтелми башлый.

Г. Тукай иҗатында иске татар язма әдәби теле белән уртак күренешләр. Әсәрләрендә борынгы г авазының саклануы: тугърысында [7, б. 194] – турында, *егълый* [7, б. 272] – елый, *угълым* – улым, *егъламай* – еламый [4, 40], *аңгар* [4, б. 152] – аңа, *язгучы* [6, б. 293] – язучы, *сыгынам* [7, б. 302] – сыенам, *гакылын* [7, б. 317] – акылын, *туп-тугъры* [7, б. 274] – туп-туры, *дугъры* [4, б. 300] – туры, *баглыдыр* [4, б. 235] – бәйледер, *сөргүче* – сөрүче, *көлгүче* [5, б. 38] – көлүче һ.б.

XIX гасыр – XX гасыр башында исем фигыльнең -*мак*/-*мәк* формасы актив кулланылышта булган. Әлеге формалар Г. Тукай шигырьләрендә дә еш очрый. Мәсәлән: *безнең гәзитләр* ***укымакымыз...*** [6, б. 11]; *бөтен зиһне* ***ашап-эчмәклә*** *мәшгуль* [4, б. 50]; *кайсысы* ***сатмактадыр,*** *кайсы ала ...* [4, б. 225]; *уйга баткан,* ***утырмакта*** *шагыйрь язып* [5, б. 196].

*Ел-ел артыннан һаман* ***үтмәктәдер,***
*Күл буе талибәләре* ***көтмәктәдер***... [4, б. 234].

*Лязим улды безгә билне* ***бумак*** *алла гыйшкына,*
*Мәгърифәтме йә һөнәрме? –* ***тугъмак*** *алла гыйшкына* [4, б. 258].

Бу күренеш кайбер татар сөйләшләрендә (эчкен, саз ягы һ.б.) сакланган, әмма сирәк кулланыла. Мәсәлән, стәрлетамак сөйләшеннән: *Тумактан* (туудан) *калмаганны, үлмәктән* (үлүдән) *калмабыз* [1, б. 156].

Г. Тукай шигырьләрендә, хәзерге әдәби тел нормаларыннан чыгып караганда, диалекталь булып саналган инфинитивның -*мага*/-*мәгә* формасы да очрый:

*Шундый күренеш – кызганыштыр* ***күрмәгә*** [4, б. 235];

*Эстәде Башны күтәреп* ***бакмага:***
*Гайрәтен вә куәтен* ***күрсәтмәгә*** [4, б. 229].

Бу үзенчәлек урта диалект сөйләшләренең олы буын вәкилләрендә дә саклана әле (минзәлә сөйләшенең бәләбәй урынчылыгы, златоуст, эчкен, нократ, касыйм, бәрәңге, пермь һ.б.). Казан арты сөйләшләрендә дә, бигрәк тә *алмаға килү* сүзтезмәсе рәвешендә, кулланышта: *Қыd алмаға киләләр пар атлар җигеп* [1, б. 153].

Әсәрләрендә хәзерге заман хикәя фигыльнең әдәби телдәгечә формасы -*ый*/-*и(й)* кушымчаларыннан тыш, сирәк кенә булса да -*ай*/-*әй* формасы очрап куя:

*Селкенмәй дә* ***чайкалмай*** [4, б. 55];

*...Хәер-фатихада* ***булышаек*** [7, б. 289].

*Йөри урыс эшен эшләп, –*
*Бән* ***егъламай****, кем егъласын* [4, б. 40].

Мәсәлән, «Гыйшык бу, йа!..» шигырендә автор теләк һәм ниятен белдерү өчен барлык фигыльләрне теләк наклонениесенең -*аем(айым)*/-*әем(әйем)* формасын кулланган:

*Бер гидае җан фидаем, гыйшкыңа* ***пәрванаем;***
*Кәл, гүзәл, гарз ит җәмалең:* ***янаем****, кәл,* ***янаем****.*
<...>
*Сурәтем биңзәр бәнем бер кансыза, бер бансыза;*
*Кыйл тәррәхем хәлемә:* ***канланаем, җанланаем*** [4, б. 282].

Бу әсәрендә әлеге форманың кабатланып килүе ритм-рифма тудыру максатында да язылган.

Фигыльләрдә -*ай*/-*әй* кушымчасын куллану Себер татарлары һәм урта диалектның Урал буе сөйләшләрендә актив таралган күренеш [1, б. 114].

Г. Тукай әсәрләрендә иске әдәби телдәгечә *исә* теркәгече фигыль формаларына ияреп килә: *тыңла дисәң* < тыңладың исә – тыңласаң, *беттисә* < бетте исә – бетсә, *киттисә* < китте исә – китсә.

*Малы, мөлке* ***беттисә,***
*Дәүләт, бәхет* ***киттисә***... [5, б. 38].

*Батарсың син, сине ул төпкә тартыр;*
*Бу чын сүз:* ***тыңла дисәң****, фәһмең артыр* [5, б. 30].

Хәзер дә кайбер сөйләшләрдә сакланган бу күренеш XX гасыр башына кадәр язучылар иҗатында актив кулланылып килгән. Бигрәк тә Урал төбәге татарлары теленә хас (мәсәлән: кормантау, тепекәй, златоуст һ.б. сөйләшләрдә), категорик үткән заман хикәя фигыль һәм *исә* теркәгеченнән торган конструкция ярдәмендә белдерелә һәм нигездә вакытны, шартны, еш кына икеләнүне аңлата: *Буран булдисә* (<булды исә – булса)*, көрт баса* (турбаслы сөйләшеннән) [1, б. 173, 133]. Үткән заман формасы белән бергә (*-ды исә*) мәгънәсе ягыннан әдәби телдәге *-гач/-гәч* кушымчалы хәл фигыльгә туры килә. Мәсәлән, кормантау сөйләшеннән: *Эшләрең беттисә* (беткәч тә), *тиз генә ҫайт* [1, б. 173].

Тукай әсәрләрендә *җ*-лаштыру күренеше дә игътибарны җәлеп итә: (ачлык) *җыланы* [7, б. 174], *җегет* [7, б. 175], *җокласын* [7, б. 177], *җуынгыч* [7, б. 181], *җыртык*, *җөдәтүче* [7, б. 185], *җүри* [7, б. 200], *җуан* [7, б. 207], *җон* [7, б. 304], *җылап* [7, б. 310].

*Җырласаң да,* ***җегет****, ачы җырла, –*
*Уяу* ***җаткан*** *кызлар* ***җокласын*** [6, б. 212].

*Җанкай-җанаш, пумала баш, чыкма урамга* ***җаланбаш;***
***Җөрмә****, шәкерт, кәләпүшсез, урыс булдың, ярамас* [5, б. 183].

Шул ук вакытта мишәр сөйләшләренең төп үзенчәлекләрдән берсе булган *й*-лаштыру күренеше дә чагыла, гәрчә *й*-лаштыру иске татар теленең китаби теле традициясе итеп каралса да, Г. Тукай әсәрләрендә ул аз очрый: *йиңел* [4, б. 40], *йибәрермез* [7, б. 286] һ.б. Асылда шагыйрь урта диалекттагыча *җ*-лаштыруны көнбатыш диалекттагыча *й*-лаштыру белән иркен аралаштыра. Гомумән, XIX гасырда һәм XX гасыр башында язылган әсәрләрдә сүз башы позициясендә *җ*-лаштыру һәм *й*-лаштыру параллель кулланылган. Бу факт әлеге күренешнең ул чорда нормалашып өлгермәгәнлеген раслый. Мәсәлән, Тукайның хатларында да йә [*җ*], йә [*е(й)*] авазлары чиратлаша: 1 нче хат – *йибәргәндә* [7, б. 286], 2 нче хат – *җулы* [7, б. 291] һ.б.

Бер шигырендә бер үк сүз ике вариантта да, ягъни берсендә [*җ*], икенче юлдагы шул ук сүздә [*й*] белән язылырга мөмкин. Мәсәлән, «Бала оҗмахта» шигыреннән:

*Мин хәзер оҗмах түрендә, - бер матур хур иркәли;*
*Мин җуанмыймын,* ***җылыймын****, син түгелсең, дим, әни!*
*Ай төсендә нурлы гыйльманнар миңа ташлый тәти,*
***Егълыймын****, алмыйм аларны, сез түгелсез, дим, әти!* [5, б. 233].

Тукайның шактый әче телле булуы мәгълүм. Шуңа күрә юмор-сатира максатында, көлкеле хәл тудыру өчен кайчак махсус язган шигырьләре дә очравы табигый. Мәсәлән, журналист, язучы һәм педагог Фәхрелислам Агиев (1887–1938) М. Лермонтовның «Ангел» («Фәрештә») исемле әсәренә охшатып бер шигырь яза. Ул «мишәрчәрәк» килеп чykканга, Тукай аңа «Шыер» исемле пародия яза:

«*Фәхрелислам Агиевның шыерын, малай, Кулаткада да севеп укыганнар. Вата, шыннан күреп, Кулаткада бер шаир безнең журналга да нәстәдер бер бәет посылать иткән. Вата:*

Бәет
Их, малай, вафасыз да бу мир!
Бак вана: Хусаен да помер!
Әмән безнең күк алаша кебек
Ашый, кәбәм, һич туймый бу йир.
Нишләсен вет, Азраил килсә, бар кеше үләр,
Тимай бай булсаң да – азанчы күмәр.
Вет праруклар да, малай, вафат булды,
Сахабалар: Али, Усман, Үмәр» [5, б. 217].

Биредә китерелгән сүзләр хәзерге чордагы кайбер төбәкләрдәге мишәр сөйләшләрендә дә активлыгын югалтмаган: *шаир* – шагыйрь, *шиер* – шигырь, *севеп* – сөеп, яратып, *вата* (< рус. вот) – менә, *вана* (< рус. вона), *вет* (< рус. ведь) – ич, *йир* – җир һ.б. Чагышт.: хвалын, чүпрәле сөйләшләрендә *ван'а,* карсун, мәләкәс, чистай *вана* – әнә (< вон) мәгънәсендә; кузнецк, стәрлетамак *ване/ваны* вариантлары да бар [3, б. 147]. *Алаша* – ‘ат’, *әмән* (фарсы алынмасы) ‘кебек, шикелле’ бәйлеген белдерә, ‘нәкъ, бугай’ кисәкчәләре мәгънәсендә шулай ук мишәр сөйләшләрендә киң кулланыла [3, б. 37, 82].

Г. Тукай иҗатында алынма сүзләр байтак. Хәзерге татар язма әдәби телендә кулланыштан төшкән гарәп-фарсы алынмалары турында без искәрттек инде. Аларның күпчелеге җирле сөйләшләребездә яшәешләрен дәвам итәләр. Мәсәлән, ***әүкатле*** [5, б. 276] – ‘бай кеше’. Бу сүзнең *әүҗәт* варианты тау ягы сөйләшләре төркемендә (Кама тамагы, тархан, норлат) ‘хәл, куәт’ мәгънәләрендә хәзер дә яшәп килә; ә тархан сөйләшендә ‘мазар, фәлән’ мәгънәсен дә белдерә.

***Хөррә*** ‘ирекле, бәйсез, азат’: *Син закон, статьяләргә баш имисең, хөррә син.* (Г. Тукай) [2, б. 693]. Әдәби телдә *хөр* сүзе сакланган. Урта диалектның кормантау сөйләшендә *хөррә* сүзенә якын булган *хөрәйрә* сүзе бар: *хөр(-әй)рә* ‘тәкәббер; горур; ирекле, бәйсез’. Бер мисал: *Күктән төшкән хөрәйрә мени – әллә кем булып тора.*

Башлангыч чор иҗатында Тукай төрек һәм гарәп-фарсы алынмаларына бай булса, соңга таба рус һәм Европа телләреннән кереп, халыкта нормалашып бара торган сүзләргә игътибар итә. Шуңа күрә әсәрләрендә рус сүзләрен иркен кулланган. Ул сүзләр кайчакта гарәп әлифбасы белән язылган текст эчендә кирил хәрефләрендә бирелгән. Мәсәлән: *школьниклар* [5, б. 275], *господа* [5, б. 184], *серьезный* [7, б. 304], *черносотенный* [4, б. 54], *достопримечательный* [7, б. 207], *рубляне* [7, б. 292], *деньгасы* [5, б. 218], *казенный* [5, б. 263], *Великий держав␣*[5, б. 190], *угроза, розга, поза* [5, б. 231].

Бер әсәрендә генә дә әллә ничә рус сүзе белән «уйный» ул. «Мич башы кыйссасы»нан: *сырость* [7, б. 170], *честный гына* [7, б. 172], *розгалавын* (суктыруын) [7, б. 171], *умывальнигы* [7, б. 170], *нервы расстроены* [7, б. 168].

Рус сүзләре 1910–1911 елларда, башка хатлары белән чагыштырганда, Сәгыйть Сүнчәләйгә язган хатларында аеруча күп очрый: (*бик) изящный* [7, б. 309], *жизнерадостный (кеше)* [7, б. 310], *резкий (нәрсәләремне)* [7, б. 311], *являться итәм* [7, б. 313], *чорт белә* [7, б. 314], *холостой выстрел* [7, б. 315], (*бер-ике атнага) заглянуть*, *изящный материаллар*, *стряпать итеп* [7, б. 317], (*аерым) личностьлар* [7, б. 320].

Әйтеп узыйк, ‘шайтан белсен’ мәгънәсендәге рус сүзтезмәсен (кызык күрепме) берничә әсәрендә куллана: «Казанга кайтыш»та – *чорт ева знат* [7, б. 176], «Мәкаләи махсуса»да – *чорт ява знат* [7, б. 191], «Сәгыйть Сүнчәләйгә» хатында – *чорт белә* [7, б. 314] һ.б.

Кайчак ул рус телендәге тулы җөмләләрне хәтта җыр кисәге итеп тә язып уза:

> *Но иной находит счастье,*
> *Чувство счастья потеряв* [7, б. 207].
>
> *Патрон берлә не шалить!*
> *патроннарны не жалеть*! [4, б. 32].

Кайбер сүзләрне үзгәртеп, үзебезнең телгә җиңелрәк итеп язганы да күренә: «Поезд барган көйгә» шигырендә – *пирбуенчы* (< первый) – беренче, *партебин* – портвейн [5, 187], *фарситта* – форсить итеп (типтереп) йөрү [5, б. 188], *абзарауный* (< образованный) – укымышлы [5, б. 241].

Шагыйрьнең бер сүзне берничә төрле итеп тә язу ихтималы бар. Мәсәлән: *образованьеңне* [5, б. 147], *абзарауный* (< образованный) [5, б. 241], *образование* [7, б. 317].

Шуны да әйтеп узыйк, Г. Тукай – XX гасыр башы татар балалар әдәбияты өлкәсендә бай мирас калдырган шәхес. Бигрәк тә гомеренең соңгы елларында язылган әсәрләре балаларның аң-белемен, әхлагын үстерүгә зур өлеш керткән шигырьләре, мәсәлләре саф әдәби телдә язылган.

Гомумән, Г. Тукай, халкына фидакарьләрчә хезмәт иткән шәхесләрнең берсе буларак, милләтен мәгърифәткә, хезмәткә чакырып язган шигырьләрен дә гади халыкка аңлашылырлык стильдә язарга тырышкан. Бу аның шигъриятендә дә, мәкаләләрендә дә, иҗтимагый тормышында да бик ачык чагыла. Иҗатының баштагы чорында заманында актив һәм аңлаешлы булган китаби гарәп-фарсы алынмаларын, соңрак рус теленнән кергән сүзләрне кулланса да, аларны җөмләдә бик урынлы куйган. Тулаем алганда, гасырдан артык вакыт узгач та, бөек шагыйребезнең тел байлыгын мул файдаланырга тырышканын күрәбез.

ӘДӘБИЯТ


1. Булатова М.Р. Морфологические особенности татарских говоров ареала «Юг Башкортостана». Казань, 2013. 240 с.

2. Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 1965. 854 б.

3. Татар теленең зур диалектологик сүзлеге / төз.: Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 839 б.
4. Тукай Г. Әсәрләр: дүрт томда. I том. Шигырьләр, поэмалар (1904–1908). Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. 431 б.
5. Тукай Г. Әсәрләр: дүрт томда. II том. Шигырьләр, поэмалар (1909–1913). Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. 399 б.
6. Тукай Г. Әсәрләр: дүрт томда. III том. Мәкаләләр, хикәяләр, мәсәлләр. Казан: Татар. кит. нәшр, 1976. 447 б.
7. Тукай Г. Әсәрләр: дүрт томда. IV том. Мәкаләләр, очерклар, фельетоннар, хатлар (1902–1913). Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 431 б.

## ПРОИЗВЕДЕНИЯ Г. ТУКАЯ В ИЛЛЮСТРАЦИЯХ ХУДОЖНИКОВ НАЧАЛА XX В.

***Вагапова Ф.Г.***

В статье анализируются иллюстрации к детским произведениям Г.Тукая, выполненные художниками начала XX века. Отмечается, что в создании иллюстраций принимали участие профессиональные художники, а также художники, не имевшие специального художественного образования. Иллюстрации к стихам Г. Тукая позволили проследить генезис и динамику развития татарской книжной графики начала XX века. Автором сделан вывод, что в творчестве художников начала XX века прослеживаются черты, характерные для восточной миниатюры, русской лубочной картинки, а также стилистики искусства модерн.

The article analyzes the illustrations for children's G. Tukaya works made by artists beginning of XX century . It is noted that in the creation of illustrations attended professional artists as well as artists who had no formal art education. Illustrations to poems G. Tukay possible to trace the genesis and dynamics of development of the Tatar book charts the beginning of XX century. The author concludes that in the works of artists of the early XX century can be traced features typical of oriental miniatures, Russian print style, and the style of art nouveau .

Габдулла Тукай – один из родоначальников новой татарской литературы. Детские годы поэта, омраченные тяготами потерь и жизненных испытаний, не могли не отразиться на его творчестве, в котором большая часть произведений адресована детям. Поэзия для детей написана в разных жанрах. Это и произведения в жанре назире и сатиры, к ним относится, например, поэма «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» («Сенной базар, или Новый Кисекбаш»), это и поэзия на темы татарского фольклора («Шурале», «Су анасы» («Водяная»). Поиск новых форм и приемов приводит его к возможности обращения к русской классике. Он переводит стихотворение А.С. Пушкина «Золотой петушок», создав произведение «Алтын әтәч».

Уже прижизненные издания произведений поэта, написанные для детей, оформлялись иллюстрациями. В оформлении первых изданий использовались наборные типографские элементы и политипажи. В начале XX века в книжной культуре татар произошли колоссальные изменения, в художественном оформлении книги [3]. Наряду с типографскими наборными элементами появляются иллюстрации.

В создании иллюстраций к произведениям поэта принимали участие как профессиональные, так и непрофессиональные художники. Говоря о профессионализме, мы имеем в виду наличие специального художественного классического образования. На рубеже XIX–XX веков только единичные представители татарской национальности осмеливались обучаться в художественных учебных заведениях столицы России. С этой точки зрения художники, оформлявшие первые печатные книги, были профессионально не подготовлены. Но с позиции той эпохи, в которой жили и творили, в контексте мусульманской культуры они были, несомненно, профессионалами. Они, являясь образованной и прогрессивной частью татарской интеллигенции, осваивая традиции русского и европейского изобразительного искусства, создавали собственные произведения. В статье мы будем использовать термины: «профессиональный», «непрофессиональный», «самобытный» художник.

Анализируемые работы мы условно подразделяем на две группы. К первой относятся книги, оформленные художниками, не имевшими специального образования. Как

известно, идеология ислама не приветствовала изобразительную деятельности. Этот факт стал одной из причин того, что первые татарские художники-иллюстраторы не подписывали свои работы. Можно предположить, что они являлись представителями татарской, в основе своей мусульманской, культуры.

Исследования показали, что издателями к оформлению книг все чаще начинают привлекаться профессиональные художники. Их работы мы выделяем во вторую группу. Среди них также имеются авторы, не подписывавшие свои работы, что делает возможным предположить, что они, являясь представителями татарской культуры, не могли в течение короткого времени отойти от данной традиции. В статье автор придерживается хронологического порядка изложения материала, соответствующего времени издания произведения.

В 1908 году в лито-типографии И.Н. Харитонова в двух вариантах издается, переведенная Тукаем, сказка А.С. Пушкина «Золотой петушок» («Алтын этәч») [4; 5]. В первом для оформления были использованы готовые политипажи. Во втором – наряду с теми же клише использовались иллюстрации, выполненные в технике цветной литографии (хромолитографии). Каждая из них расположена на отдельной странице и носит сюжетный характер. Художник тщательно прорисовывает детали: орнамент на костюмах, лепные барочные детали на стенах в интерьере комнаты, окно в мавританском стиле, в проеме которого виднеется силуэт мечети с полумесяцем.

Очевидно, рисунки выполнены профессиональным художником, имя которого не известно. Новые принципы оформления сближают его с творчеством русских иллюстраторов детской книги круга «мирискусников» («Мир искусства» – общество художников, существовавшее с 1898 по 1904 гг.) [1, с. 326], в частности И.Я. Билибина – русского художника, книжного иллюстратора и театрального оформителя [2, с. 5]. Стилистика И.Я. Билибина отразилась в цветовой гамме и использовании орнаментальной линии, ограничивающей цвета. Также в работах художника прослеживается стилистика модерна, которая выразилась как в оформлении обложки, так и в иллюстрациях. Элементы модерна проявляются в характерном изгибе напряженной текучей гибкой линии рамки, в экспрессивном движении растительного орнамента, обрамляющего текст, в использовании орнаментальных мотивов различных стилей прошлого: помпезное барокко в синтезе с мавританским стилем создают ощущение пышности и богатства.

Электро-типографией «Магариф» в 1914 году издается произведение Тукая «Сенной базар» [6], оформленное гравюрами безымянного художника. Человеческие фигуры в рисунках переданы гротескно: они то приземистые, то заостренно-вытянутые. Словно следуя идее, вложенной автором в содержание произведения, художник, изображая разнохарактерную толпу, не дает буквального толкования и расшифровки образов, не наделяет лица индивидуальными чертами. Одна из гравюр может стать иллюстрацией к строкам: «Один на рынке властвует закон: // В свое лишь дело каждый погружен» [8, с. 326]. Художник не ограничивает гравюры рамкой, расширяя тем самым границы происходящего, создавая эффект присутствия, дает возможность читателю включиться в пространство рисунка.

В 1914 г. типография «Магариф» издает сборник произведений Тукая [7], куда вошли «Шурале», «Водяная», «Сказка о козе и баране» и другие стихи. Можно предположить, что все иллюстрации выполнены одним художником, но свои инициалы «Б.Э.» он оставил только к рисункам к «Шурале», что видимо, связано с тем, что это произведение стоит в сборнике первым.

В выразительных иллюстрациях к «Шурале», выполненных самодеятельным художником, примечательно стремление образного решения в изображении природы, что помогает раскрытию содержания произведения. Сплошной темной стеной стоит лес, на фоне которого разворачивается сюжет. На переднем плане изображен пролесок с вековыми деревьями, переплетающиеся ветви которых ассоциируются с длинными пальцами Шурале. Акцентируя внимание на деталях, художник передает состояние природы в разное время суток. На первом рисунке, где события происходят ранним утром, солнце поднимается из-за густой стены лесной чащи, озаряя все вокруг мерцающим светом; на втором оно высоко стоит над лесом, освящая поляну и оставляя блики на стволах деревьев; на третьем – солнце уже исчезло, спрятавшись в вершинах деревьев. От иллюстрации к иллюстрации заметно меняется и характер главных

персонажей сказки. Вначале лесной див смело выходит навстречу человеку, чувствуя свое физическое превосходство. На другой иллюстрации, где Шурале защемил пальцы в стволе поваленного дерева, он уже менее агрессивен, в его облике – беззащитность наивного существа, пытающегося разгадать хитрость Батыра.

Средствами художественной выразительности передается внешний облик Шурале и Батыра: не залитый краской глубокий штрих, оставленный штихелем, подчеркивает рисунок длинных пальцев, крючковатый нос, рога, длинные пальцы, шерсть лесного чудища. Герои одеты в национальные костюмы: длиннополый казакин, полусферической формы меховая шапка, валенки. В целом же в передаче образов отсутствует та живая динамика, которая характерна для произведения. Анализ иллюстраций к «Шурале», дает возможность сделать предположение, что для художника были близки восточные, мусульманские традиции изобразительного искусства, что проявилось в композиционном построении рисунков, где прослеживается ее прочтение слева направо, что соответствует движению глаз при чтении арабского словесного текста.

Образы героев произведений Г. Тукая заняли особую нишу в творчестве многих художников, чей творческий путь связан с татарским дореволюционным печатным книжным искусством. В большинстве своем, оставшись безымянными, они внесли огромный вклад в развитие татарского изобразительного искусства. В оформлении печатных книг большую роль играли не только книжные знаки (обрамления, концовки, орнаменты), готовые политипажи, но и иллюстрации, для которых характерно следование тексту и стремление уловить дух произведения. Художники, чаще интуитивно, отказываясь от изображения реального мира, используют такие приемы, которые помогают читателю свободно воспринимать литературное произведение. К ним относятся: изображения без фона или без рамы, преувеличение, замалчивание.

Художественное оформление татарской дореволюционной печатной книги за короткий срок проходит различные этапы стилистического развития: от восточной миниатюры, традиций русской лубочной картинки до искусства рубежа XIX–XX веков, выразившегося в стиле модерн.

ЛИТЕРАТУРА


1. Аполлон. Изобразительное и декоративное искусство. Архитектура. М.: ЭЛЛИС ЛАК, 1997. 735 с.
2. Голинец Г.В. И. Я. Билибин. М.: Изобразительное искусство, 1972. 226 с.
3. Каримуллин А.Г. Татарская книга начала XX века. Казань: Татар. кн. изд-во, 1974. 319 с.
4. Тукай Г. Алтын әтәч. Казань: Лито-типография И.И. Харитонова, 1908.
5. Тукай Г. Алтын әтәч. Казань: Лито-типография И.И. Харитонова, 1908.
6. Тукай Г. Печән базары. Казань : Электро-тип. «Маарифъ», 1914.
7. Тукай Г. Мәҗмугаи әсәре. Ж. Вәлиди тарафыннан язылган Тукайның тәрҗемәи хәле. Казан: Мәгариф, 1914. 442 б.
8. Тукай Г. Избранное. Стихи, поэмы, сказки. Казань: Татар. кн. изд-во. 1969. С. 326.


## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ – ФЕЛЬЕТОН ОСТАСЫ


***Вафина А.М.***



В статье рассматриваются фельетоны Г. Тукая. Они отличаются своей жгучей злободневностью, сатирической заостренностью и актуальным юмором. Им присуще критическое, комическое, сатирическое начало. Фельетоны пронизаны острокритическими социальными и политическими мотивами. В исследовании также выявлено, что в фельетонах Г. Тукая высмеиваются наболевшие порочные явления в общественной жизни татар того времени.

The feuilletons of G. Tukay are discussed in this article. They are notable for their stinging vitality, satirical and topical humor. They are characterized by a critical, comical and satirical beginning. The feuilletons are imbued with pointed social and political reasons. The study also revealed that the feuilletons of G. Tukay ridiculed painful vicious phenomenon in the public life of the Tatars of that time.


Габдулла Тукай бөек шагыйрь, үткен телле тәнкыйтьче, көчле публицист кына түгел, ә оста фельетончы да. Язучы фельетоннарында көндәлек тормыштагы тискәре күренешләр үткен тел белән языла. Халыкны дулкынландырган проблемалар, вакыйгалар аның игътибарыннан читтә калмый. Ул язган фельетоннарның төп юнәлешләреннән берсе – үз чоры җәмгыятен, халыкка каршы иҗтимагый тәртипләрне,

изүче сыйныфларны фаш итү. Г. Тукай сатира укларын иң элек надан, комсыз, кадимче дин әһелләренә каршы юнәлдерә. Ф. Әгъзәмов билгеләгәнчә, Г. Тукай үзенең фельетоннарында җәмгыятьне менә ничек сурәтли: ишан һәм муллалар мәчетләргә кереп, ачыктан-ачык капиталга табына, Алланы оныта, капитал шомлыгыннан һәр мөселман исламга кире эшләр эшләргә мәҗбүр була, кызлар зинага, сәүдәгәрләр ялганга, мөхәррирләр алдауга, шагыйрьләр әллә нинди кешеләрне мактауга көчләнә, ике мулла, көндәш хатыннар шикелле, ислам кушмаган рәвештә мөхасәдәсен вә шул капитал өчен исламиятне, инсаниятне бер якка ташлый [1, б. 93]. Мәсәлән, Г. Тукай «Кыямәт көне» исемле фельетонында, дини мифологияне нигез итеп ала. Автор дөньяда явызлык кылып йөргән бәндәләргә кыямәт көне оештыра. Кемнәр соң алар?» ...Ялганчылар, гамәл сатып ашаучылар, шәкертләр хакын ашаучы муллалар, үзләре яхшы аңлап җитмәгән нәрсәне балаларга укытып, ислам балаларының гомерен ашаган хәлфәләр, милләтне ялкауландырып, фәкыйрьләндереп зәһәрләгән ишаннар...» [2, б. 142]. «Кызыкка очрау» фельетонында да язучы дин әһелләренең, дин белән сәүдә итүләрен ачык текст белән әйтеп бирә. Г. Тукай Уральскидагы Габделссалих Ишкуловның тышкы портретын тасвирлаганнан соң «...һәр җире, һәр әгъзасы моның бик надан, бик затсыз бер татар мулласы икәнлеген үзеннән сорамыйча да белдереп, сөйләп торалар иде», дип яза [3, с. 199]. Имамны газеталарда матбугатчыларның эшләпә кияргә кушулары, чалмадан көлүләре борчый. Әлеге күренешләрне мулла Коръән аятьләрен боза-боза кире кагырга омтыла. Биредә автор чагыштыру алымын оста куллана. Муллаларны милләтебезне артка сөйрәүчеләр, наданлыкка, караңгылыкка тартучылар дип бәяли. Г. Тукай Габделссалих Ишкуловның кыяфәтенә, сөйләү рәвешенә игътибар итеп, аны көлкеле ситуацигә куя, көлү объекты итә. Бу очракта ул үз-үзеңне фаш итү алымын оста куллана.

«Г. Тукай иҗатында тәнкыйть утына тотылган алымнарның берсе, аның үз сүләре белән әйткәндә, хакны белеп инкяр кыйлу» [1, б. 40]. Әлеге алым, язучының Уральск шәһәренең имамы Гайниҗамал Җәләлетдиновның «Бәянел-хак» газетасына язган мәкаләсен анализлауда ачык чагылыш таба. Гайниҗамал хәзрәт, элек ят хатын-кызга карау дөрес дип белдерсә, соңрак «Фикер» газетасында хатын-кызның качуына каршы чыккан мәкаләләргә җавап рәвешендә качмау харам дип яза. Г. Тукай исә: «Гайниҗамал хәзрәт кебиләр һәрвакыт үз кәефләре яратканча йөреп, алар бәгъзе вакыт шәригатьтә дөрест түгелне дә эшлиләр... Аның каршында качмау хәрам, ялган гуаһ булу хәләл, кымыз хәрам, кеше малын ашау хәләл», – дигән нәтиҗә чыгара [3, б. 61]. Гомумән, Г. Тукай муллаларны бер очракта ай башлы ( ягъни чалмалы) карга белән чагыштыра, икенчесендә кәкре башлы, яшел яки сары гәүдәле козгын итеп сынландыра, өченчесендә кортлар дип хурлый, дүртенчесендә чапан эченә төренгән хәйләкәр төлкегә тиңли. Дин әһелләренең наданлыгын, икейөзлелеген фаш итә. Шәригать кануннарын үз файдаларына боруларын ассызыклый.

Г. Тукай газета битләрендә язмаларын бастырып торган авторларның һәм мөхәррирләренең дә ят, кыңгырт эшләрен тәнкыйтьләп тора. Язучының фельетоннарында реакцион матбугатның эшчәнлегенә дә кагышлы әһәмиятле фикерләр әйтелә. «Ялкаулык, яхуд яңа кәсеп» әсәрендә мәсәлән, «Бәянел-хак» газетасына, аның мөхәррирләренә, сәүдәгәр Әхмәтҗан Сәйдәшевка шактый тәнкыйть сүзләре китерелә. Казан мулласы Гарифулла Салиховны Сәйдәшевләр мәсләген яклап, алдынгы карашлы яшьләргә каршы мәкаләләр бастыруын фаш итә. Газетаны «лап-лап» дип атап, аларның прогрессивлыкны, милләтне артка сөйрәүләренә ишарәли. «Алай-болай» язмасында да Г. Тукай «Бәянел-хак» газетасын изүче сыйныфлар мәнфәгатен кайгыртучы матбугат буларак бәяли. Ә. Сәйдәшев заказын үтәп эш итүчеләрне остабикәләр дип атый. Әлеге матбугатның тагын бер яшәү ысулы итеп, Г. Тукай сыра заводларының, фәхешханәләрнең игъланнарыннан керә торган керемне күрсәтә. Шуларга бәйле рәвештә ул «Бәянел-хак»тан көлеп, әлеге матбугат органын «Пьянал-хак» дип атый. Димәк, Г. Тукай бу очракта матбугат органнарының исемен үзгәртеп, көлке ясау алымын уңышлы куллана. Шулай итеп ул әлеге газетаның хуҗаларыннан ачы итеп көлә. Әхлаксызлыкларын, үз мәнфәгатьләрен кайгыртып яшәүләрен билгеләп үтә.

Г. Тукай, кара көчләрнең кулга-кул тотынышып эш йөртүләрен аңлап, тәнкыйть угын башка милләт, шул җөмләдән рус реакционерларына да юнәлтә. Әдип «Гучков» (1909) дигән фельетонында Дәүләт думасы председателе, соңыннан ак эмигрант А.И. Гучковны тәнкыйтьләп чыга. Гучков үзенең бер чыгышында: хөкүмәт сүз ирегә бирүдән курка, хөкүмәт җәберли, дип зарланган, имеш. Г. Тукай исә: нәрсә, әллә

Гучков хөррият тарафдарына әйләнгәнме? дип сорау куя. «Үзе әүвәлге Думаларда уңнарның да уңрагы булып, бөтен хөррият вә иркенлекләргә каршы барды. Үзенә хилаф партияләргә, шәхси дошманлыклар өчен, аларны мөмкин кадәр егарга тырышты. Һәм әллә нинди бер явыз тәкъдир аркасында эшенә муаффәкъ тә булды» [4, б. 34] дигән нәтиҗә чыгара. Г. Тукай Гучков кебек вәкилләрнең принципсызлыгыннан, икейөзлелегеннән, эгоистлыгыннан көлә.

«Гаҗәп түгелме?» исемле фельетонында да Г. Тукай, татар дөньясын артка сөйрәүче бәндәләр һәм күренешләр белән берләттән, Россиянең эчке эшләр министры, Дәүләт советы члены П.Н. Дурновоны дурной, ә патша генералы А.Н. Каульбарсны кан эчүче юлбарыс дип атый. Г. Тукайның сатирик әсәрләрендә башка реакцион партияләр һәм аларның әгъзалары да игътибардан читтә калмый. Мәсәлән, аның тарафыннан «Рус халкы союзы» вәкилләре каты тәнкыйтькә юлыга. Эре алпавыт, реакционер В.М. Прушкевич утлы табага бастырыла. Аеруча аның Россиядәге азчылык милләтләргә кимсетеп каравы, аларны изүне көчәйтү сәясәте тарафдары булуы игътибар үзәгенә алына. «Кемнәрнең ни дисәң котлары чыга?» дигән әсәрендә ул Пуршкевичның: «Русиянең барча гайре рус әһалисе вә хосусән яһүдиләр, руслар илә бер хокукта булып, чын Русия гражданнары булдылар инде», дисәң, Мөхәммәдгалинең «Ляховны Россия хөкүмәте кире алдыра», ди [5, б. 237].

«Төрлечә дөнья тану» фельетонында да Мөхәммәдгали хакында мондый юллар бар. Мөхәммәдгали шаһча: «Дөнья Ляхов җәнаплары ихтыярында булган бер нәрсәдер ки, ул бозса – боза ала, һәм төзесә – төзи ала. Кояш илә ай икесе дә караңгы нәрсәләр булып, нурны Мохәммәтгали шаһ таҗындагы кыйбатлы бриллианттан гына алып торалар» [3, б. 166].

«Нәрсәдән?» исемле фельетонында Г. Тукай Мөхәммәдгали ялганына нибары ике юл багышлый.

Ник бүген барча бозау Коръән үбә, Коръән ялый? –
Хәзрәти шаһ, бел ки, биш-алты ямин йоткан бүген [2, б. 231].

Әдип «Словарьдан фал ачу» дигән фельетонында Мөхәммәдгали кебек алдакчы һәм явыз тиранны «Иранда үсә торган зарарлы вә зәһәрле бер үләндер», – ди [3, б. 184]. 1909 елда Мөхәммәдгали тәхеттән төшерелә. Шаһ кача. Аның башы өчен ике йөз мең сум акча вәгъдә ителә. Бу факт берничә тапкыр Г. Тукайның сатирик каләм очына эләгә. «Өч баш» исемле атаклы фельетонында ул бер сюжет сызыгы булып китә. «Былтырның хисабы» исемле фельетонында Г. Тукай Мөхәммәдгали язмышына янә кагыла. Былтыр Мөхәммәдгали шаһ һәр көн йокыдан торгач: «Башым җилкәмдә микән?» – дип капшап карады [4, б. 125].

Г. Тукай «Тегеннән-шуннан» исемле фельетонында аксак Низами атлы татар реакционерын алдакчылыкта, иман сатуда гаепләп чыга. Иеромонах Илиодорның православие диненнән яһүдилеккә чыгып, элек еврейларны эзәрлекләве өчен милләттән гафу үтенгәнлеген хәбәр итә дә, моны дин өчен түгел, көн өчен эшләгәнлеген искәртә [4, б. 167].

«Милләтче» фельетонында Г. Тукай үз героеның социаль йөзен берничә күренешкә мөнәсәбәте аша шәрехләп бирә. Әйтик, Болгария төрек золымыннан азат ителгәннән соң князь Фердинандның таҗ киеп төшкән рәсемен күргәч, милләтченең күз алдына Болгар шәһәрләре һәм әллә ничә йөзләр элек гомер иткән бабаларыбыз килә. «Миллилек аңкып» торган шигырь яза. Ресторанда татар баеның коньяк эчеп утырганын күреп, милләт иң югары бәхеткә ирешә дигән нәтиҗәгә килә. Тукай милләтченең бушкуыклыгын, милләт дип һавалануының сукыр бер тиенгә дә тормавын билгеләп үтә.

Шулай итеп, Г. Тукай татар журналистикасында беренчеләрдән булып үз чоры җәмгыятенең гаделсезлеген, кешелексезлеген, халыкка каршы юнәлгәнлеген, кеше шәхесен харап итүен төрле сатирик алымнар һәм формалар кулланып камчылый. Г. Тукай публицистикасының тәнкыйди рухы халык тормышы һәм язмышы белән бәйләнгән.

ӘДӘБИЯТ

1. Әгъзамов Ф. Тукай-журналист. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 274 б.
2. Тукай Г. Әсәрләр: дүрт томда. 2 том. Казан: Таткнигоиздат, 1955. 219 б.
3. Тукай Г. Әсәрләр: дүрт томда. 3 том. Казан: Таткнигоиздат, 1956. Б. 9–184.
4. Тукай Г. Әсәрләр: дүрт томда. 4 том. Казан: Таткнигоиздат, 1956. Б. 34–173.
5. Тукай Г. Сайланма әсәрләр. Казан: ТаРИХ. VII том. 2002. Б. 239–241.

# ТАТАР ТЕЛ БЕЛЕМЕНДӘ Г. ТУКАЙ ИҖАТЫН ЛЕКСИК-СТИЛИСТИК ЯКТАН ӨЙРӘНҮНЕҢ ТОРЫШЫ

***Вәлиева М.З.***

В данной статье на примере трудов таких известных татарских ученых-языковедов, как Ш. Рамазанов, Г.С. Амиров, Ф.С. Сафиуллина, И.Б. Баширова и др., прослеживается история изучения лексики великого поэта Г. Тукая. Выявляются ценные научные положения и выводы, высказанные ими в связи с изучением лексико-стилистических особенностией языка поэта.

In this article, on the example of works of such famous Tatar scientists, linguists, S. Ramazanov, G.S. Amirov, F.S. Safiullina, I.B. Bashirova and others traced the history of the study of the language of the great poet G. Tukay. Identify valuable research and conclusions made by them in connection with the study of lexical-stylistic osobennostei poet.

Халык шагыйре Г. Тукайның кабатланмас сурәтләү чараларына, үзенчәлекле стильгә ия булуы узган гасыр башында ук галимнәрнең игътибарын үзенә җәлеп итә. Ф. Әмирхан, Җ. Вәлиди, Г. Камал кебек күренекле шәхесләр Тукайның тел мөмкинлекләреннән оста файдаланып, халыкка җиңел аңлаешлы телдә тирән эчтәлекле һәм халыкчан әсәрләр иҗат итүен югары бәялиләр, Г. Тукай исемен милләт, халык белән бер югарылыкка куялар, әсәрләренең сурәтләү чараларына бай булуын, үткен тел белән язылуын искәртәләр. Алга таба да Г. Тукай иҗатының лексик байлыгын төрле яклап тикшерү дәвам итә. Без исә әлеге мәкаләбездә Г. Тукай иҗатында стилистик чара буларак кулланылган лексик берәмлекләрнең өйрәнелү дәрәҗәсен ачыкларга тырышырбыз.

Узган гасыр урталарында Г. Тукайның тел-стиль үзенчәлекләрен, лексик байлыгын тикшергән хезмәтләр дөнья күрә башлый. Алар арасында Ш.А. Рамазанов хезмәте аерым урын алып тора һәм тел белемендә дә югары бәяләнә. Галим әлеге язмасында, шагыйрь иҗатында кулланылган гади сөйләм, көнкүреш лексикасы, алынма сүзләрне анализлау белән беррәттән, күчерелмә мәгънәдәге лексик байлыкның, мәкаль-әйтем һәм фразеологизмнарның кулланылыш үзенчәлекләренә дә туктала. Галим Г. Тукайның гомумхалык сүзләрен бик оста файдаланып, күчерелмә мәгънәләр тудыруда, гади сүзләрнең яшерен мәгънә төсмерләрен ачып бирүдә осталыгы зур булуын мисаллар белән дәлилләп яза. Ш. Рамазанов әлеге хезмәтендә Тукайның халык авыз әдәбиятына якын булган «яңа поэтик тел, әдәби стиль тудыруын» раслый, шагыйрьнең «идиома һәм фразеологияләрдән гаять оста файдалануына» мисаллар китерә [11, б. 144].

1960 елларда исә Ә. Исхак Г. Тукай лексикасын өйрәнү барышында шагыйрьнең иҗатында фразеологизмнар, мәкаль-әйтем, тәгъбирләрнең иситкеч күп очравын игътибарга ала, синонимнарның шагыйрь тарафыннан «көчәйткеч буларак» яратып кулланылуын искәртә [10, б. 105). Автор фикеренчә, сурәтләү чарасы сыйфатында татар халык мәкальләрен куллану ягыннан Тукай күпләрдән аерылып тора. Мәкальне ул шигырьгә бөтен килеш алмый, бәлки «әйтергә теләгән фикеренә буйсындырып сүтә, үзгәртә, өсти һәм шигырьнең табигый бер күзәнәге итеп кертеп җибәрә» [10, б. 98]. Г. Тукайның чагыштыру, гипребола, риторик фигуралар һ.б. шундый сурәтләү чараларын образлар тудыруда бик оста файдалануы хакында да Ә.Исхаков хезмәтендә беркадәр мәгълүмат бирелә.

Ә. Исхак хезмәтендә бик аз гына телгә алынган синонимия күренеше 1971 елда шактый тулы итеп С.Г. Әмиров хезмәтендә анализлана. Галим шагыйрь иҗатында 5000 чамасы сүзне эченә алган 1300ләп синонимик оя булуын искәртә һәм рус галиме М.Ф. Палевская хезмәтенә таянып, аларны өч зур төркемгә бүлеп бирә:

а) семантик синонимнар – стилистик нейтраль сүзләр: *абзый – агай – ага – абый* һ.б.

б) стилистик синонимнар. Мәсәлән, *алпавыт – бояр – дворян – помещик* һ.б.

в) семантик-стилситик синонимнар: *акыру – кычкыру – бакыру* һ.б.

Галим семантик синонимнарны, сүз төркемнәрен нигез итеп алып, дүрт өлешкә (исем; сыйфат; фигыль; рәвеш һәм сыйфат) бүлеп тикшерә. Мисалларга нигезләнеп, автор югарыда телгә алынган өч төркем арасында стилистик синонимнарның күләм ягыннан зур урын алып торуын искәртә. Чөнки стилистик синонимнар, беренче чиратта, гарәп-фарсы һәм рус алынмалары исәбенә баеса, икенчедән, диалекталь һәм гади сөйләм сүзләре дә бу төр синонимнар рәтен баета [3, б. 51–52]. Әмма, галим фикеренчә, Г. Тукай иҗатында кулланылган синонимнарның кайсы гына төрен алсак та,

аларның төп нигезе булып татар теленең көнкүреш, фольклор әсәрләрендәге лексик берәмлекләр белән баетылган үз сүзлек хәзинәсе тора. Г. Әмировның әлеге мәкаләсендә Г. Тукай иҗатында кулланылган синонимик ояларның шактый бай сүзлеге дә китерелә [3, б. 55–61].

Синонимнардан соң С.Г. Әмиров омонимия, антонимия күренешләренә туктала, аларны сан ягыннан ачыклый, төркемнәргә бүлеп анализлый. Омонимнарга килгәндә, галим аларның чагыштырмача аз булуын билгеләп уза: 200ләп чамасы омонимик берәмлек булуы телгә алына, антонимнарның исә шактый күп булуы ачыклана. Г. Әмиров бу күренешне шагыйрьнең җәмгыятьтәге тигезсезлек, хәерче һәм бай, надан һәм укымышлы һ.б. бик күп күренешләрне каршы куеп сурәтләвенә бәйләп аңлата. Дөрес, бүгенге көндә татар телендә синонимия, антонимия күренешләре галимнәр тарафыннан, инвариант һәм инвариантның парадигмаларына нигезләнеп, яңача аңлатыла [5; 5]. Мәсәлән, күренекле тел галиме И.Б. Бәширова хезмәтләрендә синонимия күренеше денотат-сигнивикат белән бәйле теориягә нигезләнеп тасвирлана һәм язма чыганаклардан китерелгән күпсанлы мисаллар белән дәлилләнә [7, б. 265 – 314]. Соңгы елларда Г. Тукай иҗатында синонимнарның кулланылыш үзенчәлекләре Э.Н. Денмухаметова мәкаләсендә дә барлана. Автор Тукай шигырьләрендә очраган синонимик берәмлекләрне абсолют, парлы, семантик (идеографик) һәм мәгънәсе буенча якын торган синонимнар дип, берничә төргә бүлеп анализлый, шагыйрь иҗатыннан мисаллар китерә. Автор фикеренчә, шагыйрь синонимнарны фикерен төгәлрәк җиткерү, образлар-вакыйгаларга төрле яклап бәя бирү, персонажларның шәхси сыйфатларын тулырак ачу һәм, әлбәттә, кабатлаулардан арыну максатларында кулланган [9, б. 242–244]. Г. Тукай лексикасының кабатланмас байлыгын тәшкил иткән омонимик һәм антонимик берәмлекләрне тикшерү бүгенге көндә дәвам итми дисәк дөрес булыр.

Югарыда телгә алынган чаралардан тыш, Г.С. Әмиров шагыйрь иҗатында киң кулланылган башка тел чараларын да аерым-аерым тукталып анализлый. Чагыштыру, эпитет, метафора, аллегория, гипербола, символ, җанландыру, градация, гротеск һәм анафора, эпифора кебек стилистик фигуралар, инверсия, риторик сорау, риторик өндәү кебек синтаксик чаралар – барысы да Г.С. Әмиров хезмәтендә чагылыш таба. Галим әлеге сурәтләү чараларын ясауда катнашкан лексик берәмлекләрне күпсанлы мисалларга таянып анализлавы белән Г. Тукай иҗатының кабатланмас булуын дәлилләргә омтыла. Дөрес, Г.С. Әмиров тикшергән тел-сурәтләү чараларының байтагы бүгенге көндә башкача тикшерелергә, анализланырга мөмкин. Әмма, ничек кенә булмасын, Г. Тукай иҗатының лексик һәм стилистик үзенчәлекләрен бүгенге көндә Г.С. Әмиров кадәр төрле яклап тикшергән, өйрәнгән монографик хезмәтләр юк. Дөрес, бүгенге көндә дә Г. Тукай шигъриятенең тел-стиль үзенчәлекләрен тикшерү төрле яклап дәвам итә.

Тукайның бер үк сүзне төрле мәгънә төсмерләре бирү өчен файдалана белү осталыгы күренекле тел галиме В.Х. Хаков хезмәтләрендә югары бәяләнә. Г. Тукай әсәрләрендәге полисемия, контекстуаль синонимнар, фразеологик әйтелмә, чагыштыру, кабатлау һ.б. лексик-фразеологик чараларның кулланылышы галим тарафыннан мисаллар белән тасвирлана. Автор лексик берәмлекләрнең күчерелмә мәгънәдә кулланылышы барыннан да бигрәк шагыйрьнең сатирик әсәрләрендә зур урын алып торуын искәртә [15, б. 285]. Ф. Сафиуллина шагыйрьнең, башка лексик чаралар белән беррәттән, кабатлауларны бик оста куллануын игътибарга ала: «Алар ярдәмендә шагыйрь фикерне үстерә, көчәйтә, актуальләштерә, сөйләмне интонацион яктан баета, төрлеләндерә, халыкның җанлы сөйләменә якынайта» [12, б. 263]. Тукай телендәге аерым лексик берәмлекләрнең кабатлануын, кулланылу ешлыгын тикшерү барышында галимнәр, шагыйрьнең теге яки бу лексик берәмлекне кабатлау аша шигырьнең эмоциональлеген, поэтик җанлылыгын арттыруга ирешүен дә раслыйлар. Теге яки бу сүзнең төрле мәгънәләрдә килә алуы да аның ешлыгы артуына китерә һәм бу шагыйрь иҗатының лексик үзенчәлеге булып тора, диләр авторлар [13, б. 297, 303].

Мәгълүм булганча, көлкеле образлар тудыру, думаны, патша кешеләрен, наданлыкны тәнкыйтьләү максатыннан Г. Тукай, башка сурәтләрү чаралары белән беррәттән, чагыштыруларга да еш мөрәҗәгать иткән. Шагыйрьнең сатирик әсәрләрендә кулланылган чагыштырулар Ф.А. Абдуллина мәкаләсендә тикшерелә. Автор фикеренчә, «Китмибез», «Мужик йокысы» һ.б. шигырьләрдәге чагыштырулар Тукайга капиталистик дөньяны төрле яклап сурәтләргә, халыкны ачлыкта басылып яшәргә мәҗбүр иткән сәбәпләрне ачарга ярдәм итә [1, б. 226–228].

Г. Тукай тарафыннан мул кулланылган лексик берәмлекләрнең тагын берсе – фразеологизмнар. Бу төр лексик берәмлекләр узган гасыр башында ук галимнәрнең игътибарын үзенә җәлеп итә. Күренекле галим Г. Шәрәф 1913 елда 170 кә якын афористик берәмлекләрне туплап «Тукаев сүзләре» дигән җыентык бастыра. Г. Шәрәф әлеге җыентыгында Тукай кулланган канатлы гыйбарәләрне 13 тематик төркемгә аерып бирә. Г. Тукай иҗатының афористик берәмлекләрен туплау юнәлшендә бу хезмәт беренче тәҗрибә булган дисәк тә ялгышмабыз. Соңрак, XX гасыр урталарына таба, Тукай әсәрләрендәге халык авыз иҗаты үрнәкләрен телче галимнәр игътибарга ала. Мәсәлән, шагыйрьнең фразеологик берәмлекләр белән мәкаль-әйтемнәрне әсәр тукымасына үтемле итеп кертеп җибәрә белү осталыгы Ш.А. Рамазанов тарафыннан күрсәтелә, «Шүрәле», «Төрекчәдән», «Катиле нәфескә» һ.б. шигырьләреннән мисаллар китерелә [11, б. 66]. Шагыйрь иҗатындагы барлык фразеологик әйтемнәрне туплап, тирәнтен анализлау юнәлешендә исә Г.С. Әмиров зур эш башкара. Аның докторлык диссертациясенең тулы бер бүлеге фразеологик әйтелмәләрне тикшерүгә багышланган. Галим Тукай фразеологиясенең төп чыганаклары итеп, беренче чиратта, халык сөйләмен, икенчедән, «Йосыф вә Зөләйха», «Кисекбаш» әсәрләреннән килә торган китап фразеологиясен күрсәтә. Автор Г. Тукай фразеологиясен, В.В. Виноградов хезмәтенә нигезләнеп, ике зур төркемгә бүлеп анализлый. Галим искәрткәнчә, Тукайның зур осталыгы халык фразологиясен үзгәртеп куллануда, яисә үз әйтемнәрен ясауда ачык күренә. Автор фикеренчә, шагыйрь канатлы гыйбарәләрне куллану җәһәтеннән аеруча соңгы елларда иҗат ителгән шигырьләрендә зур осталыкка ирешә [2, б. 42–49]. Хезмәтенең соңгы бүлекләрендә галим Тукай фразеологиясен төркемнәргә бүлә, аларның поэтик-стилистик функцияләрен күрсәтә, метафора, метонимия, чагыштыру һәм җанландыру кебек чаралар ролендә кулланылуын мисаллар белән дәлилли. Шагыйрьнең фразеологизмнарга еш мөрәҗәгать итүен галим болай дип аңлата: «Фразеологизмы привлекли поэта особенно и тем, что в них содержится осуждение, критика и осмеяние различных пороков, против которых он активно боролся» [2, б. 51]. Галим Тукай фразеологиясен анализлау белән генә чикләнмичә, аларның сүзлеген дә төзеп, кушымта буларак тәкъдим итә.

Г.С. Әмировтан соң Г. Тукай иҗатындагы канатлы гыйбарәләрне махсус алып анализлаган хезмәтләр юк. Дөрес, В.Х. Хаков, Ф.С. Сафиуллина хезмәтләрендә, башка лексик берәмлекләр белән беррәттән, фразеологизмнарга да күзәтү ясала. Мәсәлән, В.Х. Хаков Тукай иҗатында очраган канатлы әйтемнәргә мисаллар китереп, шагыйрь иҗатында әлеге лексик чараларның зур роль уйнавын искәртә: «Г. Тукайда фразеология югары яңгырашка һәм гадилеккә ирешүгә хезмәт итә...» [15, б. 284].

«Шагыйрь иҗатында татар халык мәкальләре, фразеологиясенең гаять бай чагылышын күрергә мөмкин» дип, Ф.С. Сафиуллина да шагыйрь иҗатының афористик берәмлекләр бай булуын әйтеп уза [12, б. 266].

Югарыдан күренгәнчә, Г. Тукай иҗатында сүз-сурәт яисә образ тудыру чарасы буларак кулланылган лексик берәмлекләр татар тел белемендә шактый өйрәнелгән, бу юнәлештә аеруча Г.С. Әмировның хезмәтләре ихтирамга лаек. Әмма шуңа да карамастан, Тукай иҗатының лексик байлыгын шагыйрьнең дөньяга карашы, хис-тәэссирләре, рухы белән бәйләнештә тикшергән һәм аерым китап буларак басылып чыккан, дөнья күргән хезмәтләр юк. Шуңа күрә дә Г. Тукай шигъриятенең милли моң белән сугарылган лексик байлыгын яңа фәнни карашлардан чыгып тикшерүне дәвам итү бүгенге көндә дә актуаль булып тора.

ӘДӘБИЯТ


1. Абдуллина Ф.А. Сравнени в сатирических произведениях Г. Тукая // Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар. Казан, 2011. Б. 226–228.

2. Амиров Г.С. Язык Тукая (Лексика и фразеология): автореф. дис. ...докт. филол. н. Алма-Ата, 1968. 72 с.

3. Амиров Г.С. Синонимы в произведениях Г. Тукая // Тюркская лексикологи и лексикография. М.: Наука, 1971. С. 47–60.

4. Амиров Г.С. Ономастика Тукая // Ономстика Поволжья: Сборник материалов 1-ой Поволжской конференции по ономастике. Ульяновск, 1967. С. 68–74.

5. Бәширова И.Б. Хәзерге татар әдәби теле. Семасиология: татар лексикасында системалы бәйләнеш-мөнәсәбәтләр. Казан, 2006. 192 б.

6. Бәширова И.Б. XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби теле һәм Г. Тукайның башлангыч чор иҗаты // Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар. Казан, 2011. Б. 207–210.

7. Бәширова И.Б. Татар әдәби теле. Семасиология. Казан, 2010. 532 б.

8. Вәлитова Й. Тукай шигырьләренең теле турында берничә сүз // Казан утлары. 1969. № 3. Б. 169–173.
9. Денмухеметова Э.Н. Синонимы в поэзии Г. Тукая // Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар. Казан, 2011. Б. 242–245.
10. Исхак Ә. Тукайның шигъри осталыгы. Казан: Татар.кит.нәшр., 1963. 126 б.
11. Рамазанов Ш.А. Тукай һәм хәзерге татар әдәби теле // Габдулла Тукай: шагыйрьнең тууына 60 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары. Казан: Татгосиздат, 1948. Б. 136–170.
12. Сафиуллина Ф.С. Тукай әсәрләрендә җанлы сөйләм теле // Тукай һәм XX гасыр мәдәнияте. Казан, 1997. Б. 254–258.
13. Сафиуллина Ф.С., Ризванова Л.М. Тукай теленең ешлык сүзлеген төзү тәҗрибәсеннән // Тукай һәм XX гасыр мәдәнияте. Казан, 1997. Б. 297–303.
14. Хаков В.Х. Тукай әсәрләренең телен һәм стилен өйрәнү // Совет мәктәбе. 1966. № 4. Б. 29–35.
15. Хаков В.Х. Татар әдәби теле тарихы. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1993. 324 б.

## ТАТАР ҺӘМ РУС СТУДЕНТЛАРЫ АҢЫНДА ТУКАЙ ОБРАЗЫНЫҢ ГӘҮДӘЛӘНЕШЕ
### (ассоциатив эксперимент нәтиҗәләре)

***Габдрахманова Ф.Х., Исламова Э.А.***

В данной статье представлен лингвокультурологический анализ ассоциативного поля лексемы *Тукай*, сформированного реакциями современных татаро- и русскоязычных студентов.

This article is devoted to a linguistic and culturological analysis of the associative field *Tykay* formed by reactions of modern Tatar and Russia speaking.

Габдулла Тукай – татар халкының кабатланмас талантка ия булган үткен телле, батыр йөрәкле бөек шагыйре. Аның иҗаты турында бик күп фәнни мәкаләләр язылуга карамастан, иҗатының күпкырлылыгын, кыйммәтен, әһәмиятен дәлилләүче яңадан яңа тикшеренүләр әле дәвам итә, кызыклы мәгълүматлар ачыкланып тора.

Шул нисбәттән без дә әлеге хезмәтебездә Тукайны лингвокультурологик аспектта өйрәнергә алындык. Моның өчен әлеге өлкәдә еш кулланылучы ирекле ассоциатив эксперимент методына мөрәҗәгать иттек. Мәгълүм булганча, ассоциатив эксперимент билгеле бер телдә сөйләшүчеләрнең, үткәндәге тәҗрибәсенә нигезләнеп, теге яки бу күренешкә карата мөнәсәбәтләрен ачыклый.

Безнең ирекле ассоциатив экспериментта КФУның Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында укучы татар һәм рус милләтеннән булган 18–24 яшьлек 100 ләп студент катнашты. Аларга *Төркия, яз, шайтан* лексемалары белән аралаштырылып *Тукай, Шүрәле, Су анасы* сүзләре тәкъдим ителде. Татар телле студентлардан алынган җавапларны карап үтик:

**Тукай** – Шүрәле **11,** шагыйрь **9**, Кырлай **6**, туган тел **5**, И туган тел **4**, һәйкәл **3**, шигырь **3**, бөек шагыйрь **2**, Исемдә калганнар **2**, Габдулла **1**, белем **1**, егет **1**, кәҗә **1**, китап **1**, милләт **1**, Пар ат **1**, сагыш **1**, татар **1**, татар шагыйре **1**, тел **1**.

**Шүрәле** – урман **14**, Тукай **13**, мөгез **5**, әкият **4**, Кырлай **4**, бүрәнә **2**, Былтыр **2**, Су анасы **2**, балачак **1**, балачак әкияте **1**, бүрәнә һәм бармак **1**, җен **1**, йонлы **1**, китаптагы иллюстрация **1**, куркыныч **1**, кытыклаучы **1**, озын тырнак **1**, ябык **1**.

**Су анасы** – тарак **16**, Тукай **9**, озын чәч **5**, алтын тарак **4**, әкият **4**, басма **3**, күл **2**, озын толым **2**, алтын **1**, Алтынчәч **1**, Бауман урамы **1**, карак малай **1**, Кырлай **1**, малай **1**, сулык **1**, төнбоек **1**, чәчлебикә **1**, Шүрәле **1**.

Сораштыру нәтиҗәләреннән күренгәнчә, күпчелек аңында Тукай *шагыйрь, бөек шагыйрь, татар шагыйре* булып гәүдәләнә. *И туган тел, туган тел, милләт, татар, тел* кебек җаваплардан шагыйрьнең татар милләтенең тугърылыклы улы буларак кабул ителүе аңлашыла. Иҗатыннан «Шүрәле», «И туган тел», «Пар ат» шигырьләренең студентлар аңында күбрәк беркетелеп калуы күренә. *Кырлай, Исемдә калганнар* кебек җаваплар – Тукайның биографиясе белән бәйле ассоциатлар.

Любопытно, что в этой коллегии в качестве старшего кандидата служил и Богородицкий Василий Алексеевич (1857–1941) – профессор Казанского университета, он работал в области языкознания, фонетики. Среди множества трудов у него есть и «Введение в татарское языкознание в сравнении с другими тюркскими языками» (1934). Этот труд на филологических факультетах вузов изучается по настоящее время.

А самое интересное, Богородицкий создал первую в России экспериментально-фонетическую лабораторию при Казанском университете, применял экспериментально-фонетический метод к изучению ритма русского языка. Там работал и Катанов, туда ходил и наш Тукай! Об этом пишет народный артист Башкирии, композитор Л. Эйхенвальд: «В 1911 годах, когда я вместе с Н.Ф. Катановым работал в университете в кабинете экспериментальной фонетики, часто встречался с Тукаем…» [11]. Далее он пишет, что в первые же встречи Тукая заинтересовала работа композитора по «гармонизации народных песен». Вот где могли встретить Тукая и Катанов, и Богородицкий.

Примем во внимание и то, что Н. Катанов в Каз. суд. палате был членом экспертной комиссии, присутствовал на заседаниях. Он, как высокообразованный человек, профессор, конечно же имел большой авторитет в коллегии, прислушивались к его словам. Катанов, как осведомленный человек в проблеме, касающейся Тукая, смог убедить членов Судебной палаты, что Г. Тукай очень талантливый поэт, что в его стихах ничего крамольного, что он просто верный сын своего народа и, наконец, он серьезно болен. Думается, Н. Катанов при защите Тукая в Каз. суд. палате имел поддержку и в лице Богородицкого, как члена коллегии.

Неизвестно, как бы сложилась судьба Тукая, если бы рядом не был такой ценитель его таланта как цензор Катанов.

Таким образом, с уверенностью можно сказать, что Тукая от тюрьмы спас цензор Н.Ф. Катанов.

С большим сожалением приходится констатировать тот факт, что ни в одном из музеев Тукая в Татарстане не увидишь ни документов о тех страшных для Тукая днях, не услышишь ни рассказа. Даже в главном музее Тукая в Казани плохо ведают об этом периоде жизни поэта. Не ведется научная работа, не изучается архив, более того, не интересуются даже уже описанными, 30 лет тому назад опубликованными, «готовыми» материалами. В экспозиции музея нет и преследуемого сборника «Стихотворения Габдуллы Тукая» – 4-я тетрадь (1907 г.). При музее создан научный совет, которым всегда руководили доктора наук. Однако каждый раз при обновлении экспозиции забывается период преследования Тукая.

В 2012 году на трех языках (на татарском, русском и английском) был издан каталог «В реликвиях – душа Тукая». «Каталог представляет мемориальную коллекцию татарского народного поэта Г. Тукая, сформировавшуюся в Национальном музее Республики Татарстан. Он включает личные вещи, подлинные фотографии, фотооткрытки и пожизненные издания произведений поэта». К сожалению, в этом богатом содержанием каталоге вы не увидите тот самый знаменитый сборник «Стихи Габдуллы Тукая» (4-я тетрадь), изданный в 1907 г., сборник, который стоил Тукаю глубоких потрясений. Научный совет и здесь не смог подсказать, посоветовать....

Жизнь Тукая была слишком короткой. Поэт сам сказал: «Минем һәр минутым бөтен дөнья бәһасенә тора» («Каждая минута моей жизни стоит вечности»). Каждый миг жизни Тукая должен быть нами изучен, осмыслен и освещен.

ӘДӘБИЯТ

1. ЦГА ТР. Ф. 420, оп. 1.
2. ЦГА ТР. Ф. 199, оп. 1, д. 3458.
3. ЦГА РТ. Ф. 199, оп. 1, д. 2086.
4. ЦГА РТ. Ф. 199, оп. 2, д. 1237.
5. ЦГА РТ. Ф. 420, оп. 1, д. 179.
6. ГАСО. Ф. 51, оп. 1, д. 44, л. 59 об.
7. ЦГА РТ. Ф. 199, оп. 1, д. 2425.
8. ЦГА РТ. Ф. 19, оп. 1, д. 2848.
9. «Казан утлары». 1966. № 7.
10. ЦГА РТ. Ф. 51, оп. 7.
11. «Красная Башкирия». 1946. 27 апреля.

## ТУКАЙ БЕЛӘН БӘЙЛЕ КАЙБЕР ЭПИГРАФИК ИСТӘЛЕКЛӘР

***Гайнетдинов А.М.***

Статья посвящена изучению некоторых татарских надгробных камней начала XX в., сохранившихся в Арском районе Республики Татарстан. Эти памятники установлены на могилах людей, которые были тесно связаны с жизнью Габдуллы Тукая. Автор лично выявил, исследовал и дал расшифровку их текстов.

The article is devoted to the study of some of the Tatar gravestones of the early XX century, preserved in Arsky district of the Republic of Tatarstan. These monuments are set on the graves of people who were closely connected with the life of Gabdulla Tukay. The author personally identified, researched and gave the transcript of their texts.

Бөек татар әдибе Габдулла Тукай ватаны – Арча төбәгенең борынгы каберташлары әле һаман фәнни-практик яктан тулысынча өйрәнелмәгәнгә, андагы татар авылларының зиратларында һәм аерым каберлекләрендә хәзерге көннәргә кадәр юкка чыкмыйча сакланып калган бөтен ташъязма истәлекләрне барлау һәм өйрәнү өчен узган ел без берничә фәнни экспедициягә чыктык. Эш дәвамында бигрәк тә Г. Тукай белән бәйле шәхесләрнең кабер ташларына игътибарыбызны юнәлттек: Кушлавыч, Өчиле, Яңа Кырлай авылларындагы эпиграфик истәлекләр җентекләп өйрәнелде.

Өчиле саласы зиратында Тукай нәселенә бәйле кабер ташлары табылмады. Анда фәкать ике генә гарәп язулы ташъязма истәлек барлыгы ачыкланды: берсе 1917 елда вафат булган Мөхәммәдгали Габделгафур улына, икенчесе 1927 елда үлгән Миңнежамал Муса кызына куелган. Ташъязма истәлекләрнең бик аз булуы, нигездә, теге яки бу торак пункт халкының ярлылыгын күрсәтә. Гадәттә, ташбилгеләрне бай югары катлау

вәкилләре куйган, чөнки аларны эшләтү бик кыйммәткә төшкән. Элекке заманнарда бер таш яздыру бер ат, югары зәвык белән ясалганы берничә ат бәясенә тиң булган [3, б. 56]. Шуңа күрә гади халыкның фәкать тамгасы төшерелгән кечкенә агач багана яки эшкәртелмәгән примитив бер таш кына куярга хәле җиткән. Өчиле авылы бай авыл булмаган, халкы фәкыйрьлектә яшәгән, шуңа күрә Зиннәтулла бабай оныгын, матди яктан тәэмин итәргә көче җитмичә, асрамага биреп җибәрергә мәҗбүр булган.

Г. Тукайның туган авылы Кушлавыч зиратында алты ташъязма истәлек табылды. Мәгълүм булганча, биредә Тукайның атасы Мөхәммәдгариф Мөхәммәдгалим улы җирләнгән. Кызганычка каршы, аның элек куелган каберташы сакланмаган (бәлки, бөтенләй булмагандыр да), аның урынына яңа бер мәһабәт мәрмәр таш яздыртып куелган. Тексты яртылаш гарәп графикасында, яртылаш кириллицада язылган:

Алгы ягы (уеп язылган):

1) «Мөхәммәдгариф
2) Мөхәммәдгалим углы
3) Тукайыф,
4) шагыйрь Габдулла
5) Тукайыфның этисе.
6) Мөхәммәтгариф
7) Мөхәммәтгалим
8) улы
9) Тукаев
10) 1842–1886,
11) шагыйрь Габдулла
12) Тукаевның этисе».

Мөхәммәтгариф хәзрәтнең кабере дә төгәл билгеле булмаган һәм аны бер буш җиргә бастырып куйганнар һәм чардуган тотканнар. Шунысы билгеле: аның каберенең урыны Габделхәер хәзрәт Габделкәрим улыныкы янында булырга тиеш. Әлеге кабер иясе Г. Тукайның этисеннән соң 1886–1901 елларда Кушлавычта имам булып торган. Аны Хәертдин мулла дип йөрткәннәр. Ул Кышкар мәдрәсәсен тәмамлаган, Черки-Кильдураз авылы (хәзер Татарстанның Буа районына керә) кешесе булган. Беренче имам Мөхәммәтгалим Шәмсетдин улы сукыраеп, муллалык эшен башкара алмаганга һәм аның улы – икенче имам Мөхәммәтгариф Мөхәммәтгалимов вафат булганга, Габелхәер хәзрәт авыл байлары тырышлыгы белән 1886 елның октябрендә Кушлавычка мулла итеп билгеләнгән. Аның кабере янында гына куеланып канәфер куаклары үскән. Авыл картлары хәтерләгәнчә, Г. Тукайның атасы Мөхәммәтгариф хәзрәтнең дә кабере шунда икән [1, б. 12–13].

Габелхәер муллага куелган каберташны без эзләп таптык һәм шул рәвешле Тукайның атасы каберенең урынын, якынча гына булса да, ачыкладык, дияргә нигез бар. Бу турыда Кушлавыч авылындагы Г. Тукай музее хезмәткәрләренә дә хәбәр иттек һәм Габделхәер хәзрәткә куелган ташның фотосын һәм текстының укылышын тапшырдык. Анда түбәндәге сүзләр язылган иде:

Алгы ягы (уеп язылган):

1) «Һувәл-бәәкыый
2) Габделхәйер Габделкәрим углы Тәтеш
3) өязе Килдураз авылыйның Кушлавычда
4) 15 йыл имам булыб 1901 нче йылда 4 нче
5) ийүндә 45 йәшендә вафат булды әнкәсе 2 хатыны
6) 2 сабый 3 сабыйәсе калды Аллаһ Тәгалә рәхмәт әйләсүн».

Уң ягы (уеп язылган):

1) «Илаһи мәгъфирәт кыйл Раббы йәздан
2) бихәккый гаршин гәзыймин нуури куръәән».

Сул ягы (уеп язылган):

1) «Һиҗриййә илә
2) 1319 нчы
3) йылда 5 нче сәфәр-
4) -ел-хәйердә вафат».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе:

Алгы ягы:

1) «Ул [Аллаһ] – мәңге.
2) Габделхәер Габделкәрим улы Тәтеш
3) өязе Килдураз авылыннан, Кушлавычта
4) 15 ел имам булып, 1901 елның 4
5) июнендә 45 яшендә вафат булды; әнкәсе, 2 хатыны,
6) 2 сабый улы, 3 сабый кызы калды. Аллаһ Тәгалә рәхим кылсын».

Уң ягы:

1) «Илаһым, гафу ит, Раббым Аллаһ,
2) бөек гареш, Коръән нуры хакы белән».

Сул ягы:

1) «Һиҗри белән
2) 1319
3) елның 5 сәфәр-
4) -ендә вафат».

Таш үлчәмнәре: 90×35×15.

Г. Тукайның анасы Балтач районы Сасна Пүчинкәсе (Кече Сасна) авылында җирләнгән. Аның каберендә башта каберташы булмаган, соңра үткән гасырның 80 нче елларында тарихчы-археолог Р. Фәхретдинов тырышлыгы белән әдибнең анасы истәлегенә яңа таш мемориал (авторы Р. Билалов) куелган. Мәмдүдәнең кабере «Шакир мулла җыены» дигән урында, ягъни әлеге мулланың гаиләсе күмелгән бер җирдә табылган. Анда 1916 елда 97 яшендә үлгән Шакир хәзрәт һәм аның Мәмдүдәдән тыш тагын ике хатыны шул бер тирәдә җирләнгән булган [4, б. 120–121].

Арча районы Яңа Кырлай авылы зиратында хәзерге көндә 22 эпиграфик истәлек саклануы ачыкланды. Г. Тукайның туганнарына куелган борынгы кабер ташлары табылмаса да, аның иң беренче укытучылары буларак тарихка кереп калган Фәтхерахман Гатаулла улы һәм Маһруйбикә Мөхәммәдлатыйф кызына куелган кабер ташын ачыкладык**.** Фәтхерахман хәзрәт 1857 елның 9 августында дөньяга килгән. Ул 1899 елның 20 октябрендә атасы урынына авылга имам булып калган. Аның кыска гына шәҗәрәсе түбәндәгечә: Фәтхерахман бине Гатаулла бине Гобәйдулла. 1892 елның көзендә Г. Тукай Маһруйбикә абыстайда укырга-язарга өйрәнә, ә инде 1893 елда Тукай Фәтхерахман хәзрәттә укый башлаган [2, б. 163]. Тик, белгәнебезчә, озакламый аңа Яңа Кырлайны калдырып китәргә туры килгән һәм шул рәвешле бирерә белем алуы өзелгән. Фәтхерахман мулла – «чак кына билдән бөгелеп йөргән, кечерәк кенә буйлы, очланып төшкән сирәк ак сакал-мыеклы, күзен кысыбрак кына көлемсерәп сөйләшә торган карт» [1, б. 7] булган. Ул Г. Тукайның атасы белән бергә Кышкар мәдрәсәсендә гыйлем алган.

Фәтхерахман Гатаулла улы һәм Маһруйбикә Мөхәммәдлатыйф кызына куелган каберташ текстның укылышы түбәндәгечә:

Алгы ягы (уеп язылган):

1) «Әл-мәүтү гыйбраһ
2) мулла Фәтхерахман
3) мулла Гатаулла
4) углы 55 йыл
5) имамчилек кыйлыб
6) 77 йәшендә
7) 1929 нчы йылда
8) ийүн 16 нда вафат
9) Аллаһ рәхмәт кыйлсун».

Арткы ягы (уеп язылган):

1) «Бу җанибендә
2) Маһруйбикә
3) Мөхәммәдлатыйф
4) кызы 73 йәшендә
5) 1933–23/I
6) вафат

7) Аллаһ рәхмәт
8) кыйлсун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе:
Алгы ягы:
1) «Үлем – гыйбрәт.
2) Мулла Фәтхерахман
3) мулла Гатаулла
4) улы, 55 ел
5) имамчылык кылып,
6) 77 яшендә
7) 1929 елның
8) 16 июнендә вафат.
9) Аллаһ рәхим кылсын».

Арткы ягы:
1) «Бу ягында
2) Маһруйбикә
3) Мөхәммәдлатыйф
4) кызы 73 яшендә
5) (1933–23/I)
6) вафат.
7) Аллаһ рәхим
8) кылсын».

Таш үлчәмнәре: 78×31×11.

Г. Тукай тәрҗемәи хәлен, эшчәнлеген һәм иҗатын өйрәнгәндә аның тормышы белән бәйле шәхесләрнең берсен дә игътибардан читтә калдырырга ярамый. Шуңа күрә без, бөек әдибебез турында материалны җыю һәм тулыландыру йөзеннән, архив документларны, хатирәләрне, язма чыганакларны гына түгел, эпиграфик истәлекләрне дә барларга һәм өйрәнергә тиешбез. Гомумән, тарихи чыганак буларак гарәп язулы каберташларның әһәмияте әйтеп бетергесез, шуңа күрә безгә аларны ничек булса да саклап калу зарур.

ӘДӘБИЯТ

1. Рәсүлева З.Ә. Тукай эзләреннән. Казан: Тат. кит. нәшр., 1985. 141 б.
2. Салихов Р.Р., Хайрутдинов Р.Р. Республика Татарстан: Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII – начало XX веков). Казань: Фест, 1994. 280 с.
3. Усманов В.М. Тарихи ядкәрләр. Уфа: ДизайнПолиграфСервис, 2005. 168 б.
4. Фәхретдинов Р. Мондадыр безнең бабайлар: Археолог язмалары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. Б. 120–121.

## «БЕЗГӘ КИРӘК ДИҢГЕЗ ТӨБЕ ГАУВАСЛАРЫ...»

***Гайнуллина Г.Р.***

В статье анализируется публицистика татарского классика А. Еники, где автор дает оценку личности и творчеству Г. Тукая в контексте татарской культуры и литературы XX века. В статьях, написанных 60–80-х г.г. XX в., А. Еники затрагивает проблему сохранения национальной культуры. Писатель ставит вопрос увековечения наследия Г. Тукая, памятников культуры, связанных с именем великого татарского поэта.

The article examines the journalism of the tatar classics A. Eniki, where the author gives an assessment of the personality and works of G. Tukay tatar in the context of the culture and literature of the twentieth century. In articles written in 60–80-ies of XX century A. Eniki concerns the problem of preservation of national culture. The writer raises the question of the perpetuation of the cultural monuments associated with the name of the great tatar poet.

XX йөзнең икенче яртысы әдәбиятындагы яңарышка юл сызган татар әдибе Әмирхан Еники XX йөз башы татар әдәбияты һәм үзе яшәгән дәвер арасында күпер булдырган әдип. Халык язучысы, Г. Тукай бүләге иясе, милли нигезләргә кайту әдәбиятының

башында торган әдип «XX башында туып, 1917 еллар инкыйлаплары белән үсүдән тук-таган яңалыкларны, эзләнүләрне» [2, б. 18] үз иҗатында үстереп, тергезеп җибәрә.

Публицистик язмаларында, мәкаләләрендә Ә. Еники еш кына Г. Тукай һәм аның замандашларына мөрәҗәгать итә. Язучының 1960–1980 еллар аралыгындагы публицистикасында Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, С. Сүнчәләй, Ф. Ильская һ.б. шәхесләр белән бәйле истәлекләр, аларның иҗатына мөнәсәбәт белдергән язмалар бар.

Г. Тукай шәхесенә һәм иҗатына әдип даими рәвештә мөнәсәбәт белдереп бара. «Бер генә минутка фараз итик: безнең тарихыбызда Тукай юк, Тукай булмаган ди... Никадәр ярлыланып калыр идек без, күпме дан-дәрәҗәбезне югалтыр идек!.. Әмма язмышка мең мәртәбә рәхмәт, безнең Тукаебыз бар!» [1, б. 20] – дип яза ул 1968 елда «...Йолдыз кеби» дигән язмасында.

Балачакта әле хәреф танымаган Әмирханга С. Сүнчәләй очраклы рәвештә генә Г. Тукай китабын бүләк итмәгәндер, дип фараз кылырга урын кала. «Г. Тукайның «Сәгыйть абый бүләк иткән «Су анасы» минем өчен чын мәгънәсендә тел ачкычы булды… Ихтимал, минем язучы булып китүемә дә аның берәр хикмәтле яшерен йогынтысы булмый калмагандыр» [1, б. 34], – дип яза ул «Дуслар белән бер сөйләшү» дип исемләнгән язмасында.

Ә. Еники Г. Тукайны «милли горурлыгыбыз» дип атый: «Даһиларны халык тудыра – бу бәхәссез, ләкин даһилар да үз нәүбәтендә туган халыкларына дан-шөһрәт китерә – бу да бик билгеле хакыйкать. Шуңа күрә дә аларны халыкның милли горурлыгы дип әйтәләр. Тукай да безнең әнә шундый горурлыгыбыз, һәм без, бу хакта уйлап тормастан, һәрвакыт аны күңелебездә саклап, ничектер гел тоеп тоеп яшибез» [1, б. 20].

Көчле, олпат, милләтпәрвәр шәхесләр заманында тәрбияләнгән һәрбер иҗат кешесен әдип Г. Тукай исеме янәшәсендә бәяли: «С. Сүнчәләй – шагыйрь, Тукай замандашы, Тукай белән шактый якын мөнәсәбәттә булган һәм хатлар язышкан кеше» [1, б. 33]. Замандашлары иҗатын да Тукай йолдызына тиңләп, шул үлчәмгә сала. Ф. Хөсни турындагы язмасында: «Фатих туганда әле Тукай үзе исән була, ул Тукайның замандашлары белән аралашып кала», – дип ассызыклый.

Язучы өчен иң кирәкле сыйфат – халык күңелен бик нечкә, бик дөрес сизә белүдәдер, дип инанган татар әдибе Тукайны бу яктан да үрнәк итеп күрсәтә: «Менә безнең Тукаебыз бар. Шул ук вакытта аның заманында башка зур талантлы шагыйрьләр дә булган бит әле... Әмма ни өчендер бер Тукай халык күңеленә иң якын шагыйрь булып калган. Ни өчен? Мотлак, әнә шул халык күңелен бик нечкә сизә алу, халыкның иң тирәндә яткан өмет-теләкләрен «күрә» алу кодрәтенә ия булудандыр инде» [1, б. 33].

Әдип үзе яшәгән дәвердә Г. Тукай иҗатын мәңгеләштерү турында даими уйлана. Замандашы Ә. Фәйзинең Тукайга мөнәсәбәтенә соклануын белдерә, һәр татар кешесе өчен үрнәк итеп куя: «1958 елның 9 августында Габдулла Тукайга, ниһаять, һәйкәл ачылды. Тик тантанага җыелганнар арасында Әхмәт Фәйзи генә юк иде, каты авыру аңа бу тантанага килергә мөмкинлек бирмәде. Күпме еллар көтте ул бу көнне! Көтеп йөрү генә түгел, шушы һәйкәлнең төзелүенә булышты, скульпторга киңәшләрен бирде, урынын сайлашты... Әмма тантанага килә алмаса да, сөекле Тукаена соңгы хөрмәтен, соңгы сәламен әйтеп калдырды. Тантана башлангач, Афзал ага Шамов Ә.Фәйзинең һәйкәл ачылуга багышлап язган шигырен халыкка кычкырып укыды. Бөек шагыйрьгә булган гомерлек хөрмәтен Әхмәт Фәйзи әнә шулай матур-күркәм итеп күрсәтә белде. Ә ике көннән соң үзе дә мәңгегә күзләрен йомды...» [1, б. 100]. Ә. Еники Ә. Фәйзинең Тукай белән бәйле кайбер истәлекләрне китап итеп чыгарып калдыру тәкъдимен язып калдыра: «Ә. Фәйзи, Тукайның Сүнчәләйгә язган хатлары һәм һәм Сүнчәләйнең Тукайга багышланган истәлекләре, шигырьләре белән танышкач, боларның барысын да «Тукай һәм Сүнчәләй» дигән исем астында аерым бер китап итеп чыгарырга кирәк дип әйткән иде» [1, б. 17].

Ә. Еники «Казан миңа да кадерле» (1968), «Иске белән яңа» (1977) дип исемләнгән язмаларында Казан шәһәрендәге Г. Тукай белән бәйле кадерле, истәлекле урыннарны саклау, төзекләндерү мәсьәләсен көн кадагына куя: «Тиздән нәүбәт элеккеге «Болгар» номерлары белән «Шәрык клубы»на җитәр – берзаман аларны да сүтә башларлар. Әмма кирәк микән аларны бетерү? Тукаебызның кыска гына гомере шул биналар эчендә һәм тирәсендә узган» [1, б. 216], – дип борчыла татар әдибе. Ә. Еники борынгыны иске хәленә кайтарып саклау юлын тәкъдим итеп карый: «Болгар» – «Амур» тирәсен

Тукай, Камал, Әмирханнар заманын хәтерләткән бер мемориаль почмакка әйләндергәндә һич тә начар булмас иде. Еллар узган саен тарихи әһәмияте арта гына барачак» [1, б. 217]. «Кайбер җирләрдә тегермәнче, тимерче алачыгын да саклыйлар, ә болар – безнең мәдәни учагыбыз» [1, б. 217] – дип сызлана ул.

XX йөзнең икенче яртысында милли нигезләрне тергезгән татар әдибе Ә. Еники үз чорында Г. Тукай дигән «диңгезнең төбенә җиткәнче чума алганыбыз юк әле», дип чаң кага: «Ә анда күп ачылып бетмәгән гәүһәрләр ята. Менә шул гәүһәрләрне табып чыгарыр өчен, шагыйрь үзе әйтмешли, «безгә кирәк диңгез төбе гауваслары...» [1, б. 20].

Бүгенге көндә Г. Тукай мирасы гыйльми яктан системалы төстә өйрәнелә килә, шагыйрьнең исемен мәңгеләштерү эшендә дә алга китеш шактый. Бу турыда XX йөзнең 60–80 елларында кыю рәвештә, нигезләп фикер белдерә алган әдипләребез арасында Ә. Еникинең алдынгы сафларда торганын онытырга ярамый.


ӘДӘБИЯТ

1. Еники Ә.Н. Хәтердәге төеннәр: Мәкаләләр, очерклар һәм истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. 234 б.

2. Заһидуллина Д.Ф. XX гасырның икенче яртысы татар әдәбиятын өйрәнү мәсьәләсе // Әмирхан Еники һәм XX йөз татар әдәбияты. Казан: РИЦ «Школа», 2009. Б. 13–18.


## АЛТЫ ТОМЛЫ ГАБДУЛЛА ТУКАЙ «ӘСӘРЛӘР»ЕНЕҢ АКАДЕМИК БАСМАСЫНДА ЯҢА ӘСӘРЛӘР (алтынчы том мисалында)


***Галимҗанова Э.М.***



В данной статье рассматриваются три новых произведения, которые раньше не были включены ни в одно из полных собраний сочинений Г. Тукая. Речь идет о двух статьях поэта – «Пожар вакытында кызгану», «Дүнә вә Мишә» и одном четверостишии.

This article discusses three new works that were previously not included in any of the complete works of G. Tukay. The two articles of the poet – «Regret in the fire», «Dunya and Misha» and one quatrain.


Бөек шагыйребез Габдулла Тукай 1913 елның 14 мартында «Клячкин шифаханәсе»ндә ятканда язган «Уянгач беренче эшем» исемле мәкаләсендә соңгы җиде ел эчендә язган хезмәтләрен уйдан кичерә. Вакытлар үткәч, бар гомерен халкына хезмәт итүгә багышлавын аңлауларына өметләр баглап: «Килер заман, һәр язучының үзен, сүзен һәм шәхси тормышын инәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгарлар әле» дип яза [5, б. 259].

Үзе исән вакытта халык шагыйре исеме алган Тукайның иҗат мирасы үзе үлгәннән соң ук өйрәнелә башлап, бүгенге көннәргә кадәр дәвам итә. Беренчеләрдән булып, аның тормыш юлын һәм иҗатын җентекле өйрәнеп мәкалә язучы кеше – Җамал Вәлиди. Аның бу хезмәте Тукай үзе үлгәч, 1914 елда басылып чыккан «Габдулла Тукай мәҗмугаи асар»енә кереш мәкалә буларак урнаштырыла [1]. Тиздән шагыйрьнең иҗатын барлап, текстологик яктан эшкәртеп, фәнни басма эшләү кирәклеге дә кузгатыла. Бу эшнең башында Фатих Сәйфи-Казанлы төзегән өчтомлык (1929–1931) китабы тора. Әлеге басманың «Төзүчедән» исемле керешендә ул «Моңа кадәр, бик аз эшләмәгән зур бер язучының әсәрләрен бер басмада гына тулы итеп чыгару мөмкин эш түгел, чөнки бөек язучыларымызның әсәрләре үзләре соңында берничә ун еллар буенча колллектив көч белән тулыландырылалар» дип яза [4, б. 4]. 1939 елда оешкан Татар теле һәм әдәбияты фәнни-тикшеренү институты классикларыбызның мирасын җыйнап, фәнни-текстологик яктан өйрәнү, ягъни күптомлыклар әзерләү эшен башлап җибәрә. Беренче эш итеп, Тукай әсәрләрен күптомлы Академик басма итеп әзерләүгә керешелә. Әмма әлеге эшкә тиешле әзерлек җитмәү сәбәпле, әлеге басма Академик басма дәрәҗәсендә эшләнә алмый. Җыентык ике томлы булып, 1943 һәм 1948 елларда басылып чыга. Шул рәвешле, 1955–56 елларда – беренче дүрттомлыгы,

1975–77 елларда икенче дүртомлыгы дөнья күрә. Тукайның 100 еллык юбилее уңае белән биштомлы итеп әзерләнә.

Г. Ибраһим исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге әдәбиятчы галимнәре, текстологлары бүген дә язучыларыбызның әсәрләрен өйрәнү, фәнни-текстологик яктан эшкәртеп күптомлыклар әзерләү эше белән шөгыльләнә. XX гасырның 90 нчы елларыннан соң башланган үзгәрешләр нәтиҗәсендә, классик язучыларыбызның күптомлыкларын яңадан барларга, билгеле яки билгесез сәбәпләр аркасында кыскартуларга дучар булган, яки бөтенләй төшерелеп калдырылган әсәрләрне торгызырга, аларны һәртөрле идеологиядән азат итеп, обьектив бәя бирергә мөмкинлек туды. Беренче Академик басма әзерләү эше дә Габдулла Тукай томлыкларыннан башланды. Тукайның әлеге басмасын алтытомлы итеп әзерләү һәм Академик басма дәрәҗәсендә эшләү максат итеп куелды. Г. Тукайның 125 еллыгына 1–2 томнары, 130 еллыгына 3–5 томнары дөнья күрделәр. Әлеге томнар Академик басма таләпләренә туры китереп эшләнде. Текстлар шул чорга хас язылышлар, тел-стиль үзенчәлекләре сакланган хәлдә урнаштырылды. Бернинди чикләүләргә буйсынмыйча, барлык әсәрләре бергә тупланып бирелде. Ул төзегән җыентыклар, аңа кагылышлы материаллар да аерым том буларак лаеклы урын алдылар. Нәтиҗәдә, шагыйрьнең 6–7 шигыре, 45 ләп мәкаләсе, 2 хикәясе һәм ул төзегән бер җыентыгы да күптомлыкларда беренче мәртәбә дөнья күрделәр.

Г. Тукай «Әсәрләр»енең алты томлы Академик басмасының алтынчы томын эшләү барышында табылган берничә әсәр «Өстәмә материаллар» бүлегенә урнаштырылды. Шулардан «Кәфәштатыюш» имзасы белән язылган «Казандан Думага телеграм» мәкаләсе икетомлык «Габдулла Тукай. Академик басма»сының икенче томына (1948) һәм беренче дүрттомлык «Габдулла Тукай. Әсәрләр»енең өченче томына (1956) берникадәр кыскартылып урнаштырылса, «Бичура» имзасы белән басылган «Нәҗип Ломовой шигырьләре» исемле мәкаләсе беренче дүрттомлыкның өченче томына (1956) кертелгән. Әлеге мәкаләләр 1975–1977 һәм 1985–1986 елгы басмалардан төшереп калдырылганнар. Ә менә өч әсәре Тукай томлыкларына беренче мәртәбә урнаштырылды. Беренчесе – «Дүнә вә Мишә» исемле мәкалә. Язма «Фикер» газетасының 1907 елгы 2 апрель (13 нче) саны кушымтасында «Күрдегеме? шигыре белән бергә урнаштырылган. «Шүрәле» имзасы шигырьдән соң куелган. Бу мәкалә Тукайныкы булуына бер дә шик уятмый. Беренчедән, шагыйрьнең ике әсәрен янәшә куеп, бер имза белән имзалау очраклары бар. Икенчедән, Тукайның «Дин вә мәгыйшәт» журналын мыскыллап «Дүнә вә Мишә» дип атавы аның «Гөмберрт» имзасы белән басылган «Динчеләр куаныштылар» исемле мәкаләсендә дә күзәтелә [4, б. 235]. Өченчедән, мәкаләдән соң урнаштырылган «Күрдегезме?» шигырендә дә «Дин вә мәгыйшәт» журналы телгә алына. Кызганычка каршы, алтынчы томны әзерләү барышында, «Фикер» газетасының 13 саны кушымтасы табылмады. Татарстан Фәннәр Академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә сакланган Габдулла Тукай фондында әлеге мәкаләнең Х. Хисмәтуллин тарафыннан 1953 елда күчергән кулъязмасы саклана [3]. Ни өчендер Х. Хисмәтуллин һәм Я. Агишевлар төзегән беренче дүрттомлыкның 1 нче томына (1955) бары тик «Күрдегезме?» шигыре генә урнаштырылган. Мәкалә кыскартылып күчерелүгә карамастан, фикер бөтенлеген югалтмаган. Шуңа күрә дә мәкаләнең текстын томга бирү кирәк табылды.

Мәкалә «Дин вә мәгыйшәт» журналында басылган «Әл-Мәрҗали» исемле бирәүнең язмасына каршы чыгып язылган. Тукай «Әл-Мәрҗали» иптәш үзенең язмасында ирләрнең, мөселман хатыннарының, йөзләре ачык йөри торган барлык милләт хатын-кызларының намусларына кагылып, аларны ата һәм ана көчекләргә тиңләве хакында әйтә. Тукайга әлеге мәкаләне язарга Оренбургтан бер мөселман кызының «Фикер» газетасы идарәсенә язган хаты этәргеч бирә. Хатта әлеге кыз «Дин вә мәгыйшәт» журналының һәммә мөхәррир вә наширләрен судка бирергә җыенулары хакында яза. Тукай мөселман хатын-кызларына теләктәшлек белдереп, «Сез мөселман хатынлары гына түгел, йөзләренә төшкән кимәүче һәммә башка милләт хатынлары да каршы торырга бурычлыдыр» ди. Мәкаләнең ахырында Тукай «Юк, юк! Саклан! Милләтемезнең яртысы булган гыйффәтле хатын-кызларны ачуландырудан!» дигән фикерен уздыра.

Икенчесе – «Шүрәле» имзасы белән гарәп шрифтында язылган кульязма. Сатирик рухта язылган әлеге язма да Институтның Язма һәм музыкаль мирас үзәге Габдулла

Тукай фондында саклана [2]. Башында «Ялт-йолт»ка һәм ахырында «Монтазам кыйраәт китабыннан» дигән искәрмәләре бар.

1909 елны Казанда «Мәктәп ибтидаиның соңгы вә рөшди өлкән сыйныфларына махсус» әзерләнеп, «Үрнәк» матбагасында басылып чыккан «Монтазам кыйраәт» китабының беренче кисәгендә, «Пожар вакытында кызгану» исемле хикәя урнаштырылган [9, б. 4–5]. Әлеге уку китабын төзүче – әдип, тәрҗемәче һәм журналист Әхмәтсолтан Рәхманкулый. Әсәрләр җыентыкка авторлары күрсәтелми генә бирелгән. (Ул елларда барлык җыентыклар да шул рәвешле эшләнгән). Әлеге имзасыз мәкалә үзенең эчтәлеге ягыннан Тукайның кулъязма әсәре белән бик тә охшаш. Әсәрнең беренчел варианты, ягъни «Монтазам кыйраәт»тәге хикәя йорт хайваннары тормышыннан алынып, тәрбияви максаттан чыгып язылган.

Бервакыт авылда пожар чыгып, бер йортны ут чолгап ала. Авыл халкы урамга йөгереп чыга, кычкырыш, елаш башлана. Ялкын башка өйләрне дә чолгап ала. Шул вакыт яна башлаган бер абзар түбәсендә кайдан сикерергә белмичә, мияулап, әрле-бирле йөргән бер мәче күренә. Малайлар мәчене күреп алып, эчләрен тотып көлә башлыйлар. Шулвакыт тимерче Галиулла малайларны: «Ходайның бер мәхлукы утта яна, ә сез авызыгызны ерып көләсез» дип ачулана һәм түбәгә баскыч куеп менеп мәчене коткара, иясенә тапшыра. Әсәр ахырында «Балалар! Мәчеләр, атлар тормышындагы шундый берәр хикәя үзеңез белмисезме? Белсәгез, сөйләп бирегез» дигән бирем дә бирелә [9, б. 5]. Тукай исә, әлеге хикәянең сюжетын алып, яңа әсәр иҗат итә. Хикәядәге тимерче образына «Бәянелхак» газетасының нашире һәм мөхәррире Сәйдәшев Мөхәммәтҗан Әхмәтҗан улын куя, ә мәче образын Оренбургтан килеп, шул нәшриятка эшкә урнашкан бер кешедән көлү өчен файдалана. Әсәр «Ялт-йолт» журналына бирергә дип әзерләнгән булса да, билгесез сәбәпләр аркасында басылмый кала.

Әлеге мәкалә хакында беренче тапкыр, «Мәдәни җомга» газетасының 2015 елның 24 апрель санында басылган «Тукай кулъязмалары»« исемле мәкаләсендә, Рамил Исламов язып чыккан иде [8]. Әсәр Тукай томлыкларының берсенә дә урнаштырылмаган. Кульязма әсәр берничә урыннан өзгәләнгән (зарарланган). Әмма «Монтазам кыйраәт» ге беренчел вариаты белән чагыштыргач, текстның әлләни кыскармавы, фикер эзлеклелеге югалмавы ачыкланды. Шуңа күрә дә әсәр алтытомлыкта урын алды.

Өченчесе – *** («Бүләк килгән гөбәдия капкачында...») исемле дүртьюллык шигырь. Бу әсәр хакында беренче тапкыр Нәкый Исәнбәт «Казан утлары» журналының 1976 елгы 4 нче санында «Габдулла Тукайның мәгълүм булмаган бер шигыре һәм Мәхмүт Дулат-Али хакында» мәкаләсендә язып чыга. Соңгы елларда Р. Исламов Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас фондында саклanучы Фатыймаи-Зөһрәнең (Фатыйма Бәхтиева) Габдулла Тукай турындагы истәлегенә нигезләнеп, бу шигырьнең язылу тарихына да тагы да ачыклык кертте [7].

Бервакыт Тукай дусты Мәхмүд Галиевларга (Дулат-Али) кунакка килгәч, Фатыйма Бәхтиева гөбәдия пешереп, Галиевларга күчтәнәч җибәрә. Гөбәдиянең өстенә камыр белән, Габдулла Тукай һәм йорт хуҗасы Мәхмүт Дулат-Али исемнәренең баш хәрефләрен калкытып, гарәп хәрефләре белән «Г.Т» һәм «М.Д.» дип язылган була. Гөбәдия килеп җиткәч, Тукай язуны укый да: «Моны болай гына ашарга ярамый, шигырь әйтергә кирәк» – дигән [8]. Тукай 1910 елда берничә ай Галиевларның чарлагында яши. Шунда Тукайның сакланып калган кулъязмалары арасыннан әлеге дүртьюллык шигырь дә табылган була.

ӘДӘБИЯТ


1. Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре. Казан: Мәгариф, 1914. 463 б.

2. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Музыкаль һәм язма мирас үзәге. 9 фонд, 1 тасв., 22 с.б.

3. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Музыкаль һәм язма мирас үзәге. 9 фонд, 1 тасв., 26 с.б.

4. Г. Тукай әсәрләре. 1 том / төзүчесе Ф. Сәйфи-Казанлы. Казан: Яңалиф, 1929. 176 б.

5. Тукай Г.М. Әсәрләр: 6 томда. Академик басма. 4 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 431 б.

6. Исәнбәт Нәкый. Габдулла Тукайның мәгълүм булмаган бер шигыре һәм Мәхмүт Дулат-Али хакында // Казан утлары. 1976. № 4.

7. Исламов Рамил. Габдулла Тукайның бер шигыре турында // Тормыш. 2012. 30 март.

8. Исламов Рамил. Тукай кулъязмалары // Мәдәни җомга. 2015. 24 апрель.

9. «Мөнтазам кыйраәт» китабы. Беренче җөзьә. Казан: Үрнәк, 1909. 60 б.

# НОВАТОРСКИЕ ЧЕРТЫ В ПОСТАНОВКЕ ТРИЛОГИИ СПЕКТАКЛЕЙ О ЖИЗНИ И ТВОРЧЕСТВЕ ВЫДАЮЩЕГОСЯ ПОЭТА Г. ТУКАЯ

***Галимова Э.М.***

В трилогию Казанского Татарского Государственного театра юного зрителя им. Г. Кариева вошли три спектакля: «Сенной базар» (2006 г.), «Зайтунакай» (2011 г.), «Расскажи мне, бабочка» (2014 г.). В данных спектаклях собираются воедино обрывочные сведения из жизни поэта, развенчиваются многочисленные мифы о Г. Тукае, что дает молодому поколению возможность составить наиболее целостное и объективное впечатление о выдающемся поэте. В композиции трилогии подчеркивается бесконечность и вечность фигуры выдающегося татарского поэта, который жив, пока народ чтит и помнит оставленное им наследие. В статье нами выделены новаторские черты работы режиссера, музыкального оформления композитора и актёрского воплощения образа великого поэта в трилогии.

The trilogy of the Kazan Tatar State Theatre of young spectator im. G. Karieva included three performances: "Hay bazaar" (2006), "Zaytunakay" (2011), "Tell me butterfly" (2014). In these performances come together scraps of information from the life of the poet, debunked many myths about the G. Tukay, giving the younger generation the opportunity to create the most complete and objective impression of the outstanding poet. The composition of the trilogy emphasizes the infinity and eternity of the outstanding figures of Tatar poet, who is alive until people honor and remember his legacy. In our article highlights the innovative features of the work of stage director, musical arrangement of the composer and actor clearance incarnation of the great poet of the image in the trilogy.

Гениальность личности татарского поэта Габдуллы Тукая, успевшего за прожитые им 27 лет оставить человечеству бесценное литературное наследие, продолжает восхищать умы. Его творчество вновь и вновь привлекает внимание не только соотечественников, поклонников татарского национального искусства, но и представителей мировой культуры, о чём свидетельствуют его произведения, переведённые на многие языки мира и пользующиеся большие спросом у читателей всего земного шара. Читая произведения Г. Тукая, можно найти ответы на многие волнующие нас вопросы. По истечении времени всё ярче высвечивается актуальность тем его произведений.

Современные условия жизни оказывают сильное воздействие на нравственное формирование подрастающего поколения. Меняется отношение к окружающему миру, к жизненным ценностям, к общечеловеческим идеалам. Остро встаёт вопрос эстетического и морального воспитания детей и молодёжи: проблема развития бережного отношения к прошлому своего народа, к его литературному наследию, к искусству. В связи с этим, пропаганда творчества Г. Тукая является актуальной и необходимой.

За период с 2006 года по 2014 год при поддержке Министерства культуры РТ на сцене Казанского Татарского Государственного театра юного зрители имени Г. Кариева состоялись три премьеры: «Сенной базар» (сценарий Р. Аюпова) – 2006 г., «Зайтунакай» (пъеса Р. Батуллы) – 2011 г., «Расскажи мне, бабочка» (пъеса Т. Миннуллина) – 2014 г., которые позднее вошли в состав «Трилогии спектаклей о жизни и творчестве выдающегося татарского поэта Габдуллы Тукая».

Общественное признание «Трилогии спектаклей о жизни и творчестве выдающегося татарского поэта Габдуллы Тукая» предопределил огромный творческий вклад членов творческой группы: режиссёра Рината Аюпова, композитора Эльмиры Галимовой и актёров Ильфата Камалиева и Алии Калимуллиной в осуществление поставленных задач. Создав трилогию спектаклей «Сенной базар», «Зайтунакай», «Расскажи мне, бабочка» творческая группа в данном составе поставила перед собой следующие цели:

1) пропаганда личности и творчества великого поэта Г. Тукая среди подрастающего поколения.

2) культурно-просветительская: дать возможность юному зрителю составить наиболее целостное впечатление об одной из центральных фигур татарской культуры.

3) образовательная: ознакомить молодое поколение с выдающимися произведения ярчайшего представителя татарской литературы.

4) воспитательно-патриотическая: привить высоко-художественный вкус, чувство гордости за национальную культуру, бережное отношение к культурному наследию, посредством театрального искусства.

Возрождение традиционной культуры – основная задача, которую ставил перед собой режиссёр Р. Аюпов на протяжении работы над всеми спектаклями, вошедшими

в трилогию. Собирая воедино обрывочные сведения о личности поэта, развенчивая многочисленные мифы о Г. Тукае, он даёт молодому поколению возможность составить наиболее целостное и объективное впечатление о выдающемся поэте. Взявшись за сценическое воплощение данной темы, режиссёр спектаклей представил собственную оригинальную историю судьбы поэта и бессмертия его гения. Предметом исследования Р. Аюпова стала как внутренняя линия жизни поэта, так и художественные мотивы его творчества.

Трилогия имеет кольцевую композицию: от панорамного «Сенного базара», через укрупнённый эпизод несчастной любви и смерти великого поэта («Зайтунакай»), мы возвращаемся в детство Тукая («Расскажи мне, бабочка»). Таким построением композиции режиссёр Р. Аюпов подчёркивает бесконечность и вечность фигуры выдающегося татарского поэта, который жив, пока народ чтит и помнит оставленное им наследие.

«Сенной базар» – это панорамное произведение, повествующее о творческом пути великого татарского поэта Г. Тукая. Сливаясь воедино, важнейшие эпизоды биографии Г. Тукая и сцены из центральных в его творчестве произведений, дают возможность зрителю составить наиболее целостное впечатление об одной из центральных фигур татарской культуры. В ходе работы над данным произведением, режиссёр Ринат Аюпов разглядел эпизоды, которые могут быть раскрыты в отдельных театральных постановках. В результате образовалась трилогия спектаклей о жизни и творчестве выдающегося поэта Габдуллы Тукая, в рамках которого «Сенной базар» по хронологии является первым спектаклем. В одном сценическом пространстве одновременно существует три поэта: маленький Апуш (так называли поэта в детстве), известный поэт Габдула Тукай и Ак Тукай – поэт на смертном одре. Главный герой предстаёт единым в трёх исполнителях. Кульминационным является эпизод, в котором на возглас измученного болезнью поэта: «Печать проклятья! Чёрт побрал бы эту боль!» на сцене появляется чёрт, который видится Г. Тукаю и предлагает ему здоровье взамен на отречение от творения. Но поэт отказывается от сделки и выбирает путь служения своему народу.

Равноправное участие в сценическом действии реальных исторических персонажей, «клонированной» фигуры поэта и образов, рождённых его воображением, безусловно, подразумевало некий композиционный стержень, который позволил бы объединить все элементы повествования в единую целостную конструкцию. Р. Аюпов остановил свой выбор на музыке. Так, нашли применение характерные для его режиссёрского стиля музыкально-пластические миниатюры-метафоры, органично вписавшиеся в образную плоть спектакля.

На протяжении не только спектакля «Сенной базар», но и всей трилогии, красной нитью проходит образ бабочки, который, вместе с музыкой композитора Эльмиры Галимовой, раскрывает эмоциональную составляющую спектаклей. Этот образ многогранен. С одной стороны, с бабочкой отождествляется обобщённый образ человека, который зарождается в утробе матери, подобно гусенице, будучи еще неоформленным созданием; затем – рождается, становясь куколкой, и с этого момента начинает осознавать себя, искать своё место в мире, прилагать усилия для того, чтобы «оформиться» в нечто целостное и прекрасное; и, наконец, наступает  стадия собственно бабочки, которая, по сути, и есть сама жизнь – яркая и скоротечная. И после того, как человек проходит свой жизненный путь и оставляет свой след, его освободившаяся душа, также отождествляемая с бабочкой, взмывает в небеса. Бабочка в японской философии символизирует всё лучшее, что было в жизни человека. С бабочкой ассоциируется и образ самого Г. Тукая. В его творчестве было три этапа, как три жизненных цикла у бабочки. Поэтому неслучайно, что именно в форме трилогии передаёт весь творческий путь Габдуллы Тукая режиссёр Ринат Аюпов. В одном из важнейших эпизодов спектакля измученный болезнью, поэт, умирая, движется по тоннелю и заходит в воронку, он видит бабочку, которая являлась ему еще в детстве. Она возникает при всех пограничных ситуациях в жизни Габдуллы Тукая. В бабочку обращается и его, обретшая покой и свободу, душа, возносясь в небеса и устремляясь к Богу, подарившему ему великий дар творения…

Сюжет музыкальной драмы «Зайтунакай» основан на укрупнении истории несчастной любви поэта. Жанр музыкальной драмы, выбранный для воплощения данного сюжета, восполнил пробел, возникший после произведений С. Сайдашева в

одноимённом жанре, так полюбившемся татарской публике. Музыка Э. Галимовой, на протяжении всего спектакля, привносит в эмоционально напряжённые, тяжёлые диалоги героев эфирность и очищение, которое происходит в душе возлюбленных через вынужденное разъединение. Кульминацией спектакля является последний диалог возлюбленных, в котором Г. Тукай признаётся Зайтунакай, что не любит её. Но глаза поэта выдали в этой брошенной фразе его первую и последнюю ложь. Значит, всё-таки, отрекаются любя?. И именно музыка дает намек, что любовь, пусть и несчастная, подогревая душу Г. Тукая, даёт толчок к новым сочинениям, к выполнению истинной миссии великого поэта – оставить наследие после себя.

Представим, что сказки, ставшие наследием великого татарского поэта Габдуллы Тукая, ещё в далеком детстве нашептала ему его душа-бабочка. У каждой сказки есть своя глубокая философия, не теряющая актуальность уже много лет. Именно эта идея раскрыта в завершающем трилогию музыкальной мистерии «Расскажи мне, бабочка». Этот жанр является новаторским для татарского театра, в котором ставка всегда делалась на пространные диалоги героев. В этом спектакле композитор Э. Галимова ломает сложившийся стереотип. В результате, вдохновлённый её музыкой режиссёр, максимально сокращает сложные для детского восприятия диалоги драматурга и делает ставку на музыку, тем самым выводя музыкальную драматургию на первый план. Кроме того, музыка своей интонационной и ритмической фабулой активно провоцирует актёров на сценическое действие. С одной стороны, она выполняет иллюстративно-действенную функцию, отражая событийный ряд спектакля, а с другой – глубоко раскрывает внутреннее душевное состояние главного героя.

Всё восприятие строится на визуально-эмоциональном уровне. Каждую встречу маленького Апуша со сказочными героями («Шурале», «Водяная», «Коза и овца», «Отрубленная голова») композитор воплощает в музыке, используя лейтмотивную технику. Важную роль в раскрытии сюжетной линии играют пластические элементы, выполняемые актёрами. Перед маленьким Апушом открывается портал, ведущий в волшебный мир, в котором начинают проноситься персонажи еще ненаписанных Тукаем сказок. Маленький Апуш попадает в разные истории и, помогая сказочным героям, он преодолевает свой страх. Мальчик после всех этих путешествий преображается, обретает силу духа, страх навсегда исчезает из его сердца. Он готов воплотить в жизнь своё предназначение, о котором ему поведала бабочка. Эмоционально повзрослевший Апуш уезжает с дядей в город. Решительный настрой героя в финале композитор Э. Галимова ярко передает музыкальной цитатой из известной песни Г. Тукая «Пар ат».

Композитор Эльмира Галимова, написав музыку для трилогии, обеспечила композиционный стержень, который объединил все элементы повествования в единую целостную конструкцию. В характеристике главных героев композитор использует лейтмотивную систему изложения и современные методы композиторской техники письма в оригинальном сочетании древних пластов, выраженных в гармонии с использованием кварт и пентаккордов; полифонический метод изложения в оркестровке, сквозную форму в построении арий и ариозо для воплощения музыкальной драмы. Каждый главный герой трилогии охарактеризован своей музыкально-интонационной фабулой. Таким образом, выстраивается определённая символика музыкальной философии в выражении всей жизненной драмы и внутреннего душевного состояния каждого героя. Кроме того, музыка Эльмиры Галимовой своей интонационной и ритмической фабулой активно провоцирует актёров на сценическое действие. С одной стороны, она выполняет иллюстративно-действенную функцию, отражая событийный ряд, а с другой – глубоко раскрывает внутреннее душевное состояние главного героя.

Необходимо также отметить огромный творческий вклад актёров, исполнивших главные роли в трилогии спектаклей о жизни и творчестве выдающегося татарского поэта Габдуллы Тукая. Именно благодаря таланту и способностям А. Калимуллиной и И. Камалиева и их умению не играть роли образов Тукая и Апуша, а раз за разом проживать на сцене судьбы героев, стало возможным появление спектаклей «Зайтунакай» и «Расскажи мне, бабочка», которые представляют собой укрупнённые эпизоды из первоначального панорамного «Сенного базара».

Роль маленького Апуша исполнила Алия Калимуллина. Благодаря широкой эмоциональной палитре своих возможностей, актриса смогла блистательно сыграть ребёнка противоположного пола. Виртуозно реализовала пластические рисунки, задуманные

режиссёром. Благодаря её эмоциональности, способности передать внутреннее состояние героя, режиссёру и удалось максимально сократить диалоги и сделать это не в ущерб логике сюжета. В исполнении роли маленького Апуша А. Калимуллина продемонстрировала глубокие познания в области детской психологии, в частности – особенностей восприятия юным зрителем событий, происходящих на сцене. Умение применять эти познания в актёрской игре обеспечили доверие зрителей к актрисе, которой удалось не просто сыграть на сцене, а испытать на себе нелегкую судьбу маленького Апуша и рассказать о ней детям с максимальной долей эмоциональности.

Талант Ильфата Камалиева позволил режиссёру отойти от традиции линейного воплощения образа Тукая, где акцент делался преимущественно на внешнем сходстве. Вжиться в роль актёру помогло глубинное понимание трагизма судьбы поэта. Достоверность созданного И. Камалиевым образа исходит из его метода актёрской игры. Для того, чтобы максимально точно раскрыть для зрителя образ Тукая, И. Камалиев раз за разом пропускает через себя весь драматизм жизни и все страдания героя, проецируя их на свою судьбу. Тем самым, актёру удалось показать не внешнюю оболочку шаблонного, стереотипного Тукая, а углубиться в его внутренний мир, раскрыть долю поэта, судьба которого – быть обречённым на одиночество, отдавая всю свою жизнь творчеству и народу.

Спектакли «Сенной базар», «Зайтунакай», «Расскажи мне, бабочка» имели огромный успех в гастрольной деятельности театра имени Г. Кариева в районах и городах РТ, регионах России (Москва, Уфа, Самара, Пермь, Екатеринбург, Саратов, Нижний Новгород, Йошкар-Ола), странах СНГ (Украина, Киргизия, Казахстан) и за рубежом (Турция). В 2006 году театральная постановка «Сенной базар» была удостоена самой высокой награды («За лучший спектакль») на II Международном фестивале «Арт-Ордо» в г. Бишкеке. К 120-летию Г. Тукая спектакль «Сенной базар» был показан в г. Москве и получил высокую оценку столичного зрителя. В 2011 году на торжественной церемонии открытия памятника Г. Тукая в Москве, в рамках театрализованной постановки, прозвучал гимн для симфонического оркестра «Ак канатлы шагыйрь» композитора Эльмиры Галимовой из музыкальной драмы «Зайтунакай».

Так, взаимно переплетая судьбу Г. Тукая и созданные его пером образы, режиссёр провёл зрителя через зигзаги нелегкого, но яркого жизненного пути поэта. Р. Аюпов попытался разгадать диалектику души, истоки художественного мироощущения Г. Тукая. Полифоничная музыкальная ткань композитора Эльмиры Галимовой, явившись символом неразрывной связи поэта со своим народом, вместе с тем сообщила сценическому повествованию общечеловеческий философский смысл. И во всей полноте помогла донести мысль о не приходящих художественно-эстетических ценностях, заложенных в его творческом наследии, послужившем неиссякаемым ресурсом не только для татарской культуры, но и для всего тюркоязычного мира.

## Г. ТУКАЙНЫ ӨЙРӘНҮ ФӘНЕНЕҢ ХӘЗЕРГЕ ТОРЫШЫНА РАШАТ ГАЙНАНОВ КЕРТКӘН ӨЛЕШ

***Галимуллин Ф.Г.***

Узган ел әдәби-фәнни җәмәгатьчелекнең игътибарын әдәбият галиме, бездә текстология өлкәсендәге эшчәнлекне чын мәгънәсендә фәнни нигезгә куеп эшләүнең үрнәген биргән Рашат Гайнановның тууына 90 ел тулу уңаеннан без затлы каләмдәшебезнең шәхесенә юнәлтү юлында кайбер адымнар ясаган идек. Матбугаттагы чыгышларыбызда галимнең бигрәк тә Габдулла Тукайны үз заманы чолганышында өйрәнү өлкәсендәге хезмәтләренә бәя бирергә тырыштык. Быел, бөек шагыйребезнең тууына 130 ел тулы уңаеннан, аның бу өлкәдәге эшчәнлеген тәкъдир итү аеруча урынлы булыр. Чөнки Р. Гайнановның әлеге тикшеренүләре Г. Тукайны бүгенге дәрәҗәдә аңлавыбызны, бәяләвебезне бик нык тирәнәйтте һәм киңәйтте. Аннан соң фәнгә килгән зыялыларыбыз, шул нигезгә таянып, әлеге юнәлештәге тикшеренүләрне тагын да алга алып киттеләр. Димәк, Р. Гайнановның хезмәтләре бүген дә кулланылышта, алар гомуми фәнни контекстта бик әһәмиятле вазифа башкаруларын дәвам иттерәләр.

Гайнанов Рәшит улы Гайнанов – әдәбият галиме, текстолог, тәрҗемәче. Г. Тукай иҗаты буенча фәнни эзләнүләрне узган гасырның илленче елларыннан башлый. Тукай әсәрләренең икенче дүрттомлыгын (1975–1977) һәм биштомлыгын (1985–1986) төзи. XX йөз башында нәшер ителгән газета-журналлардагы тәхәллүсләрне, имзасыз шигырь һәм мәкаләләрне җентекләп тикшерү, шагыйрьнең архивта сакланган язмаларын, замандашларының истәлекләрен өйрәнү, чагыштыру кебек киң планлы эш нәтиҗәсендә Тукайның 30 га якын ядерен имзасын ачыклый. «Хәсрәт», «Шәкерт угы», «Җен», «Тәртә башы», «Мәҗнүн», «Дугъры», «Салам Торхан», «Догачы», «Адвокат», «Мәкәрҗәдә булучы», «Бән», «Мөсафир» – шундыйлардан.

Р. Гайнанов икенче дүрттомлыкта аңа кадәрге басмаларда киткән байтак хаталарны төзәтә, әсәрләрнең язылу һәм басылу хронологиясен күпкә дөресли. Тукайныкы икәнлеге фәнни нигездә исбатланган 30 лап шигырь, 20 мәкалә, 11 хат өстәлүе дә икенче дүрттомлыкның кыйммәтен арттыра. Текстолог моңарчы Тукайныкы саналган «Казаннан Думага телеграм», «Корымлы мунчалар», «Нәҗип Ломовой шигырьләре», «Яңа әсәрләр тирәсендә», «Хәйран булып калдык», «Татар мәҗлесе» исемле фельетоннарны төшереп калдыра, аларның башка авторларныкы икәнлеген ачыклый. Р. Гайнановның гомере буе җыйган материаллары үзләре генә дә бу юлы Г. Тукай әсәрләрен биш томнан чыгару ихтыяҗын тудыра. Биредә текстолог башка басмаларда булмаган 120 дән артык әсәр урнаштыра.

Икенче дүртомлыкта ук Р. Гайнанов башка халыкларның – рус, украин, белорус, казакъ, үзбәк, әзәрбәйҗан һ. б. тәҗрибәсен өйрәнеп, текстология фәне таләпләренә туры китереп, татар филологиясендә беренче буларак, классикларның томнарын төзүнең, искәрмәләр һәм аңлатмалар язуның системасын – концепциясен төзи. Мондый эшләрне башкаруның бүген дә нигездә шушы үрнәктә алып барылуы Р. Гайнанов традицияләренең яшәүчәнлеге турында сөйли.

Биштомлыкның фәнни аппараты тагын да киңәйтелгән. Искәрмә-аңлатмалар күләм ягыннан үзләре бер томны тәшкил итә. Ул татар әдәбияты тарихы, теориясе, фәлсәфәсе мәгълүматлары тупланган кече энциклопедияне хәтерләтә. Искәрмәләрнең «Мөтәшагыйрьгә», «Җавап», «Васыятем», «Кызык гашыйк» һ. б. әсәрләргә багышланганнары мөстәкыйль фәнни мәкалә буларак карала ала. Әйтик, «Җавап» шигыренең архивта кульъязмасы сакланмаган, кемгә төбәп язылганлыгы, датасы исбатланмаган иде, текстолог аның З. Бәширигә нисбәт ителгәнлеген раслый. «Китмибез!» шигыренең язылу сәбәбен ачыклауны, фәнни бәяләүне дә Р. Гайнанов башкарды. XX гасыр башында кара горуһларның татарларга һәм башкортларга карата булган тискәре мөнәсәбәтләре патша хакимиятенең парламент эшчәнлегендә чагылуына бер гыйбрәтле мисал булуы шигырьдә сәнгати көч белән ачыла. Ул заманнарда, милли мәгарифне үстерү өчен, бер тиен акча бирелмәүнең гайре табигый нәрсә икәнлеген фаш итүдә Г. Тукай шигыренең әһәмияте күрсәтелә. Бөртекләп карасаң, Р. Гайнановның мондый табышлары тагы да бар. Биштомлык чыккан еллардагы чордашларыбыз авызыннан М. Мәһдиевнең әлеге җыентыкларны искәрмәләр һәм комментарийлар бүлегеннән укый башлаганлыгы, алардагы яңа мәгълүматларның муллыгына исе киткәнлеге турында әйткәннәрен әле дә ишетергә туры килә.

Гәрчә томнарда Тукай тормышы, иҗаты һәм эшчәнлеге үзәктә торса да, әдәбиятыбызны борынгыдан алып белү, аның башка сүз сәнгатьләре белән бәйләнешен ачык күзаллау, егерменче йөз башы иҗтимагый тормышыннан, шул чордагы вакытлы матбугаттан, язма һәм басма әдәбияттан нечкәләп хәбәрдар булу, иҗтимагый аңның төрләре булган тарихи, фәлсәфи, дини тәгълиматларны белү – биштомлыктагы фәнни аппаратның киңлеген һәм камиллеген тәэмин иткән. Тукай үзе исән вакытта чыккан 33 китап, газета-журналлар, Совет чорында басылган аерым җыентыклар, төрле басмалар, шагыйрьнең архивы – биштомлыкка керткәндә төзүче һәр әсәрне шушы басмалардан тикшереп, чагыштырып чыга, әсәрнең язылу вакыты, кайчан, кайда басылганлыгын һәм бу томга нинди чыганактан алынганын әйтеп бара. Болар басманың фәннилеген камилләштергән.

Дүрттомлыкта һәм биштомлыкта Тукай әсәрләрендә телгә алынган реаль шәхесләр турындагы мәгълүматлар да күп. 1956 елгы басмада булмаган алтмышка якын исем «Искәрмә һәм аңлатмалар»га кертелә. Кырыклап шәхес турында өр-яңа яисә тулыландырылган мәгълүмат бирелә, һәркайсының туган, үлгән еллары ачыклана. Тукайның чәчмә мирасында мәдрәсәләрдә дәреслек хезмәтен үтәгән яисә бүтәнчә кулланылышта булган иске китаплар телгә алына. 1956 елгы басмада аларның күбесе аңлатмасыз

калган. Р. Гайнанов исә, күп китапларның үзләрен күздән кичереп яисә ышанычлы чыганакларга таянып, аларның эчтәлек һәм формалары турында мәгълүмат бирә.

Р. Гайнанов 12 шигырьне Тукайныкы булу ихтимал дип бирә. Чыннан да, аларны стильләре, темалары, эчтәлекләре буенча Тукайныкы дияргә нигез бар. Икенче дүрттомлыкка кертелгән Тукайныкы булу ихтимал дип бирелгән шигырьләрнең алтысы, ягъни «Сәгадәт юк...», «Руслар эш күрәләр...», «Бунларның берсе – үз анасы...», «Аһ идәрсә...», «Сәнгә хезмәтдер...» дип башланганнары һәм «Әйтәсем килә» шигыре бу басмада тәгаен Тукайныкыныкы дип шикләнмичә тәкъдим ителә. Икенче дүрттомлыкта Тукайныкы булуы мөмкин дип урнаштырылган өч шигырь, киресенчә, бу юлы бөтенләй төшерелгән, чөнки аларның бүтән чыганактан булуы тәмам ачыкланып җиткән.

Шулай итеп, дүрттомлык һәм биштомлыкта Тукай текстларының фәнни дөреслегенә ирешү юнәлешендә Р. Гайнанов зур эш башкарган. Томнарда моңа кадәр чыккан басмаларда булмаган 170 кә якын әсәр кертелгән. Томнарны укучыга Тукайны тагын да ныграк ачу мөмкинлеген бирә торган җентекле, системалы, зур күләмдә искәрмә һәм аңлатмалар белән тәэмин иткән. Р. Гайнанов үзенең эшчәнлеге белән татар филологиясендә текстология фәнен югары баскычка күтәрә.

ӘДӘБИЯТ

1. Гайнанов Р. Билгесезлектән – яңа томга // Социалистик Татарстан. 1976. 20 май.
2. Гайнанов Р. Аның мирасыннан // Социалистик Татарстан. 1971. 25 апрель.
3. Хәким С. Тукайны укыйм // Социалистик Татарстан. 1975. 28 декабрь.
4. Галимуллин Ф. Һаман да якыная // Социалистик Татарстан. 1984. 12 октябрь.
5. Урманчеев Ф. Кадерләрәк була бара // Казан утлары. 1987. № 4. Б. 161–165.
6. Исламов Р. Тукай текстологы – Р.Р. Гайнанов // Тукай һәм XX гасыр мәдәнияте. Казан: 1997. Б. 115–120.

*Статья написана и опубликована при финансовой поддержке РГНФ и Правительства Республики Татарстан в рамках научного проекта № 15-14-16017 а (р).*

## БЕЗ – ТУКАЙЛЫ МИЛЛӘТ

***Галиуллин Т.Н, Гали Б.Т.***

В статье речь идет о нравственных источниках поэзии Тукая, который вытекает из глубокого знания жизни и чаяний народа и умелого творческого использования сокровищниц мировой культуры. Этим и объясняется глубокое влияние творчества Тукая на татарскую поэзию в последующие годы его развития. Трудно назвать татарского поэта, который не преклонялся бы перед гением Г. Тукая.

укай образын шигърияттә яктырту юнәлешендә эзләнүләр, аның тормыш юлы, мирасы турында уйланулар XX гасыр дәвамында тукталып тормады һәм бигрәк тә ике гасыр кисешкән дәвердә аеруча нәтиҗәле булды. Аерым алганда, С. Хәкимнең «Тукай дәфтәреннән» шигъри бәйләме, «Кырыгынчы бүлмә» поэмасы, И. Юзеевның «Очты дөнья читлегеннән...», М. Әгъләмнең «Тукайдан хатлар», Р. Харисның «Тукайның мәхәббәт төшләре» драматик поэмалары, М. Шабаевның «Тукайны сагыну» һәм башка күп санлы әсәрләр Тукайның рухи дөньясын аңлауда җитди адым булдылар. Туган як матурлыгы җырчысы, Тукай мәктәбенең күренекле вәкиле С. Хәкимнең «Җырын җырга куеп карыйм, Намусыма аның – намусын», – юллары Тукай наменә багышланган бик күп шигырьләр өчен бисмилла, эпиграф була ала. Тукай образын үзәккә алган шигырьләр остазларының дөньяга карашын, язмышы низагъларын, холкын, рухи-әхлакый эзләнүләрен, замана таләпләрен дә исәпкә алып, аңлау, укучыга җиткерү нияте белән яшиләр. Еш кына Тукай дөньясының төп хасиятләре – милләтенә тугрылыгы, намусына, вөҗданына кер төшермәве, илаһи пакьлеге – кичереш үзәгенә алына, ...«шигырь Алласы, вөҗданны безнең уят», – дип яза Р. Гаташ «Шигърият» әсәрендә. Шагыйрьнең югарыда искә алынган сыйфатлары атамага ук чыгарылып, әсәрнең кичереш кыйбласын билгели: Ш. Галиев «Туры Тукай», Х. Әюп «Туры сүзгә», М. Әгъләм «Әйтте Тукай», Зөлфәт «Тукай догасы», Г. Рәхим «Тукай», Л. Шагыйрьҗан «Мин Тукайның үзен күргәнем бар», М. Мирза «Тукай – иман» һ.б. әсәрләрдә Тукай – караңгы дөньяны

нурга күмә алган энҗе ташы, нур көлтәсе, яшәеш чыганагы. Р. Мингалим «Язгы Тукай янында» шигырендә язганча, «Алда гасырлар чайкала, Без аякта, без исән».

Тукайның иҗат ялкыны дөрләгән, аның халык язмышы, киләчәге өчен читлектәге кош мисле бәргәләнгән чорга, багышланган юлламалар белән беррәттән, даһины мәңгелеккә алып киткән 1913 елны үзәккә алган, мәрхәмәтсез язмышка рәнҗү хисе дә табигый рәвештә үзәккә чыга: С. Сөләйманова «Тукай. Казан. 1913 ел», Г. Афзал «Ак юл», Р. Гаташ «Кырлай юлында Сәгъди абзый белән», «1913 елның җәе. Зәйтүнә – Тукай каберендә», Р. Корбан «1913. Апрель. Тукай» һ.б. Шигъри юксынуларның үзәгендә яткан Тукайның халык белән бердәмлеге, мәңгелеге фәлсәфәсе чорыбыз вәзгыятенә аһәңдәш. Х. Туфанның «Халык төсе», И. Юзеевнең «Тукай бер генә», Э. Шәрифуллинаның «Без – Тукайлы халык» шигырьләренең үзәгендә милләт улы Тукай белән горурлану тойгысы ята.

Тукай образын, аны үстергән, каккан-суккан, иркәләгән мохитны, яңалык белән кадимчелек бәрелешен үзәккә алган иң соңгы күләмле әсәрләрдән Э. Шәрифуллинаның «Без – Тукайлы!» поэмасы булды.

Әйе, Тукайның шигъри җанлы оныклары остазларына бурычлы булып калмаска, аның образын тудыруга, рухын аңлауга омтылалар. Фәнни-гыйльми ноктадан килгәндә бу әле «Тукай» исемле олы затның шәхесенә, мирасына якынлашуның, бик мөһиме булса да, бер ягы гына. Тукайга килүнең нигезендә бөек шагыйрь иҗатының буеннан-буена сузылган миллилек идеясе, халкын азат һәм бәхетле итеп күрү теләгенең уртак булуы ята. Иҗтимагый-сәяси үсеш вәзгыятеннән чыгып караганда, Тукай иҗатына игътибар үсүнең янә бер җитди сәяси нигезе бар. Без яшәгән дәвер (ике гасыр кисешкән чор), иҗтимагый һәм милли яссылыктан чыгып бәяләгәндә, даһи шагыйребез яшәгән елларны хәтерләтеп куя. Искә төшерик, 1905 ел инкыйлабыннан соң, патша режимы халыкта өмет нуры, киләчәккә ышаныч чаткылары кабызган сәяси, шәхси, иҗат иреге бирергә мәҗбүр була. Шуңа якын манзара Русиядә 90-нчы еллар башында кабатланды, азатлык исе, мөстәкыйльлек сүзе халыкны мәйданнарга алып чыкты. Ике чорны да уртак идеал – милләт бәхете өчен көрәштә бердәмлек эзләү якынлаштыра.

Без бит кешенекен сорамыйбыз,  
Без алырга тиеш азатлык, –

дип яза шагыйрә Б. Рәхимова 1991 елда.

Нибары берничә ел дәвам иткән, өлешчә бирелгән демократия XX гасыр башында да, ахырында да һәр җәһәттән уңай һәм тискәре яклары күренгән үзгәреш-яңарышларга алып килә. Аерым алганда, Тукай чорында илнең һәр төбәгендә, шул җөмләдән, милләттәшләребез күпләп яшәгән төбәкләрдә буржуаз мөнәсәбәтләр урнаша, икътисадны үстерүдә, казылма байлыклар чыгаруда, банклар системасында татар эшкуарлары уңышларга ирешә. Татар байлары хисабына төрле төбәкләрдә мәктәпләр, мәдрәсәләр ачыла, мәчетләр төзелә, китаплар, газета-журналлар чыгарыла. Шуңа якын ситуация гасырның 90-нчы еллар башында кабатлана. Тукай яшәгән еллардагы шикелле, әдәби мәйданга йөзләгән шигырь язучылар, эч пошканнан, кызык эзләп, хикәя «сөйләүчеләр» килә, төрле яшьтәге һәвәскәрләрнең китаплары урыннарда күпләп басылу сәбәпле, зәвык түбәнәя, уртакул язманы, Туфан әйтмешли, «рифмачны» яхшыдан, соры әсәрне талантлы китаптан аеру кыенлаша. Шул гаҗизлектән Тукай «Тәнкыйть – кирәкле шәйдер», дигән мәкаләсен язарга мәҗбүр булгандыр. Бик кызганыч, 90 еллар башы халыкка талгын азатлык, иҗатчыларга тулы ирек (ни телисең, шул хакта яз) алып килсә дә, XX гасыр башында ялтырап, таң нурыдай килеп чыккан Тукай, Исхакый, Дәрдмәнд, Ибраһимов, Әмирхан, Гафури, Г. Камал, Ш. Камал кебек милли яңарыш йолдызлыкларын кабыза алмады, татарның яңа байлары да мәгариф белән мәгърифәткә ярдәм кулларын (гөнаһларын ярлыкау өчен мәчет төзүдән башка) сузарга ашыкмыйлар.

XX гасыр башында да, ахырында да, халык милли дәүләтчелеген торгызу турындагы хыялы белән саташып йөргән арада, үзәк дәүләт системасы айнып өлгерде, һәртөрле кысулар, тыюлар, төрле юнәлештәге чикләүләр башланды, милләтара ызгышлар оештырылды, язгы ташу вакытындагыдай ярларыннан ярсып чыккан елгалар иске эзләренә кайтты, милли мәктәпләр, вакытлы басмалар, төрле сәбәпләр белән ябыла башлады, зыялылар, язучылар даирәсенә, Тукай кичергән реакция чорындагы мисле үк, төшенкелек, киләчәккә ышанмау, өметсезлек, шәхеснең олы дөньядагы ялгызлыгы, гомернең кыскалыгы, яшәүнең мәгънәсезлеге кебек аһәңнәр керде, нәкъ «үсмер аксакалыбыз» (Р. Харис) әйткәнчә, «сынды кылыч, бетте көч».

Ни аяныч, милләт җуйган гасыр,
Ахры, бүген килде халыкка:
Тәңре биргән сихри, моңлы телем
Тере килеш ята табутта!

дип яза безнең көннәр шагыйре Сөләйман («...Һәр җанлыга туу, үлем зарур»).

Шул рухтагы шигырьләр Р. Зәйдулла, М. Әгъләм, Л. Шагыйрьҗан, И. Иксанова иҗатында да очрый.

Татар Тукайны сагына
язмышы юл көткән саен, –

дип яза Р. Харис «Тукайның мәхәббәт төшләре» поэмасында. Икенче урында «Татарны өянәк тота», «Тукайны оныткан саен», дип өсти. Шул рәвешле, милләт тәрәккыять юлыннан алга барганда да, сәяси-иҗтимагый кыенлыклар кичергәндә дә, шагыйрьләр Тукайга киләләр, киңәш-табыш итәләр, шигъриятеннән кодрәт алалар, юаныч эзлиләр.

Тукай иҗатында фән белән дин, тарих белән фәлсәфә, халык этикасы белән әхлакый кануннар аерылгысыз бердәмлек булып яшиләр; наданлыкка, караңгылыкка, икейөзлелеккә, үткәнебезне бозып сурәтләүгә каршы фикерләр сәнгатьчә югарылыкта ачыла. Әмма милләтен ничек кенә мөкиббән китеп яратмасын, ул аның кимчелекләрен дә күрә, татарны алдынгы Аурупа мәмләкәтләре югарылыгында күрәсе килеп, Тукайга гына хас кискенлек, килешмәүчәнлек белән сатира утында көйдерә.

Көнчелек, үчлек белән тулган татарлык,
Төяп килеп, Мәкәрҗәдә сатарлык.

Шул ук вакытта Тукай үз милләте белән горурлана, беркайчан да татар булып тууына үкенми.

Җырлап торам, торган җирем тар булса да.
Курыкмыйм, сөйгән халкым татар булса да.

Яңа чор реалистик поэзиясенә нигез салучыларның дөньяны һәм кешене күрү, аңлау алымнары, фәлсәфи уйланулары, аналитик фикерләве, күп нәрсәгә ирония белән карый алуы, милләте өчен кайгыртып, сызланып яшәве һәр чорга аваздаш, үсү авырлыкларын җиңүдә ышанычлы рухи таяныч. Җөмләдән, татар тарихына мөнәсәбәт, аны фәнни-хисси бәяләү мәсьәләләрен алыйк. Тукай тарихилыгының үзәгендә татарларның борынгы дәүләтле халык булып та, мөстәкыйльлеген югалту, аны кайтара алмаудан ачыну, әрнү хисе ята. Тукай гасырлар дәвамында изелгән, төрле кара көчләр тарафыннан сытылган милләтен коллык психологиясеннән арындырып, йокысыннан уятып, белеме, үзаңы югары, көрәшче халык итеп күрәсе килә. Бу юлда аның арка терәге – бай һәм гыйбрәтле тарихыбыз. Милли тарихыбызга, аны җилкәләренә салып барган шәхесләргә Тукай аеруча игътибарлы. Гомер бакый баш иеп, тез чүгеп яшәмәс өчен шанлы үткәнебездән гыйбрәт, үрнәк алу лязим, ди кебек шагыйрь. Нәрсә турында гына язмасын, табигать матурлыгы белән хозурланмасын Тукайның шигъри фикерләве милләт үткәненә, милләт мәнфәгатьләренә килеп чыга. «Кичке азан» шигырендә йөрәген бимазалап торган мәсьәләгә әйләнеп кайтып, татарның Казан, Әстерхан, Касыйм, Себер ханлыклары чәчәк аткан чорларны искә төшереп, «инде беттек, инде беттек», дигән ачынышлы нәтиҗәсен ясый. Шагыйрь берничә юлда эре сызыклар ярдәмендә үткәннең тарихи панорамасын тудыра, олы язмышлы шәхесләргә багышланган әсәрләрендә тарихи гаделлек кайтырга тиеш, дигән ышанычын калкытып куя.

Хәзерге татар поэзиясендәге тарихилык рухы Тукай сызлануларына барып тоташа. Югалтулар өчен үкенү, ачыну, гарьләнү хисләре З. Мансуровның «Ике еглау», Р. Харисның «Идегәй», Ә. Рәшитнең башкалабызның меңьеллыгына багышланган «Казан» поэмаларында милләтне яшәтү, инкыйраздан коткару, татар баласында горурлык аша изгелек, киләчәк наменә яшәү хисе тәрбияләү нияте ята.

Гаяз Исхакый шәхесенә Тукай аеруча игътибарлы. 1907 елда «Кем ул?» дигән шигырен нәшер итеп, Исхакыйны киң колачлы әдип, мөхәррир, милләтнең киләчәге өчен җан атып, борчылып яшәүче җәмәгать эшлеклесе итеп сурәтли. 1913 елда «Мәктәп» журналында басылган «Мөхәрриргә» дигән шигыре дә Г. Исхакыйга багышланган. Кыенлыклар белән санашмыйча, гел яктыга, үзенә тартып торган якты идеалга юл ярып барган «Даһига» (1913) әсәрендә Тукай, Мәрҗани белән беррәттән, «Ике йөз елдан инкыйраз» авторын да истә тоткан булуы ихтимал. Г. Исхакый үзе дә даһи шагыйрьнең

вакытсыз үлемен авыр кабул итә, аның рухы алдында бурычлы калмый, Тукай истәлегенә багышлап, берничә ялкынлы һәм шул ук вакытта аналитик мәкаләләрен язып чыга, Тукай иҗатының юнәлешен ачу белән беррәттән, аны һәртөрле гайбәтләрдән саклап калырга тырыша. «Мәктәп» журналында (1914, № 6) «Тукай мәктәптә» исемле фәнни-методик мәкаләсен бастыра, алдагы елларда «Милли фаҗига», «Тукай мәхәббәте» кебек язмаларын чыгара.

Ике олы шәхес арасындагы көнчелектән, хөсетлектән, икейөзлелектән азат, гаҗәеп җылы, кешелекле мөнәсәбәт безнең болгавыр, явыз чорыбыз өчен бигрәк тә гыйбрәтле; ул киләчәк буынны изгелек, сафлык, батырлык, халкыңа фидаиләрчә бирелгәнлек рухында тәрбияләүдә үрнәк була ала.

Тарихи барышка, мәдәният үсешенә гомерләрен багышлаган бөекләрне олылау кебек Тукай, Исхакыйлардан килгән йола бүгенге татар поэзиясе үсешенең бер тармагын тәшкил итә. Кол Гали, Колшәриф, Мөхәммәдьяр, Кандалый, Бабич, Такташ, Туфан, Сәйдәш, Җәлил, Ф. Кәрим, Урманче кебек бөекләребезгә шигъри багышлаулар һәркайсыбызга мәгълүм. Хәзерге татар поэзиясендә төрле елларда яшәп, иҗат иткән мәдәният әһелләре, азатлык өчен көрәшчеләр, кыскасы, милли идеягә бирелгән шәхесләрнең иҗади портретларын тарихта калдыру нияте көчле. Шагыйрь Ә. Рәшитнең тарихи дөреслекне торгызу юнәлешендәге шигъри эзләнүләре аеруча игътибарга лаеклы. Казан ханлыгы чорының өч олы тарихи шәхесенә багышланган поэмалары хәзерге татар поэзиясенең казанышлары санала ала. Аның каләменнән төшкән «Сөембикә», «Колшәриф», «Мөхәммәдьяр» поэмалары тарихи үткәнебезне Тукайча аңлауның һәм аңлатуның үрнәкләре булдылар. Югары шигъри кимәлле бу затлы поэмаларда тарихыбызны бәяләүдә Тукай традицияләре дәвамы сизелә. Сүз остазын кабатлау турында бармый. Татар тарихы ике дәвер шагыйрьләре өчен дә уртак, мотив бер, теләкләр изге.

Чал үткәнебезне аерым шәхес язмышлары аша образлы күзаллау юнәлешендә аеруча дәртләнеп иҗат итүче шагыйрь – Р. Харис. Бу юнәлештәге эзләнү-уйланулары аны Кандалый, Дәрдмәнд, Тукай, Җәлил һәм җәлилчеләр, Ф. Кәрим кебек авыр яисә фаҗигале язмышлы татар шагыйрьләре катына алып килә. Ул чорда Р. Харис Ватан сугышында һәлак булган милләттәшләренең батырлыгын хупласа, сокланса, соңрак шагыйрь һәр вакыйга-хәлнең икенче, өченче мәгънәләрендә яткан һәм күбрәк татар халкының язмышы белән бәйле төшенчәләр турында уйлана башлый. Әйтик, татарның Җәлил, Кәрим, Кутуй, Алиш кебек олы сүз осталарының батырларча үлеме татар халкына нәрсә бирде, дәүләтчелеген кайтаруга якынлаштырдымы, алар, башка милләт язучылары кебек, тылда калырга лаеклы түгелләр идеме? Буйсынган халыклар, вак милләтләр бөек җиңүдән соң да коллык тагарагы янында утырып калмадылармы?

Ә менә Р. Фәйзуллинның «Үлемнәре белән үлемсезлек...» шигырендә үлемсезлек – батырлык арасындагы катлаулы мөнәсәбәт тагын да җетерәк бирелгән. Аңа Тукай, Җәлил, Кәрим, Кутуй кебек үлемнәре аша мәңгелек җиһанына күчкән исемнәр газиз. Ләкин халык күңелендә калу өчен ниндидер идеалларны яклап, кем сугышындадыр катнашып һәлак булу батырлык өчен бердәнбер юл түгел, ди шагыйрь.

Үлеп күрсәттеләр безнекеләр!
Гомерләр булды, һай, кыска!
Ә бит үлеп үлемсезлек яулау –
бердәнбер юл түгел тормышта...

Татар улларының ачы язмышлары турында уйлану (коммунистлар фиркасенә бирелгәннәрнең берсе дә бәхеткә тармаган икәне ачылгач) Р. Харисны эзләнү-уйланулары татар тарихына алып килә. Милли дәүләтләребез турындагы фикерләре Казан ханлыгы чорын объектив тасвирлаган урыс галиме Михаил Худяков («Худяков») язмышы турындагы поэмасының нигезенә ята. Тарихчының «Очерки по истории Казанского ханства» дип, тыйнак кына аталган хезмәтенә галимнәребез югары бәя бирсәләр дә, әдәбиятыбыз башка милләт кешесе каршында бурычлы иде. Р. Харис, Тукай Ш. Мәрҗанинең тарихыбызны дөрес язарга омтылуын хуплаган кебек, галимнең тоталитар режим чорында дөреслеккә туры кала алуы өчен олылый, аның тиңсез батырлыгы алдында баш ия, бөтен татар кавеме исеменнән рәхмәтен яудыра. Р. Харисның «Идегәй» дастанына тәкълид итеп язылган, шул исемдәге поэмасы татар халкының язмышы, теле кабат авыр сынаулар кичергән чорда үткәннең фаҗигале көннәрен онытмаска чакыра, милләтнең киләчәге бердәмлектә икәнне искә төшерә.

# Г. ТУКАЙҺӘМ XX ГАСЫР БАШЫ ТАТАР ИСЕМНӘРЕ СИСТЕМАСЫ

*Галиуллина Г.Р.*

В работе сделан обзор деятельности Габдуллы Тукая в области сохранения и пропаганды национальной культуры и языка. В центре внимания Габдуллы Тукая оказывается и система личных имен татар, которая развивается на основе исламских традиций. Поэт неоднакратно критикует именник татар за отклонение от национальных традиций. По его мнению, культура, воспитание, язык, в том числе и именник, должны основываться на национальных традициях. В своих произведениях Г.Тукай часто обращается к народным вариантам антропонимов, а также сам образует весьма оригинальные варианты личных имен.

This paper presents a review of the activities of Gabdulla Tukay in the field of preservation and promotion of national culture and language. In the spotlight of Gabdulla Tukay is the system of personal names of the Tatars, which develops on the basis of Islamic traditions.The poet repeatedly criticizes the names of the Tatars for deviation from national traditions. In his opinion culture, upbringing, language, including the names should be based on national traditions. In his works G.Tukay often refers to folk variants of anthroponyms and also he himself creates quite original versions of personal names.

XX гасыр башы – татар рухи тормышында тирән эз калдырган чор. «Ул татар мәдәниятенең тизләнеп үсү чоры, милли әдәби барыштагы «алтын дәвер» буларак бәяләнә. Татарларның милләт буларак оешуы милли үзаңның уянуына да, татар мәдәниятенең үсеш юлы билгеләнүгә дә тәэсир ясый» [2, б. 7] Бу җирлектә XX йөз башы әдипләре һәм зыялыларының татар халкының рухи мирасы, аның киләчәге турында уйланулар төп кыйбласына әйләнүе табигый. Милли тарихыбызга яңача караш, мәдәни үсеш юнәлешләре, башка халыкларга иярмичә, үз юлыбызны табарга омтылу – бу чор әдипләренең язмаларында һәрдаим игътибар үзәгендә тора.

Милләтебезнең язмышы турында фәлсәфи уйланулар Г. Тукайның иҗатында төп мотивларның берсен тәшкил итә. Аның «беренче әсәрләрендә үк татар җәмгыятен гыйлем һәм мәдәният ярдәмендә үстерергә чакыру мотивы милли идеология ноктасыннан яңгырый» [2, б. 27].

Бөек шагыйребез Габдулла Тукай – үзенең иҗатын, гомерен милләткә багышлаган тиңсез зат. Аның каләме астыннан чыккан һәр язма татар милләтенең язмышын, аның мәдәниятен, телен, тарихын, әдәбиятын кайгыртуга юнәлгән. Ул үзенең кабатланмас сурәтләү чаралары, үткен теле ярдәмендә татар халкының милли сыйфатларын, психологиясен, дөньяны күзаллау үзенчәлекләрен гаять дәрәҗәдә төгәл һәм тулы рәвештә ачып сала алган. Габдулла Тукай милли телебезне саклауга һәм пропагандалауга гомере буе тугрылыклы кала. Аның иҗатының бөеклеген, тиңсезлеген исбатлый торган төп сыйфатларның берсе – татар халыкның җанлы сөйләм телендә иҗат итү. Г. Тукай әдәби телне халыкның җанлы сөйләм теленә якынайтуда, әдәби тел формалашуда, аның нигезен билгеләүдә бик зур эш башкарды. Күренекле тел галиме В.Х. Хаков күрсәткәнчә, «Габдулла Тукай әдәби телнең элекке тар стиль кысаларыннан чыгарды, заман таләпләренә туры китереп, аңа киң үсеш ачты» [3, б. 206]. Милли телгә игътибар аның үз иҗатында гына түгел, башка әдипләргә карата әйтелгән фикерләрендә дә ачык чагыла. Мисал өчен, 1910 елда Сәгыйть Сүнчәләйгә язган хатында түбәндәге юллар бар: «...Аннан соң Сезнең шигырьләрегездә мин төп халык телендә булмаган сүзләр табам. Аларны катыштырмасагыз икән...» [4, б. 329].

Рухи мирасыбызның асылын тәшкил иткән, татар милләтенең теле һәм мәдәниятенең көзгесе булган исемнәр системасына Габдулла Тукай аеруча игътибар бирә. Татар кеше исемнәре системасының халыкчан булмавын, милли мәдәниятне чагылдырмавын ул ачынып яза. Үзенең публицистик әсәрләре булмасын, ачы телле сатира әсәрләре булмасын, дусларына язган хатлары булмасын – Габдулла Тукай һәрвакыт исемнәргә гаять зур игътибар биреп килә. Татарлар арасында кулланылган исемнәрнең милли рухта булуы зарурлыгын, исемнең җисем белән тәңгәллегенә булган мөнәсәбәте әдипнең «Гаҗәп түгелме?» (1906), «Исемнәремез хакында» (1911), «Казанга кайтыш» (1913), «Мәкаләи махсуса» (1913) һәм башка хезмәтләрендә ачык чагыла.

Татар кеше исемнәре системасының милли традицияләргә нигезләнергә тиешлеге Габдулла Тукайның исемнәргә карата әйтелгән төп фикерләрнең берсе булып тора. Аерым алганда, XX гасыр башында татарлар арасында йөргән исемнәрнең милли булмавы, балаларга кушылган исемнәрнең мәгънәсенә игътибар җитмәү кебек фикерләр

әдипнең «Исемнәремез хакында» мәкаләсендә сатира аша ачык әйтелә. Шагыйрьнең татар исемнәренә булган тәнкыйть фикерләренең сәбәбе – татар исемнәр системасының катлаулы төзелешле гарәби һәм фарсы чыгышлы исемнәрдән торуында. Ул Урта Азиядән кайткан муллалар кушкан исемнәрне тәнкыйтьләп чыга: «бу мәгънәсез, эчтәлексез, катлаулы исемнәр – безнең муллаларның тырышлыгы нәтиҗәсе. Алар әле моның белән генә канәгать булмыйча, безнең чын татар исемнәрен алыштыру белән дә шөгыльләнә башладылар. Тимер, Алтынбәк кебек матур исемнәребезгә -җан кисәкчәсен кушып, катлаулы исемнәр китереп чыгардылар. Бу – татарлар өчен ямьсез һәм оят».

Мәгълүм булганча, Идел буе Болгар дәүләте ислам динен кабул иткәннән соң, исламгача чорда кулланылган борынгы төрки исемнәр акрынлап кулланылыштан төшеп кала. Исем кушуда ислам традицияләренең төрки-татарлар арасында таралуында кискен борылыш Казан ханлыгы яулап алынганнан соң башлана. Көчләп чукындыру сәясәте аркасында ислам халыкның бербөтен милләт буларак сакланып калу символына әверелә. Бу, үз чиратында, гарәби һәм фарсы чыгышлы исемнәрнең активлашуына китерә.

Тел – милләтнең тарихи, иҗтимагый, сәяси үзгәрешләр басымы астында югалмыйча сакланып калуын күрсәткән төп факторларның берсе. Татар милләте вәкиле һәм мөселман булуын ассызыклау максатыннан, татар халкы арасында бу төр исемнәрне кушу бик нык арта һәм шуның нәтиҗәсендә XIX гасырның икенче яртысына татар исемлеге тулысынча мөселманлашып бетә. Мисал өчен, 1816–1879 елларда Казан шәһәрендә ир балаларга иң күп кушылган исемнәр булып *Ибраһим, Хәсән, Муса, Хөсәен, Йосыф, Мостафа, Исхак, Мөхәммәтгали, Мортаза, Хәбибулла, Әхмәт, Мөхәммәт, Мөхәммәтҗан, Исмәгыйль* исемнәре тора.

XIX гасырда исем кушуда тагын бер яңа традициягә нигез салына. Ул катлаулы төзелешле *Мөхәммәтрәхим, Габделгаффар, Габделрәшит, Сәйфелмөлек, Вәлибикмөхәммәт, Бибинәгыймә, Бибитәскирә, Маһисорур, Зәйнәпфатыйма, Миңлегөлҗиһан* кебек исемнәр куллanудан гыйбарәт. Әдип нәкъ менә бу төр исемнәрне тәнкыйть утына тота. Габдулла Тукай милли традицияләрне истә тотып, милли йөзебезне, телебезне сакларга чакыра.

Габдулла Тукай, үзенең югарыда искәрткән мәкаләсендә, исемнең тәрбияви ролен, аның милли рухка туры килергә тиешлеген кат-кат ассызыклый. Исемнәрнең дини генә булып калмыйча, милли тәрбиябезгә хезмәт итәргә тиешлеген әйтә: «Мөселман булганымыз вакыт татар икәнлегемезне дә онытмыйк. Аллаһе Тәгалә исемнәремезне, җисемнәремезне вә рухымызны ислах иләйлә!» − ди ул [4, б. 212]. Әдипнең әлеге фикерләре халык арасында катлаулы төзелешле исемнәрнең артуына һәм аларны куллануда авырлыклар тууга бәйле барлыкка килгән дияргә җирлек бар, чөнки гади халык мәчет кенәгәләрендә теркәлгән рәсми исемнәрне үз җаена кыскартып әйтүне үз күрә: *Садретдин – Садрый, Галәлетдин – Галәй, Мөхәммәтҗан – Хәмәтҗан – Хәмәй, Мөхәммәт – Мәмәт, Габдерәшит – Габдери, Разетдин – Разый, Бибифатыйма – Биби / Фатыйма* һ.б.

Бу төр үзгәртүләр очраклы гына түгел, аның нигезе элекке төрки традицияләргә барып тоташа. Исламгача булган чорда исемнәр кыска төзелешле, җайлы әйтелешле булалар. Кыска формада язма истәлекләрдә теркәлеп калганнары да шактый: *Габдул, Сәфәр, Шәриф, Ибак* (Ибраһим исеменнән кыскартылган форма)*, Әлмәмәт Габдүкәй, Ярүкәй, Исмакай, Муллакай, Ибрай, Дусай, Сөләй, Җәмәй, Шамай* һ.б. Сүз уңаеннан: Г.Тукай халык арасында йөргән мондый төр исемнәрне һәм кушаматларны үз шигырьләрендә дә, халыкчанлык төсмере бирү максатыннан, оста файдалана:

*Кушмый ишан хилкасендә*
*Бик мактыйлар шуларны:*
*Прахут Мәхүп, Чаршау Биби,*
*Гыйлаҗ абзаң Сәрвәри.*
(Кушмый ишан хилкасендә)

* * *

*Гайфи абзый! Кайда күрдең? Син аларны мактадың:*
*Күрмисең тиз уйнаса хәтта, дидең, бармакларын!*
(Казан вә Кабан арты)

* * *

*Кирәк булса, әйтеп бирәм: ул шәп хәзрәт,*
*Тулган ай күк балкып чыккан Шиһаб хәзрәт,*
*Мәгарифкә әүвәл башлап адым салган,*
*Милләт өчен бәһа җитмәс кыйбат хәзрәт.*
(Шиһаб хәзрәт)

Г. Тукай иҗатында үзе яшәгән чорда актуаль һәм популяр булган исемнәр калыбында яңа антропонимнар ясауга да зур игътибар бирә. Мисал өчен «Уральск хәбәрләре»ндәге *Мәхлукулла* антропонимын китерергә була. Шулай ук «Казанда никах мәҗлесе. Бастыру өчен» чәчмә әсәрен карап үтик:

«*Яхшы гына зур бер мәҗлес. Мәҗлеснең бер түрендә Сәмәнетдин хәзрәт, икенче түрендә Мөштәри хәзрәт утырганнар да, берсе никах укый, берсе бу рәвешчә иҗабе кабул сүзләрен әйтә: "Син, кем, Әхмәдһади Максуди, Биби Кәүкәбел-фәна Календаретдин кызыны, вәли-вәкил булып, "Азад"етдин бине Социалистетдин угылына бирдеңме?", – Бирдем, хәзрәтләр! Бирдем.*

*– Ә син, мулла Галиәсгар Камалетдин угылы, вәли-вәкил булып, "Азад"етдин Социалистетдин угылына "Кәүкәбел фәна" Календаретдин кызыны алдыңмы?*

*– Алдым, алдым.*

*Хәерле булсын Хәмидәнең никахы!*»

Әлеге өзектә кулланылган *Биби Кәүкәбел-фәна Календаретдин кызы, «Азад»-етдин бине Социалистетдин угылы* антропонимик формулада кулланылган ясалма исемнәр әдипнең үткен телен, чорның көн кадагына сугардай мәсьәләләрен оста итеп, телнең таблигый структурасындагы калыпларны гаҗәп оста кулланып тәнкыйтьли алуын сәләтен дәлилли торган күрсәткеч санала.

Гомумән, Г. Тукайның иҗатын күзәткәннән соң, исемнәрнең сатирик әсәрләрендә һәм публицистикасында гаять күп очравын һәм аларның эстетик һәм стилистик вазифасын күрәбез.

Татарларның холкында булган чит сүзләргә, исемнәргә, гомумән, чит күренешләргә мөкиббән китүен, бу сыйфатның милләтебезгә зыян китерүен Г. Тукай үз заманында бөтен тирәнлеге белән күрә һәм күрсәтә алган. Дин әһелләре тарафыннан эзлекле рәвештә татар теле өчен ят исемнәрнең халык арасында таратылуына әдип бик борчылып, болай дип яза: «...безнең Чыңгыз, Тимер, Туктамыш, Алтынбик, Япанчы кеби гүзәл милли исемнәребез урынына ...ямьсез, тел әйләнми торган исемнәр тудырганнар. ... Мин бу сүзләрне без татар балаларына анадан тугачук әллә нинди истикъбалемез өчен яман фаллы вә мәшьум исемнәр тагылганына эчем пошканнан яздым. .... Гарәп теле – бай телләрнең дә баерагы. Татар исемнәрендә "Тәлгать"ләр тусын, "Фаикъ"лар күбәйсен, "Фатих"лар җиңеп чыксын, "Рифгать"ләр югары ашсын» [4, б. 212].

Габдулла Тукайның милли телебезне, милли исемлегебезне чит сүзләр һәм исемнәр белән тутыруга каршы фикерләре бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмый. Билгеле булганча, XX гасырның 20–30 нчы елларында татар исемнәр системасына моңарчы кулланылышта булмаган рус һәм Европа телләреннән ят исемнәр үтеп керә башлады. Татар халкының чит исемнәргә кызыгу сыйфаты тагын алгы планга чыкты. Нәтиҗәдә татар исемнәр системасында милли йөзебезне чагылдырмаган, милли телебез, мәдәниятебез өчен ят булган исемнәр үтеп керде. Аларның байтагы татар исемнәр системасына ныклап урнашып, билгеле бер дәрәҗәдә татар исемнәр системасы үсешенә дә йогынты ясадылар.

Милли исемлек – дөнья картинасы, милли психология үзгәрү күрсәткече ул. Шунлыктан кешенең формалашкан милли характер белән тумаганлыгын, бәлки аны җәмгыять кысаларында, социальләшү процессында милли йолалар, тел, мәдәният кысаларында үзләштерүен ассызыклау зарур. Традицион рәвештә кеше исеме милләт көзгесе вазифасын башкара, аның иҗтимагый статусын, кайсы чорда яшәвен күрсәтә. Хәзерге җәмгыять шартларында, үз мәдәниятебез белән чит мәдәниятләр тыгыз бәйләнгән чорда, халыкның милли характеры да формалаша, ул кеше исемнәре аша дөньяга таныла.

Бүгенге татар кешесе, бер яктан, милли традицияләргә нигезләнгән исемнәр сайлауга йөз тотса, икенче яктан, дөнья мәдәнияте кысаларында барлыкка килгән берәмлекләрне үз күрә. Алай гына да түгел, татар җирлегендә көнчыгыш һәм көнбатыш мәдәниятләренең матур үрнәкләрен берләштергән яңа исемнәр уйлап табыла. Бу милләтләрнең тыгыз керешүе шартларында эреп югалмаска, үз милли исемлегебезне

булдырып, саклап калырга ярдәм итә. Шул рәвешле, бүгенге татар кеше исемнәре системасы оригинальлеге, төрлелеге, кабатланмас булуы белән аерылып тора.

Габдулла Тукай, Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Ф. Әмирхан, Р. Фәхретдин кебек күренекле әдипләребез һәм галимнәребез белән беррәттән, татар антропонимик системасында милли традицияләрнең формалашуына зур өлешен кертте. Г. Тукай һәм аның тарафдарлары әйткән фикерләр татар исемлегендә дини эчтәлекле, структур яктан катлаулы һәм татар халкының милли теле өчен беркадәр ят булган исемнәр белән янәшә дөньяви эчтәлекле, этик һәм эстетик зәвыклы гарәби һәм фарсы чыгышлы исемнәр, төрки-татар чыгышлы исемнәр кулланыла башлауга этәргеч булды. Соңрак бу исемнәр татар милли антропонимиясенең нигез ташына әйләнделәр.

ӘДӘБИЯТ


Галиуллина Г.Р. Татарские личные имена в контексте лингвокультурных традиций. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2008. 349 с.

Заһидуллина Д.Ф., Йосыпова Н.М. XX гасыр башы татар әдәбияты тарихы: дәреслек. Казан: Казан ун-ты, 2001. 230 б.

Хаков В.Х. Тел – тарих көзгесе (Татар әдәби теленең үсеш тарихыннан). Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 294 б.

Тукай Г. Сайланма әсәрләр: 2 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 271 б.


## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ ТЕЛ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ


***Галләмов Ф.Г., Ханова А.Ф.***



В статье рассматриваются синтаксические особенности произведений выдающегося татарского поэта Габдуллы Тукая: обособленные определения, синтактико-конструктивные и стилистические повторы, двойные отрицания, сравнительные конструкции, вводные предложения, вводные слова, обращения, ряд однородных членов, диалектная лексика и т.д.

The article presents syntactic particularities in the works of Tatar poet of distinction Ğabdulla Tuqay: unattached phrases, syntactic constructive and stylistic repetition, double negation, comparative constructions, parenthesis, addresses, coordinated row, dialectal words, etc.


Г. Тукай иҗаты әдәбият галимнәрен, шагыйрьләребезне һәм язучыларыбызны битараф калдырмый. Аның иҗаты төрле яклап өйрәнелә, бөек әдибебез иҗатына зур бәя бирелә. Г. Тукай әсәрләренең тел үзенчәлекләре дә аның иҗатын өйрәнүчеләрдә кызыксыну уята. Әдәбиятта Тукай традицияләрен дәвам иттерүче, аның иҗатын өйрәнүче әдипләребезнең берсе булган С. Хәкимне барыннан да бигрәк бөек шагыйребезнең теле сокландыра. Ул Тукай телен югары бәяли:

Мәктәбем дә, телем дә ул – Тукай,
Тукайдагы кебек тел кайда?
Мең елдан соң да синең, илем,
Кайтасыңны беләм Тукайга
(«Кырыгынчы бүлмә»).

С. Хәким, «Туй» шигырендә дә Г. Тукайның «Туган тел» җырына сокланып, түбәндәге юлларны яза:

Тукайдан син әгәр өстен булсаң,
Булсаң бөек, булсаң син даһи,
Башка җыр тап, башка җырны җырла. («Туй»)

Г. Тукайның «Туган тел» җыры татар халкының гимнына әйләнгән, үзеннән-үзе җырлап тора. Ул бик җиңел тел белән, халык теле белән язылган. Җырның беренче юлы туган телгә эндәшү белән башланып китә. Тирән мәгънә салынган берьюлы өч эндәш сүз кулланылган. Эпитетларны алыштырып кабатлавы белән шагыйрь туган телгә булган мәхәббәтен, бөтен уй-кичерешләрен әйтеп бирә алган: *И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!* Бу эндәш сүзләрнең һәр строфа башында, анафора буларак, ымлык белән кабатлануы аның тәэсир көчен тагын да арттыра.

Кабатлауларның төзелеш һәм мәгънә ягыннан барлык төрләре дә бик актив булуы күзгә ташлана. Әдип аларны, төрле стилистик максаттан чыгып, бик оста кулланган.

Г. Тукай әсәрләрендә аваз кабатлауларыннан алып, аерым сүзләр, сүзтезмәләр, хәтта җөмлә кабатлауларына кадәр бар. Билгеле бер стилистик максаттан чыгып, тартык һәм сузык авазлар ешрак кабатланалар. Сузык авазларның кабатлануын – ассонанс, ә тартыкларның ешрак яңгыравын аллитерация диләр. Алар аерым-аерым да кулланылалар, күп очракта бергә дә киләләр. Бу алым Г. Тукай әсәрләренә дә ят түгел, шуңа күрә аның күп кенә әсәрләре матур яңгырашка ия:

*Җиктереп пар ат, Казанга туп-туры киттем карап;*
*Чаптыра атларны кучер, суккалап та тарткалап.*
(«Пар ат»)

Лексик кабатлаулар да бик еш очрый. Мәсәлән, «Государственная Думага» шигырендә эндәш сүз булып килгән *Дума* сүзе, һәр куплетның өченче юлында кабатланып, әсәрнең көчен арттыра:

Ник бик тиз беттең син, Дума,
Ник җир-ирек алмадың? –
Ах, син, *Дума, Дума, Дума,*
Эшләгән эшең бума?
(«Государственная Думага»)

Эпифора – җөмләләрнең, абзацларның, поэзиядә шигырь юлларының, строфаларның бер үк төрле тәмамлануы ул. Эпифора күпчелек шигъри сөйләмдә кулланыла, аның төп функциясе рифма төзүгә кайтып кала. Шулай ук фонетик, лексик, синтаксик һәм строфик эпифораларны күрсәтергә була. «Йокы» шигыренең барлык строфалары да шушы рәвешле бер төрле төзелгәннәр:

Безне адәм иткән *йокы*,
Адәмне алга илткән *йокы*,
Илтеп күккә җиткән *йокы*, –
*Йокы, йокы, йокы.* («Йокы»)

Синтаксик эпифораларда сүзтезмәләр, бер үк җөмлә кисәкләре, бер үк җөмләләр, строфалар кабатлап биреләләр. Строфик эпифорага мисал итеп, «Бәйрәм бүген» шигырен китерергә була. Анда строфалар бер үк сүзтезмәләргә тәмамланып кына калмыйча, алар кабатланып та кулланылалар.

Синтаксик яктан кабатлауларның түбәндәге төрләрен аерып күрсәтергә мөмкин. Җөмлә кисәкләренең кабатлануы мәгънәне көчәйтү өчен кулланылганнар:

Иртәгесен шүрәлеләр бу фәкыйрьне тиргиләр:
– *Син* җүләрсең, *син* котырган, *син* тилергәнсең, – диләр.
(«Шүрәле»)

Тик кенә торгандә капланды томанга бар һава;
*Кар* оча, *кар* себерелә, *кар* котрына һәм *кар* ява.
(«Буран»)

Кайгы *нигә*? Шатлык *нигә*? Гомер *нигә*? –
Мондый юк-бар нәрсәләрдән бизсен иде.
(«Утырышу»)

*Монда* тудык, *монда* үстек, *мондадыр* безнең әҗәл;
(«Китмибез!»)

Шулай ук синтаксик параллельләр күп кулланыла, алар да кабатлауларга нигезләнгәннәр:

*Китә рәхәт «килә башлый» дигәнче;*
*Яшен һәм юк була «яшьни!» дигәнче.*
(«Шекспирдан»)

Сүзтезмә кабатлаулары да актив:

*Кызганыч хәл, кызганыч хәл, бик кыен бит, бик кыен*;
Бирсәңезче бер тиен, тәңкә түгелбит, «тиен».
(«Теләнче»)

Синтаксик яктан җәенкеләндерелеп кабатланулар бик күп. Бу очракта кирәкле сүзнең мәгънә ягыннан тәгәлләнүе аның тәэсир көчен арттыра:

*Шәп иде! Бик шәп иде,* мин шуннан артык ни диим?
Шыр ялангач бит, күрәмсез, бирсәңезче бер кием.
(«Теләнче»)

*Бара* болар. *Тукталмастан һаман бара.*
Күрә болар: ерак түгел бер ут Яна
(«Кәҗә белән Сарык хикәясе»)

*«И Хуҗа, безгә ризык биргән Хуҗа!» –*
Дип, сакалын селкетеп сөйли Кәҗә…
(«Кәҗә тугърысында»)

Композицион ялгау рәвешендәге кабатлаулар аерым гыйбәрәләрне бик шома үзара бәйләү өчен файдаланылалар. Аларның төрле синтаксик функцияләрдә кабатлануы күзәтелә һәм төрле модельләрен аеры күрсәтергә мөмкин:

а) «хәбәр – кире шарт хәле»:

Тегермән *әйләнә; әйләнсә дә,* тартылмыйдыр ярма;
(«Мөтәшагыйрьгә»)

Билгеле инде, сыер һич андый төстә булмый ул;
*Юк-югын; юк булса да*, безнең тарафта булды ул.
(«Күк сыер»)

б) «хәбәр – вакыт хәле»:

Ул таныш кырлар, болыннар *тартты* әүвәл хиссеми;
*Тарта торгач,* куймады, кайтарды ахыр җисмеми.
(«Туган җиремә»)

в) «хәбәр – хәбәр»:

Яшь вакытта *яшьнәдем*, көчле вакытта *күкрәдем;*
*Яшьнәмим дә, күкрәмим дә –* утсыз инде күкрәгем!
(«Үтенеч») һ.б.

Модаль кисәккә әйләнгән кабатлау төрләре дә урын ала:

*Әйтсәм әйтим* инде сезгә: бу Кеше бик бай иде;
Эчкәне балдан, шикәрдән, ашлары тик май иде
(«Теләнче»)

Кире кабатлаулар ярдәмендә дә интенсивлык һәм мәгънә көчәйтелә:

*Мин качамын – ул куадыр, ул куадыр – мин качам*
(«Су анасы»)

Чагыштыруларның бик күп төрләреннән файдаланып, бер үк чараларны кабатлау юлы белән рифмалаштырып, шигъри әсәрләренә яңа яңгыраш бирә:

Кибеп беттек, Саргайдык без, Корып беттек *Таяклардай*;
Иснәп нәҗес Ләззәтләндек Бөтенләй *кыргаяклардай.*
(«Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр»)

Зур бу урман: читләре күренмидер, *диңгез кеби,*
Бинићая, бихисаптыр, *гаскәри Чыңгыз кеби.*
(«Шүрәле»)

Ул коточкыч сачларыннан *чишмә төсле* су ага.
(«Су анасы»)

Кыш. Буран, салкын һава, *яфрак кадәрле* кар төшә,
Җил куа карны, һаман да кар «төшәм»дип тартыша.
(«Теләнче»)

Салынып төшкән килешсез мыегы –
Бик озындыр, *мисле күсе койрыгы.*
(«Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш»)

Кабатлаулар белән чагыштыруларны бер синтагма эчендә куллану бирергә теләгән фикерне көчлерәк итә:

Башларын салындырып һәм кәкре-бөкре боргалап
Йөрделәр бу карт янында, *Юрга тайдай юргалап.*
(«Теләнче»)

Аергычлар, инверсия булганда гына аерымланалар. Аларның иң күп кулланыла торган урыны шигъри әсәрләр. Г. Тукай шигырьләрендә аерымланган аергычларның бик матур үрнәкләрен табарга мөмкин:

Ындырда юк орлык,
Иген юк *урырлык;*
Атың бар бик начар,
*Өч тәңкә торырлык.*
(«Мужик йокысы»)
Җиктеләр пар аттан,
Өй салып нараттан;
Синең йортта аш юк
*Туярлык таракан.*
(«Мужик йокысы»)
Бәйрәм өчен биш-ун тәнкә бирче, абзый!
Өйдәбер бөртек чәй, шикәр *бер шакмак* юк.
(«Бер гәзитә идарәсе хәленнән»)
Шул вакытта әллә кайдан чыга Инсан,
*Кулларына балта берлән чүкеч тоткан;*
(«Япун хикәясе»)

Тege яки бу фикерен үтемлерәк итеп раслау өчен, икеләтә инкяр формаларыннан да бик оста файдалана:

Анларны мин нукталыйм,
Һич кызанмыйчук талыйм;
Зур корсаклы байларны
*Каезламый туктамыйм.*
(«Мактанышу»)
Татарларны мин җигәм,
Минем кулымда җөгән;
*Ник җикмәскә,* татарлар
Җебегән бит, җебегән.
(«Мактанышу»)
*Кайда аңлау миңа!* Бер сүз дә аңламыйм…
(«Утырышу»)
*Җитмәгәнме* бер хатын, өч-дүрт хатын асрау нигә?
(«Тотса мәскәүләр якаң!»)
Кәҗә белән Сарык хәзер китсен бездән,
Аларны соң асрап торып *ни файда бар*?
(«Кәҗә белән Сарык хикәясе»)
*Бармыни* бездә гомумән чын кеше кадрен белү?!
Без аны кайдан белик, мискин үлеп аңлатмагач?!
(«Хөрмәтле Хөсәен ядкяре»)

Г. Тукай әсәрләре тиңдәш кисәкләрнең рәтләре озын, күләмле булуы белән аерылып тора:

Җөмләтән изге икән ич: *инешең, чишмәң, кырың,*
*Юлларың, авыл, әвен, кибәннәрең дә ындырың*;
(«Туган җиремә»)
Җәй көне. Эссе һавада мин суда *койнам, йөзәм;*
*Чәчрәтәм, уйныйм, чумам, башым белән суны сөзәм.*
(«Су анасы»)

Г. Тукай әсәрләре үзенең модаль кисәкләрнең актив кулланылуы белән үзенчәлекле:

Ул кибетләр, *мин сиңайтим,* ул хисапсыз маллары, –
Кайсын алсаң шунсы хәзер: гөлләреме, аллары?
(«Теләнче»)

Кереш сүзләр, кереш җөмләләр, керешмәләрнең төрле төзелештәге һәм төрле максатлардан чыгып кулланылуын күрергә мөмкин. Бу мәсьәләгә аерым мәкалә багышлаган иде [1].

Эндәш сүзләр Г. Тукай әсәрләрендә күпчелек ымлыклар белән, я булмаса, аергычлар белән җәенкеләндерелеп кулллланылалар:

Сау бул инде, хуш, бәхил бул, *и минем торган җирем,*
Мин болай, шулай итәм дип, *төрле уй корган җирем.*
(«Туган җиремә»)

*И мөкаддәс моңлы сазым!* Уйнадың син ник бик аз?
(«Өзелгән өмид»)

Г. Тукайның ирекле тәрҗемә әсәрләре алынма мөнәсәбәтле сүзләрнең кулланылуы белән аерылып тора. Татар телендә алынма мөнәсәбәтле сүзләр белән бәйләнеш фарсы теле тәэсирендә бик борынгы чорларда ук формалашкан. Соңрак бу бәйләнеш төре Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә актив кулланылыш тапкан. Аларны Г. Тукай һәм Һ.Такташ та бик яратып кулланганнар. Академик М.З. Зәкиев раславынча, бу төр бәйләнеш төрки телләрдә, шул исәптән татар телендә дә фарсы һәм рус телләре тәэсирендә барлыкка килгән [2, б. 381]. Безнең күзәтүләр күрсәткәнчә, алынма мөнәсәбәтле сүзләр ярдәмендә күпчелек аергыч һәм вакыт, сирәгрәк, тәмамлык, урын һәм рәвеш җөмләләр генә ясала.

Алынма парлы мөнәсәбәтле сүзләр ярдәмендә а) иярчен урын җөмләләр күп кулланылган:

Тиз китик без *шунда, кайда*
Җәелгән ямь-яшел кырлар, болыннар;
(«Мәхбүс»)

Вә [тиз китик без] *шунда, кайда* диңгезләр төтен күк
Булып күренәдер күзләргә, күм-күк
(«Мәхбүс»)

Вә [тиз китик без] *шунда, кайда* аулак, җил дә мин
Йөрербез бергә-бергә син дә мин тик
(«Мәхбүс»).

Ярда торган ач халыкка йөз дә бормый, туп-туры
Юргалый ул *шунда* тиз-тиз, *кайда* бай сайфиясе.
(«Сайфия»)

б) Иярчен аергыч җөмләләргә мисаллар:

Качасиде моннан, … *шул* җирләргә*: кайда* сайрый кошлар…
(«Кярханәдә»)

Бәхетле *шул* баладыр, *кайсы* дәрсенә күңел бирсә,
Мөгаллимне олугъ күрсә, белергә кушканын белсә.
(«Бәхетле бала»)

Уйнасын *шул* бәндә, *кемнең* акчасы бар, вакты бар;
(«Картлар»)

Алынма ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр белән бәйләнеш тә бер дәрәҗәдә кулланылган. Бу синтаксик чара ярдәмендә түбәндәге иярчен җөмлә төрләре бәйләнеп килгән:
а) Иярчен аергыч җөмләләр:

Аз шул бездә байлар, *кайсысы кем* фәрештәдән канат каермас;
(«Эштән чыгарылган татар кызына»)

б) Иярчен рәвеш җөмләләр:

Бераз елдан соң укып бу шигырьне
Карарсың, бәлки, бу хәсрәтле җырны,
Вә уйларсың: *ничек* шагыйрь яраткан,
*Ничек* янган, синең өчен җан аткан
(«Байроннан»),

Нигә мин тормадым бер читтә ялгыз,
*Ничек* күктә яна бер данә йолдыз
(«Үкенеч»).

Ходай шунда җан биргән, мин шунда туган,
Шунда әүвәл Коръән аятен укыган;
Шунда белдем рәсүлемез Мөхәммәдне,
*Ничек* михнәт, җәфа күргән, *ничек* торган.
(«Туган авыл»)

в) Иярчен урын җөмләгә мисал:

Утыр аулакка, *кайда* һич кеше юк,
Сабыйдай, тәмле-тәмле күз яше түк
(«Киңәш»)

Г. Тукай әсәрләре халык теленә бик якын, диалектизмнарның урын алуы моның ачык мисалы булып тора. Урта диалектның Казан арты сөйләшенә генә хас бик күп диалектизмнар куллану күзәтелә:

Бәхетле нарасидә! Тар бишек тә киң әле *аңгар!*
Ике ат бер тиен, диңгез тубыктан тиң әле *аңгар!*
(«Бишектәге бала»)
Сездән айрылып, туганнар! – җайсыз, *уңгайсыз* тору;
Бу тору, әйтергә мөмкиндер, кояш-айсыз тору.
(«Пар ат»)
Бүрәнәнең бер очында бар *әчелгән* ярыгы,
Шул җиреннән нык кына син тот, и урман сарыгы!
(«Шүрәле»)
Китте кушкан җиргә, атлап адымын *ире-ире;*
(«Шүрәле»)
*Куйд*ы илтеп аузын *әчкән* бүрәнәгә бармагын…
(«Шүрәле»)
Ябалагым бер-ике рәт чукып ертты,
Күз *әчкәнчә* Чыпчык та бете, вәссәлам!
(«Һәркемнең ашыйсы килә»)
Бетте әүвәлге очынмаклар, – авыр ул гер кеби;
Һич *әчелмәскә* мәхәббәткә йомылган керпеги.
(«Соңра»)
Өст-башын салган; вәләкин шикләнә
Су салырга тәнгә, чөнки *чиркәнә.*
(«Кызык гыйшык»)
Какты-суктым – *әчелде*, Тәңкәләре чәчелде;
Эте чыкты *өрмәгә*, Кызы чыкты *күрмәгә*;
(«Күк сыер»)
Күзем белән озаттым: кошчыгым *урман таба очты,*
Югалды күк йөзендә тиз вакытта, бер дә юк төсле
(«Кошчык»)
*Син кеби* һәм ул теләнчеләр дә – алланың колы;
(«Нәсихәт»)

Шулай итеп, Г. Тукай иҗатында халык теленә хас булган бөтен үзенчәлекләр дә чагылыш тапкан, шуңа күрә дә аның әсәрләре халыкка якын, халыкчан. Халык шагыйре С. Хәким әйтмешли, Аның шигырьләре халык җырларының дәвамы булып яңгырыйлар. Күбесенең халык авыз иҗатына нигезләнеп язылган булуы («Су анасы», «Шүрәле», «Кисекбаш» һ.б.) Тукайны халыкка тагын да якынайта.

ӘДӘБИЯТ

1. Галләмов Ф.Г. Г. Тукай әсәрләрендә керешмәләрнең кулланылу үзенчәлекләре // Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар: Г. Тукайның тууына 125 ел тулуга багышланган Халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. Казан, 2011. Б. 222–224.
2. Татар грамматикасы. Т. 3. М.: Инсан; Казан: Фикер, 1999. 512 б.

## ДИЛӘРИЯ АБДУЛЛИНАНЫҢ «ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИҖАТЫНДА КОРЪӘН МОТИВЛАРЫ» ХЕЗМӘТЕ

***Ганиева-Гыйниятуллина А.Ф.***

В статье анализируется монографическое исследование Д.М. Абдуллиной «Коранические мотивы в творчестве Габдуллы Тукая», подчеркивается его новизна в тукаеведении.

This article analyzes the monographic study done by D.M. Abdullina and dubbed "Qu'ran motives in the works of Gabdulla Tukay". The novelty in G. Tukay studies is emphasized in the monographic work as well.

XX йөз башында иҗат ителгән Г. Тукай әсәрләре бүгенге укучының да йөрәгенә үтеп керә, аның күңел кылларын тибрәтә. Бу исә әлеге шигъриятнең вакыт сынаулары-на бирешмәвен, халкыбызның мәдәни байлыгына әверелүен күрсәтүче фактор. Тукай иҗатының үлемсез булуы нәрсә белән билгеләнә соң? Теләсә кайсы иҗат ул язучының эчке халәте, акылы һәм дөньяга карашларының синтезыннан гыйбарәт. Тукайның үз халкының авыз иҗатын, гореф-гадәтләрен яхшы белүе, көнчыгыш һәм гарәп әдәби-ятын укуы, рус мәктәбендә белем алуы, Европа әсәрләре белән яхшы таныш булуы аны ныклы хәзерлекле каләм әһеле итә. Монда, бер яктан, нәселдән килгән зыялылык, аң-белемгә омтылыш, Аллаһ тарафыннан бирелгән талант, үзенең шәхси характеры, тырышлыгы зур роль уйнаса, икенче яктан, әйләнә-тирә мохит, заманның алдынгы фи-керле кешеләре белән аралашу аның шәхес буларак формалашуына зур йогынты ясый, иҗатын дөнья аренасына чыгара.

Тукай иҗаты – татар әдәбияты фәнендә иң күп өйрәнелгән иҗат. Һәр заман аны үз күзлегеннән чыгып бәяли, үзенә яраклаштырырга омтыла. Илебездә дингә мөнәсәбәт төрле чорда төрлечә булганлыктан, табигый, Тукайның дини карашларын өйрәнүдә дә фикерләр бертөрле генә булмый. Диләрия Абдуллинаның «Габдулла Тукай иҗатында Коръән мотивлары» дигән китабы Тукай фәне өлкәсендә һичшиксез зур алгарыш булды.

Галимә шагыйрь иҗатының асыл нигезен – динилеген өйрәнеп, фәнни ачышлар ясый, Коръәннән китерелгән мисаллар белән фикерләрен дәлилли. Ул хезмәтенең бе-ренче бүлегендә Тукай үзе яшәгән чордан алып бүгенге көнгә кадәр шагыйрь иҗаты-ның динилеге мәсьәләсен өйрәнү тарихын яза. Илдә барган иҗтимагый-сәяси үзгәре-шләргә бәйле Тукай иҗатындагы дини карашларга мөнәсәбәтне өч чорга бүлеп өйрәнә:

1) 1905–1917 еллар;

2) 1917–1980 елларның беренче яртысы. Ул үз эчендә икегә бүлеп карала:

а) тоталитар чор – 1917–1956;

б) посттоталитар – 1956–1985;

3) 1980 еллар азагыннан безнең көннәргә кадәр.

XX йөз башы татар тормышының иң әһәмиятле – милләт буларак үзбилгеләнү чоры. Шулай ук аның мәдәнияте-сәнгате дә зур яңарыш кичерә. Моңарчы дини-су-фичыл һәм Көнчыгыш традицияләре белән үскән татар әдәбияты рус һәм Европа мәдә-ниятенә йөз белән борыла. Д. Абдуллина язганча, бары тик татар әдәбияты җирлегендә генә Шәрекъ-Гареб синтезы барлыкка килә. [1, б. 7]. Шул нигездә әдәбият мәйданын-да яңа төр романтизм һәм реализм методлары үсеп чыга, еш кына бәхәскә дә керә. Хезмәтнең авторы капма-каршы позициядә торган ике зур фигурага аерым тукталып, аларның Тукай иҗатының динилегенә мөнәсәбәтләрен билгели. Аның берсе җәмгы-ятьче, ягъни реалистик әдәбият тарафдары – Җ. Вәлиди, икенчесе рухиятче –романтик юнәлешне хуплаучы Г. Ибраһимов.

Әдәбият белемендә «Беренче Тукайчы» бәяләмәсен алган Җ. Вәлиди шагыйрь иҗатын аның тормыш юлы, дөньяга карашы белән бәйләп карый. Динне дә ул Тукай дөньясының аерылгысыз бер өлеше итеп күрсәтә.

Г. Ибраһимов Тукайның динилеге мәсьәләсенә уңай яки тискәре мөнәсәбәтен белдермәстән, шигырьләренең югары сәнгать дәрәҗәсендә язылмаганнар дип бәяли. Чөнки романтик эстетика күзлегеннән караган Г. Ибраһимов Тукайның реалистик ши-гырьләрен кабул итә алмый.

Тукайның иҗатына үз чордашларының бәяләмәләре шул заман сулышын тою, аңлату ягыннан да бик әһәмиятле.

1917 елгы инкыйлабтан соң Тукай иҗаты өчен куркыныч дәвер башлана. Д. Аб-дуллина шагыйрь иҗатына карата башланган яңа мөнәсәбәтнең иҗтимагый-сәяси сәбә-пләрен аңлата. Турыдан-туры динне инкяр иткән җәмгыятьтә дини эчтәлек белән суга-рылган Тукай шигъриятенең яшәве шик астында кала.

Ф. Бурнаш, Ф. Әмирхан, Җ. Вәлиди, Г. Халит, Г. Рәхим кебек тәнкыйтьчеләр ша-гыйрьнең дини эчтәлекле әсәрләрен күпертеп тормастан, аны «халык шагыйре» дип атыйлар һәм шулай саклап калырга тырышалар, ә Ф. Сәйфи-Казанлы, Г. Толымбай, М. Максуд, соңрак Г. Сәгъди дә Тукайны «вак буржуазия шагыйре, динче, милләтче» дип бәялиләр һәм яңа җәмгыятьтә аңа урын булмаска тиеш дип белдерәләр.

Дингә каршы көрәш сугыш чорында бераз йомшап торса да, Совет кешесен интернациональ рухта динсез, милләтсез, тамырсыз итеп тәрбияләүне максат итеп куйган җәмгыять 60 еллардан яңа көч белән дингә каршы ут ача. Тукай иҗатын үз

мәнфәгатьләрендә файдаланган хакимият инде шагыйрьне атеист итеп күрсәтүгә кадәр барып җитә. Д. Абдуллина З. Ишмөхәммәтовның «Тукай атеизмы» (1971) китабына аерым туктала. Авторның каршылыклы фикерләрен анализлап, «З. Ишмөхәммәтов кебек фәлсәфәче дә кире кага алмагач, димәк, бөек шагыйребез Тукайның исламга һәм Илаһияткә булган ышанычын, бу инануның иҗатына да тирән йогынты ясавын кире кагу мөмкин түгел, күрәсең» – дигән фикергә килә [1, б. 38].

60–80 елларда Тукай иҗатын өйрәнүгә күп көч куйган Агишев, Г. Халит, Х. Госман, И. Нуруллин, Р. Нәфигов, М. Гайнуллин, И. Пехтелов, Н. Лаисов, Р. Бикмөхәммәтов, И. Нигъмәтуллина, Э. Нигъмәтуллин, Н. Юзеев һ.б. галимнәр шагыйрьнең динилеген кире какмастан, дөньяга карашларының чикләнгән булуы турында яза башлыйлар.

80 еллар ахырында илдә башланган үзгәрешләр Тукай иҗатын яңа күзлектән бәяләргә юл ача. Озак еллар дәвамында күләгәдә калган дини эчтәлекле әсәрләргә объектив бәя бирелә башлый. Шагыйрьнең 110, 115, 120 еллык юбилейларына багышланган фәнни-гамәли конференцияләрдә «Тукай һәм дин» мәсъәләсенә карата яңа гадел фикерләр әйтелә.

Д. Абдуллина үзенең остазы Р. Ганиеваның эшчәнлегенә аерым тукталып, аның Тукай фәне өлкәсендәге даими эзләнүләрен күрсәтә. «Резеда Ганиеваның татар әдәбияты һәм Шәрыкъ әдәбиятлары арасындагы күчемлелек, традицияләр дәвамлылыгын өйрәнү юлындагы ачышлары, моңа кадәр ислам динен кире кагуга мөнәсәбәтне, бары тискәре яктан гына телгә алына торган Шәрыкъ мәдәниятенә уңай караш формалашуга юл ачты, бу исә үз чиратында Тукай иҗатын бәяләүдә дә яңа мөмкинлекләр тууга сәбәп булды. Алга таба дөнья күргән хезмәтләрдә Тукай иҗатындагы шәркый мотивлар шагыйрьнең кимчелеге буларак түгел, ә иҗатының тулы хокуклы бер өлеше сыйфатында карала башлады» [1, б. 46] дип яза Д. Абдуллина.

Г. Тукай тесно сотрудничал с выдающимися азербайджанскими писателями Джалилом Мамедкулизаде, Нариманом Наримановым и другими, перевел на татарский язык стихотворение М.А. Сабира «Стон муллы», сатиру, начинающуся со строки «Разрывается, Ханбаджи, сердце от горя». Причиной перевода этих стихотворений на татарский язык, являлась их близкое созвучие с жизнью татарского народа. В его поэзии, также как и у Сабира, существует ненависть к режиму Магомедали шаха, Султана Абдульгамида. Иногда бывает и так, люди, не подчиняющиеся требованиям своего времени, ясно мыслящие, вынужденно подвергались преследованию, гнету, стеснению. В связи с напряжением исторической обстановки, человек вынужден отдалиться от родины, иногда приходится соглашаться с этой, созданной историей обстановкой, а порой и нет. Для поэта судьба нации является превыше всего, он не хочет оставлять попавшую в затруднительное положение родину, народ невежам, критикует тех, кто считает другие страны родиной и предпочитают жить в удобстве вдали от страны. Тукай в стихотворении «Не уйду» так отвечает предателям, старающимся отдалить их от родины.

Вот, что предлагают нам бесчестные с не чистою душой:
«Подойдите-ка вы к султану, тут нет светлой жизни вам».
Нет, не пойдем мы в изнывающий от гнета край,
И там мы встретим таких же, как здесь лазутчиков.
И там есть жандармы, избивающие говорящих правду.
Которые отличаются лишь только тюбетейками.
И там есть казна, грабитель, большое спасибо!
Есть грабители бедных сельчан, большое спасибо!
...Вот наш краткий ответ, таким как вы, господам:

Когда говорим «Молла Насреддин» и Габдулла Тукай, в первую очередь должны отметить, что именно журнал «Молла Насреддин» сообщил весть о смерти поэта, упомянув его с глубокой скорбью. В 1913-м году в журнале «Молла Насреддин» прошла такая заметка о гибели поэта. «Молла Насреддин» несмотря на свой сатирический дух за все время деятельности третий раз (в 1908-м году о Лейла ханум Шыхлинской, в 1911-м году о Сабире) с большой скорбью объявил читателям о смерти Тукая, и выражал сочувствие горю татарских товарищей… Журнал по своему духу нес сатирическое содержание, в нем публиковались статьи, вынуждающие народ вдуматься сквозь смех. Но бесконечная любовь к Тукаю нашло свое отражение в заметке о его смерти. Этот некролог излагал в себе образец бесконечной любви азербайджанского народа Тукаю. Журнал с начала своей деятельности печатал некролог о 3-х личностях, одним из которых был Г. Тукай.

«...В 1913-м году студенты-азербайджанцы, обучающиеся в Киеве возвысили Тукая, как писателя, на первое место, держа его наравне с русским поэтом Пушкиным…»

Весть о смерти самоотверженного поэта татарского народа Г. Тукая глубоко затронул выдающего деятеля, публициста, переводчика Джейхун бека Гаджибейли. Джейхун бек Гаджибейли смотрел на мусульман Кавказа и татаров с призмы «единого рода, единой религии, единого языка и единого мировоззрения». По его мнению, интеллигенция не должна стесняться своего национального языка, национальной литературы, искусства, не должна стараться быть похожим на «европейские образцы», потерявшие свою индивидуальность. «Новое поколение интеллигенции, которая только становиться, должна быть движущей силой, продолжающей традиции своих гениальных предшественников как Гасан бек Зардаби, М.А. Сабир, Г. Тукай и других, должны вести народ к независимости и освободить».

Критика колониальной идеи советской буржуазии XX века, держать народы Средней Азии в неволе, сеять среди них семена рабства составляла одну из основных направлений творчества Тукая. Его творчество играло роль маяка, указывающего дорогу народу. Тукай с нетерпением ждал пробуждение татарского народа, с нетерпением ждал когда придет «татарская весна» и «здешние соловьи» будут распевать свой трель.

Сказав «Пусть пройдут над нами птицы, да придет весна татарин», поэт в своих стихотворениях создал подстрочные смыслы. В строках «пусть пройдут над нами птицы» поэт намеками доводит до читателя, что татарский народ живет под игом русской колонии. В начале XX века это стихотворение поэта звучало как марш среди татарского народа. Обращаясь людям «Встань! Отряхнись! Оживи, татарин. Сделай шаг вперед» поэт призывает свой народ национальному объединению.

Поэзия решительного поэта-борца после себя открыла новый путь в татарской литературе. Сыгравший большую роль в становлении и формировании татарской литературы Габдулла Тукай оказал сильное влияние на развитие созданного впоследствии нового типа татарской литературы. Современная татарская литература продолжает и развивает открытую им тропинку.

ЛИТЕРАТУРА

1. Миннулин К. Поэзия, перешагнувшая столетие // Наследие Габдуллы Тукая в контексте национальных культур: Материалы международной научно-практической конференции, посвященной 125-летию со дня рождения Габдулла Тукая (Казан, 25 апреля 2011 г.)

2. Xəlilov P. Q. Tukay. Qabdulla Tukay Azərbaycan ədəbiyyatşünaslığında. Bakı, Elm və təhsil, 2012.

3. Məmmədov A. Q. Tukay və cədidizm. Qabdulla Tukay Azərbaycan ədəbiyyatşünaslığında. Bakı, Elm və təhsil, 2012.

4.Tukay Q. Secilmiş eserler. Ankara, Türk Kültür ve Sanatları Ortak Yönetimi. 2006.

5. Mirəhmədov Ə. Məqsəd bir olanda. Qabdulla Tukay Azərbaycan ədəbiyyatşünaslığında / Tərtibçi və ön sözün müəllifi M. Həsənova. Bakı, Elm və təhsil. 2012. S. 283.

## ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ТӘНКЫЙТЕНДӘ ҺӘМ ПУБЛИЦИСТИКАСЫНДА ГАБДУЛЛА ТУКАЙ

***Гыйлаҗев Т.Ш.***

В статье анализируются посвященные Тукаю литературно-критические и публицистические работы Гаяза Исхаки, в которых раскрывается философская и общенациональная сущность его наследия. Писателем выявляются основные характеристики его поэзии: народность, национальность и татарский дух; критик считает Г. Тукая основателем новой реалистической литературы. Г. Исхаки высоко оценив место Тукая на литературном поприще и раскрыв сакральное значение его творчества, увековечил имя поэта в истории татарской литературы и культуры.

The article throws attention to critical essays and nonfictions of a Tatar classical writer Gayaz Iskhaki, who gave social, national, philosophical and aesthetic review to G. Tukay creations. Gayaz Iskhaki examined the national spirit of the poet poems and appreciated him as a founder of new Tatar literature. The article shows the role of Gayaz Iskhaki in honoring G. Tukay's invaluable contribution to Tatar culture, history and literature, in keeping works as a treasure house of that period gems as well as memorizing his name.

XX йөз башы татар прозасының һәм милли шигъриятенең үсешен тәэмин иткән фикердәшләр Г. Исхакый белән Г. Тукайга дөньявилыкта күрешеп сөйләшү, бер-берсенә җылы һәм иҗтирами мөнәсәбәтләрен белдерү насыйп булмаса да, алар әдәби иҗатта аңлашып, уртак идеалга хезмәт иткәннәр. Г. Исхакый төрле жанрда дөнья күргән язмаларында, шагыйрь күңелле иҗат кешесе буларак, Г. Тукай шәхесенә һәм рухи мирасына үз мөнәсәбәтен белдерә. Аның мәкаләләре үзе нәшир иткән «Ил», Сүз», «Яңа милли юл» һәм, язылу максатына карап, «Мәктәп» журналларында һәм газеталарында басыла. Исхакыйның Тукайга багышланган мәкаләләренең саны бер дистәгә җыела. Болардан тыш әдип төрле максат белән төрле жанрда язылган күпсанлы мәкаләләрендә, күзәтүләрендә һәм хатларында шагыйрь шәхесенә һәм поэзиясенә мөрәҗәгать итә.

Г. Исхакыйның гыйльми-тәнкыйди, публицистик һәм әдәби мирасында Тукай темасы, ике арадагы әдәби бәйләнешләр мәсьәләсе И. Нуруллин, А. Әхмәдуллин, Х. Миңнегулов, Р. Ганиева, Ф. Мусин, Н. Дәүләт, Ә. Сәхапов, Д. Заһидуллина, А. Шәмсутова хезмәтләрендә теге яки бу күләмдә яктыртылды. Шигърият белгече Т. Галиуллинның «Гаяз әфәнде – шагыйрьдер» (2008) язмасының, лиризм белән өретелеп, шагыйранә стиль белән язылган беренче бүлеге Тукай гыйльмиятенең бу аспектын иҗтимагый-фәлсәфи һәм эстетик ноктадан анализлавы белән аерым урында тора.

«Тукай һәм Исхакый... Татарның бу бөек ике әһеле, аларның үзара мөнәсәбәте – һәм әхлакый, һәм инсани, һәм милли ноктадан гаҗәеп кызыклы, гаҗәеп актуаль мәсьәлә. – дип яза Х. Миңнегулов. – Тукай Исхакыйда «даһи» кешене, милли таңны аттыручы затны, зыялыларның остазын күрә, хәтта аны билгеле бер дәрәҗәдә иляһилаштыра да. Г. Исхакый да, гәрчә алар һич очрашмаса, Тукайны элек-электән хөрмәт иткән, аны олуг шагыйрь дип таныган, илдә вакытта да, мөһаҗәрәттә дә әдип хакында уңай фикерләр әйткән, бай эчтәлекле мәкаләләр язган» [14, б. 165–166].

1910 елда Төркия оешмасында укылган докладында Г. Исхакый татар шагыйрьләре арасында «...фикерле шагыйрьләребез бардыр, ләкин аларның иң алдынгы карашлысы, һич шөбһәсез, Габдулла әфәнде Тукаев исемле егерме-егерме бер яшьләрендәге бер яшь егеттер» [9, б. 198 ], – дип, Тукайны татар дөньясының иң беренче шагыйре итеп таный. Тукайның татар әдәбияты яңарышындагы урынын «яңа әдәбиятны нигезләүче» сыйфатында карап, шагыйрь иҗатының асыл хасиятләренән чыгып, аны «халык шагыйре», «милли шагыйрь» дип бәяли. Исхакый Тукай шигриятенең фикри-мәгънәви тирәнлеген, рухи байлыгын, дини мифологиягә мөрәҗәгать итеп, «милли зәмзәм коесы» белән чагыштыра: «Аның төптән килми, артмый торган шигырь хәзинәсе алган саен кимеми торган, алган саен саклана торган милли зәмзәм коесына әвереләчәктер. Шул зәмзәм коесының тирәсендә бик күп еллар, йөз елларга кадәр сусаганлыкларын бастырырга теләүчеләр булачаклар. Суга теләнергә, пакьләнергә теләгәннәр пакь су табачаклар» [10, б. 55]. Тукай иҗаты һәм шәхесенең халык күңелендә мәңге яшәячәген, әсәрләренең, еллар үткән саен, яңа яклары белән ачылачагын, «татар милләте яшәгәнгә кадәре Тукай яшәячәк» икәнен кат-кат ассызыклый. Татар мәдәниятен, мәгърифәтен һәм әдәбиятын үстерүгә керткән өлешен, Тукай киңкырлы эшчәнлегенең кыйммәтен танып, аны «мәдәни, гыйльми, әдәби хезмәтләрнең зур гамиле (хәкиме)» [9, б. 286] булачак дигән өметен белдерә.

Тукайга тумыштан бирелгән шагыйрьлек сәләте, язучылык таланты һәм иҗаты хакында әхлакый-фәлсәфи уйлануларын Исхакый культура-тарих мәктәбе кагыйдәләренә нигезләнеп оештыра. «Гадәттә, теләсә нинди мәктәп, юнәлешнең башында торучысы, илһамчысы була,– дип яза Д. Заһидуллина.– Татар җәмгыятьчеләр мәктәбенең нигез баганаларын утыртучы булып Гаяз Исхакый калкып чыга һәм сәнгать белән фәнне, эстетика белән фәлсәфәне көрәш идеясенә бәйли» [5, б. 173]. «Тукай халык шагыйре булып туды, халык шагыйре булып үсте» [9, б. 294] дип, Тукай иҗатының татар халкы идеаллары һәм теләк-омтылышлары, иҗтимагый-милли тормыш белән тыгыз бәйләнешен күрсәтә. «Аның [Г. Исхакый. – *Т.Г.*] карашынча, татар әдәбияты милли мәнфәгатьләргә, татар яңарышына, милләтнең рухи-мәдәни күтәрелешенә хезмәт итәргә тиеш. Г. Исхакыйның әлеге нәзари карашы татар халкының икенче бер олы феноменаль шәхесе Г. Тукайга багышланган бер төркем мәкаләләрендә, истәлек-хатирәләрендә ачык гәүдәләнеш таба» [4, б. 104]. Исхакый шагыйрь вафат булганнан соң язган «Милли фаҗига» (1914), «Тукай мәхәббәте» (1914), «Тукай мәрхүм» (1915), «Мәрхүм Тукай» (1916), «Шагыйрь Габдулла Тукай» (1938), «Тукайның вафатына егерме биш ел тулу мөнәсәбәте илә» (1938) дигән мәкаләләрендә үз концепциясенә таяна

«Милли фаҗига» (1914), «Мәрхүм Тукай» (1916) мәкалә-тәгъзияләре Тукайның вакытсыз үлеменә нисбәтле тирән үкенү, ачыну хисләре, сызлану белән сугарылган. «Исхакыйның сүз сөрешеннән аңлашылганча, автор һәр укучыда үзен гаепле санау хисен уятуга, сагыш хисенә, ягъни экзистенциаль башлангычка өстенлек бирә. Ошбу мәкаләсендә [«Милли фаҗига». – *Т.Г.*] Исхакый шагыйрьнең милләт язмышында тоткан урынын, халыкчанлыгын, бөеклеген үтемле һәм калку итеп күрсәтүгә ирешә.<...> Исхакыйның һәр сүзе җылы һәм хисле, тере һәм туры, шигырьгә битараф татарны да уйландыра торган тирән кичерешле» [1, б. 44–45]. Г. Исхакый «Милли фаҗига» мәкаләсенең башлам өлешендә шагыйрь, шагыйрьлек сәләте, шигърият куәсе, шагыйрьнең тормыш күренешләренә мөнәсәбәте хакында фәлсәфи-романтик яссылыкта уйлана. Тукайны, затлы таш алмазга тиңләп, табигатьнең татар халкына бүләге төсендә карый. Тукай шәхесенең иҗтимагый-фәлсәфи кыйммәтен шигърияте аша бәяли: «... кыска гомеренең матур чакларында матурлыгы берлә дөньяның беренче дәрәҗә шагыйрьләреннән ким түгел кыйммәте шигъриятле шигырьләр бүләк итте» [9, б. 290]. Алга таба Тукай вакытсыз үлеменең сәбәпләре турында фикер йөртүгә күчә. Мәхәббәт-гыйшык хисенең, җир гүзәлләренең шагыйрь җанлы кешеләр тормышында

һәм язмышында үзенчәлекле, хәтта хәлиткеч роль уйнауларын истә тотып ул, бу яктан Тукайның ялгызлыгын, «туңган бәгырьне эретерлек сөйгән юклыгын» фаҗига дәрәҗәсенә күтәрә: «Габдулланы йөрәк җылысы юклыгы, бер татар кызының аны сөймәве, бер татар кызының аны «шагыйрь Габдулла әфәнде Тукаев җәнабләре» димәенчә, Габдулла гына дип карамавы үтерде» [9, б. 291]. Әмма Исхакый мәсьәләне бу сызыкта гына калдырмый, аны иҗтимагый-милли яссылыкка күчерә: «Габдулланың йөрәк елысына туймауда, Габдулланың куәи хосусиясенә йомшаклык, нечкәлек бирмәүдә мин хосусый бер-бер хатынны, йә бер кызны, яисә бөтен татар дөньясының хатын-кызын гаепли дип уйланылмасын. Бу фаҗигадә гаеп кенә бар, гаепле юк. Гаепле булса – татарның бөтен тормышы, бөтен тормышының китеше...» [9, б. 292].

Язучы шагыйрь вафатыннан сүз сәнгатендә хөкем сөргән бушлык, Тукай әдәби байлыгының татар шигыре, милли әдәбиятның сәнгати-фикри күтәрелешенә, татар халкына киләчәктә хезмәт итү мөмкинлекләре хакында фаразлап, шагыйрь үлемен «милли фаҗига» дәрәҗәсенә күтәрә. Әлеге бәя-хөкем, өзгәләнү хисе «Мәрхүм Тукай» (1916) тагын да тирәнәйтелә: «Халыкның рухы – татар халкының рухы, йоклаудан торып, күзен ачкан чагындагы Тукайның рәхмәтле нисан («иң беренче җылы яңгыр» мәгънәсендә) шигырьләреннән сугарылмаенча, сусаган хәлендә яшәде. <...> Ниһаять татарның мәдәни, иҗтимагый хәрәкәтләрендәге мәтәлүләр, асты өскә килүләр Тукайның кискеч сатирасы, пакь көлүләрдән ятим булып барды» [10, б. 201–202 ]. Исхакый – шагыйрь шигъриятендә татар милләтен инкыйраздан саклап калуда зур өметләр багланган татар яшьләренең Тукай «күңел җимешләре»ннән мәхрүм калуларына үкенү-ачыну хисен белдерә: «Тукай – хәзерге үсү дәверемездәге һәр пакь йөрәк тибүен сизеп алып, киләчәк буынга бүләк биреп бара торган Тукай мәрхүм булды» [10, б. 202].

Әдип гыйльми-тәнкыйди фикернең Тукай иҗатына мөнәсәбәтендә объективлыкка ирешү, аны пропагандалау һәм дөрес булмаган бәя-хөкемнәрдән саклау юнәлешендә дә зур хезмәт башкара. Мөһаҗәрәттә Г. Исхакыйның «Шагыйрь Габдулла Тукай» (1938)[1], «Тукайның вафатына егерме биш ел тулу мөнәсәбәте илә» (1938) дигән аналитик мәкаләләре басыла. Аларда автор шагыйрь поэзиясен бәяләгәндә, культура – тарих мәктәбенең төп законнарыннан раса – милләт, тирәлек – мохит һәм моментка таяна: «Икенчеләре – туган халкы, аның тирә-юне, яшәгән мохитнең шул вакытта кичергән уйлары, хисләренең тәрҗеманы булып, шул халыкның шатлыгын, кайгысын, өмиден сөйләүче, үз мохитенең иҗтимагый омтылышларын төсләндереп яшәүче, җәмәгать эшләренең һичберсе ягыннан күз йомып, колагын тыгып үтә алмаучы җәмәгатьче шагыйрьләрдер.<...> Габдулла Тукай – менә соңгы төстәге шагыйрьдер. Үзенең мохитенең шатлыгын, кайгысын, дәрден шигырь төсенә сугучы бер тел остасыдыр. Аның яшәгән, язган дәвере бездә милләтчелекнең иң кайнаган, милли теләкләрнең берсе өстенә берсе үсеп, тирә-якны тутырган вакыт булганга, ул шул теләкләргә, шул омтылышларга бер шигырь төсе бирүче, чуалчык фикерләрдән туган агымнарга туры юл күрсәтергә теләүче милләт хезмәтчесе – милли шагыйрьдер» [11, б. 236–237].

Исхакый Г. Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре» китабында Тукайның шагыйрьлеге мәсьәләсенең куелуы фәнни яктан караганда «хата» дигән карашта тора һәм аның сәбәпләре хакында уйлана. Әдәбият-сәнгатьнең милләткә хезмәт итү вазифасын яклаган Исхакый, оппонентыннан аермалы буларак, Сәгыйт Рәмиев белән Габдулла Тукайның үзара чагыштырыла алмый торган ике мәктәп, ике мәсләк шагыйрьләре булуын әйтеп чыга: «Сәгыйть Рәми белән Габдулла Тукай һич бер – берсе белән чагыштырылмый торган, чагыштырыла алмый торган ике мәктәпнең, ике мәсләкнең шәкертләредер. Вә икесе дә үзләренең мәктәпләрендә, мәсләкләрендә үз урыннарында зурлардыр» [6, б. 173]. Әдип мондый бәяне хезмәт авторының «саф сәнгать» йогынтысына

---

[1] Мәкаләне «Татарстан» журналының 1998 ел 2 санына Л. Гайнанова әзерли. Редакция аны «Мәкаләнең беренче тапкыр кайда һәм кайчан дөнья күрүе билгеле түгел. 1938 елда язылуы гына чамалана» дигән искәрмә белән бастыра. Шушы ук мәкалә «Казан утлары»ның 2001 ел 7 санында яңадан дөнья күрә. Журнал редакциясе «Бу мәкалә Берлинда чыккан «Яңа милли юл» журналында 1938 елда басылган. Аны матбугатка филология фәннәре кандидаты Розалина Нуруллина әзерләде» дигән аңлатма биргән. Г. Тукайның 1937–1938 еллардагы публицистикасын туплаган 12 нче томда бу исемдәге мәкалә урын алмый. Күрәсең ул Исхакыйның шагыйрь иҗатын шәрехләү концепциясе тагын да тирәнәйтелгән «Тукайның вафатына егерме биш ел тулу мөнәсәбәте илә» (1938) мәкаләсенең беренче варианты булган.

бирелүенең нәтиҗәсе итеп карый. Культура-тарих мәктәбе кагыйдәләренә нигезләнеп, Тукай иҗатынын чор-заман, яшәгән мохтит һәм татар халкының иҗтимагый идеаллары, шатлык-кайгылары белән тыгыз бәйләнешен янәдән раслап, аны «җәмәгатьче шагыйрь» дип атый. Ф. Мусин бу мәсьәләгә, ике якта да «романтик-субъектив рух»ка урын калганлыкны таныган хәлдә, икенче ноктадан якын килә. Исхакый белән Ибраһимовның Тукайга шәхес, җанлы кеше буларак карау сызыгын билгели: «Иң мөһиме, бу ике зур әдип фикерләрендә Тукайны пьедесталга бастырылган җансыз сын яки җирдән аерылган илаһи зат итеп түгел, бәлки кешеләрчә җанлы һәм катлаулы шәхес рәвешендә карау бар. Исхакый белән Ибраһимов фикерләре бу яктан күпмедер күләмдә фәнни-методологик әһәмияткә ия» [12, б. 82].

Тәнкыйтьче «Шагыйрь Габдулла Тукай» мәкаләсендә бүгенге көн күзлегеннән караганда икенче бер әһәмиятле мәсьәләгә барып чыга. Хәзерге вакытта иҗат әһелләренә «халык язучысы», «халык җырчысы» һ.б. дәрәҗәләр, исемнәр, рәсми оешмалар тарафыннан бирелсә, ә бу кыйммәтнең Тукайга мантыйкый рәвештә халыкның үзе тарафыннан бирелүе, аның халык шагыйре буларак танылуы әйтелә [3, б. 168]. Г. Исхакый болай дип яза: «...Габдулла Тукай һичбер кемнең өндәве, димләвеннән башка, халык тарафыннан сөелеп җитеп, киң халык катлавының эченә, рухына сеңеп, халык шагыйре булып өлгергәндер» [6, б. 173].

Шагыйрь исемен мәңгеләштерү, «Тукай җәмгыять»ләре ачу, укулар һәм төрле әдәби-мәдәни чаралар оештыру [9, б. 284–286], каберенә таш кую, аны тәртиптә тоту мәсьәләләрен көн тәртибенә куючыларның берсе рәвешендә дә Г. Исхакыйны санарга мөмкин. Татар мәктәп-мәдрәсәләрендә яңача уку-укыту, дөньяви белем бирү, шәкертләрнең яшәү-көнкүреш шартларын яхшырту проблемаларын яктыркан мәкаләләр авторы буларак, уку-белем бирү йортларында Исхакый Тукай иҗатын өйрәнү мәсьәләсен дә күтәреп чыга. Рухи егәрлеген, зиһен көчен татар тормышын яхшыртуга, мәдәниләштерүгә, милли-социаль азатлык өчен көрәшкә багышлаган Тукайның мәктәп балалары өчен «милли каһарман», «олуг милли шагыйрь» булуын ассызыклый: «Тукай безнең яңгы, мәдәни, милли тормышыбызның иң зур нигезе булганга, аның тазалыгы, аның пакьлеге баланың күңелендә нык утырырга тиештер. Аның олуглыгы, аның бөеклеге безнең милләтемезнең бөеклеге, олуглыгы белән мөнасиб булганга, ул үзенең олуглыгы кадәр пәрдәсен ачарга тиештер. Шуны булдыру, шуларны эшләп баланың күңеленә сеңдерү – мөгаллимнәр вә мөгаллимәләр бурычыдыр. Милли-мәдәни вазифадыр» [10, б. 56].

Г. Исхакый белән Г. Тукай арасындагы багланышлар берьяклы гына түгел. Тукайның шәкерт чагыннан ук Исхакыйның әсәрләрен яратып укып, аның татар милләтен саклау һәм үстерү юнәлешендәге иҗтимагый-сәяси эшчәнлеген даими күзәтеп бара һәм үзенең «күңел җимешләрен» багышлый. Шагыйрь шәхесен, карашларын формалаштыруда һәм иҗат кыйбласын ачыклауда Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» повестеның йогынтысы аеруча зур була. Тукай «Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы ?» (1906), «Хиссияте миллия» (1906) публицистик мәкаләләрендә күп мәгънә сыйдырышлы сүзләр белән язучы әсәренең төп фикерләрен яңадан тагын бер кат ассызыклый, кайбер мәсьәләләрне тагын да тирәнәйтә: «Милләт аталарга, аналарга, мөгаллимнәргә, мөгаллимәләргә, мөрәббиләргә вә мөрәббияләргә (тәрбиячеләргә) чын мөхәррилек табигатьләренә вә сәләхиятләренә (сәләтләренә) мохтаҗ. ... Безнең милләт тә Пушкиннәргә, граф Лев Толстойларга, Лермонтовларга мохтаҗ. Кыскасы гына, безнең милләт башка милләтләрнең тәрәккъкыйләренә сәбәп булган чын мөхәррирләргә, рәссамнәргә, бардакханәдән чыкмаган (фәхешханә белән бәйле булмаган) яңа-яңа милли шигырьләргә, музыкаларга вә гайреләргә, вә гайреләргә мохтаҗ» [17, б. 195].

Тукайның татар әдәбиятының классик язучысы, фикер иясе һәм җәмәгать эшлеклесенә багышланган шигырьләре дә бар. «Кем ул?» (1907) шигырендә Тукай Исхакыйны милләтне күтәргән, аны телле иткән, беренчеләрдән булып аны саклау һәм үстерү проблемаларын яктырткан шәхес итеп карый: Кем ул бу милләтне күтәргән кеше ?/ Кем ул аңа тел биреп, тавышын яңгыраттырган кеше. <...> / Узган көннәребезне уйлаткан кем? / Һәм «Инкыйраз»ны исебезгә төшергән кем ? [15, б. 177]. «Мөхәрриргә» (1913), «Даһигә»(1913) әсәрләрендә исә милли һәм социаль азатлык көрәшчесе Исхакыйның романтик образы тудырыла: «Шагыйрьнең: Гайрәт иттең, армый-талмый йөрдең ушбу юлда син, / Чын сөбатлә алга бардың, бакмый уңга-сулга син, – дигән

бәет тулысы белән Гаяз Исхакый шәхесенә һәм аның әдәби-сәяси эшчәнлегенә туры килә. Милли азатлык һәм Яңарыш идеалларын тормышка ашыру юлындагы «сөбатлыгы» – ныклыгы өчен Тукай Гаяз Исхакыйны «Даһи» дип атый» [2, б. 43]. Исхакыйның иҗтимагый көрәшкә туплау, рухи-мәдәни алгарышта җитәкчелек, лидерлык сыйфаты һәм халык күңелендәге югары абруе, әдәби-эстетик тамырлары белән ислам мәдәниятенә барып тоташкан күчерелмә мәгънәдәге «көтүче» белән чагыштырыла: Алты ел торды чупансыз (көтүчесез), айрылышты яшь көтү; / Карт бүре күк, бары корган айрым-айрым бер оя» [16, б. 288]

Г. Исхакыйның тәнкыйди һәм публицистик мәкаләләреннән тыш, әдәби әсәрләрендә дә Тукай шәхесе һәм иҗаты белән бәйле фикерләр, эпизодлар күзәтелә. Мәсәлән, «Мөгаллимә» (1913) драмасында мәктәп балалары укытучы Габдулланы туган көне белән котлап, Тукайның «Бәйрәм бүген» шигыренә язылган җырын башкаралар. Ә мөгаллимә Фатыйма, милли күтәрелештә татарның фидакарь мәгърифәтче-көрәшчеләре ролен бәяләү уңаеннан, «бер мәртәбә татар кызыннан сөйкемле сүз, сөйкемле бер хәрәкәт күрмәгән» [8, б. 297] Тукайның вакытсыз үлемен татар хатын-кызының үзенә йөкләнгән вазифасын үтәмәве турында сөйли. «Ул әле өйләнмәгән иде» (1916) әсәрендә «Тукайның кемлеген» белү укымышлылык башка сыйфатлар белән бергә, идеал татар кызын билгеләүче үлчәм төсендә тәкъдим ителә [7, б. 389].

Мәшһүр сүз остасы Гаяз Исхакыйның әдәби-тәнкыйди һәм публицистик эшчәнлегендә Тукай темасы иҗтимагый-милли һәм фәлсәфи-эстетик яссылыкта яктыртыла. Әдип беренче язмаларында ук шагыйрь поэзиясенең милли һәм халыкчан рухын күрсәтә, аны яңа татар әдәбиятын нигезләүче буларак югары бәяли. Тукай шәхесенә инсани мөнәсәбәт, шагыйрь рухи мирасының фикри-мәгънәви кыйммәтенең зурлыгын тану язучының төрле чордагы мәкалә-язмаларында кызыл җеп булып сузыла. Татар мәдәнияте һәм әдәбияты тарихында шагыйрь иҗатының үз мәртәбәсенә лаек урынын билгеләүдә, аның мирасын яклауда һәм исемен мәңгеләштерүдә дә Г. Исхакыйның роле зур була.

ӘДӘБИЯТ

1. Галиуллин Т.Н. «Гаяз әфәнде – шагыйрьдер» (Г. Исхакый һәм татар шигърияте) // Яктылык: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. Б. 32–50.

2. Ганиева Р.К. Шагыйрьнең рухи дөньясы (Габдулла Тукай» энциклопедик сүзлек-белешмәсенә әзерләнгән материаллардан). Казан:ТаРИХ, 2002. 112 б.

3. Гыйлаҗев Т.Ш. Г. Тукай һәм Г.Ибраһимов мөнәсәбәтләре хакында Гаяз Исхакый // Югары һәм урта һөнәри уку йортларында татар әдәбиятын өйрәнүнең һәм укытуның мөһим мәсьәләләре: Габдулла Тукайның тууына 120 ел тулуга багышланаган фәнни-гамәли конференция материаллары (6–7 апрель, 2006 ел, Яр Чаллы). Казан, 2006. Б. 167–169;

4. Гыйлаҗев Т.Ш. Г. Исхакыйның гыйльми-тәнкыйди эшчәнлегендә әдәбият мәсьәләләре // Гаяз Исхакый иҗаты: хәзерге караш: Гаяз Исхакыйның тууына 130 тулуга багышланаган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары (11 декабрь, 2008.). Казан, 2008. Б. 104–105 һ.б.

5. Заһидуллина Д.Ф. Әдәбият кануннары һәм заман (Татар әдәбият нәзариясенең барлыкка килүе һәм үсеш баскычлары). Казан: Татар. кит. нәшр, 2000. Б. 186,

6. Исхакый Г. Шагыйрь Габдулла Тукай // Казан утлары. 2001. № 7. Б. 171–175.

7. Исхакый Г. Ул әле өйләнмәгән иде // Әсәрләр: Унбиш томда. Т. 2: Повестьлар һәм хикәяләр (1909–1918). Казан: Татар. кит. нәшр, 1999. Б. 362– 416.

8. Исхакый Г. Мөгаллимә // Әсәрләр: Унбиш томда. Т. 4: Пьесалар (1900–1918). Казан: Татар. кит. нәшр, 2003. Б. 285–327.

9. Исхакый Г. Әсәрләр: Унбиш томда. Т. 6: Публицистика һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре (1902–1914). Казан: Татар. кит. нәшр, 2005. 447 б.

10. Исхакый Г. Әсәрләр: Унбиш томда. Т. 7: Публицистика (1915–1916). Казан: Татар. кит. нәшр, 2008. 366 б.

11. Исхакый Г. Тукайның вафатына 25 тулу мөнәсәбәте илә // Әсәрләр: Унбиш томда. Т. 12: Публицистика (1937–1938). Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. Б. 236–242.

12. Мусин Ф. Гаяз Исхакый (Тормышы һәм эшчәнлеге). Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 191 б.

13. Нуруллин И. Г. Тукай һәм Г. Исхакый // Шәһри Казан. 1993. 17 июнь.

14. Миңнегулов Х.Й. Гасырлар өнен тыңлап... Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. Б. 163–174.

15. Тукай Г.М. Әсәрләр. Академик басма: 6 томда: Т. 1: Шигъри әсәрләр (1904–1908). Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 407 б.

16. Тукай Г.М. Әсәрләр. Академик басма: 6 томда: Т. 2: Шигъри әсәрләр (1909–1913). Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 384 б.

17. Тукай Г.М. Әсәрләр. Академик басма: 6 томда: Т. 3: Мәкаләләр, фельетоннар, хикәяләр (1904–1906). Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 415 б.

# ӘМИРХАН ЕНИКИ ТӘНКЫЙТЕНДӘ XX ЙӨЗ БАШЫ ӘДӘБИ-ИҖТИМАГЫЙ БАРЫШЫНА ҺӘМ ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИҖАТЫНА КАРАШ

***Гыйләҗева С.Ф.***

В данной статье расценивается деятельность знаменитого татарского писателя Амирхана Еники в области татарской литературной критики. Дается описание такого вида критической мысли, как критика писателей, которая является самым распространенным видом татарской литературной критики. Особое место в публицистических статьях А. Еники занимает оценка татарской литературы XX века. Писателем особенно высоко оценивается творческая деятельность выдающегося поэта того времени – Габдуллы Тукая.

This article contains the main idea of the writer's criticism, such as the type of the literature criticism, which is the most popular type of the Tatar literature criticism. Amirhan Eniki is the talantest writers of Tatar literature. Also he was the critic, which could say his opinion about literature and culture. The particular place in his critic articles takes the ideas about the Tatar literature of the beginning of XX century. Especially he appreciated the creation of the most popular Tatar poet – Gabdulla Tykai.

Әдәби тәнкыйть матур әдәбиятны зәвыксыз, эшпошыргыч әсәрләрдән арындырырга, шул ук вакытта язучы, шагыйрьләрнең да каләмен үткенләтергә ярдәм итә. Татар әдәби тәнкыйте тарихы урта гасырларны иңләп, борынгы чорга, халык авыз иҗатына барып тоташса да, әдәбият белеменең бу тармагы, фән буларак, XX йөз башында формалаша һәм әдәби хәрәкәттә күп мәсьәләләргә бәя биреп, мөнәсәбәт белдереп, татар сүз сәнгатенең сыйфат яңарышында зур роль уйный башлый. Бу чордан соң инде бер гасыр вакыт узды. Бүгенге көндә татар әдәби тәнкыйте фән буларак формалашып җитте: аның предметы, бурыч-максатлары, әдәби тәнкыйтьнең төрләре, аның тарихи чорлары аерылып, өйрәнелә. Шул нисбәттән, тәнкыйтьтә профессиональ, язучы һәм укучы тәнкыйте аерым карала. Татар әдәби барышының үзенчәлекле ягы – ул язучы тәнкыйтенең популяр булуында. Әмирхан Еники тәнкыйди эшчәнлеге дә әдәби тәнкыйтьнең шушы төренә карый.

Һәр халыкның, һәр милләтнең кабатланмас матур бизәкләр белән, үзенчәлекле тел белән язылган әдәбияты бар. Әдәбият элек-электән халыкның йөзен билгели торган төп күрсәткеч саналган. Төрле тарихчылар халык язмышын үзләренчә, үзләренә ничек кирәк шулай итеп төзергә тырыштылар, ә чын әдәбият, халыкчан әдәбият үзенең төсен, кыйммәтен беркайчан да югалтмады. Бөек татар язучылары һәм шагыйрьләре иң авыр, киеренке шартларда да милли телне саклап, халыкны яклап, тормыш-чынбарлыкны сурәтләүче әдәби әсәрләр иҗат итте. Бүгенге көндә бу әсәрләр мәктәп һәм югары уку йортларында өйрәнелә, кат-кат нәшриятлар тарафыннан бастырыла, халык арасында зур популярлыкка ия булган татар халкының классик әдәбияты санала. Татар халкының лаеклы уллары арасында XX йөз башында яшәп, иҗат иткән Габдулла Тукай һәм сугыштан соңгы чорда да аның традицияләрен дәвам итеп, әдәбият мәйданында зур урын алып торган Әмирхан Еники дә бар.

Бу әдипләр татар милләтен, әдәбиятын үстерүдә үзләреннән зур өлеш керткән кешеләр. Аларның әсәрләре бүгенге көндә татар гына түгел, башка милләт вәкилләре тарафыннан дә яратып укыла. Моның беренче сәбәбе – әсәрләрнең гомумкешелек идеяләрен алга чыгарып, халыкчан рухта язылган булуындадыр, могаен. Икенчедән, бу ике әдип тә әдәбият гыйлеменең төрле жанрларында уңышлы эшләделәр. Тукай – проза, поэзия, балалар әдәбияты, публицистика остасы булса, Еники проза һәм публицистика жанрларын үз иткән. Киң җәмәгатьчелек Тукайны күбрәк шагыйрь, ә Еникине прозаик буларак кына белә. Әдипләрнең башка өлкәләрдәге хезмәтләре никтер бәяләнеп бетми. Әдәбият фәнендәге шушы бушлыкны берникадәр тулыландыру максаты белән бүгенге көндә безнең тарафтан Әмирхан Еникинең тәнкыйди эшчәнлеге тирәнтенрәк өйрәнелә. Язучының тәнкыйди мәкаләләре тупланган ике китабы дөнья күргән: «Хәтердәге төеннәр» һәм «Кояш баер алдыннан». Әлеге хезмәтләрдә аның милли мәсьәләгә, татарча укыту проблемаларына һәм әдәбият, сәнгатьнең күренекле вәкилләренең шәхесләренә, хезмәтләренә карата булган кыйммәтле фикерләре чагылыш тапкан. Бу китаплар Ә. Еникине талантлы тәнкыйтьче дә булганлыгын раслый. Ф. Хатипов һәм Р. Сверигин заманында язучының «Кояш баер алдыннан» публицистик мәкаләләр җыентыгы турында болай дип язалар: «Автор милли мәсьәләгә, татарча укыту проблемаларына җитди

игътибар юнәлдерә. Китап кызыксынып, бер сулышта укыла. Асылда ул пәйгамбәр сүзе кебек кабул ителә» [4, с. 19] дип, хезмәткә шактый югары бәя бирәләр.

Билгеле, Еники профессиональ тәнкыйтьче түгел, әмма язучы тәнкыйте һәм профессиональ тәнкыйть арасында Кытай стенасы юк. Дөрес, укый-яза белеп, үз күңелдәгесен каләм белән кәгазьгә төшерергә теләүчеләр саны күп. Әдәбият өлкәсендә кайнап яшәгән, әдәби барышны эченнән үк яхшы белгән, тоемлаган, талантлы язучының да башкаларга карата үз фикерен, теләк-киңәшләрен әйтергә хокукы бар. Алай гына да түгел, милли әдәбиятның һәм гомум сәнгатьнең алга китешен теләп, милләте өчен янып-көюче әдип моны эшләргә тиеш тә. Шуңа күрә Ә. Еникинең дә үзенең иҗатын тәнкыйди эшчәнлек белән үреп баруы табигый.

Гомумән, үткәндәге һәм хәзерге әдәби тәнкыйтьнең зур өлешен язучы тәнкыйте алып тора. Язучы тәнкыйтенең өстенлек итүе татар әдәби тәнкыйтенең үзенчәлеге дә булып тора. Татар дөньясында төп иҗади эшчәнлекләре әдәби әсәрләр язу булса да, әдипләр әдәби тәнкыйть мәсьәләләре белән актив кызыксыналар. Әдәби тәнкыйть тәнкыйди процессны, әдәби тәнкыйть тарихын һәм тәнкыйть поэтикасы кебек тармакларны үз эченә ала. Татар язучылары тәнкыйди процесста актив катнашудан тыш, әдәби тәнкыйть үткән юлны ачыклауга һәм аның нәзари мәсьәләләрен хәл итүгә дә үзләреннән зур өлеш кертәләр. Моның сәбәпләре төрле: үзе дә бер вәкиле булган әдәби процесска караш-мөнәсәбәт белдерү, аерым тенденцияләрне билгеләү омтылышы, төрле сәбәпләр аркасында тәнкыйтьнең үз функциясен үтәп бетермәве, хәзерге сүз сәнгатендә яңалык эзләнүләрнең тулысынча ачылмавы, моннан тыш, язучының әдәби процесстагы активлыгы үзләренең иҗат йөзен, стиль үзенчәлекләрен ачу, әдәби әсәр иҗат итү серләрен башкаларга җиткерү һәм шуның белән янәшә әдәби хәрәкәттә үз урынын билгеләү омтылышы да аерым бер роль уйный. Профессиональ тәнкыйть үзенең академик характерда булуы белән аерылып торса, язучы тәнкыйтенә үтә субъективлык, шәхси башлангычның киң урын алуы, үзгә зәвыкка нигезләнү хас. Әдип теге яки бу әсәрнең үзенең әдәби-эстетик эзләнүләренә, шәхси иҗат тәҗрибәләренә нигезләнеп бәяли, мөнәсәбәтен белдерә. Шуңа күрә Ә. Еники язмаларында да көтелмәгән ассоциацияләр, бәйләнешләр, нәтиҗәләр урын алган.

Язучы үзенең бу төр мәкаләләрендә әдәби әсәрләргә әдәби-эстетик, әхлакый-фәлсәфи казанышларыннан чыгып бәя бирә; үз чорының әдәби барыш үзенчәлекләрен ача; заман биеклегеннән торып, үткән чор әдәбиятына бәя бирә; аерым шәхесләргә һәм аларның иҗатларына туктала. Ә. Еники үзенең мәкаләләрендә татар әдәбиятының алтын чоры булган ХХ йөз башы әдәбиятын бәяләүгә зур урын бирә. Бу аңлашыла да, чөнки бу чор – татар әдәбияты үсешенең иң югары ноктага җиткән чоры. Еники каләмдәшләрен һәм яшь иҗатчылар буынын махсус рәвештә бу дәвергә игътибарларын юнәлттерә. Ул үзенең замандашларын үрнәк алырдай ХХ йөз башы әдипләрнең әсәрләре белән танышып, аларның өслүбләрен өйрәнеп, кабатланмыйча, яңа төр югары зәвыклы әдәби әсәрләр иҗат итәргә чакыра сыман. Милли әдәбиятыбызның имән баганалары булган Г. Тукай, Ф. Әмирхан, С. Сүнчәләй, Н. Исәнбәт, Г. Ибраһимов, Һ. Такташ, Г. Кутуй һ.б.ларның эшчәнлекләре һәм аерым әсәрләре югары бәяләнә. Тәнкыйтьче бу әдипләрнең әсәрләренең идея-проблематикасына, жанр үзенчәлекләренә, тел-сурәтләү чараларына киң тукатала.

Язучы татар халкының бөек шагыйре Г. Тукай иҗаты турында да үз фикерен әйтмичә булдыра алмый. Беренче чиратта, ул, әлбәттә, Тукайның милли шагыйрь, халыкны аңлы-мәгърифәтле итүдә үзеннән зур өлеш керткән әдип булуын ассызыклый. «Тукай – милли азатлык җырчысы. Тукай – изелгән, җәберләнгән, әмма золымга баш ияргә теләмәгән халык җырчысы. Татар халкының гасырлар буенча җыелып килгән зар-моңы, ачу-нәфрәте, өмет-хыяллары, яңар тау ата башлагандай, Тукай иҗатында бәреп чыкты» [2, с. 20]. Г. Тукай – милләтнең беренче шагыйре. Ул үзенең соңгы сулышына чаклы милләт хәсрәтен, аның язмышын арык иңнәренә салып, тарихыбызга, үз чоры проблемаларына караган самимилекләре белән нәфис, гүзәллекләре белән камил шигъри энҗеләрен иҗат итә. Тукай шигырьләренә милләт язмышы мәсьәләләре килеп керә, һәм ул анда лирик затның бай, шул ук вакытта каршылыклы уй-кичерешләре белән үреп бирелә. Болар барысы да укучыны милләт, халык, дин, язмыш турында уйландыра.

Язучының шагыйрьгә карата булган җылы мөнәсәбәте, ихтирам итүе дә аның публицистикасында чагылыш тапкан. «Косогор заводы – Муса Җәлил – Ясная Поляна» мәкаләсендә сүз гарчә татарның тагын бер бөек улы – герой-шагыйрь Муса Җәлил

турында барса да, ахырдан Ә. Еники үзенең Красная Полянага Л.Н. Толстой каберенә зиярәт кылуы хакында яза. Әлеге истәлектә язучы сүзен юкка гына Муса Җәлил белән башлап, Толстой һәм Тукай белән тәмамламый. Ул бу өч шәхесне янәшә куеп, аларның бөеклеген янә бер кат исбатларга тели. Юллары да аны язмыш кушуы буенча тәүдә Муса Җәлилне яратып искә алган Косогор заводына илетсә, аннары соң озак еллар дәвамында Толстой яшәгән Ясная Полянага алып бара. Сәфәрдәше – Әхмәт Фәйзи киңәше буенча Ә. Еники Толстой кабереннән бер уч җир алып, аны Казанга кайтып, Тукай каберенә сала. Бу адым – ике бөек шәхесне очраштырырга теләү, аларның бөеклекләрен янәшә кую кебек аңлашыла. Рус халкы әдәбиятын Толстой дөнья күләменә чыгарган булса, татарларда ул, һичшиксез, – Тукай дип әйтергә тели сыман Еники.

Язучының татар халкының бөек шагыйренә булган мөнәсәбәте түбәндәге юлларда ачык күренә: «Даһиларны халык тудыра – бу бәхәссез, ләкин даһилар да үз нәүбәтләрендә туган халыкларына дан, шөһрәт китерә – бу да бик билгеле хакыйкать. Шуңа күрә дә аларны халыкның милли горурлыгы дип йөртәләр. Тукай да безнең әнә шундый горурлыгыбыз, һәм без, бу хакта уйлап тормастан, һәрвакыт аны күңелебездә саклап, ничектер гел тоеп яшибез» [2, с. 20]. Тукай – бөек халыкның бөек улы дип әйтергә тели сыман Еники.

Шул ук вакытта Еники тәнкыйди-публицистик мәкаләләрендә Тукай һәм аның башка замандаш әдипләре белән аралашып яшәве турында да яза. Мәсәлән, С. Сүнчәләйнең тормыш юлы һәм иҗаты хакындагы «Шагыйрь ерак сәфәрдән кайтты» дип аталган мәкаләсендә язучы С. Сүнчәләй белән Г. Тукайның дустанә мөнәсбәтләрен язмыйча булдыра алмый. «Сүз Тукай – Сүнчәләй мөнәсәбәте турында бара... Без беләбез, бу мөнәсәбәт ике шагыйрь арасындагы дуслыктан гыйбарәт. Кыска була бу дуслыкның гомере – 1911 елда гына башлана һәм Тукай үлеме белән өзелеп кала. Ләкин шушы кыска гына вакыт эчендә Тукай Сүнчәләйнең күңелендә гаять зур урын алып өлгерә» [3, с. 16].

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Ә. Еникинең әдәби тәнкыйть өлкәсендә дә киң колачлы эшчәнлек алып барганын әйтә алабыз. Әдипнең тәнкыйте язучылар тәнкыйтенә карый, ул публицистик характерда. Тәнкыйтьченең XX йөз башы әдәби процессы, аерым алганда Г. Тукай кебек үз чорының олпат фигурасы хакындагы фикерләре бүгенге көн татар әдәби тәнкыйтенең кыйммәтле ядкәрләре булып тора. Ә. Еникинең тәнкыйди мәкаләләре рухи мирасыбызның, милли хәзинәбезнең бай катламын тәшкил итә.

ӘДӘБИЯТ

1. Еники Ә. Хәтердәге төеннәр / Косогор заводы – Муса Җәлил – Ясная Поляна // Әмирхан Еники. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. Б. 82–99.

2. Еники Ә. Хәтердәге төеннәр .../ Йолдыз кеби // Әмирхан Еники. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. Б. 19–20.

3. Еники Ә. Хәтердәге төеннәр.../ Шагыйрь ерак сәфәрдән кайтты // Әмирхан Еники. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. Б. 9–18.

4. Хатипов Ф., Сверигин Р. Яшәү мәгънәсе // Мәгариф. 2009. № 3. Б. 19–24.

## XX ЙӨЗ БАШЫНДАГЫ ТӨРМӘ ЛИРИКАСЫНДА ИҖАТ ЫСУЛЛАРЫ ҺӘМ ӘЛӘКЧЕЛӘР, ШЫМЧЫЛАР ОБРАЗЛАРЫ

***Гыйлманов Д.Ш.***

Начало XX в. в России – время сложное. В литературе широкое распространение получила тема тюрьмы (произведения Г. Тукая, М. Гафури, С. Рамиева, Н. Думави и др.), которая способствовала возникновению образов доносчиков, сыщиков. В то время они становились объектом резкой критики татарских писателей.

This article deals with hard period in the beginning of XX century in Russia. There was the subjest of «prison» promoted emergence of images of informers, detectives were adopted in Russian literature (G. Tukay, M. Cafury, S. Ramieva, N. Domany and ofhers). They became object of criticism of the Tatar writers, at that time.

XX йөз башы татар әдәби хәрәкәтенең иҗтимагый-тарихи нигезе бик тә катлаулы һәм сикәлтәле. Нибары егерме ел эчендә Россия зур тетрәнүләр кичерде. Моңа сәбәпче

булып, XIX йөзнең соңгы чирегендә татар халкының да феодаль яшәештән капитализмга күчүе, уяну һәм алгарыш дәвере башлану, гасыр башындагы рус-япон сугышы, 1905 еллардагы беренче рус революциясе, реакция чоры, яңа революцион күтәрелеш, Беренче бөтендөнья сугышы, 1917 елгы Февраль һәм Октябрь революцияләре һәм, ниһаять, гражданнар сугышы торды. Билгеле, бу иҗтимагый формацияләр алмашу, сугышлар, инкыйлаблар татар халкының аңына, аның мәдәни-әдәби хәрәкәтенә зур йогынты ясады.

Бу тарихи вакыйгалар татар әдәбиятына яңа эчтәлек, яңа ысуллар алып килде, әдәби барышны да тизләтте. Г. Тукай, М. Гафури, С. Рәмиев, Дәрдемәнд, Н. Думави, С. Сүнчәләй, З. Бәшири, М. Укмасый, Ш. Бабич кебек талантлы шагыйрьләр килде. Аларның барысы да, халык мәнфәгатьләрен яклап, колониаль изүгә ризасызлык белдереп, самодержавие башбаштаклыгына һәм аның бюрократиясенә каршы күтәрелде, милли яңарыш идеяләрен куәтләде.

1905 елгы инкыйлаб вакыйгаларыннан өркеп калган патша хөкүмәте тиз арада һушына килә, милли-азатлык хәрәкәтләрен бастыру юнәлешендә чаралар күрә, аларны гамәлгә ашыру эшен тизләтә. Массакүләм эзәрлекләүләр, тентүләр, донослар чоры башлана. Революция казанышлары булган демократик ирекләр бер-бер артлы юкка чыгарыла. Погром һәм репрессияләр, гадәти күренешкә әйләнеп, матбугат һәм культура эшләренә контроль дә тулысы белән полиция, жандармерия кулына күчә. Г. Исхакый бертуктаусыз эзәрлекләнә, әле төрмәгә, әле сөргенгә озатыла. Г. Тукай, Г. Камал, Ф. Әмирхан, М. Гафури, Ф. Кәрими, С. Рәмиев, С. Сүнчәләй, Г. Коләхметов, Г. Ибраһимов, Ш. Әхмәдиев, Г. Газиз, Ә. Хәсәни, З. Рәмиев, Н. Думави һәм башкалар күзәтү астына алыналар, ә кайберәүләре төрмәләрдә дә утырып чыгалар [12, б. 59–60].

«Азатлык, милли күтәрелеш идеяләрен җырлаган һәм самодержавиенең нигезен җимерергә чакырган өчен, үч алулар башлану, эзәрлекләүләргә дучар ителү әдәбиятның иҗтимагый, әхлакый эчтәлегендә дә үзгәрешләр китереп чыгарды. Шул нигездә язучы каләме дә көз сурәте, кояш баю, эңгер, төн тасвирлары, кайгы-хәсрәт мотивлары хөкем сөргән дөньяга ешрак мөрәҗәгать итә башлый. Әсәрләрдә ачлык, төрмә, богау, палач, кабер, елан-чаянлы хәят, юлсыз, маяксыз яшәеш темалары тамыр җәя.

Тоткын – мәхбүс образы исә, гомумән, бер традицион сурәтләү алымына әверелә» [1, б. 137].

Шигъриятебездә М. Гафури, беренчеләрдән булып, милләт бәхете, азатлыгы өчен үзен корбан итәргә әзер торган лирик герой – мәхбүс образын тудырды. Аның «Фидаи мәхбүс агызыннан» шигыре (1906) – шундыйларның берсе. М. Гафуриның лирик герое – татар милләтенең хокуклары өчен көрәш алып барулары. Шуның өчен дә самодержавие ялчылары аны зинданга салганнар:

Бәне япты бу йиргә мөстәбидләр-
Бәне күрде алар дошманыннан артык.
Бүләк иттем канымны милләтемә,
Бүләк улмас җиһанда каннан артык.
Шул юлда җаным фида итәрмен,
Бу милләт чөнки бәңа җаннан артык. [3, б. 66]

Күренә ки, автор «мөстәбидләр» дип изүчеләрне – самодержавие һәм аның бюрократиясен, башка өстен катламнарын атый. Шигырь тукымасына «Милләт ул – кан берлеге» дигән фикер дә килеп кергән. «Идегәй» дастаныннан ук килгән «буында типкән кан» образы да яңача кабул ителгән. Бераз соңрак Гафуридагы милләткә бүләк ителгән иң зур «бүләк кан» образы Дәрдемәнднең «Гөрләгән сулар» шигырендә туган кавемнең «мөкатдәс каны» булып гәүдәләнәчәк.

М. Гафуриның лирик герое, нинди генә каршылыкларга, кыенлыкларга очраса да, үзенең олы максатыннан чигенмәячәк. Ул милләтенең азатлыгы өчен, Мәскәү һәм Казан кебек башкалаларны калдырып, Себер «нәфи ителергә» –читкә сөрелергә дә, үзен корбан итәргә дә риза:

Бәне гәр нәфи итсәләр моннан Себергә,
Себер Мәскәү дәхи Казаннан артык. [3, б. 66]

Күрәбез, М. Гафуриның «Фидаи мәхбүс агызыннан» шигырендә беренче рус революциясе еллары өчен хас публицистик рух әле бик тә көчле. Реакция еллары башлану белән, бу темага шагыйрь Г. Тукай да мөрәҗәгать итте. Әмма ул зиндан темасын яктыртуны тәрҗемә әсәрләрдән башлап җибәрде.

1907 елда Тукай Пушкиннан «Узник» шигырен «Мәхбүс» исеме белән татарчага нәзыйрә рәвешендә тәрҗемә итте:

Дигән төсле була: «Моннан күчик без,
Канатлан син дә, сахрага очыйк без!»
(«Мәхбүс»)

«Тукайның Пушкин әсәренә мөрәҗәгать итүе үз заманының реаль чынбарлыгы белән бәйләнгән. 1905–1907 елгы революция чигенгәннән соң, Россиядәге тормыш караңгы төрмәгә әйләнеп, шәхеснең, шагыйрьнең бик авыр шартларда калуына, кол булып яшәүгә протесты, нәфрәте һәм азатлыкка сусавы чагылды» [11, б. 48].

Пушкин шигырендәге ирегеннән мәхрүм ителгән тоткынның яктылыкка омтылуы, Тукайча, Россиядә «халыклар төрмәсе»ндә яшәүче халыкларның азатлыкка омтылышын хәтерләтте. Ләкин татар шагыйрендә бу конфликт руссочыл карашлар ярдәмендә, романтикларча, көчәйтебрәк бирелде; төрмәне хәтерләткән Россия чынбарлыгына хөр, иркен, матур сахра тормышы каршы куелды.

Шулай итеп, Тукай, символик образлар ярдәмендә калҗасын чукый-чукый мәхбүскә карап, аны үзе белән бергә аулак сахраларга, ямь-яшел кыр-болыннарга, күк диңгез, ак таулар артына очарга ишарәләгән бөркетне сурәтләп, татар әдәбиятын мәхбүс темасына язылган яңа бер романтик әсәр белән баета [2, б. 99].

1905 елгы буржуаз–демократик революция Сәгыйть Рәмиевне дә иҗтимагый–сәяси көрәш мәйданына чыгарды, гыйсъянчылык романтизмының талантлы бер шагыйре итеп формалаштырды. 1906 ел башларында ул Оренбургтан Казанга килә, Гаяз Исхакый белән «Таң йолдызы» газетасында эшли, анда патша самодержавиесенә каршы юнәлтелгән мәкаләләр бастыра. Аларда ул «ил, халык язмышы кебек зур мәсьәләләрне күтәрә, Дәүләт думасының хезмәт халкы өчен берни дә эшләмәвен, илдә ачлык, ялангачлык, эксплуатация һәм террор хөкем сөрүен күрсәтә; иске идарәне бетереп, дәүләт идарәсен бөтен халык кулына бирү, җир һәм ирек таләпләрен яклый» [6, б. 174].

Татар халкын самодержавиегә каршы көрәшкә өндәү максатыннан, ул «Марсельеза», «Бәхилләшү», «Батыр атлагыз, иптәшләр!» (Смело, товарищи, в ногу!») (1906) кебек җырларны тәрҗемә итә.

С. Рәмиев тәрҗемә иткән революцион җырлар арасында киң таралганы, мөгаен, «Бәхилләшү» җырыдыр. Бу әсәр, бигрәк тә 1905 елның октябрь күтәрелешеннән соң, Казанда һәм бөтен илдә халыкка каршы көчле репрессияләр башланган чорда киң таралып китә. Ул җыр көрәш юлында корбан булганнарга, төрмәләргә ябылган революционерларга мәдхия булып яңгырый:

Төрмәләр, кайгылар сез күп күрдегез,
Рәхимсез хакимнәр аркасында.
Дошманнар гафу аямадылар,
Тимер богауда сез йөрдегез,
Халык тиз көннән йокыдан уяныр,
Бәхетле, гайрәтле һәм ирекле…

Шул елларда Рәмиев үзе дә шундый ук күтәренке рух белән сугарылган романтик шигырьләр иҗат итә. Мәсәлән, 1906 ел уртасында, революциянең нәкъ кызган бер чорында язылган «Бел телен, эзлә юлын…» дигән шигырендә ул:

Төрмәләргә кешеләр тулган,
Себерләргә дә куылган;
Кара! Дөнья ничек канга күмелгән?
Урамнарга үлекләр өелгән!
Бел телен, эзлә юлын: нидән бу болай булган? [5, б. 28]

Инкыйлабый эшчәнлеге өчен С. Рәмиев туктаусыз эзәрлекләнә һәм төрмәгә салына. Зинданда С. Рәмиев М.Горькийның «Тормыш төбендә» (1902) пьесасыннан Бубнов һәм Кривой Зобның «Кояш чыга да, бата да…» дип башланган җырын тәрҗемә итә (бу җыр тәрҗемәдә «Богаулар» дип атала) һәм, М. Горький пьесасы геройлары кебек, золымга, коллыкка каршы үзенең романтик протестын белдерергә тели:

Кояш чыга да, бата да,
Төрмәм мәңге караңгы.
Көннәр, төннәр зобаныйлар,

Их ...................................х!
Тәрәзәмне каравыллый…
Их сез, богаулар, богаулар,
Сез –тимер зобаныйлар.
Сезнең тырнаклар аякны
Их…………………………..х!
Рәхимсез сызгалыйлар. [10, б. 48]

Бу җыр да, «Марсельеза» һ.б. революцион җырлар кебек үк, татар хезмәт ияләре арасында киң тарала. Аннан бер өзекне Г. Камал «Бәхетсез егет» драмасына кертеп җибәрә. Ул Себергә барып җитә һәм татарлар арасында «Каторжаннар җыры» дигән исем ала [6, б. 175].

Сәгыйть Рәмиевнең «Таң йолдызы»ның 1906 елгы 30 сентябрь санында басылган, исеме «Шигырь» дип кенә куелган әсәренә дә тоткынлык һәм ирексезлек мотивлары килеп кергән, «әсәрдә күбрәк игътибар илдәге иҗтимагый– сәяси көрәшкә, контрреволюция көчләренең халык хәрәкәтләренә каршы кулланган рәхимсез чараларына юнәлдерелгән» [6, б. 176]:

Әгәр баксак гәзиттәге хәбәрләргә,
Палачлар яшь җаннарны һәлак итә.
«Асу», «ату», «Себер» дигән кара сүзләр
Йөрәкләрне ярып тоз сипкәндәй итә.

С. Рәмиевнең тоткын темасына язылган һәр шигыре романтик пафос белән өретелгән, инкыйлабчыларны атучы, асучы, Себергә сөрүче самодержавие вәкилләренә карата кискен гаепләү сүзләре әйтелгән.

С. Рәмиев Октябрь инкыйлабы көннәренә кадәр жандармерия күзәтүе астында яши. Хәтта берничә тапкыр кулга да алына. Хөкүмәт органнары янау һәм куркытулар юлы белән аны яшерен агент итәргә дә маташалар…

Киң катлам укучыларга аз билгеле булган Мәхмүт Алмаев (1874–1907) шигъриятендә дә төрмә темасын очратырга мөмкин. Ул да хөррият алып килүче 1905 елгы революцияне шатланып каршы ала, халыкның азатлыкка омтылышын яклый. Инкыйлабый хәрәкәтләрдә катнашкан Алмаев реакция елларында зинданга да ыргытыла һәм анда «Төрмәдән» (1907) дигән публицистик эчтәлекле шигырен иҗат итә. Күтәренке рухтагы бу шигырь халыкны үз хакларын һәм хокукларын даулау өчен көрәшергә өнди. Замандашларының милли азатлык турындагы уй-фикерләрен, теләк-максатларын тормышка ашыру өчен, Алмаевның лирик герое үзен корбан итәргә дә риза:

Төрмәдә черсәм дә палачларның кулында,
Җаным – тәнем фида улсын хөрриятнең юлында.

Җир йөзенә ут алса да, кире кайтмам юлымнан,
Җан бирсәм дә бән бирмәсмен хөрриятне кулымнан.

И, туганнар, тырышаек хөрриятне алырга,
Залимнәрнең җаннарыны җәһәннәмгә салырга.
(«Төрмәдән»)

Стиле белән инкыйлабый эчтәлекле, мәгърифәтчелек чакыруларына корылган бу шигырь дә кара көннәрнең үтәчәгенә өмет чаткыларын сүндерми.

Кыскасы, XX йөз башы татар поэзиясендә сәяси, иҗтимагый-социаль, рухи яшәешне зиндан белән чагыштырган бик күп әсәрләр язылган. Аларның күбесе – лирик геройның эчке дөньясын ачучы романтик шигырьләр. Алар арасында Аурупа һәм рус әдәбиятларыннан тәрҗемәчеләр дә бар. Беренче рус революциясе елларындагы төрмә лирикасы явызлыкка каршы көрәш, киләчәккә өмет фикере белән яши. Реакция елларында иҗат ителгән шигырьләрдә зиндан-азатлык антиномиясе драматик, я булмаса фаҗигале кичерешләргә корыла. Унынчы еллар шигъриятендәге мәхбүс темасы, фәлсәфи эчтәлектә бирелгән рухи азатлык мотивлары белән кушылып, аерылгысыз бер бөтен булып үсеп китә.

«Шулай итеп, татар поэзиясендә традицион тоткын образы белән заман яшь кешесенең лирик образы арасында тирән аваздашлык, якынлык барлыкка килеп, нигездә, бу момент романтик чагылыш алды. Әмма шул ук вакытта монда, әдәби шартлылык һәм гомумилек күпме генә сакланмасын, заман чынбарлыгы белән бәйләнгән реаль

башлангычның өскә чыгарга теләве дә төсмерләнде. Соңгысы исә лирик геройның, шагыйрьнең беренче нәүбәттә зур чынбарлыкка, ил, халык язмышына якын торуы кебек шартлардан азыклана иде» [11, б. 154].

Әдәбиятта киң чагылыш тапкан токтынлык, төрмәләр темасы котылгысыз рәвештә доносчы, шымчы, әләкче образларын мәйданга чыгара. Әдәбиятка өр–яңа тискәре образлар килеп керә. «Татар мәгърифәт учакларын туздыру, демократик көчләрне эзәрлекләү максатыннан, репрессия машинасы, үз хәрәкәте тагын да нәтиҗәле булсын өчен, татарлар арасыннан җасуслар төркеменә дә таяна» [1, б.146]. «Провокаторлар Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Колахметов, Г. Ибраһимов кебек әдипләр һәм яшьләрнең идеологлары булган башка кешеләр арасына үтеп керәләр, самодержавиегә каршы сүз сөйлиләр, чын йөзләрен яшереп, бу әдипләр белән дуслык мөнәсәбәтләре урнаштыралар. Һәм көнлек информацияне жандармериягә җиткереп торалар. Мондый шымчылардан бигрәк тә Г. Ибраһимов, Г. Тукай, Г. Камал, Ф. Әмирхан, Г. Коләхметов, Ф. Агеев, Г. Газиз, Ш. Әхмәдиев җәфа чиккәннәр» [4, б. 35]. Без бу исемнәр янына Г. Исхакый фамилиясен дә өстәр идек. Шул рәвешле, жандармерия идарәсе һәм полиция хезмәткәрләре, гайре табигый чаралар кулланып, милли азатлык хәрәкәтен эчтән таркатырга тырыша.

Бу чор әдәбиятында сатлык җаннар, монафикълар, шымчылар тәнкыйть объектына әйләнгәннәр. Мисал итеп, М. Гафури, В.Җәлал, Г.Гайнуллин, Х.Габидов шигырьләрен китерергә була. Бу елларда М. Гафури үзенең «Доносчы» (1910), «Сатлыклар» (1911) дигән шигырьләрен иҗат итә. Мәсәлән, «Доносчы» шигырендә доносчы-провокаторның чын йөзе шигырьнең дүрт юлында ачып бирелә:

Белми бит ул алдына баскан дию –
Табынып шуңа, ул да зураймак була;
Ике тиен дә тормаслык җәлладларга
Башын сатып, тамак туйдырмак була. [3, б. 247]

Шагыйрь сурәтләгән дию – самодержавиенең терәге булган кара көчләр символы.

Бер үк вакытта автор кеше табигатенең камил булмавын, аның, хакимият каршында вөҗданын сатып, «зураерга», дәрәҗәсен күтәрергә теләвен дә искәртеп үтә. Бу бозык адымга баруның икенче сәбәбе дә бар икән: кайберәүләр бу адымга тамак туйдыру өчен баралар.

Ә «Сатлыклар» шигырендә өстен сыйныфларның халык көче белән мал туплауларын, ерткычлыкларын, әхлаксызлыкларын фаш иткән реалист – әдип кешеләрне акчага, алтынга сатылуда гаепләде. «Җир өстендә кайчан алтын бетәр, шунда туар хаклык» дигән фикер белән чыкты.

Кем бар соң сары алтынга сатылмаган,
Үз-үзен алтын белән шат кыйлмаган;
Килер җир, чыгар урын күренгәндә,
Күзе тонып, үз якынын ят кыйлмаган?
Шуның өчен хакыйкать аска калды,
Дин, вөҗдан, инсаният һәм тапалды...
Халыкның күз терәгән нәрсәсе – шул,
Башка якны уйлау-фәләннәр тукталды. [3, б. 276]

Шәрекъ, төрки һәм татар әдәбиятларында алтын – акча – байлык хакимиятен тәнкыйтьләүнең бик еракта килгән тамырлары бар. Алтынның коточкыч җимергеч көче турында изге китапларда да язылган. Урта гасырларның һәм Яңа заманның барлык күренекле шагыйрьләре алтын хакимиятен җәмгыятьтәге рухи яшәешенең нигезләрен какшатучы явыз көч итеп карадылар (Хакани, Низами, Нәвои, Фөзули, Мөхәммәдьяр, Тукай һ.б.). Мәҗит Гафури да алтынны татар халкы яшәешендәге дин, вөҗдан, инсаният кебек рухи кыйммәтләрнең тамырын корытучы явыз көч дип таный.

Доносчы образы Вакыйф Җәлал (1887–1922) һәм Гариф Гайнуллин (1878–1935) шигырьләрендә дә очрый. Бу темага һәр шагыйрь үзенчә якын килергә тырышкан. Мәсәлән, Вакыйф Җәлал «Доносчыга» шигырендә мондый затларны каты тәнкыйть утына тота, аларны «еланнан да явыз, эттән дә яманрак бәндәләр» итеп күрсәтә, пычрак ашап тамакларын туйдыручы «хинзыйр», ягъни дуңгыз белән чагыштыра. Ә Гариф Гайнуллин үзенең «Ялган доносчыга» дигән шигырендә мәгърифәтчеләрчә үгет-нәсыйхәткә мөрәҗәгать итеп, бу кара эчле затны (ә ул, өстәвенә, дин әһеле) үзенең кылган яман эшләреннән тәүбә кылырга, бары тик Алла колы булырга гына чакыра:

Бул иманлы,бул оҗмахлы – бул изге кол син генә!
Бул «мөшәех» син доноска, даимән чапмак белән…
Гайреләр тик «зиндыйк» улса, «дәһри» улса да ярар;
«Иң якыны» хакның бул син, шул уйда ятмак белән.
Уйла үзеңне: «яхшы»лардан һәм «чын голяма», диеп,
Һич урынсыз, милләтеңә ифтира япмак белән.

Шигырьнең азагында милләткә яла ягуның чын голәмә өчен Хак Тәгалә юлыннан ераклашу, дәһрилек итеп тамгалана.

Хәбибулла Габидов та (1886–1939) «Мәхбүс мөгаллим» (1916) шигырендә бу теманы дәвам иттерә. Автор үзе дә, Верхотура һәм Иркутск якларында мөгаллимлек иткәндә, көндәшләренең әләкләре – «ифтиралар ягулары» аркасында, төрмәдә утырып чыга. Шигырьдә ул үзенең төрмәдә үткәргән борчулы көннәренә һәм хәсрәтле кичерешләренә басым ясый:

Йокым килми, төннең-төн буена көтеп алам таңның атканын;
Калын диварларның арасында уйлыйм дошман мине сатканын.
Бер сискәнеп җаным, бер калтырый… әйләнәсе аның кыш кебек;
Җим эзләргә чыгып, аута төшеп әҗәл көткән мәэюсез кош кебек.
Зарлана да җаным, моңлана да… тар урынга кереп ябылгач...

Күренә ки, Х. Габидов төрмә һәм шымчылык темасын традицион образ-сурәтләр ярдәмендә ача (калын диварлар, тар бүлмә, йокысызлык, мәэюс кошка әйләнү, гакыл качу һ.б.). Шигырьнең эчтәлегеннән күренгәнчә, шагыйрь җәдитче мөгаллим булган, әмма кадимчеләр аңа яла якканнар, «мәгъсүм, яшь сабыйларга» белем бирүдән мәхрүм иткәннәр.

Мөгаллим халкы һәм балалар алдындагы изге эшен ахыргача алып барып җиткерә алмавына уфтана.

XX йөз башындагы татар зыялылары, мөгаллимнәр аеруча Ишми ишан шымчыларыннан җәфа чигәләр. Аның образы явызлык символы буларак әдәбиятка да кереп калган. Ишми ишанның самодержавие агенты булуы турында күп документлар сакланып калган. Бу хакта М. Мәһдиев мәкаләсендә, А.Х. Мәхмүтованың «Лишь Тебе, Народ, Служенье» монографиясендә күп мәгълүмәт китерелә.

Г. Тукай да 1910 елда язылган «Кайда? Кем?» дигән шигъри фельетонында Ишми ишанны «фетнәле эшләр башында» торучы тәдәнни (артка өстерәү) арбасы дип атый, сатира теле белән аны «мәлгунь», «чалмалы карт марҗа» дип сүгә:

Бәдбәхет мәлгунь кеше кем, дусларым?
Бер авылның чалмалы карт марҗасы! [9, б. 96]

Ә икенче бер шигырендә дә, халык җырлары стиленә мөрәҗәгать итеп, Тукай Ишми ишанны «милләтне сатучы», доносчы дип тәмамлый:

Кушмый ишан капкасы, нарат икән тактасы,
Нарат булмый нәрсә булсын, бар да донос акчасы.
Безнең урам– таш урам, ташу ага басудан,
Сакалына хөрмәт беткәч, милләт сата ачудан. [9, б. 153]

«Доносчы колагына хор белән әйтелер» (1912) шигырендә дә Тукай милләтен, аның алдынгы карашлы улларын сатып акча эшләгән мондый адәмнәрне үләксә, иблис, шайтан белән чагыштыра:

Ташдыйн битәр катысың!
Үләксәдәй сасысың!
Һәр көн донос ясыйсың!
Вөҗдансызсың тидия!
Һәр фетнәнең башысың!
Иблиснең юлдашысың!
Милләт башын ашыйсың!
Хәрам корсак тидия! [8, б. 346]

Шагыйрь, «Кызыл алма» дигән дини китапның стиленә ияреп, публицистларча маңгайга бәреп, хәтта натуралистик бәяләр биреп («Суга сигән җүләрсең»), унынчы еллар башында көчәеп киткән доносчылык күренешләрен камчылый.

XX гасырның башында милли азатлык хәрәкәте яңа бер үсеш баскычына аяк басты. Татар халкының төрле катламнарын берләштереп, милли аңны үстерү, милләтне иҗтимагый һәм рухи тәрәккыять баскычларына күтәрү, әһәмиятле мәсьәлә буларак, көн тәртибенә куелды. Татар зыялылары бу юнәлештә ачыктан-ачык та һәм яшерен рәвештә дә эш иттеләр: очрашулар, җыелышлар, хәтта Киевта яшьләрнең мөселман съездын үткәрүгә омтылыш ясадылар. Патша самодержавиесе, жандармерия, полиция, төрле күзәтүчелек оешмалары татарлар арасындагы сәяси хәрәкәтләрне күзәтеп торды. Бу эшкә татарларның үзләре арасыннан да шымчылар төркемен булдыруга зур игътибар бирде. Бик күп татар зыялылары пантюркизмда, панисламизмда гаепләнде. Татар зыялылары да патша хөкүмәтенең бу эзәрлекләвенә җавапсыз калмадылар: газета-журнал битләрендә мәкаләләр, шигырьләр, хикәяләр белән җавап бирделәр.

ӘДӘБИЯТ

1. Бәширов Ф.К. XX йөз башы татар прозасы. Казан: Фикер, 2002. 132–133 б.
2. Ганиева Р.К. Төрки әдәбиятларда иҗат методы мәсьәләләре: Хәзерге татар әдәбият белеменең актуаль мәсьәләләре. Казан: 1979. 97–105 б.
3. Гафури М. Әсәрләр. Дүрт томда. 4 том. Шигырьләр һәм мәсәлләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. 66 б.
4. Мәһдиев М. Татар провакаторлары: XX йөз башы татар зыялылары арасында патша хөкүмәте агентурасы // Идел.1999. № 4. Б. 35.
5. Садретдинов Ш. Сәгыйть Рәмиев иҗаты. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1973. 28 б.
6. Садретдинов Ш. Сәгыйть Рәмиев // Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. 3 том. XX гасыр башы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 174 б.
7. Сүнчәләй С. Әсәрләр һәм хатлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 88 б.
8. Тукай Г. Сайланма әсәрләр: Шигырьләр, әкиятләр, поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. 346 б.
9. Тукай Г. Әсәрләр. 4 томда. 2 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 96 б.
10. Халит Г. XX йөз башында татар әдәбияты: очерклар. Казан: Таткнигоиздат, 1954. 48 б.
11. Халит Г. Яңа гасыр поэзиясе: XX йөз башы (1905–1917 еллар) татар поэзиясендә иҗат методы, лирик герой, традиция һәм новаторлык мәсьәләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 148 б.
12. Халит Г. Әдәби процессның төп юнәлеше. Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. 3 том. XX гасыр башы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 59–60 б.

## «СӨЕМБИКӘ» ЖУРНАЛЫ (1913–1918) БИТЛӘРЕНДӘ ТУКАЙ

***Гыймазова Р.А.***

В статье рассматриваются статьи и художественные произведения, посвященные великому татарскому поэту Габдулле Тукаю, а также его произведения, нашедшие отражение на страницах журнала «Сююмбике» (1913–1918).

The article deals with the papers and works of art dedicated to the great Tatar poet Gabdulla Tukay. It also analyzes his poems published in "Syuymbike" magazine (1913–1918).

1913 елны Иж-Бубый авылы крестьяны, журналист, мөгаллим, мәгърифәтче, мәктәп дәреслекләре Якуб Ибраһим улы Хәлиуллин (Якуб Хәлили), хатын-кызлар өчен татар телендә «Сөембикә» исемендә журнал чыгарырга рөхсәт сорап, губернатор исеменә гариза яза һәм 1913 елның 16 сентябрендә 10716 саны белән теркәлгән таныклык алуга ирешә [1].

«Сөембикә» журналы, татар хатын-кызлары өчен татар телендә чыгарылган иң беренче журнал буларак, эчтәлеге белән тормышның бөтен якларын да яктыртырга тырышкан. Басманың программасы XX гасыр башы татар хатын-кызлары өчен генә түгел, XXI гасыр башында да үзенең актуальлеген югалтмаган мәсьәләләрне күтәргән.

Журнал Русиянең төрле өлкәләрендә яшәүче укымышлы, зыялы татар хатын-кызларын берләштерүдә зур роль уйнаган. Үз вакыты өчен актуаль булган барлык вакыйгалар да аның битләрендә урын тапкан. Хатын-кызларларга көндәлек тормышта ярдәм итәрдәй, киңәш бирердәй мәкаләләр белән беррәттән, җан ризыгы булырдай әдәби әсәрләр дә әлеге басмада урын алган. Хатын-кыз авторлар белән беррәттән ир-ат авторларны да, татар зыялылары хакында мәгълүматлар да күрергә мөмкин.

«Сөембикә» журналының 1914 елның апрель саны (№ 11) тулысында мөхтәрәм шагыйребез Габдулла Тукайга багышланган. Әлеге сан тышлык битендә Г. Тукайның

фотосурәте һәм «Хатыннар хөррияте» шигыре белән башланып китә. Әлеге сан шагыйрьнең вафатына бер ел тулу уңаеннан басылганлыктан, чордашларының хәтирәләре, аларның юксынулары, сагынулары белән сугарылган. Мөхәррир Якуп Хәлили «Габдулла Тукаев өчен» язмасында: «Бу көн бөтенләй безнең хәсрәтемез яңара, аның авырсулап яткан вакытлары, җан бирүләре, әллә ничә мең кешеләр белән Казан урамына сыеша алмыйча җеназасына озаткан минутлар күзалдына килә, ирексез елыйсы килеп күздән яшь чыга башлый. Шуның өчен без бу көндә матәм тотмый, кайгы-хәсрәтебезне сөйләшеп уртаклашмый, аның мөбәрак рухына дога кылмый үтә алмыйбыз» – дип, «Тукай халык кешесе, халык шагыйре иде. Ул сөйләгән сүзен халык өчен сөйләде. Җырлаган җырын халык өчен җырлады. Көйләгән көен халык өчен көйләде. Аның сүзе, җыры, көе халыкныкы иде. Ул халык өчен туды. Халык өчен яшәде. Аллаһ биргән таланты белән халыкка карап төрлечә: бәгъзан бик шатлыклы, бәгъзан бик кайгылы җырлар җырлады. ... Габдулла әфәнде үлде, ләкин ул энҗеләрне чәчеп үлде», – дип сүзен дәвам итә [2].

Шагыйрь Вакыйф Җәләл дә үз кайгысын дустын югалткан күгәрчен аркылы сурәтли:

Очып килде күгәрчен бу кабергә, кайгы, моң берлә,
Диде: «Күкләрдә очкан иң якын дустым һаман монда» [3].

Соңнан автор үзенә кайтып:

Күңел әрни, җылый, сыкрый, тибә «безнең Тукай кайда?, –

дип ачына [3].

Шунысы кызыклы, әлеге шигырьне Вакыйф Җәләл Г. Тукай шигырьләренә охшатып ике мисраглы итеп язган.

Үбәм кабереңне кайнар күкрәгем берлә, газиз юлдаш,
Сине төштә күрермен ихтимал, туфракка куйдым баш [3], –

дип, сагынган һәм юксынган юлдашын төштә булса да күрүен өмет итә.

Язучы, журналист, публицист, күренекле җәмәгать эшлеклесе Шәһид Әхмәдиев Вакыйф Җәләлнең сүзләрен дәвам итеп «Габдулла Тукаев чын милли татар шагыйре иде. Ул милләтнең нинди генә күңелсез яклары булса, һәммәсе өчен уф орды, әрнеде, көйде, сызланды. Үзенең ачы хәсрәтләрен матур тезелгән, җиңел гыйбарәле шигырьләре белән җырлады. Аның җырлавын да, күз яшьләрен дә татар халкы бик тиз аңлады», – ди [4, б. 5].

Хатын-кызлар өчен чыгарылган журнал буларак, Г. Тукайның татар-хатын кызлары белән бәйләнешле шигырьләре аша, аның тормыштагы урынын, зарын, аһ-моңы хакында Ш. Әхмәдиев тәфсилләп яза. Һәм шагыйрьнең аның хәяттәге урынын күреп, күңеле сызлануын, җаны-тәне аша аларның кичерешләрен уздыруын искә алып, әлеге шигъри юлларны китереп үтә:

Күрмисең бит син дә, синең
Яннан нечкә күңел шагыйрь узганын,
Синең болай мескенләнгән хәлең –
Аның күңлен ничек өзәсең [4, б. 6].

Язучы Садри Җәләл дә фикердәшләренең сүзләрен дәвам итеп, фәлсәфи эчтәлекле чыгышын дәвам итә [5]. Ул баласын югалткан Ата хакында сөйли. «Ата» – татар халкы. Ата кичерешләре аркылы милләтнең борыңгыдан, данлы, шөһрәтле, дәүләтле чакларын искә төшереп үтеп, михнәтләрнең килүен, бөеклекләрнең бетүен, «сөекле угыллары үзләренең якты көннәрен сагынып җырлаган кайгылы көйләре белән, кызлары да моңлы курайлары белән аның кайгысын таратырга, ничек тә булса аның күңелен ачырга тырышканнар»ы хакында язып үтә. Тора-бара әлеге Атаның угыллары арасында кадер-хөрмәте бөтүе һәм шул сәбәптән ул (Ата) Аллаһтан дога кылып, үзенә, аның шанына лаеклы уллар сорый. «Менә өч йөз елдан» соң Аллаһ Атаның сүзен ишетеп, үзе сораган балаларын бирде дип яза Садри Җәләл. «Менә шул сөекле угыллары арасында берсе үзенең моңлы җырлары белән бигрәк тә аңар охшаган. Ул углының бөтен гомере авырлыкта, ялгызлыкта үткән» [5, б. 8], шунлыктан «Өзлеп-өзлеп кенә әйтеп» биргән

Татар күңлениләр сизгәнен;
Мискин булып торган өч йөз елда
Тәкъдир безне ничек изгәнен, –

дип үз фикерен Тукай шигыре белән дәвам итә.

Соңнан бу җырчы баланың да тормыш авырлыклары көчен бетерүләре сәбәпле «әүвәлге җырлар, саф, яшь мәхәббәт чаткысы» очмый башлаган, – дип дәвам итә автор [5, б. 9].

Әй, мөкатдәс, моңлы сазым, уйнадың син ник бик аз?
Син сынасың, мин сүнәмен – айрылабыз ахрысы...,

дип моңланганын да Атасы читтән генә һаман тыңлап торган һәм озак та үтми алар аералганнар. Сөекле улын күмеп кайткач, Ата тирән сулаган да:

Бер мәел бардыр кадимнән: яхшыга булган зәвал.
Әй җаным, би назыйр мөэмин мөселманым балам!..

дигән.

Әлеге Ата әле һаман да баласын сагына, хисас күңелле, үткен сүзле шагыйр тели, ди Садри Җәләл. Халыкның Тукайны онытмауларын, аның каберен әле дә зиярат итүләрен язып:

Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабрең ташы,
Шунда тамсын күз яшемнең иң ачысы һәм татлысы!...,

дип сүзен тәмам итә.

«Сөембикә» журналының хатыннарга багышланган булуыннан чыгып Гафур Чыгътай үзенең мәкаләсендә Габдулла Тукай тормышында урын алган хатын-кызларга тукталып үтә. Анасын, тәрбияләгән, гыйлем биргән ханымнар хакында әйтеп бәянли. Иң беренче укытучысы итеп кадимчә белем бирүче абыйстай, ләкин аның хисе вә сизгерлеге белән кечкенә Габдулланың рухына тәэсир иткәнен, «хәтта шагыйрьлекнең иң элеккеге орлыгы Габдулланың күңеленә шул абыстайның өендә утыртылмыштыр» [6], ди. Соңнан аның шагыйрь булып формалашуын, аның тормышында роль уйнаган шәхесләрне язып үтеп, «әл-Гасрел-җәдид» битләрендә 9 ай буена дөнья күргән шигырьләрен анализлап, халык шагыйре булып формалашу этапларын күрсәтә. «Монда, әлбәттә, шагыйрьгә милли матбугат тәэсир иткән вә ул да рухындагы гармунын тиз үк җыерган вә тарткан да, шагыйрьлеген халыкның теләгенә муафыйк якка боргандыр» [6, б. 14], – дип язып үтә Гафур Чыгътай. Сүзен дәвам итеп: «Ул кешене ир вә хатынга аерып йөртмәде. Ул бер генә җенес халыкны – милләтне генә беләдер иде. Ул әйткән сүзен бөтен милләттәшләренә карап әйтте вә шуның өчен Т.[укай] мәрхүмнең шигырьләрен кыз балалар ир балалардан ким укымыйлар, бәлки кыз балаларның хис вә рухлары тагы нечкәрәк вә сизгеррәк булганга алар Т.[укай]ны тагы артыграк аңлыйлар вә аның матур-матур шигырьләрен кыз балалар һичкемнән калышмый ятлыйлар» [6, б. 15], – дип азсызыклый. Тукайның әлеге чордагы урынын күрсәтеп «шундый тарихи бер үзгәрештә милләтне сынудан саклый торган бер терсәк урынын тотды» һәм «без аны телгә алырга бурычлыбыз, ул безгә хезмәт итте [...] 2 нче апрельдә мае беткән шәм кебек сүнде [...] Тукай наме бу дөнья шары кояш кәррәсендә кушылып янганча яшәсен» [6, б. 15], – дип сүзен тәмам итә.

«Сөембикә»нең 16 битендә Казан шәһәреннән Г. Харисның Тукайга багышланган «Өн» исемле шигыре урын алган [7].

Гадел Лотфи да «Хатыннар турында Тукай» дигән мәкаләсендә шагыйрьнең кыз балалар тормышын чагылдырган шигырьләренә таянып, аларның авыр һәм ачы тормышын сурәтли.

Йөрәк янып һаваларга чыга төтен.
Яндырадыр ягам дисә, калдырадыр
Якмыйм дисә: аның каршысында без утын... [8, б. 17]

Үзенең мкаләсен «Тукай мәрхүм, гомумән, чын хөрриятче иде... Шуңа күрә дә бөтен ханым вә туташларыбыз белән Тукай мәрхүм өчен догада калып Л. Гадел» [8, б. 18], – дип йомгаклый.

Казаннан шагыйрь Габдрахман Сөнгати үзенең «Сүнде!..» [9] исемле шигырен Тукайга багышлаган:

Балкыды күктә бер йолдыз, нурын чәчте уйнап өскә,
Күмде куйды караңгы дөнья безне ак, көмеш төскә.

Матур нурдан тулып торды җиде кат күк бөтен җирләр,
Үсеп торды бу ак нурда хисапсыз күп матур гөлләр.

Менә шул чак шәмаилдән бер караңгылык заһир булды,
Исеп ямьсез ачы җил, күк болытлардан тәмам тулды.

Бөтен өсне караңгылык каты каплап күмеп китте,
Шушы ямьсез кара төндә матур йолдыз сүнеп китте.

Тукайга багышланган истәтек-мәкаләләр, шигырьләр белән беррәттән, журнал битләрендә шулай ук берничә фотосурәтне дә күрә алабыз. Алар: «Габдулла Тукай» [10], «Шагыйребез Габдулла Тукаевның җеназасының Печән базарыннан үтеше» [11], «Шагыйрьләребездән Г. Тукаев җеназасының мәйдандагы күренеше» [12], «Шагыйребез Габдулла Тукаевның каберстаны» [13] исеме астында китерелгән.

1914 елның 11 санын 4 тышлык битендә Камил Мотыгый тарафыннан Тукайга багышлап Габдулла Кильдешев наширлегендә нәшер ителәчәк «Тукай хәтирәләре» исемле китапның игъланы да урнаштырылган. «Мәрхүм шагыйребез Габдулла әфәнде Тукаевның вафатына нәкъ бер ел тулу мөнәсәбәтилә апрельнең 2ндә чыгарга фарыз ителә!» [14], – ди әлеге игъланда.

Шулай ук «Сөембикә» журналының башка саннарында да Габдулла Тукай белән бәйләнешле мәгълүматларны таба алабыз. Шул ук 1914 елның 1 санында «Мәгариф» китапханәсе тарафыннан нәшер ителгән 463 битлек «Габдулла Тукай мәҗмугаи әсәре», аның эчтәлеге турында мәкалә урнаштырылган [15].

Әйтеп кителгән елның 7 саны Г. Тукайның «Пәйгамбәр» исемле шигыре белән башланып китә. Аңа иллюстрация итеп Кәгъбәтулла рәсеме дә куелган [16].

Тукайны искә алуны Казанда гына түгел, ерак Бохара шәһәрендә дә уздырылуы хакында 4 нче сыйныф талибәсе Фатыйма Мәүләеваның «Бохарада Тукай кичәсе» [17] исемле мәкаләне укып беләбез. Әлеге мәҗлесне Бохарада «Мәрҗания» исемле даруханәнең хуҗасы Туктар Динникаев оештырган. Бу мәҗлестә Камил Мотыгый-Төхфәтуллинның да булуы мәҗлесне тагында ямьләндереп җибәргән. Ул Тукай рухына Коръән һәм салават шәрифләр укып, соңрак шагыйрьнең төрле шигырьләрен сөйләп һәм җырларын җырлаган. Автор мөгаллим Камал Нугаев татарфыннан Бохарада укучы татар, нугай балалары хор белән берничә шигырь әйтелүен хәбәр итә.

1916 елны да апрель (11) санында Тукайны искә алып үтәләр. «Олуг шагыйремез Габдулла Тукаевның вафатына өч ел тулу мөнәсәбәтилә» дип шагыйрьнең фотосурәте китерелгән [18]. Аннан соң шагыйрь Әбрар Сәгыйдинең «Мәрхүм шагыйрьгә» [19] исемле шыгыре урын алган.

Күпме еллар, күпме айлар үтеп китте,
Изге шагыйрь! Син дөньядан аерылганга.
Бик вакытсыз явыз тәкъдир кызганмыйча,
Татарларны шагыйреннән аерганга, –

дип зар елый автор.

Фәхрелбанат Сөләймания үзенең «Уфа хәтирәләре» исемле мәкаләсендә 1916 елның 3 апрелендә Уфада «Ханымнар җәмгыяте» тарафыннан ачылган кызлар мәктәбендә Г. Тукайның вафатына өч ел тулу мөнәсәбәте илә балалар кичәсе уздырылу хакында бәянли [20]. Мәҗлес башында кызлар хәтем иткән Коръәнне мәрхүм шагыйрьнең рухына багышлаганнар, укытучылары тарафыннан тәрҗемәи хәлләре укылып, шигырьләре көйләп укылган, укучы кызлар да остазларыннан калышмаган, берәм-берәм дә, хор белән дә мәкам белән укырдай шигырьләре көйләнгән. «Кичә гаять күңелле булып, татар кызларының, татар шагыйрен искә төшереп аны чын күңелдән ихтирам итүләре күңелгә әллә нинди шатлыклар биреп, киләчәккә зур өметләр уятты», – дип яза мәҗлес белән рухланган Фәхрелбанат ханым.

Күргәнебезчә, телгә алынып үтелгән хезмәтләр аша Габдулла Тукай әле үз дәвере татар зыялыларының хөрмәтен казанган шәхес. Аның исеме, аның мирасы киләчәктә дә чордашлары кичергән дулкынландыргыч тирән хисләрне уятыр дип өмет итәбез.

ӘДӘБИЯТ

1. Татарстан Милли архивы. 420 ф., 1 тасв., 243 эш.
2. Хәлили Я. Габдулла Тукаев өчен // 1332/1914. № 11. Б. 2–4.
3. Җәләл В. Тукай кабере янында // 1332/1914. № 11. Б. 4.
4. Әхмәдиев Ш. Шагыйремез Габдулла Тукаевның хатыннарга карашы // 1332/ 1914. № 11.
5. Җәләл Садри. Аның сөекле углы // 1332/1914. № 11. Б. 7–9.
6. Чыгътай. Габдулла Гариф улы Тукай // 1332/1914. № 11. Б. 10–15.
7. Харис Г. Өн: (бөек шагыйребез Г. Тукаевка багышлыйм) // 1332/1914. № 11. Б. 16.

8. Гадел Л. Хатыннар турында Тукай // 1332/1914. № 11. Б. 16–18.
9. Сөнгати Габдрахман. Сүнде!.. // 1332/1914. № 11. Б. 18.
10. Сөембикә. 1332/1914. № 11. Т. б.; Б. 2.
11. Сөембикә. 1332/1914. № 11. Б. 6.
12. Сөембикә. 1332/1914. № 11. Б. 10.
13. Сөембикә. 1332/1914. № 11. Б. 14.
14. Игълан: [мәрхүм Габдулла Тукаев хакында] // 1332/1914. № 11. Т.б.
15. Матбугат галәме: [«Габдулла Тукай мәҗмугаи әсәре»...] // 1332/1914. № 1. Б. 18–19.
16. Тукай Г. Пәйгамбәр // 1332/1914. № 7. Б. 1–2.
17. Мәүләева Ф. Бохарада Тукай кичәсе // 1332/1914. № 13. Б. 13–14.
18. Олуг шагыйремез Габдулла Тукаевның вафатына өч ел тулу мөнәсәбәтилә // 1334/1916. № 11. Б. 189.
19. Сәгыйди М. Ә. Мәрхүм шагыйрьгә // 1334/1916. № 11. Б. 189–190.
20. Сөләймания Фәхрелбанат. Уфа хәтирәләре // 1334/1916. № 13. Б. 227–228 (Мәкаләдә авторы: Ф.-Б. Сөләймания).

## ХАТЫННАРЫ ТӘРБИЯЛЕ БУЛГАН МИЛЛӘТ – ТӘРБИЯЛЕ....

***Гыйманова Д.Г.***

В статье рассматриваются труды известного просветителя и педагога Р. Фахреддина и татарского поэта Г. Тукая. Наряду с анализом их произведений, посвященных проблеме образования и воспитания в семье, проводятся тематические и концептуальные параллели в подходах как ученого, так и поэта к обозначению нравственности женщины как краеугольного камня в фундаменте семейного счастья.

This article contains works of well-known enlightener and scientist Riza Fakhreddin and the tatar poet Gabdulla Tukay. Along with their composition analyses about problem of education and parenting, you can see the thematic and conceptual parallel in scientist and poet approaches to means of woman's morality as cornerstone in bases of family happiness.

Р. Фәхреддин гаилә төзү кебек үтә дә җаваплы гамәлдә, аның турындагы әдәпләрне өйрәнү һәм тормышны да шул әдәпләр буенча коруны, иң мөһим бер бурыч булуын төшендерә һәм гаилә хәлләре төзек булмаганда һәм тәрбия ысулына нигезләнмәгәндә, нинди генә бөек милләт булса да, ул яши алмаячак икәнен «Гаилә» әсәрендә күрсәтеп бирә. Милләтләрнең дәрәҗәләрен күтәргән һәм саклаган нәрсәнең дә гаилә икәнен аңлатып бирә. Аның фикеренчә, милләтнең үсешен тәэмин итү өчен элек гаиләнең төзеклеген, әхлагын кайгырту кирәкле бер эш булып тора.

XX гасыр башында актуаль булган бу мәсьәлә милләтебезнең йөзек кашы булган Г. Тукайны да бик борчыган. Шул нисбәттән ул тирән мәгънәле шигырьләр язып үз фикерен белдерергә ашыккан. 1905 елда язылган «Мужик йокысы» дип аталган шигырендә ирләрнең бәхете уңган, акыллы хатын кулында икәнлеген искәртеп «мужик»-ны шелтәләп тә алган:

...Игенең урмаган,
Кибәнең куймаган,
Син үзең дә ялкау,
Хатының да «булмаган»…[1, б. 31]

Р. Фәхреддин «Гаилә» хезмәтендә аерым бүлек итеп язган тиңдәшлелек мәсьәләсе дә Г. Тукайны борчыган:

«Бәхет юк, аның тик исеме генә бар, –
Тигез-тиңлелеккә юл куймау бездә гадәт.
Ярың тиң-пар булмаса, әлбәттә, һәлакәт,
Пар булу шарт, пар булу шарт, пар булу» [1, б. 62]

«Әлислах» газетасы битләрендә 1908 елда «Фекаут» анограммасы белән басылган «Фөрьяд» әсәрендә Г. Тукай «бер хатын авызыннан» дип язып тиңдәшлелек, күпхатынлылык, хатын-кыз иреге мәсьәләләренә тукталып үтә.

«Шул зинданда үсеп җиттем унсигезгә,
Хатын булдым зур корсаклы бер симезгә.
Мәгълүм инде, аңа бардым түгел сөеп:
«Егълау – риза, дәшмәү – риза»га буйсынып.

Өч баш хатынлы иде ул, мин – дүртенче;
Җыелыштык бер тар йортка без дүрт көнче, –
Кисеп әйтә алмыйм әле дүртенче дип:
Мин булганмын, бәлки, инде ундүртенче» [1, б. 203]

Бу әсәрдә хатын-кызның ирексезлеге белән беррәттән ир-атның әхлаксыз тормыш алып баруы да күз уңында тотыла. Бу мәсьәлә җәмгыятьтә бик тирәнгә киткән авыру мисалында булганлыктан Р. Фәхреддин дә «Әсма, яки Гамәл вә җәза» әсәрендә укучыны уйланырга мәҗбүр итеп мондый фикерен җиткерә:

«Милләт, димәк, тәҗрибәле картлар, тәүфыйклы егетләр, яки игелекле һәм тырыш ирләр, тәрбияле хатыннардан тора... Бер милләтнең картлары мәчет һәм гыйбадәтханәләрдә тулып ятсалар, яшьләре бозыклыкка чумып, хатыннары исраф һәм фахишәлектә йөрсә, бу милләт бетте дигән сүз...» [4, б. 108].

«Кечкенә генә бер көйле хикәя» дип исемләнгән хезмәтендә Г. Тукай тирәнрәк итеп тиңдәш булмаган азгын хатын,үз балаларына үрнәк була алмаган ана мисалына туктала. Автор Сәйфи абзый дип исем биргән гади генә булган бер ир затын сурәтләүдән башлап җибәрә хикәясен: бик юаш холыклы, диндар, тәкъва кеше, тик үзенә тиң булмаган хатын белән гаилә корып җибәрә. Хатын дигәне Фатыйма исемле тар күңелле, холыксыз, иреннән гел зарланып яши торган, мода артыннан калышмыйча, шул нисбәттән гаиләдә тавыш-гауга чыгарырга гадәтләнгән тәрбиясез хатын итеп күрсәтелә. Үзенең төпле фикере булмаганлыктан, йортка килеп йөри торган бер карчыкның сүзенә ияреп кәеф-сафа корырга урамга чыгып китә, шулай итеп әхлаксызлык юлына баса. Ире хатынын гомерлек юлдашы, балаларның үрнәк анасы итеп күрергә теләсә дә, ялгышын аңлап, фахишәлек юлында йөргән Фатыйманы йорттан куып чыгара. Г. Тукай мондый хәлләрнең даими рәвештә татар тормышында кабатланып торганлыгын исәпкә алып болай ди:

«Бу көнгәчә булган хәлне монда яздым,
Яза-яза артык язып китә яздым;
И Фатыйма, кызганамын – нигә аздың?
Азмаганны һичбер каләм язмас имди» [1, б. 81]

Р. Фәхреддин «Әсма, яки Гамәл вә җәза» әсәрендә дә моңа охшаш хәлләрне бәян итә һәм ахырында укучыга уйланырлык итеп түбәндәге фикер белән тәмамлый «адәмнәр, кирәк яхшы, кирәк яман булса, гамәленә карап җәза күрерләр» [4, б. 148].

Гаилә эчендәге бөтен кешеләрнең бәхете – тәрбияле хатын кулында, әгәр дә гаиләдә хатын тәрбиясез булса, ул гаиләдә барысы да бәхетсез булачаклар. Р. Фәхреддин фикеренчә, ирләр нинди генә гайрәтле булмасыннар, хатыннары тәрбиясез була икән, алардан да бәхетсез кеше булмас. Чөнки чын бәхет – тәрбияле хатын белән гаилә корып рәхәт гомер итүдән гыйбарәт. Шулай булгач, иң кирәкле нәрсә - тәрбияле хатын булып, аның йогынтысы бөтен милләткә файдалы булачак. «Гаилә» әсәрендә «хатыннары тәрбияле булган милләт – тәрбияле; хатыннары тәрбиясез булган милләт – тәрбиясез; хатыннары тырыш вә идарә итүчән милләт – бай; хатыннары ялкау вә яки исраф итүчән милләт – фәкыйрь буладыр» [2, б. 23], дип Р. Фәхреддин хатын-кыз тәрбиясе мәсьәләсен милләт өчен көнүзәк проблема икәнен ассызыклый.

Хатын-кызны тәрбияләү тагын шушы ук хатын-кызлар кулында. Ничек кенә милләткә файдалы балалар тәрбияләп «чума авыруы микроблары» бәрабәрендә булган тәрбиясез аналардан, тәрбиясез хатыннардан арынырга? Р. Фәхреддин билгеләп үткәнчә «...Чын гаеп – нинди генә гаиләдән булмасын, гыйлем, мәгърифәт, тәрбиядән мәхрүм булуда. Әмма моны яхшы аңлаучы хатын-кызлар кайда?» [4, б. 124].

Тәрбиясезлекнең, әхлаксызлыкның төбендә наданлык ятканлыгын мәгърифәтче әдипләребез яхшы аңлаган. Шуңа күрә гыйлемгә, яктылыкка өндәгән әсәрләр иҗат итәргә тырышканнар.

Г. Тукайның 1906 елда «Уклар» журналы битләрендә «Шүрәле» имзасы белән «Татар кызларына» дип язылган шигыре бастырыла. Әлеге шигырь шаян телдә соклану хисе белән язылган. Г. Тукай үзен борчыган әдәплелек, инсафлылык мәсьәләсенә тукталып болай дигән:

«Сөям сезнең әдәп-инсафыңызны,
Егет кулы тиюдән сафыңызны» [1, б. 95]

Кыз баланың кемнән нинди гыйлем алып көн күргәнен, әлеге наданнардан алган гыйлемнең бары тик караңгылыкка гына илткәнен билгеләп түбәндәге фикерен белдерә:

«Яратмыйм бер дә остабикәләрне,
Сези алдарга оста бикәләрне...
Сабак «бабын наданлык»тан аласыз,
Гомер буе надан булып каласыз...
Туып алтын булып, туфрак буласыз,
Мәгарифтән сукыр-чукрак буласыз» [1, б. 96]

Р. Фәхреддин «Адабе тәгълим» исемле укыту кагыйдәләре җыентыгында хезмәтләре саваплы, вазыйфалары авыр һәм мактаулы булган укытучыларның үзләре укыткан һәм тәрбияләгән шәкертләре хакында дөньяда һәм ахирәттә бирәчәк җаваплары да җиңел булмаганлыгын искәртә һәм Г. Тукай фикере белән аваздаш булган сүзләрне язып болай ди: «алтын булачак бер шәкертне туфрак итеп җирдә калдырган укытучы да бар һәм туфрак булачак бер баланы алтын итә белгән укытучы да бар» [2, б. 41]. Беренчеләре, Г. Тукай игътибар үзәгенә куйган «оста бикәләр», икенчеләре, милләтне наданлык авыруыннан дәвалаучы ханымнар. Үрнәк алырлык гыйлем ияләре булган ханымнар турында Р. Фәхреддин «Мәшхүр хатыннар» исемле хезмәтен яза, шулай итеп татар тарихында милләтне үстерүгә үз өлешләрен керткән төрле-төрле файдалы хезмәт ияләренең исемнәрен барлый.

Милләтебезнең киләчәге тәрбияле, гыйлемле хатын-кызларкулында булганлыгын яхшы аңлаган әдипләребез Р. Фәхреддин һәм Г. Тукай халык күңелендә мәңге яши торган хезмәтләр иҗат иткәннәр. Аларны борчыган гаилә иминлеге, милләт язмышы, халыкның киләчәге мәсьәләләре бүгенге көндә дә бик актуаль булып калалар. Тәрбияви әһәмияткә ия булган әсәрләр иҗат иткән әдипләребезнең хезмәтләре әле дә укучыларны шул хакта уйланырга чакыра.


ӘДӘБИЯТ

1. Тукай Г. Әсәрләр. 5 томда. Т. 1. / әзерл. Р. Гайнанов. Казан: Татар. кит. нәшр. 1985. 405 б.
2. Фәхреддин Р. Адабе тәгълим / әзерл. Ә. Хәйри. Казан: Рухи мәгърифәт Академиясе, 2006. 123 б.
3. Фәхреддин Р. Гаилә. Тәрбияле ана. Тәрбияле хатын / әзерл. Ә. Хәйри. Казан: Академия познания, 2006. 168 б.
4. Фәхреддин Р. «Сәлимә, яки Гыйффәт» һәм «Әсма, яки Гамәл вә җәза» / әзерл. Л.И. Хәйдәров. Казан: Меддок, 2007. 150 б.


## ХАЛЫКЧАН ШИГЪРИЯТ


***Даутов Г.Ф.***



Величество творчества Тукая – его народность. Только рассмотрев творчество в целом, можно его понять. Многие факторы влияли на творчества Тукая и в совокупности только можно пройти к определенным выводам. Только эти факторы и единство большого таланта создают феномен Тукая. В творчестве поэта историческое прошлое имеет свое место. Поэзия Тукая до сих пор актуальна. Эта актуальность связана с его народностью. Несмотря на то что его произведения были написаны в начале XX века, они привлекают и сегодняшнего читателя.

The Majesty Tukay creativity – his nationality. Just consider the work as a whole, we can understand it. Many factors influenced the creativity of Tukay and in the aggregate only can go to certain conclusions. Only these factors and the unity of the great talent creates a phenomenon Tukay. In the poet's historical past has its place. Tukay's poetry is still relevant. This urgency related to his nationality. Despite the fact that his works were written in the early twentieth century, they attract today's reader.


Мәкаләне бик тә күп кабатланган һәм бик тә баналь сүзләр белән башламый мөмкин түгел, чөнки ул чыннан да шулай һәм ул хакыйкать – Тукай иҗаты бөек һәм гаять тә күпкырлы. Шуңа күрә һәркем аннан үзенә кирәкне таба, һәр кеше юаныч эзләп аның шигырьләренә мөрәҗәгать итә. Заманалар үзгәреп, чор кыйммәтләре алышынып барса да, кеше күңеле дигән нәрсә һәвакыт сагыш, моң, юксыну, ярату дигән төшенчәләр белән яши, менә шуларны аңлаешлы сүзләр белән шигърияткә әйләндерә алган Тукай иҗаты бер кайчан да кыйммәтен җуймады, шуңа күрә ул бүген дә актуаль һәм шулай

булып калачак та. Хәтта, әдәбиятны бары тик пропаганда чарасы дип кенә караган совет идеологиясе дә шагыйрьне юксыллар мәнфәгатен кайгыртучы итеп күрсәтеп, үз таләпләренә туры килгән җырләрен шомартып, кыскартып, җыентыкларны өзлексез чыгарып килде.

Югары уку йортларында Тукай иҗаты күп санлы курс, диплом, чыгарылыш квалификация эшләре темаларына җирлек булды, шигърияте төрле нокаталардан чыгып өйрәнелде һәм хәзер дә өйрәнелүне дәвам итә. Тукайны гаять тирәнтен өйрәнгән галим Т. Гыйләҗев «Татар әдәбияты XX гасыр башы: Лекцияләр, гамәли дәресләр, тестлар» [3], дигән, югары уку йортлары өчен уку әсбабы буларак чыгарылган бик тә этрафлы һәм җентекләп эшләнгән китабында, шагыйрь иҗатын гамәли дәресләрдә «Г. Тукай – Яңарыш чоры шагыйре», «Г. Тукайның гражданлык лирикасы», «Г. Тукай лирикасында күңел, пейзаж, фәлсәфи лирика» кебек темаларга бүлгәләп карый. Шулай ук «Әдәби мирас: тарих һәм заман» [4] китапларында да. «Галимҗан Ибраһимов эстетикасында Тукай», «XX гасыр башы татар әдәби тәнкыйтендә Габдулла Тукай шигъриятенең тел – өслүб мәсьәләсе» һәм башка төрле мәкаләләре урын алган. Сүз дә юк, мондый бүленеш олы бер дөнья тәшкил иткән иҗатның иң тирән төпкелләренә үтеп керергә, бик күзгә ташланмаган хасият-сыйфатларын күзалларга ярдәм итә. Әйтик, физика фәне дә иң кечкенә кисәкчекләр булган атом, нейтроннар төзелеше аша бөтен галәмнең яшәеш принципларын аңлата. Ләкин, әдәбиятка фән дип түгел, ә җан азыгы дип караган укучының теләк-таләпләрен дә күз угыннан ычкындырмаска иде.

Ул, ягъни укучы, олы биек тауны бик якын килеп караса, аерым фрагментлар гына күрәчәк, картина тулы һәм бөтен гүзәллегендә ачылсын өчен, читкәрәк китеп, аерым бер ераклыктан күз ташлау лазем.

Күренекле галим һәм тәнкыйтьче Тәлгат Галиуллин да: «Озак еллар дәвамында Тукай иҗатын төрле киртәләргә, тар кысаларга куып кертеп, ваклап бетердек. Сәяси һәм иҗтимагый таләпләргә бәйле рәвештә, аннан һәркем үзенә кирәкле юнәлеш эзләде һәм, әлбәттә, тапты. Чөнки аның иҗаты дәрья кебек киң, коедай тирән. Шулай да бу олы мирасны идеологик максатлардан чыгып кына уртак юрган шикелле тарткалау чоры узып бара кебек. Хәзер әдәбият галимнәре, тарихчылар аның иҗатын ике дәвергә – Җаек һәм Казан чорларына гына бүлеп өйрәнү концепциясенә өстенлек бирәләр» [2], – дип яза.

Бөек шагыйрь иҗатын өйрәнүгә бөтен гомерен багышлаган Ибраһим Нуруллин, Тукай шигъриятендәге үзгәрешләрне, аерым мотивларның көчәюен илдә барган сәяси вәзгыятькә, шагыйрьнең сәламәтлек халәтенә бәйләп карауны тәкъдим итә [5].

Гомумән, һәр әдип иҗатын бер бөтен итеп карау әдәбият фәненә ят күренеш түгел. Мәсәлән, Ф. Бәйрәмова, Такташ иҗатын 1923 елга кадәр һәм аннан соң дигән бүленешне, шулай ук кире кагып,аны бер агым итеп ала [1].

Чыннан да, Тукай нинди генә бөек булмасын, ул да кеше... һәм шагыйрь. Кеше буларак сәламәтлекнең яхшыруы-начарамы кәефенә, әлбәттә, тәэсир итмичә кала алмый. Шагыйрь буларак исә, илдәге гаделсезлек, XX йөз башындагы кыргый капитализм шартларындагы (мондый стадияне, ягъни капитализм үсешендә беренчел капитал туплау процесын Россия генә түгел, бүгенге тук Европа илләре дә үткән) социаль тигезсезлек, шулай ук, борчый: Рәсми рәвештә беренче шигыре буларак танылган «Мужик йокысы» (1905) шигырендә үк, ул социаль проблеманы күтәрә. Башлап шунысын искәртик: XX йөз башында зур тизлектә үсеш алган татар әдәбияты өйрәнер өчен һәм Шәрык һәм рус әдәбиятына, шул ук вакытта халык авыз иҗатына да мөрәҗәгать итә. Тукайның шушы беренче шигырендә үк әлеге эзләнүләр чагылыш тапкан: ул аны рус шагыйре А.В.Кольцовның «Что ты спишь, мужичок?» шигыренә ияреп яза. Әмма, әйтик, «Ник йоклыйсың, мужик?» дип мөрәҗәгать итү рус мужигына актуаль булса да, татар игенчесен куалап торуның хаҗәте юк. Моны XIX гасырда яшәгән Казан университеты прфессоры Карл Фукс та (1776–1846) искәртә: «Въ огородахъ у трудолюбивыхъ Татаръ насажено всего въ изобиліи: картофель, лукъ, свекла, морковъ и капуста; всъ эти овощи они запасаютъ на зиму» дип күрсәтә ул һәм чагыштырып та куя: «Судя по образу жизни Русскихъ мужиковъ, подумаете, что этотъ Татаринъ богатъ; это земледелецъ немногим богаче своего сосъеда, но уже онъ не походитъ на крестьянина образомъ своей жизни» [7].

Ләкин эшләп кенә баеп һәм нәрсәгәдер ирешеп була дип яшәү – ул татар менталитетының аерылмас бер сыйфаты һәм сүз алып бара торган шигырьдәге:

Күршеләр бай булды,
Ашлары май булды;
Син, ялкау, йоклагач,
Янчыгың сай булды –

дип юллар, мәгърифәтче әдип Муса Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә алгарышның девизы итеп китерелгән «Эшлә, эшлә, башта җәфа, аннан сафа» дигән әйтемгә аваздаш булып яңгырый.

Ләкин чын бөеклеккә күтәрелер өчен Тукай иҗаты индивидуаль кичереш-хисләр белән сугарылып баерга тиешләр. Һәр вакыйганы йөрәге аша үткәреп, үз күрүенчә белдерүне шагыйрь тиз өйрәнә. Дөресерәге, ул тиз арада теләсә кем ишетә алмый торган халык тавышын, аның күңел авазларын, иң тирәндә яткан һәм бары тик чын шагыйрь булып туганнар гына тоя алучы хисләрне аңлау бөеклегенә күтәрелә:

Күпме михнәт чиккән безнең халык,
Күпме күз яшьләре түгелгән;
Милли хисләр белән ялкынланып,
Сызлып-сызлып чыга күңлемнән.

Шушы дүрт юлга дәүләтчелек югалту ачысы да, улларын егерме биш елга патша хезмәтенә озаткан ата-ананың өзгәләнүе дә, христиан руханиларынң самодурлык белән чикләнүче башбаштаклылыгы да – барысы да-барысы да сыйган. Гасырлар буена дәвам иткән колониаль басымның нәтиҗәсе матди яшәешкә генә түгел, хәтта аңнарга да тәэсир итә:

Пәйгамбәрдән калган дип урнына килгән чегәннәрдән
Үзенә башка бер дин, кайдадыр исламыбыз, һай-һай!
Эзе дә калмаган диннең, басып киткән мәҗүсиләр;
Моны сизгән мөселманга чыдау мөмкинме җан җанмай?

Русия тарихы Тукайның «Сөткә баткан тычкан» шигырендәге тычканы кебек, бер урында әйләнә дә әйләнә. Ләкин шигъри герой шул бер урында әйләнү нәтиҗәсендә сөттән май язып исән калса, Русия һәм татар тарихы аертылган сөт ахрысы, күпме генә болгансалар, тулгансалар да нәтиҗәсе булыр сымак түгел. Инде «Зачем нам бумеранг, если у нас есть свои грабли» дигән афоризм да барлыкка килде, ләкин һаман үзебезгә үзебез ялган юллар билгеләп мәш киләбез. Хаҗга баргач яки башка максат белән гарәп илләренә, Төркиягә чыгып кайтканнарның, пакет белән апельсин, мандарин китереп биргән гарәпләргә «и ул гүзәл кешеләр», «алар шулхәтле миһербанлы», «дин кардәшләребезнең изгелеге» дип авыз суы корытучыларга яки төрекләрнең төче комплементына, гадәти генә традицияләренең дә матурлыгына шаккатучыларга шагыйрьнең «Китмибез!» шигырен укырга киңәш итәр идем:

Китмибез без, безгә мондагыдан эш кыен:
Мондагы ун урынга ул җирдә унбиш шпион.

Кызларының төреккә, гарәпкә, я американлыга кияүгә чыгып, аларның солтан җирендә я океан артында яшәүләре белән горурланучыларга әйтәсе килә: чит ил әфәнделәренә безнең туташларыбызның, беренче чиратта, репродуктив потенциалы кирәк һәм аларның балалары инде татар булмый – ә миңа, мәсәлән, татар булмагач, төрекме, гарәпме, негрмы – ул чуртыма да кирәкми һәм, аңлавымча, Тукай да шул фикердә булган.

Монда тудык, монда үстек, мондадыр безнең әҗәл,
Бәйләмеш бу җиргә безне Тәңремез (гыйззе вә җәл).

Дөнья куабыз, ярышабыз, вак кына мәшәкатьләр иң олы проблемалар булып күренә. Кешедән ким булмыйк дибез, үзебезгә зур нәрсә күреп олы сәясәт хакында сөйләшәбез, күршеләр, коллегалар белән ачуланышабыз, Кеше рәнҗеше төшү турында фәлсәфи әңгәмәләр куертабыз. Ләкин игътибар иткәнем бар: рәнҗеш төшү хакында сөйләшкәндә һәркем үзенеке төшә дип күзаллап сөйли. Һәркем аны үпкәләтүчеләр, кагучылар җәза күрәчәк дип уйлый. Беркем дә, беркайчан да үзен оппоненты урынына куеп карамый. Әмма бит мәңгелек хакыйкатьләр, барыбызга да гомум кагыйдәләр, Бөек көч – Аллаһ бар. Бары ул гына хөкемдар, абсолют хаклык буларак ул мәрхәмәтен барыбызга да тигез бирә. Олы-олы илләр тулы бер тәгълимат тәшкил иткән сәяси системалар да чын хакыйкатьне үзләренә ничек кенә яраклаштырырга тырышмасыннар,

иртәме-соңмы я җимереләләр, я туры һәм дөрес юлга кайталар. Кеше гомере ничек кенә кыска тоелмасын, ул шулай ук, үзе бер дөнья. Дөрес, яшьлектә без бу җиргә мәңгелеккә килгән кебек тоелабыз, ләкин Тукай, 24 яшендә үк, аксакаллар акылына ия булган икән:

Гомернең иң читен, җайсыз, уңайсыз бер минутында,
Әгәр янсам каты хәсрәт вә кайгының мин утында,
Укыйм тиз-тиз күңелдән бер гаҗаиб сүрә Коръәннән, –
Газаплап мәгънәви бер кул илә алынадыр җаннан.
(«Тәэссер», 1908).

Яшәешнең һәр тармагын колачлаган, тормышның төрле катламнарына үтеп кергән Тукай шигърияте әнә шул сыйфатлары белән бөек булса да аерым шәхес, кеше булган Габдулла Тукайныкы гына булудан туктап, бөтен халыкныкы булып әверелә. Халыкчанлык – шагыйрь иҗатын иң югары ноктага күтәргән сыйфат.

ӘДӘБИЯТ

1. Бәйрәмова Ф. Милләтнең бөек улы: фәнни-публицистик язмалар, драма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 144 б.
2. Галиуллин Т. Гасырлы шәхесләр турында.Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. Б. 5.
3. Гыйләҗев Т. Әдәби мирас: тарих һәм заман. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 206 б.
4. Гыйләҗев Т.Ш. Татар әдәбияты. XX гасыр башы: Лекцияләр, гамәли дәресләр, тестлар: Югары уку йортлары өчен уку эсбабы. Казан: Мәгариф, 2007. 239 б.
5. Нуруллин И. XX йөз башы татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982.
6. Нуруллин И. Габдулла Тукай. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979.
7. Фукс К. Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях. Казань, 1844. Репринтное воспроизведение с приложением Предисловия Н.Ф. Катанова к изданию 1914 г. Казань, 1991. С. 37–41.

## ИНТЕРПРЕТАЦИЯ ТАТАРСКОГО ТРАДИЦИОННОГО КОСТЮМА ДЛЯ БАЛЕТА: ОПЫТ ПЕРВЫХ ПОСТАНОВОК

***Донина Л.Н.***

В статье на примере первых постановок балета Ф. Яруллина «Шурале», созданного по одноименному произведению Г. Тукая, анализируются условия и факторы, оказавшие влияние на формирование традиций интерпретации татарского традиционного костюма для национального балета. В балетных спектаклях преимущественно использовались лишь этноспецифические элементы традиционного костюма, при этом неизменно сохранялись главные принципы художественно-образной выразительности всего комплекса.

The article on the example of the first productions of the ballet F. Yarullina “Shurale”, created by the eponymous product G. Tukaya, analyzes the conditions and factors that influenced the formation of the tradition of interpretation of the Tatar traditional costume for the National Ballet. The ballets primarily used only etnospetsificheskie elements of traditional costume, with consistently maintained the basic principles of artistic and imaginative expression of the whole complex.

Татарский традиционный костюм [19] как своеобразный комплекс компонентов, образующих целостный художественный ансамбль, сложился во 2-й половине XVIII – середине XIX в. К сценическим интерпретациям его формы Татарский драматический театр начинает обращаться лишь в середине 1920-х годов. Интерес был не случаен и предопределялся рядом ключевых событий в театральной жизни Казани, оказавших на этот процесс прямое и опосредованное влияние [4, с. 17]. Государственный статус и стационарное положение театра позволили создать театральные цеха, иметь штатного художника, т.е. стало возможным не использовать «типовые декорации» и «городские костюмы» из личного гардероба артистов [13, с. 7], а создавать образное сценографическое решение и драматургические костюмные образы сообразно жанру спектакля. В 1920–30-е годы большое место в каждом национальном искусстве занимали фольклорно-этнографические спектакли. Художники изучали национальные обычаи, обряды, традиционный костюм, давая им новое прочтение в театральном пространстве [9].

Открытие в Казани музыкального театра состоялось лишь в 1939 году. Предполагалось, что он станет центром национальной оперы, балета и музыкальной комедии, пропаганды лучших произведений русской и зарубежной классики. Как пишет Ю.А. Благов:

«…это не было, по сути, созданием некоего нового театра, а скорее стало логическим завершением затянувшегося неофициального существования казанской оперы, воссозданием того оперного театра, который существовал в Казани к этому времени уже шестьдесят пять лет» [3, с. 34].

Первые театральные интерпретации татарского театрального костюма, осуществленные в стенах драматического спектакля, к этому времени уже приобрели устойчивые формы. Поскольку два театра делили одно здание, то постановки драматических и оперных спектаклей ставились параллельно, что нередко позволяло создавать подобные декорации и играть в костюмах «на подборе». Однако балет представляет собой некоторое исключение. Надо сказать, что оформление хореографических произведений стоит обособленно от других видов театрального искусства, оно выработало своего рода каноны жанра [36, с. 56]. Татарский театр начал осваивать опыт русской сцены только в начале 1940-х годов. Для первых балетов декорации создавались с той же долей достоверности и театральной условности, что и к драматическому спектаклю. Посредством объёмно-живописных декораций, прочно утвердившихся на драматической сцене, решалась проблема создания иллюзии места действия с одним определяющим условием: ведущий компонент хореографического спектакля – танец.

Балет Ф. Яруллина «Шурале» по мотивам одноимённой поэмы Г. Тукая стал первым татарским балетом, явившим собой замечательное начало в развитии национального балетного искусства. Его называли татарским вариантом шедевра русской балетной классики «Лебединое озеро». Балет «Шурале» планировался к показу на Декаде татарского искусства и литературы в Москве 1941 года [23, л. 128]. Управлением по делам искусств при СНК ТАССР был утверждён состав постановочной труппы, в Казань из столичных театров были приглашены известные режиссёры В.М. Бебутов, Л.В. Баратов, балетмейстеры Л.В. Якобсон, П.А. Гусев, А.В. Лопухов, художник Б.И. Волков. Творческие и технические цеха также были доукомплектованы специалистами. Сююмбике танцевала Н.В. Балтачеева (Ленинград), ставшая первой создательницей образа *Девушки-птицы*. На роль *Былтыра* приглашён А. Кумысников (Ленинград). Первая постановка была осуществлена при непосредственном участии Фарида Яруллина.

Архивные документы отражают характер процесса подготовки спектакля: были написаны задники и кулисы [24, л. 443], пошиты костюмы [25, л. 60], но оформление полностью закончено не было. Генеральная репетиция прошла с большим успехом, но премьера не состоялась [25, л. 59] – началась Великая Отечественная война.

Весной 1942 года Татарский оперный театр возобновил свою работу в помещении ТГАТ им. Г. Камала. О восстановлении «Шурале», конечно, не могло быть и речи, поскольку состав артистов балета был малочислен [7, с. 124]. Лишь в конце 1943 года подготовительные работы по балету возобновилась, премьера состоялась в 1945 году [37]. Фамилия П.Т. Сперанского в составе постановочной группы и наличие выполненных им эскизов декораций позволяют нам утверждать, что оформление либо переделывалось, либо корректировалось. Костюмы пришли в негодность [32, л. 41], вероятно, их использовали в других постановках, в работе фронтовых бригад или плохо хранили. Можно предположить, что их реставрировали или заменили частично, поскольку представить, что спектакль полностью отшивали заново, учитывая условия данного периода, сложно.

Эскизы костюмов к балету «Шурале» были нами обнаружены в Музее КБДТ им. В.И. Качалова (5 эскизов, ранее принадлежавших дочери художника В.С. Никитина) и ГМИИ РТ (4 эскиза, за авторством В.С. Никитина), в частном собрании Л.Л. Сперанской-Штейн (39 эскизов) [8, с. 289–304]. Подписи художника ни на одном эскизе нет, протоколы утверждения эскизов в архивах нами не обнаружены. На премьерной афише имя художника по костюму не упоминается. На лицевой стороне двух эскизов имеются год (1941) и подпись балетмейстера Л.Якобсона, значит, выполнены они были к первой постановке. То, что серия сохранилась практически полностью, уже само по себе явление редкое, дающее нам уникальную возможность проследить процесс мышления художника, понять принципы работы над эскизами в театре. Более того, эскизы являются первой попыткой интерпретации (скорее, адаптации) татарского костюма для балета. То обстоятельство, что спектакль готовился для показа в Москве, где Татарская республика одной из первых национальных автономных республик должна была достойно представить своё искусство, ставило перед художником определённую

цель: подчеркнуть в сценических костюмах «национальное», «специфическое», «уникальное». Поэтому вполне объясним мотив, почему художник обращает внимание и берёт за основу стилизации архаичные формы традиционного костюма. Однако, такие его особенности, как многослойность, туникообразный крой, тяжеловесные съёмные украшения, тяжёлые ткани, оказались мало приемлемы для балета, поэтому художник в основном использовал лишь элементы костюмного комплекса и принципы его орнаментально-образной структуры.

Анализ эскизов и сопоставление фактов позволяют утверждать, что автором первых эскизов к балету «Шурале» надо признать В.С. Никитина. То, что серия не имеет стилистического единства, также очень характерно для его творческой манеры. Художник опирался, в первую очередь, на музыкально-драматургический материал. Музыка первого акта, построенная в гротесково-классической форме, и темы главных персонажей передаются за счёт рисунка фигур в движениях хара́ктерных танцев. Музыка второго, фольклорного, акта, рисующая татарскую деревню, предопределила акцент на особенностях национальной пластики, на манере ношения костюмов. В финальной сцене «адажио Былтыра и Сююмбике» было поставлено в традиционной манере хореографии XIX века, без какого-либо акцента в сторону национальной пластики» [6, с. 28], поэтому художник поставил фигуры на пальцы. Музыка и особенности танцевальных и хореографических форм, в свою очередь, потребовали дифференцированного подхода в интерпретации костюмов: многослойный, тяжёлый, полихромный костюм со съёмными украшениями нашёл отражение во втором акте. Критики отмечали: «Народные танцы», исполняемые в национальных костюмах, «жанровые и юмористические сцены <…> сверкали <…> и вызывали бурю оваций». Для исполнения классического балета художник максимально освобождает фигуру танцовщика, делая костюм полупрозрачным, белым и невесомым, что было принято неоднозначно: «Если бы в татарской среде, в то время, на глазах у пожилых людей, появилась бы пара в таких костюмах, их бы перебили» [32, л. 153]. Постановщик национальных танцев Гай Тагиров «дорабатывает либретто балета, чтобы максимально приблизить спектакль к тукаевскому произведению <…> Былтыр уже дровосек, а не охотник, как было ранее у Л.В. Якобсона; появляется бревно, лежащее на сцене-поляне, в щель которого попадает лапа лешего». Традиционно в театр привозили костюмы из «Арского уезда, сплошь без талии, как мешок, это исторически правильно», но балетмейстер настоял на изменении их формы. Впечатление от костюмов Тагиров усилил рисунком и пластикой движений, характерных для татар. В рамках подготовки спектакля для сбора татарских танцев и костюмов он побывал в экспедиции по деревням Татарии. Балетмейстер вспоминал: «Я поездил по колхозам и увидал там прекрасные костюмы... потребовали их применить в постановке «Галиябану» с талией, с плечами. Побывав побольше в районах, мы бы привезли больше во все наши спектакли» [17, л. 3]. Также в хореографию были введены сюжеты и музыкальные номера, обыгрывающие элементы татарского костюма: «*Сююмбике*... проявляет интерес к украшениям на одежде свахи (2 акт, 2 картина)», «Танец с катташами», «Танец с покрывалом».

Шигырьнең әдәби сурәтендә үткән, хәзерге, киләчәк аерылып чыга. Тарихи вакыт турысызыклы булып кала, ләкин мәңгелеккә якыная. Кеше гомере вакытлы, кыска, тарихи сузылган, күчемле булуы белән мәңгелеккә урнаша. Шагыйрь кеше яшәешенең катлаулы, зур мәсьәләләре – үткән, хәзерге, киләчәк, яшәү һәм үлем, мәхәббәт һәм иҗат, аларның кеше тормышындагы урыны хакында сөйли. Шәхси һәм гомуми – сүнгән көчләр, яшь айның тулган ай белән алмашынуы, тормыш юлын яктыртырлык елмаю, сулып барган табигать, мәхәббәт һәм үлем ачылыгын аңлау арасында якынлык һәм тәңгәллек урнаша.

Югалтканнар һәм мәңгелек хакындагы лирик уйланулар текстны урын ягыннан оештыру аша да ачыклана. Урын берничә оппозиция хасил итә: Җир / Күк, Югары / Түбән, ачык / ябык, турысызыклы / өзек-өзек, «минеке» / «читнеке».

Геройның ялгызлыгы һәм читләшүе галәми колач ала: ул бөтен дөньяга чит. Дөнья картинасын киңәйтү ике юнәлештә: вертикаль һәм горизонталь буенча бара. Горизонтальдә җир «пространствосы»н барлыкка китерүче детальләр булып корыган агачлар, якыннарның каберләре тора.

Дөнья сурәтенең вертикаль моделен күк, ай, йолдызлар хасил итә. Күз карашы астан өскә, галәмгә бага:

Күз тегеп баксам әгәр дә тормышымның күгенә,
Яшь Һилал урнында – анда тулган айның яктысы [3, б. 196].

Бу чиксез пространствога «дөнья читлеге» метафорасы – тар, чикле пространство каршы куелган. Ул экспрессив һәм гому-миләштерелеп тудырылган, чикләүләрдән торган, кысан, ирексез тормыш символына әверелә:

Очты дөнья читлегеннән тарсынып күндем кошы,
Шат яратса да, җиһанга ят яраткан раббысы [3, б. 196].

Лирик субъект тар пространствоны ташлап чыгарга, югарыга, илаһи киңлеккә омтыла. Тормышта үз урынын, җанына җылы табарга тели. Линеар пространство юнәлешнең билгеләнгән булуыннан килеп чыга. Хәрәкәтнең ахыргы ноктасы булып әни кабере тәкъдим ителә. Урын таба алмауга («һәр ишектән сөрде угылыңны мәхәббәт сакчысы») кабер ташы каршы куела.

Таш – мәдәни һәм дини күзаллау белән бәйле конструктив архитектура элементы. Ул – био- һәм семиосфераны, табигать һәм мәдәниятне, органик һәм органик булмаганны, яшәү һәм үлемне бәйләүче символ. Бу мотивны куллану нәселнең, милләтнең, хатын-кыз белән бәйле «борынгы хәтеренә» мөрәҗәгать төсен ала. Ташлар – телсез, алар сөйләме «өнсез». Дәшмәүләре борынгы заманнарның мифологик асылына тәңгәл килә [2, б. 7].

Кабер ташы иң кадерле хисләрне, иң югары мәдәни кыйммәтләрне кешенең танып белү һәм эзләнүләре максатында типологик актуальләштерә. Ул үзенчәлекле пространствоның үзәгенә, «үзенекенең» тупланмасына, геройны «читнекеннән» сакларга тиеш символик изге нәрсәгә әверелә. Шулай итеп, лирик геройның әхлакый линеар пространствосының әһәмиятле сыйфаты булып «югарылык, бөеклеккә омтылу тора: юл югарыга менү» кебек аңлашыла.

Г. Тукайның «Өзелгән өмид» шигырендә һәм объектив пространство, һәм субъектив кабул ителүче макрокосм бирелеше күзәтелә. Ләкин субъектив пространство киңәя һәм кичерешләр көчәя бара. Гомумән алганда, пространство сызыклары күзәтелүче-объектив, субъектив һәм мифопоэтик пространстволарның гармониясенә нигезләнә, анда хронотопны структур оештыруның һәм горизонталь, һәм вертикаль моделе катнаша.

ӘДӘБИЯТ


1. Бәширов Ф.К. Шагыйрь һәм заман // Тукай XX гасыр рухи мәдәнияте (Тукайның 110 еллыгына багышланган фәнни-конференция материаллары). Казан, 1997. Б. 106–110.
2. Заһидуллина Д.Ф. Татар әдәбияты. Теория. Тарих. / Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов, Т.Ш. Гыйләҗев, Н.М. Йосыпова. Казан: Мәгариф, 2006. 319 б.
3. Тукай Г. Сайланма әсәрләр: шигырьләр һәм поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 271 б.


## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ҺӘМ САЛИХ СӘЙДӘШЕВ МУЗЕЙЛАРЫ МИСАЛЫНДА МУЗЕЙЛАРДА КҮРЕНЕКЛЕ ШӘХЕСЛӘРНЕҢ МИРАСЫН САКЛАУ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ


***Җиһангирова Г.Р.***



Музей является хранителем и интерпретатором материального и нематериального наследия народа. Предметы прошедших поколений хранящиеся в музее являются свидетелями многообразия культур и становятся основой для развития межкультурного диалога. Еще одно направление современной музейной деятельности – это обращенность к Личности. Музеи Габдуллы Тукайа и Салиха Сайдашева в этом плане являются важнейшим звеном общекультурного развития нашего общества. Являясь хранителем наследия выраженного в подлинных мемориах музеи должны в первую очередь презентовать на должном уровне именно свои экспонаты, несущие народную память и формированию гармоничной личности и развитого общества.

The museum is the guardian and interpreter of the tangible and intangible heritage of the nation. Objects past generations kept in the museum bear witness to the diversity of cultures and stanovyatsa basis for the development of intercultural dialogue. Another direction museums activity – it appeals to

the Personality. Museum of Gabdulla Tukays and Salih Saidashevs in this respect are the most important link development of our society. As the guardian of the heritage expressed in authentic memorabilia museum should primarily represent at the proper level it exhibits carrying people's memory and the formation of a harmonious personality and developed society.

Мәдәни мохиттә музей – иң аңлаешлы һәм кызыклы җәмгыять институтларының берсе. Соңгы елларда дөньякүләм иҗтимагый үзгәрү шартларында музейларның үз урынын билгеләүгә юнәлдерелгән тикшеренүләр белән бергә, гомумән, музей эшчәнлегенең максатын аныклау буенча да, шактый тирән һәм күпкырлы эзләнүләр алып барыла. Музейлар – беренче чиратта, мәдәни, тарихи материал, һәм материал булмаган мирасны саклаучы һәм популярлаштыручы оешма буларак билгеле [3, б. 9]. Узган заманнарның ядкарьләрен саклап, музей бер яктан халыкның мәдәни тәңгәллеген, үзенчәлеген, иҗтимагый бердәмлеген саклый. Бу юнәлештәге эшчәнлек – беренче чиратта, халыклар мәдәнияте өчен әһәмиятле. Икенче яктан, музей, үз эшчәнлегендә төрле форма һәм эчтәлектәге мирасны файдаланып, мәдәниятара багланышларга этәргеч һәм нигез була, бер-берсен аңлап һәм хөрмәт итеп яшәүче күп төрле культураларны берләштерүче төзек, яраклашкан җәмгыять формалашуга булышлык итә.

Музей эшчәнлегенең хәзерге заман билгеләгән тагын бер мөһим нигезләмәсе – музейда иң мөһиме – Кеше [3, б. 4]. Бер яктан караганда, бу музейга килүчеләрнең тәлапләрен, теләкләрен тулырак канәгатьләндерү юнәлешендәге чаралар. Бирегә килүчеләргә мөмкин булган барлык уңайлылыкларны тудыру, аларга кулай шартлар булдыру, вакытларын кызыклы һәм файдалы уздыруларын тәэмин итү.

Икенче яктан, бу – әлбәттә, музей тәкъдим иткән тема, тарих һәм вакыйгаларның үзәгендә Кеше булу. Экспозиция һәм күргәзмәләрдә тамашачыларга күрсәтелүче музей экспонатларының «эчке тарихын» нәкъ менә шәхескә мөнәсәбәтле чагылдыру, шәхес язмышы аша кабул итүгә юнәлдерү. Бу яссылыктан караганда, аерым бер халыкның мәдәни үсешенә зур өлеш керткән шәхесләре хакында төзелгән музейларның эшчәнлеге аеруча мөһим.

Татар халкының XX гасыр тарихындагы үзгәрешләр дәверенең сыйфатларын билгеләүче шундый шәхесләре – Габдулла Тукай һәм Салих Сәйдәшев. Аларның тормыштагы иҗтимагый әһәмияте, язмышлары, иҗатлары бер-берсенә бик аваздаш, тәңгәл. Музейлар эшчәнлегендә чагылышлары буенча, бу ике иҗатчы да, әлбәттә, лаеклы урын алган. 1987 нче елда Габдулла Тукайның, 1993 нче елда Сәйдәшнең тормыш юлын, иҗатын чагылдыручы, тулы фомада эшләүче экспозицияләр ачыла. Музей буларак, аларның төп максаты – мирасны саклау һәм шул мирасны халыкка җиткерү. Бу максктка ирешү өчен, гадәти музей эшчәнлегендә файдаланыла торган мөмкинлекләр генә аз. Язучы һәм музыкант, гомумән, иҗат белән шөгыльләнгән шәхсләр хакында, музей мөмкинлекләре белән «сөйләү» – бик катлаулы һәм бәхәсле эш. Бу – материаль булмаган мирасны саклау һәм тәкъдим итүдәге каршылыклы мәсьәләлргә бәйле. Ягъни материал булмаган мирасны: музыка, театр, сөйләм сәнгате булган иҗади әсәләрне ничек тамашачыга тәкъдим итәргә, ничек шушы мизгелдә булган башкару моментын саклап калырга, аны ничек вакыт узу белән тамашачыларга тулырак җиткерергә? Бу сораулар музыка, әдәбият белән бәйле музейларда төрле юллар белән хәл ителә. Бигрәк тә, нәкъ менә, музей экспозициясе, үзе дә иҗади эшчәнлек буларак башкарыла икән, экспозициядә тамашачының шәхси хисләре, тәэсирләре белән музей чаралары уртак яссылыкта тәңгәлләшә ала икән, бу очракта иҗади шәхесләрнең тормышын ачып бирүдә, аларның язмышын тарихи, мәдәни, иҗтимагый җирлектә чагылдыруда бик көчле һәм кызыклы мөмкинлекләр ача.

Соңгысы, мөгаен, Сәйдәш музее экспозициясендә аеруча ачык күренә. Беренчедән, бу экспозициянең сәнгати бизәлеше гадәти булмаган рәвештә хәл ителгән [2, б. 4]. Сәйдәш тормышы һәм иҗаты нинди дә булса бер әһмиятле вакыт аралыгы яисә бер мөһим вакыйганы аерып алып, шулар аша бөтен тулы шәхес, образ буларак тәкъдим ителә. Шулай ук, музей экспонатлары, үзләренең төп күренеш-рәвешләреннән тыш, өстәмә символик мәгънә дә алалар. Мәсәлән, Сәйдәшнең үсмер чорын чагылдырган темада тәлинкәле бизмән киләчәккә юл сайлауның тотырыксыз, катлаулы, күпкырлы чор булуын күрсәтүче символга әверелә. Сәйдәш яшәгән бүлмәдәге төп нөсхә булмаган предметларның барысын да бер төскә буяу, бу мемориаль урынның ак төскә хас булган символик мәгънәләрен, шушы бүлмәнең әһәмияти эчтәлеген тирәнрәк ачуга китерә. Шула ук бу музейны ачу вакытында экспоиция белән бергә уйланылган һәм бик уңышлы тормышка

ашырылган аудиогид системасын да телгә алырга кирәк. Экспзициянең герой иҗатын чагылдыруын тирәнәйтеп композиторның әсәрләрен музей экспонаты буларак тәкъдим итү әлбәттә,бик отышлы һәм кызыклы тәҗрибә була. Үз дәверендә күрелмәгән бу үзенчәлекле һәм гадәти булмаган сәнгати-экспозицион чишелешнең музей белән танышучылар тарафыннан бертөрле генә кабул ителмәвен дә әйтеп үтәргә кирәк.

Тукай музее экспозициясе күбесенчә һәрвакыт файдаланылган, күнегелгән формада, тормышчан күренешләр, образлар нигезендә эшләнгән. Шулай да берничә урында төп бизәлеш системасыннан читкә китү күренә. Мәсәлән, экспозициядә Тукай сәяхәтләренең образы буларак, пароход штурвалы, чакырым баганасын күрәбез. Боларны һаман да шул иҗади теманы чагылдыруның шактый катлаулы булуы белән аңлатырга мөмкин.

Музейның нигезе булып торган Тукай һәм Сәйдәшнең мемориаль әйберләрен тәкъдим итүдәге аеруча мөһим мәсьәлә – төп нөсхә шәхси әйберләрнең бик аз булуы. Бу – бик аяныч хәл, бер яктан, ул заманның иҗтимагый шартларында бу шәхесләрнең яшәү рәвеше, аларның шәхси сыйфатлары белән бәйле булса, икенче яктан, бу – мирасыбызга булган мөнәсәбәтнең дә бер чагылышы. Белүебезчә, музейда Салих Сәйдәшевнең дистәгә якын мемориаль әйбере теркәлгән. Нигездә, бу музейга 1956 елда композиторның хатыны Асия Сәйдәшева тапшырган документлар һәм предметлар (1956 елның 27 марты, Акт № 667). Шулай ук, музей документларында Сәйдәшнең берничә кульязмасын композитор Җәүдәт Фәйзинең тапшыруы да теркәлгән (1958 елның 11 марты, Акт № 765) [1.14]. 1991 елда скульптор Садри Ахуновның тол хатыны музейга Салих Сәйдәшевның үлгәннән соң алынган битлеген тапшыра. Гомумән алганда, кыйммәтле һәм тарихи мәдәни әһәмитяткә ия материаллар берәмтекләп, озаклап тупланып килгән. Бу эзләнүләр 1990 нчы елларда, музей экспозициясен төзүгә мөнәсәбәтле бер күтәрелеш чорын кичерә. Музейның фәнни хезмәткәрләренең тынгысыз һәм максатчан эшчәнлеге нәтиҗәсендә Сәйдәшнең төрле музыкаль әсәрләренең нота текстлары, фотографияләр, афишалар туплана һәм алар күбесе экспозициядә урын ала.

Шуны да әйтеп узарга кирәк, Салих Сәйдәшев музеенда Габдулла Тукай хакында да материаллар урнаштырылган. Тукайның 1908 нче елда И.Н. Харитонов басмаханәсендә чыкан «Ювату» (ин. № НМРТ В-19273/140), «Алтын әтәч» (ин. № НМРТ В-19273/135), 1910 елда басылган «Печән базары яхуд кисекбаш» (ин. № НМРТ В-19273/132) һәм «Бала күңле» (ин. № НМРТ В-19273/133а) китаплары күчермәләре, Тукайның Клячкин шифаханәсендә (ин. № НМРТ В-19273/141) һәм җеназасында (ин. № НМРТ В-19273/142) алынган фото күчермәләре, булачак композиторның үсмер чорларындагы әһәмиятле вакыйга һәм тәэсирләрне чагылдыручы материаллар буларак күрсәтелә. Билгеле инде, шагыйрьнең төп нөсхә мемориаль әйберләрен Тукай музее экспозициясендә күрергә мөмкин. Күптән түгел Милли музейда саклнучы Габдулла Тукайның шәхси предметларының каталогы басылып чыгуы һәм Салих Сәйдәшев белән бәйле экспонатларның да тулы мәгълүматлы исемлеге әзерләнүнен әйтеп узу кирәк.

Музей эшчәнлегенең төп юнәлеше булган тагын бер бик мөһим мәсьәләгә тукталасы килә. Хәзерге көнгә кадәр сакланган бу мемориаль экспонатларны тәкъдим итүдә бик игътибарлы һәм таләпчән булырга кирәк. Инде искә төшереп узганча, музейларның экспозицияләре берничә дистә ел элек эшләнгән һәм, әлбәттә, вакыт узу белән, алардагы бизәлеш, материалларны тамашачыларга тәкъдим итү чаралары, кайбер мәгълүмати фактлар үзгәртүне, яңартуны өстәмәләр кертүне таләп итә. Нәкъ менә шушы бурычларны үтәү максатыннан, музейларда реэкспозиция уздыру планнары күздә тотыла. Музейлар өчен бик җаваплы һәм каталулы булган бу эшләрне башкарганда, инде телгә алынган төп нөсхә шәхси әйберләрне күрсәтү принципларын аныклап, шуларга төгәл нигезләнеп эш йөртү кирәк. Ул төп нигезләмәләрнең берсе – музейдагы төп нөсхә әйберләрнең экспозициядә тоткан урыны. Мемориаль әйберләр экспозицянең ачык бер маяклары, төп таяну ноктасы буларак игътибарны җәлеп итүче билгеләр булырга тиеш. Бу, инде күрсәтелеп киткән милли мирасның тиешле дәрәҗәдә саклану һәм тәкъдим ителүе белән беррәттән, түбәндәге гаять мөһим мәсьәләне хәл итүгә дә юнәлдерелергә тиеш. Музейда куелган табигый матди предметлар, кешеләрнең шәхси әйберләре белән белән якыннан танышу, алар белән «күзгә-күз аралашу» бүгенге көн вертуаль дөньяга күчеп баручы яшәү һәм аралашу шартларында бик кыйммәтле һәм әһәмиятле тәҗрибә булып тора. Бу бигрәк тә, тәрбия һәм уку-укыту җирлегендә, балаларның рухи үсешен киңәйтү, тирәнәйтүдә мөһим бер корал, файдалы һәм нәтиҗәле чара була ала.

Гомумән алганда, нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин, Габдулла Тукай, Салих Сәйдәшев кебек шәхесләребезнең исемнәрен буыннарга тапшыру, шуның белән халкыбызның мәдәни һәм милли үзбилгеләнүен саклау бурычын үтәүдә музейлар эшчәнлеге әһәмиятле урын алып тора. Бу юнәлештә башкарылган эшләр нигезендә яңа мөмкинлекләр – инновацион технологияләр, сәнгати бизәлеш элементларын файдаланып, мирасыбызны тиешле дәрәҗәдә отышлы һәм кызыклы формада тамашачыга тәкъдим итү чараларын табу, булган мәгълүматны аңлаешлы, үтемле, истә калырлык белем булырлык итеп тәкъдим итү кирәк.

ӘДӘБИЯТ

1. Валеева Л.Г. Мемориальные вещи выдающегося татарского композитора С.З. Сайдашева в музее. Государственный музей ТАССР. Казань, 1958.
2. Приложение к паспорту музея С. Сайдашева / составитель Г.Г. Нурутдинова. Казань, 1997.
3. Социальная и образовательная роль музеев в продвижении принципов Конвенции ЮНЕСКО об охране нематериального культурного наследия (2003 г.): Аналитическая записка / автор-составитель: Алла Сташкевич (ИКОМ Беларуси).

## XX ЙӨЗ БАШЫ «СӨЕМБИКӘ»ЖУРНАЛЫНДА ТУКАЙ

***Җиһаншина С.М.***

В статье исследуется отражение темы Тукая на страницах журнала для женщин «Сөембикә», издававшегося в Казани с 1913 по 1918 гг. Кроме литературных произведений самого Габдуллы Тукая на страницах издания регулярно печатались воспоминания о классике татарской литературы, рецензии на его произведения, а также материалы, посвященные отражению женской тематики в в творчестве поэта.

The article investigates the reflection of the theme of Tukay in the magazine for women "Sөembikә" published in Kazan from 1913 to 1918. In addition to the literary works ofGabdulla Tukay on the pages of the magazine regularly published memories of classic Tatar literature, reviews of his works, as well as materials on the reflection of women's issues in the work of the poet.

«Сөембикә» журналының тарихына күз салсак, 1913 елның 27 октябрендә Казан шәһәрендә журналның беренче саны басыла. Журнал 1918 елга кадәр чыгарыла, һәм аның 91 саны дөнья күрә. Мөхәррире Якуб Халили (Якуб Ибраһим улы Халиуллин) 1877 елның 10 декабрендә Вятка губернясы Иж-Бубый (хәзерге Тат. Респ., Әгерҗе районында) авылында туа. Авыл мәдрәсәсендә укый. 1913–1918 елларда «Сөембикә»-нең төп нәшире, 1917 елдан «Балалар дөньясы» журналының редакторы була. Бер үк вакытта «Гыйльме ысул», «Хисап мәсьәләсе», «Ысулы хисап» һәм башка дәреслекләр яза. «Сөембикә» ябылгач, Якуб Халили төрле оешмаларда эшли, Буа шәһәрендә китап мөхәррире була, Казанда китапханәче. 1937 елда кулга алына, 1938 елның 15 гыйнварында атып үтерергә хөкем ителә.

1913 елда чыга башлаган «Сөембикә» журналы – татар халкы тарихында хатын-кызлар өчен беренче журнал. Хатын-кызлар өчен татар телендә журнал чыгару бик зур казаныш була. Журнал битләрендә – бала тәрбиясе, мәгариф, музыка, кул эшләре, гигиена, һәм медицина, аш-су, йорт эшләре карау кебек үтә дә зарур материалларга юлыгасың. Басмада хатын-кыз яшәешенең барлык тармаклары – иҗтимагый, сәяси, гаилә хәлләрен яктырта. 20 йөз башы – татар милләтенен «уяну чоры» була һәм «Сөембикә» дә үзәккә мәгърифәтле милләт аналарын әзерләү мәсәләсен куя.

Татар халкының улы булган Габдулла Тукай хакында истәлекләр, аның шигырьләре «Сөембикә»дә еш урын ала. Әйтик, 1914 елда чыккан журналның 7 нче санында аның «Пәйгамбәр» шигыре басыла [1, б. 1]. Шул елны Вакыйф Җәләл «Тукай кабере янында» дигән шигырендә Тукайга карата үзенең җылы хисләрен белдерә. Шәһит Әхмәдиев «Шагыйребез Г. Тукаевның хатын-кызларга карашы» мәкаләсендә шагыйрьнең хатын-кызларга багышланган шигырьләренә анализ ясый:

«...Туташларыбызның бу хәлдә аптырап торуларына Тукай мәрхүм алдында татлы чишмә агып торганда, сусап, шуны эчми тору белән тиңләштерә һәм:

«Күз алдында аксын татлы чишмә синең,
Эчми торчы, сусап, шуны күреп торып», – ди.

Ул бездәге әллә кайчаннан, «хан заманасыннан» бирле калган начар гадәт булган кызларны карт ирләргә көчләп бирү турында да баш вата. Ул турыда туташларның берсенең үз-үзеннән:

«Шул зинданда газап чиктем, унсигезгә
Хатын булдым зур корсаклы бер симезгә.
Мәгълүм инде, аңлый бар да, түгел сөеп!
“егъларга дәшмәү риза”га буйсынып», – ди.

Һәм шундый ирләрнең күбесенең әллә ничәшәр хатыны булуны да сөйләп, шул хатыннарның үзара, ире белән булган тормышын тасвир итеп:

«Өч хатынлы иде ул, мин дүртенче,
Җыелыштык бер тар йортка без дүрт көндәш», –

ди. Шулай ук шундый ирләрнең күбесенең кабәхәт әхлаклы булуы белән барыбер хатыннары белән килгән мөгамәләләрен искә төшереп:

«Кич булгачтын үзе тагын эчеп кайта,
Авызы-борыны сасып, өс-баш тончып кайта.
Бик зур хуҗа кайткан, имеш, әйдә йөгер,
Дүртәүләшеп, дүрт ат төсле «дөбер-дөбер!»
Исерек, ләкин сөя үзе сагынганны,
Куштанлыкны, һаман үзенчә булганны.
Җитми аңар рафикларча мөгамәллә,
Синнән сәҗдә тели, сөя табынганны.
Яткызмакчы булсаң кулыңнан ычкына,
Тәмсез сүзләр сөйли, сүгенә, кычкыра», –

ди. Һәм дүрт хатын аларга шәригатьтә хөкем табуында, аларның шәригать кушканча ризалыкта тотып, барчасын да тигез күрә алмавын сөйләп!...» [2, б. 5–7].

Чыгатайның «Габдулла Гариф улы Тукаев» дигән язмасында Габдулла Тукайның тормышы, иҗат юлы яктыртыла. Аның инде 10 яшендә русча укырга өйрәнүен, зиһенле бала булуын әйтеп үтә автор. «*Безнең ошбу сагынмагыбыз «Сөембикә» булганлыктан, без мөмкин кадәр бу шагырьнең әхвәленә хатыннарның нинди катнашы барлыгын телгә алмакчы булабыз. Даһи бер хәлне яд итмәк кирәктер ки, Габдулланың сабак башлавы бер абыстайда булган. Абыстай, гәрчә борынгыча укытучы булган булса да, аның хисе вә рухында булган итагать вә сизгерлеге Габдулланың рухына тәэсир итмештер. Хәтта шагыйрьлекнең иң элекке авырлыгы Габдулланың күңеленә шул абыстайның уенда утыртылмыштыр; Габдулланың алдында абыстай кызларга көйләп сабак бирмәгәндер диярсезмени? Минемчә моңлы вә ятим вә ләкин ...рухлы Габ...ң алдында вә аның колагы төбендә абыстай матур көе белән балаларга сабак биргән*». Ятим Габдулланың иҗатына этәргеч биргән хатын-кызларны мәкаләсендә күрсәтеп үтә ул [3, б. 10–15].

*«Хатыннар турында Тукай»:*

*«Габдулла Тукай чын милли татар шагыйре иде. Ул милләтнең нинди генә күңелсез яклары булса да, һәммәсе өчен ах орды, көйде, сызланды.*

*Үзенең ачы хәсрәтләрен матур тезелгән җиңел гыйбарәле шигырьләре белән җырлады. Аның җырлавында күз яшьләрен дә татар халкы бик тиз аңлады.Бу урында аның шагырьлеге, татар әдәбиятенә китергән хезмәтләре тикшерелмичә вә саналмыйча, тик татар хатыннарының хәлләренә карашы хакында берничә сүз әйтеп китмәкче булам.Ул иң түбәнге, иң фәкыйр, иң караңгы авыл эчендә туа, үсә, тәрбияләнә. Ул баладан ук татар хатыннарының хәлләрен бик яхшы аңлап, күреп тора»* – бу язмада автор Габдулла Тукайның хатын-кызларга азатлыгы мәсьәләсенә карашы турында яза [4, б. 16–18].

«Бохарада Тукай кичәсе» [5, б. 13–14]: *«2 апрельдә мәшһүр Габдулла Тукай үлүенә 2 ел тулды. Шул уңай белән Бохарада Тукайны искә алу кичәсе үткәрелә. Узып барышлый туры килеп, Камил Мотыгый да бу кичәдә катнаша, Тукай турында сөйли. Бохарада укучы татар шәкертләре Тукайга багышланган, Тукай үзе иҗат иткән шигырьләр, җырлар әйтәләр»* – дип хәбәр итә 4 сыйныф талибәсе Фатыйма Муллаянова.

Җамалетдин Юмалаев «Яшерен мәхәббәт» язмасында Габдулла Тукайның яшерен мәхәббәт белән илһамланып та, газапланып та яшвен сурәтләгән хикәясе белән журналды чыгыш ясый [6, б. 5–9]. Габдулла Тукайга багышлап чыгарылган махсус санда, моннан бер гасыр элек Якуб Халили да «Габдулла Тукаев өчен» язмасында

бөек шагыйребезне: *«Аның авыр сулап яткан вакытлары, җан бирүе, үлүе, әллә ничә меңнәрчә кешеләр белән Казан урамына сыеша алмыйча җеназасын озаткан минутлар күз алдына килә... Габдулла Тукай исемен ни өчен һәркем белә? Ни өчен Тукай исеме чыгу белән һәркем аны ихтирам итә?* – дип яза автор. Һәм ул сорауларга җавап итеп. *– Ул сөйләгән сүзләрен халык өчен сөйләде, җырлаган җырларын халык өчен җырлады, көйләгән көйләрен халык өчен көйләде. Аның сүзе, җыры, көе халыкныкы иде. Ул халык өчен туды. Халык өчен яшәде.Аллаһ биргән таланты белән халыкка карап, төрлечә, бәгъзе бик шатлыклы, бәгъзе бик кайгылы җырлар җырлады»* [7, б. 2–4]. Шул ук санда язучы Садри Җәләл дә «Аның сөекле углы» язмасы белән чыгыш ясый. «Сөембикә»дә даими автор М. Әбрар Сәгъди «Мәрхүм шагыйребез» шигырен Г. Тукай вафатына 3 ел тулу уңаеннан яза [8, б. 8].

Күргәнегезчә, Габдулла Тукай, моннан бер гасыр элек тә укучыны уйландырган, вакытлы матбугатта аның иҗаты, аңа ихтирам ачык чагыла. Менә «...гә» дигән шигырен Куки тәхәллүсле автор Г. Тукайның «Эштән чыгарылган татар кызына» исемле шигыренә ошатып, шуның белән аваздаш итеп язган [9, б. 7–8].

*«Сөембикә» журналы бер гасыр эчендә гел үзгәрешләр кичергән: бизәлеше, битләренең саны, кәгазенең сыйфаты яхшырганнан яхшыра, сәхифәләре, аларны алып баручы журналистлар, авторлары алышынган.... Тик бер нәрсә үзгәрешсез калган: ул – журналның үз укучысына мөнәсәбәте*. Кайсы гына санын алып укысак та, «Сөембикә» журналының нәкъ бер гасыр элекке басмаларында да кешелекнең иң актуаль проблемалары, аны чишү юллары, әдәбият, мәдәният-сәнгать, тарихи сәхифәләр дөнья күргән. Журналда басылган язмаларны укучылар бик кызыксынып укып барган, алай гына да түгел, еш кына язмаларга кайтаваз рәвешендә үз фикерләрен дә җиткергәннәр. Шулай ук журналда татар халкының башка күренекле шәхесләренә, әйтик, Шиһабетдин Мәрҗани, Исмәгыйль Гаспринскийларга багышланган махсус саннарның дөнья күрүе – милләтебезнең асыл шәхесләре белән халыкны таныштыру, аларның бәяләп бетергесез иҗатларын, хезмәтләрен укучыга җиткерүне «Сөембикә» үзенең бурычы итеп куйган.

ӘДӘБИЯТ


1. Тукай Г. Пәйгамбәр // Сөембикә. 1914. № 7. Б. 1.
2. Әхмәдиев Шәһит. Шагыйребез Г. Тукаевның хатын-кызларга карашы // Сөембикә. 1914. № 11. Б. 5–7.
3. Чыгатай. Г. Гариф углы Тукаев // Сөембикә. 1914. № 11. Б. 10–15.
4. Гадел Л. Хатыннар турында Тукай // Сөембикә. 1914. № 11. Б. 16–18.
5. Муллаева Фатыйма. Бохарада Тукай кичәсе // Сөембикә. 1914. № 13. Б. 13–14.
6. Юмаев Җамалетдин. Яшерен мәхәббәт // Сөембикә. 1914. № 16. Б. 5–9.
7. Хәлили Якуб. Габдулла Тукаев өчен // Сөембикә. 1914. № 11. Б. 2–4.
8. Сәгъди М. Әбрар. Мәрхүм шагыйребез // Сөембикә. 1916. № 11. Б. 8.
9. «Куки» .... гә // Сөембикә. 1916. № 10. Б. 7–8.


## ХӘЗЕРГЕ ДРАМАТУРГИЯДӘ ТУКАЙ ОБРАЗЫ
## (Р. Зәйдулланың «Шул булды эш» драмасы мисалында)


***Закирҗанов Ә.М.***



В статье, на основе анализа драмы Р. Зайдуллы «Вот так случилось», раскрывается образ татарского поэта Г. Тукая. Драматург раскрывает окружение Тукая, определяет факторы, которые оказали сильное влияние на поэта. Основное внимание уделено выявлению художественных приемов и их функций в раскрытии как образа Тукая, так и основной идеи произведения.

The article analyzes R. Zaidulla`s drama «It happened so». It reveals the image of tatar poet G. Tukay. The author describes Tukay`s surrounding, defines factors which influenced greatly on the poet. The dramatist pays attention to artistic methods and their functions in opening Tukay`s image and the main idea of the work.


Татар халкының күпгасырлык тарихында, язмышында аерым шәхесләр үзгә урын алып тора. Шуңа да халык авыз иҗатында һәм әдәби әсәрләрдә татарның данлы һәм фаҗигале тарихы, анда шәхеснең урыны мәсьәләләре киң чагылыш таба. Аларда без эзлекле рәвештә я Шәрык дөньясында танылу алган баһадирларны, ил башлыкларын, я дин әһелләрен, соңрак исә самодержавие белән көрәшкә чыккан батырларны

күрәбез. XX йөз башында милләт буларак формалашкан, үз хокукларын яклау юлына чыккан халык өчен милли идея Яңарышның әйдәүче көченә әйләнә. Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы дәүләтләре, аларда яшәгән, халык тормышына зур йогынты ясаган шәхесләр турында күпсанлы әдәбият-сәнгать әсәрләре дөнья күрә. Милли азатлык идеясе әдәбиятыбыз «кыйбласы»на әверелә. Й. Нигъмәтуллина билгеләп үткәнчә, «идеяләр романтизмы» сүз сәнгатендә төп мотивларның берсе була [4, с. 110–111]. Совет чорында милли идеянең турыдан-туры чагылышына юл калдырылмый, билгеле. Киресенчә, милли үзенчәлек-үзгәлек мәсьәләләре чагылыш тапкан әсәрләрне тиз арада «зыянлы» дип табып, авторларын эзәрлекләү башлана. Бу дәвердә әдипләр фикер-карашларын «эзоп теле» белән, ягъни текстның икенче катламына яшереп әйтергә мәҗбүр була. 1980 елларның икенче яртысыннан милли азатлык идеясе зур көч белән алга чыга. Татарның үткәне, бөек шәхесләре белән кызыксыну бик нык арта, күпсанлы тарихи эчтәлекле әсәрләр языла. Татар җанлы һәркемнең телендә булган Аттилла, Кубрат хан, Алмыш хан, Кол Гали, Идегәй, Алтын Урда ханнары, Сөембикә, Колшәриф, Мөхәммәдъяр, Батырша, Сәет батыр һ.б. танылган шәхесләрнең әдәби образы тудырыла. Алар белән янәшәдә татар әдәбияты һәм сәнгате үсешенә зур өлеш керткән, милләт горурлыгына әйләнгән Г. Тукай, Г. Исхакый, Һ. Такташ, М. Җәлил, С. Сәйдәшев, Н. Җиһанов, Х. Туфан һ.б. образлары матур әдәбият битләрендә урын ала.

Алар арасында Г. Тукай үзгә урын били. Ул үз дәверенең уникаль күренеше буларак мәйданга чыга һәм иҗатында халыкның «моңлы көен» җырлаучы, аның рухи ихтыяҗларына җавап бирүче «үз улы» булып танылa. Үз вакытында ук халык шагыйре булып бәяләнгән Тукай XX гасыр дәвамында татарның бөек әдибе булып кала. Аның исеме, иҗаты, билгеле бер шартлы төсмер алып, татар милләте, аның идеалы рәвешендә бәяләнә башлый. Шуңа да Тукайның тормышы, шәхесе, иҗаты һәрвакыт әдәбият-сәнгать әһелләренең күз уңында булып, күпсанлы әдәби әсәрләр иҗат итүгә китерә.

Тукай образына татар драматурглары да еш мөрәҗәгать итә. Аның беренче үрнәкләре XX гасырның 30 нчы елларында пәйда булса, алдагы елларда дистәгә якын пьеса дөнья күрә [2, с. 143]. Алар арасында Илдар Юзеевның «Очты дөнья читлегеннән», Риза Ишморатның «И мөкатдәс моңлы сазым», Туфан Миңнуллинның «Без китәбез, сез каласыз», Рабит Батулланың «Сират күпере», Әхәт Гаффар «Соңгы сәгать» исемле пьесалары аеруча киң яңгыраш алып, җәмәгатьчелек тарафыннан югары бәяләнә. Әлеге пьесалар, билгеле инде, бертөрле генә түгел. Әгәр И. Юзеев шагыйрьне үз чоры улы буларак романтик сурәтлелек аша тасвирласа, Т. Миңнуллин исә Тукайның Идел буенча сәяхәтен, аның фабрикант Акчуриннарда кунак булуын үзәк вакыйга итеп ала һәм тормышка капма-каршы позициядә торган шәхесләр көрәше буларак ача. Ә. Гаффар драмасында Тукай фәлсәфи планда, яшәү мәгънәсен, иҗат асылын аңларга омтылучы, шулар аша халык тормышына якынаючы шагыйрь буларак бирелә.

Р. Зәйдулла «Шул булды эш...» драмасында Тукай шәхесенә, иҗатына XXI гасыр биеклегеннән күз ташлый, «Тукай феномены»н аңлау омтылышы белән бергә, Тукайның эш-гамәлләре аша бүгенгебезгә, заманга бәя бирә. Драматург үз алдына авыр бурыч куя: Тукай турында моңа кадәр язылганнарны кабатламыйча, олы шагыйрьне үз даирәсендә, дус-дошманы арасында сурәтләп, шәхесен бөтен каршылыгында ачу һәм иҗатын эш-гамәлләре, уй-фикерләре, теләк-омтылышлары чагылышы буларак бәяләү.

Композицион яктан әсәрдәге вакыйгалар «Әл-ислах» редакциясендә, «Шәрык» клубында, Зәйтүнәләр өендә, «Болгар» номерларында бара. Мондый төзелеш-структура Тукайны, беренче чиратта, ачык пространствода, ягъни чор-заман мохитендә күзәтергә һәм икенче яктан, шәхси тормышы, хис-кичерешләренә бәйле сурәтләргә җирлек бирә. Драма конфликты да ике яссылыкта бара: берсе – Тукай белән ул яшәгән җәмгыятьтә хөкем сөргән карашлар арасында. Вакыйгалар барышында ул бүгенгебез белән аваздашлык ала, аерым күренешләрдә XX гасыр башы белән XXI гасыр башы татар тормышы кушылып та китә һәм Тукай шәхесе, аның иҗаты милли асылыбызны юк итүчеләр белән көрәшүче төсмерен ала. Икенчесе – Тукайның эчке каршылыгы булып, мәхәббәт хисе белән янучы шагыйрьнең төрле сәбәпләр аркасында тәкъдиренә буйсынырга мәҗбүр булуында ачыла.

Драмада Тукайны шәхес буларак аңларга омтылу алгы планга чыккан. Моңа кадәр Тукай турында иҗат итүчеләрдән аермалы буларак, Р. Зәйдулла шагыйрьне, күпсанлы истәлек-хатирәләрдә урын алганча, гади-гадәти, көндәлек борчу-мәшәкатьләр белән яшәүче, шул ук вакытта, олы йөрәге, «пәйгамбәрлек» сыйфаты белән аерылып торучы

кеше итеп ача. Р. Игъламов язганча, «аның драматургиясендә, дөресрәге, бөтен иҗатында, хәлиткеч катлаулы дәверләрдә шәхеснең тарихтагы роле беренче планга чыга» [4, с. 6]. Җаена, кәеф-халәтенә карап урам малайлары белән кузна уйнарга да әзер Тукай әсәрдә сөю утында янучы «мәҗнүн» булып ачыла. Тукайның хатын-кызлар белән мөнәсәбәте турында фактик мәгълүматлар аз булып, әлегәчә бәхәсләр уята. Әмма әдип ярату хисеннән һич тә мәхрүм түгел. Аның мәхәббәт турындагы шигырьләре сөю хисенең төс-төсмерләре байлыгы, лирик герой кичерешләренең тирәнлеге, әлеге гаҗәеп хиснең шагыйрьгә никадәр көч, илһам бирүе чагылышы белән бу жанрга караган иң яхшы әсәрләрдән санала ала. Шуңа да Тукайның Зәйтүнәгә булган хисләре романтик төсмерләрдә, шәрык әдәбиятында киң урын алган «җан мәхәббәте» – әфләтүн мәхәббәте концепциясендә ачыла. Р. Зәйдулла сурәтләвендә аларга бер-берсенә гашыйк булырга күз карашлары очрашу да җитә. Әсәр герое Вафа әйткәнчә, «куллары кулга кагылып киткәндә очкыннар чәчри». Әлеге очкыннардан аларның йөрәкләрендә сөю уты кабына: «И минем яктыртучым! Тик син миңа һәр җирдә шәм; / Нәрсә ул дөнья кояшы! Син миңа нур бирмәсәң»! Үзенчәлек шунда, алар өчен рухи бергәлек мөһим. Тукай, бер яктан, сәламәтлегенең начар булуын, гомер кояшының сүнүгә таба баруын, икенче яктан, шагыйрь буларак омтылышлары, янып яшәве белән гаилә корып, балалар үстерергә әзер түгеллеген яхшы аңлый. Әйе, язмыштан узмыш юк. Әмма ул яратырга һәм үзен дә яраттырырга тели. Әлеге саф хисләренең Зәйтүнәдә теләктәшлек табуы, Тукайга шатлык, вакытлы гына булса да бәхет китерә, иҗат дәрте уята, яшәүгә көч бирә.

Зәйтүнә – XX йөз башы Яңарышы мәйданга чыгарган кызларның берсе. Ул, үзенең татар кызларына хас мөлаемлыгын, әдәп-әхлагын саклаган хәлдә, шәхес иреген, хатын-кыз эмансипациясен яклаучы булып ачыла. Тукай аңа үзенең рухи көче, шәхси сыйфатлары белән якын һәм кадерле. Шагыйрьне ул бөтен барлыгы белән аңлый, аңа омтыла, аның белән булганда, аны тыңлаганда җанына рәхәтлек, тынычлык таба.

Автор Тукайны һич тә идеаллаштыру юлыннан китми. Шуңа да әдипнең Мария Карловна белән бәйләнеш-мөнәсәбәте дә урын ала. Әлеге күренеш Тукай иҗатының башка халыклар тарафыннан кабул ителү-ителмәвен аңлау ягыннан да гыйбрәтле. Немец хатыны Тукайның талантлы шагыйрь булуын таный. Әмма аның өчен цивилизация үрнәге булып Европа илләре тора. Шуңа да татарларны кыргыйлар, мәдәни яктан артта калганнар дип саный. Тукайның самимилеге, саф күңеле, уйларының чисталыгы аларны якынайта.

Р. Зәйдулла Тукай шигъриятенең серләрен ачуга да үзгә юл белән килә. «Шагыйрь үзе шигырьләрендә яши» дигән гыйбарә бар. Автор Тукай иҗатын бөтен тулылыгында ачуны һич тә максат итми. Шәхси тормышына бәйле вакыйгаларда әдипнең мәхәббәт лирикасы көчле яңгыраш ала. Алар текстта шактый булып, Тукай кичерешләрен, уй-фикерләрен тулырак аңларга ярдәм итә, лирик җылылык, эмоциональ тәэсирлелек тудыра. Тукайның шәхси тормышы әдәби иҗатыннан, иҗтимагый эшчәнлегеннән аерылгысыз. Ул халык язмышын кайгыртып, аның бүгенгесенә һәм киләчәгенә борчылып яши, аны бердәм, дус-тату, мәдәниятле милләт итү өчен бөтен көчен куя. «Мин янып та калырмын, бәлки, тик халкым үз юлын табарга тиеш, бәйсез булырга тиеш!» – ди ул Зәйтүнә белән әңгәмә корганда. «Вакыйгаларда шагыйрьнең үз заманы өчен генә түгел, гасырлар узгач та, татар халкы өчен кыйммәтле булуы күренә» [2], – дип яза А. Әхмәдуллин.

Әсәрдә Тукай яшәгән чор белән XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы вакыйгалары чагыштырылып кына калынмый, алар үзара керешеп тә китә. Дәверләрне Тукай язмышы һәм иҗаты берләштергән кебек, һәртөр кара көчләрнең эш-гамәле дә уртак булуы искәртелә. Тукай мәхәббәте турында сөйләүче әсәр милләт язмышы, аның бүгенге хәлендә шәхси башлангычның, рухи һәм матди кыйммәтләрнең роле турындагы җитди бәхәскә, тирән уйлануларга китерә. Чөнки Тукай чорының карагруһчылары бүген дә безгә яный. Тышына «Габдулла Тукай» дип язылган китапның «кулга алынуы» һәм тантаналы төстә алып кителүе дә тирән символик мәгънәгә ия булып, туган телебезне, мәктәбебезне чикләүләргә ишарә булып тора.

«Башлам»да автор хыялында тудырылган Тукай киләчәге турында уйлана: «Мин әле кая барам?» Йөрәге аңа иң дөрес һәм бердәнбер юлны күрсәтә – халык гаме белән яшәү! Зәйтүнәнең «Бу юл кая илтә» дип соравына, Тукай болай җавап бирә: «Бу юл – йолдызларга таба». «Эпилог»та автор шартлы рәвештә Тукай белән Зәйтүнәне төрле чорларга куя. Бер караганда, алар бүгенгебездә, әнә бит Казан урамнарының берсе

Тукай исемен йөртә, Тукай музее да бар. Әмма әлеге күренешләр экзистенциаль пафос белән сугарылган. Үз дәвере кебек үк, Тукай җәмгыятьтәге гаделсезлек белән очраша, җанына тынычлык таба алмый. Кисәк кенә күренеш алмашына һәм Тукай белән Зәйтүнәне без инкыйлаблардан соңгы көннәрдә күрәбез. Инкыйлаб ясаучылар Тукайны кимсетеп кенә калмый, юк итәргә теләп, Матрос аңа револьвердан ата, әмма пуля Тукайга зыян китерми. Зәйтүнәнең «Үлми ул, үлми! (...) Үлемсез ул!» дигән сүзләреннән соң, әлеге бәндәләр качып китә. Пьеса ахырында сызлану, сыкрану чагылышы булып яңгыраган җыр белән авторТукай язмышын гына искәртми, бәлки бүгенгебезгә дә ишарә итеп, җан ачысы белән аваз сала.

Шулай итеп, Р. Зәйдулла Тукай шәхесенең әлегәчә серле пәрдә белән капланган ягын – хатын-кызлар белән мөнәсәбәтен, мәхәббәте белән бәйле вакыйгаларны иҗаты белән тыгыз бәйләнештә сурәтли, әдип яшәгән чор күренешләре аша бүгенгебезгә бәя бирә, китап укучыны, тамашачыны гыйбрәтле, сабак алырдай нәтиҗәләргә китерә.

ӘДӘБИЯТ


1. Әхмәдуллин А.Г. Күңелләрне уятыр: Хәзерге татар драматургиясе: Монография. Казан: Мәгариф, 2007. 143 б.

2. Әхмәдуллин А. Тукай образына яңа бизәкләр // Мәдәни җомга. 2012. 20 гыйнвар.

3. Нигматуллина Ю.Г. Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. Казань: Фэн, 1997. 190 с.

4. Игъламов Н. Шыпырт кына җил исәр... // Зәйдулла Р. Саташкан сандугач һәм башка пьесалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. Б. 3–8.


## Г. ТУКАЙ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ БОРЫНГЫ УЙГЫР ӘДӘБИ ТЕЛЕ ТРАДИЦИЯЛӘРЕ


***Закиров Р.А.***



Г. Тукай является одним из основоположников современного татарского литературного языка, близкого к живому народно-разговорному языку. Однако в его произведениях, особенно в поэзии, продолжают употребляться слова и грамматические формы, характерные для тюркских литературных языков предшествующих эпох, в частности для древнеуйгурского литературного языка (X–XIII вв.): 1) употребление формы местно-временного падежа *-да*/*-та* в аблативном значении; 2) использование формата исходного падежа с узким гласным *-дын*/*-дин;* 3) употребление аффиксов принадлежности I и II лица *-мыз*/*-ңыз;* 4) использование глагольной формы *-мыш* в функции сказуемого, определения и дополнения; 5) формы на *-гай* – в функции будущего времени и др.

G. Tukay is one of the founder of the modern Tatar language that is near to the living colloquial language. But in his works especially in the poetry some words and grammatical forms which are typical for the Turkic literary languages of the previous periods particularly for the ancient Uyghur language (the Xth and the XIIIth centuries) continue their using: 1) the form in the locative case -да/ -та in the ablative meaning; 2) the form of the initial case with the narrow vowel -дын/-дин; 3) the possessive affixes of the Ist and the IInd persons -мыз/- ңыз; 4) the verbal form -мыш in the predicate, attribute and object functions; 5) the forms with - гай in the function of the future tense etc.


Габдулла Тукай хаклы рәвештә хәзерге татар милли әдәби теленә нигез салучыларның берсе булып исәпләнә. «Халык әдәбияты» дигән мәгълүм хезмәтендә ул татар матбугаты һәм дәрес китаплары теленә «татар рухы вә татар үзе» булмаган «җен теле» дигән бәя биреп, халык авыз иҗаты әсәрләре телен үрнәк итеп куя [1, т. III, б. 309]. Сәгыйть Сүнчәләйгә 1910 елның 9 ноябрендә язган хатында шагыйрь каләмдәшен «шигырьләрегездә мин провинциальный һәм төп халык телендә булмаган сүзләр табам. Аларны катыштырмасагыз икән...», – дип шелтәли һәм милли әдәби телебезнең «төп халык»– Казан һәм Казан арты татарлары сөйләшенә нигезләнергә тиешлеген дәлилли [1, т. III, б. 309]. Тукай үзе дә, башлангыч чор иҗатын исәпкә алмаганда, нигездә шул «төп халык» телендә, халыкка аңлаешлы телдә иҗат иткән.

Бу, билгеле, бөек шагыйребез тулысынча гади сөйләм телендә язган, Тукайлар нигез салган татар милли әдәби теле нәкъ менә шул чор сөйләм телен чагылдыра дигән сүз түгел. **Чөнки** һәр әдәби тел үзенең элгәренә таянып, аның традицияләрен дәвам итеп кенә формалаша. Төрки әдәби телләре дә үз үсешләрендә түбәндәге төп этапларны үткән:

1) рун (орхон-енисей) язмаларында чагылыш тапкан борынгы төрки тел,
2) борынгы уйгыр әдәби теле,
3) караханид-уйгыр әдәби теле,
4) АлтынУрда (хәрәзм-төрки) әдәби теле,
5) Чагатай теле,
6) «төрки» (тюрки) әдәби тел.

Соңгысының берничә региональ варианты булган: Урта Азия, Кече Азия, Арал-Каспий, Кавказ, Идел буе һ.б. төрки әдәби телләре [2, б. 35–37].

Бу әдәби телләрнең һәрберсе үзеннән элгәре әдәби телләрдәге традицион нигезгә җирле сөйләм элементлары өстәлеп ясалган. Татар милли әдәби теле дә Идел буе төрки, башкача әйткәндә, иске татар әдәби теленең Тукайлар тарафыннан күпчелек халыкка аңлаешсыз була башлаган гыйбарәләр урынына татар сүзләре һәм формалары белән баетылган дәвамчысы.

Үз чорының белемле, зыялы шәхесе буларак, Г. Тукай иске төрки әдәби телләрне яхшы белгән. Моны аның башлангыч чор әсәрләрен, соңрак чорда кайбер шәхси хатларын да иске, классик әдәби телдә язуы да раслап тора. Шуңа да шагыйрьнең әсәрләрендә татар әдәби теленең элгәрләренә хас формалар да яңа, миллиләре белән еш кына параллель кулланыла.

Түбәндә без Тукай иҗатында борынгы уйгыр әдәби теле элементларының кулланылышына күзәтү ясап үтәрбез.

Борынгы уйгур әдәби теле – VIII гасырда хәзерге Кытайның Турфан, Ганьчжоу төбәкләренә күченеп килеп, үз дәүләтен төзегән төркиләр тарафыннан борынгы төрки (рун) әдәби теленә, аның угыз-уйгыр нигезен саклаган хәлдә, җирле тел элементлары өстәп ясалган әдәби тел. Бу телдә уйгыр (согод алфавитының төркиләштерелгән варианты), манихей, брахми, рун, эстрангело, тибет һ.б. алфавитларда бик күп дини, әдәби, фәнни (медицина, астрономия) әсәрләр, эш кәгазьләре язылган. Югары камиллеккә ирешкән борынгы уйгыр әдәби теле башка төрки халыкларга да яхшы таныш булган һәм соңрак бүтән төрки әдәби телләрне формалаштыруда зур роль уйнаган [3, б. 82–83].

Габдулла Тукай әсәрләрендә бу телгә хас түбәндәге элементлар очрый.

Морфология өлкәсендә иң кызыклы үзенчәлек – төрки телләр үсешенең борынгы чоры өчен генә хас (рун һәм борынгы уйгыр истәлекләрендә генә очрый) *-да*/*-та* кушымчасын урын-вакыт мәгънәсе белән беррәттән чыгыш килеш (аблатив) мәгънәсендә дә куллану:

Мәгәр көннәр**дә** бер көн, әмре трахтир,
Утырмыштым ки бер пивнойда сирра.
*(«Ысуле кадимче» – I, 172 б.)*
Тән**дә** җаным, чык та тәңреңә юнәл, бар, кайт кире!
*(«Өмидсезлек» – II, 115 б.)*

Шулай ук чыгыш килешнең борынгы уйгыр әдәби теленә генә хас тар сузыклы *-дын*/*-дин* формасы да Тукай әсәрләрендә актив кулланыла:

«Алла, алла! Саклый күр ут**дин»**! – диләр,
«Кыйл шәфәгать, йа Баһаветдин!» – диләр.
*(«Печән базары...» – I, 236 б.)*

Бу форманы куллануны рифма таләпләре белән генә аңлатып булмый, чөнки ул шагыйрьнең проза әсәрләрендә дә шактый еш очрый:

«Фикер» гәзитәсенең мөхәррире һәртөрле тараф**дин** хәбәрләр язып... җәмәгатьнең уйку**дин** күзләре ачылса... икән дип тырышадыр». *(«Шәһәремездәге зур тамгылы мулаларә бер-ике сүз» – III, 66 б.)*

Күрәсең, биредә Тукайга үзе үрнәк алырга чакырган халык җырлары тәэсире сизеләдер, *-дын* формалы чыгыш килешнең шагыйрьнең «Халык моңнары» лекциясендә китергән текстларда, үзенең аларга ияреп язылган «Авыл җырлары» циклында да очравы шул турыда сөйли:

Ак куян дип атканым –
Булды тауның катлавы;
Аргы жак**дин** берәү килә –
Безнең җанәй атлавы.
*(«Халык моңнары»«– II, 305 б.)*

Талдин тартма ясадым, тар буласын белмәдем;
«Әхбар» бай дип еллык яздым, ябыласын белмәдем.
*(«Авыл җырлары» – I, 181 б.)*

Борынгы уйгур һәм кайбер Енисей буе рун язмаларындагыча, юнәлеш килешне 1–2 зат тартым кушымчасына *-га*/*-гә* форманты ялгап ясау да Г. Тукай теленә хас:

Тисә киеме генә яңлыш тәнем**гә**,
Туадыр бихисап шатлык җанымда.
*(«Бер мән» – II, 130 б.)*

Әгәр исең**гә** төшсә кайсы чакта,
Качандыр уйнаганы бу яңакта.
*(«Вәгазь» – I, 116 б.)*

Стилистик максаттан Тукай 3 зат һәм күрсәтү алмашлыкларын юнәлеш килешенең аңар/аңгар, моңгар формасында да куллана:

Надан булу – гарь, татар,
**Аңгар** дөнья тар, татар.
*(«Татар кошы сайрый» – I, 75 б.)*

Тартымның 1 һәм 2 зат күплек кушымчаларын Г. Тукай борынгы төрки телләрдән килгән *-мыз, -ңыз* формасында да куллана:

Котылсак та, китәргә юлы**мы**з юк,
Оныттык: сагымыз юк, сулы**мыз** юк.
*(«Рәсемгә ишарә» – 1, 53 б.)*

Яратмыйм бер дә сезнең җәһле**ңез**не,
Караңгы сале**ңез**не, шәһре**ңез**не.
*(«Татар кызларына» – I, 47 б.)*

Дини эчтәлекле борынгы уйгыр текстларында зат алмашлыгының без (биз), сез (сиз) формалары илаһи затларга (алла, будда, бодисатва...) карата хөрмәт (яисә тыйнаклык) белдерү чарасы буларак берлек мәгънәсендә кулланыла, ә күп кеше турында сүз барганда – сезләр (сизләр) формасы язылa:

Алкынчсыз көкүзлүг бодисавт, **сиз** ынча билиң – «Зиһене чиксез бодисатва (=Аксаямати), Сез шуны белегез» [4, 16 б.]

Ол бодисавт **сизләркә** коркынчсыз бушы биргәй – «Ул бодисатва сезгә (ягъни бөтен кешеләргә) иминлек бирер» [4, 11 б.].

Бу үзенчәлек – без, сез күплек алмашлыкларын стилистик максаттан -ләр өстәп файдалану – Г. Тукай әсәрләрендә дә очрый:

Вә егъладык ачы күз яшь белән без**ләр**, тын алмастан...
*(«Бакирәнең икенче җыры» – I, 79 б.)*

Кызганамын сез**ләр**не,
Ник ачмыйсыз күзләрне?
*(«Иттифак хакында» – I, 28 б.)*

Фигыльнең угыз телләренә хас -мыш формасы Г. Тукай әсәрләрендә хәбәр (а), аергыч (ә), тәмамлык (б) функцияләрендә актив кулланыла:

а) Мөхит диңгезе үзенең ярларыннан ачу илә атылып чык**мыш.**
*(«Кыямәт көне» – III, 7 б.)*

ә) Җон белән бер рухы үл**меш**
Теп-тере мәҗнүн ага. *(«Саташкан» – I, 146 б.)*

б) Атучыга әмребез: укларны кызганмасын!
Атыл**мыш**ка нәсихәт: йөрәге сызланмасын.
*(«Уклар» журналында мөхбир уланлара тәнбиһ» – I, 32 б.)*

Шулай ук фигыльнең борынгы -гай киләчәк заман формасы да Г. Тукай шигырьләрендә очрый:

Номерың матур булса, күсе булгай,
Һәр матурда начар якның берсе булгай...
*(«Гыйбрәт вә нәсихәт» – II, 208 б.)*

Лексика өлкәсендә борынгы уйгыр әдәби теле өчен хас анчак (тик, фәкать), эксүк (кимчелек), берлә (белә, белән формалары белән параллель рәвештә), сөчүг (төче) кебек сүзләр куллануны да билгеләп үтәргә була:

Кирәк **анчак** яшәр микъдар ашарга...
*(«Толстой сүзе» – II, 287 б.)*
Һич **эксүксез,** язарым дигәч, язарым...
*(«Кечкенә генә бер көйле хикәя» – I, 39 б.)*

Чабатаң **берлә**, нинди мәнфәгать бар соң, әдәп таптап?
*(«Мөтәшагыйрьгә» – I, 85 б.)*
Мәче... **сөчүк** кенә тел илә сандугачка бу сүзләрне әйтә башлады...
*(«Мәче илә сандугач» – III, 299 б.)*

Билгеле, югарыда каралган формалар, сүзләрне Г. Тукай турыдан-туры борынгы уйгыр әдәби теленнән алмаган (Тукай чорында татарларга бу тел ядкәрләре белән танышу да мөмкин булмаган диярлек); алар чордан-чорга, бер төрки әдәби телдән икенчесенә күчеп, Идел буе төрки әдәби теленә кадәр килеп җиткән. Г. Тукай исә бу формаларны үз әсәрләрендә бик уңышлы һәм урынлы файдаланган. Борынгы уйгыр әдәби теле элементларын куллану, бердән, кайбер әсәрләрне иске төрки язма истәлекләргә ияреп, аларның форма үзенчәлекләрен саклап язу белән, икенчедән – рифма-ритм таләпләре белән аңлатыла. Кайбер текстларда бу формалар стилистик максаттан чыгып (архаизация, ирония һ.б.) та файдаланыла.

Ничек кенә булмасын, урынын һәм чамасын белеп кулланылган мондый архаик формалар Г.Тукай әсәрләренең телен аңларга комачауламый, аны аһәңле итә.

ӘДӘБИЯТ

1. Габдулла Тукай. Әсәрләр: 4 томда / төз., искәрмә, аңлатмалар авт. Р. Гайнанов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975–1977. Мисаллар шушы басмадан алынды; җәяләр эчендә әсәр исеменнән соң том (рим цифрлары белән) һәм бит саннары күрсәтелә.

2. Тенишев Э.Р. Тюркоязычных письменных памятников языки // Языки мира. Тюркские языки. М.: Индрика, 1997. С. 35–46.

3. Тенишев Э.Р. Языки древне- и среднетюркских письменных памятников в функциональном аспекте // Вопросы языкознания. 1979. № 2. С. 81–87.

4. Tekin Ş. Kuanşi im Pusar. Ankara, 1993. 57 s.

## ТӨРКИ ФОЛЬКЛОРДА ҺӘМ Г. ТУКАЙ ИҖАТЫНДА ҖАН БЕЛӘН БӘЙЛЕ ЫШАНУЛАР

***Закирова И.Г.***

Проанолизированы верования и представления тюркских народов, связанные с душой. Сохранившиеся в тюркском фольклоре и в литературных произведениях верования и представления, связанные с понятием «душа», позволяют судить, что душа является ценностью, данной небесами, и связующим звеном всех миров. Вокруг нее сконцентрированы все обряды и ритуалы.

Beliefs and view of Turkic people connected with soul’s motive were analyzed. Soul is considered as the main value and connecting link of all three worlds. All ceremonies and rituals are concentrated around it.

Татар телендә халыкның җан белән бәйле күп санлы ышанулары, күзаллаулары саклана. *Җан* сүзе күп төрле мәгънәләргә ия сүз. Мифологиядә һәм фольклорда ул «Тәңгә тереклек бирә торган һәм аннан башка да яши ала торган мәңгелек башлангыч», – мәгънәсендә өйрәтелә [5, б. 772]. Димәк, җан – тере затның үлемсез, матди булмаган, ягъни рухи өлеше, яшәешнең төп кыйммәте.

Җан төшенчәсен этнограф Эдуард Тэйлор өйрәнә. Галим җан белән бәйле ышануларның килеп чыгуын аңлата, җанга билгеләмә бирә, йокы, төш күрү, авыру-үлем күренешләренә бәйле ышану, күзаллауларны анализлау нәтиҗәсендә, җанны кешенең эчендә утырган «зат»; «ия» итеп кабул ителүен яза [8, б. 259–345].

Төрки мифологиядә да җан шундый «зат» рәвешендә күзаллана. Җанның төрле халәтен белдергән сүзләр дә төркиләрдә шактый. Мәсәлән, *тын – тун*, *кут – кот, сур, суне* һ.б. *Тын* сүзе татар телендә хәзерге вакытта сулыш мәгънәсендә сакланган. *Тын* –

*сулыш* җанлы субъектларга гына хас булып, *тын алмау* үлемне белдерә. Күп төрки телләрдә ул җан мәгънәсен саклый. Алтай телендә *тыны чыгу* – җан чыгуны*, тын өзелү* – үлемне, тува телендә – *тын* – тереклек, яшәүне аңлата. Татар телендә *тыныл калу*, *тынсыз калу* гыйбарәләре күпмедер дәрәҗәдә сүзнең борынгы мәгънәсен саклый. *Тын-сулыш* сүзләренең җан белән бәйле булуы рус телендә дә күренә. *Душа* сүзе белән*дыхание* сүзләре дә уртак тамырдан.

Җан мәгънәсендә икенче сүз *кот* сүзе, *Кот* – гомумтөрки сүз. Кот (ягъни кут) сүзенең мәгънәләре күп. Безне сүзнең *җан, рух, яшәү көче* дигән мәгънәләре кызыксындыра. Сүзнең бу мәгънәсе татар халкының әйтем-мәкальләрендә саклана. «Котым очты», «кот чыгу», «кот ботка төшү» гыйбәрәләреннән котның тәннән чыгып китүе, яки күчеп йөрүенә ышану сакланган. «Кот очкыч», «кот очарлык» гыйбарәләре куркынычлык дәрәҗәсен,«кот очу» гыйбәрәсе хәзерге вакытта көчле куркуны аңлатса, бу гыйбарәләрнең беренче мәгънәсе үлемне, ягъни җанның тәннән чыгып очып китүен аңлата.

Г. Тукай «Шүрәле» поэмасында Шүрәлене «Кот очарлык, күрсәң әгәр, төнлә түгел – көндезләре» дип сурәтли [6, б. 170].

Алдарак искәртелгәнчә, җан төрле дөньяларны бәйләп торган уртак кыйммәт. Җанны күкләр бирә, җир дөньясында яшәүчеләр гомерләре буе җаннарны саклар өчен көрәшә, аны саклыйлар, кадерлиләр, югалтудан куркып яшиләр. Үлгәннән соң кешенең җаны «теге» дөньяга, яки үлеләр дөньясына күчә.

Г. Тукай иҗаты да, шагыйрь җан төшенчәсенә аерым игътибар бирмәсә дә,татар халкының җан турындагы ышануларын саклый. Татар халкы җанның төрле халәттә кеше күзенә күренеп йөрүенә ышанып, бу ышану *җан кошы*, *күбәләк җан, чебен җан* дигән сүзтезмәләрсаклана.

Г. Тукайның «Сорыкортларга» дигән шигырендә шушы ышануны саклаган юллар бар:

> Чебен җанымны чын юлда бирәм бең кәррә, кызганмыйм [6, б. 93].

Кыргыз халкының «Манас» эпосында *чебендәй җан* дигән гыйбарә бар. Башкорт халкының «Урал-батыр» поэмасында исә җан *күбәләктәй* дип сурәтләнә. «Кызыл әтәч» дигән татар әкиятендә кешенең җаны сары чебен буларак тасвирлана. Кеше йоклаганда аның җаны чебен булып очып китә. Чебен кире кайтып кешенең авызына кергәч кенә уяна.

Татар халкы бүгенгә кадәр кешенең җаны кәбәләк булып кайтып йөри дигән ышану бар.

Мифологиядә һәм фольклорда җанның кош булып очып китүе дә саклана. Гомумән, төркиләр үлгән кешенең җаны күгәрчен яки башка кош булып оча дип күзаллыйлар. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасында да шушы ышану бар:

> Шәриф тәннән аерылды гъәзиз җаны,
> Кошка охшап, ул оҗмахка очты инде [4, с. 273].

Г. Тукайның «Өзелгән өмид» шигырендә дә җанның кошка әверелүе турында ышану чагыла. Әмма бу очракта үлем түгел, кешенең өмете өзелгәннән соңгы халәте тасвирлана. Әлеге очракта бу дөнья белән арасын өзгән кеше үзен үлгәнгә тиңли.

> Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы,
> Шат яратса да, җиһанга ят яраткан раббысы [7, б. 150].

Г. Тукай шигырьләрендә тәннең җан өчен вакытлы урын булуы, җанның кешегә бирелүе һәм кире кайтарылуы турындагы ышануларга да мисаллар күп табарга мөмкин. мәсәлән, бу ышану «Шүрәле» поэмасында очрый.

> Иртәгә килгәнче дустлар тәндә җаным торса гәр [6, б. 171].

«Өмидсезлек» дигән шигырендә күренгәнчә, вакытлы бирелгән җан кире кайтарыла. Татар телендәге «кайтарылу» сүзе үлемне аңлата.

> Тәндә җаным, чык та тәңреңә юнәл, бар, кайт кире! [7, б. 128].

«Милләткә» шигырендә Тәңре урынына Күк җан юнәлгән урын буларак килә. Үлгәннән соң кешенең җаны Күккә, Тәңре янына юнәлә.

> И Күк! Ал җанымны, тик, зинһар, алма шөһрәтемне;
> Минемчә, онытылу, тибәрелү – үлемнән яманрак [6, б. 115].

Фольклорда кешенең җаныурнашкан урыннар турында бай мәгълүмат, мифологик карашлар сакланган.

Ислам тәгълиматы буенча кешенең җанын үлем фәрештәсе Газраил килеп ала. Г. Тукай «Мәхү идәрмисән?» («Юк итәрсезме?») шигырендә Газраилне шушы нисбәттән искә ала.

Шәэнеңезгә, и мәләк! Рикъкать, тәрәххемләр кәрәк;
Син дәгелсең анларың җанлар алан Газраили [6, б. 100].

Борынгы ышанулар җанны кан белән бәйли. Бу ышанулар килеп чыгуны аңлату кыен түгел – каны агып беткән зат яшәүдән туктый. Шушы күренешне күзәткән борынгылар җанны кан белән тәңгәлләштергән. Кан бары җанлы затларда гына булып, ул аларның урта дөньяга – кешеләр дөньясына каравын да күрсәтә. Ә киресенчә геройның каны булмау – аның кеше булмавын, башка дөнья вәкиле булуын исбатлый.

Кансыз геройлар төрки эпоста да очрый. Мәсәлән, төркиләрнең уртак мирасы «Кузы Көрпәч һәм Баян-Сылу»дастанының алтай версиясе «Козын-Эркеш»нең төп герое түбәндәгечә сурәтләнә:

Козын-Эркеш юноша
Богатырем родился,
Кровью истечь – у него крови нет;
Умереть – у него души нет [3, с. 205].

Төрки-монгол халыкларында батырлар үзләрен каннарын чыгармый үтерүне сорыйлар. Бу очракта каһарман җаны исән калуга һәм яңадан дөньяга килүгә өметләнә. Мәсәлән, монгол халкының XIII йөзгә караган язма истәлеге «Сокровенное сказание» дә («Юнь-чао би-ши») Тимучинның андасы Джамуха үзен канын чыгармыйча үтерүне сорый:

Если казнишь, то казни ты меня
Лишь без пролития крови.
Смертным забудусь я сном.
Ныне же скорей отпусти же меня! [2, § 201]

Бу юллардан каны коелмаган кеше үлми, бары икенче дөньяга гына күчә, дигән нәтиҗә ясарга мөмкин.

Төрки мифологиядә һәм фольклорда җан төрле аерым органнарда да саклана. Шуларның беренчесе – баш. Кешенең җаны башында урнашкан дигән ышану белән бәйле рәвештә Кисек баш образы формалашкан. Мәсәлән, урта гасырның әдәби ядкарьләре «Кисекбаш», Хисам Кятибнең «Җөмҗемә Солтан» әсәрләрендә геройларның гәүдәләреннән аерылган башы яшәвен дәвам итә. Татар мәкаль-әйтемнәрендә дә башның иң кирәкле орган булуы аңлашыла: «Баш исән булсын», «Баш исән булса, мал табыла».

Фольклорда Кисек баш мотивы «Ак Күбек» дастанында очрый. Ак Күбек Коден ханның башын кискәч тә, Коден ханның башы сөйләшүен дәвам итә. «Огуз хан»дастанында да шушы ышануны саклана: «Я отдаю тебе свою голову, свою душу» (Др.- тюрк. men. senä bašumni gutumni berämen ) [1, с. 471]. Бу мисалда җан кот сүзе белән бирелгән. Башны бирү җанны бирүне аңлата.

Г. Тукайның «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш» әсәрендә дә Кисекбаш яшәвен дәвам итә, сөйләшә, яши [6, б. 260–276].

Дастаннарда җанның иминлеген тәэмин итүнең тагын бер шарты – һәр сөякнең урынында булуы. Җан иминлеге сөякләр ныклыгына да мохтаҗ. Мәктәп-мәдрәсәләрдә балаларны «Ите сезгә, сөяге безгә» дип тапшыру, «Сөяк-санагың сау булсын!»дигән теләк шуны аңлата.

Әкиятләр-дастаннарда җанның гәүдәдән, аерым, хәтта еракта, бөтенләй чит предметларда яшәве турында да ышанулар саклана. Әкиятләрдә Дию, Дию пәрие кебек образларның җаны еракта булып, геройга диюне җиңү өчен шактый киртәләр үтеп, аның җанын кулга төшерү кирәк була. «Унберенче Әкмәт» дигән әкияттә Җен патшасының җаны үз тәнендә түгел, ә ерак утрауда саклана. «Юк, – ди, карт әйтә, – минем җаным бу тирәдә түгел, ди, менә моннан бер 150 чакрымда читтә, бер күл бар, ди, шул күл уртасында бер утрау бар, утрау уртасында бер үрдәк оясы бар, үрдәк оясында дүрт йомырка бар, минем җаным шулар эчендә, – ди» [9, т. 1, б. 285].

Татар телендә *Сулыш өрү* дигән гыйбарә бар. Ул *җан иңү*не аңлата. Дастаннарда, әкиятләрдә геройга җан өрү аңа тын (сулыш) өрү буларак та бәян ителә. Бу очракта җан

җил буларак тасвирлана. «Турай батыр» дигән татар әкиятендә үлгән геройны анасы үзенең җылы сулышын өреп яңадан terelтә.

Тереклекнең вакытлы булуы, аның теләсә-кайсы вакыт өзелүе борынгыларда җанны нечкә җеп рәвешендә күзаллауны да тудырган. Бу күзаллау да татар телендәге үлемне аңлаткан *тыны өзелү, җаны өзелү*, яки *өзелү* гыйбарәләрендә саклана. *Җан җебе* дигән гыйбарә дә бар.

Кеше үлгәндә аның җаны, тан, сулыш, яки җил булып чыга, һәм тере кешенең җаны нинди дер зат буларак күзалланса да, ул төгәл реаль зат (материаль) буларак сурәтләнми. Ә үлгәннән соң кешенең җаны материальләшеп, күбәләк, кош булып күзаллана башлый.

Төрки фольклорда җан белән бәйле күп ышанулар сакланган. Алардан җанның күкләр тарафыннан бирелгән кыйммәт булуы аңлашыла. Ул кеше тәнендә материаль булмаган субстанция халәтендә яши һәм кеше үлгәннән соң яңадан күкләргә кайтарыла. Бу ышанулар Г. Тукай иҗатында да яхшы сакланган. Шагыйрьнең иҗатындагы аерым гыйбарәләрне халык иҗатындагы мотивлар белән чагыштырып өйрәнү татар халкының аерым мифологик мотивларыын яхшырак аңларга ярдәм.

ӘДӘБИЯТ

1. Древний тюркский словарь. Л.: Наука, 1969. 676 с.
2. Козин С.А. Монгольская хроника 1240 г. / Институт востоковедения АН СССР. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1941. Т. I.
3. Козын-Эркеш // Алтай-Буучай. Ойротский народный эпос / под ред. А. Коптелова. Новосибирск: ОГИЗ, 1941. С. 199–240.
4. Кол Гали. Кыйссаи Йосыф / төз. Н. Хисамов.Казан: Дом печати, 2008. 604 б.
5. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге.Казан: Матбугат йорты, 2005. 848 б.
6. Тукай Габдулла. Әсәрләр. Биш томда. 1 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 408 б.
7. Тукай Габдулла. Әсәрләр. Биш томда. 2 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 400 б.
8. Тэйлор Э. Первобытная культура. М.: Государственное социально-экономическое изд-во, 1939. 568 с.
9. Әкиятләр. Татар халык иҗаты / томны төзүчеләр, искәрмәләрне хәзерләүчеләр: Х.Х. Гатина, Х.Х. Ярми. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 408 б.

## ЛИТЕРАТУРНЫЙ МУЗЕЙ ТУКАЯ И PR-ТЕХНОЛОГИИ

***Залялова Г.А.***

В начале XXI века резко изменилось отношение к связям с общественностью и PR-технологиям. PR нашел отражение в работе музеев, появляются новые методы работы со СМИ. Литературный музей Г. Тукая занимается популяризацией творческого наследия поэта и его современников. В этой работе я отметила несколько успешных проектов, которые были воплощены в музее. Так в 2014 году сотрудники запустили уникальный проект – маршрут «Колыбель поэта», итогами поездки стали серия сюжетов и статей в СМИ. И не менее популярной стала акция «Читаем «Что я помню о себе», в которой приняли участие известные актеры, общественные деятели, медики.

At the beginning of the XXI century the attitude to PR-technologies and public relations has changed a lot. PR is reflected in the work of museums. There are new ways of working with the mass media. GabdullaTuqay Literary Museum is engaged in the popularization of the creative heritage of the poet and his contemporaries. In this report I have noted a number of successful projects that have been applied in the work of the museum. In 2014 museum staff launched a unique project, they organized asightseeing tour «The Cradle of the Poet». This tour has resulted in a series of videos and articles in the media. The well-known actors and public figures, doctors took part in the movement «Read «What I remember about myself», which was no less popular.

В начале XXI века резко изменилось отношение к связям с общественностью и PR-технологиям. С целью адаптации российских музеев к рыночным условиям им необходимо использовать методы маркетинга, развивать спонсорство и расширять общественные связи. Меняется структура музеев, появляются новые методы работы со СМИ. Не заслоняя профессиональной деятельности, музеи призваны стать посредниками в рекламировании всех своих акций, адресованных публике, объясняя посетителям, что музей идет навстречу их требованиям и пожеланиям.

Налаживание устойчивых связей с постоянными клиентами приобретает первостепенное значение. Музеи осознают, что они не могут иметь, дело только с посетителями-туристами, но должны иметь постоянных партнеров среди местного населения. Сущность современной музейной деятельности состоит в приобщении к ней новых посетителей.

В современном музееведении большое значение придается культурной коммуникации. Коммуникация – это не просто цепочка последовательных мероприятий по привлечению внимания широкой общественности; коммуникативная модель предполагает обязательную обратную связь между основными участниками. Функцию управления информационными потоками выполняют связи с общественностью. PR пронизывают всю музейную деятельность; PR влияет на развитие музея, формируют его облик, предопределяя его будущее развитие. PR выступает в данном случае средством стратегического управления поведением внешней и внутренней сред организации, инструментом влияния на них с помощью информационного взаимодействия.

Музей призван формировать культурную среду той местности, в которой находится. Музейная работа направлена на воспитание чувства общественного самосознания; через свои выставки и мероприятия музей обращается к каждому посетителю, эмоционально воздействуя на аудиторию, образовывая и развлекая одновременно. Таким путем преодолевается дефицит информации, повышается статус музея, так как выявляется его своеобразие среди других учреждений культуры.

Партнерами музея в массовой коммуникации являются средства массовой информации. Отдавать предпочтение кому-либо из СМИ означало бы потерять часть потенциальной аудитории. Пресса, радио и телевидение обладают рядом особенностей, проявляющихся в характере и способах донесения информации до аудитории. Планируя рекламную кампанию, следует учитывать специфику любого СМИ. При обращении читателей к прессе на первом месте оказываются стремление глубже ориентироваться в происходящем, затем – желание почерпнуть какую-либо утилитарно-полезную информацию, с толком провести свободное время. Радио удовлетворяет стремление получать оперативную информацию, которому сопутствует желание быть включенным в динамику происходящего, получать практические советы. Мотивы обращения к телевидению – желание провести у экрана свободное время. При обращении музея к СМИ быстро устанавливается «обратная связь» в обмене информацией. СМИ освещают деятельность учреждения, у музея появляется возможность получения быстрого отклика от потребителей на предлагаемые музеем услуги. Под словом «потребители» подразумеваются не только посетившие музей, но и те, кто о нем слышал, видел по телевидению или прочитал в прессе. Это – тоже аудитория, только неактивная; сделать ее своим постоянным партнером – задача музейной коммуникативной службы.

Сегодня музеи должны пропагандировать не только свои выставки, экспозиции, но и идеи, программы, знакомить общественность не только с серьезной, но и занятной информацией, рекламировать свои услуги и своих сотрудников. Оформленные в фирменном стиле музейные издания, видеофильмы и прочие достижения современных информационных технологий являются одновременно и рекламным продуктом, «визитной карточкой» музея. Фирменный стиль обеспечивает музей тем, что он становится легко узнаваемым. Его своеобразный имидж известен и понятен не только тем, кто побывал в его стенах, но и тем, кто присутствовал на презентации его проектов или знаком с музеем по его выездным выставкам.

Во всем мире сегодня придают большое значение культурным программам, которые сопровождают, а нередко и ведут за собой чисто экономические программы, нацеленные на возрождение и развитие городов и регионов.

Музеи занимают в этих программах особое место. В отличие от других учреждений культуры, они по определению имеют дело с уникальными, не тиражируемыми ценностями.

В нашем случае Литературный музей Г. Тукая – филиал Национального музея Республики Татарстан – занимается популяризацией творческого наследия поэта и его современников. Эпоха Тукая и его творчество обширная тема, которая интересна не только жителям нашей республики, но и далеко за его пределами. Туристы, приезжающие из России и из ближнего зарубежья с интересом, слушают экскурсию, знакомятся с мероприятиями музея.

Можно назвать несколько каналов коммуникации и распространения информации: личный, визуальный, интернет, предмет, СМИ. Самый большой и распространенный вид коммуникации – СМИ: пресса, радио, телевидение. В настоящее время это самый массовый канал, охватывающий громадную аудиторию. Все масс-медиа построены на:

– конкретной потребительской информации (куда могу пойти в выходные, где комфортнее и интереснее провести отпуск…).

– новостях. Учреждения культуры любой разговор начинают от истоков. Например, открывается выставка, по этому поводу присылается пресс-релиз, начинающийся с фразы: «Наш музей основан в одна тысяча косом году». Далее следует подробный рассказ обо всей многострадальной истории этого почтенного учреждения. В итоге сообщение, не дочитав, отправляют в мусорную корзину, поскольку выуживать новостную информацию по крупицам у редакции не всегда есть время. В случае с пресс-релизами Литературного музея Тукая мы решили выйти из положения таким образом: в самом начале жирным шрифтом выделяется время и место проведения мероприятия, после этого описывается актуальность этой темы и созвучность ее с именем татарского поэта, после занавес открывается и представляются известные имена в сфере культуры, которые посетят это мероприятие, что тоже не мало важно.

– сенсациях. СМИ работают с массовым сознанием, жаждущим чуда. Плюс они выходят в свет изо дня в день, и в них очень остро стоит проблема повторяемости. Поэтому все масс-медиа гоняются за редкими, уникальными фактами, курьезами, исключениями. Отправляя в редакцию информацию, не редко в ответ говорят: «Мы об этом уже писали». Поэтому приходится искать новые способы сотрудничества, так Литературный музей Тукая в 2014 году разработал уникальный проект – маршрут по местам Тукая «Колыбель поэта». Представители СМИ смогли побывать сразу в трех музеях великого татарского поэта Г.Тукая – Литературном музее Габдуллы Тукая в г. Казани, в Доме-музее семьи Тукаевых в с. Кошлауч и в Государственном литературно-мемориальном комплексе Г. Тукая в дер. Новый Кырлай в Арском районе. Это уникальная возможность не только прорекламировать новый маршрут музея, но и наладить дружеские отношения с журналистами. Во время пути опытный экскурсовод рассказывала биографию поэта, зачитывала стихи поэта. С такими лирическими отступлениями было приятно проехать по дорогам, по которым неоднократно проезжал великий татарский поэт Габдулла Тукай. Представители СМИ были рады этой поездке и собрали информации не только на один сюжет и материал, а на несколько. Итогами поездки были: серия сюжетов в телекомпании ТНВ «Новый век» (новости); материалы в печатных и электронных СМИ: «Мәдәни җомга», «Ватаным Татарстан», «Интертат.ру», «116.ру», «Казанские ведомости», «Республики Татарстан»; передачи на радио: «Болгар радиосы», «Радио Татарстан».

Этот проект позволил нам найти «своих» журналистов, которых можно приглашать на различные мероприятия музея, также укрепил дружеские отношения с музеями Тукая нашей республики.

Также не менее популярной стала акция «Читаем «Что я помню о себе» приуроченная 105-летию создания Г. Тукаем автобиографической повести «Что я помню о себе», в которой приняли участие известные актеры, общественные деятели, медики. Акция нашла отражение в республиканских СМИ и стало востребованным.

– Пресс-служба и сотрудники музея научились максимально эффективно использовать социально-политическую ситуацию в обществе. Например, во время «Универсиады» 2013 года и «Чемпионат мира по водным видам спорта» 2015 года в столицу Татарстана прибыло множество региональных и зарубежных СМИ. Учитывая плотный график тренировок и соревнований учащихся Литературный музей Тукая на время состязаний изменил график работы. Желающие могли его посетить до 21.00. И нужно отметить рост потока туристов в эти периоды.

Очень важный фактор, влияющий на специфику всех средств массовой информации – их аудитория: зрители, читатели, слушатели. Литературный музей Г. Тукая нашел свое место в СМИ литературные и поэтические вечера, проводимые здесь стали популярны среди аналитических передач и изданий. Так, например, для передач «Татарлар» телерадиокомпании ТНВ «Новый век» и «Ижат» ГТРК «Татарстан» актуальны такого рода мероприятия. Не смотря на ото что в Национальном музее Республики Татарстан проходят тоже «Литературные солоны» и встречи со знаменитыми деятелями культуры

представители выше указанных СМИ не приезжают, а приезжают в основном новостные группы. Это говорит о налаженности контактов и нахождение своей аудитории.

Литературный музей Г. Тукая в ряде случаев сотрудничают с масс-медиа на основе бартера. Главное помнить, что блага могут исходить не только от СМИ, но и от музея. То есть для СМИ организовываются экскурсии и мероприятия в музее.

Чтобы облегчить работу с многочисленными средствами массовой информации, пресс-служба сформировала базу данных СМИ. В нее входят: название, тематическая направленность (рубрики, полосы, отделы), аудитория, периодичность, тираж, способы распространения, главный редактор, зав. профильных отделов, журналисты, учредители, телефон, факс... На всех интересующих нас журналистов в отделе ведется досье: дни рождения, хобби, досуг, художественные предпочтения, вообще любая информация, которая способна помочь наладить личные и деловые отношения. Поэтому стараемся каждого из представителей СМИ поздравить с днем рождения и праздниками, если не лично, то хотя бы послать поздравительную открытку, не забываем позвонить и поблагодарить за удачный материал, пригласить на мероприятие, о котором журналист не пишет... База данных по СМИ упростила и формализовала многие вещи. На ее основе, например, мы можем сделать необходимую выборку и разослать типовые письма сразу в ряд адресов.

Работа со СМИ дает результаты, только если она ведется очень последовательно и широко. И последнее: добиться серьезных результатов в PR возможно только задействуя все каналы и комбинируя различные формы работы.

Так в этом году Литературный музей Г. Тукая разработал конкурс для детей в журналах «Салават күпере» и «Гаилә». В литературном журнале «Безнең мирас» периодически выходят статьи о деятельности музея и о его экспонатах. Таким образом сотрудники музея удовлетворяют потребности своей аудитории и развивает интерес и любовь у подрастающего поколения к личности Тукая и его творчеству.

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ХАЛКЫБЫЗНЫҢ ЭТНИК ТАМЫРЫ ТУРЫНДА

***Зәкиев М.З.***

В докладе речь идет о том, что творчество Тукая пронизано идеями сохранения и развития своего народа. Поэт владел основными направлениями истории народа, прекрасно представлял себе роль истории в решении вопросов национального возрождения. Он, как и Г. Исхаки, не был сторонником противопоставления наших предков-булгар современным татарам, старался рассматривать их как два отрезка одной линии развития, был ярким противником единства современных татар с монголо-татарскими завоевателями.

The report deals with the fact that the ideas of preservation and development of Tatar people run through Gabdulla Tukay’s creative work. The poet was aware of the history of his nation and the role of the history in national revival. As well as G. Iskhaki, Tukay was not a supporter of the opposition of the Bulgars to modern Tatars and tried to refer them to two segments of one development line. He was a vivid opponent of the unity of the modern Tatars with the Mongolo-Tatar conquerors.

Мин Тукайның юбилейләрендә 1966 елдан, ягъни шагыйрьнең 80 еллыгыннан башлап катнашып киләм.

80 еллык юбилейга «Г. Тукай һәм әдәби телебез» дигән чыгыш әзерләгән идем, ул шул ук 1966 елда «Совет мәктәбе» журналында басылып та чыкты (№ 4, 22–26 б.).

1976 елда Тукайның 90 еллыгына багышланган халыкара конференциядә мин «Г. Тукай татар әдәби теленә нигез салучы» темасы белән катнаштым. Ул чыгышым «Г. Тукай: материалы научной конференции и юбилейных торжеств, посвященных 90-летию со дня рождения поэта» җыентыгында басылды (АН СССР. КФ. ИЯЛИ. Казань, 1979, 125–132 б.).

1986 елда, Г. Тукайның 100 еллыгына багышлап, Тел, әдәбият һәм тарих институты «Слово о Тукае: писатели и ученые о татарском народном поэте» китабын әзерләде (Казан, 1986), анда минем «Тукай һәм татар әдәби теле» дигән мәкаләм басылып чыкты (340–346 б.).

1996 елда Тукайның 110 еллыгы халыкара конференциясен миңа Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры буларак оештырырга һәм үткәрергә туры килде. Мин анда

«Милли үсеш һәм Тукай иҗаты» темасына доклад сөйләдем. Ул 1997 елда «Тукай и духовная культура XX века» (Материалы научной конференции, посвященной 110-летию со дня рождения Тукая) исемле җыентыкта басылып чыкты (5–11 б.).

2011 елда Корстон бинасында Тукайның 125 еллыгына багышланган халыкара конференция үткәрелде. Мин анда «Тукай и этнические корни татарского народа» дигән темага доклад сөйләдем. Бу доклад «Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар» дигән җыентыкта басылды (199–201 б.].

Бу докладны тагын да баетып, «Этногенез народа в творчестве писателя Тукая» исеме белән «Проблемы востоковедения» журналында яңадан бастырдым (Уфа, 2012, № 3. 6–20 б.).

Г. Тукайның тууына 130 ел тулуга багышланган халыкара конференциягә менә шушы докладымны тагын да камилләштереп тәкъдим итәм. Аның татарча эшләнгән вариантын «Фәнни Татарстан» журналдында чыгару урынлы булыр дигән фикергә килдем, чөнки бүгенге көндә Тукайның этник карашлары буенча теге яки бу дәрәҗәдә түгәрәкләнгән бер хезмәт юк әле.

* * *

Мәгълүм ки, үз халкы тарихы белән кызыксынмаган һәм аны белмәгән язучы халыкның милли үсеше проблемалары турында халыкка бер гыйбрәтле сүз дә әйтә алмый. Ә менә Тукай иҗатында үз халкын саклау һәм үстерү идеясе төп юнәлешләрдән санала. Димәк, шагыйрь үз халкы тарихының төп проблемаларын яхшы белгән, халык тарихының милли үсеш мәсьәләләрен хәл итүдәге ролен дөрес күз алдына китергән.

Тукай һәрчак тарихи яңалыклар белән танышып торган.

Халык үсеше мәсьәләләрен белеп тору һәм укымышлы кеше булу өчен, Тукай яшьләргә һәрчак белемнәрен тирәнәйтеп торырга киңәш итә. Үзенең «Хиссияте миллия» әсәрендә бу турыда ул болай яза: «Укымак – дөрестнең ялганны, яктының караңгыны, турының кәкрене, сафлыкның бозыклыкны җиңүләренә иң үткен, иң кирәкле коралдыр. Укымак – фикерләрне җирдән күккә җибәрмәк. Укымак – үз янында булып торган нәрсәләрдән бигрәк, фикерләрне булачакларга сузмак. Укымак – үткәннәрдән кичеп, киләчәкләр – истикъбальләр тугърысында пәйгамбәрлек итмәк. Укымак – хәзерге көннәрне киләсе көннәр өчен, бу көнге мәсьәләләрне киләчәктәге мәсьәләләрне чишү угърында ташламак (юлына чыгармак) димәктер... Укымак – үзеңне һәрнәрсәне белергә вә һәр максудка ирешергә вә бөтен дөньяга солтан булырга лаек дип танымактыр.

«Укымак» ләфзы (сүзе) астында моның кеби хисапсыз мәгънәләр чыкса да, барчасы үз халкымызга хезмәт итмәк дигән сүзгә кайтадыр» [3, б. 187].

Шагыйрь фикеренчә, милли үсешне тәэмин итү өчен, халкыбыз милләт файдасын күз өстендәге кашы дәрәҗәсендә гаҗиз тота торган милләт арысланнарына мохтаҗ... Безнең милләт тә Пушкиннәргә, граф Лев Толстойларга, Лермонтовларга мохтаҗ... Бу әйтелгәннәр булмаганда, безнең тормышыбыз күңелсез, үлек чыккан өй төсле моңлы... рәхәтсез булачактыр [3, б. 186].

Халкыбызның этник тамыры турында Тукай фикерләрен укучыга җиткергәнче, ул чорда бу турыда нинди фикерләр булуы белән танышырга кирәк.

XIX гасыр ахырында, XX гасыр башында рәсми тарих фәнендә, Көнбатыш, Көнчыгыш халыклары һәм рус халкы тарихында татар халкына бары тискәре караш кына урнашкан була. Бу тарихи хезмәтләрдә Идел-Урал татарын монгол-татарлардан аермыйлар, аларның икесен дә *тартар* ‘тәмугъ кешеләре, варварлар’ дип кенә атап тискәре яктан тасвирлыйлар.

Сүз дә юк, дөнья әдәбияты белән танышып барган Тукай төрле халыклар тарихларындагы бу караш белән таныш булган, ул үз халкын, үз татарын да, монгол-татарны да яхшы белгән, аларны бер үк халык дип бутамаган, үз татарының үсеше өчен, аның бәхете өчен җан аткан. «Үз-үземә» дигән шигырендә менә ул ничек язган:

> Күңел белән сөям бәхтен татарның,
> Күрергә җанлылык вактын татарның,
> Татар бәхте өчен мин җан атармын:
> Татар бит мин, үзе дә чын татармын [1, б. 120].

Дөнья тарихында һәм рус хезмәтләрендә татарга – монгол-татарга һәм Идел-Урал татарына бары тискәре генә булуын истә тотып, Г. Тукай үзенең «Бер татар шагыйренең сүзләре» шигырендә болай язган:

Җырлап торам, торган җирем тар булса да,
Курыкмыйм, сөйгән халкым бу татар булса да,
Күкрәк биреп каршы торам, миңа милләт
Хәзерге көн мылтык-ук атар булса да.
Уңга, сулга аумыйм, һәнүз алга барам,
Юлда манигъ (киртә) күрсәм, тибәм дә аударам;
Каләм кулда була торып, яшь шагыйрьгә,
Мәгълүмдер ки, курку белән өркү харам [1, б. 175].

Тукай хәзерге татарларның элгәрләре дип монгол-татарларны түгел, ә болгарларны саный, шуны башкаларга да аңлатырга омтыла.

Искәрмә ясап әйтергә кирәк: Г. Тукай яшәгән чорда безнең элгәрләребез болгарлардан гына тора дип уйлаганнар. Болгарның мишәрләр генә икәнен, урта диалектта сөйләүчеләрнең *косан* (ак сөннәр, ак һуннар) дип аталганлыгын әле белмәгәннәр.

«Әлгасрел җәдит» журналына реклама итеп язылган «Гыйлемнең бакчасында» шигырендә менә шундый юллар бар (хәзерге телгә тәрҗемәсе бирелә):

Безне дәүләтләр хайван санамасыннар дип,
Кыю һәм батыр рәвештә алга хәрәкәт итик.
Теләсәк яшәргә, хаклы икәнебезне исбат итик;
Дәлилләр китереп, каршыларны сүздән туктатыйк.
Дөньяда болгарлар әле дә бар икәненә ышансыннар;
Якты бәхетебезгә көнләшсен һәм үзләре дә омтылсыннар [1, б. 25].

Үзенең «Халык әдәбияты» дигән публицистик әсәрендә Тукай болгарларны безнең элгәрләребез дип тагын белдерә. Анда аның шундый юллары бар: «Халык җырлары – безнең бабаларымыз тарафыннан калдырылган иң кадерле вә иң бәһале бер мирастыр. Әйе, бу кадерле мирас, кыйммәтле мирас! Мәгъмүр болгар шәһәрләре, болгар авыллары, бер дә булмаган төсле, кырылдылар да беттеләр, эзләре дә калмады. Әмма менә бу кыйммәтле мирас дидекемез халык шигырьләрен туплар да ватмады, уклар да кадамады [4, б. 173–174]. Бу өзектә болгар авылларын һәм шәһәрләрен җир белән тигезләгән монгол-татар агрессорларына тискәре караш та чагыла.

Үз халкының борынгылыгына сагыш белән язылган «Милли моңнар» әсәрендә дә шагыйрь боларны искә алмыйча калмый.

Хәйран булып җырны тыңлап тордым,
Ташлап түбән дөнья уйларын;
Күз алдымда күргән төсле булдым
Болгар һәм Агыйдел буйларын [2, б. 55].

Г. Тукайның гомере буе халкыбызның этник тамырлары белән кызыксынуы турында тарихчы Ф.Н. Шәкүров шагыйрьнең 110 еллыгы конференциясендә сөйләгән «Тукай иҗатында тарих» дигән докладында шундый бер мәгълүмат бирә. Г. Тукай тормышының соңгы атналарында Фатих Әмирханга хат яза, бер гарәпчә шигырьгә ияреп, Шиһабетдин хәзрәт тарафыннан Болгарның мәчет манарасы турында язган бәетен җибәрүне сорый. Фатих Әмирхан, бу бәетне табып, Тукайга җибәргәнме-юкмы, билгесез. Ләкин докладчы Ф.Н. Шәкүров бу бәетне таба һәм үз докладу текстында аны татарчага тәрҗемә итеп бирә:

– Әйтерсең, бу манарадан мөәзиннең, Аллаһыны зикер итеп,
Турылыкка чакыручы авазы күтәрелмәгән!
Әйтерсең, яшәмәгән Болгарда Аллаһыны бер санаучы
Мөэмин, булмаган изгелекне таратучылар!
Дәшмә, яман! Чынлыкта алар гомер-гомергә монда яшәделәр.
Күңелем иркендә – бөек гасырлар...
Болгарның рәхәт искән ягымлы җиленә сәлам!
Мосафирлар йөрәгендә моң-хәсрәтләр кузгата алар [9, б. 237–235].

Бу тексттан Шиһабетдин Мәрҗани да, Г. Тукай да халкыбызны монгол-татардан килә дип түгел, ә гомер-гомергә шушында яшәгән җирле төркиләр-болгарлар булганнар дип тасвирлыйлар.

Г. Тукайның бу карашлары турында сөйләгәндә, тыңлаучылар еш кына сорау бирәләр:

– Тукай боларны ничек белгән, кайдан алган? Билгеле, Тукайның ике чыганагы булган: беренчесе – халыкның үзендә сакланган мәгълүматлар, икенчесе – шул чордагы рус һәм болгар чыганаклары. Рус чыганаклары бик күп, шуңа күрә аларны биредә санап чыгу мөмкин түгел. Шул чыганакларны файдаланып, танылган археолог А.П. Смирнов халкыбыз тарихы буенча шундый нәтиҗә ясый: «Монголлар, Идел Болгарын ут һәм кылыч белән айкап чыктылар, ләкин хәзерге татарларның физик кыяфәтләренә сизелерлек йогынты ясамадылар. Монгол-татарлар басып алгач та болгарлар үз исемнәрен озак сакладылар... Рус елъязмалары да аларны татар дип түгел, болгар дип теркәп килделәр. Мәсәлән, 1311, 1366, 1370, 1374–1391 еллардагы вакыйгаларны тасвирлаганда, Никон елъязмасы болгарларны бер генә дә татар дип атамый, *болгар*, *косан* (*казанцы*) яки *бесермян* дип атый. Хәтта XV гасырда да Федор Пестрый походын тасвирлаганда, елъязма халыкны болгар дип белә» [8, б. 14].

Габдулла Тукайның халкыбыз монгол-татарлардан тормый, аның болгар дигән тирән җирле тамыры бар дигән карашы Гаяз Исхакыйның тарихи фикерләре белән туры килә. Бу бөек затларыбызны тыңлау, аларның фикерләренә таянып эш итү безнең тарихчыларыбыз өчен мактаулы эш булып саналырга тиеш иде кебек.

Ләкин күп кенә тарихчыларыбызның, халкыбызны монгол-татар белән тиңләүне үзләренең мактаулы бурычы дип саныйлар. Алар урдачылар исеме астында болгарчыларга каршы көрәш оештырдылар. Болгарчылар халкыбызны янәсе бик кечкенә Болгар дәүләте белән бәйлиләр, ә урдачылар халкыбызны бик зур территорияле Алтын Урда эчендә карыйлар. Беренчедән, Алтын Урда болгарларны гына түгел, башка төрки дәүләтләрне дә берләштерә. Икенчедән, монгол яуларына кадәр Болгар дәүләте бик киң территорияне алып торган: аның көнбатыш чикләре Борынгы Русьның көнчыгыш чикләре белән туры килгән; төньяк чикләре элекке Биармиянең төньяк чикләре Төньяк Двинадан Печера елгасына кадәр булган [6, с. 22]; көнчыгыш чикләре Иртыш һәм Тубыл тирәләреннән үткән; көньяк чикләре Хорезм чикләре белән тоташкан [5, б. 151–160].

Хәзерге татарларның һәм монгол-татарның бер үк булулары турында урдачылар фикере чит илләрдәге тарихчылар тарафыннан яңартылып тора, сәбәбе – хәзерге татарның абориген икәнлеген инкяр итү, аларның киләчәктә дә яшәү-үсүләрен шик астына кую.

Урдачыларның тагын бер уйдырмасы шунда, алар Болгар шәһәрендә Батый ханның беренче ставкасы булган дип ялган тараталар. Чынлыкта болгарлар Батый ханның беренче һөҗүмнәрен Жигули таулары янында туктаталар, шуңа күрә Батый хан җиңүгә ирешкәч, Болгарга әйләнеп тә карамый, төп ставкасын Болгар иленең Саксин-Сарай шәһәрендә оештыра.

Рус елъязмаларының хәбәренә караганда, болгар ханы һәм рус кнәзе 1242 елда, үз илләре белән идарә итәргә рөхсәт сорап, Саксин-Сарай шәһәренә Батый хан янына баралар. Батый хан ставкасы Болгарда булса, болгар ханы рус кнәзе белән бергәләп Саксин-Сарайга барып йөрер идемени? [7, б. 158–159]. Батый ханның Болгарга булган тискәре карашы аның дәвамчыларына да барып җитә. Шундый дәвамчы Мәнгү Тимур Болгарны туздыруны Сморленски һәм Ярослав кнәзе Федор Ростиславовичка йөкли. 1277–1278 елда Болгар туздырыла, моның өчен Мәнгү Тимур Федор Ростиславовичка үзенең кызын бирә һәм 36 болгар шәһәрен бүләк итә [10, с. 164].

Җирле төрки кабиләләр берләшмәсеннән торган болгарлар монгол-татарлардан бернинди этник, антропологик, культура һәм тел үзенчәлекләрен алмаганнар, ләкин бик күп еллар үткәч, монгол-татарчылар көче белән болгар халкына *татар* атамасы керә. Әмма хәзер чит ил мәктәпләрендә, рус вузларында укыган татар яшьләре *татар* этнонимыннан читләшергә тырышалар, алар халкыбызның этник тамырлары җирле булуы белән горурланалар.

ӘДӘБИЯТ

1. Габдулла Тукай. Әсәрләр. Биш томда. 1 том. Шигырьләр (1901–1908). Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 407 б.

2. Габдулла Тукай. Әсәрләр. Биш томда. 2 том. Шигырьләр. Поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 400 б.

3. Габдулла Тукай. Әсәрләр. Биш томда. 3 том. Проза. Публицистика (1904–1906). Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 391 б.

4. Габдулла Тукай. Әсәрләр. Биш томда. 4 том. Проза. Публицистика.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 351 б.

5. Закиев М.З. История татарского народа. Этнические корни, формирование и развитие. М.: Инсан, 2008. 560 б.

6. Карамзин Н.М. История государства Российского. Кн. 1. Т. I, II, III, IV. (СПб. 1842). М., 1988.
7. Риза Бариев. Волжские булгары. История и культура. СПб., 2005. 302 с.
8. Смирнов А.П. К вопросу о происхождении татар Поволжья // Происхождение казанских татар. Казань, 1946. С. 5–26.
9. Шәкүров Ф.Н. Тукай иҗатында тарих // Тукай и духовная культура XX в. (Материалы научной конференции, посвященной 110-летию со дня рождения Тукая). Казань, 1997. С. 233–238.
10. Шпилевский С.М. Древние города и другие булгаро-татарские памятники в Казанской губернии. Казань, 1877.

## Ә. ЕНИКИ ҺӘМ С. КУДАШ Г. ТУКАЙНЫҢ ДӨНЬЯГА КАРАШЫ ХАКЫНДА

***Идрисов Р.Р.***

Личность и творческое наследие классика татарской литературы, основоположника национальной словесности и современного литературного языка Габдуллы Тукая оставались в центре внимания в течении столетия. В зависимости от общественно-политической обстановки в стране творчество и взгляды поэта оценивались в угоду господствующей идеологии. После воинствующей антирелигиозной пропаганды 50–60-х годов прошлого столетия в 1971 году вышла книга «Атеизм Тукая». Против явного искажения правды смог публично выступить только А. Еники, и его поддержал в своем письме собрат по перу в Башкортостане С. Кудаш. Этот смелый поступок логически вытекал из гражданской позиции и зрелости личности писателя.

Personality and creative heritage of the founder of the Tatar classic literature and the modern language of Gabdulla Tukay remained in the centre of attention during a century. In dependence of socially-political situation in the country creativity and views of the poet were estimated in favor of the dominant ideology. In 1971 a book «Tukay's atheism» was published after the militant antireligious propaganda of the $50^{th}$–$60^{th}$ years of the last century. Only A. Enikey could speak publicly against a clear distortion of the truth and he was supported by his fellow S. Kudash in Bashkortostan. This brave action followed his citizenship and maturity of the writer's personality.

1960 нчы еллардан башланган әдәбиятыбыз үсешенең яңа чоры каршылыклы үсеш еллары булып тарихка керде. Гомумән, ул рәсми рәвештә «Киң колач белән коммунизм төзү», «Җитлеккән социализм», «Җепшеклек һәм торгынлык» чоры әдәбияты кебек исемнәр алса да, аның төп эчтәлеген сталинизмнан арына башлау дәвере итеп күзалларга мөмкин булыр иде. Әдәбият галиме һәм язучы Сәгыйдулла Хафизов аны «Каршылыклы үсеш еллары» дип бик дөрес атаган иде. Бу чорның рухи тормыштагы бер зәхмәте – ул Хрущев хакимияте сәясәтендәге сугышчан дәһрилек пропагандасы. Дин, милләт кебек төшенчәләр җуелып, бердәм совет халкы төзү максат итеп куелды. Моның өчен милли шәкелдәге, социалистик эчтәлекле һәм интернациональ рухтагы әдәбият барысын да эшләргә тиеш иде. Кызыл язучылар, кызыл әсәрләр, купшы кызыл сүзләр фонында иман-кыйбланы һәм шәхес бөтенлеген саклап калу ифрат авырлашты. Идеологик басымның бер чагылышы булып, өлгер галим З. Ишмөхәммәтовның 1971 елда «Тукай атеизмы» дип аталган китабы басылып чыга. Тукайны атеист итеп раслаган бу фальсификация Еникине битараф калдыра алмый, һәм ул язучылар җыелышында бу китапны бик көчле дәлилләр белән тәнкыйтьләп чыгыш ясый. Соңрак «Ялганны яклау» дип аталган мәкаләсендә ул (1992), С. Кудашның хатындагы дәлилләрне дә китереп, үткәндәгегә хисап биреп, аның сабакларын искә төшерә. Соңрак бу мәсьләгә Ф. Галимуллин һәм Ә. Закирҗановлар игътибар итте һәм әдипнең гражданлык позициясен, егетлеген һәм әдип тантанасын характерлый торган гамәл буларак билгеләп үттеләр [1, б. 7, 20].

Тукайның Аллаһыга мөнәсәбәте бүген ниндидер бәхәс уятмый, шулай да Еникинең үткән гасырның 70 нче елларында – торгынлыкның иң җәелгән чорындагы рухи кыюлыгы сокландырмый калмый. Каян көч алган соң Еники шул битарафлык диңгезендә берүзе рәсми идеологиягә каршы чыгарга? Нинди рухи маяклар аның кыйбласын тотып торган, рухи көч-куәт һәм дәрт-дәрман биргән? Бу мәсьәләләр, кызганычка каршы, бүген дә актуальлеген югалтмый.

Еникинең берүзе агымга каршы сүз әйтә алуы аның шәхси кыйбласының ачыклыгыннан киләр. Бу чорда партия идеологиясе һәм пропагандасы белән халык аңлаган тормыш хакыйкате арасындагы каршылык чорның төп конфликтын тәшкил итә. Шул ике чик арасында бәргәләнә әдипнең намус кошы. Еникинең чор идеологиясе белән

катлаулы мөнәсәбәтләре нигезендә аның иҗат мәсләге ята. «Иҗат эше минем өчен башта шәхси эш, өзлексез уйлану белән бәйләнгән күңел һәм намус эше иде. Мин бары үзем белгәнне, үзем ышанганны гына язарга тиеш дип уйлый идем. Ләкин бер бәхәс чыкканда миңа әйттеләр: син үзең белгәнне, үзең уйлаганны эчеңдә калдыр, ә безгә без таләп иткәнне яз!», – диделәр. Әмма үз күңелемдә булмаганны заказ буенча язу? – Юк, мин моны аңлый да, кабул итә дә алмый идем», – дип язды ул [2, б. 474].

Әдипнең үз чыгышлары һәм көндәлекләрендәге язмаларга караганда, Еникигә гадел булмаган тәнкыйть чыгышларына бирешмәскә эчке инанганлык, гражданлык позициясе, хакыйкатьне белү, ышанычлы фикердәшләре булу, рухи ныклык һәм үз кыйбласына инанганлык ярдәм итә. Намус һәм вөҗдан хөкеме, рухи төшенкелектән саклап алып калып, аңа җан тынычлыгы бирә һәм яңа иҗади эзләнүләргә этәрә.Үз иҗатына карата булган тискәре караш-бәяләрне ул үз тәнкыйте күзлегеннән карый һәм аларны дөрес бәяләү биеклегенә күтәрелә ала. Шуңа да аның рухи кыйбласы һич кенә дә какшамый, тик көнкүреш хәлләрендә, кәеф мәсьәләләрендә генә авырлыклар өстәлергә мөмкин була. Һәм, әлбәттә, гадел булмаган мөнәсәбәт күңелне кыра, үпкә-рәнҗеш хисе тудырмый калмый. Ләкин бу кичерешләр, никадәр генә авыр булмасын, иҗат әһеленә кеше күңеленең төпкелләрен байкарга, психологик үзенчәлекләрене тирәнрәк аңларга ярдәм дә итә. Шәхси планда кыерсытылу, кимсетелүләр иҗади активлыкка да этәрә, – әдиптә гаделлеккә сусауны кандыру аша хаклыгыңны раслау теләген көчәйтә. Моны эчке эмиграциягә китү, оппозициядә булу, үзенчәлекле татар диссидетлыгы, дип әйтергә ярыйдыр.

Еникинең Тукайның иманын яклап көрәшкә ташлануы шундый рухи каһарманлыкның чагылышы итеп санала ала, безнеңчә. Әдипнең әхлакый йөзе аның басылырга исәпләнмәгән, көндәлекләрендә теркәлгән язмаларында күренә: «Язучыны күкләргә чөеп мактау өчен аның чын мәгънәсендә талантлы әсәр язуы һич тә шарт түгел. Иң мөһиме – начар булса да күп булсын! Ә син үзең шома, тәти егет булырга тиешсең». Шунда ук Еники өстәп куйган: «Иң яратмаган нәрсәм – ярарга тырышу...» Монда ук әдип зыялылыкның төп формуласын да язып куйган: «Язучы һәрвакытта критически уйларга тиеш. Ходай аңа үзе шулай кушкан». Шул ук дәфтәрдә Еники, тәнкыйть тарафыннан күпме генә битәрләнүенә карамастан, мондый фикер-инануын белдерә: «Язган әсәрем өчен үкенгәнем булмады диярлек, әмма сөйләгән сүзләрем өчен үкенгәнем күп булды». Әдипнең рәсми тәнкыйтькә, идеологиягә мөнәсәбәтеннән бер нәрсә аңлашыла: Еники аның иҗатны буып торуы, иҗат ирегенең талантка кирәклеге, әдәбиятның үсешен тәэмин итүе хакында тәкрарлый. Һәм шунда әдип үз позициясен бик ачык белдерә дә. 1956 елда ук көндәлегенә ул мондый юллар яза: «Мин җиз төймәле швейцар мундиры кигән һәм «ләббәйкә» дип, баш бөгеп торган язучы түгелмен – менә ни өчен шәхес культы рухы белән агуланып беткән әдәбияттагы диктаторлар мине яратмыйлар. Әйе, мин кагылган да, сугылган да кеше, бигрәк тә « Х.» кебек полицайлар тарафыннан, шуңа күрә минем настроением идиотларныкы кебек ваемсыз, уйсыз түгелдер... Ләкин бу әле идеалым юк, минем якты кәгъбәм юк дигән сүз түгел: «Бар ул: ул минем халкым, халыкка булган мәхәббәтем».

«Җанлы, аяклы хакыйкать» (С. Хафизов) Тукайны яклап чыгуда әдипнең вөҗдан һәм намус колы булып яшәве дә төп рольне уйнаган булырга тиеш. «(«Вөҗдан» повестен искә алыйк). Еники бер-берсенә якын торган намус һәм вөҗдан төшенчәләрен аерып карый иде. 1994 елгы бер әңгәмәбездә ул болай диде: «Вөҗдан ул – югары хөкем. Синең эшеңне, гамәлеңне хөкем итүче. Бер дә ярамаган эш эшләсәң, вөҗдан газаплана, рәнҗи, ачуы килә. Ә намус ул – яраган белән ярамаганны аера торган төшенчә. Намус белән вөҗдан – борын-борын заманнан, Адәм пәйгамбәрдән үк, кешенең җанына салынган сыйфатлар. Гадәттә, вөҗдан һәм намус күбрәк дин белән бәйләнгән, Аллаһыга ышанган кешеләргә хасрак нәрсә инде ул» [3, б. 44].

Шулай ук Тукайның иманын яклап чыгуга этәргән икенче бер сәбәп, әлбәттә, – әдипнең үзенең дингә, Аллаһыга һәм дин әһелләренә анык позициясе. Бу хакта ул гомеренең соңгы чорында болай дигән иде: «Эш Аллага ышануга гына кайтып калмый. Мин Алланы инкарь иткән кеше түгел. Чөнки ул минем көчемнән дә килми. Дөньяның, табигать, галәмнең серләре ачылып бетми торып, аның юклыгын исбат итү мөмкин дә түгел. Аңа ниндидер бер кодрәт иясе итеп карау да бар...Менә шул кодрәт иясенә ышану сакланачак дөньяның бөтен серләре ачылып бетми торып. Аллага гади кешеләр генә түгел, бик күп галимнәр дә ышана. Чит илләрнең барлык галимнәре дә дин тота. Аның икенче ягы да бар бит әле. Шәригать кануннары бар. Нәрсә – савап, нәрсә –

гөнаһ. Ул инде кешеләрне тәрбияләү законнары. Шәригатьнең тәрбияви әһәмияте бик зур. Һәм аңарга каршы чыгарга кирәкми... Бөтен бәлә шунда: аның әле мәчете дә бар, мәктәп-мәдрәсәләр дә ачыла. Ләкин диннең зур галимнәре, белгечләре юк дәрәҗәсендә аз. Революциягә кадәрге Муса Бигиев, Зыя Камали, Хәсәнгата Габәши, Шиһабетдин Мәрҗәни, Риза Фәхретдинов кебек диннең фәлсәфәсен, тәгълиматын белүче кешеләрер бик аз бүгенгебездә» [4, б. 36].

Дингә, дин әһелләренә мөнәсәбәттә Тукай белән карашлар уртаклыгы да Еникине шагыйрьне яклауга китергән дип исәпләү дә дөреслеккә туры килергә мөмкин. Халкы язмышын кайгыртучы әдип бакыйлыкка күчәргә берничә көн кала дусты Фуат Маннаповка болай ди:» Дин сәясәткә хезмәт итмәскә тиеш, аның эше тәрбия, югары әхлак, яхшылыкка өндәү. Аның үз вазыйфасы, үз эше. Сәясәткә буйсынып, ул үзенең югары вазыйфасын югалта, тәрбияләүче була алмый. Мәчет тирәсендә яхшы кешеләр дә бар, ләкин алар күп түгел, азчылык...Әхлакый яктан түбән, белем ягыннан наданнар күп. Үз файдасы өчен генә тырышучы кешеләр күбәебрәк китте» [5, б. 4].

Соңгы әсәре булган «Юбилей сабаклары»нда да Еники нәкъ Тукайча Аллаһыга сыена:» Әмма үлемнең никадәр әшәке нәрсә икәнен белсәм дә, үземдә бернинди курку-каушау кебек борчылу сизмим. Гаҗәп мин бик тыныч... Моның сәбәбе – тәкъдиремне бер Аллага тапшыруда түгел микән?!» [6, б. 466].

Еникинең Сәйфи Кудашка язган хатында мондый юллар бар: Мин әйтергә тырыштым: Тукай ишан-муллаларны бик каты тәнкыйть иткән, диннең үзенә дә тел тидергән. Әмма Тукай Алланы инкарь итмәгән, Аллага ышанган, дидем... Хөрмәтле Сәйфи ага! Сез мине гафу итегез инде, кинәт кенә сезгә эчемне бушаттым да куйдым. Монда, үзебездә беркем белән дә сөйләшә алганым юк. Берәү дә килми дә, дәшми дә...» [7, б. 3]. Һәм Еники рухи теләктәшен Башкортстанда таба. Җавап хатында С. Кудаш дустын тынычландыра: «Әгәр дә мин шул җыелышта булган булсам, үз карашымны чыгып әйтмичә чыдап кала лмаган булыр идем... Мин мондый вакытларда тамашачы булып кына кала алмыйм. Чөнки Тукай мәсьәләсе безнең – үз язмышыбыз. Тукай халкыбызның вөҗданы, намусы һәм иманы...» Тукайның халыкның сөекле шагыйре булып китүенең сәбәбен дә С. Кудаш илаһилык белән өретелгән шигырьләреннән күрә: «Тукайның халыкның күпчелеге тарафыннан шулай бик тиз танылуын, сөелүен һәм табыну дәрәҗәсендә культка әйләнүен мин үзем шушы рухтагы шигырьләрнең катнашуыннан башка күз алдына да китерә алмыйм... Алар дини, илаһи булулары белән генә түгел, бәлки балаларда сафлык, пакьлек, тугрылык, намуслылык һәм ата-аналарга – олыларга хөрмәт тойгылары тәрбияләүләре белән әһәмиятлеләр. Коры дидактикага корылган иске мөнәҗәтләр үзләренең ... ялангач вәгазьләре белән балаларда курку тойгылары гына уяталар иде», – ди ул [7, б. 3].

Теләктәше С. Кудаш хатыннан соң «бөек шагыйрь турында бары тик саф дөресен язу кирәклеге өчен» тырышкан Еники үзе өчен бик мөһим ачыш та ясый:» Татар халкы бит күпме гасырлар буена Аллага инанып яшәгән, авыр язмышын да, киләчәккә ышанычын да Аллага баглаган, һәм бу аның какшамас иманына әверелгән. Менә шуны бик яхшы белгән, бөтен барлыгы белән тойган Тукай да, билгеле инде, халыкның иманына тугрылыклы булып калган» [6, б. 115].

Заманында гражданлык батырлыгы үрнәге күрсәткән Еникинең мәкалә ахырындагы кисәтүе бүген дә бик актуаль яңгырый: «Әнә шул рәвешчә, моннан егерме ел элек мөхтәрәм язучыларыбыз җан тынычлыгы саклау өчен һәм безне биләп алган рәсми идеология хакына, Тукай турындагы ялганны, теләпме-теләмичәме, күмәкләшеп якларга мәҗбүр булдылар. Дөреслектән качуны мин башкача аңлый да алмыйм, аңлата да алмыйм» [6, б. 117].

Гомере буена «Тукайчы» булып калып, аның гражданлык идеяләрен катлаулы елларда саклап дәвам итә алган Ә. Еникинең васыяте һәм сабаклары шулардан гыйбарәт.

ӘДӘБИЯТ

1. Әмирхан Еники һәм 20 йөз әдәбияты. Казан: РИО «Школа». 424 б.

2. Еники Ә. Соңгы китап: истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 504 б.

3. Идрисов Р. Иман-кыйбласына тугры әдип // Тулпар. 2009. № 2. Б. 44–45.

4. Гыймазова В., Идрисов Р. Әмирхан ага Еники сабаклары// Тулпар. 1999. Б. 32–37.

5. Идрисов Р. Без китәбез, сез каласыз// Өмет. 2000. 25 март. Б. 4.

6. Еники Ә. Әсәрләр: 5 томда. 5 том: Публицистик язмалар, мәкаләләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 479 б.

7. Кудашева С. Тукай үз халкы һәм заманы шәхесе // Кызыл таң. 2000. 26 апрель. Б. 3–4.

# XX ГАСЫР БАШЫ ТАТАР СУФИЧЫЛЫК ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ СТИЛЬ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

## (Г. Тукай һәм Дәрдемәнд иҗатлары мисалында)

***Йосыпов А.Ф.***

В истории татарского народа суфизм занимает особое место, именно поэзия стала своеобразной ареной для пропаганды теологических, философских, суфийских воззрений. Суфизм способствовал и развитию языка, в котором сформировался стилистически разработанный сложный технический язык. Язык суфийских произведений Г. Тукая и Дардменда отличается необычайной образностью и экспрессивностью, разнообразием стилистических средств и фигур (метафоры, сравнения, символы и т.д.). В таких произведениях прослеживается тенденция сближения мотивов суфийской поэзии со сферой «возвышенного» поэтического стиля.

Sufism takes special place in the history of the Tatar people. It was the poetry that became a unique space for propaganda of theological, philosophical and sufi views. Sufism fostered the development of the language which became a basis for stylistically developed and technically complex language. The works of such sufi poets like G. Tukay and Dardmend are characterized by unusual figurativenest, expressiveness, a variety of stylistic means and figures (metaphors, similes, symbols, etc.). There is a tendency of convergence of Sufi poetry motives with the realm of sublime poetic style.

Татар әдәби теле тарихында XIX йөз ахыры – XX йөз башы зур үзгәрешләр һәм тел тирәсендә барган көрәшнең иң кызган чагы буларак билгеләнә. Шул ук вакытта XX гасыр башында халыкның сөйләм теленә нигезләнгән татар әдәби теле формалашып җитә һәм «матур әдәбиятның жанр һәм стиль ягыннан баюына, функциональ стильләрнең формалашып җитүенә китерә» [6, б. 196].

Бу чор татар әдәби теле нормаларының формалашуы, үзенчәлекләре хакында сөйләшү барышында суфичыл әсәрләр дә үзәктә тора. XX йөз башы суфичыл характердагы әсәрләр телендә XIX йөз татар суфичылык шигърияте теленә хас лексик-стилистик чаралар, грамматик формалар һәм жанр үзенчәлекләре күзәтелә; стилистик вариантлылык максатында классик шигъри тел һәм суфичылык әсәрләре теленә хас тел үзенчәлекләре кулланыла. Әлбәттә, бер мәкалә чикләрендә генә суфичыл әсәрләрнең телен тулаем тикшерү, анализлау мөмкин түгел, бу материалда стилистик вариантлылык нигезендә сурәтләү чарасы булып киткән грамматик формалар һәм еш кулланыла торган кайбер стиль чараларын тикшерү максат итеп куела. Әлеге үзенчәлекләр ике шагыйрь – Г. Тукай һәм Дәрдемәнднең суфичыл әсәрләре мисалында өйрәнелә.

Бу чор татар поэзиясендә Г. Тукайның «Алла гыйшкына» (1905), «Ифтиракъ соңында» (1905), «Гыйшык бу, йа!..» (1906), «Мәхү идәрмисән?» (1906), «Сөеклекнең кабер ташында» (1906), «Мәхәббәт» (1908) һ.б. әсәрләре әдәбият белгечләре тарафыннан суфичыл характердагы әсәрләр буларак билгеләнә. Дәрдемәнднең «Җәй үтте...», «Бүзләрем маналмадым...» (1908), «Хәят», «Ятам кайчаклары моңлап...», «Рәсем» һ.б. шигырьләрендә дә суфичыл символ һәм идеяләр алга куела.

Инглиз белгече Аннемари Шиммель билгеләп үткәнчә, «суфичылык тел үсешенә дә зур йогынты ясый: юристлар, дин белгечләре һәм тәрҗемәчеләр суфичылыкка хас әйләнмәләрне тел өлкәсенә алып кереп, гарәп телен баета һәм камилләштерә, аны сыгылмалы итә, мәгънә җиткерү мөмкинлекләрен киңәйтә». Поль Нвийа мистикларның «аутентик» тел барлыкка китерүен ачыклый һәм нәкъ менә мистиклар ярдәме белән гарәп телендә күп мәгънәле, яшерен эчтәлекле сүзләрнең артуын билгели. Аның фикеренчә, суфичылык текстларында тел-сурәтләү чаралары гади, бизәк чарасы булудан туктап, мәгънә тирәнлеген, мистик эчтәлекне җиткерү баскычына күтәрелә. А.Шиммель суфичыл әсәрләр телен «стилистик яктан катлауландырылган техник тел» [7, с. 50] буларак билгели. Н. Пригарина фикеренчә, мондый стилистик катлаулылык көнчыгыш шигъриятендә XI–XII гасыр чикләрендә канун дәрәҗәсенә күтәрелә һәм гадилек инде түбән стиль буларак кына кабул ителә башлый [4, с. 95]. Бу фикер татар теле мисалында да раслана ала, татар суфичылык поэзиясе телендә дә тел-сурәтләү чаралары, образлылыкның үзәктә торуы күзәтелә [8, с. 222].

Без өйрәнүгә алган алган авторларның берсе – Г. Тукай – XX йөз башында әдәби тел үсешендә барган үзгәрешләрне аңлап кабул иткән хәлдә, суфичыл характердагы әсәрләренең теле күпгасырлык классик шигъри язма традицияләргә нигезләнә. «Традицияләрнең кинәт кенә юкка чыкмавын да истән чыгарырга ярамый. Әдәби телне

халыкка аңлашылмаган чит формалардан арындыру, халык теленә нигезләү өчен билгеле бер аралык кирәк. Саф татар телендә язылган әсәрләр булу өстенә, К. Насыйри һәм Г. Тукай кебек күренекле шәхесләрнең әсәрләрендә борынгы традиция җирлегендә чыгтай, төрек, гарәп-фарсы элементларының шактый урын алуы нәкъ шуның белән аңлатыла» [6, б. 190].

Мәсәлән, аның мондый әсәрләре телендә күплек мәгънәсен белдерүдә татар телендә хас булган ике ысул кулланыла: морфологик һәм лексик-синтаксик. Күплек санының *морфологик ысулында* сүзнең нигезенә *-лар/-ләр* аффикслары ялгана:

*Сән дәгелсең анларың* ***җанлар*** *алан Газраили.*
(«Мәхү идәрмисән?»).

Күплекнең *лексик-синтаксик ысулында* исемнәрнең аергычлары функциясендә микъдар саннары яки күплек мәгънәсен белдерә торган аерым сүзләр кулланыла. Г. Тукайның тикшерелә торган әсәрләрендә мондый сүзләр вазифасында гарәп алынмалары актив:

*Бу юла һиммәт итик, и өммәт, алла гыйшкына;*
*Буйлә һиммәт безгә* ***җөмлә сөннәт*** *алла гыйшкына.*
(«Алла гыйшкына»).

*Дәмбедәм илһам итәр дәрдең бәңа гыйльмел-гаруз;*
*Нә кадәр яздымсә – яздым* ***җөмлә илһамыңлә*** *бән.*
(«Ифтиракъ соңында»)

Билгеле булганча, мондый әсәрләрдә «сынык» күплек саны формасындагы гарәп исемнәре кулланыла. Билгеле булганча, гарәп телендә «сынык» күплек саны формасы сүзнең эчке төзелеше үзгәрү юлы белән. Мәсәлән:

*И җамилә! Гыйшкыңызда бунча* ***әшгар*** *сөйләдем*;
(«Мәхү идәрмисән?»).

*Бән дә* ***әнварең*** *илә парланаем, парланаем.*
(«Гыйшык бу, йа!..»).

«Төрки-татар теле өчен әдәби норма булган күплектәге исемнәрнең һәм гарәп-фарсы телендә әдәби булган күплектәге исемнәрнең кулланылышында функциональ-стилистик вариантлылык күзәтелә, ягъни алар төрле текстларда төрле дәрәҗәдә кабатлана, төрле микъдарда сайланып алына... Алынма сүз һәм сүзформаларның ешрак кабатлануы ... Г. Тукайның башлангыч чор иҗатында күзәтелә, димәк, боларның барысында да күплек сандагы гарәп-фарсы алынмалары да махсус рәвештә сайланып файдаланыла» [1, б. 13].

Суфичылык әсәрләре телендә ***теләк фигыльнең*** хәзерге татар әдәби телендә кулланылмый торган күп кенә формалары сакланып калган. XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби телендә теләк фигыль угыз һәм кыпчак телләренә хас булган ике әдәби тел нормасында кулланыла, аерым графемаларның төрлечә язылышында чагылыш табып, графофонетикага нигезләнгән һәм, бер үк морфеманың төрле контекстта төрле вазифа үти алуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән, графоморфологик вариантлылык хасил итә.

Язма текстның яки стильнең яисә шул стильнең нинди дә булса бер жанр-төренең таләбе белән, кайсы да булса бер чараның махсус рәвештә сайланып алынып, ешрак кулланылуы, теләк фигыльнең функциональ-стилистик вариантлылыгы булып кабул ителә [1, б. 160].

Сөйләүченең теләген һәм ниятен белдерү өчен, тикшерелә торган әсәрләрдә *-айым/-әйем* угыз-төрек формасы кулланыла:

*Бер гидае, җан фидаем, гыйшкыңа* ***пәрванаем;***
*Кәл, гүзәл, гарз ит җәмалең: янаем, кил* ***янаем.***
(«Гыйшык бу, йа!.. »)

Хәзерге вакытта теләк наклонениесенең *-алым/-әлем* формасы төрек телендә генә сакланып калган. Татар әдәби телендә әлеге форма сакланмаса да, галимнәр билгеләвенчә, XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар язучылары телендә актив булганлыгы билгеле Теләк наклонениесенең *-алым/-әлем* формасы төрле фонетик вариантларда татар теленең аерым сөйләшләрендә очрый.

Тикшеренүләр Г. Тукай әсәрләре телендә теләк наклонениесенең *-айым/-әйем* формасы актив булуын күрсәтә: шагыйрьнең «Гыйшык бу, йа!.. » әсәре тулысынча әлеге форманың кабатланып килеп, ритм-рифма тудыруы нигездә язылган.

Шул ук вакытта теләк фигыльнең хәзерге татар әдәби теленә хас булган формасы да кулланыла:

***Җанланыйк**, баш **кузгатыйк** һәр йирдә алла гыйшкына.*
(«Алла гыйшкына»).
***Калдырыйк** бу галәми дәр хәйрәт алла гыйшкына.*
(«Алла гыйшкына»).

Шулай итеп, теләк наклонениесенең хәзерге татар теленә хас формасы һәм *-айым/-әйем* угыз-төрек формасы кабатланып килеп, функциональ-стилистик вариантлылык тудыра; әсәр телендә билгеле бер форманы еш куллану һәм стиль хаталарыннан арындыра.

Тикшеренүләр суфичылык әсәрләре телендә *күчерелмә мәгънә белән бәйләнешле стилистик алымнарның* аеруча киң кулланылуын күрсәтте. Галимнәр фикеренчә, суфичыл поэзиядә символ, метафора көчле һәм символик образлар, гомумән, суфичылык әдәбиятының үзәгендә торган стилистик алымнарның берсе. Шуңа да суфичылыкның «символлар бирелеше ноктасыннан гадилектән нәфис стильгә таба үсеш кичергән» [10, с. 209] татар поэзиясен мәгънә һәм символлар ягыннан баетуда өлеше зур була, ул «моңа кадәр кулланылып килеп, иҗади яңалыгын югалткан клише-образларның мәгънәләрен трансформацияләп, үзгәртеп, дини-суфичыл, фәлсәфи эчтәлеккә төреп тәкъдим итә башлый» [3, с. 96]. Н.И. Пригаринаның фарсы әдәбиятына кагылышлы әйтелгән бу фикере татар поэзиясе мисалында да актуаль яңгырый. XX гасыр әдәбиятының буеннан-буена, гомумән, суфичылык символларының активлыгы, аларның суфи эчтәлектә яки трансформацияләнгән хәлдә кулланылуы күренә [9, с. 284]. Гасырлар дәвамында рухи халәтне, хис-тойгыны җиткерү өчен аның үз төшенчәләре, образлар системасы эшләнә һәм алар үзенә бер мәгънәне беркетә [2, б. 112]. Үзе дә серлелеккә омтылган поэзия суфи авторлар өчен дөньяви һәм яшерен, трансценденталь идеяләрне, фикерләрне, сакраль эчтәлекне җиткерүдә чикләнмәгән мөмкинлекләр ача. Мәсәлән, Хакыйкатьне ирештерү максатыннан *чәч толымы, кол, җан, шәраб,шәм, күбәләк, ай, сөйгән яр* кебек символларга мөрәҗәгать итә, Аллаһ абсолют хаклык, хакыйкать, идеал мәгънәсен ала, еш кына ике катламлы, гадәти һәм символик мәгънәле образларга мөрәҗәгать ителә: исерү хакыйкатькә ирешү, Аллаһ белән кушылу, шәраб – хакыйкать, шәм – Аллаһ, матур кыз, Ләйлә, сәмруг кош та Аллаһ эчтәлегендә кулланылышта йөри, гөл һәм былбыл, шәм һәм күбәләк илаһи, Аллаһка мәхәббәтне белдерүдә файдаланыла. Суфичылык мотивлары, метафора һәм символлары, әлеге әдәбиятка хас стилистик үзенчәлекләр Г. Тукай әсәрләрендә дә урын алалар.

Мәсәлән, Г. Тукайның суфичыл әсәрләре телендә *шәм* һәм *күбәләк, гөл* һәм *былбыл, ай, йөз, матур кыз* кебек тасвирый билге – символлар кулланыла. Шулардан кайбер мисаллар:

*Бер гидае, җан фидаем, гыйшкыңа пәрванаем;*
*Кәл, гүзәл, гарз ит җәмалең: янаем, кил янаем.*
(«Гыйшык бу, йа!..»)

Югарыда китерелгән өзекләрдә *шәм (ут)* һәм *күбәләк (пәрванә)* символик образлары кулланылган. Биредә *шәм* образы туры мәгънәсендә бирелми, ул өзектә *ут – яну* мәгънәсендә аңлашыла.

Тел-стиль чарасы буларак, тасвирый билгеләрнең функциясе бик киң. Алар чынбарлыктагы күренешләрне сәнгатьчә аңлатуга, тирән фикер белән белдерүгә ярдәм итәләр. Билгеле булганча, суфичылык поэзиясендә *гөл* һәм *былбыл* символлары да Аллаһка булган мәхәббәтне аңлатуда кулланыла:

*Кадре гөл былбыл шинас һәм кадре җәүһәр җәүһәри;*
*Итмә тәрҗих бән кеби мәфтүнеңә бер җаһили*
(«Мәхү идәрмисән?»)

Г. Тукай шигырьләрендә Аллаһ белән кушылу идеясе мәхәббәт шигырьләре аша үткәрелә, еш кына сөйгән ярга булган мәхәббәт Аллаһ тәгаләгә мәхәббәт белән тиңләштерелә:

*Аһ, насыл! Без яз идек: сән бән идең, бән сән идем;*
*Калмады бундан әсәр – калды мәгәр шәукың һәнүз.*
(«Сөеклемнең кабер ташында»).

Билгеле булганча, шәрык суфичылык шигъриятендә Аллаһка хатын-кызларга эндәшкән кебек мөрәҗәгать итү киң таралган була. Соңрак көнбатыш һәм шәрык әдәбиятларында хатын-кыз иляһи зат буларак кабул ителә башлый. Г. Тукай шигъриятендә дә мәхәббәт лирикасы ярдәмендә әлеге фикер үткәрелә [5, б. 98–99]:

*Алга сөрсен гашыйкый анчак мәхәббәт камчысы.*
(«Мәхәббәт»).

Дәрдемәнднең иң билгеле «Җәй үтте...», «Кораб» (1908), «Без» (1908), «Бүзләрем маналмадым...» (1908), «Хәят», «Ятам кайчаклары моңлап...» һ.б. шигырьләрен алсак та, суфичыл символларның киң кулланылуы күренә. *Өн, су, мәләк, туй, кояш, шәм, көн, таң, ай, болыт, яз, чокыр, кыш, шоңкар, аккош, җил, тау, талчыбык, яз чәчәге, кырмыска* кебек символлар шагыйрьнең фәлсәфи шигырьләрендә кабатланып килә торган символларга әйләнә. Мәсәлән, «Тиң булырмы йолдыз тулган айга... » шигырендә Дәрдемәнд *йолдыз* һәм *тулган ай* символик образларына мөрәҗәгать итә. Суфичылык символикасы кысаларында *ай – матур кыз – Аллаһ* янәшәлеге күзәтелә.

*Ялвару кирәкмәс, кирәк наз гына,*
*Ул да – урыны белән, аз-аз гына!*

Биредә матур кызга омтылган йолдыз Аллага мәхәббәт тотучы суфины аңлату өчен кулланыла. Моннан тыш Дәрдемәнднең «Рәнеж хәтер...», «Исәрме яз җиләс җилләр», «Булырмы яз, исеп җилләр...», «Җәй үтте...» һ.б. шигырьләрендә *яз* һәм *кыш* символларына еш мөрәҗәгать ителә. Шигырьләрдә алар лирик геройның күңел халәтен җиткерергә ярдәм итә, кеше гомеренең этапларын, мәңгелектәге яшәеш циклларын тәгәлләштерә.

Шул рәвешле, XX йөз башы суфичыл әсәрләр телендә күпгасырлык классик шигъри тел һәм суфичылык әсәрләре теленә хас үзенчәлекләр саклана: рифма чарасы һәм стиль таләбе буларак шигырьләрдә грамматик формаларның функциональ-стилистик вариантлылыгы күзәтелә. Шулай ук суфичылык әдәбиятының төп үзенчәлеге – яшерен мистик эчтәлекне ачу өчен, күчерелмә мәгънә белән бәйле стилистик алымнар, сыйфатлау чараларына еш мөрәҗәгать ителә. Мондый төрдән без метафорик төркемгә (метафора, чагыштыру, символ һ.б.) аеруча басым ясый алабыз.

## ӘДӘБИЯТ


1. Бәширова И.Б. XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби теле: Жанр-стильләре, аерым грамматик категорияләрдә норма һәм вариантлылык. Казан, 2008. 340 б.
2. Заһидуллина Д. Дөнья сурәте үзгәрү. Казан: Мәгариф, 2006. 191 б.
3. Пригарина Н.И. Образное содержание бейта в поэзии на персидском языке // Восточная поэтика. М., 1983. С. 89–108.
4. Пригарина Н. Введение // Суфизм в контексте мусульманской культуры. М.: Наука, Гл. ред. вост. лит., 1989. С. 3–17.
5. Саяпова А.М. Дардменд и проблема символизма в татарской литеретатуре. Казань: Алма-Лит, 2006. 246 с.
6. Хаков В.Х. Тел – тарих көзгесе (Татар әдәби теленең үсеш тарихыннан). Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 295 б.
7. Шиммель А. Мир исламского мистицизма / пер. с англ. Н.И. Пригариной, А.С. Рапопорт. М.: Алетейа, Энигма, 2000. 416 с.
8. Юсупов А.Ф, Юсупова Н.М. Суфизм в средневековой татарской культуре: роль, особенности и модели мира // Филологические науки. Вопросы теории и практики. 2012. № 5(16). С. 219–222.
9. Юсупова Н.М. Возрождение религиозно-суфийской символики в татарской поэзии рубежа XX–XXI веков (на материале поэтических произведений Г. Салима) // Филология и культура. 2015. № 3(41). С. 284–287.
10. Юсупова Н.М., Юсупов А.Ф. Символизация в тюрко-татарской поэзии средневековья и нового времени (на примере суфийских поэтических произведений) // Филологические науки. Вопросы теории и практики. 2015. № 10(52). Ч. 2. С. 209–211.

# Г. ТУКАЙ ӘСӘРЛӘРНЕҢ ИНГЛИЗ ҺӘМ ТӨРЕК ТЕЛЕНӘ ТӘРҖЕМӘЛӘРЕ

***Йосыпова Ә.Ш., Салихова А.И.***

Историю татарской литературы начала XX века невозможно представить без Габдуллы Тукая. Пройдя через призму ценностей разных национальностей Габдулла Тукай стал известен всему миру. Это определяется совершенством произведений поэта и, конечно, переводом стихов Г. Тукая на разные языки. Произведения Тукая переведены на 26 языков мира. Имеются переводы на русский, украинский, французский, башкирский, турецкий, английский, немецкий, арабский, китайский, узбекский, казахский языки. В статье делается сравнительный анализ стихов Г. Тукая на татарском, английском и турецком языках.

The history of the Tatar literature of the early 20th century cannot be imagined without Gabdulla Tukay. His name is known all over the world through the prism of values of different nationalities. This is determined by the perfection of the poet's works and, of course, the translation of G. Tukay's poetry into different languages. Tukay's works have been translated into 26 languages. There are translations in Russian, Ukrainian, Bashkir, Turkish, English, German, Arabic, Chinese, Uzbek, and Kazakh languages. This article is a comparative analysis of poems by G. Tukay in Tatar, English and Turkish languages.

Шагыйрьнең 1907 елда язылган «Шүрәле» әкияте искиткеч зур уңыш казанган әсәрләренең берсе. Поэма авторның шәхси хис-тойгылары, хатирәләре белән баетылган. Вакыйгаларның Кырлайда баруы да очраклы түгел: Тукай туган ягының гүзәл табигатен, халык йолаларын, авыл кешеләренең тапкырлыгын, зирәклеген яратып сурәтли. Шуңа да «Шүрәле» халык тарафыннан бик милли, татар халкының рухын чагылдыручы әсәр дип бәяләнә. Рәссамнар, скульпторлар, шагыйрьләр, язучылар, композиторлар Шүрәле образын сурәтләргә алыналар. Бүгенге көндә «Шүрәле» әсәре бик күп балаларның яраткан әкиятенә әверелде, төрле телләргә тәрҗемә ителеп, бөтен дөньяга таралды.

Билгеле булганча, бер әдәби әсәрнең берничә тәрҗемәи варианты булырга мөмкин. 15 телгә тәрҗемә ителгән «Шүрәле» әкиятендә вариантларның күплеге буенча беренчелекне, әлбәттә, рус теле ала (Н. Ашмарин, П. Радимов, С. Липкин, Н. Алкин, В. Шацкий, Р. Бохараев, Р. Нугманов, В. Думаева-Валиева h.б.). Шул ук вакытта инглиз телендәге хезмәтләр дә байтак. Без, үз чиратыбызда, Равил Бохараев һәм Ләлә Гильманованың «Шүрәле» поэмасының ингиз телендәге, Али Акбашның һәм Мостафа Өнәрнең «Türk dili ve edebiyatı araştırmaları dergisi VI» китабындагы төрек телендәге интерпретацияләре чагыштырып каралды.

Иң беренче аерма инде тәрҗемәләрне кулга алгач ук күренә: бу поэманың структур төзелешенең охшаш булмавы. Л. Гильманова һәм Мостафа Өнер китабында Г. Тукайдагы кебек икеюллыклар белән эш ителсә, Р. Бохараев һәм Али Акбаш аралаш рифмалы дүртьюллыкларны сайлыйлар:

Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл – Кырлай диләр;
Җырлаганда көй өчен «тавыклары җырлай» диләр. (Г. Тукай)

In vicinity of Kazan there's a village named Kyrlai,
Their chorus is the mightiest when its cocks in loud cry. (Л. Гильманова)

Past Kazan into the country
There's a village called Kurlai.
In that village even hens cluck.
God alone could tell you why. (Р. Бохараев)

Гәрчә анда тугъмасам да, мин бераз торган идем,
Җирне әз-мәз тырмалап, чәчкән идем, урган идем. (Г. Тукай)

Orada doğmamıştım,
Biraz kalmıştım ancak,
Tırpanla, ektim, biçtim,
Dolaştım köşe bucak. (Али Акбаш)

Gerçi orada doğmasam da ben biraz durmuştum (kalmıştım),
Toprağı biraz tırmıklayıp karıştırmıştım, ekin biçmiştim.
(«Türk dili ve edebiyatı araştırmaları dergisi VI»)

Билгеле булганча, Г. Тукай – гаруз шагыйре. Гаруз дип без озын һәм кыска иҗекләрләр чиратлашып, ритм тудыра торган гарәп-фарсы метрик шигырьләрне атыйбыз [5, б. 58]. Шуны әйтергә кирәк, тәрҗемәчеләрнең варианты да оригиналдагы сыман ритмик, телгә ятышлы итеп төзелгән.

Икенче бер аерма әсәрләрнең исемнәрендә яшеренгән. Бу Р. Бохараевта «Shuraleh», Али Акбашта «Şüreli» һәм икенче төрек телендәге вариантта «Şürele», ә Л. Гильмановада «Shuraleh» атамасы янында җәяләр белән аерымланган икенче төрле вариант («Goblin») арасында чагылыш таба. Инглиз теленең аңлатмалы сүзлегендә табылган информация түбәндәгечә яңгырый: «GOBLIN (~s) In fairy stories, a ~ is a small, ugly creature which usually enjoys causing trouble» [4, б. 65], ягъни гадәттә әкиятләрдә гоблин гел начарлык кына эшләп йөрүче зур булмаган, ямьсез җан иясе.

Шүрәлене Р. Бохараев «its nose, hooked like a moose's» (аның борыны пошыйныкы кебек ), «its form like man of woman born» (хатын-кызга да, ир-атка да охшамаган), «ugly fingers like the devil's» (шайтанныкы сыман ямьсез бармаклы) һ.б. сурәтли.

Л. Гильманова да Р. Бохараев кебек бер-берсенә охшамаган буяулар куллана:

Ugly nose of the being touched his chin, as long as knife.
Long thin hair of a beard, knotty all from top to toe,
Deep black eyes without eyelids were sparkling as a coal.

(Ямьсез борыны пычак сыман иягенә кадәр салынган.
Башыннан аягына кадәр нечкә озын чәчләр белән капланган,
Тирән кара күзләре күмер кебек ялтырый).

Төрек телендәге тәрҗемәләр түбәндәгечә яңгырый:

Parlıyor alev gibi,
Çukurdaki gözleri,
Gündüz bile korkulur
Değil ki geceleri. (Али Акбаш)

Parlıyor, ışıldamakta içe gömülmüş gözleri,
Ödün kopar, görsen eğer gece değil gündüzleri.
(«Türk dili ve edebiyatı araştırmaları dergisi VI»)

Ялтырый, ялт-йолт киләдер эчкә баткан күзләре,
Кот очар, күрсәң әгәр, төнлә түгел – көндезләре. (Г. Тукай)

«Türk dili ve edebiyatı araştırmaları dergisi VI» китабында турыннан-туры тәрҗемә тәкъдим ителгән, ләкин Али Акбаш күчермә һәм алмаштырулар белән эш итә. «Ялтырый, ялт-йолт киләдер эчкә баткан күзләре»җөмләсен тәрҗемәче чагыштыру белән алмаштыра: «учак кебек ялтырый» («Parlıyor alev gibi»), «чокырга баткан сыман күзләре» («Çukurdaki gözleri»). Ә бу строфаның соңгы җөмләсе исә трансформацияләнгән, Али Акбаш сүзләрнең тәртибен үзгәртүне уңай файдалана.

Л. Гильманова тәрҗемәсендә Шүрәлегә «Shuraleh» (Шүрәле), «the ugly being» (куркыныч җан иясе), «timber-cow» (урман сыеры), «the monster» (монстр) һ.б., Р. Бохараев «the beast» (ерткыч), «Shuraleh» (Шүрәле), «the dunce» (ахмак) һ.б., ә төрек телендәгеләре оригиналга якын «Şüreli» (Шүрәле), «Şürele» (Шүрәле) кебек атамалар бирәләр.

Шулай ук икенче төп образның да исемендә аерма бар: Л. Гильманова аны «Past», Р. Бохараев «A Year Ago», ә төрек телендәге тәрҗемәләрдә оригиналдагы кебек тәкъдим ителә:

– Әйтсәм әйтим, син белеп кал: чын атым Былтыр минем.
Бу Җегет абзаң булыр бу, бик белеп тор син, энем! (Г. Тукай)

**«Past»** my name is, understood?
I should be your elder brother. (Л. Гильманова)

Well then, listen and remember.
I am called «**A Year Ago».** (Р. Бохараев)

«Madem ki çok yalvardın,
Söyleyeyim adımı,
Adıma **Bıldır** derler,
Unutmayın yadımı» (Али Акбаш)

– Söylesem söyleyeyim sen de bil (daima): Hakiki adım **Bıltır** benim,
Bu yiğit ağabeyin olur, iyice biledur sen, kardeşim.
(«Türk dili ve edebiyatı araştırmaları dergisi VI»)

Шуны әйтергә кирәк, Р. Бохараев Былтырны «A Year Ago» белән бер рәттән «a fellow» (егет), «poor fellow» (мескен егет), «man» (кеше), «the woodsman» (утынчы), «the forester» (утынчы) дип, Л. Гильманова күпчелек очракта оригиналдагы кебек «Dzhigit» (Җегет), шулай ук «Batyr» (Батыр), «the woodcutter» (утынчы), Али Акбаш «Bıldır», «bir köylü», «yiğit», «Türk dili ve edebiyatı araştırmaları dergisi VI» китабында «Bıltır», «yiğit» атамаларын куллана.

Мәсәлән, Шүрәленең «кети-кети уены» Л. Гильманова вариантында «titi-titi-titi – titillating game», Р. Бохараевта «a game of tickling», Али Акбаш «gıdıklama oyunu», «Türk dili ve edebiyatı araştırmaları dergisi VI» китабында «gıdı-gıdı» дип бирелә.

Шулай ук Л. Гильманованың «Кырлайның җырчы тавыкларын» «әтәчләргә» алмаштыруы, әкиятнең мәгънәви ягын бер дә бозмый:

Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл – Кырлай диләр;
Җырлаганда көй өчен «тавыклары җырлай» диләр. (Г. Тукай)

In vicinity of Kazan there's a village named Kyrlai,
Their chorus is the mightiest when its cocks in loud cry. (Л. Гильманова)

Али Акбаш, үз чиратында, «тавыклары җырлай» булуларының сәбәбен эзләп карап, «Havadan mı, sudan mı» («Һаваданмы, суданмы») өстәлмәсен куллана:

Kazan ardında bir köy,
Adına Kırlay derler,
Havadan mı, sudan mı,
Tavukları da öter. (А. Акбаш)

Мостафа Өнер китабындагы тәрҗемәдә «көй» сүзе «türkü» буларак тәкъдим ителә. Тәрҗемәче «көй»не «şarkı» (җыр, көй) сүзе белән тәкъдим итә алса да, төрек мәдәниятенә якын сүз белән алмаштыруны кулай күрә:

Tam Kazan arkasında taşrasında vardır bir köy, Kırlay derler
Ötünce türkü için tavukları ötüyor derler.
(«Türk dili ve edebiyatı araştırmaları dergisi VI»)

Тукайның «урта һавасын» Р. Бохараев һәм Мостафа Өнәр китабындагы тәрҗемәләрдә укучыга түбәндә китерелгән, оригинал текстка бик якын торган тәрҗемә аша җиткерелә, Л. Гильманова җыйнак итеп тапшыруны уңышлы дип таба:

Анда бик салкын вә бик эссе түгел, урта һава,
Җил дә вактында исеп, яңгыр да вактында ява. (Г. Тукай)

Neither cold nor hot, its water
Mild and soft will ever please;
At times it rains, at times it snows,
And sometimes comes a gentle breeze. (Р. Бохараев)

Orada pek soğuk ve pek sıcak değil, orta hava,
Rüzgar da vaktinde esip yağmur da vaktinde yağar.
(«Türk dili ve edebiyatı araştırmaları dergisi VI»)

Air isn't cold or hot – it's all comfortable there. (Л. Гильманова)

Али Акбаш бу тәкъдим ителгән строфаны тәрҗемә иткәндә алмаштыру, өстәлмә кебек трансформацияләр куллана. «Урта һаваны» «Pek güzeldi havası» («бик гүзәл (әйбәт) һавасы») алмаштыра һәм «Cennet gibi ovası» («җәннәт кебек (идиллик)») өстәлмәсе белән тулыландыра:

Ne soğuk, ne de sıcaktı,
Pek güzeldi havası,
Yel eser, yağmur yağar,
Cennet gibi ovası. (А. Акбаш)

Шулай итеп, Ләлә Гильманова, Равиль Бохараев, Али Акбаш һәм Мостафа Өнер китабында тәкъдим ителгән тәрҗемәләр бер-берсеннән һәм Г. Тукайның «Шүрәле» әкият-поэмасыннан үзләренең структур якларында чагылган үзенчәлекләре, сурәтләү

чараларының оригиналь булулары белән аерылып тора. Ләкин шуңа да карамастан, бу хезмәтләр инглиз һәм төрек телендә сөйләшүче халыкларны «татарларның шүрәлесе» белән таныштыру өчен искиткеч интерпретация.

Бу бүлекчәдәге икенче чагыштырма анализ Г. Тукайның иң популяр әсәрләреннән саналган «Су анасы» әкият-поэмасына ясалды. Ул 1908 елда «Җуаныч»та басылган. Әсәрнең исеме астына җәя эчендә «Бер авыл малае авызыннан» дип куелган.

Тукай тудырган әсәрдә Су анасы образ-сурәте классик дәрәҗәгә күтәрелә. XX гасыр башында, шагыйрь иҗат иткән «Су анасы»на кадәр дә, су анасы образын гәүдәләндергән шигъри әсәрләр бар. Мәсәлән, «Әлислах» газетасының 1908 елгы 3 апрель санында К. Исәнбаеваның «Су анасы» шигыре урнаштырылган. Тукай шигыре исә, балаларга атап язылып, әхлакый тәрбия ягыннан үзгә әсәр, боларга охшамаган. Гомумән, югары дәрәҗәдә камил эшләнеп, тасвирый сурәтләргә бай әсәр булуы белән әһәмиятле [3, б. 407].

Анализларга Айдар Шамсетдиновның инглиз теленә һәм Фатма Өзканның төрек теленә тәрҗемәләре сайланып алынды.

Әсәрнең исемнәрен тәрҗемәчеләр оригиналга якын итеп сайлылар. Төрек телендә ул «Su anası» («Су анасы») дип тәкъдим ителсә, А. Шамсетдинов та турыдын туры тәрҗемә итүне кулай күрә («Water maid»). Инглиз телендә Су иясе һәм Су кызының популяррак вариантлары да бар, мәсәлән, aquatic *(*суда яшәүче*)*, water-sprite (Су иясе), mermaid (Су кызы), water-nymph (Су кызы) һ.б.

Әсәрнең яңгырашын саклап калуда А. Шамсетдинов һәм Ф. Өзканның оригинал әсәрнең структур төзелешен саклап калулары да уңай роль уйный:

Йөгереп чыктым судан, тиз-тиз киендем өс-башым;
Куркам үзем әллә нидән, – юк янымда юлдашым. (Г. Тукай)

So quickly I ran out of the lake to put my clothes on.
But what was wrong? A sence of fear! And all my friends were gone!
(А. Шамсетдинов)

Koşup çıktım sudan, çabuk çabuk üzerimi giyindim.
Korkuyordum bilmem neden, yoktu yanımda arkadaşım. (Ф. Өзкан)

Тәрҗемәләрнең икесендә дә күп төрле трансформацияләр кулланылган. Бу үзгәрешләр инде беренче строфада ук күзгә ташлана:

Җәй көне. Эссе һавада мин суда койнам, йөзәм;
Чәчрәтәм, уйныйм, чумам, башым белән суны сөзәм. (Г. Тукай)

The summer day was hot and sunny, and I was swimming in the lake;
A splash of water, games so funny and dives I liked to take.
(А. Шамсетдинов)

Bir bahar günü. Hava sıcak, suda yüzüyordum;
Su sıçratarak, oynayarak, dalıp başımla suyu yararak. (Ф. Өзкан)

А. Шамсетдинов хәзерге заманны үткән заман (past continuous) белән алмаштыра һәм «су»ны конкретлаштырып «the lake» («озеро») сүзе куллана (суда койнам, йөзәм – I was swimming in the lake).

Ф. Өзкан тәкъдим иткән тәрҗемәнең икенче строфасында синтаксик алмаштыру күзәтелә: бер-бер ияртүле синтетик иярчен вакыт җөмлә гади җөмлә белән алмаштырылган:

Шул рәвешчә бер сәгать ярым кадәрле уйнагач,
Инде шаять бер сәгатьсез тирләмәм, дип уйлагач. (Г. Тукай)

Bir buçuk saat kaldıktan sonra,
Artık bir müddet terlemem diye düşündüm. (Ф. Өзкан)

Шул строфаның инглиз вариантында «бер сәгать ярым» «for an hour» («бер сәгать эчендә») төшенчәсе белән бирелә:

This merry way I did enjoy my playing for an hour
And certain was I not to sweat, moreover short I was of power.
(А. Шамсетдинов)

Өченче строфада А. Шамсетдинов риторик сорау куллана («But what was wrong?» – «Куркам үзем әллә нидән») һәм берлек санда бирелгән «юлдашым»ны күплек сан белән алмаштыра («all my friends»).

Инглиз телендәге интерпритациядә тагын башка бик күп өстәлмәләр дә бар, мәсәлән, дүртенче строфада «Was she a mermaid or a witch?» («Су анасымы бу, убырмы?»), 5 строфада «I had doubts no more» («мин бүтән шикләнмәдем»), 6 строфада «I felt tremor in my knees» («мин тезләремнең дырылдавын сиздем»), 7 строфада «Oh, my Lord» («Әй, Аллам»), икенче бүлекнең беренче строфасында «I was lucky not to drown. Thanks to God I wasn't dead» («Аллага шөкер, батмадым, үлмәдем») һ.б.

Төрек телендәге вариантта алмаштырулар ешрак очрый, мәсәлән:

Бер заманны әйләнеп баккан идем артка таба,–
Ah, харап эш! – Су анасы да минем арттан чаба. (Г. Тукай)

Bir ân dönüp bakınca arkama doğru,
Ah ne göreyim! Su Anası da peşimden gelmiyor mu? (Ф. Өзкан)

Бу строфада «Ah, харап эш!»не «Ah ne göreyim!» (Ah, ни күрәм) белән бер рәттән, хикәя җөмлә тойгылы белән алмаштырылу да күзәтелә.

Киләсе строфада исә синтаксик алмаштыру күзәтелә («аласың» – «aldın»):

Bağırıyordu: «Kaçma! Kaçma, dur, dur, ey hırsız!
Neden aldın onu sen, o benim altın tarağım!» (Ф. Өзкан)

Кычкырадыр: «Качма! Качма! Тукта! Тукта, и карак!
Ник аласың син аны, – ул бит минем алтын тарак!» (Г. Тукай)

Икенче бүлекнең дүртенче строфасында очраучы «пычагым кергери» дә тәрҗемәчеләрне дикъкатле булырга чакыра. Төрек телендә ул «Allah'ın cezası» («Аллаһның җәзасы») дип бирелсә, инглиз телендәге тәрҗемәдә бөтенләй төшерелеп калдырылган:

– Ни кирәк? Кем бу? Кара төндә вакытсыз кем йөри?
Нәрсә бар соң төнлә берлән, и пычагым кергери! (Г. Тукай)

«Who is there making dogs to bark? Who is walking in the dark?
Decent people stay at home, night is not the time to roam!»
(А. Шамсетдинов)

Nedir bu? Kim o? Geceyarısı kimdir acaba?
Ne var gecenin bu vaktinde Allah'ın cezası! (Ф. Өзкан)

Оригиналда инверсия булган җөмләләрнең төрек телендәге тәрҗемәдә уңай сүз тәртибе белән алмашуы күзәтелә:

– **Су анасы мин, китер**, кайда минем алтын тарак?
Бир! Бая көндез алып качты синең угълың, карак! (Г. Тукай)

**Ben Su Anasıyım**, getir, nerede altın tarağım?
Ver! Alıp kaçtı gündüz, senin hırsız oğlun! (Ф. Өзкан)

**Ayın şulesi düştü**. Yorganın altından bakıyordum;
Titriyor, korkuyordum, Allah'ım nereye kaçayım, diyordum
(Ф. Өзкан)

**Төшкән айның шәүләсе**, мин юрган астыннан карыйм;
Калтырыйм, куркам: «Ходай! – дим, – инде мин кайда барыйм?»
(Г. Тукай)

Соңгы үрнәктә шулай ук синтаксик алмаштыру да күзәтелә: нәтиҗәле үткән заман («төшкән айның шәүләсе») билге үткән заманга («Ayın şulesi düştü») күчкән.

Шулай итеп, Фатма Өзман һәм Айдар Шамсетдинов тәрҗемәләрендә күп төрле трансформацияләр кулланалар. Төрек телендәге интерпретациядә синтаксик һәм лексик алмаштырулар, ә инглиз телендәге вариантта төшермәләр еш очрый.

Киләсе анализланган әсәр – «Ана догасы». Ул 1909 елда «Балалар күңеле»ндә басылган. Чагыштырма анализ өчен Зөлфия Миннебаева һәм Г. Тукайга багышланган официаль сайттан (gabdullatukay.ru) алынган инглиз телендәге, Фатма Өзканның төрек телендәге тәрҗемәләре сайланып алынды.

Шигырьнең исеме барлык вариантларда да турыдан туры тәрҗемә ителә: «Mother' prayer» һәм «Ana duası».

Әсәрнең структур төзелеше оригиналга якын:

**Менә кич**. **Зур авыл** өстендә чыкты нурлы ай калкып,
Көмешләнгән бөтен өйләр, вә сәхралар тора балкып. (Г. Тукай)

**Evening comes** to **the Tatar village**; **the magic** bright moon is in the sky
Under its light all seems silver: houses, roofs, fields nearby. (З. Миннебаева)

The effervescent moon over the village rises. Night.
Painting the houses silver, bathing fields in light. (gabdullatukay.ru)

İşte akşam. Koca köyün üzerine doğdu nurlu ay,
Gümüşlendi bütün evler ve sahralar parlıyor. (Ф. Өзкан)

З. Миннебаеваның күрсәтелеп үткән беренче строфа тәрҗемәсендә өстәлмә («the magic bright moon» – «сихри нурлы ай»), алмаштыру («the Tatar village» – «Татар авылы») һ.б. трансформацияләрне очратырга мөмкин. Сайттагы тәрҗемәдә «нурлы ай» «The effervescent moon», ягъни «чыжылдый торган/ кайнап торган ай», Ф. Өзкан «nurlu ay» («нурлы ай») дип тәрҗемә итә.

Төрек вариантыннан аермалы буларак, инглиз телендәге интерпретацияләрдә өстәлмәләр шактый: З. Миннебаевада «a little trembling light» («кечкенә калтыравык ут»), «her wrinkled face» («аның җыерчыклы йөзе») һ.б., сайттагы тәрҗемәдә «window casts a light» («тәрәзәдән ут төшә») һ.б.

Киләсе строфада бирелгән намазлык һәм ястү сүзләренең тәрҗемәләре аерым игътибарга лаек:

Әнә шул өй эчендә **ястүеннән** соңра бер карчык
**Намазлыкка** утырган, бар җиһаннан күңлене арчып. (Г. Тукай)

O evin içinde **yatsıdan** sonra, bir kadıncağız,
**Seccadesine** oturmuş, bütün dünyadan kesmiş ilgisini. (Ф. Өзкан)

And in that house, after her **evening prayer**
An older woman sits; her thoughts so far from there. (gabdullatukay.ru)

An old woman in that house has knelt down on **a prayer rug**
And her soul is soaring now very high in heavens' hug (З. Миннебаева)

Бары тик төрек телендәге вариантта гына ике сүз дә сакланып калган. Г. Тукайның официаль сайтында «ястү» «evening prayer» («кичке дога/намаз») дип бирелә, ә «намазлык» сүзе төшерелеп калдырыла. З. Миннебаеваның тәрҗемәсендә киресенчә, ул «намазлык»ны «a prayer rug» («дога колу өчен келәмчек») дип бирә.

Бишенче строфадагы туры сөйләмне З. Миннебаева кыекка күчерә, ә калган тәрҗемәләрдә туры сөйләм сакланып кала:

Күтәргән кул догага, яд итә ул шунда үз угълын:
Ходаем, ди, бәхетле булсайде сөйгән, газиз угълым! (Г. Тукай)

She has raised her hands in prayer and her wish is only one
She is whispering with devotion asking God to bless her son. (З. Миннебаева)

Her arms raised up in prayer, she asks about her son:
«Oh Allah, make his life a happy one!» (gabdullatukay.ru)

Ellerini yukarı kaldırarak, hatırlar oğlunu,
«Tanrı'm» der, «mesut olsun sevgili oğlum!» (Ф. Өзкан)

Сайттан алынган текстта «Тәңре каршына» «The Creator's ears» («Ходай колакларына») дип алмаштырыла.

Чагыштырма анализ барышында шул аңлашылды: бер телләр гаиләсенә караган төрек телендәге тәрҗемәләр еш кына сүзен-сүзгә, төгәл тәрҗемә белән башкарылган, ә инглиз телендәгеләрендә тәрҗемәченең иҗади якын килүе дә сизелә. Ритм, темп, интонацияне ике телдәге интерпретацияләрдә дә саклап калырга тырышканнар.

ӘДӘБИЯТ

1. Abdullah Tukay'ın Bir Şiiri: 'Şüreli'. E.Ü. Türk Dili ve Edebıyatı Araştırmaları Dergisi 6.C. İzmir 1991-193. 239 s.
2. Abdullah Tukay'ın Şiirleri (Metin-Aktarına-inceleme). Özkan, Fatma. G.Ü. Ankara, 1992 s. 960, D. Prof. Dr Ahmet B. Ercılasun.
3. Тукай Г. Әсәрләр: 6 томда. Академик басма. 1 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 407 б.
4. Инглиз теленең аңлатмалы сүзлеге http://slovar-vocab.com
5. Татар әдәбияты: Теория. Тарих / Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов, Т.Ш. Гыйләҗев, Н.М. Йосыпова. Тулыл. 2 нче басма. Казан: Мәгариф, 2006. 319 б.

# XX ГАСЫРНЫҢ ИКЕНЧЕ ЯРТЫСЫ ТАТАР ПОЭМАЛАРЫНДА ТУКАЙ ОБРАЗЫ
## (С. Хәкимнең «Кырыгынчы бүлмә» һәм М. Әгъләмовның «Тукайдан хатлар» поэмалары мисалында)

***Йосыпова Н.М.***

Образ Тукая в татарской поэзии второй половины XX века становится сложным и многоплановым. В рамках одного произведения сосуществуют реалистические, романтические, мифологические, модернистские пласты, этому способствуют условная игра, интертекстуальность, мифологическая символика, обогащение романтического пафоса реалистическими деталями. В поэмах, посвященных Тукаю, происходит углубленная интерпретация образа поэта за счет использования приёмов, характерных для эпических произведений. Таковы поэмы «Сороковой номер» С. Хакима, «Письма Тукая» М. Аглямова. В них биографическо-реалистические компоненты переплетаются с размышлениями о народе, о его национальной самобытности, раздумьями о его прошлом и будущем и с философскими размышлениями о человеке и смысле его жизни. Собственно литературные проблемы – литература и её роль в жизни общества и отдельной личности поэта – соприкасаются с политической проблематикой и философскими размышлениями.

Image of Tukay in the Tatar poetry of the second half of the XX century becomes complex and multiplane. Within the frames of one work realistic, romantic, mythological, modernist layers coexist, it is assisted with such means, as conditional game, intertextuality, the reference to religious and mythological symbolics, enrichment of romantic pathos by realistic details. In the poems devoted to Tukay, there is a profound interpretation of the poet's image due to use of approaches, characteristic for epic works. They are poems «Fortieth room» by S. Khakim, «Letters of Tukay» by M. Aglyam. In them, biographic-realistic components combine with thoughts about people, about its national originality, reflections over its past and the future and with philosophical ideas about the person and sense of his life. Actually literary problems: the literature and its role in the life of the society and the poet's person, – adjoin to the political problematics.

XX гасыр татар әдәбиятының буеннан-буена Тукай турында әсәрләр язылу, Тукайның поэтик образын әдәби интерпретацияләү, сүз сәнгатен, иҗади югарылыкны, татар дөньясы алга куйган идеалны һәм, гомумән, тормышның үзен аның белән үлчәп карау гасыры буларак билгеләнә. Тукай турындагы әдәбият XX йөз башында формалаша һәм узган гасыр буена үстерелә, камилләшә килә, шагыйрь образын төрле статусларда татар укучысына тәкъдим итә. Тукай образын үзәккә алган әдәбият, гомумән, гомумәдәби процесстагы тенденцияләргә авазадаш үсеш-үзгәреш кичерә [2, б. 129], шуңа бәйле төстә XX гасырның беренче яртысында образ бирелешендәге эволюция Тукай – шигъри пәйгамбәр, Тукай – милләткә хезмәт итүче, Тукай – милли идеал, Тукай – «суфичылык фәлсәфәсендә Ибн Гарәби тарафыннан тәкъдим ителгән һәм нәзари яктан эшләнгән «камил инсан» [5, б. 221] дәрәҗәсендәге камиллек үрнәге, Тукай – пролетар, Тукай – түбән сыйныфларны яклаучы, Тукай – халыкчан шагыйрь кебек янәшәлекләр аша алып барыла.

Тукай турындагы поэзиядә яңарыш, иҗтимагый яшәештәге үзгәрешләр тәэсирендә, 1960 елларның икенче яртысыннан башлана, татар әдәбиятының киңәю-тармаклану вакытында яңа сыйфат үзгәрешләре белән байый, тулылана. Аның, алдагы чорлар белән чагыштырганда, башкарак юнәлештә үсеп китүе фәлсәфи һәм әдәби фикердәге яңалыклар, әдәбиятның иҗтимагый кануннарны алга куйган идеологик кысалардан чыгуга омтылышы, дөньяны, яшәешне сәнгатьчә кабул итүнең яңа яклары ачылу белән аңлатыла. Шушы чордан Тукай образының сурәтләнеше катлаулы һәм катнаш төс ала: бер әсәр чигендә Тукай образына мөнәсәбәттә шагыйрь һәм шигъриятнең хәле, реалистик, романтик һәм мифологик традицияләрнең бергә кушылуы күзәтелә, моңа исә төрле сәнгати алымнар аша ирешелә [3, б. 136]. Бу үзенчәлек аеруча поэма жанрында калку чагылыш таба.

XX гасырның икенче яртысында Тукайга багышлап иҗат ителгән поэмалар шагыйрь образын сурәтләүне эпик әсәр мөмкинлекләрен файдаланып тирәнәйтә. С. Хәкимнең «Кырыгынчы бүлмә» (1971), М. Әгъләмовның «Тукайдан хатлар» (1986), Р. Харисның «Тукайның мәхәббәт төшләре» (2000) поэмаларында биографик-реалистик, сатирик-тәнкыйди яңгыраш, иҗтимагый фикерләр: милләт, аның язмышы, үткәне, бүгенгесе, киләчәге; фәлсәфи уйланулар: кеше һәм яшәеш, яшәү мәгънәсе һәм кешелек алдындагы бурыч; әдәби мәсьәләләр: әдәбият һәм аның кеше, милләт тормышындагы

роле, әдәбиятның шагыйрьгә йөкләтелгән олы вазифасы, шагыйрь шәхесе; сәяси ачыну: марксистик идеология һәм система китергән фаҗигаләр хакында сөйләү белән үрелеп бара. Мәсәлән, С. Хәкимнең «Кырыгынчы бүлмә» (1971) поэмасында шагыйрь образы төрле катламнарның синтезы ярдәмендә сурәтләнә. Тукайның биографиясендәге аерым мизгелләр, уйланулар аша автор ул яшәгән «Болгар» кунакханәсенең кырыгынчы бүлмәсенә килә. Катламнар шунда бер-берсенә килеп кушылып, төенләнеп, чор сәясәте, шигъриятнең бүгенге хәле, киләчәккә үсеш юллары, Тукайга мөнәсәбәт турындагы уйланулар үзара үрелә.

Реалистик катламда лирик герой, шагыйрьнең балачагыннан башлап, гомер йомгагына кадәрге тормышын барлый, еллар агышы Тукай шәхесе белән бәйләп барыла. Балачагында әтисенең Әтнә базарыннан алып кайткан китабыннан башланган мавыгу лирик геройны яшьлек еллары, дәһшәтле сугыш чорлары буенча «картлыгы»на кадәр озата килә. Бу юллар авторга Тукайның үз тормышында тоткан урынын, шәхес буларак җитлегүдәге ролен ачыкларга мөмкинлек бирә.

Биографик мәгълүматлар белән баетылган әлеге реалистик катлам белән янәшәдә сәяси катлам ачыла һәм Тукай чорының җәмгыяви кануннары, шуңа бәйләп үзе яшәгән дәвернең сәяси кануннары турында сүз башлый:

Тынгысыз чат, тынгы бирмәс җанга,
Үзем тынгач, шушы чат тынар,
Тукай тавышы, кычкыра күк Тукай,
Бер генә сүз яңгырый: саттылар...
Базарларда печән, он сатылган,
Җыр сатылган, кеше сатылган... [4, б. 42]

Тукай чоры турында сөйләү аркылы автор үз чорына бәя бирә, матди байлыкларның гына түгел, рухи кыйммәтләрнең дә «сатылуы» хакында чаң суга. «Тукай тавышы» лирик геройның милли хәл-халәттән ризасызлыгы булып та аңлашыла. Киләсе строфаларда үз чорының «җан богавын, фикер богавын өзгән» Ш. Мәрҗаниләр, аларга алмашка килгән Тукай, Ямашлар белән горурлану хисләре өскә калка. Шул рәвешле, Тукай хөр фикер, сүз, җан азатлыгы, халык бәхете өчен көрәшүче шәхес булып күз алдына бастырыла. Әлеге фикергә бәйләп, С. Хәким Тукайга мөнәсәбәт мәсьәләсен калкытып куя:

Үлде бөек токым... Кем дә әйтмәс:
Улларыңнан син, дип, уңмадың,
Халкым, алда улларыңны сакла,
Авыр чорлар кичерә улларың... [4, б. 52]

Бар дөньясына әрнеп, «моннан соң болай булмасын» дип үлгән Тукайның халкына рәнҗеш-үпкәсе лирик геройның әрнүе булып та укыла, автор үз чорында да аваздаш хәлләрнең дәвам итүенә, милләтнең үз «улларын» саклый алмавына әрни, аны чор кануннарының төп җитешсезлеге буларак бәяли.

Фәлсәфи башлангыч шагыйрь шәхесен яңа сыйфатлар белән баета. Намус, вөҗдан, хакыйкать турында уйланулар аркылы лирик герой, Тукайда әлеге хасиятләрне барлап, изгелеккә ия шагыйрьне вөҗдан, намус һәм хаклык символы итеп күтәрә:

Җырны җырга якын куеп карыйм,
Намусына аның – намусым.
Хакыйкатькә – хакыйкатьне, җанны,
Эзли күңел үзенең иясен...
Эзли күңел, ник ул җитми һаман?
Ник борчуда уза күп айлар?
Калдырып зур мирас, нәрсәнедер
Алып китте кебек Тукайлар... [4, б. 45]

С. Хәким үз чорына хас яшәешкә намус, вөҗдан, хаклык кебек изге, матур сыйфатларның җитмәве өчен борчыла, үзе төзегән тормыш моделенең үзәгенә әлеге хасиятләрне беркетә. Алар поэзия җирлегенә күчерелә дә, Тукай иҗаты белән янәшәлектә шигърият турында сүз алып баручы әдәби катлам ачыла.

Кырыгынчы бүлмәнең салкын, ямьсез һәм буш булуына да карамастан, дусларга бай иконлек фикере киңәеп, татар халкының яшәеше, поэзиянең үсеше белән тоташа. Тукайның эчке дөньясы Пушкин, Лермонтов, Байроннарның сүз, фикер хөрлеген үзенә

сыйдырган, шигъриятләрендәге уңай сыйфатларны туплаган. Әлеге сүз-фикер аша автор «хәзерге шагыйрьнең дә менә шул киңлеккә, шул бөеклеккә ашкынырга тиеш»леген ассызыклый, поэзиянең киләчәк үсешен шунда күрә.

Бу – бердәнбер биксез бүлмә җирдә,
Урындык һәм өстәл, кәрзине...
Урлатасы әйбере юк, хөрлек
Һәм азатлык, шигырь һәр җире [4, б. 47].

Бу юллары белән автор сәнгатьнең бәйсез, азат һәм «ачык» булырга тиешлеге хакындагы идеясен үткәрә.

М. Әгъләмовның Тукай турындагы поэзиягә жанр һәм фикер үстерелеше җәһәтеннән яңалык алып килгән «Тукайдан хатлар» (1986) поэмасында шагыйрь образы төрле стиль, катламнарның синтезы төсендә бирелә.

М. Әгъләмов шагыйрь шәхесен сурәтләү барышында аз өйрәнелгән якларның берсе – аның дусларына, туганнарына язган хатларына мөрәҗәгать итә һәм үзара бәйләнешкә кергән хатларны шәхси фикерләве, чор сулышы белән бергә үрә. Поэма цикләрендә төрле стиль һәм жанрларның синтезы хасил булып, алар аша Тукайга төрле яклы бәя ачыла.

Әсәрнең керешендә үк М. Әгъләмов Тукайның Габдулла Кариевка язган хатындагы «*Сез дә, һаман бер төсле караңгы вә ямьсез эт оясыннан чыгып, кояш күрдеңез...*» [1, б. 209] юлларын эпиграф итеп кертә һәм киләсе строфалар кояш символының төрле мәгънәләрен «укуга» юнәлтелә.

Бер яктан, дөньяны яктыртучы, нур сибүче кояш символы гайбәтләрдән өстен хакыйкатьне символлаштыра,»үткәнең һәм киләчәгең өчен ант итәрлек булсын кояш белән» дип, дөреслекне әйтеп бирүнең мөһимлеген дәлилли. Алга таба кояш символы гасыр башына күчерелеп, хаклык, хакыйкать Тукай шәхесе белән бәйләп куела. Шуңа мөнәсәбәттә хакыйкатьне белдереп килгән кояш әлеге сыйфатка ия Тукай образын символлаштыруга юнәлтелә. Автор шул чорны аңлау-белү, бәяләү өчен шагыйрь белән янәшә барырга кирәклекне искәртә:

Яшәп була кояш астында да
Рәхәт күреп яки себерелеп,
Үзе бәхет бит ул күзәтүе
Кояш кебек нәкъ уртага менеп,
Без зенитта бүген кояш кебек [1, б. 210].

Кояш, бердән, Тукайның бөеклеген, көчен бирергә ярдәм итсә, икенче яктан хакыйкать белән берләштерелеп, яшәвенең төп максаты дөреслек өчен көрәшү икәнлеген ассызыклый. Өченчедән, Тукайның бөеклеген генә түгел, үз халкына карау ноктасын билгеләргә мөмкинлек бирә. Шул сыйфатны автор үзенә күчерә дә, Тукай кебек күп якларны күрә һәм бәяли алуын, дөреслекне, хакыйкатьне җиткерергә теләвен ассызыклый. Шул рәвешле, кояш образының бирелеше аркылы өч затка бәя бирелә: Тукай, лирик «мин» һәм «без». Ахыргы строфада кояш илдәге канун, идеологияне символлаштырып, «дүрт яктан күзләп торган офык астында» яшәүнең җиңел түгеллеген дә искәртеп куя. Шул рәвешле, кояш символы поэма структурасындагы катламнарны үз тирәсенә туплаган күпкатламлы символ югарылыгына күтәрелә, кереш өлешендә үк автор әсәрнең катламнарын билгеләп куя: яшәеш кануннары, яшәү рәвеше, гомер, хакыйкать, бөеклек турында уйлануларны эченә алган фәлсәфи катлам; Тукай шәхесенә, иҗатына, аның аркылы бүгенге шигърияткә бәя биргән әдәби-мәдәни катлам; чор сәясәтен ачып күрсәтүче, ачы дөреслекне укучыга җиткерергә мөмкинлек бирүче сәяси башлангыч. Аларның синтезы Тукайга, аның чорына, шулар аша бүгенгегә яңача карарга, бәя бирергә ярдәм итә.

Поэманың багышлау бүлеге үк әсәр структурасында мәдәни, әдәби катламның үзәккә куелуы турында сөйли. Автор, бүгенге әдәбият вәкилләренең «тышкы» матурлык белән генә мавыгуына каршы чыгып, сүз сәнгатенең хаклыкны җиткерү үзәге булырга тиешлеген искәртә, дөреслекне әйтә алуның батырлык булуын ассызыклый, бүгенгеләрне аңардан үрнәк алырга чакыра. Шушы юлда Тукай шигърияте, аның төп хасиятләре, иҗат итү шартлары белән таныштыра. Автор шагыйрьнең иҗади тамырларын барлап, Курсави, Кандалый, Акмулла, К. Насыйри, Мәрҗаниләрнең иҗатларына барып чыга һәм Тукайны шушы чылбырның бер буыны итеп күтәрә. Тукай иҗатының асыл сыйфатын

символлаштырган хәнҗәр символик детале дөреслекне җиткерү, хакыйкатьне әйтә алу көченең куәтенә ишарәле һәм әлеге сыйфатларны шигъриятнең үзәгенә күтәрә.

Әдәби катламда икенче якны бүгенге поэзия турында уйланулар тәшкил итә. Автор татар шигъриятенә Тукайдагы кебек батырлыкның, ачы дөреслекне әйтүнең җитмәвенә борчыла. Ләкин алдагы строфадагы ак каурый образының кертелүе шартлы төстә Тукай дәвамчыларының булуына ишарә кебек тә кабул ителә. Бүгенге поэзиянең бурыч-максатлары, вазифалары турында сүз Тукайның лирик геройга җиткергән васыяте белән бәйләнештә алып барыла. Шушы фонда дөреслек, хаклык үрнәге булырга тиешле шигъриятькә яңа сыйфат өстәлә: ул халык бәхете өчен көрәш мәйданына күтәрелә.

Әдәби катламнан сүз сөреше сәяси катламга күчерелә. Бу катламда авторны кешелекнең уйланмыйча, «үз-үзенә сорау бирмичә» «рухи богауда» яшәве борчый. Милләтнең бу хәлгә төшүендә ул сәяси тәртипләрне, идеологияне тәнкыйтьли һәм аны яшеллекне юкка чыгаручы кырау символик образы аша гәүдәләндерә. Шуңа да Тукай поэзиясеннән килүче «ил җылый» гыйбарәсе лирик герой чорына юнәлтелгән булып аңлашыла. Димәк, Тукай чорын язу аша автор үз чорының сәясәтен, идеологиясен дә бәяләп бара, Тукай чорындагы тәртип-кануннарның дәвамлылыгына ишарәли, шагыйрьләргә мондый мөнәсәбәтнең дәвам итүен ассызыклый. Бу халәтнең озак дәвам итү нәтиҗәсе милләт, халыкның инкыйразы булачагын да искәртә. Бу хакыйкать икенчел эчтәлек тудыру алымы аша Тукай чоры «пәрдәсе», дини төшенчәләр артына яшерелә.

Чор сәясәте турында уйланулар шагыйрьнең бөеклеген, яшәү мәгънәсен раслаучы фәлсәфи катламга юл ача. «Халык җанына әверелү» гыйбарәсе белән М. Әгъләмов аның татар тормышындагы урынын да, кадерен дә төгәлләштереп куя. «Ачы еллар» аркылы «ярма кебек килегә салып төйгән» заманнарда да Тукайның бөек, ак, изге күңелле булып кала алуы соклану хисе уятуга сәбәп төсен ала. Шуңа да «ишектән кергән ап-ак уй» безнең тормышыбызга кергән «ак» Тукай булып аңлашыла. Шагыйрьнең аклыгын, сафлыгын, бөеклеген күрсәтү аша автор бүгенге кешелек өчен Яшәеш үрнәген, моделен төзи. Икенчедән, ул сәнгатьнең сафлыгы мәсьәләсен күтәрә, сәнгатьнең саф, аның вәкилләренең дә намуслы, хакыйкатьне сөюче булырга тиешлеген канун дәрәҗәсенә күтәрә.

Бер-берсенә кушылып килгән катламнарны үзара җыеп, туплап торучы образ – «мин әле кая барам?» гыйбарәсе аша белдерелүче юл. Бу сорауны шагыйрь поэманың буеннан-буена, һәр катламда кабатлый. Нәкъ менә кабатлау аша юл үзе үк берничә мәгънәне бирүче символ югарылыгына күтәрелә. Беренчедән, ул Тукайның үз чорыннан безгә килгән һәм киләчәккә барачак юлын символлаштыра, икенчедән, поэзиянең үсеш юлын гәүдәләндерә, әсәрдә автор аның төп хасиятләрен – сукмакларын билгели, өченчедән, сәяси юнәлештә милләтнең үсү юлы буларак конкретлаша, дүртенчедән, аклык, сафлык турындагы уйлануларга нигезләнгән кешелекнең Яшәеш юлын күрсәтә, бишенчедән, лирик геройның Тукай тормышы буйлап, уй-фикер, иҗади максатларын барлап үтелгән юлы булып аңлашыла. Поэманың башында шул «юлга» чыккан лирик герой ахырда сәяхәтен тәмамлый. Иң соңгы өлештә Тукайның «... мин кайтып җиттем. Бер нәрсәгә дә аптырамадым. Әлегә җитәр» дигән сүзләрен эпиграф итеп урнаштыру шуны дәлилли. Әнә шулай М. Әгъләмов «Тукайдан хатлар» поэмасында Тукайның шәхси, иҗади сыйфатларын сурәтләү аша чор сәясәтен, милләтнең яшәү рәвешен, хәлен ачып бирүгә ирешә. Шушы юлда паратекстуальлек алымыннан оста файдаланыла: Тукай хатларының эчтәлеге бүгенгегә юнәлтелеп, хәзерге чорны ачып бирүгә хезмәт итә. Шагыйрьнең калкуландырылган сыйфатлары аша чор поэзиясенә нәкъ менә шул сыйфатларның җитмәве ассызыклана.

Шулай итеп, XX гасырның икенче яртысы татар поэмаларында Тукай образының сурәтләнеше катлаулы төс ала, моңа төрле катламнарның синтезы аша ирешелә. Моннан тыш аларда Тукайга объектив һәм субъектив бәянең бер үремтәдә бирелүе дә күзгә ташлана, бер әсәр чигендә иҗтимагый, рухи, әхлакый һәм сәнгати бәяләр кушыла. Тукай образы Яшәешкә әхлакый үрнәк итеп куела, милләтне рухи яшәтүче, азатлыгы өчен көрәшүче шәхес булып күтәрелә. Тукай турындагы поэзиядә шагыйрь иҗатына, шәхесенә бәйләп, сәнгатьнең вазифалары, сафлыгы турында фикер актуальләшә, Тукайга мөнәсәбәт мәсьәләсе калкытып куела. Моның аркылы чор сәясәтен ачып бирүче, милләтнең яшәү рәвешен тәнкыйтьләүче сәяси катлам ачыла. Шул рәвешле, катлаулы, берничә яссылыкны эченә алган сурәт тудырыла. Бу – XX гасырның икенче яртысы татар поэмаларының төп шигъри табышы.

Шулай XX йөз башында милли идеал булып күтәрелгән Тукай образы шушы чорда иҗат ителгән поэмаларда тормыш-яшәешнең гомумән татар әдәбиятын борчыган, кызыксындырган барлык өлкәләрен үз янына җыя. Шул рәвешле, Тукай турындагы әлеге поэмалар XX гасыр әдәби-эстетик фикерендә барган үзгәреш-яңарышларны тагын бер кат шәрехләп бара, әдәби традицияләрнең дәвам ителешен, үстерелешен, мәгънәви баетылышын дәлилли һәм сүз сәнгатенең милли нигезләрне, кыйммәтләрне югалтмавы хакында сөйли.

ӘДӘБИЯТ

1. Әгъләмов М. Тукайдан хатлар // Иман тәрәз шакый. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. Б. 209–242.
2. Галиуллин Т.Н., Юсупова Н.М. Образ Тукая как национальный идеал в татарской поэзии XX века // Филология и культура. 2012. № 3 (29). С. 126-129.
3. Гафиятуллина Н.М. XX гасыр татар шигъриятендә Тукай образы: филол. ф. канд. … дис. Казан, 2002. 152 б.
4. Хәким С. Кырыгынчы бүлмә // Тукай турында поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. Б. 39–54.
5. Юсупов А.Ф., Юсупова Н.М. Суфизм в средневековой татарской культуре: роль, особенности и модели мира // Филологические науки. Вопросы теории и практики. 2012. № 5(16). С. 219–222.

## ТӨРКИ ДӨНЬЯ ХАЛЫКЛАРЫ ТУКАЙ ТУРЫНДА

***Йосыфҗанова Н.Г.***

Габдулла Тукай – туган халыкның гына түгел, бөтен төрки халыклар, Идел буенда һәм Урал янында яшәүче угро-фин халыкларының мәдәни үсешенә билгеле өлеш керткән зур абруйлы шәхес. Аның турында тугандаш халыклар галимнәре, әдипләре, сәнгать эшлеклеләре язган тирән эчтәлекле бик күп җылы фикерләр шул хакта ачык сөйли. Ничек куанмыйсың: данлы Тукаебыз иҗаты XX гасыр башында ук башка халыкларны да сокландырган бит.

Габдулла Тукай классик көнчыгыш поэзиясе һәм фәлсәфи фикернең кыйммәтен һәрвакыт югары бәяләде. Хафиз, Хәйям, Нәваи, Низами иҗатлары, борынгы төрки – татар поэзиясенең классик үрнәкләре кебек үк, аның өчен гуманизм һәм шигъри осталык мәктәбе булып торды. Алай гына да түгел, Шәрекъ поэзиясенең традицияләрен үзләштерүдә Тукай яңа баскычка күтәрелде, кешегә, аның акыл һәм рух көченә, матурлыгына дан җырлаган шигърият дөньясын яңа шартларда заман ихтыяҗларына җавап йөзеннән тагы да киңрәк колачлый алды. Нәтиҗәдә Габдулла Тукай үз иҗатында Шәрекъ һәм гарәп әдәбиятларының иң яхшы традицияләрен бергә кушып, борынгы төрки-татар поэзиясе казанышларына нигезләнгән, сыйфат ягыннан яңа шигъри дөнья ачты. Моның белән без шагыйрьнең эстетик карашлары классик Шәрекъ шигъриятенең гадел поэтик фикерләү байлыгы белән кушылуына, синтезына нигезләнгән булуын ачык күрәбез. Бу исә реализм һәм халыкчанлык юлыннан үсәчәк яңа татар әдәбиятына ышанычлы һәм ныклы нигез салыну дигән сүз иде.

Габдулла Тукай – бер татар халкының гына түгел, аның өчен мәдәни бишек булган Шәрекънең дә бөек шагыйре. Ул – барыннан да бигрәк төрки халыкларның әдәби, мәдәни үсешенә көчле йогынты ясаган кабатланмас шәхес.

Каракалпак шагыйре Ибраһим Йосыпов «Тукайга» шигырендә аңа түбәндәге бәясен бирә:

Төрки дөнья шигъриятен яңартып алга әйдәдең,
Шигъри ике материкны тоташтырып бәйләдең.
Байрон, Лермонтов Шәрыкка танылды синең аша,
Сәгъди, Хафизлар белән хәзрәте Пушкин сөйләшә...

Тугандаш халыклар әдәбиятында башка тагын бик күп милләт шагыйрьләре Тукайга мөнәсәбәтләрен белдерде. Әйтик, казакъ шагыйре Сагынгали Сеитов «Тукай турында уйланулар»шигырендә болай дип язган:

Күктән атылып төште... җиргә ятмады,
Кояш булып чыкты, ләкин батмады.

Дөрестән дә, бөек Тукаебызның бай иҗаты төрки телле халыклар өчен аеруча якын һәм үз. Әдәби телнең уртаклыгы, язуның бердәйлеге аркасында, Урта Азиянең күп халыклары Тукай әсәрләрен әле үзе исән чагында ук татар телендә укый алганнар.

Күренекле казакъ әдәбияты белгече Е. Исмаилов: «Тукайның, бер яктан, үсеп килүче рус демократик революцион әдәбияты һәм, икенче яктан, Көнчыгыш халыкларының милли-азатлык көрәше белән тыгыз бәйләнгән иҗаты татарларга якын һәм кадерле булган кебек үк, казакъларга, әзәрбайҗан, үзбәк, төрекмән, кыргызларга – гомумән, татар телен белгән-аңлаган бөтен халыкларга да кадерле», – дип әйтүе белән хаклы иде.

Үзләренең туган әдәбиятлары белән XX гасыр башы татар әдәбияты арасындагы бәйләнешләрне өйрәнүче бик күп күренекле тикшеренүчеләрнең карашлары да шушы фикергә тәңгәл яңгырый (Гафур Голәм – үзбәк язучысы, Сабит Муканов – казах язучысы, Самид Вургун – азербайҗан шагыйре, Берди Кербабаев – төрекмән язучысы).

Чыннан да, XX гасыр башындагы иҗтимагый тетрәнүләр дулкынында татар әдәбиятының һәм мәдәниятенең кискен күтәрелеп китүе Россиянең көнчыгыш халыклары әдәбияты үсешенә көчле этәргеч бирде. Нәкъ менә шушы чорда татар прогрессив әдәбиятының Урта Азия, Идел буе һәм Урал халыклары әдәбиятларына йогынтысы көчәйде.

Тугандаш халыклар шагыйрьләрен Тукай шигърияте, барыннан да элек, эчтәлегенең тормышчанлыгы, сурәтләү чараларының байлыгы һәм жанр материалларының төрлелеге белән илһамландырды. Ул җәмәгатьчелекнең аңлы өлешенә йокыдан уянырга, дәртләнеп эшкә керешергә, Европаның алга киткән һәм мәдәни бер милләте булырга чакырып мөрәҗәгать итә.

Казах әдәбияты классигы Сабит Муканов тикмәгә генә Тукайны «Көнчыгыш поэзиясе титаны» дип атамаган бит.

Көнчыгышның күренекле фикер ияләренең Тукай поэзиясе һәм иҗаты белән турыдан-туры бәйләнеше турында сөйләгәндә, төрки халыклар арасында таралган татар газеталары, журналлары һәм китапларының прогрессив ролен истә тотарга кирәк. (Бу хакта китап белгече академик Ә.Г. Кәримуллин һәм күренекле тарихчы Р.Г. Әмирханов хезмәтләрендә ышандырырлык итеп язылган).

Тукай шигърияте тәэсире кыргыз язучысы Османали Сыдыков әсәрләрендә дә кызыл җеп булып сузыла. О. Сыдыков иҗатында Тукайның мәгърифәтчелек поэзиясе белән бәйле эзләр – кыргыз шагыйре мәгърифәт, мәдәният һәм тарих мәсьәләләренә мөрәҗәгать иткәндә аеруча калку чагыла.

Билгеле, шул ук вакытта Тукайның үзенең дә Фирдәүси, Хафиз, Сәгъди, Нәвои кебек Көнчыгышның бөек классикларыннан килгән яхшы традицияләрне үзләштергән булуын да онытырга ярамый. Бу турыда татар әдәбияты галимнәреннән Гали Халит, Хатип Миннегулов, Ибраһим Нуруллин үзләренең гыйлми хезмәтләрендә ассызыклый.

Ә инде безнең көннәрдә, кыргыз халык язучысы Чыңгыз Айтматов, борылыш елларында кыргыз мәгърифәтчеләренә татар остазлары күрсәткән игелекле эшләргә зур рәхмәтен белдереп, Көнчыгыш халыкларының мәдәни тормышында даһи татар шагыйре Тукайның урынын билгеләп, аны «Европа һәм рус революцион фикерләрен үткәрүче», дип юкка гына әйтмәде.

Тукай шигърияте кыргыз, казах, төрек телләрендә күп тапкырлар аерым китап булып басылып чыкты. Шагыйрь әсәрләре инде бик күптәннән үзбәк халкының да рухи байлыгына әйләнде. Димәк, Тукайның үлемсез иҗаты һәм сүнмәс-сүрелмәс шәхесе, татар халкының милли хәзинәсе генә булып калмастан, барча төрки телле Шәрык халыкларының горурлыгы да ул.

Күпмилләтле Җаекта яшәп, рус мәктәбендә укып, рус басмаханәсендә хәреф җыючы булып эшләп, шәһәр китапханәләрендәге рус классикларының әсәрләре белән танышып, Тукай Евразия шагыйре булып формалаша. Җаектан башка, безнең Кырлайда гына калып, Тукай – шагыйрь, бигрәк тә безнең көннәрдә аеруча актуаль булган Евразия киңлегендәге халыкларның идеяләрен чагылдыручы Евразия масштабындагы Шагыйрь буларак үсеп җитә алмас иде.

Татар-төрек багланышларының якты бер сәхифәсе дә Габдулла Тукай исеменә бәйләнгән. Ул Уральскийның «Мотыйгия» мәдрәсәсе шәкерте дәверендә үк төрек китапларын укырга керешә. Төркиядән куылган Габделвәли Әмрулланың шушы шәһәргә килүе Тукайның госманлы матбугаты һәм әдәбияты белән кызыксынуын тагын да дөрләтеп җибәрә. («Тукай турында истәлекләр» дигән китапта шагыйрьнең замандашлары «Габделвәлинең шагыйрь булуын, Габдулланың аннан төрек телен өйрәнүен» искәртәләр).

Тора-бара Тукай төрекнең әдәбиятын гына түгел, аның тарихын, сәясәтен, эчке һәм тышкы көрәшләрен бик яхшы күзаллауга ирешә. Нәтиҗәдә, Габдулла Тукай

иҗатында төрек һәм Төркия темасы һәрвакыт үзәк урыннарның берсен алып тора. «Яшь төрекләр»гә мөрәҗәгать итеп, ул 1906 елда ук «Әлгасрелҗәдит» (9/IX) журналында «Борадәренә нәсихәт» шигырен бастыра һәм анда революцион яшьләрне икейөзле булмаска, көрәштә эзлеклелек һәм кыюлык күрсәтергә өнди.

Тукай, авторларын күрсәтмичә генә, татар матбугатында «төрекчәдән» дип шактый күп шигырьләр бастыра. Аларның бер ишесе — иркле тәрҗемә, икенчеләре — ияреп язу. Мисал өчен шуларның берсе белән танышыйк:

Тән үстерсәң — җиһанда, бер дә шиксез, фил булу мөмкин:
Укып рухыңны гали әйләсәң — Җибрил булу мөмкин.

Әмма Тукай ифрат намуслы, иҗатына әһәмиятле этәргеч бирүчеләрнең исемнәрен укучыларына да белдерә. Мисалга, «Күңел йолдызы» шигырен ул 1909 елда Габдулла Җәүдәтнең (1869–1932) «Бер кыйтга» шигыреннән илһамланып яза, төрек каләмдәшенең икеюллыгын үз әсәренең эпиграфы итеп бастыра.

Күргәнебезчә, Габдулла Тукай иҗатында шәрык әдәбияты һәм иҗтимагый фикеренең тәэсире зур булган кебек, тугандаш төрки халыклар да аңа татар халкының олуг шагыйре, үзләре өчен бөек үрнәк буларак карыйлар. Г. Тукай төрки халыкларның эстетик фикерен якынайтуда, чыннан да, тиңе булмаган урын яулаган. Аны, хаклы рәвештә, барлык төрки кавемнәр үз итәләр, үзләренең сүз сәнгатьләренең табигый бер үрнәге буларак бәялиләр.

Тулаем алганда, киләчәктә төрле телләрдә Габдулла Тукай турында басылган мәкаләләрне барлау, бергә туплау безнең изге бурычыбыз булып калачак.

Татар халкының аталы язучысы, милли азатлык хәрәкәте җитәкчесе Гаяз Исхакый да Габдулла Тукай турында байтак мәкаләләр язган. Аларның кайберләре галимнәребез тырышлыгы белән җәмәгатьчелеккә килеп ирешт. Әмма әдипнең Төркиядә Тукай турында басылган кайбер мәкаләләренең эчтәлеге әлегә кадәр галимнәребезгә мәгълүм түгел.

Тукай – тугандаш төрки халыкларның иҗтимагый һәм әдәби фикер үсешенә зур йогынты ясаган шагыйрьләрнең иң күренеклесе. Шагыйрь әле үзе исән чакта чыккан шигырь җыентыклары Россия империясенең татарлар яшәгән барлык төбәкләрендә укылалар; Казан, Оренбург, Җаек шәһәрләре аша, Үзәк Азия һәм Төркестанда таралалар, Кырым белән Кавказга да үтеп керәләр; башкорт, казак, кыргыз, үзбәк, төрекмән, каракалпак, комыклар Тукай шигырьләрен тәрҗемәсез генә укып, көйли-җырлый башлыйлар. Милләтәшләребез тырышлыгы белән аның шигъри җәүһәрләре төркиләр яшәгән чит илләргә дә барып ирешә (Төркия, Кытай уйгырлары). Төрки дөньяның күп кенә зыялылары, шагыйрьләре Тукайдан илһам алдылар, аны остаз иттеләр; төрки-татар телләрен белгән таҗик Садретдин Гайни, кавказлы лак Сәед Габиев кебек каләм әһелләре татар шагыйре иҗаты белән оригиналда таныштылар.

Төрки дөнья яның күренкле шәхесләренең бөек Тукаебызга карата булган мөнәсәбәтләре турындагы мәгълүматны Г. Тукайның Яңа Кырлай авылындагы әдәби-мемориаль музей комплексында урнаштырылган экспозициянең «Тукай безнең көннәрдә» дигән бүлегендә дә күреп китәргә мөмкин. Биредә Каракалпакстанның халык шагыйре Ибраһим Йосыповның, Казахстан язучысы Җакана Сыздыкова, Анкара да яшәп иҗат итүче төрек язучысы Фатыйма Оскан, кыргыз язучысы К. Җунусов тәрҗемәләрендә Г. Тукай китаплары да саклана.

Яңа Кырлай урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыткан Яруллин Гомәр абыйның истәлекләренә күз салыйк: «1966 елның 26 июне Кырлайда Г. Тукайның тууына 80 ел тулуга багышланган юбилей, әдәбият бәйрәме, халыклар дуслыгы бәйрәме. Тантанада районыбызның меңләгән хезмәт ияләре, күпсанлы кунаклар, язучылар,сәнгать осталары. Казах язучысы, академик Сабит Мукановның, үзбәк язучысы галим Гафур Голәмнең Тукайның бөеклеге, аның иҗатының тугандаш әдәбиятларыбыз үсешенә уңай йогынтысы турында горурланып сөйләүләре әле дә хәтердә саклана» – дип язып калдырган ул.

Шушы олы юбилейдан башлап бездә һәр елны 25 апрельдә шагыйрьгә багышланган шигырь бәйрәме үткәрелә. Истәлекле вакыйгаларның берсе булып 1969 елның 28 маен да атап үтәргә кирәк. Бу көнне Яңа Кырлайда Әзербайҗан әдәбияты һәм сәнгате көннәре дә халыклар дуслыгы бәйрәме дәрәҗәсендә үтә.

Менә шул көннәрдән соң Кырлайга шагыйребез һәйкәленә кемнәр генә чәчәкләр китермәде икән?! Меңнәр, ун меңнәр Тукай йөргән эзләрдән Кырлайга килделәр. Алар:

Каракалпакстанның халык шагыйре, тәрҗемәче Ибраһим Йосыпов (1986), чит илдә яшәүче милләттәшебез Истамбул дәүләт университеты профессоры Надир Дәүләт 1995 елның 11 июлендә безнең музейга килеп: «Без чит илдә татарның бернәрсәсен белмәсәк тә, Тукайны белеп, аның шигырьләрен ятлап, «И туган тел, и матур тел» – дип җырлый идек», – дип язып калдырган. Надир ага Дәүләт Истанбулда чыккан «Тукай бюльлетене»нең һәрбер санында Тукай шигырьләрен урнаштыра килгән. Шуннан соң 1970–1982 елларда чыккан «Казан» журналында Тукай шигырьләрен төрекчәгә тәрҗемәләрен бастырган.

Язмабызны 2011 елны Тукайның 125 еллык юбилее уңаеннан үткәрелгән шигырь бәйрәмендә катнашкан төрек язучысы һәм тәрҗемәчесе Фатих Котлы сүзләре белән тәмамлыйсы килә: «Дөнья әдәбиятында эти-әнисез үсеп шундый олы шагыйрь була алган икенче бер кеше юктыр мөгаен. Мин Габдулла Тукайны Аллаһы Тәгаләнең татар милләтенә бик зур рәхмәте һәм бүләгедер дип саныйм».

ӘДӘБИЯТ

1. Ганиева Р.К. Шагыйрьнең рухи дөньясы («Габдулла Тукай» энциклопедик сүзлек-белешмәсенә әзерләнгән материаллардан). Казан: ТАРИХ, 2002. 112 б.).
2. Солнце народа. Габдулла Тукай. По материалам татарской эмигрантской печати. Казань, 2006. 190 с.
3. Тукай... Дөнья халыклары Тукай турында. Казань, 2006. 221 с.
4. Бөек Тукай Ватаны син, Арча. Казан: Яңалиф, 2007. Б. 194–201.
5. Тукайга чәчәкләр. Шагыйр турында шигыр ләр һәм фикерләр. Казан, Татар. кит. нәшр., 1975. 129 б.
6. Миннегулов Х. Этапы развития тюрко-татарской античной и русской литературы. Казань, 2010. 288 с.
7. Нуруллин И. Габдулла Тукай. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 301 с.

## КЫРЛАЙ КЕШЕЛӘРЕ ХАТИРӘЛӘРЕНДӘ Г. ТУКАЙ

***Кариева Л.Ә.***

Тюркский мир хорошо знает творчество своего великого поэта Г. Тукая. Его жизнь была нелегкой, он рано остался без родителей. В 1892 году очередные приемные родители привезли его в деревню Кырлай, где он жил до осени 1894 года. Кырлай он назвал «местом, где открылись его глаза на мир». Здесь люди помогли ему выжить в трудные годы, познакомили с песнями, баитами, легендами этого края. Потом герои фольклора дали ему импульс для создания прекрасных произведений. Г. Тукай прославил Кырлай поэмами о Шурале и Водяной. Позже старожилы этой деревни рассказывали ученым-литераторам свои воспоминания о детстве поэта. Эти рассказы раскрывают душу народа и подтверждают мысль поэта, «что народ – писатель и поэт».

The work of the great poet G. Tukay is well-known in the Turkic world. His life was not easy. He early was left without parents. In 1892, regular foster parents brought him to the village Kyrlay, where he lived until the autumn of 1894. "The place where the eyes were opened to the world", wrote Tukay in his memories about Kirlay. Here, people helped him to survive in the difficult years, introduced the songs, Baits, legends of this region. Then folk heroes gave him the impetus to create wonderful literary works. G. Tukay glorified Kyrlay with poems about Shurale and Water. Later, the old-residents of the village told scientistswriters about his childhood memories of the poet. The stories describe the soul of the people and confirm the idea of the poet, "that the people – a writer and a poet."

Борынгы Төрки берлек традицияләре гасырлар үтү белән генә онытылмады. Яңа Кырлай авылы кешеләре дә һәрвакыт төрки дөньяның бер кисәге булып яшәделәр. 1966 елның җәендә Г. Тукайның 80 еллык юбилеена, Кырлай авылы кешеләре чакыруы буенча кунакка килгәч, казакъ һәм үзбәк халыкларының танылган әдипләре Сабит Муканов һәм Гафур Голәм Казакъстанда һәм Үзбәкстанда Г. Тукайны үз шагыйрләре итеп кабул итүләрен Татарстан халкына сөйләп бирделәр. Менә шуңа күрә дә XX йөз башындагы Г. Тукай иҗаты гасырлар дәвамында күп сынаулар кичергән халыкларның җан авазы булып яңгырый. Ул «дөньяга күзем ачылган урын» дип санаган Кырлай бөек шагыйрь өчен туган илнең символы, ул балигъ булганчы туплаган күңел хәзинәсе һәм тормышны фәлсәфи кабул итүенең чишмә башы. Бу авылда ул табигатьнең гүзәллегенә сокланырга өйрәнә, әкиятләр, бәетләр, җырлар эчендә, үзләре хыялда тудырган

фантастик дөнья һәм табигать белән гармониядә яши белүче хаклыкны күрә. Халык иҗаты образлары булган Шүрәле һәм Су анасы хакында ул, монда ишетеп, соңыннан, шул нигездә мәңге үлмәс мифологик образлар тудыра.

Г. Тукай Кырлайда 1892 елның июненнән 1894 елның көзенә кадәр яши [1, б. 10–12]. Бөек шагыйрь үзенең тормыш юлы хакында 1909 елда язып калдырган «Исемдә калганнар» истәлекләрендә Кырлай чорына байтак урын бирә [2, б. 14–25]. Советлар вакытында, татар матбугатының 20 еллыгы уңаеннан 1926 елда, гарәп әлифбасында басылган Г. Тукай шигырьләре җыентыгының кереш сүзендә язучы Ф.Бурнаш аның Кырлай тормышы хакында шулай ук, «Исемдә калганнар» әсәрен файдаланып, беркадәр мәгълумат китерә [3, б. 8].

Бөек шагыйрь Г. Тукай турында истәлекләр туплау исә дәһшәтле Бөек Ватан сугышы көннәренә туры килә. Язучы һәм галим Мөхәммәт Гали Татарстан АССР Халык Комиссарларының махсус карары нигезендә 1944 елның 1–7 февраль көннәрендә Кызыл Юл районында командировкада булып, Кырлай кешеләреннән истәлекләр язып ала. Ул чагында шагыйрьне күреп белгән кешеләр исән була әле. Истәлекләр яздырганнарның тулы исемлеге филология фәннәре докторы Рамил Исламов тарафыннан «Мәдәни җомга» газетасында басылып чыкты [4, б. 11]. Мөхәммәт Гали шул кешеләрдән үзе язып алган истәлекләрдән өзекләрне Г. Тукай тормышына багышлап балалар өчен чыгарылган «Шагыйрь баскан эзләрдән» дигән китабында файдалана. Анда Г. Тукай замандашларыннан Нәфисә Әхмәтшина, Сафа Мөхәммәтшин, Әһли Хәлиуллин исеменнән Камилә Хәлиуллина, Хәлирахман Гобәйдуллин, Ахун Сабирҗанов истәлекләреннән өзекләр китерелә. М. Гали Тукайның шигырьләрен, табигать һәм ел фасылларын, тормыш белән хезмәтне янәшә куеп, балаларга аның иҗатын шагыйрьнең күзәтүләре аша аңлатып бирә [5, б. 10–28].

Шул ук 1944 елның июль аенда Татарстан партия өлкә комитеты язучыларны һәм галимнәрне фольклор экспедициясенә Кырлайга җибәрә. Бу уңайдан Тукайның замандашларын һәм авылдашларын, басуда эшләгән җирләреннән чакырып алып, бер төркемгә туплап, рәсемгә төшереп калалар. Бу рәсемне әнием Рәшидә Кариева гомер буе үзендә саклады һәм аны 2006 елның апрелендә, шагыйрьнең юбилее уңаеннан, Милли мәдәният музеена бүләк итте [6, б. 75]. Рәсемдә танылганнар исемлеге: Сафа Мөхәммәтшин (сулдан өченче), янәшәсендә – Таип Әхмәтшин, бабам Әһлиулла Хәлиуллин үлгән булу сәбәпле, аның урынына, татар мәҗлес гадәте буенча, энесе Ярулла Хәлиуллинны утыртканнар, Ахун Сабирҗанов, Хәбибрахман Гатауллин (Хәбри хәлфә), Нәфисә Әхмәтшина Һәм Фатыйма Шакирова.

Истәлек текстларының идеологик максатларда үзгәртелүе сәбәпле, һәркем дә хатирәләре белән уртаклашырга ашыкмый иде. Авылда бу хакта истәлек авторлары үзләре дә әйтә иде. Шундыйларның берсе әбием Камилә Хәлиуллина булды. Ул ире – бабам Әһлиулла Хәлиуллинның дусты Г. Тукай турындагы амәнәт итеп тапшырылган истәлекләрен язучы һәм галим Мөхәммәт Галигә сөйләп бирсә дә, үзенеке хакында дәшми кала иде. Аның истәлекләре шагыйрнең Өчиле авылына, тормыш кояшы баеп барган көннәрдә, 1912 елда, кунак булып кайтып йөрүен тасвирлый. Сөйләвен һәрвакыт: «Ул фирештә кебек иде», – дип тәмамлый иде. Кырлай янындагы Яңа Иябаш авылы мулласы, кодабыз, галим-энциклопедист Шәмсетдин Күлтәсинең кияве, Тукайның сабакташы һәм яшьтәше Хәбибрахман Әхмәрев та истәлекләрен язучы-галимнәргә сөйли алмый калды. Ул борынгы зыялы тәрбия алган кеше иде.

Тукай тормышының истәлекләрдә чагылышыннан тыш, Әхмәт Фәйзинең Тукай романының 1 китабы «Үги еллар» ны авылдашлар ярдәме белән язуы үзе бер вакыйгага әверелде. Кырлай турында язганда, автор, тормыш материалын, халыкның рухын тирәнтен өйрәнеп, аңа этнография, тарих, әдәбият, фольклор аша карап, Тукай иҗатының психологик нигезләрен тасвирлый белде [7, б. 139–284].

Быелгы «Безнең мирас» журналының беренче санында Рамил Исламов һәм Җәүдәт Миңнуллин «Тукай –ядкярләрдә» дигән мәкаләдә Г. Тукай турындагы басылган истәлекләргә күзәтү бирәләр. Шулай ук журналда беренче мәртәбә мәкалә авторлары хәзерләгән Камилә Хәлиуллина сөйләп бирүендә Әһлиулла Хәлиуллин һәм Хәким Нигъмәтҗанов истәлекләре дә тулысынча бирелгән . Хәким абый авылда оста теллелеге, фантазиясе белән дан алган кеше иде, аның истәлекләрендә ялтыратылмаган чын тормыш чагыла . Шулай итеп, журналда дөнья күргән бу мәкаләдә Г. Тукайның Кырлай чорын өйрәнүгә байтак материал өстәлгән [8, б. 24–29].

Р.Исламов һәм Җ.Миңнуллин моңа кадәр басылган Тукай турындагы истәлекләр тупланмаларына да бәя бирәләр. Аларга Кырлай кешеләре истәлекләре дә кертелгән. Шулардан беренче тапкыр аерым китап буларак 1960 елда дөнья күргән Сәгыйт Исәнбаев тарафыннапн төзелгән «Тукай турында замандашлары: Истәлекләр,мәкаләләр һәм әдәби әсәрләр җыентыгы». Китаптагы «Тукай Кырлайда» дигән аерым бүлектә Сафа Мөхәммәтшин, Ахун Сабирҗанов, Халирахман Гобәйдуллин истәлекләре урын алган [9, б. 31–38]. 1976 елда Ибраһим Нуруллин һәм Риф Якупов төзегән «Тукай турында хатирәләр» җыентыгында Кырлай кешеләре Хәлирахман Гобәйдуллин, Ахун Сабирҗанов., Хәбибрахман Гатауллин хатирәләре бирелгән [10, б. 9–15]. 1986 елда шагыйрь замандашларының хатирәләре – «Тукай турында истәлекләр» китабы дөнья күрде. Анда кырлайлылар Сафа Мөхәммәтшин, Халирахман Гөбәйдуллин, Ахун Сабирҗанов, Хәбибрахман Гатауллин истәлекләре басылган [11, б. 12–19].

Тукай тормышын өйрәнүгә күп көч салган журналистларның берсе Зәкия Рәсүлева. Аның «Тукай эзләреннән» дигән китабы игътибарга лаек. Автор бу җыентыкны «фәнни-документаль булуга дәгъва итми» дип белдерсә дә, андагы Кырлайга багышланган язмалар кызыклы, җанлы, җыентыкта халыкның Тукайга мөнәсәбәтен төрле яклап ачып бирелә. З. Рәсүлева үзе дә Кырлай кешеләре белән туганлык җепләре белән дә бәйләнгән булганга (җизнәләре Хәлирахман Гобәйдуллин), ул Кырлай кешеләренең борынгы нигезләрен дә санап чыга. Кереш сүз З.Рәсүлеваның Кырлай турындагы истәлекләренә багышланса, Кырлай кешеләре: Нәфисә Әхмәтшина, Һаҗирә һәм Гайфетдин Фәйзрахмановлар сөйләгән истәлекләр дә китапта урын алган [12, б. 3–9, 20–22].

Шушы гади һәм кыска гына истәлекләрдә соңыннан Г. Тукай әсәрләрендә расланачак гомумкешелек кыйммәтләре турында тирән тормыш фәлсәфәсе, халыкның шаян табигате, рухи ныклыгы күренә. Модый шартларда тормышта тәрбияләнгән шагыйрь киләчәктә Галәм югарылыгында гомумиләштерүләр ясаячак. Иҗади эшчәнлегендә монда күргән һәм ишеткәннәр композицион модель, жанрлар булып формалашмасалар да Дөнья сүрәте Кырлайда оеша. Соңыннан үсеш алачак гомуми образларына Кырлайда нигез салына. Киләчәктә поэзия «җан турындагы фән» буларак әдәбият гыйлемендә юл яргач, бу истәлекләр шул яссылыктан каралып, Тукай фантазиясе, илһам энергиясе белән чагыштырып, өйрәнелер.

ӘДӘБИЯТ

1. Габдулла Тукай: Тормыш һәм иҗат елъязмасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 271 б.
2. Тукай Габдулла. Әсәрләр : 4 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 431 б.
3. Тукай Г. Шигырьләр. Казан: Гажур, 1926. 198 б.
4. Исламов Рамил. Истәлек авторлары фотоларда // Мәдәни җомга. 2013. № 33. Б. 11.
5. Гали Мөхәммәт. Шагыйрь баскан эзләрдән. Таткнигоиздат. Яшьләр-балалар әдәбияты редакциясе. Казан. 1957. 48 б.
6. Мингазова Индуса, Шагеева Розалина. Два солнца нынешней весны // Казань. 2006. № 4. С. 75.
7. Фәйзи Әхмәт.Тукай: Роман. Беренче китап. Үги еллар. Казан: Татгосиздат. Матур әдәбият редакциясе. 1952. 301 б.
8. Исламов Рамил, Миңнуллин Җәүдәт. Тукай ядкярләрдә // Безнең мирас. 2016. № 1. Б. 24–29.
9. Тукай турында замандашлары: истәлекләр, мәкаләләр һәм әдәби әсәрләр җыентыгы / төзүчесе һәм текстларны әзерләүче Сәгыйт Исәнбаев; Г. Халит редакциясендә. Казан: Татар. кит. нәшр.,1960. 296 б.
10. Тукай турында хатирәләр / төзүчеләр һәм текстларга аңлатма бирүчеләр: Ибраһим Нуруллин, Риф Якупов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. 191 б.
11. Тукай турында истәлекләр / җыентыкны төзүчеләр һәм искәрмәләрне әзерләүчеләр: Ибраһим Нуруллин, Риф Якупов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 256 б.
12. Рәсүлева З.Ә. Тукай эзләреннән. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 141 б.

## Г. ТУКАЙ ИҖАТЫНДА АРХАИК ИЯРТҮЧЕ ТЕРКӘГЕЧЛӘР

***Кириллова З.Н.***

Работа посвящена исследованию архаичных форм подчинительных союзов в произведениях Г. Тукая: чөн ‘потому что, так как’, ‘когда’; чөнкем ‘потому что, так как’; гәр ‘если’; әгәрчә ‘хотя’; санки ‘будто, как будто, словно’; хосусән ‘особенно’. Данные союзы больше встречаются в творчестве Тукая до 1909 года и вводят придаточные причины (чөн, чөнкем, зирә), времени (чөн), условия (гәр), уступительности (әгәрчә) и образа действия или сравнения (санки,

санкем). Из современных тюркских языков устаревшие для современного татарского литературного языка варианты подчинительных союзов сохранились в огузско-сельджукской подгруппе тюркских языков.

Work is devoted to research of archaic forms of subordinating conjunctions in Tukay's works: чөн 'because, as', 'when'; чөнкем 'because, as'; гәр 'if'; әгәрчә 'though'; sledge 'as if, as though, as if'; хосусән 'especially'. These unions meet in Tukay's creativity more till 1909 and enter causal clauses (чөн, чөнкем, зирә), time (чөн), conditions (гәр), ustupitelnost (әгәрчә) and an image of action or comparison (санки, санкем). From modern Turkic languages the options of subordinating conjunctions which were outdate for the modern Tatar literary language have remained in oguz-seldzhuk subgroup of Turkic languages.

Г. Тукай – XX йөз башы татар әдәбиятының иң күренекле вәкиле, чын мәгънәсендә халык шагыйре, җәмәгать эшлеклесе һәм, гомумән, күпкырлы шәхес. Аның әсәрләре әдәби яктан гына түгел, тел яссылыгында да шактый өйрәнелгән һәм хәзер дә тикшеренүләр үзәгендә кала бирә.

Чыгышыбызның максаты – Г. Тукай әсәрләрендә ияртүче теркәгечләрнең искергән формаларын тикшереп, XX гасыр башы татар әдәби телендә аларның иярченле кушма җөмлә һәм өлешчә гади җөмлә кисәкләре төзүдәге ролен ачыклау. Тикшерү берьяклы гына булмасын өчен, әлеге теркәгечләрне куллану үзенчәлекләре ягыннан Тукайның кайбер замандашлары иҗатына да мөрәҗәгать ителде.

Гомумтөрки истәлекләрдә дә, аерым төрки телләрнең беренче язма чыганакларында да бер-бер артлы тезелеп барган гади җөмләләр өстенлек ала. Алар ярдәмендә тезүле бәйләнеш тә, ияртүле бәйләнеш тә белдерелергә мөмкин [6, б. 162]. Әмма тел үсеше дәвамында аерым җөмләләрне тезеп бирү генә барлык мәгънә төсмерләрен бирә алмый башлый. Нәтиҗәдә, төрки телләрдә, бер яктан, иярчен җөмләнең хәбәрен затланышсыз фигыль формалары белән белдерү, икенче яктан, гади һәм кушма җөмләләрдә теркәгеч яки теркәгеч сүзләрне куллану арта бара. Теркәгечләрнең төрки телләрдә урын алуына гарәп һәм фарсы телләренең көчле йогынтысы да этәргеч бирә.

Тукай әсәрләрендә ияртүче теркәгечләрнең искергән формаларына чөн, чөнкем, гәр, әгәрчә, санки, хосусән керә. Шуларга аерым-аерым тукталып үтик.

Сәбәп мәгънәсен белдерү өчен, хәзерге төрки телләрнең күпчелегендә урын алган фарсы чыгышлы чөнки теркәгече белән беррәттән, төрки чыганакларда **чүн/чөн** формасы да кулланыла. Көньяк төрки телләр тарихында чүн теркәгече иярчен вакыт, сәбәп һәм шарт җөмләләрне формалаштыруда катнашкан, хәзерге вакытта исә ул сәбәп мәгънәсен генә белдерүгә күчкән [4, б. 365]. Г.А. Абдурахманов тикшеренүләреннән күренгәнчә, XI гасыр язма истәлеге «Котадгу белек» әсәрендә чүн теркәгече бер дә очрамый, ә XVI йөздә иҗат ителгән «Бабурнамә»дә исә ул зур урын ала. Чүн теркәгеченә күпчелек мисаллар сәбәп мәгънәсен белдерүгә хезмәт итә, вакыт һәм кире шарт мөнәсәбәтенә исә берничә җөмлә генә табылган [1, б. 206].

Иске татар телендә язылган әсәрләрдә әлеге теркәгеч сәбәп яки вакыт мөнәсәбәтләрен белдерергә мөмкин. Г. Тукай шигырьләрендә аның сәбәп мәгънәсен белдерүенә мисаллар күбрәк урын ала. Мәсәлән:

Дугъры сөйлә, дугъры яз – хәүфитмә һичбер кемсәдән,
Сабир ул, чөн дөшмәмешдер эшләрең сәһли сәңа.
Бәхтиярсән дүрт җаридә сахибе улмакла сән, –
Чөн акар һәр дүрт тарафдан мәгърифәт ңәһри сәңа.

(Дөресне сөйлә, дөресне яз – беркемнән дә курыкма;
Сабыр бул, чөнки сиңа эшнең җиңеле йөкләнмәгән.
Дүрт газета-журнал иясе булуың белән син бәхетле –
Чөнки сиңа һәр дүрт яктан мәгърифәт елгасы ага).
(Мөхәрриргә («Китмәсен кәйфең...»), 1906)

Чөн теркәгеченең иярчен сәбәп җөмлә хасил итеп, аның башында килүе тулысынча хәзерге телдәге чөнки теркәгеченә тәңгәл килә.

Чөн теркәгеченең вакыт мәгънәсен белдереп, кайчан дип тәрҗемә ителүенә бары 2 мисал гына табылды, алар икесе дә бер үк әсәрдә урын алган:

Чөн болар һәп (болар барысы да. – *З.К.*) пәһлеванны күрделәр;
Бер авыздан бөйлә фөрьяд кыйлдылар (ачынып еладылар. – *З.К.*);

Чөн Печән базары халкы күрделәр,
Барча күрешмәк өчен йөгерделәр.
(«Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш», 1908)

Күренгәнчә, соңгы мисалларда чөн теркәгече иярчен вакыт җөмлә башында килеп, аны баш җөмләгә бәйләүдә төп рольне үти, һәм мондый җөмлә тибы хәзерге телебез өчен хас түгел.

Азәрбайҗан, төрек һәм төрекмән язма истәлекләрендә табылган чүнким теркәгеченең [5, б. 156] аналогы булган **чөнкем** бәйләүче чарасына бары бер мисал гына табылды:

Нәрсәдә ләззәт икән? Чөнкем ялан дөньяда кәм;
Мин ләзиз шәйләр, вә ли кайсында ләззәт, кайда тәм? –
(Нәрсәдә ләззәт? Чөнки азмыни ләззәтле нәрсәләр;
Ләкин аларның кайсында ләззәт тә кайсында тәм?)
(«Ләззәт вә тәм нәрсәдә?», 1907)

Төрле төрки телләрдә егер/эгер/әкәр/кәр формаларында кулланылучы [4, б. 351] фарсы чыгышлы әгәр теркәгеченең **гәр** вариантына Тукай шигырьләреннән 10 мисал табылды, аларның зур күпчелегендә теркәгеч, хәзерге телдәге әгәр кебек үк, иярчен җөмләнең шарт фигыль формасындагы хәбәре белән берлектә кулланылып, өстәмә роль генә үтәп килә:

Сән гасәл (бал. – *З.К.*) вир анлара, гәр вирсәләр зәһри (агу. – *З.К.*) сәңа.
(Мөхәрриргә («Китмәсен кәйфең...»), 1906)

Гәр теркәгеченең ирсә ярдәмлеге яки -са да формасы белән килүенә берәр мисал гына күзәтелде:

Мәкам тот (урын тап. – *З.К.*), эстәр ирсәң гәр, сәмадан йә сөрәйядән
(күктә я йолдызлар арасында. – *З.К.*).
(«Хөрриятә», 1907)

Корсагы гәр туйса да,
Туймагай һич тә күзе.
(«Ахырзаман галәмәте», 1907)

Күренгәнчә, Тукайга нисбәт ителгән «Ахырзаман галәмәте» шигыреннән алынган өзектә гәр теркәгече иярчен кире җөмлә составында урын алган.

Әгәр сүзеннән ясалган егерчи/герчи/герче теркәгечләре азәрбайҗан, төрек, төрекмән телләрендә һәм аларның язма истәлекләрендә очрый [4, б. 351]. Тукай әсәрләрендә исә **әгәрчә** формасына бары бер генә мисал табылды:

Әгәрчә зәррә мыскал һиммәте (яхшылыгы; ярдәме. – *З.К.*) бар,
Анның артында тау-тау миннәте (мактанып сөйләве. – *З.К.*) бар.
(«Тормыш», 1908)

Дәрдмәнд шигырьләрендә исә әлеге теркәгеч активрак кулланыла:

Әгәрчә мөмкин эштер һәр җүләргә
Авыз җырып һөнәрледән көләргә [...].
Кибетчегә биреп, диде, китапны
(Әгәрчә дәртләргә дәва бу) һ.б.

Хәзерге телдәге гәрчә теркәгеченнән аермалы буларак, әгәрчә бәйләүче чарасы шарт фигыль кушымчасы һәм да/дә кисәкчәләре белән кулланылмый, нәтиҗәдә аналитик иярчен кире җөмлә ясауда төп рольне үти.

Көньяк-көнбатыш төрки телләрдә, шулай ук кумык телендә чагыштыру мәгънәсен белдергән иярчен җөмләләр төзүдә катнашучы **санки** [4, б. 363] теркәгеченә XX йөз башы татар әдәбиятыннан мисалларны Дәрдмәнд һәм Г. Тукай әсәрләреннән генә табарга мөмкин. Г. Тукай үзенең башлангыч чор шигырьләрендә генә түгел, башка архаик теркәгечләрдән аермалы буларак, икенче чор иҗатында да санки бәйләүче чарасына мөрәҗәгать итә. Охшату-чагыштыру мәгънәсен белдерә торган әлеге теркәгеч гади җөмләдә дә урын алырга мөмкин:

Һәр каралткан кәгаземдә санки багъ, бостан (бакча. – З.К.) була;
Һәр хәрефтән каршыма вилдан вә гыйльманым (җәннәт
хезмәтчеләре. – З.К.) килә.
(«Тәрәддед вә шөбһә» («Икеләнү һәм шикләнү»), 1909)

И җәмилә! Гыйшкыңызда бунча әшгар сөйләдем;
Зәррә микъдар варса мәйлең, кабили ли кабили!
Санки гыйшкың – бер кәлисә, бән – аның накусием;
Икләрем аһ-ваһ идеб, мән насыйри, мән маили.

(И гүзәл кыз! Сезне сөюдән күп шигырь сөйләдем;
Аз гына сөйсәң, мин шиксез кабул итәм, кабул итәм!
Гүя гыйшкың – бер чиркәү, ә мин – аның чаңымын;
Аһ-ваһ итеп, мин ул тавышны көчәйтергә тырышамын).
(«Мәхү идәрмисән?» («Юк итәрсезме?»), 1906)

Ләкин күпчелек мисалларда санки теркәгече, иярчен рәвеш җөмлә хасил итеп, аның башында да, уртасында да килергә мөмкин:

Бар күңел хәдсез, хисапсыз мәрхәмәт, шәфкать тулы,
Санки күңлең – җиргә күктән ингүче рәхмәт юлы.
(«Сагыныр вакытлар», 1912)

Бераздан санки безгә килде илһам:
«Гыйлем» булдык, хәзер без әһле фәтва (соңгы сүзне, хәлиткеч фикерне әйтүче. – *З.К.*).
(«Ысуле кадимче», 1908)

Дәрдмәнд исә әлеге теркәгечнең санкем формасын да куллана:

Санкем угыл-кыз туен итмәктә ул, кызган уен,
Йөгрешеп, курчак төшеп менмәктә ак бармагына.

Хәзерге татар әдәби телендә я аныклаулы мөнәсәбәт урнаштыручы ияртүче теркәгеч сүз (8, б. 258; 7, б. 361), яки аныклаучы теркәгеч [9, б. 96; 10, б. 370] дип билгеләнгән бигрәк тә, аеруча бәйләүче чараларының архаик формаларына түбәндәге теркәгечләрне кертергә мөмкин: хосусән, хосуса, хассы, бахосус/ба хосус, ба хосус ки, хосусилә, хосусы илә ки, бәлхассән һ.б. Алар арасыннан бары гарәп теленнән алынган **хосусән** теркәгеченә генә Г. Тукай әсәрләреннән аныклагыч җөмлә кисәген һәм иярчен аныклагыч җөмлә хасил иткән мисалларны китерергә мөмкин:

Сөям бигрәк, хосусән, садреңезне (күкрәгегезне. – *З.К.*);
Ни соң ул: шәмсеңезме (кояшыгызмы. – *З.К.*), бәдреңезме (тулган аегызмы. – *З.К.*)?
(«Татар кызларына», 1906)

Һаман сак бул, кара ул як, бу якны;
Хосусән сак тоту лазем колакны.
(*** («Ничек тормак тиеш, дустым? – дисеңме...», 1909)

Гомумән, хосусән теркәгече XX гасыр башы татар әдәби телендә гаять актив. Мәсәлән: *Хосусан, мондай бер кыз килеп кергән вакытта үзенең камзулчан гына утыруына оялып китте, вә көзгене тизрәк бер читкә – өстәлгә алып куйды* (Ф. Кәрими). *Хәятның рус телен бик яхшы белүе һәм, кечкенәдән үк рус гаиләләренә, вә хосусан, Мясниковларга катышып килеп, рус җәмгыятендәге гореф вә әдәпләрне яхшы ук өйрәнгән булуы да тәрбияләр арасындагы бу зур аерманы каплап тора иде* (Ф. Әмирхан) һ.б.

Башка төрки телләрдән әлеге теркәгеч хәзерге төрек, үзбәк, азәрбайҗан телләрендә дә кулланыла. Ф. Кәрими, Г. Исхакый әсәрләрендә күзәтелгән бахосус, хосусилә, бәлхассән теркәгечләренә мисаллар исә Тукай әсәрләрендә урын алмый.

Шулай ук XX йөз башы татар әдәби телендә, сәбәп мөнәсәбәтен белдерү өчен, фарсы теркәгече **зира/зирә** дә актив кулланыла. Нигездә азәрбайҗан, гагауз, төрек һәм үзбәк телләрендә таралыш алган әлеге теркәгеч [4, б. 352; 5, б. 157–158] җөмләләрне бәйләүдә үзе генә яки ки теркәгече белән катнаша. Мәсәлән: *Ләкин, борадәрем, хата итәсез, зира бер нәрсәне белү өчен мотлак үзең кылу лязем түгелдер* (Г. Исхакый). Тукай шигъриятендә әлеге теркәгечкә мисал табылмаса да, «Рәхәт йокы» хикәясендә ул зирә теркәгеченә мөрәҗәгать итә: *Гөнаһсыз бала! Кулыңда форсат бар вакытта уйна да көл, зирә озакламый шундый бер хезмәтләр, мәшәкатьләр уртасында калырсың ки, бу көнге хуш вакытлар, күңелле заманнарыңның эзе дә калмас.*

XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби телендә, моннан тыш, гарәп чыгышлы һәм «чөнки, әгәр шулай икән, чынлыкта» мәгънәләрен белдерүче **мадам ки** теркәгече дә урын ала: *Мәдәнияте юк бер милләтнең промышленносте була алмый,*

*мадамә ки ул юк әле, сыйнфый низагларга да иртә* (Ф. Әмирхан) һ.б. Әмма Г. Тукай әсәрләрендә мадам ки теркәгече күзәтелмәде.

Тукай шигырьләрендәге ияртүче теркәгечләрнең искергән формалары белән хәзерге телдә актив булган вариантларны чагыштырып карасак, аларның кулланылыш ешлыгын түбәндәге саннар белән күрсәтергә мөмкин: чөн – 10 (сәбәп мәгънәсендә – З.К.), зирә – 1, чөнки – 33; гәр – 10, әгәр – 47; әгәрчә – 1, гәрчә – 8; санки – 9, гүя – 14 [2; 3]. Искергән формалар Тукайның 1909 елга кадәрге иҗатында күбрәк урын ала, бары санки теркәгече генә әлеге кагыйдәдән чыгарма булып тора. Хәзерге тел өчен табигый булган вариантлар исә шагыйрьнең барлык иҗаты дәвамында кулланыла.

Йомгак ясап әйткәндә, Тукай әсәрләрендә ияртүле бәйләнешне барлыкка китерүче теркәгечләрнең искергән формаларына чөн, чөнкем, гәр, әгәрчә, санки бәйләүче чаралары керә. Алар сәбәп, вакыт, шарт, кире шарт яки охшату-чагыштыру мөнәсәбәтләрен белдерү өчен хезмәт итәләр. Тикшерелгән ияртүче теркәгечләр Тукайның 1909 елга кадәрге иҗатында зуррак урын били. Аныклаулы мөнәсәбәтне белдерүче архаик теркәгечкә хосусән бәйләүче чарасын кертергә мөмкин, әмма ул XX гасырның 90 нчы елларыннан яңару процессын кичерде. Ияртүче теркәгечләрнең искергән формалары хәзерге төрки телләрнең угыз-сәлҗүк төркемчәсе (төрек, азәрбайҗан) телләрендә сакланып калган.

ӘДӘБИЯТ


1. Абдурахманов Г.А. Исследование по старотюркскому синтаксису (XI век). М.: Наука, 1967. 210 с.

2. Габдулла Тукай: Шигърият теле: Сүзлек. 2 китапта. 1 нче китап / К.Р. Галиуллин, Р.Н. Кәримуллина. Казан: Мәгариф, 2009. 503 б.

3. Габдулла Тукай: Шигърият теле: Сүзлек. 2 китапта. 2 нче китап / К.Р. Галиуллин, Р.Н. Кәримуллина. Казан: Мәгариф, 2009. 527 б.

4. Гаджиева Н.З. Основные пути развития синтаксической структуры тюркских языков. М.: Наука, 1973. 408 с.

5. Гаджиева Н.З. Синтаксис сложноподчиненного предложения в азербайджанском языке (в историческом освещении). М.: Изд-во АН СССР, 1963. 220 с.

6. Гаджиева Н.З., Серебренников Б.А. Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Синтаксис. М.: Наука, 1986. 284 с.

7. Зәкиев М.З. Татар грамматикасы. Т. III. Синтаксис. М.: Инсан, Казан: Фикер, 1999. 512 б.

8. Зәкиев М.З. Татар синтаксисы: Югары уку йортлары өчен д-лек. Казан: Мәгариф, 2005. 399 б.

9. Ибраһимов С.М. Татар телендә аналитик төзелмәләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. 131 б.

10. Татар грамматикасы. Т. II. М.: Инсан, Казан: Фикер, 2002. 448 б.


# ОБРАЗЫ К. ИВАНОВА И Г. ТУКАЯ В ЧУВАШСКОЙ И ТАТАРСКОЙ ДРАМАТУРГИИ


***Кириллова И.Ю.***



В статье проведен анализ произведений чувашской и татарской драматургии, которые посвящены К. Иванову и Г. Тукаю. Их связывает историческая эпоха, всенародное признание и одинаковая трагическая судьба, которая и отразилась в литературе о них.

In the article the analysis of works of Chuvash and Tatar drama, which is dedicated to K. Ivanov and G. Tukay. Their unites era, national recognition and the same tragic fate, which was reflected in the literature about them.


Г. Тукай и К. Иванов гениальны в своем национальном. Благодаря им возрастают вес и значение татарской и чувашской литератур в глазах других народов. Они подготовили почву для будущих поколений. Опираясь на заложенные ими реалистические традиции, поднялось много других поэтов. Их образы стали неисчерпаемым источником вдохновения для создания произведений практически во всех литературных жанрах. Особый интерес представляют их образы в драматургии.

К образу Габдуллы Тукая в драматургии в разное время обращались такие татарские писатели как А. Файзи («Тукай», 1938), Т. Миннуллин («Мы уходим, вы остаетесь», 1985), А. Гаффар («Последний час», 1986), И. Юзеев («Улетела из клетки мироздания», 1980–1991), А. Баян («Черная птица», 1989–1991) и другие. Каждый из авторов в своих творениях старался отразить как жизнь поэта в целом, так и отдельные

ее периоды. Но цель у всех одна – раскрыть роль и значение классика в жизни и деятельности татарского народа. Анализ этих драм и трагедий показывает, что «не только произведения великого Тукая, но и его жизненный путь, его мужественный образ, как факел, помогал читателям и зрителям в непростые годы XX века достойно вынести трудности и тяжёлые испытания» [8, с. 87].

В разные периоды развития общества драматургами выявляются свои особенности изображения характера Тукая, его жизнедеятельности. Так, если в советские годы конфликт в этих пьесах разрешался в социально-классовом ключе, то современные трагедии в большей степени озадачены решением проблемы становления Тукая как личности, впоследствии воздвигнутого в ранг национального героя и передового мыслителя своего времени.

Так, в трагедии И. Юзеева «Улетела из клетки мироздания» представлена «картина его жизни с рождения до становления в качестве истинного борца за светлое будущее татарского народа» [7, с. 157]. Свободу татарского общества Тукай видит в просвещении, во взаимодействии с Европой и Востоком, преобразовании медресе и т.п. Конфликт между Тукаем и Хазрет (собирательный образ консервативного исламского духовенства начала XX в.) вырастает до противостояния поэта с властью: «Поэт – духовный лидер татарского народа – с глазу на глаз беседует с русским монархом во время празднования трехсотлетия дома Романовых. Однако после этой беседы политика, проводимая Царем в отношении татарского народа, не меняется: «Самое правильное – держать его в клетке…» [7, с. 158]. Совсем еще молодой Тукай умирает от тяжелой болезни, не дожив до освобождения татарского народа от оков старой жизни, борьбе с которой он посвятил себя, но его имя и стихи навсегда останутся в памяти народа.

Трагическая судьба Г. Тукая во многом созвучна с жизнью великого классика чувашской поэзии Константина Иванова.

Художественное воплощение образа К. Иванова в чувашской драматургии более полно было представлен в драме «Константин Иванов» И. Максимова-Кошкинского, современника поэта. Они оба учились в Симбирской чувашской школе, основанной просветителем чувашского народа И.Я. Яковлевым. События в драме происходят именно в период учебы поэта в этой школе.

Драма «Константин Иванов» имеет несколько вариантов, что объясняется переходной эпохой времени ее создания и меняющимся общественным отношением к историческим личностям, героям драмы. Основной конфликт в пьесе 1950 г. выстраивается на столкновении классика чувашской поэзии К.В. Иванова с чувашским просветителем И.Я. Яковлевым в преддверии первой русской революции. Противопоставление двух одинаково значимых для народа исторических фигур было вызвано неоднозначным отношением к И.Я. Яковлеву в послереволюционные годы, когда патриарх в силу атеистической политики советской идеологии и устранения представителей старого, отжившего режима был обвинен в миссионерско-русификаторской деятельности. Усиливая нападки, ему было «приписано» обвинение в преждевременной смерти К. Иванова, по которому якобы «Яковлев его посадил на Библию», и «занятия переводом этой книги подорвали и без того слабое здоровье поэта» [2]. Вскоре это утверждение укрепилось в сознании общественности, а «сама конфликтная ситуация, где изображается поэт (словно птица в неволе), проклинающий сильных мира сего, чахнет на глазах, иссушая душу над бессмысленным переводом «отмененной» большевиками книги, легла в основу многих произведений чувашских авторов» [1, с. 225]. Это и поэма «Поэтпа миссионер» (Поэт и миссионер, 1929–1930) П. Хузангая, и трагедия «Хура элчел» (Черная судьбина, 1940) Я. Ухсая, и пьеса «Константин Иванов» И. Максимова-Кошкинского и другие.

Характер Константина Иванова в пьесе И. Максимова-Кошкинского получился разноплановым: это бесстрашный боец за справедливость, который восстает против обирающего бедняков отца-богача, против своего учителя И.Я. Яковлева, который из-за боязни закрытия Симбирской чувашской учительской школы (СЧУШ) заставляет учеников переводить религиозную литературу и преклоняется перед «его величеством» царем, против деспотичного мужа любимой Прасковьи. Суть характера героя отразил в названии спектакля по данной пьесе главный режиссер Чувашского академического драматического театра (ЧГАДТ) В.Н. Яковлев, через 65 лет восстановивший

спектакль к 125-летию со дня рождения поэта-классика – «Вĕри юнлă çемçе чун» (дословный перевод – «Мягкая душа с горячей кровью», 2015).

Выбранный автором образ К. Иванова был продиктован самим временем создания пьесы. Советские литературоведы, в частности М.Я. Сироткин, в силу идеологизированно направленной критики пытались представить поэта революционером-пролетариатом, а конфликт его классической поэмы «Нарспи» связывали с отражением классовой борьбы богатых и бедных [5].

Сегодня же, исходя из воспоминаний современников К. Иванова, мы знаем, что поэт был далек от политики и революции [4, с. 35–36]. Цели и задачи чувашской интеллигенции он видел в просвещении народа, обогащении ее языка, литературы и культуры через опыт мирового культурного наследия. Его поэма «Нарспи», отразившая в себе отпечаток чувашского эстетического сознания рубежа XIX–XX веков, является ярким примером «взаимодействия мифологического начала (народного) с эстетическими системами Запада (привнесенными в чувашскую литературу учениками СЧУШ)» [3, с. 110].

Если бы образ К. Иванова в пьесе соответствовал реальности, конфликт в ней был бы не столь острым и принижающим роль И.Я. Яковлева в национальной истории, ведь по сути деятельность обоих была направлена во благо чувашского народа.

После выхода в 1954 г. в ЧГАДТ спектакля «Константин Иванов», в печати выступил близкий друг поэта И. Трофимов с опровержением легенды, по которой К. Иванов «благодаря Библии заболел чахоткой»: «Известный чувашский драматург И.С. Максимов-Кошкинский главный конфликт своей пьесы основывает на этой ложной легенде. Эта легенда безжизненна. Иван Яковлевич никогда не принуждал К.В. Иванова переводить Библию и не мог этого допустить» [6, с. 15]. При этом сельский учитель приводит неопровержимые доказательства и весомые аргументы. Этому способствовала и политическая «оттепель», в период которой честное имя И.Я. Яковлева было восстановлено. В Чувашской АССР в 1968 г. торжественно и всенародно празднуется 100-летие СЧУШ и 120-летие ее основателя.

К этому событию И. Максимов-Кошкинский написал третий вариант пьесы, по которому на сцене ЧГАТ был поставлен спектакль «Тăвăл хыççăн тăвăл» (Буря за бурей, 1968). Конфликт между К. Ивановым и И.Я. Яковлевым в нем был смягчен, а деятельность последнего оправдана тяжелыми временами царизма.

Пьеса «Буря за бурей» (Константин Иванов) И. Максимова-Кошкинского заслуживает внимание читателей и литературоведов как первая историческая драма о классике чувашской поэзии.

Как видим, в рассмотренных нами произведениях драматургии и Г. Тукай, и К. Иванов представлены писателями национальными героями, вобравшими в себя лучшие качества своего народа. И здесь свою роль играют значимость классиков в истории литературы и всеобщее народное признание их творчества. Кроме того, раскрывая жизнедеятельность великих, авторы поднимают проблемы, которые волновали народ в разные периоды его истории, и которые непосредственно связаны с общечеловеческими идеями. Ведь судьба человеческая – это судьба народная (Пушкин), и судьбы Тукая и Иванова неопровержимое доказательство этому.

ЛИТЕРАТУРА


1. Артемьев Ю.М. Константин Иванов: Жизнь. Судьба. Бессмертие. Чебоксары: Чуваш. кн. изд-во, 2013. 255 с.

2. Васильев-Шубоссинни Н. 15 çултан // Канаш. 1922. Чӳк, 14.

3. Кириллова И.Ю. Внутрижанровый синтез в чувашской литературе // Филологические науки. Вопросы теории и практики. Тамбов: Грамота, 2015. № 11 (53): в 3-х ч. Ч. 3. С. 109–111.

4. Константин Иванова аса илеççĕ. Шупашкар: Чăваш кĕн. изд-ви, 1990. 271 с.

5. Сироткин М.Я. К.В. Иванов. Критико-биографический очерк. Чебоксары, 1955. 32 с.

6. Трофимов И. К.В. Ивановпа пĕрле ĕçлени // Ялав. 1955. № 5. С. 14–15.

7. Шаехов Л.М. Образы исторических личностей в трагедиях Ильдара Юзеева // Ученые записки Казанского государственного университета. Гуманитарные науки. Казань: КГУ, 2010. Том 152, кн. 2. С. 155–160.

8. Шарипов М.С. Татар драматургиясендә Тукай образы гәүдәләнеше // Наследие Габдуллы Тукая в контексте национальных культур: материалы международной научно-практической конференции (25 апреля 2011 г.). Казань: ИЯЛИ, 2011. С. 87–90.

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ И НАЦИОНАЛЬНАЯ ЛИТЕРАТУРА

***Кириллова Р.В.***

В статье анализируется поэтическое творение великого татарского поэта, классика Габдуллы Тукая, созданное на широком фольклорно-мифологическом материале татарского народа, отмечены особенности стихосложения, композиции, стиль языка. Выделены наиболее значимые мотивы и сюжеты произведений. Актуализирована значимость его произведений для дальнейшего развития татарской литературы, культуры и роста самосознания народа.

The paper aims to analyze great Tatar poet Gabdulla Tukay's poems which are based on Tatar folklore and mythology. The author researches their features of versification, composition and language, emphasizes their most significant motifs and plots, and also highlights the importance of his poetry for further development of Tatar literature, culture and consciousness raising.

Г. Тукай (1886–1913) вошел в историю татарской литературы как великий поэт, заложивший основу новой национальной поэзии, как один из основоположников современного татарского языка; творчество великого Тукая принадлежит мировой литературе и культуре. Он стал одним из самых продуктивных татарских поэтов того времени: при его жизни увидели свет более 30 сборников стихов. Его труды переведены на многие языки мира. К сожалению, творческая деятельность поэта продолжилась недолго. Он ушел из жизни в возрасте 27 лет, оставив после себя более 400 стихов, 9 поэм, 107 басен, свыше 300 рассказов, фельетонов, очерков и воспоминаний…

Исключительная широта творчества Г. Тукая базировалась на прочном фундаменте: он хорошо владел устным народным творчеством, был знаком с шедеврами арабской, персидской и турецкой литератур, прекрасно владея их языками; вскоре он откроет для себя богатейший мир русской и западноевропейской литератур.

Его ранние стихотворения общественно-политического направления («О свободе», «Одно слово друзьям», «О единстве») призывают к защите прогресса и равноправия народов. Изначально и до конца жизни Г. Тукай был тверд в своей гражданской позиции. Уже в 1908 г. он создал цикл стихотворений о крестьянах, сельской жизни и о своей малой родине. К дореволюционному творчеству поэта относятся высокохудожественные поэтические и очерково-публицистические произведения, исчерпывающе ясно и глубоко выражающие его отношение к народу: «Осенние ветры» (1911), «Гнет» (1911), «Дача» (1911), «Чего же не хватает сельскому люду?» (1912), «Надежды народа …» (1913) и другие. Это – классические образцы гражданской и социальной лирики для широкого круга читателей – о сложной, своеобразной судьбе народа, исполненной боли и радостей. Так, в одном из выступлений в Государственной думе, а также в официальной печати татарам было предложено уехать из Российской империи; многие соотечественники Г. Тукая были поставлены тогда перед выбором: оставаться на родной земле или уехать с в Турцию? На что поэт ответил стихами «Не уйдем»:

...Мы уйдем, когда за нами вдаль уйдут и города,
Цепь лихих тысячелетий, наши горькие года.
От рожденья до кончины за родной живя чертой,
Мы срослись навеки плотью с почвой родины святой!
(Перевод С. Липкина)

Сиротство настигло Габдуллу Тукая еще в колыбели: в 4-месячном возрасте он лишился отца, а в 4 года остался без матери, так что детство его прошло без родительской ласки и любви, по большей части – в невыносимых условиях жизни. Вот почему сумел он во всей полноте передать в своем творчестве трагическую историю простого народа, его тяжелое настоящее и неопределенное будущее. Посвятив себя поэзии, Тукай яростно боролся со всеми проявлениями реакции. Его главным девизом стало:

С кем только жизнь в злой распре ни бывала?
В борьбе ты ей не уступай нимало!
(«Жизнь», 1908) Перевод Л. Липскерова.

В стихотворениях «Татарским девушкам», «Кого любить?», «Осень» «Поэту», «Книга» уже ясно чувствуется зреющий талант тонкого лирика. Он пробуждает глубинные переживания, волнующие читателя, или же подкупает простым, задушевным словом, образностью, высоким мастерством лаконичного выражения.

Не бывать цветам и травам, если дождик не пойдет.
Что ж поэту делать, если вдохновенье не придет?
Всем известно, что, знакомы с этой истиной простой,
Байрон, Лермонтов и Пушкин вдохновлялись

«Любовь» (1909). Пер. Вс. Рождественского

Он глубоко любил народную музыку, татарские песни, вдохновлявшие его на создание лучших своих произведений: таких, как «Шурале», «Су анасы», «Национальные мелодии», «Книги». Они восхитили современников поэта не только общим содержанием, но и самим словом. Хотя и существовали разные мнения. Так, «…Ему предъявлялись обвинения в том, что язык литературных его произведений – это язык улицы, язык необразованных торговцев и крестьян, который никак нельзя брать в качестве основы для литературного языка "Печэн базары теле" (*Язык Сенного базара*) "чабаталы урам теле"» (*уличный язык*) [11, с. 161].

Тукаю близок и дорог народный язык – это язык деревни, «родной язык». Именно такое название («Туган тел») носит стихотворение, до настоящего времени считающееся наиболее ярким выражением любви Тукая к своему *народу*, *краю* и *языку*. Для поэта все они – неразделимые понятия, их постоянно воспевал он в своих произведениях и в устных выступлениях, что явилось ярким примером для подражания ему многих поэтов и писателей. Красота родного языка, ощущение его духа согревают в самые трудные минуты жизни, дают для нации духовные крылья, согревают лучами солнца. Стихотворение «Туган тел» («Родной язык», 1910) обрело статус национального гимна.

Родной язык – святой язык,
отца и матери язык,
Как ты прекрасен!
Целый мир в твоем богатстве
я постиг!

(Перевод С. Липкина)

Обращение Габдуллы Тукая к фольклору и народным традициям помогло ему создать стихи и басни для детей на очень простом языке, не требующем особых пояснений. Среди многих идейно-творческих задач в творчестве Тукая выделяются две как главные: возвысить значение устного народного творчества и создать новую литературу для детей.

Такие его стихи, как «Кончил дело – гуляй смело», «Ребенок и бабочка», «Забавный ученик», «Гали и коза», «Ленивый пёс» и др., переведены на многие языки мира и способствуют формированию в детях трудолюбия, честности, смелости, скромности, чувства ответственности; прививают им интерес к чтению и знаниям о жизни.

Тукай активно обращался к образам мифологии и мифопоэтики, его интересовали приемы психологизма, способы передачи в поэзии внутренней, духовной жизни человека. В изображении картины мира он использует символические образы, архетипы, мифологемы, фантастические и условные способы воплощения действительности.

Поэт изучал фольклор разных народов, творчество русских и мировых классиков, учитывая их опыт. Так, крупные образцы фольклорных произведений на русском языке дали ему импульс для написания собственных произведений, в первую очередь – одной из самых известных его поэм – «Шурале» (1907). Это литературное переложение сказочной фабулы о лесном духе Шурале (Леший), своими корнями восходящей к одной из разновидностей мифологии народов Волго-Камья и Приуралья. Поэма Тукая, яркая страница его творческой биографии, раскрывает многие черты национального характера: смекалку, трудолюбие, любовь к природе, к своей малой родине и др. Связь ее с фольклором татарского народа изучена довольно обстоятельно. Поэма нашла путь и к зарубежным читателям, став достоянием многих народов. Не менее интересны и другие его сказки, связанные с мифическими существами (например, «Су анасы» [«Водяная»]).

Горечь мне жить суждено жизни печальной моей? [2, с. 233].
(«Трудная доля». Перевод С. Северцева)

Җиһаның эссесен, салкын, бозын күрдем, карын күрдем,
Ниләр күрсә бөтен үксез – барын күрдем, барын күрдем [1, II т., б. 247].

Буквальный перевод:

Жару, мороз, холод льда Вселенной видел я, снег видел,
Все, что могли видеть все сироты, – я все видел, я все видел.

Эти душераздирающие строки не только плод художественной фантазии, а, в первую очередь, отражение выстраданной судьбы автора.

Тукай в 1895–2007 гг. жил, учился и работал в Уральске (Яике), а оставшуюся жизнь провел в Казани. У поэта не было своего дома, семьи, постоянного жилья. Он скитался по частным квартирам, по дешевым номерам гостиниц. Трудная, сиротская жизнь рано подорвала здоровье Тукая. Болезнь легких изо дня в день прогрессирует.

... В прошлом – песня утешала, народясь в тишине,
Допою до середины – душит кашель неуемный [2, с. 289].

Как известно, по приглашению Мусы Бигиева и некоторых других наших соплеменников Тукай в апреле 1912 года побывал в Петербурге. Поэта показывают известному доктору университета Польне. После внимательного, тщательного осмотра больного, врач сказал сопровождающему Тукая Шакиру Мухаммедьярову (1883–1967) следующие слова: «Последняя стадия туберкулеза. Лишь четверть легких и дыхательных путей действует. А остальные части (т.е. три четверти) их поражены («череп беткән») [11; 7, с. 95]. Представить даже трудно: при таком состоянии здоровья Тукай еще жил около года, самостоятельно ходил, ездил даже в Уфу, Троицк..., работал. Поэт хорошо осознал, что дни его сочтены. В ожесточенной, изматывающей силы схватке с болезнью, в беспощадном, постоянном поединке с приближающейся смертью, даже в последние дни пребывания в больнице, Тукай, напрягая все оставшиеся силы, продолжает писать, творить.

Тукая родил апрель, и этот же месяц унес его, поэтому татары часто называют апрель тукаевским месяцем. По свидетельству очевидцев, на проводах поэта в последний путь принимало участие огромное, доселе невиданное в истории Казани количество людей. [Такое второй раз наблюдалось и при похоронах знаменитого композитора Салиха Сайдашева (1900–1954)]. Могила Тукая на кладбище Татарской слободы Казани и по сей день является как бы местом паломничества многочисленных посетителей.

Возникают естественные вопросы: «В чем же причина, что именно Тукай стал великим поэтом?» «Какие факторы способствовали формированию и становлению его творческой личности?...» Здесь, конечно, много причин, предпосылок. О них нам уже неоднократно приходилось писать и творить в своих статьях и выступлениях [«Гений татарской поэзии» (8, с. 212–219); «Шагыйрьлеккә тугры Тукай» (7, с. 89–94); «Абай

и Тукай: сравнительно-типологический анализ» (9, с. 15–22) и др.]. В данном докладе назовем лишь некоторые факторы, которые сыграли значительную роль в творческой биографии и судьбе поэта.

Прежде всего – это естественный талант Тукая. У него были впечатлительная натура, обостренная внимательность, отличная память, эмоциональное мироощущение и мировосприятие, нестандартная, оригинальная манера речи. Известно, что природа оказывает большое влияние на формирование творческой личности. Детство будущего поэта прошло, в основном, в сельской местности, на лоне естественного ландшафта. Тукай любил природу, ее леса, поля, речки, растения, птиц, животный мир, восхищался ими. Не зря в его произведениях нашло обильное отражение образы, картины и детали окружающего поэта естественного мира.

Хотя Тукай не родился в известных или дворянских семьях, его родители для своей местности, времени были относительно грамотными, воспитанными. Имеющиеся в их менталитете такие свойства как татарскость, почтение исламских ценностей, нравственность, порядочность..., видимо, передавались в генах, в молоках матери, в младенчестве. Любовь к родителям, особенно к матери поэт сохранял до конца своей жизни. Вспомним только эти строки:

> ...Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабрең ташы, –
> Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы [1, II т., б. 138].

В переводе А. Ахматовой:

> ... Всех сердец теплее и мягче надмогильный камень твой,
> Самой сладостной и горькой смочу его слезой [3, с. 218].

Заказанье (Казан арты) – нынешние Арский, Балтасинский и Атнинский районы Татарстана – это истинно национальный, исторический регион татар, один из важнейших очагов, источников нашего литературного языка, национальной культуры, образования и науки. Именно в этих краях родился и вырос Тукай, впитывал в себе тонкости и прелести языка, фольклора, накопленные веками духовное богатство. Говорят «Без худа нет добра». Скажу, мысль может быть она и спорна, что сиротство Тукая сыграло значительную роль в творческой судьбе поэта, так как оно часто заставляло его страдать, переживать, размышлять, с ранних лет его приучило к самостоятельности, ответственности за свои действия и поступки. Пребывание и контакты в различных семьях воспитывало у юного Тукая видение и восприятие жизни и людей в разных ракурсах.

Будущий поэт не учился в престижных Благородных пансионатах и лицеях, знаменитых столичных учебных заведениях. Но у него, наряду с «университететами сиротства», были обычные для татарской жизни очаги образования. Это, в первую очередь, медресе в Кырлае, где маленький Тукай начал осваивать азбуку грамотности и вскоре знакомиться с образцами словесности. В 1896–1906 гг. он – шакирд известной в тюрко-татарском мире медресе «Мутыгия» (г. Уральск), где основательно изучал, кроме своего родного языка, арабский, османско-турецкий, русский языки и фарси, а также восточные литературы. Среди его учителей были выпускники университета «Аль-Азгар» (г. Каир) Мутыги Тухфатуллин и его сын Камил Мутыги (1883–1941), которые «сыграли важную роль в формировании мировоззрения Г. Тукая, становления его как поэта» [12, с. 302]. Между прочим, К. Мутыги был основателем, издателем и редактором журналов «Аль-гасраль-джадид», «Уклар» (сатирическое издание) и газеты «Фикер», в которых работал и сотрудничал Тукай. Кроме того, он славился и как певец-баритон. Как известно, Тукай очень любил песни и сам пел. Таким образом, их сближало многое.

Тукай до 10 лет жил в сельской местности. Но последующие годы его жизни связаны с Яиком и Казанью, т. е. городским образом бытия, которые наложили своеобразный отпечаток на его творчество, способствовали созданию синтеза сельской и городской культур. Уральск (Яик), в период пребывания Тукая там, считался одним из важнейших торговых, административных, культурно-образовательных центров нынешнего Западного Казахстана. Основное население его составляли русские, татары, а также казахи. В городе функционировали различные учебные заведения, мечети, церкви. Городская публичная библиотека славилась богатой коллекцией книг, в том числе и на иностранных языках, разнообразной периодикой. Тукай часто посещал эту и другие библиотеки. Как известно, он, кроме родного языка, хорошо владел русским, арабским и персидским (фарси), турецким. Читал в оригинале книги на этих языках.

Тукай особенно предпочитал русскую классику и османскую словесность. Через них он ознакомился с образцами западноевропейской литературы.

В формировании и развитии Тукая как поэта и личности огромная роль Казани – восточной столицы России, важнейшего центра проведения колониальной и миссионерской политики царизма, крупного университетского города, одного из главных очагов татарской культуры, образования и науки. Несмотря на отдельное высказывание негативного характера, Тукай, в целом, высоко оценивает, даже в некоторой степени идеализирует Казань, её общественно-национальную значимость. По его словам, «здесь деянья дедов наших, здесь священные места... Здесь науки, здесь искусства, просвещения очаг» [2, с. 96]. Одно их стихотворений поэта начиняется со следующей строфой:

О Казань, ты как светильник на горе горишь в ночи,
Словно свеча – минареты, колокольни, каланчи [2, с. 282].

Конец XIX – начало XX вв., т. е. период жизни Тукая – это время значительных общественно-политических, национально-культурных событий и движений как и в российском масштабе, так и в татарском мире. Русско-японская война, первая русская революция 1905–1907 гг. буквально лихорадили, как землетрясение закачивали имперскую жизнь. Татары, как один из государствообразующих народов России, все настойчивее и настойчивее требовали свои национальные права, выражали свое недовольство колониальной политикой России, общественно-социальным неравенством. Процесс возрождения, начатый Г. Утыз-Имяни, Ш. Марджани, Х. Фаизхановым, К. Насыри и другими просветителями, в начале XX века еще более усилился, расширялся вширь и вглубь. Рост национального самосознания наблюдается во многих сферах духовной жизни. Огромное количество издаваемых в Казани, Оренбурге и в некоторых других городах татарских книг, распространялось не только в Идель-юрте, но и во всем тюрко-мусульманском мире. Периодика, театры, возникшее лишь, в основном, в начале XX века, буквально в течение двух-трех лет стали важнейшим, необходимым атрибутом татарского культурного пространства.

Тукай не только участник, очевидец бурных событий начала XX века, но и активный деятель этого возрожденческого процесса. Он и интуитивно, и осознанно чувствовал возникающие в жизни проблемы, стремился отвечать на них, удовлетворять потребности и спросы своего народа.

Таким образом, становление и развитие Тукая как поэта были обусловлены несколькими взаимосвязанными факторами, предпосылками и обстоятельствами как и личного, так и общественно-социального характера. Главные из них: естественный поэтический талант, сиротство, учебы в медресе, жажда к чтению, национальная жизнь, получение сельского и городского воспитания; бурный переходный период... Одним из основных факторов в творческом развитии поэта является то, что он уже рано осознал главную миссию литературы – служение народу, служение гуманистическим целям. Размышляя о счастье, о смысле жизни, в конце стихотворения «В чем сладость?» (1907) Тукай приходит к следующему выводу:

...Лишь служение народу признаю за счастье.
В этом лучшая отрада, сладость жизни для меня [2, с. 115].
(Перевод В. Тушновой)

Тукай всем своим естеством, всем телом и душой сросся с менталитетом своих соплеменников, связан со всеми капиллярами с организмом своей нации. Его судьба в определенной степени напоминает трагико-драматическую, бесправную, но ненадломленную судьбу татар. Наверное, поэтому сугубо личные мысли и переживания поэта получают общественно-национальное звучание.

Когда речь идет о взаимоотношениях народа и писателя, Тукай превыше всего ставит интересы, чаяния и потребности народа. В этом плане поучительно звучат строки из стихотворения «К народу».

Мысли все и днем и ночью о тебе, народ родной!
Я здоров, когда здоров ты, болен ты – и я больной.

Ты священен, уважаем, от тебя не откажусь,
Если даже все богатство мир положит предо мной.

...Как я горд, народ прекрасный, что тебе принадлежу!
Быть хочу твоим поэтом, за тебя стоять стеной.

Близок сердцу дух народный, я мечтаю, край родной,
Жить с тобой одной печалью или радостью одной [2, с. 63].
(Перевод С. Ботвинника)

Тукай благодарен своему народу за то, что он был поддержкой, опорой в его тяжелой, «сиротской» судьбе:

Иль в сиротской доле мало испытать пришлось невзгод?
Кто растил меня с любовью? Только ты, родной народ [2, с. 260].
(Перевод С. Ботвинника).

В оригинале:

...Азмы какканны вә сукканны күтәрдем мин ятим?
Азрак үстерде сыйпап тик маңлаемнан милләтем [1, 2 т., б. 229].

Тукай – истинно народный поэт, плод назревшийся на родной ему почве, на дереве нации. Он хорошо знал жизнь, историю, литературу, мифологию, фольклор, мироощущение и мировосприятие татар. Поэт особенно часто контактировался с устным народным творчеством, предшествующей письменной тюрко-татарской литературой, мусульманскими духовными ценностями. Он успешно и творчески продолжил, обогатил поэтические традиции татарской словесности Средневековья, XIX столетия [Об этом подробнее: 5], а также фольклора. Примечательно то, Тукай с детства любил песни, сказки, баиты, легенды народа, немного позднее собирал, комментировал и издавал их, даже читал публичную лекцию о фольклоре. Многие его сочинения, особенно адресованные детям, созданы с творческим использованием образов, мотивов, сюжетов народной словесности.

Кроме своего, национального духовного достояния, Тукай, как мы уже отметили, относительно хорошо разбирался как в восточных [Об этом подробнее: 6], так и в русской, западноевропейских литературах, обильно использовал их идейно-эстетический опыт, синтезировал многие духовные достижения других народов.

Творчество Тукая многогранна как сама жизнь, как человеческая природа, как бытие его соплеменников. Его перу подвластны любая тема, любой жанр, любой поэтический прием. Он пишет и о современности, и об истории, и об общественно-социальных и философских вопросах, о нравственности и любви..., сочиняет газели и рубаи, мадхии и марсии, поэмы и баллады, хикаяты и басни... Создает образцы юмора и сатиры, публицистики и критики, а также назиры и художественных переводов. Язык Тукая сочный, острый, гибкий, музыкальный... Он впитывает в себя все богатства и тонкости разговорной и письменной речи. Как стихотворения Аль-Мутаннабби (915–965) в арабской, Хафиза (XIV в.), в персидской, А. Пушкина в русской литературах, так и поэтические сочинения Тукая в татарской словесности считается эталоном, высшим критерием определения поэтичности словесного искусства.

Тукай хотел видеть свой народ цивилизованным, просвещенным, воспитанным, культурным, изо всех сил стремился, чтобы татары были в числе передовых наций человеческого сообщества, и с этой целью часто критиковал его недостатки, иногда даже бичевал пороки своих соплеменников. В стихотворении «Кручина» («Тәләһһеф», 1910) Тукай с горечью пишет:

Грязью, подлостью и ложью мы внутри начинены,
Месть, обман, подлог, коварство превратили в дело мы.

Отвести не можем взора от красивой кожуры
И продать готовы душу за сверканье мишуры.

Липнет к духу грязь, и совесть чахнет в омуте тенет,
Отчего для тела баня, а для духа бани нет?! [3, с. 140].
(Перевод В.С. Думаевой-Валиевой)

Последняя строфа в оригинале звучит так:

...Керләнә өст-өстенә рух, һич хозур вөҗданга юк,
Ни сәбәптән җир йөзендә тәнгә – мунча, җанга – юк?! [1, 2 т., б. 140].

Критику, как известно, никто не любит: ни шахи, ни рабы, ни дети, ни взрослые, ни народы. Поэтому и у Тукая были противники, злопыхатели. Об этой жизненной

истине и сам поэт хорошо знал. Даже написал стихотворение под названием «Враги» (1912), где есть такие строки:

Вокруг меня со злобой змеи извиваются, шипят,
Мне желают только горя, даже и ночью копят яд.

... Ниже слов они последних, низок ум их, низок взгляд.
О плохом во мне трезвонят, про хорошее – молчат.

...И болезни, и преграды с ясным встречу я лицом,
Ну, а то, что сердцу тяжко,– посчитаю пустяком... [2, с. 260].
(Перевод С. Ботвинника)

Подавляющее большинство соплеменников хорошо поняло и знало, что критика Тукая – это одно из проявлений чрезмерной любви поэта к своей нации. В целом, народ на любовь Тукая к нему отвечал любовью, взаимностью. Уже при жизни поэт стал действительно народным, выпускал более 30 книг, на страницах газет и журналов, учебников его произведения занимали доминирующее место.

Уже прошло более ста лет после смерти Тукая. За это время значимость и ценность его произведений из года в год возрастают. Пламенные стихи поэта, ставшие по-настоящему атрибутом нашей духовной жизни, воспитывали уже несколько поколений. Сочинения Тукая многократно издавались на различных языках мира. О поэте создано множество произведений литературы и искусства. В этом направлении наиболее плодотворно работали А. Файзи, С. Хаким, Т. Миннуллин и др. Тукаеведение, специальная отрасль литературоведения, изучающая великого поэта, представлено, в первую очередь, такими именами как Дж. Валиди, Г. Халит, И. Нуруллин, Р. Гайнанов, Р. Ганиева, Р. Нафигов, З. Рамиев... Примечательно то, что к 130-летию со дня рождения Тукая подготовлено и выпущено академическое издание сочинений поэта в шести томах. Наконец-то завершена долгожданная «Энциклопедия Тукая». Одобрительно будет встречено новое дополненное издание библиографии поэта и воспоминаний о нем.

По словам классика узбекской поэзии Гафура Гуляма (1903–1966), Тукай «гордость не только татарского, но и у других тюркских народов» [10, с. 18]. Аналогичную мысль высказывают и Чингиз Айтматов [«Тукай принадлежит не только татарскому народу, география принадлежности его гораздо шире...» (10, с. 32)], Сабит Муханов (1900–1973), Берды Кербабаев (1894–1974) и многие другие классики XX столетия. Произведения татарского поэта особенно широко распространялись в тюркском мире, читались на языке оригинала, а также в переводах. Тукай сыграл большую роль в судьбе многих мастеров пера. Известный казахский литературовед, критик, профессор, директор Института тюркологических исследований Международного казахско-турецкого университета имени Х.А. Ясави (г. Туркестан) Кульбек Ергобек в своем выступлении на Международной научной конференции (Казань, 25.04.2011 г.), посвященной 125-летию со дня рождения Тукая, сказал: «Тукай – «великий тюркский поэт», «личность мирового масштаба»; «что без него даже невозможно представить казахскую литературу XX века» [4, с. 22–27]. По утверждению выдающегося русского поэта советской эпохи Михаила Луконина, «Тукай – это наше представление о поэзии и о поэте. На небосклон мировой поэзии он взошел крупной и яркой звездой, и, запрокинув голову, сразу увидишь эту звезду в созвездии Пушкина» [10, с. 39].

В одном из стихотворений молодой Тукай в 1906 году писал:

...Пусть умру – народ запомнит имя скромное мое,
В этом цель моя, такою буду счастлив я судьбой [2, с. 63].
(Перевод С. Ботвинника)

Пророческие слова великого Тукая сбылись: имя и проникновенные стихи его навсегда вошли в память народной: это – большое счастье для Поэта.

ЛИТЕРАТУРА

1. Тукай Габдулла. Әсәрләр. Дүрт томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. I т. 432 б.; 1976. II т. 400 б.; 1976. III т. 447 б.; 1977. IV т. 431 б.
2. Тукай Г. Избранное. Казань: Таткнигоиздат, 1969. 420 с.
3. Тукай Габдулла. Избранное / перевод с татарского В.С. Думаевой-Валиевой. Казань: Магариф, 2006.239 с.
4. Күлбек Ергобек. Түрікстан жинагы (Алтынчы китап). Түрікстан: Туран, 2015. 400 б.

5. Миңнегулов Х. Тукай һәм Урта Гасыр әдәбияты // Тукай һәм XX гасыр мәдәнияте: Шагыйрьнең 110 еллыгына багышланган халыкара конференция (Казан, 1996) материаллары. Казан, 1997. Б. 54–63.
6. Миңнегулов Х. Тукай һәм Шәрык әдәбиятлары // Творчество Тукая в контексте евразийской культуры: Материалы международной конференции (Академия наук Татарстана, ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова. Казань: Фикер, 2002. С. 95–107.
7. Миңнегулов Х. Гасырлар арасында уйланулар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. 319 б. («Тукайны Питер да онытмый мәкаләсе». Б. 94–98)
8. Миннегулов Х. Этапы развития тюрко-татарской, античной и русской литератур. Казань: Ихлас, 2014. 288 с.
9. Миннегулов Х. Абай и Тукай /Абай – әлемдік феномен: Халыкаралык гылыми-практикалык конференция (30. 10. 2015, Астана) материалдары. Астана: Назарбаев университеті, 2015. С. 15–22.
10. Слово о Тукае. Писатели и ученые о татарском народном поэте / сост. Ф. Зулькарнаев. Казань: Таткнигоиздат, 1986. 431 с.

## Г. ТУКАЙ ТУРЫНДАГЫ ИСТӘЛЕКЛӘРДӘ «БАЛАЧАК ХӘТЕРЕ»НЕҢ ТАСВИРЫ

***Минһаҗева Л.И.***

В статье рассматриваются воспоминания о Тукае. Эти воспоминания доказывают, что Г. Тукай смог сохранить «память детства», что способствовала большому интересу к его произведениям, которые актуальны и сегодня.

The article deals with the memories of Tukay. These memories show that G. Tukay could save "childhood memory", which contributed to a great interest in his works, which are still relevant today.

XX гасыр башында татар балалар әдәбияты өлкәсендә иң бай мирас калдырган шәхес – Г. Тукай (1886–1913). Татар балалар поэзиясенең бу чорда ныклы, профессиональ үсеш алуы да аның исеме белән бәйләнә. Мәгълүм, ул татар балалар әдәбиятының гаять дәрәҗәдә ярлы булуын күреп, аңа ярдәм итү, баету, белем һәм дөрес тәрбия бирү омтылышы белән әлеге өлкәгә килгән шәхес [4, б. 5].

Г. Тукай шигырьләре фикергә, образ һәм хисләргә бай, кичерешләре тирән. Шуның белән бергә, лирик әсәрләрендә шагыйрь бала психологиясен тирәнрәк итеп ачуга, аны тормышчан итеп яктыртуга да зур игътибар бирә. Нәкъ менә шуңа күрә лирик геройларның логикасы, фикер үсеше – балаларча. Бер яктан, фикерләрнең төплелеге авторның – олы кешенең караш-фикеренә ишарә итә. Икенче яктан, бала кичереше садәлек, гаҗәпләнү, моңсулык һәм шатлык интонациясе аша бирелә. Мисал итеп, «Таз», «Эш беткәч, уйнарга ярый», «Безнең гаилә», «Ата илә бала» «Сабыйга», «Карлыгач», «Шаян песи», «Фатыйма белән Сандугач», «Кызыклы Шәкерт», «Шүрәле», «Су анасы» кебек лирик әсәрләрен китерергә мөмкин. Мондый уңышка, әлбәттә, «балалык хәтерен» саклап калган очракта гына ирешергә мөмкин. Г. Тукайда бу хәтернең дәрәҗәсен ачыклау өчен истәлекләргә мөрәҗәгать итик.

Беренчедән, Г. Тукайның тышкы кыяфәте, нигездә, түбәндәгечә бирелә: «...ялан-баш, кара күзлектән, өстенә казакимы, җөббәме, иске генә бер нәрсә кигән, аягында тузган кара буркалы шыксыз гына бер малай, минем «ие» дигән сүземне дә көтмичә, каршымда, өстәл кырыенда, буш торган урындыкка килеп тә утырды» [5, б. 115]. Яки, икенче бер истәлектән өзек: «...Аңа җентекләп карадым: башына иске картуз, естенә озын жеббә сыман пальто, аяк асты коры булса да, ботинка белән галош кигән, ябык һәм сары йөзле...

– Сәгыйть эфәнде, безгә бер авыру рус малае килә, – дидем» [5, б. 149]; «Көннәрнең берендә кечкенә генә гәүдәле, өстенә, «абыйсының бишмәтен кигән» дигән шикелле, иңбашлары төшеп торган кием кигән, бер күзенә бераз акта төшкән, йонсыз-төксез, өтек кенә бер малай редакциягә керде дә, тәкәллефсез-нисез генә редактор өстәле янындагы урындыкка утырып, өстәл өстендәге гәзитләрне дә актара башлады» [5, б. 71].

Г. Тукайны беренче тапкыр очраткан кешеләр тәэсиреннән күренгәнчә, нигездә ул бала кебегрәк кабул ителгән. Дөрес, бер яктан, тышкы кыяфәтнең шигъриятькә катнашы юк кебек. Әмма, татарның иң мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» дастанына тукталыйк. Кол Гали төп герое Йосыфны тасвирлаганда, иң беренче итеп, аның тышкы кыяфәтенә ихтибар итә:

Беренчедән – буе зифа, сылу үзе,
Икенчедән – күрекле һәм якты йөзе [3, б. 84].

Шуннан соң гына аның эчке гүзәллеген тасвирлый. Чөнки нәкъ менә эчке кичерешләр, эчке чисталык һәм пакълык тышкы якны матур итә. Димәк, бу очракта Г. Тукайның да эчке халәте беркадәр кыяфәттә чагылган дияргә мөмкин.

Икенчедән, истәлекләрдә Г. Тукай балаларга хас характер сыйфатлары, балаларга хас эчке дөньясы белән ачыла: «Ташаякка барып кергәч, аның теләве буенча, иң әүвәл туп-туры карусельгә таба юнәлдек. ... Икемезгә бер рәттән ике агач аргамак табып алдык. Икемезгә дә атларның матур, яхшы, шәп төслесе тугры килде. Атландык.

...Ул миннән соң, тагы ике тиенлек әйләнде» [5, б. 144]; «Ул ... балалар шикелле, карусель атларына атланып әйләнә торган иде. Тукайның карусель атларына атланып әйләнүе Уральскида еш-еш кына була иде»; «Шагыйрьнең аргамакка атлангач, егыла курмим дигән бала шикелле, куллары белән бик каты кысып, аргамакны тушәмгә беркеткән нечкә тимер баганага бик нык тотынганы әле хәзер дә күз алдымда. Әгәр ул тотыну гади бер тотыну гына булса, мин аны язмас та идем, ләкин ул – чын күнелдән саклану иде» [5, б. 143].

Мондый истәлекләрне, мисал итеп, күпләп китерергә мөмкин. Г. Тукайның карусель атларында яратып әйләнүен дә төрлечә аңлатырга була. «Исемдә калганнар» автобиографик повестендә ул үзе: «Кайчакта әни белән Ташаяк базарына барып, андагы уенчык базарларына кызыгып вә самокатларда шатланып-шатланып агач атларга атланган малайларны карап, көнләшеп тора идем», дип язган иде. Зур үскәч, кабат-кабат карусельгә утыруы һәм «үч кайтты», «үч алдым» [5, б. 144] кебек фикерләренә дә таянып, бу гамәлне балачак хыялларын тормышка ашыру, шуннан канәгатьлек хисе алу дип тә билгеләп булыр иде. Әмма, болай аңлату берьяклы гына булыр кебек. Чөнки, «балачак хыяллары» гына булса, мөмкинлеге чыкса, чыкмаса сәбәп итеп, ул һәрдаим карусельгә бармас иде: «Тукай тагын бер исне китерде. ... Сәгыйть белән мине карусель янына тартып алып китте. ... Ул шулкадәр хозурланып балаларча әйләнде ки, аңа минем генә түгел, кәмит караучы башка кешеләрнең дә исе китте. Ул бер генә әйләнеп канәгатьләнмәде, тагын һәм тагын әйләнде» [5, б. 150]. Димәк, киңрәк яссылыктан чыгып бәяләгәндә, балалар белән карусельдә кабат-кабат әйләнүе ул – аның күңел халәте, ихтыяҗы да булган.

Өченчедән, истәлекләрдә Г. Тукайның балалар кебек уен уйнарга яратуы да кабат-кабат күрсәтелә. Мәгълүм, уен балалар тормышының аерылгысыз бер өлеше. Уен акыл үсешенә дә тәэсир итә, уеннар вакытында бала шәхес буларак формалаша һәм ул кичерешләрен, эмоцияләрен дә уенга күчерә.

«Шагыйрь кайсы вакытта идарәханәгә кесәсенә кузна тутырыл килә дә, йорт хуҗаларының балаларын алып чыгып, ишегалдында бик кәефләнеп кузна уйный иде. Гәүдәсе белән үсмеррәк балалардан күп аерылмый торган Габдулла бу вакытта бөтенләй бер балага әверелә иде» [5, б. 122]; «...Алардан берәр тиенгә ун кузна сатып алып, без дә уенга катнаштык. Габдулла, чын бала сурәтенә кереп өстенлекне бирмәс өчен бар көчен куен уйнады. Кузналарны бәреп екса, аларны йөгереп барып җыя, тидерә алмаса, күңеле төшә, маңгаеннан тирләр бәреп чыга иде» [5, б. 97].

«Шул арада Тукай абый белән әннәм, бер читкәрәк китеп, тагын ашык уйный башладылар» һ.б. [5, б. 159].

Бу очракта истәлекләргә бәйләп, инде шәхес, «бөек шагыйрь» булып формалашкан Г. Тукайның кичерешләрен, эмоцияләрен уенга күчерүе һәм күңелендә балалык хисләренең, балалык сыйфатларының, һәм, ниһаять, балалык «хәтеренең» нык сакланып калуын ассызыклау дөрес булыр кебек.

«Свет» кунакханәсенең номерында торган вакытта, төне буе үзен борчып чыккан күселәрдән котылу өчен, шагыйрьнең «үзенчәлекле» чара табуы да моңа мисал: «... Мин үзем мәче булырга уйладым. Беркөн кич аякка киез итек һәм өсткә, эчен тышка әйләндереп, тун кидем. Башта да эче тышка чыгарылган бүрек иде. Тунның арт итәгенә мунчаладан койрык төсле бер нәрсә тактым…

Үземә бик яхшы, бөтенләй мәчечә тоелганга, мин төн уртасында, һәйбәтләп аяк бөкләп, күсе чыга торган тишек янында утырам. Менә мияулыйм, менә мораулыйм!» [2, б. 211].

Истәлекләрдә Г. Тукайның ач, хуҗасыз мәче яки этләр янында туктап: «Нихәл, кәкре койрык, тунгансың, тамагың ач булырга кирәк, хуҗан юктыр...» – дип, алар белән

сөйләшүе. Урам мәчеләрен үзе торган номерга алып кайтып, буфеттан калдык-постык ашларны биреп яки сөт алдырып, ашатып җибәрүләре турында да сөйләнелә. Болар да шагыйрьнең саф булып калган җанына мисал була ала.

Мәгълүм, балаларда кызыксыну уятырлык итеп язу, тәрбия юнәлешендә дә төпле фикер җиткерү язучыдан зур осталык таләп итә. Чөнки автор акылы, тирә-якны танып белүе бала аңларлык рәвештә сурәтләнергә тиеш. Бу хакта фикер йөртеп, үзенең бер мәкаләсендә В.Г. Белинский да түбәндәгечә яза: «Дөньяны балаларча образлы кабул итүгә яраклашу мөмкин түгел. Зур бала булу кирәк, әлбәттә, туры мәгънәсендә түгел, бәлки балаларча эчкерсез характер белән дөньяга туарга кирәк». Автор андый шагыйрьләрне «балаларның куанычы» дип атый, чөнки нәкъ менә шундый язучылар гына бала күңеленә үтеп керә ала [1, б. 79].

Истәлекләрдән күренгәнчә, Г. Тукай – абыйларга җиткерер сүзләре булган, әмма сабыйлык кичерешләрен, балалык «хәтерен» үзендә тирән саклап кала алган, балаларча саф «зур сабый» булган. Чөнки ул балалар күзе белән яшәешне күреп, алар шикелле үк бәяли алган. Һәм ул, чыннан да, «балаларның куанычы» булып, татар балалар әдәбиятында онытылмаслык мирас калдырган бөек шагыйрь.

ӘДӘБИЯТ


1. Белинский В.Г. О детской литературе. Второе изд. М.: Дет. лит., 1983. 430 с.
2. Габдулла Тукай: Тормыш һәм иҗат елъязмасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 20003. 268 б.
3. Тукаев Г. Мөкаддимә / Тукаев Г. Мәктәптә милли әдәбият дәресләре. Казан: Татар.кит.нәшр., 2000. 160 б.
4. Тукай трында истәлекләр / төз. И. Нуруллин, Р. Якупов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 256 б.


## РАБИТ БАТУЛЛА ИҖАТЫНДА ТУКАЙ ОБРАЗЫНЫҢ ЧАГЫЛЫШЫ


***Минһаҗева Р.Ә., Габидуллина Ф.И.***



В статье исследуется образ великого татарского поэта Габдуллы Тукая в творчестве писателя-прозаика, драматурга Рабита Батуллы. В своих первых произведениях, посвященных Тукаю (повести «Острее меча, тоньше струны», драме «Мост над адом») он обращается к последним дням жизни Г. Тукая. Образ Тукая раскрывается многогранно: в связи с историческими событиями начала XX века; в окружении верных ему друзей (Х. Ямашев, С. Рамиев, Ф. Амирхан, И. Бикчурина) и недругов (Шәүлә (Тени)); в отношении поэта к Зайтуне туташ и замужней женщине, благотворительнице Гаухаршат ханум.

Article is examining the image of great Tatar poet Gabdulla Tukay in compositions of Rabit Batulla. The author describes last days of the poet's life in his story and drama. The poet`s image opens up in connection with historical events beginning XX th century, surrounded by his loyal friends and enemies, in relation to the poet to Miss Zaytuna (tutash) and Mrs. Gauharshat (hanum).


Еллар узган саен Г. Тукай шәхесе безгә якынрак, кадерлерәк була бара. Даими туып торган әдәби һәм фәнни мәкаләләр, әдәби әсәрләр һәрвакытта да Тукай (1986–1913) шәхесенә, аның гаять бай әдәби мирасына тиешле кызыксыну уята. Шагыйрь иҗаты, шәхесе үзе яңадан-яңа әдәбият һәм сәнгать әсәрләренең нигезенә алына.

Хәзерге татар әдәбиятында Тукай образына багышланган күләмле әсәрләр күп түгел. Шулар арасында Г. Тукай премиясе лауреаты Рабит Батулланың Тукай шәхесенә багышланган әсәрләре аерым игътибарга лаек. Аның «Кылдан нечкә, кылычтан үткен», «Сират күпере», «Күк капусы ачылганда», «Апуш –Тукай», «Зәйтүнәкәй» әсәрләре шагыйрь образын төрле юнәлештә яктырту, хәзерге иҗтимагый-сәяси барыштагы инсан күзлегеннән күзәтү, җанлы итеп сурәтләү белән аерылып торалар.

«Сират күпере» һәм «Күк капусы ачылгандагы могҗиза» әсәрләрендә автор героен халык кайгысын кайгыртучы шагыйрь, милләт хадиме итеп сурәтли.

«Күк капусы ачылгандагы могҗиза» әсәрен Р.Батулла фантастик жанрда иҗат итә: анда Тукай безнең реальлеккә куелып, һаман исән, эшли һәм иҗат итүче итеп бирелә.

Р. Батулла «Сират күпере» драмасында, «Зәйтүнәкәй» пьесасында Туташ һәм Ханым образлары ярдәмендә Тукай дөньяга үз карашы белән ачыла. Габдулла да сөюгыйшкы утында янучы, сөю хисенә ия булган олы җанлы кеше итеп ачыла төшә.

«Кылдан нечкә, кылычтан үткен» (1995) исемле кыйссасында Р. Батулла үлем алдындагы шагыйрьгә бәйле һәм чынлыкта да булырга мөмкин фаразларын күз алдына

бастыра. Повестьның беренче битләреннән үк без Тукайның тугры сүзле, намуслы, фәкыйрь-мохтаҗларга ярдәм итүче итеп күрәбез.

Шагыйрьнең соңгы көннәрен калку яктырткан бу кыйссадагы вакыйгалар автор фантазиясе белән үрелеп бирелсә дә, әсәр тарихи кыйммәтен югалтмый, шагыйрь образы тарихи фонда ачыла. Әсәрдә тарихилыкны тәшкил иткән ике шартка: тарихи геройлар һәм тарихи вакыйгаларга шактый тулы дикъкать ителә.

Автор Тукай белән бәйле тарихи чор, биографик фактлар, вакыйгалардан тыш, үзенчәлекле шартлы образ − Шәүлә образын җанландыра. Әсәрдә Тукай белән Шәүлә арасындагы конфликт калку күрсәтелгән.

Тукайның барыр юлына шом салучы, бәхетен җуючы икенче бер образ – «ике башлы зур Каракош» образы. Каракош, нигездә, Тукайның төшендә пәйда була. «Төш күрдем бугай мин... Имеш, урамда мин, нәмаешта. Халык белән бергә каядыр барабыз. Шатланабыз, кычкырабыз. Кинәт күктән зур каракош атылды. Ике башлы зур каракош кешеләрнең башларын, күзләрен чукырга тотынды. Мин кычкырам, каракошка ташлар атам. Аннан кинәт кенә үземне читлектә итеп күрдем... Читлектә, төрмәдә...» [2, б. 19], – дип уртаклаша Тукай дусты Хөсәен Ямашевка күргән төше белән.

Кешеләргә һөҗүм итүче ике башлы зур Каракош − турыдан-туры Рәсәй хөкүмәте символы. Каракош кешеләрнең иреген тыючы читлек, халыклар төрмәсе, үлем белән янәшә куелган. Ул әсәрдә үзенең һөҗүме белән тагы берничә тапкыр очрый.

Тукай – милләтпәрвәр, үз халкының бәхете өчен көрәшүче каһарман. Ул бу юлда хәтта үзенең шәхси бәхетеннән дә ваз кичә. «Мин тулаем халыкныкы, Фатих! Башым, иҗатым, авыруым белән мин халыкка кире кайтарып алмаслык итеп тапшырылган зат. Мин гаиләдә вакланып бетсәм, халыкка ни калыр? Шуңа күрә, мин беркайчан да өйләнмәскә уйладым» [2, б. 127]. Ул үзенең өметсез авыру икәнен белеп, сөйгәне Зәйтүнә туташ алдында изге ялганга барырга мәҗбүр була. Бөек шагыйрь үзенең максатын нәрсәдә күрә соң? «Әгәр милләт мине, илтифат итеп, искә алса, шул минем максатым, теләгем һәм бәхетем...» – дип җавап кайтара Тукай бу сорауга. Аның иң соңгы сүзләре дә шул рухта яңгырый: «Кыйналып-суелып бетмәгән, Шигъри динем, исән бул! Изелеп-кырылып үлмәгән, Татар халкым, исән бул!» [2, б. 137–138].

Тукайны әдип горур, туры сүзле, үзенең җирдәге урынын яхшы аңлаган, дусларын яраткан, хатын-кызга кырысрак һәм беркадәр кыюсыз мөнәсәбәтле, хокуксыз милләтнең вөжданы, таянычы, ышанычы итеп тасвирлый.

Язучы Р. Батулла Зәйтүнә туташ белән химаяче Гәүһәршад ханым образлары ярдәмендә Тукайны үз иҗаты белән күп хатын-кызларның рухи дөньясын яулап алган, аларның идеалына әверелгән каһарман итеп күрсәтә. Ханымның: «Мин бит сезнең дәвамыгыз, Тукай. Сезнең шигырьләр миндә милли горурлык уятты. <...> Аңсыз бер кыздан фида булган мөрәүвәтле бер җан ясаучы ул сез! <...> Бүгенге көндә мин татар халкының бүгенгесе, киләчәге турында уйланыр дәрәҗәдә сездән тәрбия алган хатын» [2, б. 75], сүзләре моңа дәлил булып тора.

Шулай итеп, бу әсәрдә Тукайны хәерчеләргә карата юмарт, олы җанлы, нечкә хисле, көчле тойгыларына баш була белгән, аларны шагыйрьләрчә матур итеп сүзләргә төрә алган, тыйнак та, беркадәр хыялый да мәҗнүн итеп күрәбез [1, б. 146].

Р. Батулланың «Сират күпере» драмасы авторның алда иҗат ителгән «Кылдан нечкә, кылычтан үткен» повестеның пьесасы, сәхнә варианты. Катнашучылар да нигездә шулар ук, әмма Тукайның дуслары булган тарихи шәхесләр үзләренең кушамат-тәхәллүсләре белән бирелә: Ядкәр − Хөсәен Ямашев, Агабәк − Фатих Әмирхан, Сагышлы егет − Сәгыйть Рәмиев, Бикчура – Исхак Бикчура, Туташ− Зәйтүнә Мәүледова, Ханым – Гәүһәршат ханым, Бай − Хисаметдин Сираев.

Драмада Тукай үз чордашлары әйләнәсендә, үзенең соңгы айлары һәм көннәрендә сурәтләнгән. Вакыйгалар аның «Болгар» кунакханәсенең уңайлыклары булмаган, салкын бүлмәсендә бара. Үзенең бөек иҗатыңа тәңгәл номерда яшәмәвен Бай да, Шәүлә дә, искәртә. «*Бай.* Шушы, сезмени инде ул Туры Тукай? (бүлмәгә карап). ... Номер не высший сорт. [3, б. 397].

*Шәүлә.* Да, кстати, ә менә син нигә бу бүлмәдә яшисең, ә? Күселәр, тычканнар... Суык, бәдрәфе дә урамда, Яшә модерный номерларда» [3, б. 402].

Әмма Тукай халык белән янәшә торуны хуп күрә, аның номер ишеге Казанның һәр фәкыйре өчен ачык. Ул аларга хәереннән дә, сыеннан да җитәрлек өлеш чыгаручы, юмарт күңелле кеше итеп сурәтләнә.

Драманың төенләнеше дип, редакцияләргә «Тукай каты авырый, Тукайны хастаханәгә салырга җыеналар» дигән ялган телеграмма барып ирешүен әйтеп була. Вакыйгалар үстерелешендә каршылык хәрәкәт итә башлый, катнашучы яклар турында мәгълүматлар арта, тирәнәя. Телеграммадан соң Тукайның охранкадан яшеренеп йөргән дуслары берәм-берәм аның янына хәл белергә киләләр. Бу – жандармерия шымчылары өчен менә дигән җим, тозак.

Мәсәлән, күпме эзәрлекләп тә, эзләп тә таба алмаган Ядкәр Хөрмәтовны (революционер Хөсәен Ямашев) Тукай янында булганнан соң, тиз генә эләктереп алалар. Монда шартлы Каракош образының явызлыгы, рәхимсезле хакында төштә түгел, ә өндә, Тукай авызыннан ишетәбез: «Канатларын җәя каракош. Каплый дөньяны каракош. Сәер үлемнәр, серле җинаятьләр берлә тулды Казан» [3, б. 409]. Алга таба Каракошның үлем томшыгы бер-бер артлы күпме дусларын эләктерәчәк...

Әйе, Тукай хәзергә әле ялгыз түгел, аның җан дуслары бар. Күршесендәге Агабәк (прототибы Фатих Әмирхан) кенә ни тора. Шагыйрьнең кайгысын да, шатлыгын да уртаклаша, киләсе көнгә көч бирә. Сагышлы, Бикчура исемле дуслары да Тукайның хәлен белеп торалар.

Алар һәммәсе шагыйрьнең иҗтимагый тормышындагы, милләт язмышындагы урынын ачыкларга, аның әдәбиятка карашын, иҗат кешесенең җәмгыять тормышында биләгән урынын күзаллавына төшенергә, шагыйрьнең нинди граждан һәм патриот икәнлеген гәүдәләндерергә булышалар [1, б. 147].

Повесть вариантында халыкның Тукайга мәхәббәте Казан мәчете, чиркәве тирәләрендәге гавамның «Тукай үлем хәлендә икән» хәбәргә мөнәсәбәттә, шагыйрьне һәр татар һәм рус өчен яхшы таныш булган, дәрәҗәле шәхес икәне күрсәтелсә, җыйнаграк формада язылган драма вариантында халыкның шагыйрьгә мөнәсәбәте нигездә аның әйләнәсендә, бүлмәсендә еш булган персонажлар аша күрсәтелә.

Драмада Тукай язмышы халык язмышы белән тиңләштерелә. Мәсәлән, Ядкәрнең «Татарның ютәленә дәва юк, Тукай», дип әйтүе генә дә милләтебезне ютәлләп ятучы Тукайга тиң итә.

Әсәрдәге Тукайның тагын бер сыйфатына тукталып китми булмый. Ул аның шәхси тормышына, мәхәббәтенә кагыла.

Алдарак язылган әсәрләрдә Тукай берьяклырак, күбесенчә көрәшче-революционер, үз милләте өчен җан атучы гына итеп сурәтләнгән булса, Р. Батулла Туташ һәм Ханым образлары ярдәмендә Тукайны үз рухи дөньясы булган шәхес итеп тә тасвирлый. Тукай – җир шарындагы һәрбер кешегә хас сөю хисенә ия булган олы җанлы кеше. Ул мәхәббәт шигырьләре язарга илһамландыручы Туташны чын күңеле белән ярата. Аның белән аралашкан күренешләр тирән лиризм белән сугарылган, тамашачыны да, укучыны да тетрәндерергә мәҗбүр итә. Бу да авторның зур уңышы дип әйтергә була. Үзенең терелә алмаслык авыру икәнен белгәнгә күрә, шагыйрь Туташның мәхәббәтен кире кага. Хәер, гашыйкларның мөнәсәбәте кавышу белән очланмавын Тукайның төше дә күрәзәлек итә. Анда шагыйрь аландагы чәчәкләрне Туташка җыеп, бүләк итәргә генә үрелә, күктән тагы шул ике башлы каракош килеп чыгып, канатлары белән давыл чыгарып, сәйләннәрне коеп төшерә [3, б. 411]. Һәр бөек шагыйрьгә хас пәйгамбәрлек, алдан күрә белүчәнлек, Тукайга сөйгәненең хисләрен кире кактыра, «мин сезне сөймим» дип, ялганларга мәҗбүр итә. *Тукай (үзалдына).* «Хуш, бәгырем, мәңгегә бәхиллә бу ялганымны! Мәхәббәт шигырьләремнең илһамчысы, хуш, бәхил бул! Әльаман, туташ, әльаман. Әлвидаг, туташ, әлвидаг!» [3, б. 412].

Химаяче Ханым белән сөйләшкән өлештә Тукайның тагын берничә сыйфаты ачыла. Ул – горур, хатын-кызга хөрмәт белән карауучы инсан. Ул кеше акчасын, бигрәк тә хатын-кыздан матди ярдәмне беркайчан да кабул итмәячәк. Аны халык өчен саклап калу өчен ярдәм кулы сузган, ихлас хөрмәт иткән Ханымның ярдәм-химаясен Тукай, үпкәләтмичә, кире кага.

Әсәрдә Тукай дошманы – Шәүлә. Ул – драматургның зур табышы [1, б. 149]. Вакыйгалар барышында Шәүлә образы − теләнче, базар хәерчесе, күрәзәче, күзәтүче, фәйләсүф, пәйгамбәр, сәхнәдә әверелеш даһие − актер булып та төрләнә. Кульминацион ноктада Шәүлә үзенең бөтен серен, пычрак эшләрен Тукайга сөйләп бирә. Ахыр чиктә, ул сатлыкҗан, жандармерия шымчысы, Тукайның дусларына ялган телеграмма сугып, аларны бер-бер артлы юк итүче, Тукай әймешли, «революцияне буучы палач» булып чыга. Ул патша жандармериясенең астыртынлыгын, мәрхәмәтсезлеген,

икейөзлелеген һәм акыл көчен гәүдәләндерә. Күрәбез: Шәүлә көчле, мәкерле һәм шул ук вакытта акыллы да. Шунысы игътибарга лаек, Рабит Батулла Шәүлә образын берьяклы гына сурәтләми. Дөрес, ул – мәкерле, астан гына эш йөртүче. Әмма, Шәүлә сүзләрендә хаклык та бар.

«*Шәүлә.* <...>…Революция ясаучыларның туксан проценты надан була. Биш-ун хыялыйның идеясенә котырып, наданнар баш күтәрә. Баш күтәрү вакытында акыллылары үлеп бетә. Революция юлы уртасында шыр наданнар гына торып кала. Баралар наданнар, кая барганнарын белмиләр. Кая барабыз соң без, барабыз да барабыз, дип сораганнарны әлеге наданнар революция исеме белән кырып ташлыйлар. Интеллигенция бетә, аек фикерлеләр атыла, шиклеләрне аталар. Алай-болай булмагае дип, һич гаепсезләрне дә төрмәләргә тыгып бетерәчәкләр. Илне шом, деспотизм шаукымы басачак... <...> Мин менә шуннан куркам, Тукай. Әнә шундыйлар Россия халыкларын ялгыш юлдан алып китмәгәе дип, бөтен көчемне, талантымны биреп көрәшәм» [3, б. 416].

Чыннан да, 1917 елдагы инкыйлабтан соң көткән хыяллар тормышка ашмый. Киресенчә, рус булмаган милләтләрне юкка чыгару сәясәте тагын да көчәя, шәхес культы һәм башка репрессияләр башлана.

Пьеса ахырында Шәүләнең үзенең күзәтү объекты булган Тукайга хәтта хөрмәт белән карый башлавының шаһиты да булабыз. *Шәүлә.* «Син бик тә сихерле кеше бит, Тукай. Синең арттан шымчылык итәргә куелган агент үзеңне ярата башлый. Синең өстән язарга теләми, сине яклый башлый» [3, б. 415].

Күрәбез, Тукай белән тартышында Шәүлә рухи яктан җиңелә төшә. Тукайның соңгы сулышында ул үзенең җиңелүен тәмам таный. *Шәүлә.* «Синең һәр бәйрәмеңне олылап бөтен Европа күләмендә узгарачаклар... Синнән кала Әмирханнар, Рәмиевләр, Кариевлар, Сәхипҗамаллар, Камаллар даһи саналачак [3, б.419].

*Тукай.* «Соң шулай булгач, мине үлем куркыта аламы? Их, син, <…> шуннан башка миңа ни кирәк? Әгәр милләт мине илтифат итеп искә алса, шул минем максатым, теләгем һәм бәхетем...» [3, б. 420].

Драманың финалында Тукайның физик үлеме рухи үлемсезлек, халык күңеллендә мәңгелелеге белән алышына. Аның башлаган эшләрен, күрәбез, башкалар дәвам итәчәк.

Шулай итеп, язучы-прозаик, драматург Р. Батулла иҗатының Тукайга багышланган бу ике тәүге әсәрендә шагыйрьнең тормыш көзендәге яшәеш сәхифәләренә, иҗат тарихына мөрәҗәгать итеп, алдына күп төрле сораулар куйганнан соң, Тукайның соңгы көннәрен үзенчә күзаллап, шул ук вакытта тарихи фактларга, әдип биографиясенә нигезләнеп, сәнгати итеп, укучыга һәм тамашачыга кызыклы итеп тасвирлап та бирә алган.

Р. Батулла иҗат дәверендә Тукай темасына тугрылыклы булып калды. Беркадәр соңрак язылган «Апуш – Тукай» повестенда, «Күк капусы ачылгандагы могҗиза», «Зәйтүнәкәй» пьесаларында Тукай образы тагы да тирәнрәк ктыртыла төшә.

ӘДӘБИЯТ


1. Әхмәдуллин А.Г. Күңелләрне уятыр: хәзерге татар драматургиясе. Казан: Мәгариф, 2007. 223 б.
2. Батулла Рабит. Кылдан нечкә, кылычтан үткен: Кыйсса. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. 143 б.
3. Батулла Рабит. Сират күпере // Татар драматургиясе (1960–1980 еллар). Сайланма пьесалар. Казан: Хәтер, 2003. 495 б.
4. Габидуллина Ф.И. Из истории татарского романа // Материалы международной научно-практической конференции «Современные направления теоретических и прикладных исследований 2012». Вып. 1. Том 25. Одесса: КУПРИЕНКО, 2012. С. 3–6.


## Г. ТУКАЙНЫҢ БАЛАЛАР ӨЧЕН ЯЗЫЛГАН ШИГЫРЬЛӘРЕНДӘ СӘЛАМӘТ ЯШӘҮ РӘВЕШЕ


***Миңнуллина Р.Ф.***



В статье рассматривается проблема воспитания здорового образа жизни в произведениях великого татарского поэта Габдуллы Тукая. Г. Тукай в своих стихах («Холодно», «Поезд идет») поднимает проблему пьянства. Считает, что это большой грех. Жизнь пройдет, пьяный человек и не заметит. Ничего хорошего в его жизни не будет. В ряде стихов оживает чистая природа, где жить, творить человеку. Поэта волнует и то, что люди из деревень приезжают в город и идут работать на заводы. Г. Тукай поднимал и проблему физического и духовного воспитания детей.

In the article the problem of upbringing of a healthy lifestyle in tatarskogo the works of the great poet Gabdulla Tukay. G. Tukay in his poems («Cold», «the Train is coming») raises the issue of how people ruin oneself by drink. Believes that it is a great sin. Life will pass, a drunk person won't notice. Nothing good in his life will not. In a number of poems comes to life net nature, a place to live to do to a person. The poet venue and the fact that people from the villages come into town and go to work in factories. G. Tukay raised the issue of physical and spiritual education of children.

Сәламәт яшәү рәвеше тәрбияләүдә укытучылар түбәндәге укыту принципларын истә тотып эш итәләр: фәннилек, оптимальлек, укыту һәм тәрбия берлеге, әдәбиятны сүз сәнгате буларак өйрәнү, әдәби әсәрне шәхси кабул итү, кешелеклелек һ.б. Балалар сәламәт яшәү рәвеше төшенчәсен дөрес аңларга тиеш, шул очракта гына алар алга куелган максатка ирешү юлларын эзләячәк. Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру өчен укучыларда билгеле бер күнекмәләр формалаштыру; булган күнекмәләрне ныгыту, үстерү һәм камилләштерү кирәк. Белгәнебезчә, сәламәт яшәү рәвеше үз эченә берничә аспектны ала: физик яктан да, рухи яктан да канәгать булу; физик хезмәт белән ялны дөрес чиратлаштыру; дөрес туклану һәм башкалар.

Сәламәтлек бер бездән генә тормый. Сәламәт яшәү рәвешен саклау безнең әйләнә-тирә мохитебезгә бәйле. Җир йөзендәге һәр җан иясенең сәламәтлеге, табигатьнең матурлыгы турыдан-туры экологиягә бәйле. Кешеләр, гомер-гомердән яшел бишегебез – Җир анабыз үзенең табигый торыклыгын мәңге саклар, дип уйлаганнар. Алар табигатькә үзгәрешләр кертергә тырышканнар, шуның белән табигатькә зыян салуларын башларына да китермәгәннәр. Үзен «табигать патшасы» дип исәпләгән адәм баласының эшчәнлеге гел генә уңай нәтиҗә бирми, киресенчә, фаҗигале үзгәрешләр дә алып килгәли.

Җирнең матурлыгын, һаваның сафлыгын саклау мәсьәләләре Г. Тукайны да борчыган. Ул бу турыда уйланган, шул хакта күп кенә әсәр иҗат иткән. Шагыйрь фикеренчә, дөнья матур, шушы матурлыкны күп вакыт кеше үзе бетерә. Шагыйрь иҗатында кеше яшәгән бердәнбер урын буларак, Җир күпмегә түзәр икән, дигән хафалану да чагыла. Шулай да Г. Тукайның табигатькә, туган ягына багышланган шигырьләре саф табигатькә дан җырлаудан гыйбарәт. Аның кичерешләре дә саф табигать белән чагыштырыла.

И күңелнең шаулап аккан чишмәдән сафрак чагы!
И гомернең нурланып үскән яшел яфрак чагы!
(«Сагыныр вакытлар»).

Шагыйрь табигатьнең һәртөрле матурлыгын күреп шатлана, аның белән горурлана. Үзенең рухи хәләте дә табигатькә бәйле.

Әй кояш нурлы – ачылган бакчаларның гөлләре;
Яктылык! Рәхәт! Бәхет! Сайрый ходай былбыллары!
(«Кичә һәм бүген»).

Г. Тукай иҗатыннан табигатьнең бер мизгеле дә читтә калмый, ул һәр мизгелнең матурлыгын күрә, җаны-тәне белән тоя. Аны табигатьнең бөтенлеге, кирәксез нәрсәләрнең булмавы гаҗәпләндерә.

Экологиянең чикләре бик киң. Тукай бу мәсьәләгә төрле яктан якын килә. Аны татар халкының хәмергә тартылуы аеруча борчый. «Суык» шигырендә шагыйрь:

Эчә халык суык дип тә, бәйрәм дип тә,
Эчә халык хәләл дип тә, хәрәм дип тә, –

дип ачына. «Поезд барган көйгә» шигырендә авторның хатын-кызлар, әби-карчыкларның да хәмергә тартылуына йөрәге әрни. Хәмер кешеләрне баткаклыкка сөйрәүче, яшь кызларны, егетләрне юлдан яздыручы, җәмгыятьне таркатучы. Алар арасында татарларның булуы тагын да аяныч...

Исерек кеше гомеренең узуын да, тормышның ямен дә сизми. Хәмер беркемне дә кызганып тормый. Шул турыда уйланырга куша шагыйрь...

XX гасыр башында промышленность үсә башлый. Казан авыл кешеләрен җыя. Завод-фабрикаларда эшләү өчен эшчеләр кирәк. Саф табигать кочагыннан шәһәргә килгән кеше тынчу, пычрак мохитка эләгә. Бу хәл шагыйрьне борчуга сала. Сәнгать үсеше табигый матурлыкка зыян китерә.

Ут, төтен, фабрик-завод берлә һаман кайный Казан;
Имгәтеп ташлап савын, сау эшчеләр сайлый Казан.
(«Казан»).

Шагыйрьне бөтен «өязгә нур чәчеп» торган Казанның пычрануы, төтен, корымга күмелүе сызландыра.

Бер борыл да, и Казан, син бу Казан артына:
Нур чәчәсең бар өязгә, үз өязең кап-кара.
(«Казан вә Казан арты»).

Шагыйрьне бигрәк тә үсеп килүче яшь буынның хәле уйландыра. Тукай киләчәкне үз кулларында тотучы сау-сәламәт яшьләрне күрергә тели. Шуңа күрә шагыйрь яшьләрдә әхлаклылык сыйфатларын үстерүне үз бурычы итеп саный. Үсеп килүче буында табигатькә, аның «тере почмагына» карата мәрхәмәт иясе тәрбияләргә омтыла. Иң кечкенә балаларга язылган «Бала белән күбәләк» шигыре балага гомерлек үгет-нәсихәт булырлык. Күбәләк баладан:

Тик гомрем бик кыска:
Бары бер көн генә, –
Бул яхшы, рәнҗетмә
Һәм тимә син миңа! –

дип ялвара.

Бөек шагыйребез «Экология» фәнен өйрәнмәсә дә, яшәү йортыбыз булган Җир һәм анда яшәүчеләрнең тормышлары өчен борчылган. Ул табигатьнең кешегә яшәү өчен матди мөмкинлекләр дә, иҗат өчен илһам да бирүен дөрес аңлаган [1, б. 8].

Әхлак тәрбиясе – тормыш өчен кирәкле кешелек сыйфатлары тәрбияләү. Һәр кешенең әхлаклылыгы аның эш-гамәлләреннән күренә. Әдәби әсәрләрдә сурәтләнгән геройларны да без аларның кылган гамәлләренә карап күз алдына китерәбез. Әдәби геройларга характеристика бирү укучыларга әхлак төшенчәсен аңларга ярдәм итә.

Физик тәрбия – ул әхлакый тәрбиянең бер өлеше, чөнки кеше һәр яктан камил булырга тиеш. Физик тәрбия бүгенге көн шартларында бигрәк тә актуаль тема, чөнки күп сәбәпләр аркасында елдан-ел сәламәт туган балалар саны кими. Мәктәп укучыларына гына түгел, мәктәпкәчә яшьтәге балаларның да сәламәтлеген ныгыту мәсьәләсе беренче пландп булырга тиеш. Укытучылар балалар һәм яшүсмерләрнең үсеш үзенчәлекләрен генә түгел, организм эшчәнлегендә тәүлеклек, атналык, айлык, еллык, сезонлы һәм башка ритмнар барлыгын белергә тиеш. Аларның күбесе табигать шартларына бәйле. Бу «биологик сәгать»нең ничек эшләвен белү – бүгенге көндә әле тулысынча өйрәнелеп бетмәгән сорауларның берсе. Организм эшчәнлегендә тәүлеклек һәм атналык тирбәнешләр булганлыктан, кешенең акыл һәм физик хәрәкәткә булган сәләте дә үзгәрә. Мәсәлән, кече яшьтәге мәктәп балаларының эшкә сәләте беренче дәрестән өченче дәрескә, ә олы яшьтәгеләрнең беренче дәрестән дүртенче дәрескә арта. Эшкә сәләт иртәнге сигездән уникегә кадәр югары, ә аннан соң 14–15 сәгатьләрдә ул нык кими. Эшкә сәләт атна буе да үзгәрә, шуңа күрә мәктәп балаларын һәм студентларның эшкә сәләте дүшәмбе һәм шимбә көнне бик түбән. Бу исә укыту һәм тәрбия процессын планлаштыруда исәпкә алына. Көндәлек режим булдыру һәм аны үтәү әһәмиятле. Биоритмнарны онытмаганда гына югары нәтиҗәле физик һәм акыл хезмәтенә ирешергә мөмкин [2, б. 142].

Шулай итеп, планетада бөтен тереклекнең яшәеше табигатьнең гомуми ритмнарына буйсына.

Г. Тукайның балаларга багышлап яки балаларны күздә тотып язылган шигъри әсәрләрен, экиятләрен, прозасын, мәсәлләрен тикшереп, без алардагы 3 аспектка игътибар бирдек: физик хезмәт белән ялны чиратлаштыру, хәрәкәт активлыгын пропагандалау; яшь буынны дини рухта тәрбияләү; тирә-яктагы матурлыкны күрә белү, аннан уңай эмоциональ кичерешләр алу.

Г. Тукайның «Ана мәктүбләре» дигән публицистик әсәрендә балаларга дөрес тәрбия бирү мәсьәләсе бөтен тулылыгы белән яктыртыла. Автор эпистоляр жанрга мөрәҗәгать итүне уңай күрә. Сюжет җебе шуннан гыйбарәт: Гайшәнең бертуган агасы кисәк кенә авырып вафат булып, аның биш яшьлек кызы Газизә ятим кала. Гайшә кызчыкка опекун була, әмма укыту-тәрбия эшендәге тәҗрибәсезлеге аркасында ул бераз югалып кала. Киңәшләр ишетер өчен ул мөгаллимәлек тәҗрибәсе булан дусты Фатыймага хатлар яза башлый. Автор аларны номерлап, укучыга тәкъдим итә.Чыгарылыш квалификацион эшебезнең темасына нисбәтән, безне «Алтынчы мәктүб» аеруча кызыксындыра. Г. Тукай хезмәтенең бу өлешендә балаларны сәламәт яшәү рәвешенә күнектерү буенча кыйммәтле киңәшләр бирә.

Иң элек Г. Тукай баланың физик һәм рухи сәламәтлеген бербөтен итеп карый. Физик яктан сәламәт булмаган кешенең рухи байлыкны, шул исәптән, белемне дә тиешле дәрәҗәдә үзләштерергә сәләтсез булуы бәхәссез. Мәсәлән, Гайшә Газизәнең һазымы (аппетиты) начар булуга зарлана. Автор Фатыйма исеменнән болай фикер йөртә: «Бу хәл аның өйдә генә утырып, яхшы һавага чыкмаганыннан киләдер. Аңар, әлбәттә, күп сәер итү һәм күп вакыт яхшы һавада һәр көн иң азында сәгать ярым булырга кирәк. Шуның белән бергә аңа бераз хәрәкәтләнергә, җөгерергә, туп уйнарга яки тимер көрәк берлән җир казырга кирәк» [3, б. 122]. Балаларга файдалы шөгыльләрдән автор шулай ук суда йөзү, каек ишкәкләү, велосипедта йөрү, гимнастика ясауны атый. Хәрәкәтләнгән вакытта, баланың киемнәренә дә игътибар бирергә киңәш итә: алар кысып торырга тиеш түгел.

Алга таба Г. Тукай баланың йоклау урыны турында сөйли: «ул йоклаганда саф вә нәфис һавада, хәтта, әгәр мөмкин булса, ачык тәрәзә янында йокласын. Шулай итеп тәрбия иткәндә, аның һазымы да, йокысы да яхшы булыр» [3, б. 122]. Г. Тукайның әлеге фикерләре бүгенге педагогикада да чагылыш таба. «Саф һава, барыннан да элек, организм өчен – кислород, чыныгу өчен – салкын һава, яшәү шатлыгын тою өчен – җылы җиләс җил ул», – диләр алар [4, б. 89]. Шул ук автор җәяү йөрү, ял көннәрен шәһәрдән читтә үткәрү, походларга йөрү, өйдә тәрәзәне ешрак ачык тоту, сыйныфта һаваның сафлыгын күзәтер торуның әһәмиятен ассызыклый.

Г. Тукай тәрбия эшендә баланың иркенә генә таянмаска, тиешле көн режимы үтәлүне таләп итәргә кирәклеген дә ассызыклый. Бала махсус бер вакытта йокларга ятарга, махсус бер вакытта торырга, юынырга, киенергә, фәкать шуннан соң гына иртәнге аш табынына утырырга тиешлеен ассызыклый. Бу җәһәттән ата-ананың каты торуына, баланың көйсезләнүенә, хәтта елап карышуына игътибар итмәскә киңәш бирә.

Г. Тукай балаларны дөрес туклануга күнектерү буенча да файдалы киңәшләр бирә. Монда да ул режимның әһәмиятенә басым ясый. Әгәр дә инде баланың иртәнге аш белән көндезге аш, көндезге аш белән кичке аш арасында ашыйсы килсә, теләсә нәрсә бирергә ярамаганлыгын кисәтә, ә бәлки җылы сөт яисә яңа пешкән җиләк-җимеш бирергә тәкъдим итә. Дөрес туклану буенча авторның тагын бер файдалы киңәше ашаганда баланың сайлanучанлыгына кагылышлы. Билгеле, кечкенә балалар төрле файдалы ризыкны яратмаска, аннан кискен баш тартырга мөмкин. Бу очракта нәрсә эшләргә? Автор болай дип яза: «Кызны өстәлгә ни килсә, шуны ашарга гадәтләндер. Әгәр, мәсәлән, ул бер-бер төрле ашны яратмаса, син аны көчләп ашарга кушма. Шул ук вакытта син ангар шундыйн башка бернәрсә дә бирмә. Икенче вакытта ангар ул ашны татып карарга ачлык үзе көчләп кушар. Һәм ул шуны ашарга гадәтләнеп китәр» [6, б. 122].

Ниһаять, Г. Тукайның әлеге хезмәтендә искәртеп кенә кителә торган, әмма хәзерге заман шартларында аеруча әһәмияткә ия булган аспект зарарлы гадәтләргә карый. Автор укучысын балага бер генә йотым сыра, бер йотым хәмер дә тискәре йогынты ясаячагын ассызыклый. Әлбәттә, моның начар нәтиҗәсе шул ук мизгелдә күзгә ташланып, сәламәтлекне какшатмаска мөмкин. Әмма нәфеснең исерткеч эчемлеккә тартуы шушы бер йотымнан башланып, олыгайган көндә кешене фаҗигаләргә җиткерергә мөмкин.

Г. Тукайның балаларга атап язылган шигырьләрендә, әкият-поэмаларында да тәрбияви идеяләр чагылыш таба. Аның «Эш» шигырен һәрбер татар укучысы, татар баласы белә. Әлеге әсәрдә шагыйрь тормышны заяга үткәрмәү, тырышу зарурлыгын күрсәтү өчен, үгет-нәсихәт биреп кенә калмый, ә гүзәл сүз-сүрәт тудыру чараларына мөрәҗәгать итә. Шигырьнең баштагы строфаларына күз салыйк:

Тынма, эшлә, и сабый! Бел, тәңредән эшләргә – көн,
Эшләп аргачтан, бирелгәндер тыныч йокларга төн [5, б. 120].

Бирсдәге юлларда сәламәт яшәү рәвешенең нигезе булган эш белән ялны чиратлаштыру турында сүз бара. Билгеле, баланың төп эше – уку. Хәзерге галимнәр искәртүенчә, бала өчен дәресен, язу-сызу, уку эшләрен төнгә калдырырга тиеш түгел. Зиһеннең иң ачык вакыты – иртәнге сәгатьләр. Галимнәр ачыклавынча, сәламәт яшәү рәвеше системасы биологик ритмнарга зур әһәмият бирә. Кеше организмының эшләү сәләте иң югары булган вакыты – көннең беренче яртысы – иртәнге 8 дән 13 сәгатька кадәр [4, б. 88].

Г. Тукай да бу хакта искәртә:

Иртә торгач та язарга, дәрсең укырга тотын;
Тынма, эшлә, торма тик, тынсаң тынарсың җомга көн [3, б. 120].

Билгеле булганча, җомга көн мөселманнар өчен бәйрәм, ял көне саналган. Бу көнне Г. Тукай яшь дусларына ял итәргә киңәш бирә. Эш һәм ялның чиратлашуы турында автор алга таба матур чагыштырулар аркылы бәян итә:

Күр, ничек эшли кояш: иртә тора, таң аттыра,
Көнозын күктә йөзә һәм көн буенча яктыра.
Соңра, арган төсле, ул ирнеп кенә тауга бата,
Йоклый рәхәт, ял итә һәм җир йөзен дә йоклата.
Син кояштан үрнәк алсаң, иҗтиһад итсәң һаман,
Күп арасында кояш күк ялтырарсың бер заман! [5, б. 19]

Охшаш идеяләр Г. Тукайның «Эш беткәч, уйнарга ярый» шигырендә дә чагылыш таба. Әсәрдәге герой – дәрес хәзерләп утыручы бала – иртәгесе көнгә кушылган сабакларны хәзерләп куйганнан соң, саф һавада уйнарга чыгып китә.

Г. Тукай әсәрләрендә балаларның психик сәламәтлеген саклау белән бәйле темалар да яңгыраш ала. Билгеле булганча, кечкенә сабыйлар олыларның һәр әйткән сүзен дөрес дип кабул итәләр. Шул рәвешле шүрәле, албасты, убырлы кебек куркыныч затларның барлыгына да ышанырга мөмкиннәр. Аеруча нечкә күңелле, психик яктан тулысынча җитлегеп бетмәгән балалар мондый «куркыту»ларның тискәре нәтиҗәсен гомер буена тоярга мөмкиннәр.

Нигезсез куркытуның кешенең психик, физик һәм социаль сәламәтлегенә йогынтысы хакында Г. Хәбибуллина болай дип яза: «Медицина исә күптән инде курку-куркытуның бала психикасы өчен үтә зыянлы булуын, бик күп авыруларга җирлек, башлангыч булуын исбатлады. Ә без үскән чорда әле куркыту тәрбия алымы иде. Һәм бик үтемлесе. Шуңа бәйле рәвештә нәрсәдән генә куркытмадылар безне! Муенга атланган шайтаннан да, ... су анасыннан да, жен-пәридән дә… Нәтиҗәдә тулы бер куркак буын үсте. Олыларга каршы әйтергә ярамый дип тә, үзеңне-үзең күрсәтә күрмә, эшеңне башкалар күрсен, бәяләсен дип тә, башкаларга юл бир дип тә чикләделәр безне. Кеше сүзеннән, башкалар фикереннән уттан курыккандай куркырга күнектерделәр. Нәтиҗәдә абсолют күпчелек үз сүзен әйтергә курка, үз-үзен бәяли белми, үз-үзенә ышанмый, башкалар фикереннән бәйле булып үсте» [6, б. 3].

Г. Тукай да «Сабыйга» дигән шигырендә балаларны андый затлардан курыкмаска өнди:

Һич сине куркытмасыннар шүрәле, җен һәм убыр;
Барчасы юк сүз – аларның булганы юктыр гомер.
Җен-фәлән дип сөйләшүләр искеләрдән калган ул;
Сөйләве яхшы, күңелле – шагыйранә ялган ул.
Һич өрәк, албасты булган сахралар, кырлар да юк;
Шүрәле асрап ята торган кара урман да юк [5, б. 18].

Шулай итеп, Габдулла Тукай балаларга тәрбия бирү мәсьәләсендә сәламәт яшәү рәвешенә дә зур җаваплылык белән карый. Бала тәрбияле, сау-сәламәт үсәргә тиеш. Әдип шушы фикерне ассызыклый.

ӘДӘБИЯТ


1. Гыймадиева Н. Г. Тукай иҗатында экология темасы // Мәгариф. 2009. № 4. Б. 6–8.
2. Балалар, яшүсмерләр физиологиясе һәм гигиенасы / Ф.Г. Ситдиков редакциясендә. Казан: Мәгариф, 1995. 142 б.
3. Тукай Г. Сайланма әсәрләр. 2 томда. Т. 2. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.
4. Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Тәрбия – мәңгелек фәлсәфә. Казан: Мәгариф, 2001.
5. Тукай Г. Бәхетле бала. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011.
6. Хәбибуллина Г. Һич сине куркытмасыннар... // Ватаным Татарстан. 2010. 30 июнь.


## ТАТАР ДРАМАТУРГИЯСЕНДӘ ТУКАЙ ОБРАЗЫНЫҢ ГӘУДӘЛӘНЕШЕ
### *(И. Нуруллин, Т. Миннуллин, Р. Батулла пьесалары мисалында)*


***Миңнуллина Ф.Х.***



В данной статье расматриваются художественные воплощения образа Габдуллы Тукая в татарской драматургии. Анализируются пьесы И. Нуруллина, Т. Миннуллина, Р. Батуллы.

In this article we are risen artistic embodiment of the image Gabdulla Tukay in Tatar drama. Analyzes the play I. Nurullina, T. Minnullina, R. Batully.

Татар халкы үзенең катлаулы тарихында бөек шәхесләрне аз тудырмады. Татар әдәбиятында да тарихи темаларга, шәхесләргә мөрәҗәгать итү еш күзәтелә. Кол Гали, Сөембикә, Кол Шәриф, Батырша, Бәхтияр Канкаев, Г. Тукай, С. Сәйдәшев, М. Җәлил, М. Солтангалиев кебек тарихи шәхесләребезнең матур образлары үзәккә куйган роман-повестьлар, хикәяләр, шигырь-поэмалар күп языла. Татар драматурглары да әлеге процесстан читтә калмады. А.Әхмәдуллин билгеләгәнчә: «Дөрес, бу өлкәдә аларның уңышлары сан ягыннан башка әдәби төрләргә караганда шактый ук тыйнак. Шулай да язылган кадәресе әдәби-эстетик яктан һичшиксез игътибарга лаек. Кыскасы, хәзерге драматургиядә тарихи һәм тарихи-биографик жанр төрләре җанланды дип әйтергә мөмкин» [2, б. 142]. Язылган әсәрләрнең үзәгенә милли азатлык өчен көрәшкән шәхесләр, аларның язмышлары куела. Әйтергә кирәк, Г. Тукайның тормышына һәм иҗатына багышлап күп санлы мәкаләләр, фәнни хезмәтләр, монографияләр язылган, сәнгать әсәрләре иҗат ителгән. М. Шәрипов язганча: «Шунысы кызык, Тукайны күреп белгән замандашлары гәрчә бәгъзеләре драматург булсалар да, совет хакимияте чорында аның хакында бер генә пьеса да иҗат итмәделәр. Сәбәп аңлашыла: теге яисә бу әдип хакында әсәр иҗат итү традицияләре юк дәрәҗәсендә иде әле ул вакытта милли әдәбиятта. Язучы шәхесенә, аның биографиясенә игътибар итү традициясе татар әдәбиятында XX йөздә генә юл башлады» [6, б. 88]. Бу эшне 30 еллар ахырында Ә. Фәйзи башлап җибәрә. Бүгенге көндә киң җәмәгатчелеккә Ә. Фәйзинең «Тукай», «Тукай Җаекта», И. Нуруллинның «Тукай Петербургта», И.Юзеевның «Очты дөнья читлегеннән», Р. Ишморатның «И мөкатдәс моңлы сазым», Т. Миңнуллинның «Без китәбез, сез каласыз», Р. Батулланың «Сират күпере», Ә. Гаффарның «Соңгы сәгать» кебек пьесалары мәгълүм.

Г. Тукай образына мөрәҗәгать итеп язылган пьесаларда шагыйрь образы төрле аспектларда ачыла. И. Нуруллинның «Тукай Петербургта» драмасында мәсәлән, Тукайның Петербургка килүе, аның аралашу даирәсе хакында языла. Бу Тукайның үпкә авыруы көчәйгән вакыт. Дусларының Петербургка чакыруы да шуның белән бәйле. Татар байлары арасында аны дәваларга теләүчеләр дә табыла. И. Нуруллинның әлеге драмасында Тукай хис-кичерешләргә бай шәхес итеп күрсәтелә. Шагыйрьнең хатын-кызлар белән очрашуы, аларга атап шигырьләр язуы, фоторәсемнәр алышуы турындагы урыннар шул хакта. Гомумән, автор Тукайны талантлы каләм иясе буларак та бәяли.

Т. Миннуллин пьесасында исә Г. Тукайның тарихи шәхес буларак горурлыгы, байлыкка битарафлыгы, хатын-кызлар белән мөгамәләдә оялчанлыгы яңа ситуацияләрдә ышандырырлык итеп сурәтләнә. Мәгълүм ки, тарихи шәхесләрне сурәтләү обьекты итеп алганда драматурглар уйланма вакыйгаларга да еш мөрәҗәгать итәләр, тарихи фактлардан читкә чыкмаска, реальлекне сакларга омтылалар. Бу хакта Т. Миңнуллинның «Без китәбез, сез каласыз» драмасына карата әйткән фикерләре кызыклы. «Мин тарихчы түгел, һәм мин тарихи-документаль әсәр язарга алынмадым. Мине Тукай образы кызыксындырды. Барлыгы 27 ел яшәп, үз җилкәсендә гаҗәеп авыр йөк күтәргән, тулы бер халыкның язмышын үз йөрәге аша үткәргән шагыйрь образы дулкынландырды... Шагыйрь 1909 елда фабрикант Акчуриннарга кунакка бара... Тукай һәм фабрикантлар, һич янәшә куеп булмаслык факт. Акча, байлыкка аз гына да исе китмәгән, җае чыккан саен туклардан әче итеп көлгән кайнар йөрәкле Тукай һәм, берничә дистә ел эчендә гади сәүдәгәрдән атаклы капиталистка әйләнгән нык куллы, салкын акыллы, булдыклы Акчуриннар. Ни сөйләште икән алар? Ул хакта ни Тукай, ни Акчуриннар язып калдырмаган»[5, б. 3]. Күренә ки, Т. Миңнулин документаль әсәр язуны максат итеп куймый. Киресенчә, тарихи фактка нигезләнеп, Г. Тукайның халык мәнфәгатьләре белән янып яшәвен, тирән хис-кичерешләргә бай шәхес итеп ача. Драманың нигезендә язучының бертуган фабрикантлар Хәсән, Якуб, Абдулла Акчуриннар белән үзара мөнәсәбәтләрен күрсәтү ята. Әсәрдә Хәсән Тукайга ихтирам күрсәтергә омтыла. Шагыйрьнең иҗатын, максатын яхшы белүгә карамастан, аның Тукай белән аңлашырга омтылышы барып чыкмый. Якуб Акчурин исә байлык артыннан куа. Тукай Якубка карап: «Сездән кан исе килә», ди [5, б. 24]. Абдулла Акчурин исә, экчечелеккә бирелеп, шәхес буларак таркалуга җиткән.

Т. Миңнуллинның әлеге драмасы турында Г. Арсланов түбәндәге фикерләрне әйтә: «Максат нинди чаралар ярдәмендә тормышка ашырыла соң? Автор максатка илтүче төп ишарә итеп социологик схеманы алган һәм шул социологик схема ярдәмендә, сыйнфый күзлектән чыгып, Тукайның калган барлык Персонажларга, төрле социаль

катлау кешеләренә мөнәсәбәтен билгеләгән... мондый шартларда шагыйрьнең эчке дөньясын ачу, поэтик фикерләү югарылыгынкүрсәтү мөмкин булмаган нәрсә», – дип яза [1]. Т. Миннулин исә: «Тукай һәм Акчуриннар мөнәсәбәтен мин һич кенә дә сыйнфый каршылыкка кормадым. Тукайдан большевик ясарга җыенмадым. Шулай да Тукайның Акчуриннарга мөкиббән китеп, аларның үзара яратышуын язарга да хакым юк иде. Бу Тукай образына хилафлык китерү булыр иде. Тукай беркайчан да байларны яратмаган. Үзе байлыкка исе китмәүче шәхес буларак, ул байлардан һәрвакыт көлгән, аларны мыскыл иткән. Укыгыз Тукайны игътибар белән. Шулай булгач ул Акчуриннарны гына ярата алмый инде, бигайбә» [4, б. 3], дип белдерә үзенең бер язмасында.

Г. Шакирова билгеләгәнчә, Тукай Акчуриннарга каршы түгел, ул аларның байлыгына, аларның философиясенә каршы көрәшә. Әйтергә кирәк, драмада төп конфликт Г. Тукай һәм шагыйрь яшәгән җәмгыятьтә хөкем сөргән карашлар белән бәйле.

Р. Батулланың «Сират күпере» драмасында шагыйрь буларак формалашкан Г. Тукайның сонгы көннәре, төгәлрәк әйткәндә шагыйрьнең хастаханәгә китәр алдыннан булган ике көне сурәтләнә. Элегрәк язылган әсәрләрдән Г. Тукай шагыйрь һәм көрәшче буларак сурәтләнсә, Р. Батулла драмасында ул хис-кичерешләргә бай шәхес буларак тулырак гәүдәләнеш таба. Язучыга хас бу сыйфатлар Туташ һәм Ханым, Шәүлә образларына мөнәсәбәтле күренешләрдә ачыла.

Драмада Тукай горур, туры сүзле, хатын-кызга мөнәсәбәттә кыюсыз, киң карашлы шәхес буларак бирелә. Әдипнең Туташ дип исемләнгән ханым белән очрашуларында, аның олы мәхәббәт хисенә ия булуы билгеләнә.Сөеклесен авыр хәлдә калдырмас өчен, ул мәхәббәтеннән баш тарта.

Ханым белән сөйләшү күренешендә инде Тукай хатын-кызны хөрмәт итүче, дөнья мәдәниятен һәм әдәбиятын яхшы белүече буларак күзаллана. Р.Батулла драмасында Тукай халык бәхете өчен көрәшчүче шәхес буларак та ачыла. «Мин гаиләдә вакланып бетсәм, халыкка ни калыр? Шуңа күрә мин беркайчан да өйләнмәскә уйладым», ди ул үзенең яшәеше, омтылышлары хакында.

Драмада шагыйрьнең Агабәк (Фатих Әмирхан), Ядкәр Хөрмәтов (Хөсәен Ямашев) кебек якын дуслары, көрәштәшләре белән янәшә Шәүлә образы да сурәтләнә. Ул шагыйрьнең дошманы. Тукайның соңгы көннәре дә аның белән көрәшеп үтә. Шәүлә тараткан «Тукай каты авырый» дигән ялган хәбәр шагыйрьнең дусларын, якыннарын борчуга сала. Көрәштәшләре Ядкәрнең, Бикчураның фаҗигаләрен тизләтә. Шәүлә бу хакта болай ди: «...Хөрмәтов Ядкәрне дә ... урыны җәннәттә булсын... без юк иттек» [3, б. 438]. А. Әхмәдуллин раславынча: «Шәүлә образы – драматургның зур табышы. Бу кеше жандармериянең астыртынлыгын, хыянәтчел икейөзлелеген, мәрхәмәтсезлеген һәм акыл көчен гәүдәләндерә... Ләкин шул ук вакытта Шәүлә моңарчы әсәрләрдә күреп өйрәнелгән, кап-кара тискәре образ да түгел. Югыйсә Тукай кебек тарихи шәхесләргә каршы көрәшкән көчләр берьяклы гына, акылга таманрак, гел этлек эшләп йөрүче, явызлыкны үзендә туплаган схематик образ кыяфәтендә генә күренә иде» [2, б. 148]. Мәсәлән, Шәүләнең:«Чын революцияне яклаучы мин. Революция ясаучыларның туксан проценты надан була... Баш күтәрү вакытында акыллылары үлеп бетә... Россия әле чын революциягә әзер түгел. Мин менә шуннан куркам, Тукай. Әнә шундыйлар Россия халыкларын ялгыш юлдан алып китмәгәе дип, бөтен көчемне, талантымны биреп көрәшәм» [3, б. 436]. Шулай да, Шәүлә рухи җиңүгә ирешә алмый. Үлем алдында да Тукай үз идеяләренә тугры кала: «Әгәр милләт мине, илтифат итеп, искә алса, шул минем максатым, теләгем һәм бәхетем», ди [3, б. 438]. М. Шәрипов фикеренчә: «Батулла пьесасында да Тукай холкын җанлырак итеп гәүдәләндерү буенча кызыклы ачышлар бар, гомумиләштерелгән Туташ, Агабәк, Ядкәр, Сагышлы, Шәүлә образларының хәрәкәте төп каһарманның сыйфатларын ачуга юнәлтелгән» [6, б. 89]. Гомумән, Р. Батулла драмасында төп конфликт Г. Тукай һәм шагыйрь яшәгән җәмгыятьтә хөкем сөргән карашлар, шагыйрь күңелендә барган эчке каршылык белән бәйле.

Каралган әсәрләрдә Г. Тукай кешелекнең якты хыялларын үзендә туплаган олы җанлы, батыр йөрәкле шәхес булуы тулы сурәтләнә. Шагыйрь ил, Ватан, милләт, халык язмышы, мәнфәгатьләрен алга куеп эш итүе бирелә. Авторлар тарихи дөреслеккә, биографик фактларга тугрылык сакларга, геройның холык-фигыльләрен, башларыннан кичкән хәлләрне, ситуацияләрне, каршылыкларны тормышта булганча яктыртырга омтылалар.

ӘДӘБИЯТ

1. Арсланов Г. Якты йолдыз булып атылдын // Ватаным Татарстан. 1996. 19 апрель.
2. Әхмәдуллин А. Күңелләрне уятыр. Казан: Мәгариф, 2007. 223 б.
3. Батулла Р. Кичер мине әнкәй: Пьесалар. Татар. кит. нәшр., 1988. 449 б.
4. Миңнуллин Т. Без китәбез, сез каласыз. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. Б. 3–9.
5. Миңнуллин Т. Байлар, байлар бал эчә // Заман. 1999. 23 апрель.
6. Шәрипов М. Г. Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар // Г. Тукай тууына 125 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. Казан, 2011. Б. 81–86.

# РОЛЬ КНИГ ГАБДУЛЛЫ ТУКАЯ В ПРОСВЕЩЕНИИ ТАТАРСКОГО НАРОДА

***Мирдиянова Г.Р.***

Статья рассматривает период истории образования и просвещения татарского народа – конец XIX – начало XX в. Приводятся сведения о развитии особого движения «Джадидизм» в системе образования, т. е. нового метода. Автором проводится анализ учебников татарского поэта XIX–XX вв. Габдуллы Тукая. Обосновывается их роль в развитии образования и просвещения татар. Даны сведения о наличии их фондах Татарстана на сегодняшний день.

This article considers the period of the history of education and enlightenment of the Tatar people – end of XIX – beginning of XX centuries. Provides information about the development of special «Jadid movement» in the education system, that is, the new method. The author analyses the textbooks of the Tatar poet of XIX–XX centuries Gabdully Tukaya. Is justified by their role in the development of education and enlightenment of the Tatars. Given information about their available funds of Tatarstan to date.

Конец XIX в. ознаменовался переломом в сфере просвещения и образования татар. В обществе нарастала неудовлетворенность системой образования, в частности, неэффективностью буквослагательного метода чтения, пренебрежением национальным татарским языком, ограничением только лишь преподаванием религиозных предметов. Все это привело к развитию особого движения «Ысулы жядид», т.е. нового метода. Это движение означало внедрение европейской культуры в татарскую. Одно за другим открываются медресе, работающие на основе новометодной программы: «Мухаммадия», «Касыймия» (Казань), «Галия» (Уфа), «Хусаиния» (Оренбург), «Расулия» (Троицк), «Буби» (дер. Иж-Бобья Сарапульского уезда Вятской губернии) и др. Благодаря внедрению новометодного подхода реформы в системе образования прошли в нескольких направлениях: вместо буквослагательного метода чтения утвердился азбучно-звуковой метод; наряду с традиционными религиозными методами, составляющими основу программы обучения, вводилось большое количество светских предметов, формирующих научное мировоззрение; впервые внедрялось изучение родного татарского и русского языков; устанавливается классно-урочная система с использованием школьного оборудования [4, с. 25].

В новометодном медресе наряду с религиозными предметами преподавались такие светские дисциплины, как арифметика, алгебра, геометрия, география, история, природоведение, химия, физкультура, пение, а также и специальные предметы: педагогика, дидактика, физиология, психология, методика преподавания. Все они преподавались на татарском языке, а религиозные предметы – на арабском и персидском.

Образование осуществлялось на базе учебной литературы. В старометодном учебном заведении обучение велось, традиционно, по учебникам религиозного содержания на арабском и персидском языках. В новометодном заведении, напротив, использовали светские труды – сочинения представителей передовой татарской интеллигенции.

Однако, татарские светские издания начали публиковаться лишь во второй половине XIX в. Тогда же выходят в свет и первые татарские учебные книги А. Вагапова, С. Кукляшева, М. Бикчурина. В дальнейшем издаются труды К. Насыри, Г. Махмудова, Г. Баруди, Х. Максуди, Ш. Тагирова, Т. Яхина, Г. Фаизханова, Р. Фахрутдина, Г. Фаизханова, М. Иманаева [1, с. 95].

К началу XX в. в программе медресе активно используются татарские учебники и методические пособия. Из них особое внимание привлекают учебники великого

татарского поэта Габдуллы Тукая. Ощущая нехватку татарских учебников в татарских медресе, особенно учебников по литературному чтению, Тукай решается на создание сборников и хрестоматии. Из-под его пера выходят в свет очень востребованные на тот момент книги: «Яңа кыйраәт» («Новое чтение») (1909), «Әдәбият» («Литература») (1909) и «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» («Уроки национальной литературы в школе») (1910).

В предисловии к хрестоматии «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» он высказывается о важности введения в учебный план урока «татарское литературное чтение», о необходимости воспитания детей посредством чтения татарских произведений: «…Ләкин ни сәбәптәндер, бу көнгә чаклы мәктәп-мәдрәсәләребездә милли әдәбият вә ана телемезгә бер төрле курку аралаш нәфрәт белән карыйлар иде ... мин һәр никадәр балаларның рухларына азык бирү вә аны тәрбия итүне беренче максуд итеп тотсам да, икенче тарафтан, әдәбиятның мәктәпкә керүе аркасында, аңар гомум милләт тарафыннан әһәмият бирелмәсме вә шул саядә әдәбият Русия мөселманнары арасында тиешле кадәр таралып китмәсме дигән өмидем дә бар иде» («Однако, до этих дней в школах и медресе было пренебрежительное отношение к родному языку и литературе ... первоначальной моей целью было обогатить души детей, воспитать их, с другой стороны, я надеялся, что появившись в школе, этой книге отдадут должное внимание и мусульмане всей России») [3, II].

Опровергая слова некоторых представителей интеллигенции, которые считали, что у татар нет языка, нет литературы, он пишет: «Татарларда тел юк, әдәбият юк диючеләрне ... кызганам. Әйе, бездә әдәбият бар һәм дә бай әдәбият!» («Я жалею тех, кто считает, что у татар нет ни языка, ни литературы. Да, несомненно, у нас есть литература, к тому же богатейшая!») [3, II].

В хрестоматию вошли образцы татарской прозы и поэзии для детей того времени. Наряду со стихами Тукая в ней были представлены и произведения К. Насыйри, Дэрдмэнда, Г. Исхакый, Ф. Амирхана, М. Гафури, Р. Фахретдина, Г. Баруди, С. Максуди, С. Рамиева, Н. Думави, З. Башири, М. Укмасый, Р. Ибрагимова, Ш. Шарафа и др. [2, с. 209]. При составлении хрестоматии Тукай ставил следующие задачи: нравственное воспитание детей; знакомство их с передовыми татарскими писателями и поэтами того времени; ознакомление с богатой историей своего народа; расширение кругозора; ознакомление с иностранной литературой (в переводах на татарский язык) и др.

В книгу «Яңа кыйраәт» («Новое чтение») были включены только произведения Тукая. Выбирая то или иное стихотворение, поэт преследовал определенные цели. В предисловии к хрестоматии «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» («Уроки национальной литературы в школе») по поводу построения учебника «Яңа кыйраәт» («Новое чтение») он пишет: «... һәр шигырь вә мәкаләләрне бер төрле мәгълүм максад белән дәрәҗә иткән идем» («Приводил каждое стихотворение и изречение с определенной целью») [3, III].

В начале книги через притчу «Табигать һәм инсан» («Природа и человек») и стихотворение «Аллаһ Тәбәракә вә Тәгалә» («Аллах Благословенный и Всевышний») автор знакомит ребенка с его Творцом: « ...Аллаһ Тәгаләне балага таныту вә соңгы шигырь белән балада Аллаһ Тәгаләгә карашы, мәхәббәт уяту максады» («Цель – знакомство ребенка с Всевышним, пробуждение любви к Нему») [3, III].

Через стихотворение «Туган авыл» («Родная деревня») Тукай стремиться привить детям любовь к посланнику Аллаха Мухаммаду: «...Туган авыл» кеби шигырь белән пәйгамбәребезгә мәхәббәт хисе кузгату» («Посредством стихотворения «Родная деревня» привить любовь к нашему пророку») [3, III].

Следующая притча «Баланың ата-анасын сөюе» («Любовь ребенка к родителям») призывает детей уважительно относиться и любить своих родителей. Стихотворение же «Туган тел» («Родной язык») повествует о любви к родному языку и литературе. Последующие стихотворения и притчи призывают детей к любви и бережному отношению к природе, к труду, усердию. Завершают сборник шедевры творчества Г. Тукая поэма «Шүрәле» («Шурале»), стихотворения «Пар ат», «Бәйрәм бүген» («Сегодня праздник»), «Казан шәһәре» («Город Казань»).

Учебники великого поэта активно использовались в учебной деятельности медресе не только г. Казани, но и других городов, где проживали татары. Выпускались они типографией «Үрнәк», библиотеками «Мәгариф» и «Сабах» с 1909 г. вплоть до 1919 г.

На сегодняшний день же они составляют богатое письменное наследие татарского народа и хранятся в фонде Научной библиотеки им. Лобачевского в отделе рукописей и редких книг. В фонде представлены книги Г. Тукая – «Яңа кыйраәт» (1909), «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» (1911), «Әдәбият» (1910, 1913).

ЛИТЕРАТУРА

1. Габдельганеева Г.Р. Типографская деятельность Казанского университета по печатанию востоковедческих книг (вторая половина XIX в.) // Татарская книга: страницы истории = Татар китабы: тарихи сәхифәләр. Казань, 2012. С. 91–99.

2. Галимҗанова Э.М., Фәйзуллина Ф.Г. Г. Тукайның «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» хрестоматиясе // Инсани фәннәр: эзләнү һәм табышлар: Йомгаклау конференциясе материаллары. Казан, 2013. Б. 207–213.

3. Тукай Г. Мәктәптә милли әдәбият дәресләре. Казан: «Сабах» китапханәсе, 1911. 154 б.

4. Ялалов Ф. Г. Гимназическое образование народов России. Казань: Магариф, 2002. 248 с.

## ГАСЫРЛАР ЧИГЕНДӘ «МИЛЛИ ӘДӘБИЯТ ДӘРЕСЛӘРЕ» ҺӘМ ТУКАЙ

***Мотыйгуллина Ә.Р.***

В статье раскрывается научно-методические идеи Г. Тукая. Анализируется методическое наследие поэта, заложенное в вводную часть учебника «Национально-литературные уроки в школе». Кроме этого, учебник сопоставляется с современными УМК.

In the article the scientifically-methodical ideas of G. Tukay. Analyzes the methodological heritage of the poet, laid down in the introductory part of the textbook «the National literary lessons at school». In addition, the textbook is mapped to the modern CMO.

Татар халкы борынгы заманнардан ук гыйлем тупларга, белемле булырга омтылган. XX гасыр башына татарларда шактый белем бирү системасы формалашып бетә: мәдрәсәләр эшләп тора, Татар укытучылар мәктәбе оеша, хәтта дәрәҗәле татар халкы вәкилләре югары белем алуга да ирешә. Белемне Казан университетында гына түгел, чит илдә дә күтәрү күзәтелә (С. Максуди Арсал – Сорбоннада, Г. Сәгъди – Төркиядә һ.б.) Шулай итеп, XX гасыр башындагы белем бирү системасын «яңа агым» дип атый башлыйлар.

Күренекле шагыйрь Г. Тукайга да шушы шартларда яшәргә һәм эшләргә туры килә. Әдипнең милләтне алга җибәрү турындагы хыяллары булып милли үзаңны үстерү, хезмәткә өндәү «хезмәт эчендә йөзмәккә» икәнлеген искә алсак, ул «яңа агым»нан читтә кала алмаган. XX гасыр башы галимнәре, әдипләренә ияреп, Тукай да үрнәк мөселман тәрбияләү бурычын гамәлгә кую эшенә керешә.

Шул максатны күздә тотып, әдип 1908–1912 елларда балаларга өйдә уку өчен үз әсәрләрен һәм күренекле башка язучылар әсәрләрен туплап, түбәндәге исемдәге 6 җыентык бастырып чыгара: «Юаныч» (1908), «Энҗе бөртекләре» (1909) «Балалар күңеле», «Күңелле сәхифәләр» (1910), «Күңел җимешләре» (1911), «Җан азыклары» (1912). Аларда шигырьләре белән беррәттән әдипнең «Шүрәле», «Мияубикә», «Кәҗә белән Сарык әкияте» кебек зур күләмле, төрле жанрдагы әсәрләре дә урын алган. Бу җыентыкларга кертелгән әсәрләрдә нигездә хезмәт кешеләренең тормышы, уйтеләкләре, омтылышлары, авыл табигате һ.б. тасвирлана. Шунда ук аларда Г. Тукай әсәрләре белән беррәттән халык авыз иҗаты әсәрләреннән гүзәл үрнәкләр, рус классиклары А. Пушкин, М. Лермонтов, Л. Толстой, И. Крылов, Н. Некрасов әсәрләреннән тәрҗемәләр дә урнаштырылган. Шул юл белән әдипнең төрле культураларның үрелеп үсүенә дә игътибар итүе күзәтелә.

Г. Тукай дәреслекләр, хрестоматияләр язу эшенә иҗади якын килә. Аның фәнни-педагогик эшчәнлеге өлкәсендәге беренче дәреслек «Яңа кыйраәт» (1909) була. Анда укыту-тәрбия материаллары бер системага салына. Бу дәреслек балалар өчен татар телендә китаплар бастырып чыгару өлкәсендә беренче адым, беренче «карлыгач» буларак та әһәмиятле. Уку китабы буларак ул мәктәпләрдәге «Кисекбаш», «Иман шарты». «Бәдәвам» китапларын алыштыра. Г. Тукай мәктәпләрнең алдынгы тәҗрибәсен гомумиләштергән, рус педагогикасының фәнни принципларын эшләгән педагог К.Д. Ушинский, Л.Н. Толстойлар эшчәнлегенә югары бәя бирә, дәреслекләр һәм уку китаплары төзегәндә аларның хезмәтләреннән шактый урынлы файдалана [1, б. 37].

«Яңа кыйраәт» дәреслеге турындагы фикерләрен Г. Тукай «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» (1911) дигән хрестоматиясенең кереш өлешенә кертеп җибәрә. «Мин моннан әүвәл язганым «Яңа кыйраәт» китабымны, аның мөндәриҗаты (эчтәлек) үз тәхрир (язма) вә тәрҗемәләрем генә булганга, һәр шигырь вә мәкаләләрен һәртөрле мәгълүм максат белән дәреҗ иткән идем (урнаштыру)» [4, б. 7].

«Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» (2011) беренче чыганактан аерылып тора. Ул чорның әдәби казанышлары белән таныштыру максатын куеп төзелгән, эзлекле, фәнни-методик таләпләргә җавап бирүе белән кызыклы. Аның гасыр башындагы вариантын табып алып, Рөстәм Мәһдиев иҗади эшкәртелеп, кабат бастырыла. Ул Тукай төзегән дәреслеккә игътибар юнәлтүен түбәндәгечә аңлата: «Мәдрәсәләрдә китап киштәсе» җыентыгы өстендә эшләгәндә кулыма шәхес культы корбаны, указлы мулла Сөнгатулла бабамның коточкыч афәтләрдән сакланып калган -тышлыклары саргаеп, тетелеп беткән бер китап килеп керде. Гарәп имлясында басылган һәм бөек Тукай тарафыннан төзелгән әдәбият дәреслеге иде бу. Ике дә уйламастан, мин аны гамәлдәге шрифтка күчереп, компьютерыма җыйдым, сүзләргә аңлатмалар биреп, өстәмә белешмәләр өстәдем» [4, б. 150].

Дәреслек-хрестоматиянең кереш өлешендә төзелеш принцибы ачык күрсәтелә: «Монда төрле багъбаннарыбызнын (бакчачыларыбыз) хәссас (сизгер) күңелендә җитешкән әдәбият гөлләреннән берәр-берәр чәчәкләр алынды. Безгә, сабый балаларыбызнын кулында моңарчыга кадәр булган әрекмән, кычыткан вә балтырганнарны алып, алар урынына шушы китап кеби чәчәк бәйләмнәре бирергә тиештер. Таки (шул рәвешле) балаларыбызның күзе гүзәл нәрсәләр күрергә вә борыннары да хуш вә татлы исләр иснәргәияләшсен»[4, б. 5].

Дәреслекнең сүз башында Г. Тукай мөгаллимнең эшчәнлеген дә күздә тота. Аңа каты бәрелми: «мәшәкатьләнүләрен хәзергә көтмим», – дип белдерә. Шунда ук «... моңа кадәр күрелмәгән ят бер кыйраәт китабының үзе ят булганы кеби, аны балаларга укыту рәвеше дәят тоелачактыр» [4, б. 7].

Дәреслек-хрестоматия төзелеше дә камил. Ул сүз башы (мөкаддимә), әсәрләр урнаштырылган төп өлештән тора. Мөкаддимә өлешендә түбәндәге якларга игътибар ителә:

1) дәреслекне төзүнең максаты билгеләнә: «Яшь балаларымыз кулына шуның (әдәбият бакчамыз) чәчәкләреннән ясалган бер чәчәк бәйләме тоттырмак безгә күптән лазем иде» [4, б. 5];

2) дәреслекнең актуальгеге ачыклана: «моның кирәклеге фикере аңлы мөсеманнарыбызның башында эшләнеп чыгып, аннан милли гәзитәләремез сәхифәләренә дә гакес (чагылыш) иткән иде» [4, б. 5]. Шунда ук яшь буынны тәрбияләүнең юнәлешләрен ачыклап – матурлыкны күрсәтү, тупаслыктан читләштерү икәнлеген ассызыклый;

3) Тукайның әдәби әсәрләрне сайлау принциплары да күрсәтелә: «Мин үземчә яхшы һәм матур дип белгән кыйтга вә шигырьләрне генә сайларга тырыштым» [4, б. 6].

4) төзелеш принцибын ачыклап, «руслардагы «Живое слово» нам кыйраәт китабы минем «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре»нең тарзы (форма) тәртибендә рәһбәр (юлдаш) итеп тотылды» [4, б. 7]. Ягъни үрнәккә алган китабын да яшерми.

Шунда ук Тукай китап төзү өлкәсендә беренче тәҗрибә булмаганлыгын да сиздереп куеп. Китапка кертелгән әсәрләрнең эстетик вазифасын ачыклый. «Яңа кыйраәт»кә кертелгән «Туган авыл» «пәгамбәребезгә мәхәббәт хисе кузгату», «Туган тел» «туган тел һәм әдәбиятыбызга мәхәббәт уяту», «Чыршы», «Җил вә Кояш» «шигырьләре белән баланы дөнья вә табигать хакында уйлату һәм аны сөйдерү», Ике сабан», «Эш», «Япун хикәясе» «балаларны эш вә иҗтһадка тәргыйп итү (тырышырга кызыктыру), «Шүрәле», «Бәйрәм бүген», «Пар ат» шигырьләре вә «Казан шәһәре» мәкаләләре белән балаларыбызда миллият вә милләт мәхәббәте тудыру өмет ителде» [4, б. 7–8]. Ул дәрестә яңа материалны үзләштерү балаларның белемен үстерүдә әһәмиятле шарт булуын билгеләп үтелә.

Дәреслеккә язылган сүз башында текстны укыганнан соң, балалар алдында аларны тирән уйланырга мәҗбүр итәрлек сораулар куярга кирәклеген, балаларның укыган текст эчтәлеген үз сүзләре белән сөйләп бирергә тиешлекләрен укытучыларга искәртеп куя. Мондый методик тәкъдимнәре белән Г. Тукай иске мәктәпләрдә кулланылып килгән аңламыйча ятлау методикасына кискен каршы төшүен дәлилли.

«Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» китабының төп өлешенә салынган әсәрләр арасында күпчелекне Г. Тукай шигырьләре алып тора. Аның 12 шигыреннән тыш,

«Исемдә калганнар» дигән автобиографик әсәре, аның тәрҗемәсендә А.С. Пушкинның «Алтын Әтәч турында әкияте»ннән өзек, алдынгы карашлы татар язучыларының шигырьләре, хикәяләре, поэмаларыннан өзекләрләр урнаштырылган (Закир Һади, Р. Фәхретдин, Г. Исхакый, Ф. Кәрими, Шәһәр Шәрәф, М. Гафури, Мирсаяф Кәримбаев, С. Рәмиев, Садри Максуди, Гайнетдин Әхмәров, Ф.Әмирхан. Дәрдемәнд, Габдерәшит Ибраһимов, Зариф Бәшири, Нәҗип Думави һ.б.), К. Насыйри туплаган мәкальләр һәм әйтемнәр бирелгән.

Г. Тукайның хрестоматиягә кертелгән «Шүрәле», «Су анасы», «Япон хикәя»се кебек һ.б. иҗат җимешләре, М. Гафуринын «Электр фонарена хитаб», «Яшь гомер» кебек әсәрләре югары художестволы һәм тирән идеяле булулары, аерым дидактик бурычларны үтәүләре белән башка материаллардан шактый аерылып торалар. Әдәбиятның тәрбияви әһәмиятен тирән аңлаган шагыйрь дәреслеккә кертелгән әсәрләр ярдәмендә яшь буынга тирән белем, дөрес тәрбия бирү мөмкинлекләрен чагылдырырга омтыла [1, б. 42]. Әдәбият буенча төзелгән хрестоматиянең гади, җанлы, образлы тел белән язылырга тиешлеген аңлатыла.

Хрестоматиянең кереш сүзендә Г. Тукай мәктәп дәреслекләренә балаларның яшь үзенчәлекләрен, белем дәрәҗәләрен исәпкә алып, аларга аңлаешлы булган, сәнгатьчә эшләнгән әсәрләрне генә кертергә киңәш итә. Балаларның дөньяга карашын формалаштыру, аларда тормышка актив мөнәсәбәт, белемгә омтылыш, авырлыкларны җиңүгә ихтыяр тәрбияләү максатында әдәбияттан урынлы һәм нәтиҗәле файдаланырга өнди. Яшь буында әдәбиятка, китапка мәхәббәт тәрбияләргә омтыла.

Хрестоматия тематик яктан да төрле: ата-анага ихтирам – Р. Фәхретдин «Ана нәсыйхате». «Зөһрә ханым» һ.б.; Казан турында мәгълүматлар – Р. Фәхретдин «Казан», Гайнетдин Әхмәров «Казан каласының ничек салынганлыгы турында бер хикәя», «Иван Грозный тарафыннан Казан каласының мәсхарәсирәсе һәм алынуы» һ.б. Гомумән, бу дәреслектә дә автор балаларда эстетик зәвык тәрбияләү, әхлак сыйфатларын үстерү максатын куя. Бүгенге көндәге УУД (универсаль уку гамәлләре) таләп иткән укучының белемне укытучы ярдәме белән үзе эзлзп табарга тиешлегенә басым ясый, белем алуның системалылык, җиңелдән авырга бару принципларына нигезләнеп төзелүе шарт булуы турында кисәтеп үтә.

«Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» туган тел һәм әдәбият буенча Г. Тукай төзергә планлаштырган китапларның берсе була. Вакытсыз үлем бөек әдипкә хрестоматиянең икенче кисәген тудырырга ирек бирми. Шагыйрь бу кисәкне киңрәк итеп төзергә, анда мәшһүр кешеләрнең тормыш хәлләре һәм рәсемнәре белән беррәттән. халыкның иҗтимагый тормышын һәм тарихын күрсәтү, рәсемнәрне урнаштыруны да планлаштырган була. Г. Тукайның җыентыклары балаларның сөйләм культурасын, фикерләү сәләтләрен үстерүгә шактый ярдәм итте. Алар татар милли культурасын, педагогик фикерен баетуда шулай ук кыйммәтле чараларның берсе булдылар.

Шулай итеп, Г. Тукай төзегән дәреслекләрдә, хрестоматияләрдә, уку китапларында яшь буынга тәрбия бирүнең аерым яклары ассызыклана, әсәр сайлау принциплары тәгаенләнә. Шуларны җыеп, туплап әдинең педагогик карашлары безнең көннәрдә дә үзләренең актуальлекләрен югалмавын, яшь буынны гуманистик рухта тәрбияләүдә нигез булып торуын күрсәтә алабыз.

XXI гасырда язылган дәреслекләрдә дә Тукай табышлары, карашлары дәвам иттерелә. Беренчедән, әдип карашлары әсәр сайлау принципларын эшләгәндә ярдәм итә; икенчедән, универсаль уку гамәлләрен (УУД) булдыруда Тукайның балаларны мөстәкыйль фикерләргә өйрәтү юнәлешенә тукталабыз; өченчедән, Тукай хрестоматиясенә кертелгән Р. Фәхретдинов, К. Насыйри, Г. Исхакый, В. Радлов иҗаты әле дә өйрәнелеп килә; дүртенчедән, һәр сыйныфта әдинең иҗат җимешләрен даими өйрәнеп барабыз.

Күпмилләтле мохиттә 5–9 нчы сыйныфларында укыту өчен сайланган әсәрләр дә Тукай тәкъдим иткән матур әдәбият әсәрләренә аваздаш. Әйтик, Г. Тукай хрестоматиясnә кертелгә Р. Фәхретдиннең «Ана нәсыйхәте», «Сәлим бабай», «Зөһрә ханым», В. Радловның «Төн», «Болытлар», К. Насыйри «Милли мәкалләр», М. Гафуриның «Яшь гомрем»нән, «Электрик фонарена хитаб», Ф. Әмирханның «Мәхәббәтсез үрдәк баласы», «Татар кызы»ннан, Н. Думавиның «Сугыш» әсәрләре XXI гасырда төзелгән дәреслекләрдә дә дәвам иттерелелә. Шул ук авторларның башка әсәрләре укучыларга тәкъдим ителә: Р. Фәхретдиннең «Әсма, Гамәл вә җәза» әсәреннән өзек, В. Радловның «Шаян кеше», К. Насыйриның «Патша белән карт», «Әбүгалисина» әсәреннән өзек,

М. Гафури мәсәлләре, Ф. Әмирханның «Хәят», «Фәтхулла хәзрәт» әсәрләреннән өзек, Н. Думавиның «Беренче кар», «Габдулла» әсәрләреннән өзекләр һ.б. әсәрләр [3].

Шуның белән беррәттән хәзерге чор дәреслекләрендә Г. Тукайның иҗатын өйрәнү дә билгеле бер системага салынган: аның 5 нче сыйныфта «Су анасы», «Исемдә калганнар»; 6 нчы сыйныфта «Туган тел», «Туган авыл», «Шүрәле» экият-поэмасы; 7 нче сыйныфта «Милли моңнар», 8 нче сыйныфта «Пар ат», 9 нчы сыйныфта «Татар кызларына» кебек әсәрләре өйрәнелеп килә. Тукай иҗатын мәктәптә өйрәнүнең әһәмиятен билгеләп, гасыр башында ук Г. Исхакый «Тукай яңа буынның үз-үзен аңлавында, үзеннән-үзе дөньяга караш карауны ясавын – үзенең тирә-юнен тануында беренче роль тотачак шагыйребез, әдибебез, мөхәрриребез», – дип билгеләп үтә [2].

ӘДӘБИЯТ


1. Заһидуллина Д.Ф. Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы: Метод. кулланма. Казан: Мәгариф, 2000. 335 б.

2. Исхакый Г. Тукай мәктәптә // Мәктәп. 1914. № 6. 10 апрель.

3. Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен татар әдәбиятыннан программа (татар телен өйрәнүче укучылар өчен). 5–9 нчы сыйныфлар / Ә.Р. Мотыйгуллина, Р.Г. Ханнанов. Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. 67 б.

4. Тукай Г. Мәктәптә милли әдәбият дәресләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 160 б.


## Г. ТУКАЙ ШИГЪРИЯТЕНДӘ XIX ЙӨЗ АЗАГЫ ТӨРЕК МӘГЪРИФӘТЧЕЛӘРЕНЕҢ ӘДӘБИ ЭШЧӘНЛЕГЕ
### (Нәмык Кәмал һәм Габдулла Җәүдәт иҗатлары мисалында)


***Мөбарәкшина А.Р.***



В статье рассматриваются литературные связи выдающегося татарского поэта Габдуллы Тукая с творчеством писателей турецкой литературы конца XIX века Н. Кемаля и А. Джевдета.

Article is examining literary connections of the known Tatar poet G. Tukay with creative activity of poets-enlighteners of Turkish literary N. Kemal and A. Dcevdet.


Дөнья классикларының гүзәл үрнәкләреннән өлге алып иҗат иткән татар шагыйре Габдулла Тукай шигъриятендә төрле милли әдәбиятлар белән текстара бәйләнешләр еш очрый. Бу бигрәк тә госманлы-төрек әдәбиятына мөнәсәбәттә ачык чагыла. Җаек каласында мәдрәсә шәкерте булган заманда госманлыларның дини-дидактик жанрдагы М. Чәләбинең «Мөхәммәдия» әсәре белән мавыгуы, дуслары белән бергәләп еш кына Мөхәммәдия кичәләре уздырулары шигъриятенең стиленә һәм төзелешенә көчле йогынты ясый. Тукайның башлангыч чор иҗатын «Мөхәммәдия» калыбына таянып, музыкальлеккә корылган төрки гарузының рәмәл һәм һәзәҗ үлчәмнәрендә язылган үгет-нәсыйхәт, дини-дидактик рухтагы әсәрләр хасил итә. Ул гаруздан дәртләнеп илһамлануы турында 1906 елгы шигырендә «Дәм-бә-дәм илһам идәр дәрдең бәңа, гыйльмел гаруз, / Нә кадәр яздымсә, яздым җөмлә илһамыңлә бән» («Ифтиракъ соңында»), – дип яза.

Иске госманлы әдәбиятыннан илһамланып язган вакытта ук шагыйрьгә 1902–1903 елларда Мотыйгыя мәдрәсәсендә яшәп киткән төрек студенты Габделвәли Әмрулла Тәнзимат әдәбияты вәкилләренең французларга ияреп иҗат ителгән төрек романнарын, пьесаларын сөйли. Мотыйгулла хәзрәт дәресләре һәм мәдрәсәгә килгән төрле вакытлы матбугаттагы мәгълүматлар аша да Тукай Тәнзимат дәверенең әдәби-мәдәни һәм иҗтимагый-сәяси хәрәкәте белән танышып бара. Уральскида чыккан «Уралец», «Уральский дневник», «Уральские войсковые ведомости» газеталарында да XX йөз башында госманлы империясендә барган үзгәрешләр, иҗтимагый вакыйгаларны яктырткан хәбәрләр, «Төрекчәдән» дип исемләнгән әдәби әсәрләр еш басыла. Шагыйрь замандашларының сүзләренә караганда, Тукай төрекләрнең «Карагөз», «Төрек йорды», Париж, Каһирә калаларында «яшь төрекләр» чыгарган «Җөмһүрият», «Төрек» матбугатын да укыган.

XIX йөз урталарында Госманлы империясендә барган реформалар нәтиҗәсендә, иске төрек диван әдәбияты кискен үзгәрешләр кичерә, Көнбатыш, аеруча, французларның рухи-әхлакый кыйммәтләре һәм фәлсәфи-эстетик карашларын алга сөргән

мәгърифәтчелек әдәбияты мәйданга чыга. «Төрек сүз сәнгате төрки әдәбиятлар арасында беренчеләрдән булып Көнбатыш Европа әдәби эстетик тәҗрибәсен актив үзләштерә башлый, драматургия, проза кебек яңа әдәби төрләргә, жанрларга байый, әдәбият белеменә һәм тәнкыйтькә караган беренче хезмәтләр языла, вакытлы матбугат җанлана, әдәби телне халыкка аңлаешлы итү өчен көрәш кыза; ватан, милләт, ирек, хатын-кыз азатлыгы, шагыйрьнең гражданлык бурычы кебек әһәмиятле мәсьәләләр күтәрелә», – дип бәяләмә бирә профессор Р. Ганиева төрек Тәнзимат әдәбияты чоры турында [1, б. 530]. Илдәге иҗтимагый-сәяси вәзгыять турыдан туры милли культура, мәдәният, әдәбиятка да тәэсир итә. 1830 нчы еллардан үзгәреш кичергән Яңа төрек әдәбияты башка кардәш әдәбиятларга өлге, үрнәк вазифасын үти. Тукай да, кызыксынып, Ибраһим Шинаси, Нәмык Кәмал, Рәҗаизадә Әкрәм, Әхмәт Хашым, Әбүззыя Тәүфикъ, Тәүфик Фикрәт, Габдулла Җәүдәт кебек яңа төрек әдәбияты әдипләренең әсәрләрен өйрәнә. Аның Уральскида народный домда куелачак Н. Кәмалның «Гыйшык бәласы» спектаклендә Габдессамат хәлфә ролен башкарырга җыенуы һәм ни сәбәпледер спектакльне уйный алмыйча калулары турында мәгълүмат бар [3, 61]. К. Мостакаев истәлекләрендә Тукайның моңсу вакытларында Н. Кәмалның «Ватан мәнзумасы» шигырен көйләп йөрүе [4, 127], В. Бәхтияров хатирәләрендә патриотизм идеясе белән сугарылган бәйсезлеккә омтылучы милли геройлар тирәсендә оештырылган сюжетлы беренче төрек романы Н.Кәмалның «Ватан илә Силистра»ны татарчалаштыру өстендә эш алып барганы билгеләнә [5, б. 79]. Тукайның шулай ук тәнзиматчылар нәшер иткән газета-журналларын даими укып баруы аерым бер шигырьләре аша да ачык күренә. Мисал өчен аның «И төрек...» дип башланган исемсез икеюллы бәйте «Тасвири әфкяр» газетасына мәдхия уку кебек кабул ителә. Төрекләрнең беренче дөньяви газетасы «Тасвири әфкяр» (1862–1925; 1910 елдан «Йени тасвири әфкяр») драматург Ибраһим Шинаси (1826–1871) тарафыннан чыгарыла башлый, өч елдан соң аның эшен Нәмык Кәмал (1840–1888), соңрак Рәҗаэзадә Әкрәм (1846–1913), Әбүззыя Тәүфикъ (1849–1913) кебек мәгърифәтчеләр дәвам итә. «Тасвири әфкяр»дә яктыртылган алдынгы карашлы әдипләрнең Көнбатыш фәлсәфи-эстетик идеаллар йогынтысындагы фикерләре белән Тукай таныш була. Соңрак, Казанга кайткач, татар шагыйре иҗатына иске төрек әдәбиятына алмашка килгән Тәнзимат чорына хас идея-тематик үзенчәлекләр үтеп керә, төрек мәгърифәтчеләренең йогынтысы сизелә башлый. Тукай «Ялт-йолт» журналының 1911 елгы 21 нче (20 апрель) санына «Тасвири әфкяр»дә басылган бер төрекнең сурәтен тәкъдим итә һәм рәсем астына «И төрек, иң әүвәл үк әйтим сиңа: борның кылыч; / Гыйльмилә хикмәт базарында синең урның кылыч», – дигән икеюллык урнаштыра. Рәсемдә «Тасвири әфкяр» мөхәррире» дигән аңлатма да бар. Моның белән Тукай газетаны чыгаручы Ибраһим Шинаси, Нәмык Кәмал, Рәҗаэзадә Әкрәм, Әбүззыя Тәүфикъ эшчәнлекләренә хөрмәтен күрсәтә, төрек милләтенең аң-белемен, мәгърифәтен үстерү өлкәсендә кылган гамәлләренә мәдхия укый.

Тукайның Казан чоры иҗатында Тәнзимат мәгърифәтчеләре, «Сәрвәти фөнүн» (гыйлемнәр байлыгы) журналы тирәсендәге язучылар, солтан Габделхәмид IIнең идарә иткән режимына каршы көрәшкә чыккан «яшь төрекләр» хәрәкәте вәкилләренең әдәби хезмәтләреннән аллюзия, эпиграф, цитата кебек текстара бәйләнешләр еш очрый. Тукай шигърияте башка милли әдәбиятлар яссылыгында өйрәнүчеләр хезмәтендә татар шагыйрен Н. Кәмал белән чагыштырулар бар. Тукай үлеменнән соң Төркиядә чыккан «Ислам дөньясы» (1913, апрель) журналы «Габдулла Тукаев кайгы вә рәнҗүен милләтнең кайгы вә рәнҗүеннән, дәрт вә шатлыгын янә милләтнең дәрт вә шатлыгыннан җыйган бөтен мәгънәсилә милли бер шагыйрьдер. Бу игътибар илә бездә Габдулла Тукаевка охшаган бер шагыйрь Нәмык Кәмалбәктән башка юк кебидер», – дип яза. Бераздан бу язманы «Вакыт» газетасы кабатлап бастыра һәм әлеге шагыйрьләрнең иҗатлары милли яссылыкта кисешүенә игътибар ителә [6]. Чит илләрдә, гомеренең соңгы елларында Төркиядә яшәгән татар галиме Гали Акыш Тукайны «төрекләрнең Нәмык Кәмалы кебек бөек шагыйрь һәм философ» дип атый [7, б. 16]. 90 нчы елларда Тукай иҗаты буенча диссертация язган төрек галиме М. Акбаш Тукайны Н.Кәмал янәшәсенә куеп, икесен дә милли тәрәккыяттә «фикер сугышчысы» (fikir savaşçısı) буларак бәяли [8, б. 24]. Тукай шигърияте Нәмык Кәмал (1840–1888) иҗаты янәшәсендә тикшерсәң, «И каләм!», «Милләтә», «Дустларга бер сүз» кебек милли рухтагы шигырьләре әдәби-эстетик яктан төрек әдибенең аң-белемгә, хөр фикергә, ирекле яшәешкә омтылган «Vatan» («Ватан»), «Vatan yahut Silistra» («Ватан яки Силистрия»), «İntibah», «Cezmi»

(«Җәзми»), «Tahribi Harabat» («Җимерелгән бушлык») әсәрләрен искә төшерә. Һәр ике шагыйрь дә – үз милләтләренең алгарышы, киләчәге өчен сызланучы, милләт кайгысын шәхси кайгы итеп сурәтләүче, яшәү мәгънәсендә милләт язмышын күрүче шагыйрьләр. Н. Кәмал, төрекләрнең якты тормышын күрү бәхетенә ирешә алмавы өчен борчылып: «Үлүрсәм күрмәдән милләттә өмид иттекем фәезы, / Язылсын сәнең каберемдә ватан мәхзүн, бән мәхзүн», – дип төшенкелек белән үлеменә Ватан кайгысының сәбәбен күрсәтсә, татар шагыйре оптимистик рухта «татар бәхете» өчен соңгы сулышка кадәр бирешмәячәген, «җан атачагын» искәртә: «Күңел берлән сөям бәхтен татарның, / Күрергә җанлылык вактын татарның. // Татар бәхте өчен мин җан атармын: / Татар бит мин, үзем дә чын татармын. // Хисапсыз күп минем милләткә вәгъдәм, / Кырылмасмы вавы, валлаһе әгъләм?» («Үз-үземә»).

Яшь төрекләр хәрәкәтенең фикердәше Габдулла Җәүдәт Карлыдаг (1869–1932) иҗаты да татар шагыйренең фикри куәсенә уңышлы тәэсир итә. Солтан Габделхәмид IIнең режимын туктату максатында, 1889 елда яшерен «Иттихад вә тәррәкый» фиркасен төзегән дүрт студентның берсе булган Г. Җәүдәтнең Ватан һәм милләт кайгысын киң яктырткан әсәрләре татар шагыйрен илһамландыра. М. Акбаш Тукай иҗатында Госманлы империясендәге вазгыятьләргә зур өстенлек бирелүен Җәүдәтнең Мисырда чыккан «Kahriyat» («Авырлыклар», 1906) шигырьләр җыентыгын һәм «Kafkasyadaki Müslümanlara Beyanname»сен («Кавказ мөселманнарына декларация», 1906) укуы, андагы мотивларны үзләштерүе белән аңлата, татар шагыйренең солтан Габделхәмид II идарәсе һәм яшь төрекләр хәрәкәтенә багышланган шигырьләре һәм публицистик мәкаләләре Җәүдәт иҗатының тәэсире белән мәйданга килде дип раслый [8, б. 40].

Татар шагыйре еш кына төрекләрнең шигырьләрен тәрҗемә иткән вакытта авторын күрсәтми генә «Төрекчәдән» дип билгели. Бу – төрек чыганакларын ачыклауны катлауландыра, чөнки Тукай тәрҗемә иткән вакытта турыдан-туры түгел, ә ирекле тәрҗемә белән эш итә, төрек мотивларын татар милли җирлегенә күчерә. Шунысы мөһим: төрекчәгә ияреп язылган шигырьләре арасында «Күңел йолдызы»на («Йолдыз». 1909. 29 ноябрь) эпиграф итеп алынган «Тәнәфферләр, тәрәххемнәр, тәхаттырларла дөньядан / Гөзарым зәхемдар, васыл – бер һәҗре мөкәүкәбдер», дигән юлларның Габдулла Җәүдәтнеке булуын шагыйрь искәртеп кенә калмый, түбәндәге сүзләрне дә теркәп куя: «Күптән инде Габдулла Җәүдәтнең шул ике сәтыры күңелемә ошагач, мин дә бер нәрсә язган идем. «Йолдыз»га мөнәсәбәте булганга, шунда дәреҗ иттем». Бу Тукайның Җәүдәт иҗатына хөрмәте зур булуы турында сөйли. Төрек шагыйренең «Бер кыйтга» дип аталган дүртьюллык азәрбайҗан журналы «Фәюзат»ның 1906 елгы 6 нчы санында басыла: «Юлымда бин хакыйкать вирдегем бер шанлы руядан / Калан пишане гомремдә бер набуд кәүкәбдер / Тәнәфферләр, тәрәххемнәр, тәхаттырларла дөньядан / Гөзарым зәхемдар, васыл – бер һәҗре мөкәүкәбдер» [9]. Ягъни «Юлымда мин мең хакыйкать биргән шанлы бер хыялдан / Калган гомеремнең күгендә юкка чыгучы бер йолдыздыр. / Нәфрәтләнүләр, шәфкатьлелекләр һәм искә төшерүләр белән дөньядан / Үтүем яралы, кавышу – йолдызлы бер аерылышудыр». Төрек шагыйре илендә барган иҗтимагый-сәяси вазгыять өчен борчыла, юлына куйган мең төрле максатларына ирешә алмаудан, үзен күктә сүнеп баручы бер йолдыз белән чагыштыра, үлеме белән ризасызлык белдерә, «дөньядан үтүен» – «йолдызлы аерылышу»га тиңли. Лирик герой күңеле нәфрәт-шәфкать хис-кичерешләре каршылыгында бирелә, шигырьдә төшенкелек, өметсезлек сурәтләнә. Г. Җәүдәт лирик героеның җан ачынуына аваздашлыкта, Тукай оптимистик күтәренке рух белән милләт язмышы өчен көрәшүче, киләчәккә өмет белән яшәүче лирик «мин»не иҗат итә. Юлына каршы төшүче мәлгунь, кара көчләр, шәйтаннарның «күзләреннән канлы яшь түгүләрен» тели, күңелендә янган «изге», «якты, һаман нурлы» йолдызын сүндерергә омтылып та, зарар китерә алмаячакларына үзенең көчле ышанычын яңгырата: «Зарар юк, барча кодсиятебез дә айлы, йолдызлы!» Тукайның «күңел йолдызы» символик мәгънәгә ия булып, иң югары төшенчәсендә татар милләтенең якты киләчәге өчен хезмәт иткән Шигърияте гәүдәләнә. Р. Ганиева фикеренчә, Тукай һәм Җәүдәт шигырьләре яшәү фәлсәфәсен яктыртуга юнәлдерелгән: «төрек шагыйре иҗатында яралы, әмма йолдызлы мәхәббәт тарихы шәрык әдәбиятлары өчен хас традицион рухта яктыртылса, Тукай экзистенциаль мәсьәләләрне заманга ярашлы рәвештә иҗтимагый эчтәлек белән баета, Европа-рус шагыйрьләре кебек, замандашлары алдындагы рухи-әхлакый вазифасы турында уйлана, әлегә кара төн булса да, халкының киләчәге кодсиятле, айлы, йолдызлы булачагына өметен өзми» [10, б. 134].

Югарыда мисалга китергән Н.Кәмал һәм Г.Җәүдәт шигырьләрендә төшенкелектә сурәтләнгән лирик геройлар Тукайда «һич ялыкмый алга бар»учы, көчле герой булып милли җирлеккә күчерелә. Төрек Тәнзимат әдәбияты вәкилләре Тукай иҗатының төрек мотивларына корылган әсәрләренә генә түгел, татар милли үзенчәлекләрен яктырткан шигырьләренә дә көчле йогынты ясый.

ӘДӘБИЯТ


1. Ганиева Р. Көнчыгыш традицияләрен үстереп // Татар әдәбияты тарихы. XX гасыр башы татар әдәбияты: 6 томда. Казан: Татар. кит .нәшр., 1986. 3 т. Б. 530.
2. Харрасова Р.Ф. Әдәби бәйләнешләр яктылыгында. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. Б. 24.
3. Кариев Г. Габдулла Тукаевның Уральскидагы тормышы // Тукай турында замандашлары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. Б. 54–61.
4. Мостакаев К. Тукай турында исемдә калганнар // Тукай турында замандашлары. Казан, 1960. Б. 127.
5. Бәхтияров В. Тукай турында кайбер истәлекләр // Тукай турында истәлекләр. Казан, 1986. Б. 79.
6. Газеталардан // Вакыт. 1913. 24 апрель.
7. Akış Ali. Büyük türk tatar şairi Abdullah Tukay'ın halkçılık ve milliyetçilik cepheleri // Azerbaycan. 1965. № 10–12. S. 15–16.
8. Akbaş M. Tatar şair ve yazarı Abdullah Tukay'ın eserlerinden seçmeler ve bunlardaki dil özellikleri. İstanbul, 1996. S. 290.
9. Җәүдәт Г. Бер кыйтга // Фәюзат. 1906. № 6. Б. 73.
10. Ганиева Р. Габдулла Тукай иҗатында төрек мотивлары // Казан утлары. 2014. № 4. Б. 132–138.


## ТУКАЙ ФОЛЬКЛОРИСТИКАДА ҺӘМ ЭПИК ФОЛЬКЛОРДА


***Мөхәммәтҗанова Л.Х.***



Фольклористика начала XX в. связана с именами таких творческих деятелей, как Г. Ибрагимов, Ф. Амирхан, Г. Рахим, Х. Бадиги, Ф. Туйкин и др. В этот же ряд автор статьи относит и Г. Тукая, создавшего отдельный труд в форме раздумий и наблюдений об особенностях и признаках произведений татарского народного творчества. Наблюдения великого поэта автор статьи оценивает как попытку теоретического осмысления и изучения фольклорных жанров на начальном этапе фольклористики. Особое внимание в статье обращается эпическим жанрам фольклора. Определяя место и роль Тукая в фольклористике, автор одновременно проводит обратную связь с фольклором, выявляя эпические тексты, где фигурирует образ самого Тукая.

Folklore beginning of XX century associated with such creative personalities as G. Ibragimov, F. Amirhan, G. Rahim, H. Badigi, F. Tuykin and others. In the same row, and the author considers G. Tukay, create a separate work in the form of thoughts and observations about the features and attributes of the works of the Tatar folk art. Observations of the great poet author estimates as an attempt of theoretical understanding and study of folklore genres of folklore at the initial stage. Special attention is drawn epic genres of folklore. By identifying the role and place of Tukay in folklore, the author simultaneously conducts feedback folklore, revealing epic texts, which featured an image of Tukay.


Бүгенге көндә эпик фольклор атамасы белән билгеле жанр әсәрләренә бөек Тукайның мөнәсәбәтен берничә аспектта карарга мөмкин. Беренчесе – Тукайның халык эпосын, ягъни әкият, риваять, дастан кебек әсәрләрне үз иҗатында чагылдыруы, икенчесе исә – аларга аңлатмасы, ягъни фәнни бәяләмәсе. Әлеге аспектлардан тыш соңрак халыкның эпик фольклорына Тукай образы килеп керү һәм Тукай әсәрләренең халыкчан интерпретацияләнүе – фольклор фәне өчен шулай ук мөһим элемент һәм аны фольклор һәм Тукай темасында өченче аспект итеп билгеләргә мөмкин. Беренче аспектка мөнәсәбәттә татар фольклористикасында да, әдәбият тарихында да тикшеренүләр шактый күп булды. Хезмәтебез югарыда телгә алынган икенче һәм өченче аспектларга, ягъни Тукайның эпик фольклор турындагы фикерләренә аерым игътибарны юнәлтү һәм бүгенге көндә эпик фольклорда Тукай образының чагылышына күзәтү ясау максаты белән башкарылды.

Фольклор фәне XX йөз башында ук халык иҗатының асыл сыйфатларына игътибар юнәлткән, фольклор әсәрләренә күзәтү ясап, әлеге күзәтүләрен аерым хезмәт итеп язып чыккан Тукай исеме белән шактый нык бәйле. Бүгенге көндә эпик фольклор төшенчәсе белән мәгълүм әсәрләрнең татар дөньясында элек-электән бик әһәмиятле урын биләве – мәгълүм факт. Әмма татар халык эпик фольклорын жанрларга бүлү һәм

өйрәнү тарихын әллә ни озын һәм тирән дип билгеләп булмый. Шул ук вакытта бөек Тукай кебек үз милләтенә тирән мәхәббәт белән сугарылган шәхеснең үз чорында ук әлеге төр әсәрләргә игътибар итми калуы да сорау тудырыр иде. Фольклористиканың әле башлангыч чорында ук Тукайның бу мәсьәләгә карата үз карашлары, әлбәттә, булган һәм алар шактый кызыклы.

XX йөз башында татар әдәбияты белемендә фольклор мәгънәсендә халык әдәбияты дигән сүз йөргән. Тукай бу терминга: «Бу нәүгы әдәбият – әле дөньяда язу сәнгате булмаган чактук, авыздан авызга сөйләнеп, бабадан – атага, атадан – балага ишетелеп, буыннан буынга калып килгән әдәбиятдыр» – дигән билгеләмә биргән [1, с. 165]. Шунысына игътибар итәргә кирәк: фольклорга Тукай биргән әлеге билгеләмә, гасырдан артык чор узуга карамастан, «фольклор» сүзенә билгеләмә биргәндә бүгенге көндә дә актуаль һәм бу сүзне аңлату өчен әле дә Тукай билгеләмәсе нигез итеп алына. Моның сәбәбе түбәндәгедән гыйбарәт: Тукай үз билгеләмәсенә фольклорга хас булган төп үзенчәлекләрнең барысын да диярлек сыйдырган. Фольклор әсәрләре дип санала торган ядкарьләрнең асыл сыйфатлары – телдән иҗат ителү һәм телдән-телгә күчеп яшәү; коллектив-күмәк иҗатны тәшкил итүе; вариантлылыгы; синкретик иҗат; традиционлык һәм дәвамлылык-күчүчәнлек; милли-этник характерда булуы. Татар халык иҗатының үзенчәлекләре турында уйланган шәхес буларак, Тукай үзенең 1910 елда Казанның Шәрекъ клубында укыган һәм «Халык әдәбияты» дип аталган лекциясендә татар халык иҗаты иңли торган сыйфатларны барлаган, аларга этрафлы аңлатма бирүгә ирешкән. Соңыннан аның бу чыгышы күләмле мәкалә булып басылып чыккан булуын беләбез [2].

Тукай эшчәнлек иткән XX йөз башы – татарларның үз даирәсендә халык эпосына игътибар бермә-бер арткан чор. Бу чорда илдәге вәзгыять эпик фольклорның тарихи һәм романтик вакыйгаларга багышланган төрләрен – героик һәм романик дастаннарны алгы планга чыгара. «Таһир – Зөһрә», «Ләйлә – Мәҗнүн», «Йосыф китабы», «Сәйфелмөлек», «Бүз егет», «Каһарман Катил», «Түләк китабы» кебек элек кульъязмалардан укылган әсәрләрне Казан, Оренбург, Уфа һ.б. шәһәрләрдәге татар матбагачылары кат-кат китап итеп бастырып чыгара. Аларга халыкның ихтыяҗы зур булуны басылып чыккан китапларның тиражлары зур булу ук раслый. Г. Тукай, бу күренешкә беренчеләрдән булып мөнәсәбәт белдерә һәм болай дип яза: «Бу кем китабы? Татар китабы. Бу – татарның бик искедән бирле укылып килгән әдәби китабы. Минем гөманымча, кечкенә чагында шушы китапны укып, җыламыйча үскән ирләремез вә хатыннарымыз сирәкдер» [1, с. 179].

Бүгенге көндә дастан, әкият, риваять, сөйләк кебек аерым жанрлар буларак карала торган эпик фольклор әсәрләрен теге я бу термин белән атау, аларны фәнни классификацияләү үз чорында, ягъни шушы әсәрләр халык арасында актив таралган этапта булмаган һәм була да алмаган. Әйтик, XX йөз башында әле Г. Тукай да, эпик жанрларга игътибар юнәлткән кайбер башка авторлар да кульъязмасы кулдан кулга күчеп укылган, XIX йөз ахырыннан басылып та чыккан дастаннарыбызны эпик фольклор жанрында караудан ерак тора. Бу – татар филологиясендә кайбер терминнарның әле ныгып урнашмаган булуыннан килә торган күренеш. Гомумән татар фольклористикасында жанр атамаларына ачык, төгәл билгеләмә бирү, жанр чикләрен билгеләү кебек проблемалар бүгенге көндә дә бар. Татар фольклорының үзенең дә илленче еллардан соң гына татар халык иҗаты термины белән аталып йөртелә башлавы мәгълүм [3, с. 6].

Көнчыгыштан кергән сюжетлы эпос-дастаннарга Тукайның мөнәсәбәтенә килсәк, шагыйрь аларны татарга аңлаешлы телдә булмаулары җәһәтеннән телгә ала. «Таһир – Зөһрә», «Йосыф китабы» мисалындагы төрле вариантта таралыш алган дастаннар турында Тукайның: «Алар кем телендә? Алла белә, җен телендә» [1, с. 178] диюендә хаклык бар. Чыннан да, XX йөз башында да әле дастаннарыбызның теле гарәп-фарсы алынмалары белән генә түгел, кыргыз, казакъ сүзләре белән дә нык чуарланган, гади халык өчен аңлауда зур кыенлыклар тудыра торган тел булуы мәгълүм. Бу, әлбәттә, дастан жанрының элитар жанр булуыннан, аның укымышлы катламга нисбәтле таралуы белән бәйле күренеш. Әмма әдәби тел формалашу чорында Тукайның эпос-дастаннарыбыз теленә шундый бәя бирүен аларның тарихилык һәм тел ягыннан беренче кат фәнни бәяләнүе дип кабул итәргә кирәк. Тукайның дастаннар теленә биргән әлеге бәяләмәсе бүгенге көндә дә бик актуаль. Әйтик, дастан текстларын рус теленә тәрҗемә итү мәсьәләсендә тел-стильнең шушы дәрәҗәдә чуарлыгы бик зур катлаулылыклар китереп чыгара.

Димәк, бөек Тукай бу мәсьәләгә XX йөз башында ук игътибар юнәлткән, беренчеләрдән булып бу хакта язып чыккан һәм аның бәяләмәсе проблеманы төгәл күрү һәм көн кадагына кую характерында булуы белән әһәмиятле. XX гасыр башы фольклористикасы татар халык иҗаты турында уйланулар һәм күзәтүләр рәвешендә аерым хезмәтләр язган әдипләр Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан һәм фольклорның төрле жанрына мөнәсәбәтле текстларны туплап бастырып чыгарган Г. Рәхим, Х. Бәдигый, Ф. Туйкин, Г.Рәшиди кебек фольклорчылар эшчәнлегеннән гыйбарәт булса, шушы ук чорда, ягъни татар фольклор фәненең башлангычында шагыйрь Г. Тукайның аерым урын биләгәнлеге бәхәссез.

XX йөз башында халык авыз иҗаты әсәрләрен халыктан җыю, аларны матбугатта бастырып чыгару эше киң колач белән барган. 1907–1913 елларда тугыз дистәгә якын фольклор җыентыгы басылып чыгу шул хакта сөйли [3, с. 20]. Әлеге вәзгыять Тукай иҗатына турыдан-туры тәэсир иткән: әдипнең балаларга атап язылган күп әсәрләренең нигезендә фольклор ятканлыгы – мәгълүм факт.

Соңгырак чорда Тукайны укып үскән, бу шәхеснең үзен күреп белгән кешеләр тарафыннан сөйләнгән тарихи риваятьләрдә, сөйләк, истәлекләрдә шагыйрь образы гәүдәләнү – фольклористикада аерым әһәмият таләп итә торган юнәлеш. Халыкның эпик иҗатында тарихи затларга киң урын бирелә, соңгырак чор фольклорында шундый реаль шәхесләр рәтендә күренекле шагыйрьнең пәйда булуы – заман фольклорына хас күренеш. Әйтик, Мамадыш районы Үсәли (Өчиле) авылында Фазылов Мансур Фазыл улыннан (1939 елгы, 74 яшь, һөнәре белән инженер-механик, хәзер пенсиядә) комплекслы фәнни экспедиция вакытында язып алынган топонимик риваятьтә Тукай образы чагылыш тапкан. «Монда Габделхәй хәзрәт булган бик атаклы. Тумышы белән Түбән Ушмыныкы булган бу хәзрәт. Аның атасы – Түбән Ушмының Мөхәммәдмәгъсүм хәзрәт. Бу Габделхәй хәзрәт Катмыш кызы Мәрьямгә өйләнеп, Үсәли мәдрәсәсендә җәдитчә укыткан. Алар Габдулла Тукайны белгәннәр. Өчилене, Өчиле урманнарын Тукай бик үз иткән. Килә торган булган монда. Мәрьям абыстай үзе сөйли торан ые Тукай белән аралашуларын: “Бик ябык ые инде Тукай” – ди торган ые» – Үсәли авылына багышланган риваятьнең өчтән бер өлешен диярлек Тукай хакындагы мәгълүмат биләү – игътибарга лаек факт.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Тукайның фольклористика өлкәсендәге эшчәнлеге, аның халык иҗатына мөнәсәбәте һәм киресенчә, фольклорның бөек шәхесебезгә мөнәсәбәте – әлеге юнәлешләрнең барысын бер түбә астына җыйнап, махсус фәнни эзләнү алып барганда һәм монографик хезмәт язганда бик кызыклы булыр иде, чөнки Тукайның үзенең халыкка биргән бәясе югары булган кебек, халык вәкилләре дә әлеге шәхескә зур ихтирам белән карыйлар. Заман фольклоры мисалында моны тоемлау кыен түгел.

Г. Тукай шәхесенең фольклорда чагылуына бер үрнәк буларак, түбәндә Фазылов Мансур Фазыл улыннан язып алынган риваятьне тулысынча китерәбез.

**Үсәли (Өчиле) авылы һәм Тукай**
(риваять)

Монда әүвәл өч кеше килеп утырган: Тукай, Биги, Юныс. Өч нәселдән киткән авыл булганга, Өчиле дигәннәр авылның исемен. Элекке документларда да шулай Өчиле дип теркәлгән ул. 1906 елгы документта шулай теркәлгән. Җәя эченә урысча (Три дома) дип тә өстәп язылган булган әле. Аннары гына аны русча Усали дип яза башлап, шуннан татарчасы да Үсәлигә әйләнгән.

Зур базарлы авыл булган Үсәли. Гомер буе кирпеч сукканнар монда. Шул кәсеп белән көн иткәннәр. Казан бае Габдрахман Апанаев килеп чыкан ирегә. Аның монда 300 га чамасы җире булган, 30 еллап файдаланган бай шул җирдән. Хәзер дә Үсәлидә Апанай елгасы, Апанай чишмәсе, Апанай күпере дигән җирләр бар. Әнә Үсәлине чыкканда Түбән Сонга таба бара торган юлда кала Апанай чишмәсе. Шул Апанаев исеме белән бәйле атамалар инде ул.

Монда Габделхәй хәзрәт булган бик атаклы. Тумышы белән Түбән Ушмыныкы булган бу хәзрәт. Аның атасы – Түбән Ушмының Мөхәммәдмәгъсүм хәзрәт. Бу Габделхәй хәзрәт Катмыш кызы Мәрьямгә өйләнеп, Үсәли мәдрәсәсендә җәдитчә укыткан. Алар Габдулла Тукайны белгәннәр. Өчилене Тукай бик үз иткән. Килә торган булган монда. Мәрьям абыстай үзе сөйли торан ые Тукай белән аралашуларын: «Бик ябык ые инде Тукай» – ди торган ые.

ӘДӘБИЯТ

1. Тукай Г. Әсәрләр: 6 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 432 б.
2. Тукай Г. Халык әдәбияты. Казан: «Сабах» көтепханәсе, И.Н. Харитонов матбагасы, 1910. 22 б.
3. Урманче Ф. Татар халык иҗаты. Казан: Мәгариф, 2002. 335 б.

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ҺӘМ АНЫҢ ШӘҖӘРӘСЕ

***Мөхәммәтшина Л.М.***

Данная работа посвящена изучению родословной Г. Тукая. В начале статьи дается краткая характеристика об истории деревни Кошлауч, где родился великий поэт Г. Тукай. К этому времени из разных источников было известно о 120 потомков поэта по отцовской линии и 90 – по материнской. Родственники Тукая по отцу и матери впервые собрались в стенах нашего музея в 2014 году. Общение с потомками поэта дали возможность уточнить некоторые факты, связанные с родословной поэта. Работа будет интересна не только учащимся, но и учителям и всем, кто интересуется своей родословной и историей.

This work is devoted to the study of G. Tukay's genealogy. At the beginning of the article there is a brief description of the history of the village Koshlauch, where the great poet was born. By this time it was known from different sources that the poet had 120 descendants of his father and 90 descendants of his mother. The relatives of G. Tukay's parents met together within the walls of our museum in 2014 for the first time. The communication with the poet's descendants gives a good opportunity to clarify some facts about G. Tukay's genealogy. This work will be useful not only for students, but for teachers and all the people who are interested in their genealogy and history too.

Татарстан Республикасының Арча районында Кушлавыч исемле зур булмаган бер авыл бар. Биредә, Кушлавычта, мулла Мөхәммәтгариф гаиләсендә 1886 елның 26 (14) апрелендә бер ир бала – булачак шагыйрь Габдулла Тукай дөньяга килә.

Элеккеге Казан губернасының Мәңгәр волостена кергән Кушлавыч авылы Казан артындагы башка татар авылларыннан бер ягы белән дә аерылып тормаган. Ул Казаннан 60 чакрым ераклыкта урнашкан. 1885 елгы хисапка алу буенча анда 120 хуҗалык, 794 кеше саналган. Авыл халкы фәкыйрьлектә яшәгән. Төп кәсепләрен умартачылык алып торган. Авылда бер кибет, бер тимерче алачыгы булган. Бердәнбер күренекле урынны мәчет тәшкил иткән. Габдулла Тукай заманында Кушлавыч әнә шундый булган.

1996 елда шагыйрьнең тууына 110 ел тулу уңаеннан Кушлавычта Тукаевлар гаиләсенең музей-йорты ачыла. Музей экспозициясе шагыйрьнең әти-әнисенең йорты белән таныштыра. Шагыйрьнең балачагы һәм аның балалар өчен язылган иҗаты – Габдулла Тукай әсәрләре һәм алар буенча ясалган рәсемнәр экспозициядә мөһим урын алып тора.

Тукаевлар нәселендә җиде буын муллалар булган дип сөйлиләр. Тукай үзе исә «Исемдә калганнар» дигән истәлекләрендә, әтисеннән тыш, бары тик бабасы Мөхәммәтгалим мулланы гына телгә ала.

Музей экспозициясендә Габдулла Тукайның электрон шәҗәрәсе зур урынны алып тора. Шагыйрьнең шәҗәрәсен өйрәнергә теләүчеләр сенсорлы компьютер экраны аша таныша алалар. Аның өч телдә булуы килгән кунаклар өчен бик отышлы да. Бүгенге көндә төрле чыганаклардан шагыйрьнең әтисе ягыннан туганнары 120, әнисе ягыннан 90 туганы билгеле.

Сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның нәсел-нәсәбен, кардәш-ыруларын өйрәнүгә Зәкия Рәсулова бик күп көч куйды. Ул бөек Тукай эзләреннән йөреп күп җирләрдә булды. Арча – Әтнә якларын аркылыга-буйга айкап чыкты. Мәскәү, Ленинград, Казакъстан, Ерак Көнчыгыш якларына барды. Шуларның нәтиҗәсе буларак, ул 1985 елда «Тукай эзләреннән» дип аталган китап чыгарды һәм анда шагыйрьнең әтисе һәм әнисе ягыннан булган нәсел җепләрен бастырып чыгарды. Аннан соң да Зәкия апа Тукай турында мәгълүматлар туплавын дәвам итте, яңа табышларын газета-журналлар аша халкыбызга җиткерә килде.

Әйе, милләтебезгә бик тә игелекле эш эшләп калдырды Зәкия Әхмәт кызы Рәсулова. Ул 1999 елның октябрь аенда үзе туган Казан шәһәрендә 83 яшенә җитеп вафат булды. Авыр туфрагы аңа йомшак мендәр дә, җылы юрган да булсын.

Габдулла Тукайның әтисе Мөхәммәтгариф 1864 елның 30 апрелендә Кышкар мәдрәсәсендә муллалыкка указ алып Кушлавыч авылының икенче мәхәлләсенә мулла

итеп билгеләнгән була. Ул, истәлекләргә караганда, «уртача буйлы, коңгырт чәчле, зәңгәрсу күзле, матур борынлы кеше булган. Үзе телгә-сүзгә бик оста, мәзәкчел булып, кием-салымны да купшы кияргә яраткан. Башына кырпулы каракүл бүрек киеп, аны аз гына кыңгыр салып җибәрә торган булган». Мөхәммәтгарифның хатыны Бибигафифә Сираҗетдин кызы 1885 елның 28 апрелендә (яңа стиль белән 10 майда) бала тапканда кан китеп 42 нче яшендә вафат була. Шуннан соң Мөхәммәтгариф хәзрәт 8 яшьлек кызы Газизә, 13 яшьлек улы Мөхәммәтшәриф белән тол кала. Ул Зиннәтулла Зәйнелбәшир улы Әмиров дигән Өчиле авылы имамының Камилә исемле беренче хатыныннан туган Бибимәмдүдәгә өйләнә. Менә шушы никахтан Габдулла Тукай туа. Әтисе аны метрикә кенәгәсенә «Габдуллаҗан» дип теркәгән. Кызганыч ки, баланың әти-әнисе бик иртә үлеп китә. Әтисе Мөхәммәтгариф 1886 елның 29 августында (яңа стиль белән 10 сентябрьдә), Бибимәмдүдә исә 1890 елның 18(30) гыйнварында бакый дөньяга күчәләр. Беренчесе – 44, икенчесе 26 яшендә була. Әтисеннән Габдулла 4 ай ярымлык, әнисеннән 3 яшь тә 7 айлык булып ятим кала. «Мәмдүдә озынчарак йөзле, сызылып киткән кара кыйгач кашлы, матур кылыч борынлы, төскә-биткә чибәр, матур буй-сынлы, кирәк чакта шигырь белән җавап бирә торган оста телле, үзе тегү-чигүгә маһир бер мөлаем сылу булган».

Әйе, Габдулла Тукай әтисе ягыннан да, әнисе ягыннан да муллалар нәселеннән. Габдуллада зыялы затлар каны аккан.

Әмма хәзергә кадәр «Тукаев» фамилиясенең кемнән килүе, аңа Габдулла Тукай нинди мөнәсәбәттә булуы ачыкланмаган. Шагыйрь нәселендә Тукаев – Тукаева фамилияләрен йөртүче бер кеше дә юк. Барысы да диярлек үзләренә фамилия итеп әтиләренең исемен алганнар. Зәкия апа Рәсулова хезмәтләрендә шагыйрьнең нәселен күрсәткән менә мондый исемлек ярылып ята.

Габдулла Тукай – аның атасы Мөхәммәтгариф, аның атасы Мөхәммәтгалим, аның атасы Шәмсетдин, аның атасы Мортаза, аның атасы Туктулы бабай. Кем белә, бәлкем әнә шул Туктулы бабайны Тукай дип йөргәннәрдер.

Габдулла Тукайның әнисе Бибимәмдүдә ягыннан шәҗәрәдәге төп исемлек: Бибимәмдүдә, аның атасы Зиннәтулла, аның атасы Зәйнелбәшир, аның атасы Әмир (Әмирхан) була. Бу исемлектәге Зиннәтулла хакында замандашларының җылы сүзләре байтак. Ул китап яратучы, язу-сызу белән дә шөгыльләнүче кеше булган. Кайбер шигырьләре дә сакланып калган. Ул Пермь ягыннан, Гайнә иленнән Кышкар мәдрәсәсенә укырга килгән. Соңыннан мөэзин булып Кушлавычта эшләгән. Ә инде Өчиле авылы мөселманнарының соравы буенча аларга имам буларак хезмәт итә. Менә шул хәзрәтнең Камилә исемле беренче хатыны аңа Бибимәмдүдә исемле бердәнбер кызын бүләк итә һәм озак та тормый вафат була.

Бибимәмдүдә булачак бөек шагыйребезнең газиз анасы. Ул да дөньяга фәкать бер генә бала – Габдулланы гына таба.

Шулай да ата-баба ягыннан Габдулла Тукай нәселенең шәҗәрәсе һаман тармаклануын дәвам итә. Әйтик, Тукайның апасы (ата бер, ана башка) Газизә Зәбирова, я булмаса әтисе белән бертуган Газизә Госманова, Фаизә Шәмсетдиноваларнын балалары, оныклары, туруннары хакында озын һәм күп итеп язарга мөмкин булыр иде.

Мәсәлән, Зәкия апа Рәсулова язганча, Газизә Зәбированың алты баласы була. Шуларның берсе яшьтән үк үлә. Олы кызы Гайшә исә студент чакта вафат була. Вәли исемле улы СССР Фәннәр академиясенең тарих фәннәре ассоциациясе гыйльми секретаре. Аның Раҗия исемле кызы – медицина хезмәткәре, Сәлим – су асты көймәсе командиры, Рөстәм – инженер-механик.

Газизә Забированың Гали исемле улы мехчы булган, гражданнар сугышында Чапаев дивизиясе составында сугыша. Аның Суфия, Рәшит, Рәисә, Рафаэль исемле балалары туып үскәннәр.

Газизә апаның Фаизә исемле кызы Ленинградта «Эрмитаж»да фәнни хезмәткәр булып эшләгән. Ә инде кече улы Хөсәен югары белем алып төзүче-инженер һөнәрен үзләштерә. Ул Бөек Ватан сугышында башыннан ахырына кадәр катнаша, күп кенә орден-медальләр белән бүләкләнә. Аның өч кызы була. Әлфия белән Наилә архитектор булалар. Төпчек кызлары Диләрә дә Мәскәү архитекторлар институтын тәмамлый, аннан соң Казан төзүче-инженерлар институтында хезмәт куя. Газизә апаның оныклары Наилә һәм Диләрә апалар 2014 елның 16 декабрендә Кушлавычка кайтып музей белән таныштылар, Мөхәммәтгариф каберенә зиярат кылдылар. Нык истә калырлык очрашу

булды бу. Очрашуда шулай ук Г. Тукайның әтисе ягыннан туганнарыннан Лилия Фатыхова да бар иде. Ул үзе төзегән шәҗәрәсен дә алып килгән иде. Лилия Фатыхова Арча шәһәренең данлыклы 2 нче урта мәктәбендә инде менә егерме тугыз ел татар теле һәм әдәбиятын укыта. Сыйныф җитәкчесе буларак өч чыгарылышны олы тормыш юлына озаткан. Хәзер элеккеге укучыларының балалары да Лилия ханымда белем ала.

1985 елда «Тукай эзләреннән» китабын бастырган галимә Зәкия Рәсүлева үзенең хезмәтен язганда шагыйрьнең туганнарын эзләп, Арча-Әтнә якларын, Советлар Берлегенең төрле төбәкләрен аркылыга-буйга айкап чыкканда, Лилия Фатыхованың әбисе – Сатыйга апа Нуриева янына да Арчага еш кайткан.

Тукайның әтисе ягыннан шәҗәрәсенә күз салсаң, әтисе Мөхәммәтгарифнең (1842/43–1886) Шакирҗан, Газизә, Зариф һәм Фәизә исемле бертуганнары булган. Төпчекләре Фәизә өч бала тәрбияләп үстергән – Мөхәммәтһади, Гөлчәһрә һәм Габдрахман (1886-1957). Менә шул Габдулла Тукай белән бер елда туган Габдрахманның кызы – Сатыйга – Лилия ханымның әнисе ягыннан әбисе.

– Әбием 1984 елда 77 яшендә вафат булды, – дип искә ала Лилия Фатыхова. – Ул гаиләдә сигез баланың иң олысы булган. Буйга җиткәч, язмыш кайсын кайда сипкән, Мәскәү, Казахстан якларына киткәннәре дә, Арчада, Казанда төпләнеп калганнары да бар. Бүген аның бертуганнары арасыннан Арчада яшәүче туксан яшен узган Дания апа гына исән-сау. Дания апа – 2009 елда «Тукай фонды»н оештырып җибәргән күренекле журналист Риман Гыйлемхановның әнисе.

Тукайның туганнары шул кадәр күп булып та, нишләп ул ятимлектә үскән дигән сорауны шагыйрьнең тормыш юлын өйрәнүчеләр еш яңгырата.

– Бу хакта әбиемнең хатирәләре бар иде. Аңа әтисе Габдрахман болай дип аңлаткан: «Гаиләдә без ун җан иясе идек. Ачлык еллары тормышыбызны тагын да авырайтты. Шуннан Фәизә әни Габдулланы үзебезгә ала алмагач, Уральскидагы бай сәүдәгәргә кияүгә чыккан үзенең бертуган апасы Газизә Госмановага хат яза. Шулай итеп, Габдулла Кырлайдан Җаекка эләгә», – дип сөйли Лилия ханым.

Сатыйга апа да, аның хәләл җефете Һашим абый да дин әһелләре нәселеннән. Сатыйга әби тормышлары турында түбәндәгеләрне әйтеп калдырган: «Фәизә әби Кушлавыч авылыннан Арчаның Масра авылындагы Җәләлетдин муллага кияүгә чыккан, шунда гомер иткән. Аларның өч балалары була. Әтием Габдрахман белән аның кыз туганы Гөлчәһрә шактый озын гомер яшәгәннәр. Әнием Бибифатыйма белән әтием Габдрахманның уналты балалары туган, сигезебез генә исән-сау үскән. Әти Кышкарда муллалыкка укыган кеше. Җәләлетдин бабай үзе мулла булгач, Фәизә улын да мулла итәсе килгән. Әти безнең комсыз, оятсыз мулла булмады. Әгәр дә ачлы-туклы яшәгән ярлы кеше сәдака китерсә, «дога кылып алдым, хәзер үзенә бирәм бу өлешне», дип, ярлыга сәдакасын тоттырып җибәрер иде. Совет власте елларында муллалар эзәрлекләнү сәбәпле, бу шаукым безнең гаиләгә дә кагылды. Иң элек бабамның йортын тартып алып ясле ясаганнар. Аннан соң бабамны «органнар» алып китә. Шөкер, берничә көннән кире кайтаралар. Бабамны Себергә җибәрмәүләренә төп сәбәп – аның укымышлы, алдынгы карашлы булуында дип беләм».

– Әбием Сатыйга күп сөйләшергә яратмый иде, – ди Лилия ханым. – Ләкин ул һәрвакытта үзенең чисталыгы, пөхтәлеге, сабырлыгы, тыйнаклыгы белән аерылып торды. Мин әби белән бабайны бик яраттым. Һәрвакыт аларга кунакка бара идем, университетта укыган чорда да атна саен яннарына кайтып йөрдем. Мин үзем Арча районының Яңа Кишет авылында үстем, әтием – тарих укытучысы, мәктәп директоры иде, әнием рус теле укытты. Әмма бөтен балачагым Арчада әбиләрдә узды. Әби Тукайның әсәрләрен миңа гарәп язулы китаплардан укый иде. Гомеренең соңгы елларында күзләре начарлангач, инде мин үзем аңарга ул китапларны укыдым, чөнки университетта гарәп теле дә өйрәндек. Кызганычка, әби мәрхүм булгач, бөтен китапларны, иске документларны әбинең Чиләбе өлкәсендә яшәгән улы – Әнзәр абый җыеп алып китте. Мин, ул чакта студент кыз, аларны сорап калырга кыенсындым.

Лилия Фатыхова Тукайга барып тоташкан шәҗәрәсен 1980 елда Казан дәүләт университетына кергәч төзергә алына. Бу хакта ул болай сөйли:

– Казанда укыганда әбиемнең бертуганы Наилә апа гаиләсендә яшәдем. Аның ире Рифкать абый Вәлиуллин: «Кызым, нәсел-нәсәпне белергә кирәк», – дип миңа киңәшләрен биреп, беренче мәгълүматларны тупларга ярдәм итте. Шулай акрынлап, Тукайның ул вакытка кадәр билгеле нәсел агачына «яңа яфраклар» өстәлә башлады.

Ләкин әле аны һаман да тулы дип әйтеп булмый, чөнки чит төбәкләргә таралган, араларыбыз өзелгән туганнар бар. Әлеге шәҗәрә рәсемен Тукайның дүртенче буын туганы Риман абый Гыйлемхановка да бүләк иткәч: «Миндә әле мондый мәгълүматлы шәҗәрә юк иде», – диде.

Риман Гыйлемханов үз чиратында Тукайның бишенче буын туганы Лилия ханым төзегән шәҗәрәне куанып кабул итүен әйтә. «Тукайның туганнары бихисап. Пермь крае Барда районында имам-хатыйб Рәфыйк хәзрәт Акманаев исемле гаҗәеп кеше белән танышырга насыйп булды. Без аның белән Тукайның әнисе яклап туганнар булып чыктык. Ул Тукайның әнисе ягыннан бабасы Зиннәтулла Әмировның шәҗәрәсен төзегән. Тамырларыбызга игътибар артуын, буыннар бәйләнешен күрү бик күңелле хәл», – дигән фикерен җиткерә ул.

Университетны тәмамлагач, Лилия ханымга Казанның Тукай әдәби музее директоры Госман Хәбибуллин музейда фәнни хезмәткәр вазифасын да тәкъдим иткән икән. Тик ул чакта университетта укыткан, язучы Мөхәммәт Мәһдиев: «Сеңлем, кайт син туган ягыңа», – дип, аңа Арчага эшкә кайтырга киңәш биргән.

– Бүген зур галимнәр булып җитешкән Ким Миңнуллин, Таһир Гыйләҗев, Рифә Рахманнар заманында укыдым мин. Казанда эшләп калган булсам, мин дә әллә кемнәр булган булыр идем, – дип шаяртып сөйли Лилия Фатыхова. – Шулай да үкенмим, иремә Казанда эш тәкъдим итеп чакырганнар иде, без китәргә риза булмадык. Сатыйга әбинең йорт нигезенә хәзер бертуган сеңелем Миләүшә үз гаиләсе белән төпләнде. Ул да КДУны тәмамлады, Арчаның Габдулла Тукай исемен йөрткән педагогика көллиятендә укыта. Инде икебез дә оныклар тәрбиялибез.

Лаеклы ялга чыккач, Лилия ханым Тукайның әнисе ягыннан шәҗәрәсен дә тулыландыру турында хыяллана. «Мөхәммәт Мәһдиев безгә туган тиешле кеше, ә аның нәселе үз чиратында Тукайның әнисе ягыннан нәсел агачына барып тоташа.

Г. Тукайның әнисе Бибимәмдүдәнең сеңлесе Бибисаҗидә Арча районы Өчиле авылында 1877 елда туа, 1893 елның 25 декабрендә аны Казанда мәдрәсә тәмамлаган 24 яшьлек Әхмәтсафага кияүгә бирәләр. Туйларын Арча районы Өчиле авылында уздыралар һәм апасының туена Кырлайдан Габдулла Тукайны да китертәләр. Җизнәсе белән апасында берничә көн кунакта да була. Туйдан соң Әхмәтсафаны Каенсар авылына мулла итеп куялар. Алар гомер буе Каенсар авылында яшиләр һәм җиде бала тәрбияләп үстерәләр.

Бибисаҗидәнең беренче ир малае туа, аңа Габделваһаб дип исем кушалар. Ул яшьтән үк Герман сугышына алынып, үз башыннан Гражданнар сугышын да, Бөек Ватан сугышын да кичереп, сигез бала тәрбияләп үстерә һәм 1957 елда бакыйлыкка күчә.

Икенче кызы Мәсрүрә, Арча районы Орнашбаш авылында яши. Мәсрүрә Зәбированың дүрт баласы туа һәм бүгенге көндә дәвамчылары Арчада һәм Казанда яшиләр.

Бибисаҗидәнең өченче кызы (1903–1975) Өммеһания. Арча районы Түбән Көектә укытучы булып эшләгәндә Бөек Ватан сугышы башлана һәм аны Яшел Үзән районы Бәчек авылына укытучы итеп күчерәләр. Озак еллар анда мәктәп директоры хезмәтен башкара, авыл халкының абруен казана. Бу вакытларда дүртенче малае Солтанәхмәтнең сугышта үлү хәбәре әнисе Бибисаҗидәнең хәлен тагын да авырайта. Өммеһания сеңлесе Әкълимә белән әнисен үз куенына сыйдыра. Авыру әнисен тәрбияләп, аларны матди яктан яшәтү мәшәкатьләре Өммеһания җилкәсенә төшә. 1956 елда Бибисаҗидә, каты авырудан соң вафат булып, җиргә иңдерелә. Шушы авыр газапларны кичрү Өммеһаниянең дә сәламәтлеген какшата. Сеңлесе Әкълимә бик күп көчләр куеп тәрбия кылса да, 1975 елда Өммеһания гүр иясе була.

Дүртенче баласы Солтанәхмәт Каенсар авылында укытучы булып эшләгәндә Бөек Ватан сугышына китә һәм әйләнеп кайта алмый. Каберенең Могилёвта булуын раслаган документлар барлыгы билгеле.

Бишенче кызы – Фатыймабикә Казан заводларының берсендә электромонтёр булып эшләгән. Мәсгуть исемле улы булган. Ул Владивостокта боцман булып хезмәт иткән.

Алтынчы кызы Нурдидә, Казан шәһәре фабрикаларының берсендә тегүче булып эшләп, пенсиягә чыкканнан соң, картлар йортында яши һәм авырып үлә.

Бибисаҗидәнең җиденче кызы Әкълимә әнисен дә, апасын да Бәчек авылында җирләгәннән соң, кулында бер һөнәре һәм яшәү өчен бер тиен килере булмаган килеш,

олы абыйсының улына, дүрт кешелек гаилә өстенә бала караучы булып килеп сыена. Соңыннан аңа Казанда фатир бирәләр.

Чынлап та, Бибисаҗидә киләчәктә дөньякүләм бөек шагыйрь булып танылачак Тукаебызның рухын саклап кала. Аның таянычы, терәге була. Иң мохтаҗ чагында хатын-кыз тәрбиясе, ана назы бүләк итә һәм бу аналарча җылылык, Тукай исән вакытта гомер буена сузыла да.

Тукай – халык шагыйре, татар халкының мәшһүр улы. Ул үзенең иҗаты белән бөтен төрки дөньяга хезмәт итә. Без Тукайны бишектән үк ишетеп беләбез, аның шигырьләре, җырлары, әкиятләре белән әсирләнеп үсәбез, һәр җанда шагыйрьгә булган җылылык арта бара.

Шагыйрь һәм Кеше буларак, Тукай – мәңге кабатланмас, мәңге уникаль шәхес. Күкләрне яктыртып, һава сафландырып узган яшендәй гомере белән ул халкыбызның әдәби, мәдәни, рухи күгендә җуелмас эз калдырды.

ӘДӘБИЯТ

1. Рәсүлева З.Ә. Тукай эзләреннән. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 141 б.
2. Гарифуллин Дамир. Шәҗәрәләр: 1 китап. Яр Чаллы, 2002. 160 б.
3. Гаделшина Л. Туганлык җепләре Тукайга тоташа // Атна вакыйгалары. 2014. № 16. 25–29 апрель.

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ШИГЫРЬЛӘРЕНДӘ СИНТАКСИК ФИГУРАЛАР

***Мөхиярова Р.Х.***

В статье анализируются такие стилистические фигуры в поэзии Г. Тукая, как инверсия, риторический вопрос, риторическое обращение, разные виды повторения (удвоение, эпифора, эпанафора), параллелизм. Умелое использование таких фигур способствовало выделению наиболее важных в смысловом отношении слов и выражений, содействовало повышению силы эмоционального воздействия стихотворений. Поэт своим творчеством показал и неисчерпаемые возможности родного языка.

Such stylistic figures in the G. Tukay’s poetry as an inversion, a rhetorical question, a rhetorical addressing, different types of repetition (reduplication, epiphore, epanaphora), parallelism are analyzed in this article. Skillful use of such figures made for the distinguishing of more important words and word combinations in their semantic relation, promoted to increasing of the emotional power of the poem. By means of his creation the poet showed the inexhaustible capacity of the native language.

Матур әдәбият телебезнең барлык мөмкинлекләрен дә файдалана. Язучылар төзек җөмләләр белән язарга тырышалар, әмма фикерне укучыга сурәтле, кызыклырак, мавыктыргыч итеп җиткерү өчен, җөмлә төзелешенә төрледән-төрле үзгәрешләр кертәләр. Җөмләнең шундый үзенчәлекле корылышын поэтик синтаксис дип атыйлар. Галимнәр поэтик синтаксиска инверсия, риторик сорау, риторик эндәшләрне, кабатлауның төрле төрләрен (анафора, эпифора, ялгау, рефрен, рәдиф), градация, янәшәлекләр, антитеза, эллипсларны кертәләр. Аларны башкача синтаксик фигуралар дип тә йөртәләр.

Югарыда саналган синтаксик фигураларның күпчелеге борынгы әдәбияттан ук килә. Күренекле шагыйребез Г. Тукай да, җөмләләр төзегәндә, төрле кызыклы фигуралар кулланган. Билгеле бер мәгънәне, тойгыны көчлерәк итеп бирү максаты белән, Г. Тукай аеруча инверсия алымын еш файдалана. Гадәттә төп максат эш яки хәлнең үзе турында хәбәр итү булса, хәбәр иягә кадәр куела:

Шулай **чорнап тора** безне **җәһаләт...**
(«Рәсемгә ишарә»)

Кузгалтмакчы булсаң, халык күңелләрен,
Тибрәтмәкче булсаң иң нечкә кылларын,
Көйләү тиеш, әлбәт, ачы хәсрәт көен,
**Кирәк түгел** мәгънәсе юк **көлке, уен.**
(Сәрләүхәсез»)

Аергычның аерылмыштан соң килүе игътибарны аергычның үзенә юнәлтә, андый аергычлар интонация, пауза белән дә аерымланып киләләр. Г. Тукайда да андый мисаллар күп:

Шул вакытта әллә кайдан чыга Инсан,
**Кулларында балта берлән чүкеч тоткан.**
(«Япон хикәясе»)

Матур әдәбият стилендә хисне көчәйтү, фикерне төгәлрәк дәлилләү һәм раслау өчен риторик сораулардан актив файдаланалар. Бу алымны Тукай аеруча яратып куллана:

Кем белер кадереңне, җаным, дәртле күңел булмаса?
(«Булмаса)
Ни кыйлырсың, хаҗи абзам, тотса мәскәүләр якаң?
(«Тотса мәскәүләр якаң)
И мөкаддәс моңлы сазым! Уйнадың син ник бик аз?
(«Өзелгән өмид»)

Риторик эндәшләргә дә Г. Тукай еш мөрәҗәгать итә:

Кит әле син, **аксакал кыш!** Күр, әнә таудан туры
Тәгәридер ул матур кыз – язның алтын фәйтуны.
(«Кышка бер сүз»)

Риторик эндәш куллануның классик мисалын исә мәшһүр «Туган тел» шигырендә табабыз:

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.

Шагыйрьнең башка шигырьләреннән түбәндәге риторик эндәш объектларын санап китәргә мөмкин: и бәрәңге, и күңел, исәр җил, китап, и матур, и фикрем кояшы, и сабыйлар, и гүзәл кыз, и карендәш, и җегет, эшчеләр, и Казан шәһәре, и үлем, тәңрем, и тәгалә, йа илаһым, падишаһым, Ходам, җаным һ.б.

Күренүенчә, Г. Тукай иҗатында гап-гади үсемлекләрдән башлап, Аллаһы Тәгаләгә кадәр эндәшү бар. Шагыйрь эндәш сүзләр янында «и» ымлыгын еш куллана. Бу ымлык күбрәк якын күрүне белдерсә, кайчагында кызгану, шелтәләү төсмере дә ала, димәк, Г. Тукай үзе эндәшкән җанлы һәм җансыз предметларны якын күрә, үз итә.

Шигъри әсәрләренең тәэсир көчен арттыруда әһәмиятле чараларның берсе – кабатлаулар. Г. Тукай төрле үзенчәлекле кабатлауларны шигырьләрендә оста кулланган. Шагыйрь аеруча фигыль-хәбәрләрне кабатларга ярата. Кайбер шигырьләрендә һәр строфа азагында фигыльләр кабатланып килә һәм аларга төп мәгънә салына:

Сихерләгәнеңне шатландыр: бер генә моннан үт;
Синең аяк туфрагында **тәгәрием, тәгәрием,**
Үлгәнче котылмам, шул чаклы синнән исергәнмен;
Күз һәм кашыңнан синең **әйланыем, әйланыем.**
(«Гыйшыкмы соң бу!..»)

Бик еш кына кабатлана торган фигыльләр һәр строфаның икенче юлында да килә. Мондый кабатлауны гадәттә эпифора дип атыйлар:

Җиһанның эссесен, салкын, бозын **күрдем,** карын **күрдем**;
Ниләр күрсә бөтен үксез – барын **күрдем,** барын **күрдем.**
(Монафикъка»)

Сүзнең грамматик формасын үзгәртеп кабатлау алымын да Г. Тукай оста файдалана:

Гүзәлсең син, **матурсың** син, **матурсың,**
**Матурларның матурыннан матурсың.**
(«Хур кызына»)

«Тавыш хакында» дигән шигырендә шагыйрь бер тамырдан төрле фигыль төркемчәләре ясаган:

Эшче туган! **Тартыш** кирәк, кирәк **тартыш,**
**Тартышмаган** эшчеләргә бик батар теш;
Изге эшләр **тартыш,** зинһар**, тартыш, тартыш!**

Монда тартыш беренче юлда – исем фигыль, ә соңгы юлда – боерык фигыль,тартышмаган – сыйфат фигыль. Тагын бер үзенчәлек: беренче юлдагы ике җөмлә ия белән

хәбәр урыннарын алыштырып кабатланган һәм бу тартыш сүзенең мәгънә егәрен тагын да ныграк көчәйткән.

Башка сүз төркемнәрен кабатлап та, Г. Тукай сүз уйнатуга охшаш, бик тәэсирле юллар төзи:

Йа ходай! Нигә төрле-төрле кылдың кешеләрне?
Ни сәбәптән соң мин бөтен **түбәннәрдән** дә **түбән?**
Киләчәгем, бәхетем минем һәр **каралардан кара!**
Миндәге бу **каралык** та шуннан йокканмы әллә?
(«Сораулар»)

Сорау алмашлыкларын кабатлау шагыйрьгә гаҗәпләнү- соклану хисен үтә дә көчле итеп белдерергә ярдәм итә:

И матур! Иренмәче, еш-еш кына көзгегә бак! –
Күр йөзеңне: **нинди** нурлы, **нинди** алсу**, нинди** ак!
(«...га»)

Зат алмашлыкларының урыннарын алыштырып кабатлау да шигырьләрне үзенчәлекле һәм тәэсирле итә:

Уйларыгызны языгыз, уегыз яктыртучы булсын;
**Сезнең уйлар** – **безнең уй, безнең уйлар** – **сезнең уй.**
(«Фикер» газетасына гына махсус түгел»)

Кайвакытта Г. Тукай бер үк юлда икешәр сүзтезмәне кабатлый. Бу әсәрнең тәэсир көчен аеруча арттыра:

**Кызганыч хәл, кызганыч** хәл, **бик кыен** бит, **бик кыен,**
Бирсәңезче бер тиен тик, тәңкә түгел бит, «тиен».
(«Теләнче»)

Бер юлның ахырында, икенче юлның башында бер үк сүз яки сүзтезмәләрне кабатлауны, ягъни эпифора алымын да Г. Тукай еш файдаланган:

Йокла,угълым, **йом күзең,**
**Йом, йом күзең,** Йолдызым.
(«Авыл хатынының бала тибрәткәндә өмидләре»)

Чиновниклар безнең канны бик күп **имде,**
**Имәлмәсләр, җитәр инде, җитәр инде!**
(«Дусларга бер сүз»)

Һәр строфаның башында һәм азагында бер үк сүз һәм сүзтезмәләрне кабатлау да Г. Тукай иҗатында хас күренеш:

**Ни эшлим,** асылым – нигезем кайсы-хәсрәткә корылган;
Яратылыштан ук кайгы-хәсрәткә батканмын, **ни эшлим?**
**Ни эшлим**, минем тирә-ягымны кайгы гаскәре чолгаган**;**
Гүя аждаһа авызы алдында торам**, ни эшлим?**
(«Дәрдемәнд түгелме мин?»)

Г. Тукай еш кына рәдиф белән эпифораны бергә үреп биргән. Эпифора һәм рәдиф сүз итеп шагыйрь күбрәк фигыльләрдән файдаланган:

Ай кеше! Тыштан үзендә изге сыйфат **күрсәтә,**
Яхшыга – рәгъбәт, ялган эшләргә нәфрәт **күрсәтә.**
(«Күрсәтә»)

Мисаллардан күренгәнчә, Г. Тукай синтаксик фигураларның күп төрләрен кулланган. Алар шигырьләренең яңгырашын үзенчәлекле итә, эчтәлекне ачуда төп роль уйнаучы сүз һәм сүзтезмәләрне ассызыклый. Кабатлау алымын кулланганда, Г. Тукай фигыльләр белән аеруча оста эш итә, гап-гади фигыльдән дә әһәмиятле синтаксик фигура ясап, телебезнең сыгылмалыгын, иксез-чиксез мөмкинлекләре барлыгын күрсәтә.

ӘДӘБИЯТ

1. Тукай Г.М. Сайланма әсәрләр: шигырьләр, поэмалар һәм чәчмә әсәрләр. Икенче басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. 479 б.

# ЦВЕТОВАЯ ГАММА Г. ТУКАЯ И СПОСОБЫ ЕЕ ПЕРЕВОДА НА РУССКИЙ ЯЗЫК

***Мугтасимова Г.Р.***

Статья посвящена рассмотрению актуальных вопросов перевода цветонаименований на примере поэзии Габдуллы Тукая. В статье проанализированы разновидности лексико-семантической трансформации цветообозначений в переводах стихов Г. Тукая на русский язык.

This article is devoted to topical issues of translation of cetoniinae like poetry Gabdulla Tukay. The article analyzes the types of lexico-semantic transformations of the color-indication in the translations of poems by G. Tukay in Russian language.

Цветообозначения наиболее употребляемы в речи. Кроме того, цвет имеет огромное значение в жизни человека. Зачастую от него напрямую зависит настроение, эмоции и даже физическое самочувствие людей.

Изучая образный мир поэта, анализируя его в связи с внетекстовыми структурами, мы через цвет приближаемся к пониманию мыслей, идей и образа автора. То же самое можно сказать и о поэтике. Как раз в поэтике отражается духовная и творческая индивидуальность автора. Все это нашло отражение и в поэзии Г. Тукая, выдающегося татарского народного поэта.

Актуальность исследования обусловлена целым рядом причин. Во-первых, это непрекращающийся интерес к творчеству Г. Тукая. Во-вторых, не ослабевает интерес к проблемам перевода его поэзии.

В статье рассматриваются разновидности лексико-семантической трансформации цветообозначений в русских переводах поэзии Г. Тукая. Оригинальные тексты поэта сопоставляются с переводами Р. Морана, А. Ахматовой, В. Тушновой, В. Думаевой-Валиевой и других.

Исследование осуществлялось с опорой на труды Я.И. Рецкера, описавшего основные виды лексических трансформаций [1], так же теоретической базой исследования стали труды Р.А. Юсупова [4].

Колоративная лексика играет столь важную роль в формировании семантической структуры стихов и в реализации эстетического замысла автора, особое внимание уделяется её адекватной передаче в тексте перевода.

Поля основных цветов в татарском и русском языках совпадают. Несмотря на этот факт, существуют существенные различия в восприятии цветового пространства у носителей этих языков. При переводе художественного текста, как бы идеален и близок оригиналу он не был, неизбежны отличия от текста оригинала: замены, добавления, опущения, вызванные такими факторами, как личность переводчика и своеобразие его восприятия подлинника, разносистемность языков, различия социокультурной среды.

Приведем несколько примеров, иллюстрирующих переводческие совпадения: *Бар, җаным, инде **яшел** урманга оч,Тиз ятим кошчыкларың берлән кавыш!* («Фатыйма һәм Сандугач») – *Будь свободен и в **зеленый** лес лети, Соловьят своих на воле ты расти!* («Фатима и Соловей», пер. С. Обрадовича); *Галибанә яктырып, әкрен генә **ал** таң ата* («Җәйге таң хатирәсе») – *Одолев смятенье ночи, всходит **алая** заря* («Рассвет», пер. В. Думаевой-Валиевой); *Абый белән бергәләшеп, **кара** җирне Сука белән ертып-ертып йөргәннәрем* («Туган авыл») – *Я помню, как, бывало, по **черной** борозде Шагал со старшим братом я за сохою вслед.* («Родная деревня», пер. В. Тушнова); *Булса – бир, булмас исә – җайлап сөйлә булмаслыгын, – Сизми калма **ак** сакаллы карт Хозыр Ильяслыгын!* («Нәсыйхәт») – *Есть что подать – подай, не можешь – скажи, на слово не скупясь. Тот с бородою **белой** старец, быть может, сам Хозыр-Ильяс* («Назидание», пер. В. Думаевой-Валиевой). В выполненном Р. Мораном переводе этого же стиха цветообозначение подвергается трансформации: *Имеешь – дай, а нет – ответствуй спокойно, не хуля, Как знать, быть может, этот нищий старик – пророк Илья?*

Материал исследования показал, что в большинстве случаевцветообозначения имеют эквивалентные совпадения в татарском и русском языках. На наш взгляд, такое явление можно объяснить тем, чтов двух языках поля основных цветообозначений совпадают; несмотря напринадлежность к разным культурам, носители татарского и русскогоязыков имеют много общего в восприятии цветового пространства.

При переводе стихов Г. Тукая был использован один из видовпереводческой трансформации – опущение. Чаше всего опущениюподвергаются слова, являющиеся семантически избыточными, то естьвыражающими значения, которые могут быть извлечены из текста. При этомне происходит потеря основной информации: *Ул авылның, һич онытмыйм, һәр ягы урман иде;Ул болын,* ***яшел*** *үләннәр, хәтфәдән юрган иде.* («Шүрәле») – *Эта сторона лесная вечно в памяти жива. Бархатистым одеялом расстилается трава.* («Шурале», пер. С. Липкин); *Урманында* ***кып-кызыл*** *кура җиләк тә җир җиләк*(«Шүрәле») – *От малины, земляники все в лесу пестрым-пестро* («Шурале», пер. С. Липкин); ***Ак, кызыл, ал, сап-сары, зәңгәр, яшелдән*** *чәчкәләр; Һәр тарафка тәмле исләр чәчкәли бу чәчкәләр* («Шүрәле») – *Сколько* ***синих, желтых, красных*** *там цветов переплелось, И от них благоуханье в сладком воздухе лилось* («Шурале», пер. С. Липкин); *Җәй көнен яздым бераз; языйм әле кыш, көзләрен,****Алсу*** *йөзле,* ***кара*** *кашлы,* ***кара*** *күзле кызларын* («Шүрәле») – *Летний лес изобразил я, – не воспел еще мой стих Нашу осень, нашу зиму, и красавиц молодых* («Шурале», пер. С. Липкин); *Моңланып, хәсрәтләнеп, ялкау гына* ***ак*** *ай бата* («Җәйге таң хатирәсе») – *Над больной луной, что никнет, скорбно, жалобно смотря* («Рассвет», пер. В. Думаевой-Валиевой).

Также мы встречаем конверсию – переход из одной части речи в другую.При переводе цветообозначений довольно часто происходит замена колоратива, выраженного прилагательным, на цветообозначение, выраженное глаголом: *Пәрдәдән чыкты, ачылды* ***ямь-яшел*** *кыр һәм япан* («Җәйге таң хатирәсе») – *Покрывало ночи сбросив,* ***зеленеют*** *лес и дол* («Рассвет», пер. В. Думаевой-Валиевой). Чтобы сохранить структуру предложения переводчики прибегают к конверсии.

Следующий вид трансформации, использованное при переводе стихов Г. Тукая это – добавление: *И Куян, куркак Куян, йомшак Куян, Моңланасың, нинди хәсрәт, кайгыдан?*(«Бичара куян») – *Заяц* ***серый,*** *Заяц мягкий, что с тобой? Отчего ты, Заяц, ходишь сам не свой*? («Бедняга заяц», пер. Гл. Семенова); *Шунда аңгар бик матурлап елмаеп көлде Кояш* («Эш беткәч уйнарга ярый») –*Тут солнце* ***красное*** *ему с небес улыбку шлет* («Кончил работу – играй», пер. Р. Морана)Введение дополнительных слов обусловливается рядом причин. В этом случае добавление обусловлено чисто стилистическими соображениями.

При переводе текста стихотворений Г. Тукая возникает целый ряд трудностей. Проведенное исследование показало, что, несмотря на значительные трудности, возникающие при переводе стихотворений Г. Тукая на русский язык, переводы его текстов отвечают основным требованиям адекватности перевода: сохранение смысла, стиля и национального своеобразия.

Самым частым способом передачи цветообозначений в стихах является эквивалентный перевод. Переводчики заменяют оригинальное цветообозначение эквивалентным словом в языке перевода. Среди переводческих трансформаций используются конверция, опущение и добавление. Наибольший интерес с точки зрения переводоведения представляют переводческие трансформации и несоответствия.

ЛИТЕРАТУРА

1. Рецкер Я.И. Теория перевода и переводческая практика. М., 2010. 244 с.
2. Тукай Г. Әсәрләр: 6 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 384 б.
3. Тукай Г. Избранное. Казань: Магариф, 2008. 223 с.
4. Юсупов Р.А. Проявление общего и специфического в парадигматических отношениях слов русского и татарского языков // Филология и культура. Philology and culture. 2013. № 2 (32). С. 38–44.

## ТӘРҖЕМӘ ТӘҖРИБӘЛӘРЕ
## (Г. Тукайның «Олуг юбилей мөнәсәбәте белән халык өмидләре» шигыренең тәрҗемәләре хакында)

***Мусабәкова Р.Р.***

В статье проведен подробный сравнительный анализ стихотворения Г. Тукая «Олуг юбилей мөнәсәбәте белән халык өмидләре» в переводах на русский язык С. Липкиным, В. Ганиевым, Р. Бухараевым и Н. Ахмеровым. Выявлены особенности переводов, отмечены как некоторые неточности, так и удачи.

The article gives a detailed comparative analysis of the poem G. Tukaya "Olug anniversary mənəsəbəte belən Halyk əmidlərе" in translation into Russian S. Lipkinym, V. Ganievym, R. Buharaevym and N. Ahmerovym. The features of translation, noted some inaccuracies, and good luck.

Үз әдәбияты белән генә чикләнеп, башка халыкларның мәдәни-сәнгати казанышларын танымыйча яшәгән халыкны күз алдына китереп булмый һәм бу мөмкин түгел хәл. Тәрҗемә кешелек тарихында яшәгән, яши һәм яшәячәк, гәрчә берәүләр аны мөмкин түгел күренеш дип атаса да, икенчеләр тел белеме фәненә, өченчеләр әдәбият белеме фәненә кертсә дә. Чөнки телләр, әдәбиятлар бихисап күп, аларны өйрәнеп тә, белеп тә бетереп булмый.

Оригиналны бүтән телгә тәрҗемә иткәндә матур әдәбиятта хәрефкә-хәреф төгәллеккә ия булган һәм поэтик яктан тәңгәл булган тәрҗемә арасында мәңгелек дилемма яшәп килә. Гадәттә тәрҗемәче эш барышында юл чатында икеләнеп, кайсы юлны сайларга белмичә, аптырап кала. Ләкин ул барыбер нинди дә булса юлны сайларга мәҗбүр була.

Тәрҗемә белгече Р. Мостафин бу хакта болай яза: «Тәрҗемә өлкәсендә төгәллек кирәк дигән фикер белән барыбыз да килешәбез. Ләкин эш шунда ки, тәрҗемә итү процессында тәрҗемәче төгәллек хакына шул төгәллектән үк чигенергә мәҗбүр була» [9, с. 537].

Әйе, бу фикер парадоксаль яңгырый. Тик шулай да, әдәби әсәрне тәрҗемә иткәндә, абсолют төгәллектән берникадәр чигенү – практикада котылгысыз чара. Ахыр чиктә тәрҗәмәгә бәя бирү критерие булып тәрҗемәнең форма һәм эчтәлек ягыннан оригиналдан ни кадәр читкә китүе тора.

Тәрҗемәнең уңышлы чыгуы тагын бер фактор белән бәйле, ул да булса – тәрҗемәченең индивидуаль йөзе чагылуы. Әдәби тәрҗемәдә, әйтик, фәнни тәрҗемәдән аермалы буларак, әдәби төгәллек карашыннан чыгып фикер йөрткәндә, берничә, ә инде теоретик планда бик күп вариантлар туарга мөмкин. Әйтик, берничә дистә тәрҗемәчеләр бер үк шигырьне тәрҗемә итсә дә, ике бертөрле тәрҗемә беркайчанда тумаячак. Һәм алар арасында иң уңышлысын сайлап алу да мөмкин булмас иде, чөнки тәрҗемә практикасы күрсәткәнчә, бер тәрҗемә дә оригиналның чын мәгънәсендә югары дәрәҗәсен тулаем бирә алмый, чөнки, кызганычка каршы, ул – югалтулар юлы. Шуңа да карамастан тәрҗемәләр һаман туа тора һәм бу процесс беркайчанда туктап калмаячак.

Тукай әсәрләрен тәрҗемә итүнең шактый бай тарихы бар. Аның шигырьләрен рус теленә беренче булып П. Радимов тәрҗемә итә [5].

Совет чорында һәм аннан соңгы елларда Тукай әсәрләрен йөзгә якын әдәбиятчы рус теленә тәрҗемә итте. Иң күп тәрҗемә иткәннәр арасында, беренче чиратта Р. Моран, С. Липкин, С. Ботвинник, В. Тушнова, С. Северцев, О. Дмитриев, В. Звягинцев, Д. Бродский, К. Липскеровларны атап үтәргә кирәк. Г. Тукай шигырьләре, күбрәк очракта, икешәр тапкыр тәрҗемә ителгән, ләкин, моннан тыш, өчәр, дүртәр, һәттә биш тапкыр тәрҗемә ителгәннәре дә бар.

Бу мәкаләдә без Г. Тукайның 1913 елда язылган «Олугъ юбилей мөнәсәбәте белән халык өмидләре» шигыренең дүрт шагыйрь тарафыннан тәрҗемә ителгән вариантларын карап чыгарга булдык. Шигырь Романовлар нәселенең Россиядә патшалык итә башлавының 300 еллыгы уңае белән язылган. «Шагыйрь авыру хәлендә дә татар дөньясында һәм ил күләмендәге вакыйгалардан хәбәрдәр, алай гына да түгел, шуларга үзенең мөнәсәбәтен белдерергә тырыша. Ул рус халкына, алдынгы рус культурасына олы ихтирам белән карый» [5, б. 241].

Бу уңайдан 1913 елда Россиянең берничә шәһәрендә бәйрәм чаралары оештырыла, шул исәптән Казанда һәм Казан губерниясендә дә. Билгеле, бу күренешкә Г. Тукай игътибар итми калмый. Шигырьдән тыш ул «Юбилей мөнәсәбәте белән» исемле мәкалә дә яза.

Шигырь 38 юлдан тора, алты кисәккә бүленгән. Аерым юллары төп әсәрдән аерылып мөстәкыль гыйбәрә рәвешен алган, хәттә аларны кулланганда гадәттә төп чыганакның исемен дә искә алмыйбыз:

Рус җирендә без әсәрле, эзле без...

яки:

Без сугышта юлбарыстан көчлебез,
Без тынычта аттан артык эшлибез.

Тәрҗемәгә алынганда, әдәбиятчы үзалдына ниндидер максатлар куя, ниндидер поэтик ысулга мөрәҗәгать итә, һәм алар күп төрле булырга мөмкин. Танылган, тәҗрибәле тәрҗемәчеләр С. Липкин [2], В. Ганиев [3], Р. Бохараев [4] һәм Н. Әхмәров [1] тәрҗемә иткән вариантлар шактый дәрәҗәдә аерылып торалар. Гомүмән, ике тәрҗемәне генә тулаем тәрҗемә дип атап була, алар В. Ганиев («Великий юбилей и связаниные с ним чаяния народа») һәм Н. Әхмәров («Надежды народа») вариантлары. С. Липкин белән Р. Бохараев шигырьне өлешчә генә (өченче һәм дүртенче кисәкләрен) тәрҗемә итәләр, күрәсең, аларның максатлары тулаем тәрҗемә эшләү булмаган. Шуңа күрә бу күренешне зур хата дип атап булмый. Мондый хәл белән тәрҗемәнең исемен дә аңлатып була: икесе дә «На русской земле» дип атала. Андый очраклар тәрҗемә эшендә очраштыргалый. Шуңа да карамастан, шигырьне тәрҗемәдә тулаем күләмдә күрәсе килә.

Бу очракта без тәрҗемәләрнең дүртесен дә бер рәткә куеп чагыштыра алмыйбыз, әлбәттә. Чагыштыру өчен С. Липкин – Р. Бохараев һәм В. Ганиев – Н. Әхмәров вариантларын карап чыгу кирәктер. Әйтергә кирәк, С. Липкин шулай да тәрҗемә исеме астына җәя эчендә (Из стихотворения «Надежды народа в связи с великим юбилеем») дип куя. Бу, беренче карашка, вак кына мәсьәлә шигырь тәрҗемәсенең рус телендәге исемен эзләп табу эшендә зур кыенлыклар тудыра. С. Липкин тәрҗемәсен исә эзләп табу авыр булмады.

Ике тәрҗемә дә Тукай шигыре рухын чагылдыра, чын мәгънәсендә русча яңгырый, аларда бернинди киная дә, яшерен фикер дә сизелми. Билгеле гыйбарә булып киткән юллар да шактый матур яңгырыйлар:

> На русской земле проложили мы след... (С. Липкин)
>
> Наш след не померкнет на русской земле... (Р. Бохараев)

яки:

> Как тигры, воюем, нам бремя не бремя,
> Как кони, работаем в мирное время... (С. Липкин)
>
> Как тигры, смелы мы в тревогах войны,
> Как лошади, трудимся в мирные дни... (Р. Бохараев)

В. Ганиев һәм Н. Әхмәров Тукай шигырен тулаем тәрҗемә иткәннәр. Әйе, һәр заман үзенә хас булган тәрҗемәләр тудыра, чөнки заман үзенчәлекләре, аның идеологиясе, башка нечкәлекләре тәрҗемәгә дә тәэсир итми калмый. Моны раслый торган мисалларны бик күп китереп булыр иде. Шуның өчен бер үк әсәрләр байтак вакыт үтү сәбепле заман таләбе буларак кабат тәрҗемә ителәләр. Мондый хәлнең дә мисаллары бихисап.

В. Ганиев тәрҗемәсе бу күренешне очык дәлилли. Бу очракта Н. Әхмәров күзәтүләре белән килешми булмый. Чыннан да: «Идеяләр, образлар, хисләр һәм фикерләр диапазоны буенча Тукай шигърияте шул кадәр киң, аңардан төрле идеологик күрсәтмәләргә раслау эзләп табып булыр иде. Теләсәң, аны монархист яки антимонархист, клерикал яки антиклерикал, милләтче яки интернационалист, революционер яки консерватор итеп күрсәтеп булыр иде... Кызганычка каршы, озак еллар дәвамында аның әсәрләрен тәрҗемә итүче күп кенә тәрҗемәчеләр бу мөмкинлек белән кирәгеннән артык файдаландылар. Аерым очракларда бу хәл Тукай шигырьләренең мәгънәсен бозып, ялганга кадәр барып җитә иде» [1].

Бу фикер, кызганычка каршы, Р.Ганиев тәрҗемәсенә туры килә, чөнки аның тәрҗемәсендә Тукай, чыннан да, рус патшасыннан күпмедер дәрәҗәдә көлә, татар укучысының күз алдына революционер булып килеп баса (Тукайны революционер һәм атеист итеп күрсәтергә тырышу заманалары бар иде шул). В. Ганиев үзе үк бу фикерне куәтләп, «Юбилей мөнәсәбәте белән» диюе (Тукайның. – *Р.М.*) шигырьнең исеме белән генә бәйле, чынлыкта исә татар шагыйре патша һәм Романовларга карата барлык милләтләрнең гади кешеләренең кайгы-хәсрәтләрен, татарларның – Россиядә иң күпсанлы халыкларның берсе булган халыкның хокуксыз икәнен искә төшереп, ачы, ләкин гадел хакыйкатьне белдерә. ... Бу бит Патшаның үзенә карата кыю һәм куркусыз каршы чыгу?! ... Г. Тукай Пушкин, Лермонтов, Жуковскийлар алдына тез чүксә дә, патша-император, монархия алдында беркайчан да тез чүкмәде», – дип яза [7, б. 46]. Оригиналда беренче һәм соңгы дүрт юл кабатлана, Р.Ганиев соңгы дүрт юлны нигәдер бераз үзгәртә.

Н.Әхмәров игътибар иткән икенче мәсьәлә – тел мәсьәләсе. Аныңча: «.. бөек Тукай шигърияте русларга таба Тукай строфаларының тышкы төзелешенә ияру юлы белән түгел, ә, кайчан да Пушкин нигез салган, гадәтләнгән эстетик кабул итү формаларында юнәлеш алырга тиеш» [7, б. 46].

Бу очракта да Н. Әхмәров фикере игътибарга лаек. Чыннан да, әгәр тәрҗемә руслар өчен эшләнгән икән, ул рус поэзиясенең эстетик нормаларына тәнгәл булырга тиеш. Шушы ук фикерне танылган рус шагыйре һәм тәрҗемәчесе Н. Заболоцкийда да очратып була: «Әгәр чит телдән тәрҗемә ителгән әсәр уңышлы рус әсәре кебек укылмый икән, бу очракта тәрҗемә я йомшак, я начар эшләнгән булып санала» [8, б. 426].

Моңа дәлил булып Н. Әхмәровның тәрҗемәсе тора, дөрес, аерым очракларада бу юнәлештә ул берникадәр оригиналдын тайпылырга, бераз үзеннән дә өстәргә мәҗбүр була. Ләкин нәтиҗәдә русча матур укыла, Тукай фикерен һәм хисен рус укучысына җиткәрә ала торган тәрҗемә туа. Тәрҗемәнең башы һәм ахыргы юлларына килгәндә, Әхмәров тәрҗемәсендә шигырнең башы берникадәр киңәйтелгән.

Сөендергәне шул: Тукаебыз иҗаты гасыр дәверендә яшәп, бүгенге укучыны да үзенә җәлеп итә тора, заманча укыла, башка телдә укучыларга да әледән-әле тәрҗемә ителеп тора. Димәк, Тукаебыз яши бирә.

ӘДӘБИЯТ

1. Ахмеров Н. Тукай по-русски // Татарский мир. № 6–7. 2004.
2. Тукай Г. Избранное. Казань, 1978. 271 с.
3. Тукай Г. Стихотворения и поэмы. Л., 1988. 431 с.
4. Тукай Г. Стихотворения, поэмы и сказки. Казань, 1986. 415с.
5. Габдулла Тукай. Тормыш һәм иҗат елъязмасы. Казан, 2003. 269 б.
6. Тукай Габдулла. Узюльган умид. Казань. 1920. 31 с.
7. Ганиев В. Всего одна страница из творческой жизни поэта (к 110-летию со дня рождения Г. Тукая) // Дом Ростовых. Литературное приложение к «Вестнику» Международного Сообщества Писательских Союзов. Сент., 1966. М., 1996. 63 с.
8. Заболоцкий Н.А. Заметки переводчика // Перевод – средство взаимного сближения народов. М., 1987. 638 с.
9. Мустафин Р. Школа точности // Художественный перевод. Проблемы и суждения. М., 1985. 576 с.

## ХӘҘЕРГЕ БАШҠОРТ ШИҒРИӘТЕНДӘ ҒАБДУЛЛА ТУҠАЙ ИЖАДЫ

***Набиуллина Г.М.***

В статье анализируется стихи современных башкирских поэтов о Г. Тукае. С годами не потускнеет наследие великого поэта, а вновь и вновь вдохновляет новых творческих сил покорять вершины поэзии. Его персонажи в новом свете появляются в современных стихах.

The article analyzes the modern Bashkir poetry writers, dedicated to the art G. Tukay. Over the years, his work does not fade, and again and again inspires new creative forces to conquer the peaks of poetry. His characters appear in a new light in modern poetry.

Башҡорт әҙәбиәтендә Ғабдулла Туҡайҙың ижади мираҫына, уның поэзияһының бөйөклөгөнә ҡарап һоҡланған, уны аңларға тырышҡан байтаҡ әҫәрҙәр, иҫтәлектәр яҙылған.

Был хаҡта Ф.Б. Юнысова үҙенең «Ғабдулла Туҡай башҡорт яҙыусылары иҫтәлектәрендә» тигән мәҡәләһендә «1966 йылда Өфөлә Туҡайға арналған «Туҡай Башҡортостанда» тигән иҫтәлектәр, шиғырҙар, хикәйәләр һәм мәҡәләләр тупланған йыйынтыҡ донъя күреүен» билдәләп үтә. Шунда уҡ ғалимә китапҡа һылтанма яһап, башҡорт шиғриәтендә Шәйехзада Бабичтың «Ғабдулла әфәнде Туҡаев», «Туҡай үлгәс», М. Хәйҙең «Үлем юҡ шағирға», Г. Мәсәғүт «Балалыҡ дуҫым», Б. Вәлидтең «Туҡай мондары», Ғ. Ғүмәрҙең «Өлгө һин», Ә. Вәлиҙең «Тере Туҡай», Ҡ. Даяндың «Ғ. Туҡайға», М. Сөндөклөнөң «Туҡайға», Ш. Биҡҡолдоң «Юлда», Х. Ғиләжевтың «Туҡай Өфөлә», Б. Бикбайҙың «Саф алтын», Ғ. Рамазановтың «Оло кеше», Р. Ғариповтың «Шағир», А. Игебаевтың «Шағир һәм әжәл», Мостай Кәримдең «Туҡайға» тигән шиғырҙары булыуын да яҙып үтә.

Билдәле башҡорт шағиры Ирек Кинйәбулатов «Туҡай урамы» исемле мәҡәләһендә: «Ә инде мәшһүр Туҡай хаҡында мин, шиғыр яҙған һәм донъя шиғриәтен апаруҡ

уҡыған кеше булараҡ, Туҡай һымаҡтар бит барлыҡ быуаттарға бер тыуа, тип әйтер инем. Һәм был һүҙҙе, иманым камил, башҡа илдәрҙә, башҡа ҡитғаларҙа йөҙҙәрсә, меңдәрсә телдә әйтәләрҙер. Әйтмәһә лә, тап шулай уйлайҙарҙыр. Хәреф танығандан бирле ҡолаҡҡа һәм зиһенгә һеңеп ҡалған: «Эй, туған тел, эй, матур тел, атам-әсәмдең теле!..» – тигән ябай һәм үлемһеҙ һүҙҙәрҙе әйтеүсе шиғриәт бәйғәмбәре Туҡайҙың тыуыуына 125 йыл тулыу байрамына исемләп саҡырылыу бәхете насип булыу шағир өсөн йыһанға осоуҙан да кәм түгелдер», – тип үҙенең уй-кисерештәре менән бүлешә. Казанда булған сағында Ш. Бабич, З. Биишева, Ә. Атнабаев, Р. Бикбаевтарҙың Туҡайға арналған шиғырҙарын һөйләп ишеттереүе хаҡында телгә ала Ирек Кинйәбулатов һәм мәҡәләһен үҙенең «Туҡай урамы» исемле шиғыры менән тамамлап ҡуя.

Тарихсы ғалим Ә.Ғ. Сәлиховтың «Туҡай һәм башҡорт әҙәбиәте» тигән мәҡәләһе лә мәғлүмәти яҡтан иғтибарға лайыҡ.

Башҡорт шиғриәтендә Назар Нәжмиҙең «Булғандар бит», Рәми Ғариповтың «Шағир» (Туҡай ҡәбере эргәһендә уйланыу), Әнғәм Атнабаев «Шағирҙар», Раул Бикбаевтың «Туҡайға»шиғырҙары менән бер рәттән, һуңғы йылдарҙа Ирек Кинйәбулатовтың «Туҡай урамы», Ҡәҙим Аралбаевтың «Туҡай маршы», Ҡол-Дәүләт «Туҡай урамында тыуған шиғыр», Салауат Әбүзәрҙең «Эй, Шүрәле, Туҡай Шүрәлеһе» исемле шиғырҙары донъя күрҙе. Юғарыла әйтелгән ғалимдарҙы ҡабатламаҫ өсөн беҙ шиғырҙарҙың һуңғыларына иғтибарҙы тупламаҡсыбыҙ.

Шағир Ҡол-Дәүләт «Туҡай урамында тыуған шиғыр» әҫәренә Башҡортостандың халыҡ шағиры Назар Нәжмиҙең «Өфө йүкәләре беҙҙең хаҡта ла әле, япраҡ ҡоя-ҡоя һөйләрҙәр» тигән юлдарын эпиграф итеп алып, уны түбәндәгесә башлап ебәрә:

«Туҡай урамында илаһи мәл,
Алтын миҙгел итә тантана».

Ысынбарлыҡта булған, Өфө ҡалаһында урынлашҡан төп урамдарҙың береһе – Туҡай урамы атамаһына шағир тәрән мәғәнә һалған. Алтын көҙ – ул тәбиғәттең иң матур, бай мәле. Ошо муллыҡ, гүзәллекте үҙендә туплаған көҙгө илаһи бөйөклөк менән йайлап Туҡай ижады араһында бәйләнеш тыуа. Туҡай урамы – ул ябай, ҡәҙимге генә урам түгел, ә оло шиғриәт донъяһы. Туҡай шиғриәте – ул йәштәр өсөн маяҡ, уға ҡарап һәр кем намыҫлана, үҙенә баһа бирә.

Ҡол-Дәүләттең лирик геройы ла шиғриәт тигән илгә аяҡ баҫҡас, үҙен Туҡай мираҫы алдында яуап тоторға тейешлеген аңлай:

«Бар әйләнәм тынмаҫ йыр ҙа моң,
Был урамға баҙнатлығым етеп,
Ҡайҙан, ҡасан килеп индем һуң?
Кем мин бында?»

Ҡол-Дәүләттең геройы һәр йәш ижадсы кеүек үҙенә үҙе һорау бирә, яҙғандарын баһаларға ынтыла. Лирик герой өсөн Туҡай ижады шиғриәттең тотош бер урамын тәшкил итһә, ул үҙе Туҡай урамында «бер йүкә япрағы» булып йәшәһә лә, «үкенмәҫ тә инем», – ти. Ғабдулла Туҡай кеүек шағирҙың талантын, ижад бейеклеген ошо кимәлгә еткереп ысын шағирҙар ғына баһалай алалыр, моғайын.

«Япраҡ тинем дә ул,

Шулай була ҡалһа, ҡана һуң!» – Ҡол-Дәүләттең лирик геройы ныҡлап уйлана торғас, Туҡай ижады янында үҙе япраҡ ҡына түгел, хатта бер кескәй генә тамсы булһам да, йәғни, беҙҙең аңлауыбыҙса, Туҡайҙың халҡы өсөн башҡарған эштәренең тамсыһын ғына эшләй алһам да үкенмәҫ инем, ти.

Ҡәҙим Аралбаевтың «Туҡай маршы» исемле шиғыры ла иғтибарҙы үҙенә йәлеп итә. Шағир билдәләп үтеүенсә, Туҡайҙы, уның ҡабатланмаҫ моңон, сазын Татар иле, татар донъяһы ғына түгел, башҡорт ерендәге Балҡантау ҙа, Ҡаратау ҙа, Алатау ҙа өҙөлөп һағына. Ҡазан артын, Ҡырлайҙы урап сыҡҡан Туҡай маршы Урал буйҙарын гиҙеп йөрөй, ижадсының күңелен тултыра, йөрәген тулата, шағирҙарҙа дауылдарға ҡаршы барырлыҡ көс уята.

Ҡ. Аралбай өсөн Туҡай маршы «моңло-дәртле», уны ишеткәндә «елдәр шаулай, урман үкһей, күк ярыла, ямғыр ҡоя, сал ҡылғандар аҡ ҡайынға ҡушылып йырлай, дарья булып хистәр таша, моң түгелә, ул, шул уҡ ваҡытта, хаҡ көрәшкә әйҙәй, халыҡ

өсөн изге эштәр атҡарырға саҡыра». Был марштың моңо йә һағышлы, йә наҙлы, ул кәкүк булып та саҡыра, һандуғас булып та сыңғырай, ҡыр ҡаҙы кеүек тә ҡаңғылдай, бөркөт булып та саңҡылдай. Ҡәҙим Аралбай шиғырынан күренеүенсә, Ғабдулла Туҡай ижады донъялағы барлыҡ көс-ғәйрәтте, гүзәллекте, ярһыу-шашыуҙарҙы, күкрәү-йәшнәүҙәрҙе үҙенә туплаған бер илаһи көс булараҡ уҡыусы күҙ алдына килеп баҫа.

Хәҙерге әҙәбиәт ғилемендә интертекстуаль бәйләнештәрҙе өйрәнеүгә ҙур иғтибар бүленә. Ғалимә З. Шәрипова «Художестволы әҫәрҙә әҙәби алынмалар функцияһы» тигән мәҡәләһендә был проблемаға ҡағылышлы түбәндәге фекерҙәре менән уртаҡлаша: «милли әҙәбиәттең йә булмаһа бүтән әҙәбиәттәрҙең теге йәки был фактына күпмелер дәрәжәлә мөрәжәғәт итеүҙе фәндә реминисценция тигән төшөнсә менән атайҙар», «беҙ әҙәби реминисценцияны башҡортсалап «әҙәби алынма» тип тә атау яғында» [5, с. 140], – ти. З.Я. Шәрипова юғарыла атап үткән мәҡәләһендә реминисценцияларҙың асыҡ һәм йәшерен төрҙәргә бүленеүен, «әҙәби алынмаларҙың әҫәрҙәге функцияларын айырып ҡына билдәләү – шаҡтай ҡыйын эш» [5, с. 152] икәнлеген асыҡлап китә. Н.Ә. Хөббитдинова ла «интертекст – текст-ара бәйләнеште булдырыуҙа реминисценция ла мөһим роль үтәп килә» [4, с. 71], – тип З.Я. Шәрипованың әйткәндәренә таяна.

Салауат Әбүзәрҙең «Эй, Шүрәле, Туҡай Шүрәлеһе» исемле шиғырында Ғабдулла Туҡайҙың персонажы Шүрәлегә мөрәжәғәт итеп, уны үҙенең әҫәренең тексына индереп ебәреүе ғалимәләр З. Шәрипова һәм Н. Хөббитдинова әйткән әҙәби алынма күренешенең матур бер үрнәге ул. Салауат Әбүзәр бөгөнгө көндәң көнүҙәк мәсьәләләрен үҙе исеменән генә әйтһә, бының тәьҫир итеү көсө әллә ни булмаҫ та ине кеүек, сөнки был мәсьәләләр күптәргә таныш, уны һәр саҡ ҡабатларға тура килә. Шағирҙың Туҡай Шүрәлеһенә мөрәжәғәт итеүе мәсьәләлргә бөтөнләй яңы яңғыраш һала, уларҙың мөһимлеген, тәрәнлеген Туҡай күҙе аша ҡараған кеүек була уҡыусы:

Эй, Шүрәле, Туҡай Шүрәлеһе,
Меҫкен хәлдә ҡалған Шүрәле!
Беҙҙең хәл дә бик үк шәптән түгел,
Хәлебеҙҙе, туған, күр әле.

С. Әбүзәрҙең шиғырында шулай уҡ Ғабдулла Туҡайҙың Былтыры ла хәрәкәт итә, ул бөгөн килеп тағы Шүрәле төҫлө бер ҡатлы халыҡтың бармаҡтарын төрлө ҡанун ярығына ҡыҫтырып китә, был ғына етмәй, тора бара ағас ярығына ғәзиз телдәре лә килеп ҡыҫыла. Шағир әҫәрен Туҡай юлдары менән тамамлай:

Һыҙланаһың, халҡым, өнөң сыҡмай,
Буйһонаһың һаман ҡушҡанға.
Бер көн килеп, әйтмәҫтәрме һиңә,
Ҡысҡырма, тип, былтыр ҡыҫҡанға...

Шулай итеп, хәҙерге башҡорт шиғриәтенә лә Ғабдулла Туҡай йоғонтоһон күҙалларға мөмкин. Бөйөк шағирҙың ижады йәш быуын өсөн шиғриәт юғарылығы булып торһа, уның әҫәр геройҙары әҙәби алынма функцияһын башҡарып, бөгөнгө көндөң көнүҙәк мәсьәләләренең тәрәнлеген, мөһимлеген генә арттыра. Ғабдулла Туҡай ижадының көсөн ваҡыт арауығы һис кәметә алмай, сөнки ул дөйөм кешелекте борсоған мәсьәләр күтәргән, уның шиғриәте халыҡтың рухи донъяһының бер ҡуҙы төҫлө замана елдәренән һүрелмәй, киреһенсә ҡабына ғына бара.

ӘҘӘБИӘТ


1. Аралбаев Ҡ.А. Һөйөүем йондоҙо. Өфө: Китап, 1986. 112 б.
2. Кинйәбулатов И.Л. Туҡай урамы // Йәшлек. 2011. 17 май.
3. Ҡол-Дәүләт. Һигеҙенсе мөғжизә. Өфө: Китап, 1991. 80 б.
4. Хөббитдинова Н.Ә. XIX быуат аҙағы – XX быуат башы башҡорт әҙәбиәтендә фольклор традицияларының художестволы сағылышы. Өфө: Ғилем, 2013. 1888 б.
5. Шәрипова З.Я. Художестволы әҫәрҙә әҙәби алынмалар функцияһы // Ағиҙел. 2008. № 6. Б. 139–152.
6. Әбүзәр С. «Эй, Шүрәле, Туҡай Шүрәлеһе» // Йәшлек. 2012. 16 май.
7. Юнысова Ф.Б. Ғабдулла Туҡай башҡорт яҙыусылары иҫтәлектәрендә http://gabdullatukay.ru (дата обращения – 10.03.2016).

# НАЦИОНАЛЬНАЯ ИДЕНТИЧНОСТЬ В ПЕРЕВОДЕ
## (на материале переводов стихотворения Г. Тукая «Милли моңнар» на русский язык)

***Нагуманова Э.Ф.***

В статье рассматриваются особенности передачи поэтики стихотворения Г. Тукая в переводах, выявляются трансформационные изменения в них, обусловленные несовпадениями лексических систем языка оригинала и языка перевода, а также эстетическими факторами.

In the paper based on Russian translations of poem by G. Tukay, transformational changes, brought about by differences in the lexical systems of two languages are revealed. Poetic correspondence is also examined.

Проблемное поле понятия «национальная идентичность» в компаративистике охватывает явления, возникающие, прежде всего, в зоне контакта между национальными литературами (читательская рецепция, перевод). Идентичность проявляется как столкновение двух систем (произведений, литератур) и обнаруживает себя в феноменах, отражающих контраст между ними: смысловая интерференция, возникающая в процессе рецепции инолитературного текста, непереводимость.

Переводчик в силу причастности к иной культуре, в которой действуют логико-смысловые отношения, отличные от тех, которые существуют в его языковом сознании, как правило, не транслирует имеющиеся в оригинале смыслы. Согласно представителям восточной поэтики, текст, существующий в рамках иной (с точки зрения смыслопорождающих процедур) культуры, как правило, непереводим в другое смысловое поле. В статье «Подражания восточным стихотворцам: встреча русской поэзии и арабо-персидской поэтики» Н. Чалисова и А. Смирнов, рассматривая разные варианты перевода коранического выражения на русский и английский языки, подчеркивали, что переводчики «стремились передать не возможность осуществления процедуры понимания иносказания, но работали на уровне передачи его содержания. <…> при такой трансляции потерялась суть транслируемого…» [5, с. 331].

В переводах идентичность не растворяется в содержании знаковой памяти, а обретает новую форму в знаках переводящего языка. В подтверждение данного тезиса обратимся к стихотворению Г. Тукая «Милли моңнар» и к переводам это стихотворения на русский язык В. Тушновой, Н. Бухараева и В. Думаевой-Валиевой. Стихотворение Г. Тукая имеет подзаголовок «“Зөләйлүк” көенә» («На мелодию песни “Зиляйлюк”»), что свидетельствует о его синтетической природе, нераздельности вербальной и музыкальной («Зиляйлюк» – известная татарская народная песня) составляющих.

Стоит отметить, что переводчики стихотворения Тукая отличаются владением татарского языка: поэтесса В. Тушнова не владела татарским языком и, как и многие известные переводчики Тукая (А. Ахматова, С. Липкин, Р. Моран), переводила по подстрочнику; поэт Р. Бухараев, известный своими переводами из татарской поэзии, создавал свои оригинальные стихотворения на русском языке, его билингвизм не распространялся на область художественного творчества; В. Думаева-Валиева – переводчик-билингв. В одном из своих выступлений она отметила, почему обратилась к переводам Г. Тукая. Когда в 2009 году она услышала стихи Тукая на русском языке, поняла, что для современного читателя нужно Тукая переводить, и поэтому с этого времени переводы из Тукая прочно вошли в ее творчество. По мнению Думаевой, перевод с советских времен изменил свои цели, ориентиры, только аутентичный перевод, не искажающий подлинник, позволит русскоязычному читателю открыть подлинного Тукая. В предисловии к избранным произведениям Тукая она пишет: «… для воссоздания «духа» произведения необходимо максимально точное воспроизведение его «буквы», т.е. формы» [4, с. 7].

В каждом из рассмотренных нами переводов обнаруживаются смысловые трансформации: нивелирование отдельных моментов произведения и, наоборот, включение в текст перевода компонентов, отсутствующих в стихотворении Г. Тукая.

М. Гали в статье «Тукай – җырчы һәм җыр-музыка сөюче» («Тукай – певец и любитель музыки») писал о том, что натолкнуло Тукая к написанию этого стихотворения: «Көннәрнең берсендә Тукай, “Болгар” номерларында үз бүлмәсендә утырганда,

бик матур бер җыр тавышы ишетә. Үзенең халык җырларына һәм халык көйләренә булган зур мәхәббәте аркасында ул чыдый алмый, коридорга чыга. Җыр тавышы тагын да якынрак һәм тагын да ачыграк ишетелә. Ирексез, ул шул тавыш килгән якка китә. Ул вакытта бик сирәк җырланган көй булганлыктан, Тукай бу көйнең нинди көй булганлыгын да тиз генә аңлап җитә алмый. Ишеге ярык кына калдырып ачылган бер бүлмәгә килеп туктый һәм, аның ишек яңагына башын куеп, тирән уйларга калып, бүлмә эченнән килә торган җыр тавышын тыңларга керешә. Ул бүлмә Сәгыйть Рәмиев бүлмәсе булып чыга һәм кроватьта ятып моңлы калын тавыш белән "Әллүки" көенә җырлаучы кеше дә Тукайның иң яраткан җырчысы – шагыйрь Сәгыйть Рәмиев була. Башка вакытта Сәгыйть белән күбрәк шаярып сөйләшергә яраткан Тукай бик җитди кыяфәт белән аның бүлмәсенә керә дә:

– Әйт, туган, нинди көй җырлыйсың син? Синең бу җырың минем аяк буыннарыма китте, – ди.

Сәгыйть, бер дә исе китмәгән кыяфәт белән:

– Нигә, белмисеңмени, "Әллүки" ич, – ди.

Шуннан соң Тукай үзенең "Милли моңнар" шигырен язып, аны Сәгыйтьтән "Әллүки" көенә җырлата һәм үзе дә аны шул көйгә яки "Зиләйлүк" көенә салып җырлап йөри» [2, с. 37].

Стихотворение Г. Тукая отличается многоплановостью, в нем тесным образом соотносятся понятия «я» и «нация». Как отмечают современные исследователи, «лирический герой Г. Тукая, исполнитель песни «Әллүки», и народ, сложивший ее, образуют особую субъектную целостность, которая отличается такими чертами, как нераздельность «я» и «другого», «я» и «мы», отсутствие между ними субъектных границ» <…> «Родовое сознание людей, испытывающих трехсотлетний гнет и размышляющих о своей судьбе, сливается с сознанием личности, концентрирующей в своем внутреннем мире эмоционально-психологический опыт «мы» народа» [6, с. 81–82].

В название стихотворения выносится концепт «моң», который относится к числу непереводимых на другие языки. «"Моң" … служит обобщенным художественным выражением эмоционального восприятия народом своей жизни» [1, с. 227]. «Моң» – «это не столько переживание боли и утраты, сколько глубоко внутреннее состояние часто беспричинной тоски и печали, которые имеют подсознательную природу и проявляются наиболее остро в моменты душевных томлений» [3, с. 247].

Переводчики по-разному перевели название стихотворения: «Национальные мелодии» (Пер. В. Думаевой-Валиевой), «Национальные чувства» (Пер. Р. Бухараева), «Национальные мелодии» (Пер. В. Тушновой). Как мы видим, два переводчика сошлись в том, чтобы сохранить общий эмоциональный настрой стиха, заявленный уже в заглавии, и использовали наиболее близкое к «моң» понятие «мелодия», Бухараев этого не делает, но только у Бухараева стихотворение имеет подзаголовок «Аллюки». В переводах Думаевой и Тушновой редукция жанрового подзаголовка обусловлена тем, что для русскоязычного читателя он не несет четкой смысловой нагрузки. Эта особенность произведения, сопряженная с особой (синтетической) формой его существования, релевантной, с одной стороны, субъектному синкретизму стихотворения, с другой – самому концепту «моң», и составляет область непереводимого в нем.

В стихотворении Г. Тукая выражено то общее, что свойственно внутреннему миру представителей татарского этноса – общее в мировосприятии, жизненной позиции, идейно-эмоциональных реакциях на явления действительности. Однако в «Милли моңнар» «субъект речи, совмещающий в себе голоса «других» до полного слияния и неотделимости друг от друга, в то же время остается самим собой» [6, с. 82].

Переводчики по-разному передали особенности тукаевского стиха в своих произведениях, актуализирую те или иные грани поэтики Тукая.

Наиболее эстетически емким оказываются тукаевские образы и мотивы в переводе Думаевой-Валиевой. Это можно объяснить прежде всего тем, что билингвальная личность чутко реагирует на всякие неточности в переводе и стремится удовлетворить потребности даже самого придирчивого читателя.

Переводчик – билингв знает языковые особенности двух культур, однако языковая и этническая идентичность билингвальной личности не всегда определяется однозначно. Многое зависит не только от психологического чувства принадлежности к тому или иному этносу и отождествлению себя с ним, но и от включенности в ту культурную

среду, в которой должен «жить» перевод. Писатель-билингв репрезентирует русским языком реалии своей культуры, при этом вычленяя смыслы, отраженные в оригинале, он достраивает эти смыслы до необходимой полноты уже в новой языковой системе с целью их адекватной передачи носителю русского языка. Не все семантические единицы, существующие в национальной культуре, могут быть переведены на язык другой национальной культуры. Возникающие в процессе переводов смыслы могут быть не идентичны содержанию этих единиц в той культуре, из которой осуществляется перевод. В данном случае мы сталкиваемся с непереводимостью, и непереводимое выступает важнейшим фактором диалога литератур как диалога различий.

Подтвердим свои рассуждения примерами из переводов стихотворения Тукая.

Обратимся к переводу первой строфы стихотворения Г. Тукая.

| «Милли моңнар» | Пер. В. Думаевой | Пер. Н. Бухараева | Пер. В. Тушновой. |
|---|---|---|---|
| Ишеттем мин кичә: берәү җырлый<br>Чын безнеңчә ***матур, милли көй***;<br>Башка киләүйлар төрле-төрле, –<br>Әллә нинди ***зарлы, моңлы көй.*** | *Вчера подслушал я, как кто-то пел*<br>*По-нашему протяжно, и, смутив,*<br>*Рой разных мыслей в голове вскипел,*<br>*Хватал за душу **горестный мотив**.* | *Вчера я слышал – кто-то напевал*<br>*Наш **кровный, светлый, ласковый мотив**...*<br>*Щемил он сердце, думы навевал,*<br>*До боли близок, **вечен и красив**.* | *Вчера я слышал – песню кто-то пел,*<br>*Ту, что народом нашим сложена.*<br>*И я подумал: сколько грусти в ней,*<br>*Как беспредельно жалобна она.* |

Интерес вызывают переводы тукаевских эпитетов. В переводе Р. Бухараева увеличивается количество эпитетов, относящихся к слову «көй», которое два раза встречается в первом катрене: «матур, милли көй» (досл.: «красивый национальный мотив») – «кровный, светлый, ласковый мотив»; однако «зарлы, моңлы көй» (досл.: «жалобный, печальный мотив») он полностью трансформировал. Думаева-Валиева сохраняет эпитет, относящийся к слову мотив во втором случае – «горестный мотив». В. Тушнова не акцентирует внимание русскоязычных читателей на эпитетах Тукая.

В переводе Р. Бухараева редуцирован момент этнической идентификации: автор переводит этноним «татары» словом «народ» (примечательно, что в переводе В. Тушновой этот этноним сохраняется, а у Думаевой-Валиевой «татар күңле» (досл.: татарская душа) переводится как «народ», а «безнең халык» (досл.: наш народ) как «душа татарина»).

Обращает на себя внимание ритмико-интонационное сходство переводов: все они выполнены пятистопным ямбом, размером, который в русской классической поэзии ассоциируется с жанром трагедии. Выбранный переводчиками размер не случаен: он обусловлен содержащимся в стихотворении Тукая мотивом трагической судьбы татарского народа, выпавших на его долю тяжелых испытаний.

Таким образом, на примере анализа стихотворения «Милли моңнар» Г. Тукая и переводов на русский язык, мы можем сказать о том, что в переводах в целом сохраняется национальная идентичность. Из всех переводов наиболее адекватным является перевод В. Думаевой-Валиевой, это можно объяснить тем, что человеку, в совершенстве владеющему двумя языками и имеющему представление о специфике двух культур, легче передать многообразие татарского стиха на русском языке.

ЛИТЕРАТУРА

1. Бахтиярова Ч. Обновление национальной традиции // Национальное и интернациональное в литературе и искусстве. М.: Мысль. С. 224–261.

2. Гали М. Тукай – җырчы һәм җыр-музыка сөюче // Совет әдәбияты. 1943. № 4. Б. 37.

3. Галиева А.М., Нагуманова Э.Ф. Особенности передачи национально-специфических концептов в переводных текстам (на примере концепта *Моң* // Учен. зап. Казан. ун-та. Сер. Гуманит. науки. 2013. Т. 155, кн. 2. С. 245–252.

4. Тукай Г. Избранное / перевод с татарского В.С. Думаевой-Валиевой. Казань: Магариф, 2008. 223 с.

5. Чалисова Н.Ю., Смирнов А.В. Подражания восточным стихотворцам: встреча русской поэзии и арабо-персидской поэтики // Сравнительная философия. М.: Издательская фирма «Восточная литература» РАН, 2000. С. 245–344.

6. Amineva V.R., Ibragimov M.I., Nagumanova E.F., Khabibullina A.Z. G. Tukay's poetry: the aspects of national identity // XLinguae European Scientific Language Journal. Volume 8. Issue 1, January 2015. С. 79–87.

# ГАДУЛЛА ТУКАЙ ҺӘМ БАШКОРТСТАН
## (фәнни-тикшеренү проекты турында)

***Насипов И.С.***

В статье раскрывается содержание научно-исследовательского проекта «Габдулла Тукай и Башкортостан», реализация которого связана с увековечиванием памяти великого поэта и приурочена к 100-летию приезда Г. Тукая в г. Уфа. Научные исследования посвящены изучению влияния творчества поэта на формирование и развитие башкирской литературы и татарской литературы в регионе. Результаты исследования должны найти место в экспозициях меомориального кабинета «Тукай в Уфе», расположенного в БГПУ им. М.Акмуллы.

Article covers the contents of the research and development project «Gabdulla Tukay and Bashkortostan», implementation of which is related to memorialization of the great poet and confined to the 100th anniversary of visit of G. Tukay to the city of Ufa. Scientific research is dedicated to the study of the influence of the poet's works on formation and development of the Bashkir literature and the Tatar literature in the region. Study results should find their place in the exhibitions of the memorial office «Tukay in Ufa» situated in M. Akmullah BSPU.

Татар халкының бөек улы Габдулла Тукайның иҗаты дөнья күләм мәдәни мирас санала. Әдипнең үлемсез мирасының әһәмияте ул яшәгән чордан ерагайган саен арткannan арта гына бара. Аның даһилыгы, әсәрләрендә яңгыраган заман авазы бүгенге татар баласына гына түгел, төрки һәм бар мәдәни дөньяга җан дәвасы булуы көннән-көн ачыла бара. Шагыйрьнең тууына 125 ел тулу уңаеннан ЮНЕСКО һәм ТҮРКСОЙ халык-ара оешмалары, Татарстан Республикасы Президенты 2011 елны «Тукай елы» дип игълан итүләре, моңа бәйле Тукайның истәлеген мәңгеләштерү һәм мирасын дөньякүләм танытуга бәйле чаралар моның ачык мисалы. Ел саен уздырыла торган мәдәни чарлар да аның тормышы һәм иҗатының илаһилыгын яңадан-яңа бизәкләрдә таныта. Чөнки «Тукай иҗатының тамырлары татар халкының тирән тамырына барып тоташа. Аның шигъриятенең эстетик асылы татар милли әдәбиятының күп гасырлык традицияләре тәэсирендә формалашты. Тукайның иҗат мирасы исә бөтен төрки-татар шигъриятенең үсешенә йомгак ясады. Бер үк вакытта ул үзенә дөнья әдәбиятының гомумкешелек кыйммәтләрен дә тирән сеңдерде» [1, с. 9].

Габдулла Тукай иҗаты төрки халыклар әдәбиятының үсешенә зур йогынты ясый, бигрәк тә ике якын кардәш халыкның татар һәм башкорт әдәбиятларының тыгыз бәйләнеше бүген дә тәэмин итүче чишмә ролен үти. 2012 елда Габдулла Тукайның Уфага килүенә 100 ел тулуга бәйле мәдәни чаралар моның мөһим дәлил булып тора. Бу тарихи сәхифәне мәңгеләштерү йөзеннән төрле тәкъдимнәр дә күп булды. Уфада Тукайга һәйкәл кую шуларның иң әһәмиятлеседер.

Шул ук елны М. Акмулла исем. Башкорт дәүләт педагогия университеты ректоры Р.М. Асадуллин университетның филологик белем бирү һәм мәдәниарадаш коммуникацияләр институтында «Тукай Уфада» мемориаль кабинетын булдыру инициативасын яңгыратты, аны үтәүне татар теле һәм әдәбияты кафедрасына йөкләде. Озакламый бу идея «Тукай һәм Башкортстан» фәнни-тикшеренү проектына кадәр үсте. Чөнки «Тукай Уфада» мемориаль кабинетын булдыру һәм аны эчтәлек ягыннан тулыландыру өчен, зур оештыру эшләре белән беррәттән, әдипнең тормышы һәм иҗатының башкорт әдәбияты һәм Башкортстанда татар әдәбияты үсешенә йогынтысы мәсьәләрен фәнни өйрәнү кирәклеге дә ачыкланды. Болар барсы да төрле дәрәҗәдәге дәүләти һәм иҗтимагый грантлар исәбенә башкарылырга тиеш дип карала.

Проект ике төп өлештән тора:

– фәнни өлеше татар теле һәм әдәбияты кафедрасы укытучылары һәм студентлары, магистрлары, аспирантлары, башка белгечләр башкаруында фәнни-тикшеренү эшләр алып баруга юнәлтелгән;

– хуҗалык-техник өлеше сәнгати-бизәлеш эшләре алып баруга һәм мемориаль бүлмәне материал-техник җиһазлауга юнәлтелгән.

Бүген «Тукай Уфада» мемориаль кабинетын өчен бүлмә бирелде, ул К.А. Аблязев һәм Х.И. Акчуриннарның ярдәме белән төзекләндерелеп, анда мәгълүмати-күргәзмә һәм техник чара җиһазларын урнаштыру эшләре башланды. Мемориаль кабинетта М. Акмулла исем. Башкорт дәүләт педагогия университеты студентлары тарафыннан диплом проекты буларак башкарылган һәм татар бүлегенә бүләк ителгән агачтан

эшләнгән Тукай сыны урын алган. Иске Уфа урамы фонына урнаштырыла агач сынга карасан, гүя шагыйрь безнең күз алдында Уфа урамы буйлап килә.

Бүлмәдә шагыйрьнең китаплары, аның турында әсәрләр, фонотека фондлары туплана. Аудитория заманча мебель һәм техник чаралар белән җиһазлана. Мәгълүмати-күргәзмә җиһазларында Габдулла Тукайның Башкортстанның мәдәни тормышына, башкорт һәм төбәкчелек татар әдәбияты үсешенә йогынтысына бәйле сәхифәләр урын алырга тиеш. Аларны якынча түбәндәгечә күзалларга мөмкин.

Иң беренче чиратта, аларда Габдулла Тукайның Уфага килүенә бәйле тарихи хәл-вакыйга чагылыш табарга тиеш. Күп кенә чыганакларда әдип Уфага бер тапкыр килгән буларак яктыртылса да, ул шәһәрдә ике мәртәбә аз гына вакыт булса да туктала. Шагыйрь 1912 елда Казаннан яңа стиль белән 27 апрельдә, Иделдә навигация башлану белән китеп, Самарадан поезда Уфага 30 апрель иртән килеп җиткән. Шәһәрдә хәзерге Свердлов белән Карл Маркс урамнары чатында урнашкан «Сабах» көтепханәсе йортында урнашкан китап кибетенең арткы бүлмәсендә, китаплар төяп китерелгән әрҗәләрне карават итеп тезеп шунда яшәргә урнашкан. Ләкин, бу вакытта әле Уфада кымыз булмау сәбәпле, килүенең икенче көнендә Петербургка киткән. Пайтәхеттән яңа стиль буенча якынча 20–21 майда Уфага кире әйләнеп кайткан. Уфадан яңа стиль белән 1912 елның 28 маенда, беренче тапкыр шәһәргә аяк басуына бер ай туларга ике көн калгач, Троицкига кымыз эчәргә китеп барган [2, с. 8–13].

Тукайның Уфага килүенә бәйле икенче сәхифә, әлбәттә, шәһәрдә шагыйрьнең монда яшәүче әдипләр белән аралашуын чагылдыра ала. Болары, беренче чиратта Мәҗит Гафури белән бәйле булса да, аларда җырчы Әхмәтфаиз Даутов белән тарихчы, әдәбиятчы Габделбарый Баттал, китапханәче Мөбәрәк Әмировка урын булырга тиештер.

Өченче сәхифә Тукай вакытында аның иҗаты тәрбиясендә үскән кечеме-олымы шагыйрь-әдипләргә багышланырга мөмкин. Боларында Шәйхзадә Бабич, Сәйфи Кудаш, Давыт Юлтый, Сәгыйть Агиш, Фәүзия Рәхимкулова, Рәис Габдрахманов, Хәниф Кәрим һ.б. турында азмы-күпме мәгълүмат биреп булыр иде.

Дүртенче сәхифәдә егерменче-утызынчы елларыннан башлап бүгенге көнгәчә Башкортстан белән бәйле татар һәм башкорт әдипләренең иҗатына Тукай йогынтысы турында мәгълүматка, әдипләрнең бу зур чорда Тукайга кагылышлы иҗат өлгеләренә урын бирелә ала.

Бишенче сәхифәдә Башкортстанда Тукайның башкорт һәм җирле татар әдәбияты белән бәйләнеше турында үткән гасырның егерменче-утызынчы елларында ук дөнья күрә башлаган төрле характердагы мәкаләләр, башкорт язучылары һәм әдәбият белгечләренең бигрәк тә кырыгынчы-илленче еллардан башлап актив чыгышларына, 1966 елда Уфада башкорт телендә дөнья күргән «Тукай Башкортстанда» дигән җыентыкка, С.Г. Сафуанов кебек галимнәрнең хезмәтләренә бәйләнешле материаллар урын алырга мөмкин. Казанда һәм Уфада халык шагыйре иҗатына багышлап уздырылган гыйльми конференцияләрдә аның Башкортстан белән бәйләнеше турында докладларга да туктып булыр иде.

Алтынчы сәхифәдә хәзерге чорда Башкортстанда Тукайга бәйле материалларга игътибар үзәгендә тора ала. Җиденчесендә инде шагыйрьнең башкорт халкының бай һәм үзенчәлекле авыз-тел иҗатына карата кайнар мәхәббәтен күз уңында тотабыз. Монда Тукайның халык авыз иҗатына мөнәсәбәте дә ачыклана ала.

Тукай образы, аның әсәрләренең Башкортстан сәхнәсендә сәхнәләштерелүе сигезенче сәхифәдә бирелә ала. Бу мәсьәлә әлегә ныклы өйрәнелүне сорый. Мемориаль бүлмәдә бар сәхифәләр Иске Уфа күренешләре һәм фотографияләре фонында стильләштерелә.

«Тукай Уфада» мемориаль кабинеты, шулай ук «Габдулла Тукай һәм Башкортстан» гыйльми проектында татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның Башкортстан белән бәйләнеше турында сүз алып барыла. Беренчедән, аның безнең якларга килүен, бу җирдән нинди тәэссоратлар алуын, башкорт халкының бай һәм үзенчәлекле авыз-тел иҗатына карата кайнар мәхәббәтен күз уңында тотыла. Икенчедән, аның халык гаме белән, азат тормыш, бәхет өчен көрәш пафосы белән сугарылган, югары шигъриятле иҗатының Башкортстан халыкларының рухи дөньясында нинди урын алуы, башкорт әдипләренең иҗади формалашуына һәм югары осталыкка ирешүенә нинди йогынты ясавы ачыкланаз. Өченчедән, башкорт һәм татар язучыларының, шагыйрьләренең, сәнгать осталарының, киңрәк алганда – мәктәп бабаларыннан алып киң

җәмәгатьчелекнең аңа олы рәхмәт тойгыларының ничек белдерүләрен, аның образын җанлы итеп сынландыруларын, бөек шагыйрьгә муафыйк шигъри һәйкәлгә нинди бизәк-детальләр өстәвен ачыклау кирәкле [2, с. 6].

«Тукай Уфада» мемориаль (уку-укыту методик) бүлмәсе М. Акмулла исемендәге БДПУ өчен милли мәдәният казанышларын пропагандалауда һәм профориентацион эштә имиджлы әһәмияткә ия булачак.

Төп нәтиҗәләре:

– фәнни-тикшеренү, мәдәни-агарту эшен оештыру (конференцияләр оештыру, җыентыклар чыгару, мәкаләләр бастыру).

– Габдулла Тукай иҗаты, башка күренекле милли әдипләр иҗаты исәбенә яңа темалар буенча лекторийлар, әңгәмәләр тематикасын киңәйтү һ.б.;

– төрле дәрәҗәдәге (республика, регионара, россия, халыкара) мәдәни чаралар һәм акцияләр оештыру.

«Тукай Уфада» мемориаль кабинеты музей ролен башкарудан бигрәк, уку-укыту тәрбияви максатта күзаллана торган проект. Бу проект буенча эш 2013 елдан башланса да, аны презентацияләү ике тапкыр 2014 елда уздырылды. Беренче тапкыр мәктәп балалары алдында 12 сентябрь М. Акмуллы исемендәге БДПУда Фән фестивале вакытында. Бу фестивальне Бөтенроссия фән фестивале кыссаларында Башкортстан Республикасы Фәннәр Академиясе һәм Башкортстан Республикасы Фәнгә ярдәм һәм үсеш фонды берлектә оештырган иде. Икенче тапкыр мәктәп һәм вуз, ссуз укытучылары, мәгариф җитәкчеләре һәм җаваплы хезмәткәрләре алдында 2 декабрьдә Татар теле һәм әдәбияты укытучыларының Регионара конференциясе вакытында Башкортстан Республикасы мәгариф министрлыгы, Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы М. Акмуллы исемендәге БДПУда оештырды. Анда Башкортстан Республикасы мәгариф министры Ә.С. Гаязов, Татарстан Республикасы премьер министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры Э.В. Фәттәхов катнашты.

Бүгенге көндә «Тукай Уфада» мемориаль кабинеты тулысынча үз вазыйфаларын уку-укыту һәм тәрбияви максатта үти. М. Акмуллы исемендәге БДПУның филологик белем бирү һәм мәдәниарадаш коммуникацияләр институтында татар теле һәм әдәбияты кафедрасы оештырган барлык чаралар да бу кабинетта уза, яисә анда башланып китә. Көндәлек расписание буенча уздырылган дәресләрдән тыш, кабинетта махсус дәресләр, студентларның «Чаткылар» иҗат түгәрәге утырышлары, түгәрәк өстәлләр еш була.

Гомүмән алганда, «Тукай Уфада» мемориаль (уку-укыту методик) бүлмәсе Габдулла Тукай иҗатын пропагандалауга, аның халыклар әдәбияты үсешенә, шул исәптән башкорт әдәбияты үсешенә әһәмиятле йогынтысын күрсәтүгә, татар әдәбияты тарихы, Башкортстан халыклары мәдәнияте буенча программ материалларныүтемле үзләштерүгә ярдәм итәрдәй, халыклар әдәбияты традицияләрендә күчемлелек, әдәбиятлар һәм мәдәниятләр үзара йогынтысы һәм бәйләнешләре мәсьәләләрен чагылдыруга, хәзерге заман яшьләрендә туган телгә, халыклар дуслыгына сакчыл карау кебек иң күркәм сыйфатлар тәрбияләүгә, фәнни-тикшеренү эш алымнарын үзәштерүгә хезмәт итәчәк. Шулай булгач «Гадулла Тукай һәм Башкортстан» фәнни-тикшеренү проекты зур әһәмияткә ия.

ӘДӘБИЯТ


1. Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни бәйләнешләр: Габдулла Тукайның тууына 125 ел тулуга багышланган Халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары (25 апрель, 2011 ел). Казан: Г. Ибраһимов исем. ТӘСИ, 2011. 315 б.

2. Сафуанов С.Г. Габдулла Тукай и Башкортостан: Учеб. пособие по курсу «Татарское литературное краеведение Башкортостана». Уфа: Изд-во БГПУ, 2005. 49 с.


## ТУКАЙНЫҢ ШИГЪРИ ВАТАНЫ – ҖАЕК


***Насыйбуллина Н.Ш.***



В статье освещаются связь татарского народного поэта Тукая с Уральском по нескольким аспектам: пребывание Тукая в Уральске; влияние Мотигуллы и Камиля Тухватуллиных на развитие будущего великого поэта, наследие Тукая в наше время.

An article highlights the relationship of the Tatar national poet G. Tukay with the Ural on several aspects: stay Tukay in Uralsk; the influence of Motigulla and Kamil Tukhvatullins on the development of the future great poet, the legacy of Tukay in our time.

Иң борынгы тарихи шәһәрләрдән саналган Җаек (Уральск, Орал) Көнбатыш Казахстан өлкәсенең административ үзәге, Каспий буе түбәнлегенең төньяк өлешендә Җаек (Урал) елгасы буена урнашкан. Шәһәр тарих битләренә Емельян Пугачёв, Александр Суворов, Александр Гумбольдт, Петр Паллас, Иван Крылов, Гавриил Державин, Александр Пушкин, Владимир Даль, Василий Жуковский, Тарас Шевченко, Александр Алябьев, Лев Толстой, Аркадий Столыпин, Федор Шаляпин, Владимир Короленко, Габдулла Тукай, Габдулла Кариев, Нәҗип Җиһанов, Камил Мотыгый, Галия Кайбицкая, Сәлим Айткулов исемнәре аркылы кереп калган.

Татар милләте өчен Җаек үтә дә кадерле санала. Чөнк ул Бөек Тукайның яшьлек эзләрен саклый. Тукай яшәгән йорт, Тукай хезмәт иткән типография, аның исеме белән бәйле урыннар күп монда. Габдулланың җизнәсе – Галиәсгар Госмановның Почиталин урамындагы асты таш, өсте агач булган ике катлы йорты, Орджоникидзе урамындагы Мотыйгулла Төхфәтуллинның ике катлы таш йорты, сул якта – Тукай эшләгән типография, бала чак эзләрен саклаган Җаек елгасы ярлары, «Мотыйгыя» мәдрәсәсеннән якындагы гына агып яткан, Тукай су кергән Чаган елгасы, Тукай беренче мәртәбә маевкада катнашкан «Хан әрәмәлеге» дип аталган җирләр – барысы да безнең көннәргә кадәр шагыйрьнең якты истәлеген саклаганнар. Булачак шагыйрьнең тормышка карашы, фикерләре дә нәкъ биредә формлашкан. 1895 елның кышында 18 көнле юлдан соң тугыз яшьлек Апушны Җаек шәһәрендәге татар бистәсенә сәүдәгәр Усманов Галиәскәр һәм аның хатыны Газизә йортына алып киләләр. Галиәскәр вафат булганнан соң Тукай «Мотыйгыя» мәдрәсәсенә күчә. Мәдрәсәне нигезләүче Җаек ахуны Мотыйгулла хәзрәт Төхфәтуллин – татарларның күренекле дин эшлеклесе Габдулла Тукайның остазы була. Ул 1846 елда Зөя өязе Кече Кайбыч авылында мулла гаиләсендә туа. Башта үз авыл мәдрәсәсендә белем ала, соңрак Кышкар мәдрәсәсенә укырга җибәрелә, анда Кушлавыч авылыннан Мөхәммәтгариф (Тукайның әтисе) белән таныша. Кышкар мәдрәсәсеннән соң 1867 елда Мисырдагы Каһирә шәһәренә Әл-Әзхәр университетына җибәрелә. 1877 елда туган ягы Кайбычка кайтырга чыга һәм юлда апасы Газизә янына Җаекка керә. Җирле татарлар аның белемен күреп Түбән Оч мәхәлләсенә мулла булып калырга үгетлиләр. Җаекта өйләнә һәм хатыны Газзиназ белән җиде бала тәрбияләп үстерәләр. Тукайның әтисе Мөхәммәтгариф хөрмәтенә бер баласына аның исемен куша. Сабакташы Мөхәммәтгарифнең үлүен ишетү белән Тукайны үз янына алдыра. Югары белемле, алдынгы карашлы, бай китапханәгә ия булган Мотыйгулла Төхфәтуллин мәдрәсәдә фәлсәфә, астрономия фәннәре буенча дәресләр бирә, Тукай монда Омар Хәйям, Фирдәүси һәм башка данлыклы шәрык шагыйрьләренең иҗатлары белән таныша. «Мотыйгыя» мәдрәсәсе каршында эшләп килгән рус мәктәбендә Габдулла Пушкин һәм Лермонтов иҗаты белән мавыгып китә. Нәкъ монда Тукайның рус һәм чит ил әдәбиятына мәһәббәте кабына. Остазы Габдуллада шагыйрьлек көче сизә, аның беренче тәҗрибәләрен хуплый. Каһирәдә укып кайткан улы Камилгә Тукайның бик сәләтле булуын сөйли. Яңалыкка, яктылыкка омтылучы; артта калганлыкка ихлас күңеле белән нәфрәтләнүче Камил Мотыйгый яшь Тукайга көчле тәэсир ясый. 1905 елдагы революцион күтәрелү чоры Камилгә «Фикер» гәҗите, «Уклар», «Әлгасрелҗәдид» һәм «Новый век» журналын бастырырга мөмкинлек тудыра. Габдулла өчен бу басмалар шигырьләре, мәкаләләре дөньяга чыгу мәйданы булып хезмәт итә. Камил Төхфәтуллин ярдәме белән Тукай шигырьләре киң җәмәгатьчелеккә чыга. Камил Мотыйгый, типографиянең рәсми хуҗасы һәм нашире буларак, социал-демократлар оешмасы белән тыгыз элемтә тота. Рус һәм татар телләрендә прогрессив газета-журналлар чыгара, революцион листовкалар бастыра. «Уралец» исемле басмада Тукай русча тәрҗемә итү буенча да тәҗрибә туплый. Сталин урамы белән Коммунистлар урамы кисешкән урында зур, ак бина әле дә исән. Бу элекке типография бинасында бүгенге көндә – шәһәр типографиясе урнашкан. Хәзер анда ике өлкә газетасы – «Октябрь туы» (казах телендә) һәм «Приуральская правда» (рус телендә) басыла. Ленин урамында элеккеге коммерция банкы бинасы да үзенә җәлеп итә. Кайчандыр бу йортның подвалында «Фикер», «Әлгасрел-җәдид», «Уклар» нәшер ителгән. Шунысы кызганыч, хәзер Габдулла Тукайны белгән, аның белән аралашкан кешеләр Җаекта калмаган. Шулай ук яшь шагыйрь хәреф җыйган басу машинасы да сакланмаган.

Мотыйгулла хәлфәнең хатыны да Гыйззиназ утыз елдан артык мәдрәсәдә хатын-кызлар укыта. Ул татар дөньясында беренче булып хатын-кызлар хорын оештыра. Кечкенә кызы Галия (Кайбицкая) шул хорның танылган башкаручысына әверелә. Гаиләнең бай традицияләре булачак җырчыга тормыш һәм иҗат юлын билгеләүдә зур роль уйный. 15 яшьлек Галия Жаекта 1921 елларда Әдһәм Кайбицкий һәм Хәмит Төхфәтуллиннар тарафыннан оештырылган татар театр труппасы спектакльләрендә катнаша. Казан театр техникумына укырга керә. Шул ук вакытта татар драма театрында музыкаль спектакльләрдә рольләрне оста башкара. Тирән белемгә омтылышы аны Көнчыгыш музыка техникумына китерә. Ул елларда татар театр мәдәниятенең күренекле эшлеклеләре – К. Тинчурин, С. Сәйдәшев, С. Габәши, М. Фәйзи, Х. Әбҗәлилов, Ф. Ильская, Г. Болгарская һ.б. белән аралашу Г. Кайбицкаяның иҗади яктан үсүенә зур йогынты ясый.

1934 елда Г. Кайбицкая Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясенә укырга җибәрелә, 1939 елда ачылган Татар опера театрының төп җырчысына әверелә, татар опера сәнгатенең үз традицияләрен булдыруда армый-талмый илһамланып эшли. 1940–50 елларда опера театры сәхнәсендә Г. Кайбицкая барлык татар опера һәм музыкаль комедияләрендә диярлек төп партияләрне («Алтынчәч» операсында Алтынчәч, «Наемщик»та Гөлйөзем, «Башмагым»да Сәрвәр, Галиябануны шул исемдәге операда, «Качкын»да Рәйханә, «Түләк» операсында Сусылу һ.б.) зур осталык белән башкара. Рус һәм чит ил операларында бик тә катлаулы партияләрне башкаруы («Риголетто»да Джильда, «Травиата»да Виолетта, «Фауст»та Маргарита, «Патша кәләше»ндә Марфа, «Кар кызы»нда Кар кызы) җырчының зур таланты, осталыгы турында сөйли. Сирәк очрый торган табигый сәләте, яңгыравыклы ягымлы тавышы белән Г.Кайбицкая башкару осталыгы белән тыңлаучылар арасында киң танылa, Татарстанның халык артисты исеменә лаек була.

Шулай ук милли театрның нигез ташларын салучыларның берсе Габдулла Кариев та (Миңлебай Хайруллин) җырчы, сүз остасы, мәзәкче буларак Җаекта танылу ала. Ул чыгышы белән Татарстанның Норлат районы Күлбай Мораса авылыннан. 1904 елда Җаек шәһәренә укырга килә, татар халык шагыйре Г. Тукай һәм күренекле җырчы, җәмәгать эшлеклесе Камил Мотыйгый (Төхфәтуллин) белән очраша һәм алар якын дуслар, фикердәшләр булып китәләр. Г. Кариев тормышын тулысы белән татар халкының мәдәниятен, сәнгатен үстерүгә багышлый.

Казан консерваториясен ачуда зур көч куеп һәм озак еллар әлеге югары музыкаль белем бирүче уку йортын җитәкләүче, шуның белән татар сәнгатенә ифрат дәрәҗәдә зур өлеш кертүче классик композитор Нәҗип Җиһанов та Җаекта туа. Биредә яшәүче милләттәшләребез әлеге шәхесләрне олы ихтирам белән искә алалар, дөньяның төрле кыйтгаларында яшәүче галимнәр, әдәбият һәм тел белгечләре, язучылары, артистлар, журналистлар, җәмәгать эшлеклеләре, иҗтимагый оешма вәкилләре, яшьләр белән конференцияләр, әдәби кичәләр оештыралар.

Уральскийдагы Г. Тукай исемендәге Евразия үзәге җитәкчесе профессор Абдеразак Абдрахман улы Әбүзәров тырышлыгы белән М. Үтәмесов исемендәге Көнбатыш Казах дәүләт университетында халкыбызның бөек шагыйре Тукайга багышлап алты тапкыр халыкара фәнни-гамәли конференция уздырылган. Абдеразак Абдрахман улы чыгышы белән Кытай чигендәге Андреев районының Лепсинск авылыннан (Әтисе Абдрахман белән әнисе Минсафаның әби-бабалары бу якларга Омски шәһәре тирәсендәге Серебрякова авылыннан 1860 елларда күченеп килеп төпләнеп калалар). Педагогия училищесын тәмамлагач, әти-әнисе аны Алмата шәһәренә укырга җибәрә. Башкалада ул рус теле белгечлегенә укый. Тел белгече һәм укыту эшләре алып бару белән генә чикләнеп калмый милләттәшебез, тарих белән дә кызыксына, аеруча төбәк тарихына игътибар юнәлтә. Гыйльми хезмәтләре арасында Тукай тормышы һәм иҗатына багышланган «Уральск – поэтическая родина Тукая», «Уральск в судьбе Тукая», «Творчество Тукая в контексте Евразийской культуры» исемле китаплары да дөнья күрә. Тынгысыз хезмәт нәтиҗәсендә ул 1995 елның 23 декаберендә Уральскида Г. Тукай үзәген оештыра. Аның тырышлыгы белән биредә шагыйрьгә 2001 елның 30 октябрендә һәйкәл-бюст куела (скульпторы М.М. Гасимов, архитекторлары С.С. Айдаров, А.М. Галеев, Р.А. Вафеев), бик зур матди чыгымнар таләп иткән күпъеллык катлаулы эш нәтиҗәсендә җимерек хәлдәге Мотыйгулла хәзрәт Төхвәтуллин яшәгән йорт реставрацияләнә һәм шул йортта Тукайга музей ачыла, аның директоры итеп Марат

Рафаэль улы Баһаутдинов билгеләнә. Тукай музеенда яшь шагыйрьнең эзләрен саклаган баскыч та сакланган. Мотыйгулла хәзрәтнең оныкчыгы танылган рәссам Ильяс Айдаровның иҗат җимешләренә дә урын түрдән бирелгән.

Нәтиҗәле эшләрнең дәвамы булып Татар бистәсендәге 1871 елны төзелгән Кызыл мәчет тә реставрацияләнә. Шунысын да билгеләп узу кирәк – бу Аллаһ йорты Җаекның иң иске мәчете булып санала. 2006 елга кадәр ташландык хәлдә булган мәчетне татар эшмәкәре Ришат Хәйруллин шәһәр күркенә әверелдерә. Заманында татарлар өчен сыенер урын булган Кызыл мәчетне аякка бастырырга кирәклеген васыять итеп улына әнисе калдыра. Ришат әфәнде әнисенең васыятен үти. Татар тормышында тирән эз калдырган атаклы мөгаллим Мотыйгулла хәзрәт Төхфәтуллин исеме белән бәйле Аллаһ йорты тарихи сәхифәләрне үз эченә алган. Фаҗигале рәвештә гомере өзелгән мөгаллимне Кызыл мәчет янына җирлиләр. Совет хакимияте еллары вакытында биредә тулай торак була, Мотыйгулла хәзрәтнең кабере ташландык бер хәлгә килә. Аның кызы атаклы җырчы Галия Кайбицкая атасының җәсәден зиратка күчертә. «Без һәрвакыт Мотыйгулла хәзрәткә дога кылабыз. Җаекта аның бик тә танылган, зыялы мөгаллим булуын татарлар гына түгел, казахлар да яхшы белә», – ди мәчетнең имам-хатыйбы Әйхан хәзрәт. Казахлар Мотыйгулла хәзрәт турында сөйләгәндә, татарның бөек әдибе Тукайның беренче Коръән аятьләрен өйрәнүе турында телгә алалар.

Бүген Җаекта милләттәшләребезне бергә туплап торучы урын – Татар иҗтимагый үзәге һәм әдип исемендәге музей. Бу йортта казахлар яшәгән, инде кайберәүләр бүлмәләрен хосусыйлаштырган да булган. Әмма милләттәшләребез Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиевкә хат юллаганнар. Өлкә акимәте (губернаторы) Н.А. Назарбаев указы нигезендә биредә яшәгән казахларга фатирлар бирелгән. Ә бинаны яңадан аякка бастыруны Ришат Хәйруллин үз канаты астына алган. Музей төзү эшен җиң сызганып башлаучы Көнбатыш Казахстан дәүләт университеты профессоры Разак Әбүзәров. Ул бөтен булмышы белән Тукай мирасын торгызу өчен янып-көеп яши. Кайчандыр Тукай урамын Пролетарскийга үзгәрткән булалар. Шагыйрьнең исемен кайтару өчен шактый ишекләрне шакырга, хәйран гына бусагалар таптарга туры килә. Аның арбасына милләтпәрвәр татарлар да утыра. Музейны да торгызалар, үзәкне дә җанландырып җибәрәләр, Тукай мирасын халыкка җиткерү максатыннан төрле чаралар оештыралар. Мондый күркәм чараларның әһәмияте глобаль мәсьәләләрне чишүгә, делегатларның үзара очрашуына, аралашу вакытында тәҗрибә уртаклашуга, уртак планнар коруга булыша.

ӘДӘБИЯТ

1. Абузяров Р.А., Туаева З.И. Уральск в судьбе Габдуллы Тукая. Уральск: РИО ЗКГУ. 2002. 128 с.
2. Абузяров Р.А. История Евразийского центра Г. Тукая. Уральск: РИО ЗКГУ. 2012. 209 с.

## ТУКАЙ ЯДКЯРЛӘРЕ – ХАЛКЫБЫЗ МИРАСЫ

***Нәгыймуллина Р.В.***

В центре внимания статьи – бесценные реликвии Г. Тукая, хранящиеся в литературном музее поэта. Освещаются также проблемы поиска экспонатов для новой экспозиции.

In the spotlight of arctics there are – Gabdulla Tukay's priceless relics that are kept in poet's literature museum and the problem of searching for new exhibits for new exhibitions

Быел халкыбыз үзенең сөекле шагыйре Г. Тукайның 130 еллыгын билгеләп үтә. Тукай – үзе исән чагында ук кыю фикере, үткен теле белән халык күңелен яулаган шәхес. Замандашы, күренекле әдип Фатих Әмирхан әйтүенчә: «...Аны халык бик яшьләй үз шагыйре итеп таныды; аны аңлады, ул җырлаган нәрсәләрнең үз рухындагы нәрсәләр икәнен тойды. Шәхси тормыштан мәхрүм Тукаев үзенең шигырьләре, ул шигырьләрнең халык күңелендә яңгыраткан яңгырашы белән генә яшәде, шул гына аңа тормыш иде...» [3, б. 144].

Татарстан Республикасында Тукай исемен мәңгеләштерү максатыннан һәйкәлләр салынды, аның исеме белән урамнар һәм мәйданнар аталды. Казанның үзәген биләп торган Иске татар бистәсенең Тукай урамында да шагыйрьне халыкка танытуга хезмәт

итә торган бина бар. Бу – Габдулла Тукай әдәби музее урнашкан йорт. Аны XIX гасыр ахырында беренче дәрәҗәле татар сәүдәгәре Ибраһим Апаков кызына бирнә итеп салдырган. Кызы Бибимәрьямбану исә Кавказ халыкларының бәйсезлеге өчен көрәшен җитәкләүче имам Шамилнең уртанчы улы генерал Мөхәммәтшәфигә кияүгә чыгып 1906 нчы елга кадәр биредә яши. Шунлыктан, халык телендә, бу йорт Шамил йорты дип тә йөртелә.

Габдулла Тукайның бу бинада булуы турында төгәл мәгълүмат юк. Әмма ул вакытларда байлар өйләрендә әдәби-музыкаль кичәләр уздырырга яратканнар. Анда шагыйрьләр, музыкантлар, җырчылар чакырылган. Алар арасында Тукайның да булуы ихтимал. Һәрхәлдә, ул әлеге йорт тирәсеннән үтеп йөргән. Янәшәдәге Мәйдан бакчасында ял иткән, дуслары белән очрашкан, ялгызы гына уйланып утырган... Казан халкы сөекле шагыйрен соңгы юлга да Юнысов мәйданыннан озатып калган. Мәйданның бер өлешендә «Ялт-Йолт» сатирик журналы чыккан. 1910–1913 елларда биредә Тукай сәркатиплек иткән.

Тукай урамының (элекке Екатерининская) 63 нче номерлы йортында иҗтимагый-сәяси һәм әдәби мәсьәләләрне чагылдырган «Әл-Ислах» газетасы чыккан. Шагыйрь анда дуслары Ф. Әмирхан, И. Әмирхан, В. Бәхтияров һәм К. Бәкер белән бергәләп хезмәт иткән. Московская һәм Татарстан (элеккеге Евангелистлар) урамнары киселешендә урнашкан «Болгар» номерларының кырыгынчы бүлмәсендә яшәгән, гомеренең соңгы айларын «Амур» кунакханәсендә уздырган. Якында гына Тукайны атаклы «Печән базары, Яхут яңа Кисекбаш» сатирик поэмасын язарга этәргән Печән базары гөрләп торган. Музейдан ерак түгел урында читекче Сабитовлар тоткан йорт сакланган. Биредә «Шәрык клубы»нда татар яшьләре кичәләр уздырган. 1910 елда Тукай да монда үзенең «Халык әдәбияты» лекциясен укыган һәм рухланып: «Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул...» [2, б. 26] дип белдергән.

Узган гасырның илленче елларыннан Г. Тукайның иҗатын саклау һәм киләчәк буыннарга җиткерү нисбәтеннән аның тормышы, иҗаты белән бәйле экспонатлар җыю башланып китә. Җаек шәһәре, Уфа, Оренбург, Петербург һәм шагыйрь яшәгән башка җирләргә экспедицияләр оештырыла. Шактый сандагы көнкүреш әйберләре, китаплар, документлар табыла. Шушы тупланмалардан, 1986 елда, шагыйрьнең тууына 100 ел тулу уңаеннан Г. Тукай музее ачыла.

Шагыйрь балачагыннан ук йорттан-йортка йөреп тәрбияләнгән, «зуп-зур Тукай» булгач та төрле кунакханәләрдә яшәгән. Өй төзергә дә, гаилә корырга да өлгермәгән. Шуңадыр, шәхси әйберләре бик аз сакланып калган. Шагыйрьнең кул җылысын саклаган кадерле ядкярләр Г. Тукайның Казандагы музеенда күренекле урынны алып тора.

Казахстанның Җаек шәһәрендә Тукай беренче тапкыр кулына каләм ала һәм тора-бара «Уралец» типографиясендә, «Әл-гасрел җәдид» газетасы, «Уклар» сатирик журналында хезмәттәшлек итә. Беренче хезмәт хакы алгач та ул фаянс тартмачык сатып ала һәм бердәнбер апасы Газизәгә бүләк итә. Агач төбе формасында эшләнгән тартмачыкның тышына төшерелгән урман күренешләре аларга, мөгаен, туган якларын хәтерләткәндер. Музейга аны Газизәнең улы Хөсәен Зәбиров тапшыра. Ә көмеш җиң каптырмаларын шагыйрьгә «Аң» журналында бергә эшләгән хезмәттәшләре Хәсәниләр нәшрият эшләре белән Германия, Австрия илләренә сәяхәтләре вакытында алып кайталар. Аларны музейга рәссам Альфред Низаметдинов тапшыра.

1908 елда Шәрәфләр матбагасында Тукайның шигырьләр җыентыгы басылуга хәзерләнә. Китапка шагыйрьнең рәсемен дә урнаштырырга кирәк була. Гыйльметдин Шәрәф Тукайны С.И. Иванов фотоостаханәсенә алып бара. Тукайның озын чәчләреннән кыенсынып торуын күргәч, кесәсеннән кара вельвет түбәтәй алып бирә. Габдулла Тукайның сәяхәтләре вакытында аерылгысыз юлдашы булган, камыштан үреп эшләнгән юл кәрзине дә экспозициянең түрендә саклана. Җаектан Казанга кайтыр алдыннан сатып алынган бу кәрзингә Тукайның бөтен мөлкәте сыйган. Шагыйрьнең вафатыннан соң кәрзин Маһруй Мозаффариянләрдә саклана. Аның кияве Әхмәт Урманчиев белән бергәләп Тукай 1910 елда «Ялт-Йолт» сатирик журналын оештырып җибәргән һәм анда җаваплы сәркатип вазыйфасын башкарган була. Музейга кәрзин М. Мозаффариянең улы композитор Мансур Мозаффаров аркылы килеп керә.

Петербургка сәяхәте вакытында Тукай үз-үзенә бүләк ясый: бик нәфис итеп кургаштан коелган карандаш савыты сатып ала. Петербургның дымлы һавасыннан Тукайның үпкә авыруы көчәя, аңа күбрәк урын өстендә ятарга туры килә. Шагыйрьнең хәлен

белергә килгән курсисткалар аңа ау күренешен тасвирлаган кара савыты бүләк итеп калдыралар. Ядкярләрнең соңгысы Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана.

Экспонатлар туплау бүгенге көннәрдә дә дәвам итә. Соңгы егерме биш ел эчендә шагыйрь даирәсеннән К. Мотыйгыйның бай архивы, Тукай китапларын нашир итүче бертуган Шәрәфләр гаиләсеннән сакланып калган көнкүреш кирәк яраклары, сөйгәне Зәйтүнә Мәүлүдованың шәхси әйберләре һәм башка экспонатлар музейны тагын да баеттылар.

Соңгы көннәрдә музей үзгәреш алдында тора. Бинага капиталь ремонт ясалып, экспозиция дә яңартылачак. Әлбәттә, яңа экспонатлар туплау да дәвам итә. Музей хезмәткәрләре Иске татар бистәсе тирәсендә яшәгән кешеләр белән аралаша, Тукай яшәгән авылларга сәяхәт оештыра. Тукай чорында яшәгән өлкәннәребез аркылы шагыйрь тормышы һәм иҗаты белән бәйле әйберләр табыла. Шундыйлардан Тукай дип җан атучы галимнәребездән Рәмзи Вәлиев музейга Тукай кулланган чынаяк һәм балкашык бирергә әзер. Алар аңа Шәһәр Шәрәфнең кызы Сания апа Шәрәф аркылы кергән. Күренекле язучы Рабит Батулла шагыйрьнең Клячкинда үләр алдыннан дуслары төшергән фотосыннан алынган открытканы тапшырды.

Халкыбызның яраткан шагыйре Габдулла Тукай әдәби музееи тагы да бай итеп күрәсе килә. Бары тик бергәләп кайгыртсак кына, кыйммәтле мирасны саклый алырбыз һәм киләчәк буыннарга да җиткерербез.

ӘДӘБИЯТ

1. Нәгыймуллина Р. Кыйммәтле ядкярләр // Шәһри Казан. 1913. 12 ноябрь.
2. Тукай Г. Әсәрләр. 4 томда, 2 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1955. 376 б.
3. Тукай Г. Фотоальбом. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 304 б.
4. Ядкярләрдә Тукай рухы: Татарстан Республикасы Милли музее җыелмасында татар халык шагыйре Габдулла Тукайның мемориаль тупланмасы каталогы. Казан: Заман – Татар. кит. нәшр., 2012. 144 б.

## Ғ. ТУҠАЙ ӘҪӘРҘӘРЕНЕҢ ТӘҮГЕ ТУЛЫ БАҪМАҺЫ ТУРАҺЫНДА БЕР НИСӘ ҺҮҘ

***Нәҙерғолов М.Х.***

В 2014 году археографической экспедицией Института истории, языка и литературы Уфимского научного центра Российской академии наук в башкирской деревне Абдрашитово Дуванского района Республики Башкортостан была обнаружена и приобретена книга великого татарского поэта Г. Тукая, которая была издана год спустя после его смерти. Состояние книги отчетливо указывают на то, что она была популярной и любимой среди сельчан. В ней содержатся и записи поэта по башкирскому фольклору.

In 2014, the archaeographic expedition of the Institute of history, language and literature Ufa scientific center, Russian Academy of Sciences in the Bashkir village Abdrashitova Duvanskij district of the Republic of Bashkortostan found the book of the great Tatar poet G. Tukay, which was published a year after his death. The condition of the book clearly shows that she was popular and loved among the villagers. It contains entries of Bashkir folklore.

2014 йылдың июнь аҙаҡтары – июль баштарында Рәсәй фәндәр академияһы Өфө ғилми үҙәге Тарих, тел һәм әҙәбиәт институтының бер төркөм ғилми хеҙмәткәрҙәре Рәсәй гуманитар ғилми фондының гранты иҫәбенә Башҡортостандың төньяҡ-көнсығыш төбәгендә урынлашҡан Дыуан һәм Салауат райондарына археографик экспедицияға барып ҡайтты. Ошо юлдарҙың авторы ла ҡатнашҡан был экспедицияның төп маҡсаты урындағы халыҡта һаҡланған боронғо ҡулъяҙма һәм баҫма китаптарҙы өйрәнеү һәм йыйыу, эпиграфик ҡомартҡыларҙы, йәғни иҫке ҡәбер таштарындағы яҙмаларҙы, тикшереү һәм халыҡтың ауыҙ-тел ижады үрнәктәрен яҙып алыу ине. Бәхетебеҙгә күрә, ҡуйған маҡсатыбыҙға тулыһынса ирештек: ауылдарҙа ғәрәп яҙмаһындағы боронғо ҡомартҡыларҙы һаҡлаған кешеләр әле лә байтаҡ икән, төбәк эпиграфик сығанаҡтарға ла бай, халыҡтың әкиәттәрен, мәҡәл һәм әйтемдәрен, бәйет һәм мөнәжәттәрен хәтерҙәрендә һаҡлаған оло быуын кешеләре лә сәфәребеҙҙә күп осраны беҙгә.

Экспедицияның ҡыҙыҡлы табыштары тураһында бик күп һөйләргә мөмкин. Был осраҡта мин уҡыусының иғтибарын шуларҙың береһенә генә йүнәлтмәк булам.

Дыуан районы Әбдрәшит ауылында йәшәүсе ил инәһе Фәхриева Роза Әхтәмйән ҡыҙы (1936 йылда тыуған) институттың Ҡулъяҙмалар һәм иҫке китаптар фондына ике тиҫтәгә яҡын боронғо китап һәм ҡулъяҙма бүләк итте. Шулар араһында күп уҡылыуҙан таушалып, йыртылып бөткән, башы ла, аҙағы ла булмаған, яһалма тышлы, ярайһы уҡ ҡалын ғына бер китап та бар ине.

Һаҡланып ҡалған тәүге биттәрен асып ҡарағас та был ҡомартҡының татар халҡының мәшһүр шағиры Ғабдулла Туҡайға мөнәсәбәтле икәнлеге шәйләнде. Уның иҫән ҡалған беренсе биттәрендә шағирҙың ҡаты ауырыуҙан һуң 2 апрель көнө (йылы күрһәтелгән бит һаҡланмаған) киске сәғәт 8 тирәһендә вафат булып ҡалыуы хәбәр ителеп, ғүмеренең һуңғы мәлдәрендә ҡағыҙға төшөргән ике яҙмаһының (береһе «Васыятым» тип исемләнгән, икенсеһе «Толстой сүзе» тигән кәлимә менән башлана) копиялары бирелеүе асыҡланды. Шунда уҡ уның үлем түшәгендә ятҡан килеш төшөрөлгән фотосүрәте лә урын алған. Артабан «Туҡаевның шиғырлары хаҡында мөләхәзәләр (фекерҙәр)» тигән баш аҫтында шағир ижадына ярайһы уҡ иркен генә байҡау яһалған һәм «Туҡаев туғрысында матбуғат» исеме менән заманындағы ҡайһы бер гәзит-журналдарға күҙәтеү үткәрелгән. Әммә экспедиция ваҡытында был юлдарҙың авторы кем булғанлығын асыҡлап булманы, сөнки ул биттәр һаҡланып ҡалмаған ине.

Китаптың ҡалған иң ҙур өлөшөн шағирҙың ижад емештәре алып тора. Улар «Ғабдулла Туҡай мәжмүғә-и аҫары (әҫәрҙәренең йыйынтығы)» тигән баш аҫтында бирелгән. Йыйынтыҡты төҙөүсе шағирҙың әҫәрҙәрен бер нисә төркөмгә бүлгән: улар «Етди шиғырлар», «Көлкөлө вә һөжү (сатира)», «Балалар ҡисымы (бүлеге)», «Халыҡ моңлары» һәм «Нәҫер ҡисымы» тип исемләнгән. Һуңғыһында Ғ. Туҡайҙың баласаҡ хәтирәләре лә бирелгән. Әҙиптең атаҡлы «Шүрәле» поэмаһы иһә үҙе айырым бүлексәне тәшкил итә.

Экспедиция мәлендә фәҡәт бына ошо мәсьәләләрҙе генә асыҡлап булды.

Институтҡа ҡайтҡас, был яҙма ҡомартҡыға диҡҡәт итеүем юҡҡа ғына булмағанлығына тағы ла ныҡыраҡ инандым. Баҡтиһәң, әлеге табышыбыҙ, шағир мәрхүм булғас, 1914 йылда донъя күргән китап икән. Уны заманында танылған әҙәбиәтсе ғалим Ямалетдин Вәлидов (Я. Вәлиди) әҙерләп сығарған. Йыйынтыҡҡа инеш һүҙ ҙә уның тарафынан яҙылған. Китаптың дөйөм күләме 464 бит булып, ул Ҡазандың «Мәғариф» матбағаһында 5 мең данала нәшер ителгән. Күренекле татар әҙәбиәтсеһе профессор Мөхәммәт Ғәйнуллин үҙенең «XX быуат башындағы татар әҙәбиәте һәм публицистикаһы» тигән рус телендә сыҡҡан китабында (Ҡазан, 1983) был ҡомартҡыны Ғ. Туҡай әҫәрҙәренең шул замандарҙағы иң күләмле һәм тулы баҫмаһы, тип атап, Я. Вәлидовтың баш һүҙенә лә юғары баһа бирә.

Тимәк, әлеге китап бөйөк шағирҙың тормош юлы һәм ижады менән ҡыҙыҡһыныусылар өсөн бик ҡиммәтле сығанаҡ булып тора. Тик уға тейешенсә ентекле анализды һәм баһаны бөгөнгө хеҙмәттәрҙән табырлыҡ түгел. Ҡыҙғаныс хәл, әлбиттә.

Ғабдулла Туҡай китабының башҡорт ауылында табылыуына һис тә ғәжәпләнерлек түгел. Халҡыбыҙ күңеленә уның шиғырҙары үтә лә ятышлы һәм яҡын. Туған әҙәбиәтебеҙ менән бәйләнеше хаҡында бик күп һүҙҙәр күптән әйтелгән дә инде. Өҫтәп шуны ғына билдәләргә була: ҡабатланмаҫ ижадына илһамды Ғ. Туҡай башҡорт ерлегенән дә алған. Быны хатта әлеге йыйынтыҡ та раҫлай. Ундағы «Халыҡ моңлары» тигән бүлектә бирелгән йыр текстарының бер нисәһе үҙҙәренең йөкмәткеһе менән башҡорт ерҙәренә, Ағиҙел, Сәрмәсән һәм Ҡармасан буйҙарына туранан-тура бәйләнгән. Уларҙа башҡорт халыҡ йырҙарының рифма-ритмик системаһы ла теүәл сағыла. Миҫалға бер өҙөк:

Камчат та бүркең күтәр-күтәр,
Әйләнәсендән аның ел үтәр,
Бу донъялар шулай үтәр китәр,
Ҡауышып ҡалыуларға ни етәр.

Был строфала халҡыбыҙҙың милли баш кейеме һаналған ҡамсат бүрек телгә алыныуы ғына түгел, «ел», «етәр» һүҙҙәренең башҡорт теленә хас формала яҙылыуы ла ерле-юҡтан түгелдер. Йыр юлдарындағы йәнә бер өҙөккә иғтибар итәйек:

Аҡ чәчәккәй берлән ай Миләүшә
Гөл чәчәге берлән чеңләшә.
Үзем генә монда булған белән,
Күңелем жанкәй берлән сөйләшә.

Был дүртюллыҡтағы «чеңләшә» һүҙенә Я. Вәлидов, бит аҫтына төшөрөп, шундай аңлатма биреп киткән: «Чеңләшә» кәлимәсе (һүҙе) безнең бик иске лөғәтемез булырға кирәк. Ул русларның «лепечеть» дигән сүзләренә моҡабил (оҡшаш) түгел микән?» (345-се бит). Ә башҡорттарға иһә «сеңләү», «сеңләшеү» һүҙен һис кенә лә аңлатыу кәрәкмәй, халыҡ телендә ул әле лә актив ҡулланыла.

Әйткәндәй, Ғ. Туҡай үҙе 1910 йылда «Шүрәле» псевдонимы менән сығарған «Халыҡ моңлары» тигән китабына индергән «Ашҡаҙар көйө» тураһында түбәндәгеләрҙе яҙа: «Ғишыҡ вә мөхәббәт сәбәпле кияүгә барган бер башҡорт түрәсенең кияүе Ашҡазар дигән суның буйына ау ауларга китеп, шунда суга батып үлә. Моның вафат хәбәре мәғшуҡасына (һөйөклө ҡатынына) ишетелгәч, ул бик ҡайғыра. Хәсрәтен ничек изһар итәргә (күрһәтергә) дә аптырый. Бер көнне бу ҡыз, башҡорт ҡызлары арасындағы барча жырчы ҡызларны чаҡырып, алардан вафат булған кияүе хәтирәсенә бик моңлы бер көй чығаруларын үтенә. Әгәр дә күңеленә муафиҡ (ярашлы) бер моңлы көй чығара алсалар, аларға әллә ничә баш төйәләр һәдиә (бүләк) итмәкче була. Ҡызлар төрлечә көйләр чығарып ҡарыйлар, ләкин берсе дә түрә ҡызының күңеленә охшамыйлар. Бу жырчы ҡызлардан бер нәрсә дә чыҡмағач, түрә ҡызы, бер төрлө рух вә илһам белән рухланып, хәзерге «Ашҡазар көйө»н жырлап жибәрә. Жырчы ҡызлар хәйран ҡалалар…».

Әлбиттә, боронғо йырҙарҙың легендалары һәм риүәйәттәре халыҡ телендә төрлөсәрәк вариантта һәм төрлөсәрәк күләмдә йәшәгән. Берәүҙәрендә улар төп мотивтарында ҡыҫҡаса ғына һаҡланып ҡалған булһа, икенселәрендә йыр тарихына бәйле хәл-ваҡиғалар бәйнә-бәйнә хикәйәләнгән, хатта сәсмә текст йыр куплеттары менән тығыҙ үрелеп-аралашып килгән.

«Ашҡаҙар» йыры тарихының ҒабдуллаТуҡай күсермәһе нәҡ шул тәүгеләренә ҡарай ҙа инде. Унда, танылған ғалимәбеҙ, бик күп боронғо башҡорт йыр-риүәйәттәрен берәмтекләп-төпсөрләп йыйып, башҡорт телендә генә түгел, рус һәм инглиз телдәрендә лә донъяға сығарған Фәнүзә Айытбай ҡыҙы Нәҙершина әҙерләп баҫтырған вариант менән байтаҡ айырма бар. Унда, мәҫәлән, төп герой һәм персонаждарҙың исемдәре, сабыйлыҡ һәм йәшлек йылдары, Таңһылыу менән Йомағолдоң бер-берейһенә булған сикһеҙ мөхәббәте, никах туйҙары, Йомағолдоң аянһыслы һәләк булыуы, уны юҡһынып-зарығып һөйгәненең йыр сығарыуы, ахирәттәренә шуны йырлап ишеттергәндән һуң үҙе лә ташҡын һыуға ташланып йән биреүе бик ентекле бәйән ителә [был хаҡта ентекләберәк ҡара: 1, б. 212–214].

Нисек кенә булмаһын, бөйөк Туҡайҙың башҡорт йыр-моңдарынан да үҙенә күңел кинәнесе, ижад илһамы алғанлығын йәнә бер тапҡыр раҫлай. Халҡыбыҙҙың ижад емештәрен һәр саҡ яратып, һоҡланып, үҙ күреп, ҡайта-ҡайта уҡыған һәм тыңлағандыр, күрәһең.

ӘҘӘБИӘТ

1. Башҡорт халыҡ йырҙары, йыр-риүәйәттәре / Автор-төҙөүсеһе Ф.А. Нәҙершина. Өфө, 1997.

## СВОЕОБРАЗИЕ ТАТАРСКОЙ ПЕСНИ В ОРИГИНАЛЕ И ПЕРЕВОДЕ (в свете песенной концепции Г. Тукая)

***Нигматуллина Д.Э.***

Статья посвящена особенностям перевода татарских народных песен на русский язык.

The article is devoted to peculiarities of translation of tatar folk songs into Russian.

В последнее время после длительного затишья вновь отмечается интерес к вопросам перевода. И наибольшее внимание притягивает жанр песни, в котором особое место занимает народная песня.

В этой связи нельзя не коснуться взглядов такого знатока татарского фольклора, как Г. Тукай. Отдельные его наблюдения, мысли, отражённые в статьях и тексте лекции, выстраиваются в определенную песенную концепцию. Можно отметить её основные положения.

1. Песня – отражение народной жизни и души человека. Г. Тукай замечает, что татары очень быстро реагировали на события, происходящие в их жизни. И тут же

слагали стихи, песни, баиты. Но не просто описывали случившееся, а выражали своё отношение к этому [5, с. 266–268].

2. Смысловое несоответствие зачина основной части строфы песни. Тукая возмущает, что в большинстве своём песня начинается с ничего не значащей фразы, а лишь затем идут имеющие значение последние строки. Он упоминает о полном смысловом слиянии двух частей строфы, но лишь как об исключении.

Правда, он приходит к заключению, что зачин в песне выполняет служебную функцию – подготовку читателя к восприятию основной части песни.

3. Полнота информации при экономии средств в содержании и исполнении. Г. Тукай сетует на то, что зачастую песни утяжеляют ненужными именами, бессмысленными словами, тогда как песня должна быть лаконична и звучна. Интересны его замечания о специфике исполнения татарами песен: тихим голосом, похожим на звук музыкального инструмента, чуть приоткрыв рот. Собранность, ёмкость содержания и сдержанность в исполнении свидетельствует о глубинной эмоциональности татарского народа [5, с. 268, 277–278].

4. Трудность перевода татарских песен на другие языки. Г. Тукай указывает на то, что народные песни со всеми несуразностями и недочётами дороги лишь самому народу, что в переводе на другие языки, в частности на русский, песни выходят бессмысленными или даже смешными [5, с. 269].

Опираясь на высказывания Тукая о своеобразии песен и песенной культуры татарского народа, я хотела бы выразить свои соображения относительно перевода татарских народных песен на русский язык (ограничусь собственным опытом перевода).

По степени несогласованности двух частей татарские песни можно разделить на несколько групп. В зависимости от того, насколько эти части разобщены или слиты, переводчик выбирает способы и средства переложения оригинала на переводимый язык.

Первую группу составляют песни, в которых смысловая связь между частями отсутствует.

Например:

| | |
|---|---|
| Кулымдагы балдагымның<br>Исемнәре Клара;<br>Совет иле үсә, ныгый<br>Көннән-көн алга бара. [1, с. 246] | (На руке моей кольцо,<br>На нём имя «Клара»,<br>Край советский расцветает<br>День ото дня недаром.) |

Или же пример четверостишия, которое Г. Тукай приводит в своей лекции, говоря о сложности перевода.

| | |
|---|---|
| Калфагым бар, шәлем юк,<br>Шәл алдырмый хәлем юк;<br>Синнән башка сөйгәнем юк,<br>Сине алмый хәлем юк. | (Есть калфак, но шали нет,<br>Не купить шаль воли нет;<br>Ты мила мне, прочих нет,<br>Не жениться воли нет.) |

В данном случае сохранение редифа даёт возможность передать общий ритм оригинала.

Определённую трудность в рифмовке представляют песни, в которых зачин одинаковый, но основные части разные (это обычно наблюдается в припевах).

| | |
|---|---|
| Әй, алмалар, алмалар,<br>Тәлинкәләр эчендә;<br>Синең белән бергә булган<br>Һәр минута исемдә. [1, с. 247] | (Эх, яблочки, яблочки,<br>На тарелочках горой;<br>Помню каждую минуту,<br>Проведённую с тобой.) |
| Әй, алмалар, алмалар,<br>Тәлинкәләр эчендә<br>Януларым, көюләрем<br>Бары синең өчен дә. [1, с. 247] | (Эх, яблочки, яблочки,<br>На тарелках столько;<br>Грусть-тоска, страдания<br>Из-за тебя все только.) |

Как видно, в угоду соблюдения рифмы переводчик вынужден видоизменять вторую строку.

К этой же группе примыкает большое количество четверостиший, обычно юмористического характера, которые начинаются с одной и той же строки – «Әнә килә

автомобиль...» («Вон идёт автомобиль...»). Переводчику в погоне за сохранением общего рисунка, общего ритма таких «серийных» четверостиший приходится непросто.

| | |
|---|---|
| Әнә килә автомобиль,–<br>Төягәннәр папирос;<br>Кайчан судия булырсыз, –<br>Шунда аларсыз допрос. [2, с. 335] | (Вон идёт автомобиль,<br>Полный кузов папирос;<br>Когда будете судьёй,<br>Учините мне допрос.) |
| Әнә килә автомобиль,–<br>Төягәннәр дилбегә;<br>Синең ярың кырык сигез,<br>Икәү кирәк иллегә. [2, с. 334] | (Вон идёт автомобиль,<br>Вожжей полный агрегат;<br>Твоих милых сорок восемь,<br>Нужны две, чтоб пятьдесят.) |

Неполной согласованностью отмечены песни второй группы.

Бохар ефәк яулык бигрәк җиңел, Рамай,
Җил очырыр, җилдә кимәгез;
Өзелеп сөйгән кеше хыяллана, Рамай,
Хыяллана, өзелеп сөймәгез. [3, с. 361]

(Бухарский шёлковый платок так лёгок, Рамай,
Ветер сорвёт, уж не носите;
Всей душой влюблённый теряет разум, Рамай,
Теряет, всей душой не любите.)

Третья группа не столь многочисленна. В неё входят песни, в которых зачин и основная часть слиты. Задача переводчика при работе с ними – попытаться отразить это соответствие.

Здесь наличие символических образов по сходству или контрасту внутренне сближают обе части строфы.

| | |
|---|---|
| Җилфер-җилфер җил искәндә,<br>Их, мин җилкәннәр булсам;<br>Мин җилкәннәр булыр идем,<br>Син минем иркәм булсаң. [3, с. 354] | (При шуме ветра колыханья<br>Мне бы парусами стать;<br>Стал бы парусами, коль<br>Мог тебя любимой звать.) |

Тут строки перетекают одна в другую, этому помогают и образы, пронизывающие всю песню.

Итак, проведённая классификация татарских песен на основе тукаевской концепции и анализ переводов подводят к заключению, что выбор приёмов и средств передачи своебразия оригинала зависит от умения переводчика обнаружить внутреннюю связь двух частей строфы песни. Сохранение смыслового богатства, звукового рисунка поможет переводчику показать иноязычному читателю красоту и глубину песенного творчества татарского народа.

ЛИТЕРАТУРА

1. Татар халык иҗаты: Йола һәм уен җырлары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. 319 б.
2. Татар халык иҗаты: Кыска җырлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 392 б.
3. Татар халык иҗаты: Тарихи һәм лирик җырлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. 488 б.
4. Тукай Г. Әсәрләр: 4 томда. Т. 3. Мәкаләләр. Хикәяләр. Мәсәлләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. 447 б.
5. Тукай Г. Әсәрләр: 4 томда. Т. 4. Мәкаләләр. Очерклар. Фельетоннар. Хатлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 431 б.

## Г. ТУКАЙ ИҖАТЫНДА ПЕДАГОГИК ЮНӘЛЕШ

***Нуриева А.Р.***

В статье анализируется творчество Г. Тукая, в частности поэзия, посвященная детям. Стихи для детей рассматриваются в четырех направлениях: о природе, о животном мире, посвященные самим детям, социального характера, религиозной тематики. Г. Тукай старался с помощью своих стихов воспитывать детей на примере не только народной литературы и поэзии, но и Восточной, русской литературы. 1909 году поэт для детей составляет хрестоматию. Он призывал детей изучать русский язык, русскую науку. В своих педагогических сочинениях «Хиссияте

миллия» / «Национальные чаяния», «Письма матери» / «Ана мәктүпләре», во многих стихотворениях поэт отмечает огромное значение научных знаний. Важнейшую задачу воспитания Г. Тукай видел в формировании человека. Перед образованием Г. Тукай выдвинул такие задачи: развитие способностей человека к познанию реальной действительности; развитие способностей для применения знаний на практике.

The article analyzes the works of G. Tukay poetry dedicated to children. Poems for children are considered in four areas: about nature, about animal world, dedicated to the children themselves, social issues, religious themes. G. Tukay tried using my poetry to educate children by example not only of folk literature and poetry, but also the Eastern, Russian literature. 1909 the poet for children is the reader. He exhorted children to study Russian language, Russian science. In his pedagogical essay «Hesiate Millia» / «National aspirations», «Mother Letters» / «Ana mctyler», in many poems, the poet recognizes the immense value of scientific knowledge. The most important task of education G. Tukay seen in the formation of man. Before the formation of G. Tukay have put forward the following objectives: the development of human capacities for cognition of reality; the development of abilities to apply knowledge in practice.

Соңгы елларда җәмгыятебездә кыйммәтләр алмашыну, яңа рухи нигезләр эзләү процессы күзәтелә. Шундый шартларда традицион милли педагогикага, әби-бабайларыбыз, үткән буынның уңай тәҗрибәсенә игътибар бирү бик зарур.

Мәгълүм булганча, галимнәр, зыялылар XX йөз башын тарихыбызның аерым чоры дип бәялиләр. Кыска гына вакыт аралыгында мәдәниятебез, әдәбиятыбыз бик күп яңа исемнәр белән байып, халык, милләт өчен җанын бирергә әзер торган дистәләрчә шәхесләрнең исемнәре тарих битләрендә мәңгегә язып калдырылды. Гомерен халыкка хезмәт итүгә багышлаган шундый күренекле шәхесләрнең берсе бөек шагыйребез Габдулла Тукай татар шигърияте үсешенә бар гомерен багышлый. Моннан кала, ул милли педагогика өлкәсендә дә хезмәт куйган шәхес.

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында бөтен ил күләмендә барган иҗтимагыйтарихи вакыйгалар, үзгәрешләр җәмгыять яшәешенең бөтен өлкәсенә дә гаять көчле йогынты ясый. Шулар арасында зур әһәмиткә ия булганнарының берсе – татар җәмәгатьчелегендә үсә баручы буынга игътибар көчәю. Бу чорда балаларга әхлак тәрбиясе бирү, аларда милли үзаң үстерү, төрле яктан мәгърифәтле шәхес тәрбияләү бурычы актуаль проблема дәрәҗәсенә күтәрелә. Сүз дә юк, бу мәсьәләне хәл итү кадими мәдрәсәләр хәленнән килми. Киң җәмәгатьчелектә белем бирү системасын төптән үзгәртү турында бәхәсләр куера. Яңа дәреслекләр, яңа әдәбият формалашу проблемасы да туа.

XX гасыр башында татар балалар поэзиясе беренче адымнарын атлый. Әлеге поэзия, нигездә дини риваятьләргә корылып, я булмаса, үгет-нәсихәт әйтүне үзәккә алып, сабыйларны һәм халык педагогларының таләпләрен канәгатьләндерә алмый башлый. Заман сулышын сизгер тойган шагыйрьләр матбугат битләрендә балаларга атап язган иҗат җимешләрен бастыра башлыйлар.

Г. Тукай иҗатында балаларга багышланган әсәрләр аерым урын алып тора. Галимнәр: «Тукайның балалар әдәбиятына килүе зур вакыйга була, бу өлкәдәге күп кенә яңалыклар аның иҗаты белән башлана», – дип язалар [3, б. 23]. Балалар әдәбияты өлкәсендә Г. Тукай гомеренең соңгы көннәренә хәтле яратып эшли.

Җитмешкә якын шигырь һәм поэма, 100 дән артык хикәя һәм мәсәл, публицистик мәкаләләр – болар барысы да шагыйрьнең балалар әдәбиятына керткән өлеше.

Тукайның балалар өчен язган шигырьләрен 4 төркемгә бүлеп карыйлар:

– табигатьне тасвирлау («Җәй көнендә», «Җир йокысы» һәм башкалар);

– сабыйларны бөҗәкләр, җәнлекләр, кошлар, хайваннар белән таныштыру («Карлыгач», «Кызыклы шәкерт», «Гали белән Кәҗә» һәм башкалар);

– балаларның үзләренә багышланган шигырьләр («Бәхетле бала», «Эш», «Сабыйга» һәм башкалар );

– социаль эчтәлекле шигырьләр («Кышкы кич» һәм башкалар);

– дини тематика («Таян Аллага», «Ана догасы», «Кадер кич» һәм башкалар).

Г. Тукай татар балаларын милли әдәбият, милли поэзия белән берлектә, шәрык һәм рус әдәбияты үрнәкләре белән дә таныштыруны зарур саный. Балаларга багышланган 70 шигырьнең 20 се рус һәм дөнья әдәбияты әсәрләре тәрҗемәсе яки кемнеңдер яхшы әсәренә таянып язган иҗат җимешләре була.

Г. Тукай балаларга багышланган күп кенә әсәрләр иҗат итеп кенә калмый, педагогик эшчәнлеген дә җәелдереп җибәрә. Г. Тукай – татар халкының сөекле шагыйре,

татар әдәбиятында үзенең поэтик мәктәбен тудыру белән бергә, халкыбызның педагогик культурасын үстерүгә дә зур өлеш керткән шәхес.

Мәсәлән, Г. Тукайның «Ана мәктүбләре» дигән публицистик әсәрендә балаларга дөрес тәрбия бирү мәсьәләсе төрле аспекттан: балага индивидуаль якын килү, балага мөнәсәбәттә һәм уку мәсьәләсен хәл иткәндә, яшь үзенчәлекләрен исәпкә алу, дөрес туклану, җитәрлек дәрәҗәдә физик күнекмәләр бирү, начар гадәтләргә ияләштермәү кебек проблемалар хәл ителә.

Шагыйрь баланы үткен зиһенле, югары әхлаклы итеп тәрбияләү проблемасына аеруча зур игътибар бирә. Монда ул иң кулай чара итеп матур әдәбиятны күрсәтә.

«Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» хрестоматиясенең кереш өлешендә ул балаларга яңа милли әдәбият әсәрләреннән торган «чәчәк бәйләме» бүләк итәргә кирәклеген ассызыклый. 1909 нчы елны Г. Тукай башлангыч мәктәп укучылары өчен «Яңа кыйраәт» («Яңа уку») исемле дәреслек-хрестоматия төзи. Китапта мәсәлләр, фәнни, әхлакый эчтәлекле мәкаләләр һәм әдәби проза урын ала.

Г. Тукай фәннәрне тирәнтен өйрәнү белән бергә, балаларга әхлак, эстетик, хезмәт, физик тәрбиягә зур игътибар биргән. Иҗатында аеруча патриотик хисләр һәм кеше шәхесенә тирән хөрмәт тәрбияләгә басым ясый.

Шагыйрь балаларда рухи сыйфатлар, дуслык, намус, гаделлек, батырлык, максатка ирешүдә ныклылык, таләпчәнлек кебек сыйфатлар тәрбияләүне зарур күрә. Җәмәгатьчелек, галимнәр Г. Тукайның бу өлкәдәге эшен хуплыйлар. 1913 елда «Мәктәп» журнылының 5 санында бастырылган «Г. Тукайның балаларга йогынтысы» дип аталган мәкаләдә: «Балалар арасында Г. Тукай бик популяр. Өйдә дә, мәктәптә дә балалар аның аңлаешлы, гади итеп язылган шигырьләрен, мәкалләрен, укыйлар, яттан сөйлиләр. Тукай шигырьләре озак яшәрләр һәм балалар тарафыннан укылырлар», – дип язалар. Әйтергә кирәк, Г. Тукайның балалар өчен язган хәтсез китапларын бастырып та чыгаралар. Мәсәлән, 1950 елда рус телендә «Балалар өчен шигырьләр һәм поэмалар» китабы, 1952 елда «Мәсәлләр» китабы бастырыла. Моннан соң да, Г. Тукай әсәләренә, китапларына еш мөрәҗәгать итеп торалар. Даими рәвештә рус телендә, татар телендә балалар өчен китаплары бастырылып килә.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: Г. Тукай иҗатының зур өлеше балаларга багышлана. Бу өлкәдә аеруча актив эшләгән чоры 1909–1910 елларга туры килсә дә, аның шигырьләре һаман да заманча яңгырый, кешегә бишектән алып гомере буе тугры юлдаш була. Шуңа да, Г. Тукай әсәрләре үзе төзегән хрестоматияләрендә генә түгел, һәр чордагы мәктәп дәреслекләрендә үзәк урынны алып торалар. Шагыйрьнең аерым публицистикасы, ата-аналарга, укытучыларга багышланып, бала тәрбияләү принципларын, шартларын конкрет мисаллар белән сурәтләү ягыннан да кыйммәтле.

Бүгенге көндә бала мәктәпкә укырга керү белән әлифбаны, туган телне, әдәбиятны өйрәнә башлый. Дәреслекнең беренче битләрендә үк укучы бала Габдулла Тукай портреты, биографиясе һәм шигырьләре белән таныша башлый. Һәр сыйныф өчен әдәбият дәреслегендә, хрестоматиясендә укучы өчен Габдулла Тукай турында мәгълүматлар бирелә. Татарстанда балалар бакчаларында, мәктәпләрдә балалар шагыйрь сүзләренә «Туган тел» җырын җырлыйлар. «Су анасы», «Шүрәле» әкиятләрен бергәләп укыйлар. Кечкенәләр «Бала белән күбәләк» җырын өйрәнәләр. Югары уку йортларында Г. Тукайның туган көнен зурлап уздыралар. Студентлар аның иҗатына багышланган конкурсларда катнашалар, курс эшләре, диплом эшләре язалар. Әдипнең шигырьләрен яттан сөйләп, шагыйрьне искә алалар.

Тукай бүген дә балалар белән, яраткан халкы белән.

ӘДӘБИЯТ

1. Балалар әдәбияты / төз. Ф. Ибраһимова. Казан: Мәгариф, 2004. 543 б.
2. Галиуллин Р. Тукай һәм без // Шәһри Казан. 2010. 22 апрель.
3. Галимуллин Ф. Шагыйрь турында истәлекләр. Казан: Хәтер (ТаРИХ), 2002. Б. 20–25.
4. Исламов Ф. Тукай образы – әдәбиятта һәм сәнгатьтә // Мәгариф. 2006. № 4. Б. 88–89.
5. Идрисова Г. Тукай рухы – мәңгелек // Шәһри Казан. 2009. 3 апр. Б. 3, 12.
6. Лерон Л. Тукай абый сөйли // Салават күпере. 2009. № 4. Тышл. 4 б.
7. Рамазанов Д. Г. Тукай әсәрләренең тел үзенчәлекләре бүген дә актуаль // Фән һәм тел. 2010. № 1. Б. 34–37.
8. Хәсәнова А. Тукайга таянып яшибез // Ватаным Татарстан. 2009. 28 апр.

# Г. ТУКАЙНЫҢ ЗАМАНДАШЫ СОЛТАН РАХМАНКОЛЫЙНЫҢ ӘДӘБИ-МӘДӘНИ МИРАСЫ

***Нурмөхәммәтова Р.С.***

В статье дается краткая биография и описание литературно-культурного наследия Султана Рахманкулова – современника, друга и соратника Габдуллы Тукая.

The article includes short biography and description of literary and cultural heritage of the Gabdulla Tukay's contemporary, friend and colleague Sultan Rakhmankulov.

Фәнни әдәбиятта Солтан Рахманколый турында мәгълүматлар шактый таркау һәм аның мирасы тиешле дәрәҗәдә җентекләп тикшерелмәгән. «Әдәбият тарихына караган хезмәтләрдә, мемуар әдәбиятта аның исеме күренгәләп китә. Күренгәләп китә – ләкин шуннан ары түгел. Ул истәлекләрдән аңлашылганча, С. Рахманколый язучы да, җырчы да, публицист та, тәрҗемәче дә, педагог та булган икән», – дип язды аның исемен татар әдәбиятына кайтаруга күп көч куйган мәшһүр язучыбыз М. Мәһдиев [2, б. 128].

Солтан Рахманколый гыйбрәтле, әмма кыска гомерендә татар халкы өчен зур хезмәт куйган. Аның Г. Тукай, Ф. Әмирхан, С. Сәйдәшев кебек бөек шәхесләр белән якыннан аралашып иҗат итүе дә зур игътибарга лаек. Тел белеме, тәрҗемә һәм әдәбият тарихында калдырган хезмәтләре С. Рахманколыйның киңкырлы иҗади шәхес булуын исбатлый. Бу хезмәтебездә без әлеге шәхеснең тормышы һәм эшчәнлеге турында булган мәгълүматны туплап, мирасын берникадәр барлауны максат итеп куябыз.

Солтан Рахманколый 1888 елда хәзерге Татарстан Республикасының Теләче районы Олы Шыңар авылында туа. Солтан туып, берникадәр вакыт үткәч (1890 елда) Рахманкуловлар гаиләсе Казанга күчеп килә. Вакыты җиткәч, Солтан Рахманколый беренче реаль училищеда укый башлый. Беренче рус революциясе елларында, революцион хәрәкәткә катнашкан өчен, ул бер төркем студентлар белән училищедан куыла. Бу вакытта аңа 18 яшь була. Үзен яңадан училищега алуларын сорап, гариза яза, әмма аның үтенече канәгатьләндерелми.

1907 елларда ул иҗат эшенә керешә. 1908 елда әтисе каты авырудан үлеп китә һәм гаиләне карау мәшәкатьләре Солтан өстенә төшә. Мохтаҗлыктан котылу юлларын эзләп, ул төрле өлкәләрдә үзен сыный башлый. Вакытлы матбугат битләрендә үзенең алдынгы карашларын уздыра, «Йолдыз», «Бәянел хак» кебек татар газеталарында мәкаләләрен бастыра, төрле әсәрләр тәрҗемә итә, сүзлекләр төзи, хикәяләр яза.

Кызганыч, С. Рахманколый иҗатының чәчәк атып килгән чагында 1916 елның 8 апрелендә Казанда вафат була.

Дөньялыкта Г. Тукайныкы кадәр гомер генә яшәп, үзе дә Г. Тукай белән бергә иңгә-иң куеп, татар халкы өчен хезмәт иткән С. Рахманколый шәхесенә һәм аның каләме тудырган кайбер хезмәтләргә күзәтү ясап үтик.

С. Рахманколый шәхес буларак гаять кызыклы кеше була. Аның бик матур җырлавы, мандолинада уйнавы мәгълүм. Гомумән, бу гаилә үзенең сәнгатькә якынлыгы белән аерылып торган. Солтанның сеңлесе – Мәрьям Рахманкулова киләчәктә татар халкының танылган, яраткан җырчысы булып үсеп җитә.

Г. Тукай иҗатын өйрәнгән галим И.З. Нуруллин С. Рахманколыйның сәләтле, туры сүзле, ясалмалылыкны күралмаучы кеше булганлыгы турында искә ала, аның кешеләр белән авыр аралашуына басым ясый [4]. «1907 елның көзендә Г. Тукай Казанга килә. Монда ул баш-аягы белән иҗатка чума һәм ул «Әл-ислах» газетасы, «Яшен» журналы белән хезмәттәшлек итә башлый. Аның яңа дуслары – Ф. Әмирхан, Х. Ямашев, К. Бакир, В. Бәхтияров, Г. Камал, С. Рахманколый, Г. Колахмәтов, соңрак – С. Сүнчәләй пәйда була» [7]. Бу дуслык С. Рахманколый өчен бик мөһим була. Алар Г. Тукай белән Европа, рус әдәбияты белән кызыксыналар, бергә китаплар укыйлар, музыка тыңлыйлар. Г. Тукай аны халык арасына – демократик рухтагы шәкертләр, журналистлар арасына алып керә. «Алар бергәләп төрле кичәләр оештыралар, ул кичәләрдә Солтан мандолинада уйный, җырлый торган була» [5, б. 199].

Г. Тукайга С. Рахманколыйның мандолинада уйнавы, җырлавы бик ошаган. Солтан еш кына Тукай шигырьләренә җырлар башкарган. Д.З. Саинова-Ахмерова хезмәтендә, кайбер мәгълүматлар буенча, Г.Тукайның барлык башкаручыларны да кабул итмәве, ә һәвәскәр Солтан Рахманколыйның мандолинада уйнавын яратуы һәм аны

сәгатьләр буе тыңлавы турында бәян ителә. С. Рахманкулов белән С. Сәйдәшевне ул башка сәнгатькәрләрдән ачыктан-ачык өстен күргән [6].

Тәрҗемәчелек белән С. Рахманколый 1908 елларда шөгыльләнә башлый. Аның бу өлкәгә керткән өлеше Э.Г. Нигъмәтуллин төзегән күрсәткечтә ачык күренә [3]. Татар укучысы А.С. Пушкинның «Дубровский», «Алеко, яки Чегәннәр», «Борис Годунов», И.С. Тургеневның «Яһүди», «Төтен», В. Гюгоның «Вөҗдан газабы» әсәрләре һ.б. язучыларның иҗаты белән С. Рахманколый тәрҗемәләре аша таныша. Ул шулай ук «Телләр тарихы», «Хәйванат» кебек фәнни-популяр жанрдагы әсәрләр дә тәрҗемә итеп бастыра.

Алда әйтелгәнчә, С. Рахманколый үзе дә хикәяләр яза. Аның үз әсәрләре сан ягыннан күп түгел. Ул «чын-чыннан язучы булып бик кыска вакыт эчендә – империалистик сугышның беренче елларында формалаша», – дип яза аның турында М. Мәһдиев һәм 1979 елда аның хикәяләрен туплап, «Мәлихә куаклыгы» исеме белән аерым китап итеп бастырып чыгара.

С. Рахманколыйның татар тел белеме өлкәсенә керткән өлеше дә бәяләп бетергесез. Ул – XX гасыр башында зур популярлык казанган дүрт сүзлек, бер үзөйрәткеч авторы. Аның сүзлекләре һәркайсы аерым игътибарга лаек, алар материалның бирелеше ягыннан да, максатлары ягыннан да бер-берсен кабатламый.

С. Рахманколыйның татар лексикографиясе өлкәсендәге эшчәнлеге 1911 елда «Русча-татарча мөкәммәл лөгать» хезмәте белән башланып китә. Бу сүзлекне ул тәҗрибәле тәрҗемәче, театр белгече Габдрахман Кәрам белән бергә төзи. Сүзлек зур күләмле, 624 биттән тора. Анда 25000 чамасы рус сүзенә татарча аңлатма бирү күздә тотыла. Моңа кадәр русча-татарча сүзлекләр шактый дөнья күргән булуга карамастан, алар ул хезмәтләр белән генә чикләнеп калмыйча, лөгатьлекне, В.Даль сүзлегенә нигезләнеп, үзләре төзиләр. Сүзлекнең татарча өлеше сүзгә-сүз тәрҗемә белән дә, аңлатма бирү юлы белән дә төзелгән. Тәрҗемәләрдә гарәп-фарсы, төрек сүзләре күп очрый. Нәкъ менә шул сәбәпле бу хезмәт каты тәнкыйть утына эләгә дә инде. «Рахманкуловлар үзләренең бу сүзлекләрендә ул вакыттагы госманлы-төрек теле тәэсиренә бирелеп, бик күп гарәп, фарсы сүзләре сүзләре кертәләр һәм үзләренең сүзлекләрен ул вакыттагы югары катлау буржуа интеллигенциясе өчен генә кулланырга яраклы итеп чыгаралар» [1, б. 83]. Ни генә булмасын, бу хезмәт татар халкы арасында тиз тарала һәм 1920 елда (С. Рахманколый вафат булгач) тагын бер тапкыр тулыландырылып, 35 мең сүз белән яңадан бастырыла.

XX гасыр башы ихтыяҗларын күздә тотып С. Рахманколый 1912 елда «Учебник-самоучитель разговорного татарского языка для русских (Казанское наречие)» дигән үзөйрәткеч төзеп бастыра. Бу хезмәтнең ахырында русча-татарча лөгать тә бирелә. Сүзлекчә 2500 чамасы сүзне үз эченә ала. Монда инде сүзгә-сүз тәрҗемә өстенлек итә, чөнки телне башлап өйрәнүчеләргә сүзнең бер мәгънәсен белү җитә дип, бик дөрес уйлаган автор. Сүзтезмә, тезмә сүзләрдә басым күрсәткәндә С. Рахманколый интуитив рәвештә энклиза һәм проклиза күренешләренә юлыккан: мондый тәрҗемәләрдә ике сүзнең берсенә генә басым куелган. Татар сүзләренең дә басымнарын күрсәтү бу чорда төзелгән сүзлекләрнең күбесендә юк, шуңа күрә моны авторның уңышы дияргә дә була.

С. Рахманколыйның сүзлек төзү өлкәсендәге тагын бер зур хезмәте – 1913 елда басылган «Татарча-русча лөгать» китабы. Сүзлектә 10000 чамасы татар сүзен русчага тәрҗемә итү күздә тотылган. Бу хезмәтне С. Рахманколый үзе генә башкарып чыга. Сүзлекнең лөгатьлеген автор, алда искә алынган хезмәтенең картотекасыннан файдаланып төзегән булырга тиеш. Болай уйлау өчен берничә сәбәп бар: 1) моңа кадәр татар сүзләрен бу күләмдә туплап төзелгән тәрҗемәле сүзлек юк; 2) сүзлек үзенә күрә татар теленең синонимнар сүзлеге вазифасын да башкара. Лөгатьлек ягында синонимнар бирү элегрәк чыккан сүзлекләрдә күзәтелми; 3) русча-татарча сүзлектә татар ягында синонимнар шулай ук күп. Әйләндереп куйганда, татарча-русча сүзлектә лөгатьлек ягында да синонимнар килеп чыга: *гора – тау, таг (1911: 109), тау, таг – гора, холм (1913: 138); дождь – ягмур, яңгыр (1911: 128), ягмур, яңгыр – дождь (1913: 102); душа – җан, рух, нәфес (1911: 138), җан, рух – дух, душа (1913: 78)* һ.б. Димәк, С. Рахманколыйның татарча-русча сүзлек лөгатьлеген үз көче белән төзү өчен белеме дә, тәҗрибәсе дә, материалы да җитәрлек булган дияргә нигез бар.

1915 елда (вафатына 1 ел кала) С. Рахманколыйның «Русча-татарча кесә лөгате» дип аталган сүзлеге дөнья күрә. Ул 280 биттән гыйбарәт, анда 10000 чамасы рус сүзенә татарча аңлатма бирелә. Бу сүзлек белән С. Рахманколый татар лексикографиясенә тагын

бер яңалык алып килә: ул беренче булып кесә сүзлеге төзеп бастыра. Дөрес, русларда мондый сүзлекләр булган. Лексикография казанышлары, сүзлек төзү эшләре белән даими кызыксынып торган С. Рахманколый аларга игътибар итми кала алмаган, билгеле, һәм ул бу алымны татар сүзлекчеләре арасында беренчеләрдән булып гамәлгә кертә.

Дөньяда нибары 28 ел яшәгән С. Рахманколыйның алда санап үтелгән хезмәтләре аның XX гасыр башы татар мәгърифәтчеләре арасында лаеклы урынын дәлиллиләр.

ӘДӘБИЯТ

1. Гали М. Русча-татарча сүзлекләр // Совет әдәбияты. Казан, 1939. № 2. Б. 79–91.
2. Мәһдиев М. Солтан Рахманколыйның иҗат эшчәнлеге // Казан утлары. 1966. № 11. Б. 128–138.
3. Нигматуллин Э.Г. Указатель переводов произведений русской литературы на татарский язык. Казань: Унипресс, 2002. topreferat.znate.ru›docs/index-41808.html
4. Нуруллин И.З. Жизнь замечательных людей (№ 255) – Тукай. ModernLib.ru›books/nurullin_ibragim_zinnyatovich/…
5. Рәми И., Даутов Р. Әдәби сүзлек. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 389 б.
6. Саинова-Ахмерова Д.З. Салих Сайдашев. Казань, Татар. кн. изд-во, 1999. TATshop.ru›content/view/87/
7. bestpeopleofrussia.ru›persona/Gabdulla-Tukay/bio

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИҖАТЫН ЗАМАНЧА ТЕХНОЛОГИЯЛӘР КУЛЛАНЫП ӨЙРӘНҮ

***Нурова Л.А., Хөснетдинов Д.Х.***

Статья раскрывает особенности изучения творчества Г. Тукая с помощью современных технологий обучения. Творчество Г. Тукая сыграло огромную роль в развитии современного татарского языка. В связи с этим изучение произведений великого поэта в образовательных организациях средствами современных технологий помогает лучше раскрыть сущность и красоту татарского языка.

This article reveals the peculiarities of the study of G. Tukay creativity by means of modern technologies of training. The creativity of G. Tukay has played a huge role in the development of modern Tatar language. In this regard, the studying of the works of the great poet in educational organizations by means of modern technologies helps to open better the essence and beauty of Tatar language.

XIX йөз ахырында һәм XX йөз башында татар әдәби телен гомумхалык теле нигезендә үстерү процессы башланып китә. Әлеге каршылыклы хәрәкәттә халык шагыйре Г. Тукайның тел өлкәсендә башкарган эшләре гаять әһәмиятле. Ул татар әдәби телен халык теленә якыйнайтуда, матур әдәбият стилен үстерүдә, камилләштерүдә, традицион китап телен халык теле үзенчәлекләре белән аралаштырып бирү эшен генә түгел, халык теленең бай мөмкинлекләреннән файдаланып, шул нормаларны төрле стильләрдә чагылышын практик яктан ачык күрсәтеп һәм дәлилләп күрсәткән кешеләрнең берсе. Г. Тукай иҗаты, бер яктан, татар халкының әдәби үсеш процессын һәм әдәби теле оешу тарихының үткәннәрен чагылдырса, икенче яктан татар әдәбияты һәм татар әдәби теленең җитлеккән гүзәл үрнәкләре булып тора, дип яза Ш. Рамазанов [1, б. 88].

Соңгы унъеллыкта җәмгыятебездә барган үзгәрешләр белем бирү системасын да игътибарсыз калдырмады. Ул дөньякүләм белем бирү кинлеге үсеше тенденцияләрен исәпкә алып үзгәрергә мәҗбүр. Димәк, педагогик тәрбия, практика, язучыларның иҗатын өйрәнү заманча таләпләргә җавап бирергә тиеш. Моның өчен укучыга карата мөнәсәбәт белән бергә укытуның эчтәлеге дә үзгәрергә тиеш. Бу исә, эксперименталь һәм хосусый мәктәпләр, лицейлар, гимназияләр ачылуга этәргеч салды. Аларда, белем бирүнең сыйфатын сизелерлек күтәрүче яңа (инновацион) технологияләр дә уңышлы файдаланыла.

Хәзерге заман татар теле дәресе проблемалы ситуацияләрдән, мәгълүмати технологияләрдән башка үстерешле була алмый.

Тәрбияле, белемле, бар яктан булган шәхес, ягъни көндәшлеккә сәләтле укучы тәрбияләү өчен заман белән бергә атлау, укучыларны кызыксындырырлык яңа технологияләр кулланып эшләү мөһим. Бүгенге мәктәп шартларында педагогларның шәхескә бик сак якын килә белү сәләтенә, тирә-юнь белән аралашканда балаларга фәнни-нигезле тәэсир итүне булдыруга юнәлтелгән технологияләргә ия булуы зарури. Инновацион

технологияләрнең нигезен тәшкил итә торган эшлекле һәм рольле, имитацион уеннар укучыларның оештыру сәләтен, икътисади фикерләү дәрәҗәсен экологик культурасын үстерергә ярдәм итә. Төрле дидактик шоу рәвешендә уздырыла торган уеннар да кызыксыну уята. Алар мөстәкыйль эзләнү эше нәтиҗәсе, талантлы, сәләтле балаларны иҗади эзләү чарасы да булып тора [5, б. 138].

Һәрбер язучының татар әдәби теле тарихында тоткан роле тарихи-иҗтимагый процесс белән бәйләнештә өйрәнелә. Г. Тукай иҗаты аша без шагыйрьнең татар теленең сүзлек хәзинәсе белән оста эш итүен, лексик чараларның төрле үзенчәлекләреннән файдалануын күрәбез. Мәсәлән, сөйләмнең аһәңен, яңгырашын, эмоциональлеген көчәйтү өчен автор авваздаш сүзләрдән актив файдаланса (Яхшылыкка эреп китәм *балавыз* мин, мактап сөйлим изге эшне – *бал аваз* мин («Бер татар шагыйренең сүзләре» шигыреннән) [2], стиль чарасы буларак, сөйләмне дөрес төзүгә, форма белән эчтәлекнең логик бәйләнешен булдыру өчен синоним сүзләргә мөрәҗәгать итә (Бик нык торам үз *хакымны* теләүдә мин, Һәнүз шул ук *хокук* көен көйләүдә мин («Фөрьят» шигыреннән) [2].

Татар теле һәм әдәбиятын укытканда, шул исәптән мәктәптә язучыларның иҗатын өйрәнгәндә, инновацион якын килү белем бирү процессын яңарту-үзгәртү күзлегеннән чыгып карарга мөмкинлек тудыра, гадәти «репродуктив» юнәлеш вакытындагы кебек уңай нәтиҗә гарантияләнә. Шул ук вакытта, белем бирүгә технологик якын килү укучыларга билгеле бер белемнәрне хәбәр итүгә, эшчәнлекне укытучы тәкъдим иткән үрнәк буенча оештыруга юнәлтелә: яңарту-трансформацияләүләр уку-укыту процессы турындагы традицион күзаллауны үзгәртә, ул исә, үз чиратында, танып белү эшчәнлеген оештыруны тәэмин итә. Эзләнүле якын килү репродуктив эшчәнлек нәтиҗәсендә традицион белем бирүне үзгәртеп кору мөмкинлегенә ия. Ул – куелган максатларга ирешүне уңай хәл итә, димәк, көтелгән нәтиҗәгә китерә.

Г. Тукай иҗатын өйрәнгән вакытта төрле педагогик һәм психологик ситуацияләрне һәм мәсьәләләрне чишү кебек технологияләр дә укучыларга үзләренә әхлакый дөрес юл сайларга ярдәм итә. Болардан тыш бөек шагыйребезнең иҗатын үзләштергәндә түбәндәге инновацион технологияләрне дә кулланып булуын әйтеп үтәргә кирәк:

– иҗади үсеш технологиясе;
– уку эшчәнлеген төркемнәрдә оештыру;
– тәнкыйди фикерләү технологиясе;
– шәхескә якын килү технологиясе һ.б. [3, б. 1375].

Хәзерге заман татар теле һәм әдәбияты укытучысына педагогик технологияләр җыелмасына ия булу бурычы куела. Бу исә балаларның социаль әһәмиятле эшчәнлеген оештырып, алар белән аралашу мөмкинлеге тудыра.

Укытучы укытуның сыйфаты, укучыларның белем һәм тәрбия дәрәҗәсе өчен җавап бирә. Шуңа күрә белем бирү төшенчәсенә билгеле бер максатка юнәлдерелгән процесста укучылар үзләштергән белемнәрнең нәтиҗәсе һәм шул нигездә формалашкан дөньяга карашлары, шәхеснең әхлак сыйфатлары, аның иҗади көче һәм сәләте, үсеше кергәнен укытучы һәрвакыт күздә тотып эшләргә тиеш.

Тормышның төрле өлкәләрендәге техник чараларның артуы мәктәп тормышына да үзгәрешләр кертте. Белем бирү процессын компьютерлаштыру, төрле педагогик, шул исәптән яңа технологияләр кертү, Г. Тукай шигырьләрен яңача анализларга ярдәм итә. Шагыйрьнең шигырьләре башка телләрдән кергән алынмаларга, гарәп-фарсы, рус теленнән һәм рус теле аша Көнбатыш Европа телләреннән кергән алынма сүзләргә бик бай. Гарәп-фарсы алынмаларының күбесе бүгенге көндә актив кулланылышта йөрсә дә, кайберләре исә күптән архаик формага күчкән. XX гасыр татар әдәби телендә иҗтимагый-политик төшенчәләрне белдергәндә татар теленең үз сүзләреннән кала, башка телләрдән кергән алынмалар да актив кулланыла. Мәсәлән, *сыйныф, бәһа, алмашмак* һ.б.

Шагыйрьнең гарәп-фарсы, төрек элементларын, рус теле һәм аның аша Көнбатыш Европа телләреннән кергән лексик байлыкны төрле стильләрдә сатира чарасы итеп куллануы, беренче чиратта, аның тел белән эшләүенең зур мөмкинчелекләреннән файдалануын һәм киң диапозонда эшләвен күрсәтә. Аның иҗатын анализлау барышында без җәмгыятьтәге тәртипләрдән, теге яки бу шәхестән көлү максатыннан Г. Тукайның татар теленең сүзлек хәзинәсенә кереп урнашкан, киң кулланылышта йөргән алынма сүзләрнең, шулай ук татар теленең әдәби нормалары булып кабул ителгән сүзләрнең төрле максаттан чыгып кулланылуын ачыкладык.

Г. Тукайның иҗатын чорларга бүлеп караганда, галим В. Хаков аның башлангыч чор иҗатында халык теленнән тайпылыш барлыгын билгеләп үтә. Аның фикеренчә, автор шигырьләрендә традициягә ияреп төрек һәм гарәп-фарсы сүзләрен урынсыз һәм еш куллану күренешләре күзәтелә. Гомумән, XIX йөз башы XX гасыр әдәби әсәрләрендә һәм кайбер социаль катлаулар телендә билгеле күләмдә төрекчелек юнәлеше урын ала һәм билгеле ки, әлеге процесста Г. Тукай да үз йогынтысын ясый. Әлеге мәсьәлә, В. Хаков фикеренчә, тарихи чор белән бәйләнештә, элекке традицияләрнең дәвамы юнәлешендә каралырга тиеш [4, б. 56]. Аерым Г. Тукай иҗатында кулланылган төрек теле элементларын автор сатира тудыру максатына буйсындырса, ә гарәп-фарсы теленнән кергән сүзләр ярдәмендә комик эффект барлыкка китерә. Әлеге эффект тудыру өчен шагыйрь гарәп-фарсы сүзләренә һәм изафәләренә мөрәҗәгать итә. Әлеге изафәләр, язма әдәби тел традициясе буларак, XX йөз башында һәм аннан элегрәк язылган әдәби әсәрләрдә урын алган. Шуларның кайберләре: *инсане Гали, әһле ислам, әһле базар, әһле Петербург* һ.б. Татар әдәби телендә булмаган әлеге изафәләрне Г. Тукай үзенең әсәрләрендә сатирик сөйләм үзенчәлеге тудыру максатыннан бик уңышлы кертеп җибәрә. Мәсәлән, аның «Дөнья бу!» исемле шигырендә әлеге формалар башка сүзләр белән кушылып, автор тарафыннан отышлы вариант тәгъдим ителә:

Бер заманнар Рәшиткә *«габде милләт»* нам виреп,
Хәзер инде *«габде корсакка»* төшергән дөньядыр.
(«Дөнья бу») [2].

Әлеге өзектә Рәшит исеме астында XIX йөзнең ахырында, XX йөзнең беренче елларында самодержавиегә каршы һәм прогрессны яклап көчле пропаганда алып баручы, укучы яшьләрнең, шәкертләрнең фикере ачылуга хезмәт итүче Габдерәшит Ибраһимов турында сүз бара. Г. Тукай Габдерәшит Ибраһимовның милләт өчен тырышып йөрүеннән көлеп *«габде милләт»* дип атый, ягъни милләт колы мәгънәсендә, һәм комик эффектны ныгайту максатыннан беренче изафәгә яңгырашлы «габде корсак» (корсак колы) сүзтезмәсен куллана.

Шагыйрьнең «Нәрсәдән?» исемле шигырендә депутат Байбуринны тәнкыйтьләү өчен автор шулай ук әлеге формаларга мөрәҗәгать итә:

Ник бүген атлар, сыерлар сөйләшәләр телләнеп?
Шәбһә юктыр, *нәфсе Байбурин* нотык тоткан бүген.
(«Нәрсәдән?») [2].

«... гә» шигырендә дә көлү объекты итеп бай балалары алына:

Бу кеше, байбәтчәләрнең *калдыгы хәмрен* көтеп...
(«...гә») [2].

Алда китерелгән мисаллардан күренгәнчә мондый төрдәге сатирик алымнар бик оригиналь яңгырыйлар.

Нәтиҗә ясап, түбәндәгеләрне китерергә мөмкин: Г. Тукай иҗатында диалекталь, гади сөйләм сүзләр белән беррәттән, борынгы тел элементларын (мәсәлән, *аглаю, күрәлем, андыйн, белең* һ.б.), хәзерге телдә дә актив һәм архаик формага әверелгән гарәп-фарсы (*җәһаләт* – наданлык; *ислах* – реформа һ.б.) һәм төрек алынмаларын очратырга мөмкин. Шигырьдә кулланылган борынгы формалар, гарәп-фарсы сүзләре һәм изафәләр нигезендә авторның сатирик сөйләм стилен оригиналь формада тәгъдим итәргә булыша.

XX гасыр ахыры XXI гасыр башы мәгълүмати технологияләрнең бик нык үсүе, информацион бушлыкның тиңдәшсез үзгәрүе белән үзенчәлекле. Иҗтимагый тормышның төрле өлкәләре турында мәгълүмат булуы инде аптыраш тудырмый [3, б. 1580]. Мәгълүмати мохитне проектлаштыру һәм аның белән идарә итүне оештыру мәсьәләләре эшчәнлекнең теләсә кайсы өлкәсендә, шул исәптән, мәгариф өлкәсендә дә менеджментның көндәлек эшенә әверелә.

Бүгенге көндә мәгариф системасы шактый эзлекле үсә. Мәсәлән, гомуми белем оешмалары, гимназия, лицейларның барысын да компьютер техникасы белән тәэмин ителеп килә; аларны интернет челтәренә тоташтыру актив алып барыла. Мәктәпләрдә укытыла торган барлык фәннәр буенча, шул исәптән язучыларның иҗатлары буенча электрон дәреслекләр комплексы булдырылып килә.

Нәтиҗә ясап әйтсәк, белем бирү оешмаларында Г. Тукай иҗатын өйрәнүнең нәтиҗәлелеге күп төрле чараларга бәйле. Болар методологик, оештыру-педагогик, методик

һәм техник чаралар. Ләкин хәлиткеч чара булып, әлбәттә, педагогның белем бирү өлкәсендәге һәр яңалыкны күрә белүе, аны үз эшендә куллануы тора. Шуннан башка укытучы үз максатларына ирешә алмаска мөмкин. Бөек шәхесебез Р. Фәхреддин әйткәнчә, һәрбер кеше үз кулыннан килгән кадәр эш эшләргә, байлык вә һөнәр һәм дә сәнгать өлкәләрендә милләтнең күтәрелүенә ярдәм кылырга тиеш. Халкының үткәнен, тарихын, сәнгатен өйрәнгән, хезмәт сөйгән, матурлыкны күрә белгән, үзара дус һәм тату мөнәсәбәттә тәрбияләнгән балаларның киләчәге өметле [5, б. 136]. Габдулла Тукайның иҗатын заманча технологияләр кулланып өйрәнгәндә дә моны истә тотарга кирәк.

ӘДӘБИЯТ


1. Рамазанов Ш.А. Совет чорында татар әдәби теленең үсеше (Татарстанның XXV еллыгына багышлап) // Совет әдәбияты. 1945. № 6. Б. 87–98.
2. Тукай Г. Әсәрләр: 6 томда. Академик басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011.
3. Нурова Л.А. Внедрение инновационных технологий в учебный процесс (на примере обучения татарскому языку) // В мире научных открытий. Красноярск, 2015. № 7. 4 (67). С. 1571–1582.
4. Хаков В.Х. Татар әдәби теле (стилистика). Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 304 б.
5. Хуснутдинов Д.Х., Нурова Л.А. Использование инновационных технологий во внеклассных мероприятиях на татарском языке // В мире научных открытий. Красноярск, 2015. № 11 (71). С. 134–140.


## ДИАЛЕКТИЗМНАРНЫҢ Г. ТУКАЙ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ КУЛЛАНЫЛЫШЫНА КАРАТА


***Рамазанова Д.Б.***



Конец XIX – начало XX века ознаменовалось движением за демократизацию татарского письменного литературного языка, за приближение его к татарскому народному. Этот процесс нашел яркое воплощение в творчестве деятелей татарской литературы, в том числе и Г. Тукая, который вложил большие усилия борьбе за чистоту языка, требовал, чтобы в языке произведений не употреблялись старотатарские особенности, непонятные для народа арабизмы. В этой ситуации особую актуальность приобретает проблема отношения к диалектизмам. Исследования показали, что в творчестве Г. Тукая диалектизмы использованы целенаправленно: в соответствии с требованиями стиля, образности, более выпуклого отражения недостатков в обществе того времени, формы родного говора. При интерпретации приведены сравнения из истории татарского языка, данные этнографии, сопоставления из различных говоров и языков. Разносторонний анализ диалектизмов в языке классиков способствует глубже раскрыть процессы, происходящие в формировании татарского литературного языка начала XX в.

The end of the nineteenth and beginning of the twentieth century was marked by the movement for the democratization of the Tatar written literary language, for its approach to the Tatar folk. This process found a vivid expression in the works of the Tatar literary figures, including G. Tukay who made great efforts in the struggle for the purity of the language, demanded not to use Old Tatar especially incomprehensible to people Arabisms in the language of the works. In this situation the problem of relation to the dialecticisms becomes particularly urgent. The studies have shown that in the works of G. Tukay dialecticisms are used intentionally: in accordance with the requirements of the style, figurativeness, more vivid reflection of shortcomings of the forms of the native dialect in the society of the time. When interpreting the comparisons from the history of Tatar language, ethnography data, the comparison of different dialects and languages are shown. The versatile analysis of dialecticisms in the language of the classics provides to deeper reveal the processes occurring in the formation of the Tatar literary language of the early twentieth century.


Билгеле булганча, хәзерге татар әдәби теле формалашуда XX гасыр башы әһәмиятле һәм нәтиҗәле чор булды. Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Г. Камал, М. Гафури, Г. Исхакый кебек әдипләребезнең иҗат теле әлеге чорда әдәби телне халыклаштыру юлында аеруча максатчан эшләделәр [1]. Беръяктан, язма әдәби телебезне иске татар язма әдәби теле элементларыннан арындыра бардылар, икенче яктан исә гади сөйләм элементларын куллануда да сак һәм таләпчән булдылар.

Г. Тукай иҗаты да менә шушы үзенчәлекле чорга туры килде. Күзәтүләргә караганда, Г. Тукай теленең халыклашуы шактый кызу темплар белән бара, иҗатының азагына таба аның әсәрләрендә иске татар язма әдәби теленең күпчелек үзенчәлекләре күзәтелми башлый. Шулай да хәзерге татар әдәби телгә нигез салучыларның берсе булган әдибебез Г. Тукайның әсәрләре телен тикшерү ул яшәгән чорны, шул чорга хас телне дә өйрәнергә мөмкинлек бирә. Тел белемендә, милли тел әдәби тел һәм диалект теле дигән ике төрнең берлегеннән тора дип карала [3, б. 100–105].

Г. Тукайның әсәрләрен диалектолог күзлегеннән чыгып махсус өйрәнү әдипнең гади сөйләм элементларын, җирле сөйләшләргә генә хас булган күренешләрне өнәп җиткермәвен, телнең сафлыгы, чисталыгы мәсьәләсенә җитди каравын күрсәтә.

С. Сүнчәләйгә юллаган хатларының берсендә «төп халык телендә булмаган сүзләр[не] катыштырмасагыз икән» дип яза һәм мисал итеп «булмай» сүзен китерә [6, б. 5, 95].

Г. Тукай әсәрләрендә диалектизмнар чагыштырмача сирәк күзәтелә. Алар, нигездә, түбәндәге максатлардан чыгып кулланыла: а) әдипнең туган төбәгенә хас сөйләшнең чагылышы; б) җәмгыятьтәге шул чорга хас җитешсезлекләрдән көлүне (юмор, сатира, сарказм, гротеск) көчәйтү; в) персонажны тулырак сыйфатлау, калкурак гәүдәләндерү һ.б.

Биредә Г. Тукай әсәрләрендә чагылыш тапкан диалекталь күренешләргә кыскача күзәтү тәкъдим ителә. Алар, тел белемендә кабул ителгәнчә, өч төркемгә бүлеп карала.

1. Авазлар кулланылышы белән бәйле үзенчәлекләр.

Ике сузык арасындагы [д] авазының яңгыраулашуы: йозрык (сөйләм телендә йозырык) – йодрык. Мондый фонетик күренеш казан арты (бигрәк тә мамадыш), минзәлә, бөре сөйләшләрендә билгеле бер төркем сүзләрдә (изән – әд. идән, қазақ – кадак, Изел – Идел, йозрык – йодрык, Бәзерттин – Бәдертдин һ.б.) шактый даимилек саклый торган фонетик күренеш. Ягъни әдипнең туган сөйләшенә хас үзенчәлек.

[ң] авазы янында [ғ], [г] авазы өстәлү. Мәсәлән: иңгүче – иңүче, исеңгә – исеңә, нәселеңгә – нәселеңә, өстеңгә – өстеңә һ.б.

Бу күренеш тә Г. Тукайның туган сөйләшенә хас үзенчәлек. Билгеле булганча, ул хәзерге Татарстанның Әтнә, Дөбъяз, Арча, Биектау районнарында һәм шулай ук Мари Элнең Бәрәңге төбәгендә актив күзәтелә торган үзенчәлекләрнең берсе [4, I, б. 19–78].

Бүрек, күрек, күрекле сүзләрен көнбатыш диалекттагыча бүрке, күрке (мәсәлән, бүркесе, күркеле) вариантында куллану очраклары теркәлгән.

2. Морфология өлкәсенә караган үзенчәлекләр.

Хәзерге заман хикәя фигыльләрдә һәм *нинди* сорау алмашлыгында әдәби телдәге *-ый/-и(й)* кушымчасын киң вариантта куллану Г. Тукайның, нигездә, башлангыч иҗатында күзәтелә: *язаем* (I, б. 25) – әд. языйм, *ниндәй* (I, б.26) – нинди, *түзмәерди* (I, б. 27) – түзми иде, *нишләем* (I, б. 29) – ни эшлим, *булмаенча* (III, 89) – булмыйча һ.б. Шунысы характерлы, мондый күренеш төрки, шул исәптән татар теленең дә тарихи үсеш этабын чагылдыра. Билгеле булганча, бу кушымча борынгы төрки телдә, шулай ук исәптән борынгы татар телендә дә, -аг(ы)/-әг(е) (> -ай)/-әй > -ый/-и(й) вариантында кулланылган, татар теленең урта һәм себер диалектларына хас, ләкин ул урта диалектның периферияләге (мәсәлән, Урал төбәге, Киров өлкәсе һәм Удмуртия), яисә теге яки бу сәбәпләр аркасында үз эчендә үсеш-үзгәреш кичерә торган керәшен, касыйм сөйләшләрендә генә сакланып килә, ә Казан артында һәм Тау ягында таралган урта диалект сөйләшләрендә, мишәр диалектында бу кушымча хәзерге әдәби телдәге вариантта әйтелә. Димәк, Г. Тукай чорында, әле язма әдәби тел традицияләре дә үзен шактый көчле сиздереп торган чорда, *-ай/-әй* варианты, гәрчә шагыйребез аны яратмаса да, кулланыла торган булган, кисәк кенә төшеп кала алмаган.

Алмашлыкларның юнәлеш килеше даими рәвештә *аңгар* – әд. аңа, *моңгар* – моңа, *шуңгар* – шуңа формасында кулланыла. Билгеле булганча, *-гар/-гәр* кушымчасы борынгы күренеш булып санала, ул татар теленең урта диалектында, аеруча Дөбъяз, Әтнә төбәкләрендә, бәрәңге (Мари Эл), керәшен, бастан, нурлат сөйләшләрендә бар.

Әсәрләрдә тагын урта диалект сөйләшләренә хас булган *кайсысы* – әд. кайсы, *ауганчыга кадәр* – әд. ауганчы, *торганымда* – әд. торганда (чагышт.: шулай ук мамадыш, пермь сөйләшләрендә һәм тубыл-иртыш, бараба диалектларында), *күрем* – әд. күрермен, *язарым* – язармын кебек күренешләр, җирле сөйләшләрдә генә сакланып калган *мисале, мисле* [Г. Тукай, I, б. 148, 208; 48] чагыштыру бәйлекләре һ.б. күрсәтергә мөмкин.

«“Заманымызның әдип вә мөхәррирләренә гаид” мәкаләсенә гаид» әсәрендә *көчәрез* – күчәрбез, *бөерез* (бөегербез) – күтәрелербез формалары теркәлгән. Аларның тубыл-иртыш, бараба һәм том диалектларындагы *барырыс* – барырсыз, *күрәрс* < *күрәрсес* < күрерсез формалары белән зур охшашлыгы бар. Җирле сөйләшләрдәге мондый янәшәлекләр татар теле һәм аның әдәби төре тарихларын өйрәнгәндә һичшиксез искә алынырга тиеш.

Г. Тукай әсәрләрендә *ул* алмашлыгының *у, шул* алмашлыгының *шу* вариантлары теркәлгән. Шундый ук вариантлар хәзерге көндә татар теленең борынгылыкны үзендә аеруча нык саклап килә торган пермь, красноуфим, нократ, златоуст, тепекәй сөйләшләрендә, себер диалектларында, һәм күп кенә төрки телләрдә дә яшәп килә.

Җирле сөйләшләрдә дә, иске әдәби телдә дә, Г. Тукай әсәрләрендә дә *исә* теркәгеченең фигыль формаларына ияреп килү күренеше бар: *киптисә* < кипте исә [I, 206] – әд. кипсә; *үләрсәм* < үләр исәм [I, 41] – үлсәм; *яздымсә* < яздым исә [I, 18] – язгач, *беттисә* < бетте исә [II, 34] – бетсә, *таптым исә* – тапсам, *тыңладисәң* < тыңладың исә [II, 21] – тыңласаң, *калдыйсәң* < калдың исә [II, 24] – калсаң һ.б. Иске татар язма әдәбиятында бу конструкция, «Кыйссаи Йосыф»тан башлап, XX йөз башына кадәр актив кулланылып килә, нигездә эш яки хәлләрнең башкарылу вакыты ягыннан эзлеклелеген белдерә. Хәзер ул, аеруча, Урал төбәге сөйләшләрендә актив, вакытны, шартны, еш кына икеләнүне, шикләнүне дә белдерә [2, б. 88–98].

Билгеле булганча, татар теле, аның сөйләшләре фигыль формаларына бай. Мондый хәл иске татар язма әдәби телендә үк күзәтелгән. Г. Тукай иҗатында исем фигыльнең *-мак/-мәк* формасы төрле мәгънәләрдә кулланыла. *Бул-* ярдәмче фигыле белән килгәндә, ниятне, исәп итүне белдерә һәм хәзерге әдәби телдәге *–макчы/-мәкче (була)* төзелмәсенә туры килә: *кулдан ычкынмак була, .... бер-бер эш кылмак була*. Татар теленең бараба диалектында мондый форма шушы ук мәгънәдә системалы рәвештә кулланыла, мөстәкыйль грамматик категорияне тәшкил итә [4, II кит. ].

*-мак/-мәк* формасының юнәлеш килеше формасы максатны белдерә: *Әйдә халыкка хезмәткә, хезмәт эчендә йөзмәккә* һ.б.

Билгеле булганча, татар теленең урта диалектына караган нурлат, минзәлә, тау ягы керәшеннәре һ. б. сөйләшләрендә *-малы/-мәле* кушымчалы сыйфат фигыль таралган, ә казан арты сөйләшләрендә ул күзәтелми. Әмма бу форма Г. Тукай яшәгән һәм иҗат иткән чорда әле кулланылышта булган булса кирәк, чөнки шагыйрьнең Әхмәт Урманчиевка язган хатында һәм башка кайбер әсәрләрендә *тырышмалы* (әд. тырышасы, тырышырга кирәк мәгънәсендә) кебек очраклар теркәлгән. *-малы/-мәле* формасы татар телендәге болгар чорыннан килә торган борынгы күренешләрнең берсе. Ул нурлат, минзәлә сөйләшләрендә активлыгын хәзер дә саклый. Башка төрки телләрдән угыз телләренә хас.

3. Өченче төркем диалектизмнарны Г. Тукай әсәрләрендә кулланылган диалекталь сүзләр тәшкил игәләр. Бу төркемгә күптөрлелек хас.

Диалекталь сүзләрнең күпчелеге гади тормыш-көнкүрешкә карый, Г. Тукай иҗатында алар төрле жанрдагы әсәрләрдә, шулай да күбесенчә, халык җырлары көлтәләрендә табыла: *чабын* – әд. чабынлык, *бүз тургай* (камышлы сөйләшендә *бастургай*) – бүдәнә, *бистургай* – тургай, касыйм сөйләшендә *бустыр'ай* – тургай (күрәсең, элек бу сүз киңрәк ареалда таралган булган), *ызба* – өй, йорт (бу сүз этрусклар телендә үк, ягъни безнең эрага кадәр үк булган, каралты мәгънәсендә кулланылган), *хәстәлек* – чир, *хәстә төсле* – авыру төсле, *хәстә ятып* – чирләп ятып, *хәтем* – коръән (хәзерге көндә бигрәк тә мишәр һәм себер диалектларында актив кулланыла), *кортка* – карчык, *аңкаулык* – аңгыралык, ахмаклык, *зипун* – эш алъяпкычы, *пашча* – патша, *кәпәч* – түбәтәй (аеруча себер диалектларында, Оренбург төбәге сөйләшләрендә киң таралган), *кәкре калфак* – сөйләшләрдә хәзер дә беләләр; *әмирхан читек* – байлар гына кия торган читек, *пима* – киез итек, *серкә* (*чабатаңның сиксән сигез серкәсе*) – яшь кызларга, яшь киленнәргә кешлеккә кияргә чабатаның йөзен нәфисрәк юкәләр белән төрлечә бизәп, ягъни *серкәләп* ясый торган булганнар һ.б.

Күргәнебезчә, лексик үзенчәлекләр төркемендә көнбатыш диалектка хас сүзләр дә (зипун, аңкау, хәстә һәм аның нигезендә ясалган тәгъбирләр һ.б., *бүрек* сүзенең *бүрке,* күрек сүзенең *күрке* вариантларында, ягъни мишәрчә кулланылуы) игътибарны җәлеп итә. Шулай итеп, Л.Т. Мәхмүтова һәм Н.Б. Борһановаларның казан арты сөйләшләрендә йомышлы татарларның (башта алар мишәрләрдән генә торганнар) эзе калган булу турындагы фикерләре XIX йөз азагы – XX йөз башындагы җирле сөйләш материаллары белән раслана.

Г. Тукай әсәрләрендәге диалектизмнарны тикшерү хәзерге көндә аерым сөйләшләрдә генә сакланып калган үзенчәлекләрнең XIX йөз азагы – XX йөз башында шактый актив һәм киңрәк кулланылганын күрсәтә. Мәсәлән, *гамь чигү, зәхмәт чигү* (чагыштыр: әдәби телдәге *газап чигү), рәхәт сөрү* – әд. рәхәт чигү; *хәттән тыш* (пермь сөйләшендә *хәттин ашкан*) – искиткеч һ.б.

Г. Тукай әсәрләренең теле үзенчәлекләргә бай һәм аларны төрле аспекттан чыгып карарга мөмкин. Диалектизмнарны тикшерү, язучының тел-стиль үзенчәлекләрен генә түгел, татар әдәби теленең формалашу тарихын өйрәнү өчен дә зур әһәмияткә ия.

ӘДӘБИЯТ

1. Бәширова И.Б. XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби теле: исем категорияләре һәм фигыль наклонениеләрендә әдәби норма вариантлылыгы һәм функциональ-стилистик вариантлылык. Казан: КДТУ нәшр., 1999. 576 б.

2. Рамазанова Д.Б. Общие особенности говора пермских татар со старотатарским литературным языком // Истоки татарского литературного языка. Казань, 1988. 88-99 б.

3. Рамазанова Д.Б. Диалектный язык как одна из разновидностей национального языка // Единство татарской нации. Казань, 2002. Б. 100–105.

4. Рамазанова Д.Б. Урта диалект // Татар халык сөйләшләре. 2 китапта. Беренче һәм икенче китап. Казан: Мәгариф, 2008.

5. Рамазанова Д.Б. Г. Ибраһимов иҗаты: башлангыч чоры әсәрләренең теленә күзәтүләр // Г. Ибраһимов мирасы һәм төрки дөнья. Казан, 2012. Б. 196–198.

6. Тукай Г. Әсәрләр. 5 томда. 5 том: Истәлекләр, юлъязмалар, хатлар. Мәсәлләр һәм балалар өчен хикәяләр (1902–1913). Казан: Татар. кит. нәшр., 1986.

## ТУКАЙ ШИГЪРИЯТЕНДӘ СОМОНИМИК ЛЕКСИКА

***Сабитова И.И.***

В статье рассматриваются сомонимы, использованные в произведениях Г. Тукая. На основе анализа установлено, что в поэзии Тукая встречаются сомонические единицы и их дериваты. Также в рамках одного произведения отмечен частый повтор одних и тех же сомонимов. Тукай в стихотворных строках активно использовал сомонимическую лексику, особенно часто употреблял лексемы баш ‘голова’, тел ‘язык’, күз ‘глаза’, бит ‘лицо’.

The article deals with somonyms used in the works of G. Tukay. On the basis of the analysis it was found that somonymic units and their derivatives were used in Tukay’s poetry. Also the frequent repetition of the same somonym is marked throughout one work. Tukay made active use of somonymic vocabulary in poetic lines, especially such lexical items as bash ‘head’, tel ‘tongue’, kuz ‘eyes’, bit ‘face’.

Көндәлек тормышта, аралашуда бик еш кулланылган әгъза атамалары халкыбыз шагыйре Габдулла Тукай әсәрләрендә дә зур чагылыш таба.

Тән әгъзаларын белдерә торган лексика тел белемендә соматик терминнар яки соматизмнар дип атала. Алар үзләре зур биш төркемгә бүлеп карала: сомонимнар, остеонимнар, спланхнонимнар, ангионимнар, сенсонимнар, кеше организмының төрле авыруларын һәм эчке халәтен белдерә торган лексика [3, б. 6].

Сомонимия соматик лексиканың иң зур бүлеге. Р.Ю. Мугу сомонимнарның үзләрен биш төркемгә бүлеп тикшерә: кеше гәүдәсе өлешләрен гомумән атый торган лексемалар; баш һәм аның өлешләре атамалары; муен һәм гәүдәнең аерым өлешләре атамалары; югары очлыклар атамалары һәм түбән очлыклар атамалары [4, б. 81–82].

Бу мәкаләбездә Тукай әсәрләрендә очраган сомонимик лексикага – сомонимнарга һәм аларның дериватларына күзәтү ясарбыз. Анализ өчен К.Р. Галиулин һәм Р.Н. Кәримуллиналар тарафыннан төзелгән «Габдулла Тукай: Шигърият теле: Сүзлек»не алдык. Әлеге сүзлекне әдипнең шигъри әсәрләре материаллары тәшкил итә һәм ул күләмле ике китаптан тора.

Сомонимнарның беренче төркемен **гәүдә, тән, сан, очлыклар** кебек атамалар хасил итә. Тукай «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» әсәрендә берничә тапкыр **гәүдә** сүзен куллана:

*Гәүдәсе юк бер гаҗәеп Баш ирер.*

**Гәүдә** атамасы белән беррәттән әдип **тән** атамасы белән дә эш иткәне күренә:

*Газап китми кабердә тән черүдән* (Катиле нәфескә).

Кеше тәне әгъзалары атамаларының икенче төркеменә Тукай бик еш мөрәҗәгать иткән. Моның шулай булуын **баш** соматизмының күп тапкырлар очравы дәлилли:

*Баш өстендә алтын зонтик күләгәле* (Япон хикәясе).

Шагыйрь әсәрләрендә әлеге лексеманың семантик кыры искиткеч киң икәнлеге күренә. **Баш** сүзе төп лексик мәгънәдә генә түгел, күчерелмә мәгънәдә дә еш кулланылган. Аның фигыль дериватлары, кушымчалау юлы белән ясалган дериватлары да шактый:

*Түшәлә* *башлый* *томан* (Тәүлек).
*Һәр бәхетнең башы шуннан* *башлана* (Кулың).
*Чөнки хәзер* *башлыклары* *китеп качты* (Кәҗә белән Сарык хикәяте).
*Дин эшендә* *башчы* *иттек без аларны* (Дустларга бер сүз).
*Күрәмсез: бу кырык* *башлы* *чаян бит* (Рәсемгә ишарә).
*Башаклар* *пеште* (Елның дүрт фасылы).
*Моннан* *башка* *юктыр сезне кызганучы* («Тавыш» хакында).
*Камчылар – шул иске камчы,* *башкалык* *– тик фәсләре!* (Китмибез!).
*Шул ук сәгать үземнән,* *башкалардан* *баш-күз алдым да* (Пәйгамбәр).

**Баш** сүзе белән кушма, тезмә һәм парлы сүзләр дә ясалган:

*Җанкәй-җанаш,* *пумала баш,* *чыкма урамга* *җаланбаш* (Киңәш).
*Бөтен* *бит-баш* *кызарды, тотты кызма* (Ысуле кадимче).
*Тирбәтә һәм* *өстен-башын* *каплап тора* (Ай һәм кояш).
*Шул ук сәгать үземнән, башкалардан* *баш-күз* *алдым да* (Пәйгамбәр).

**Авыз//ауз** лексемасы белән Тукай шактый күп эш иткән:

*Нинди елмайган* *авызлар*! *Күрсәнә, ул нинди шат!* (Мияубикә).
*Һавадин очкан кошларның* *аузы* *тулы балавыз* (Безнең эти аягында).

Шулай ук **авыз//ауз** сүзенең дериваты да очрый:

*Нигә пивнойда татарларның* *авыз-борны* *каный?* (Нәрсәдән).
*Аузы-борны* *сасып, өст-баш тынчып кайта* (Фөрьяд).

Бу төркемгә караган лексекадан, сирәк булса да, **ияк, ирен, маңлай (маңгай), яңак** кебек атамалар да күренә:

*Борнын, аузын,* *иякләрен,* *беләкләрен* (Утырышу).
*Үбү булса әгәр чут-чут,* *ирен* *һәм бит кабарганчы* (Иһтида).
*Яңак,* *маңлай* *җыйрылмаган, тешләр дә сау* (Бабай).

Ешрак **борын, каш, колак, теш, чәч//сач** сомонимнары һәм аларның дериватлары кулланылган:

*Уянмый ул, селкетми дә* *борын* *очын* (Карлыгач).
*Бик матур бит, бакчы бу кызның күзенә,* *кашына* (Бер рәсемгә).
*Кайвакытта кара күзле, кара* *кашлы* (Шүрәле).
*Йөрмәсен бәгъре өзек милләт киеп* *кашсыз* *йөзек* (Татар яшьләре).
*Мужикларның тырма* *теше* *кеби* *тешең* (Суык).
*Әүкатлене* *тешли* *алмый салкын, суык* (Суык).
*Колакны шаулата инде суык җил* (Көз).
*Чәч* *тararга бер печәнлектән алган тырма, ди* (Яз).
*Мөселманнарны сатабыз* *чәчле* *абзыкайларга* (Сагыныр вакытлар).
*Шул тарак белән утыра тузгыган* *сачен* *тарап* (Су анасы).
*Тотса баштан* *сачтараш,* *шылтыр да шылтыр җон ага* (Саташкан).

**Бит** сомонимы иң күп очрый торган лексемаларны берсе. Шулай ук аннан ясалган кайбер ясалма сүзләр дә бар:

*Электә бер кешедә бар иде киң* *бит,* *зур ындырдай* (Борын).
*Бөтен* *бит-баш* *кызарды, тотты кызма* (Ысуле кадимче).
*Тәшагыйрь итмә, зинһар, кермә шагыйрь* *битлегенә* *син* (Мөтәшагыйрьгә).

**Бит** атамасының синонимы буларак **йөз** сүзе дә үзенең дериватлары белән еш кулланылган:

*Тулган айга охшаш* *йөзе,* *башы аның* (Сөбханалла, сөбханалла).
*Алсу* *йөзле* *кызларын* (Шүрәле).
*Көлгәннәр* *йөзтүбән* *китте, – аллаһ дигел, бәдәвам* (Кыямәт якын килде).

**Тел** соматизмы татар телендә киң семантикага ия. Тукай аны үзенең шигырьләрендә туры мәгънәсендә кулланмый. Ул **тел** сүзенең күбрәк «үзара аралашу, аңлашу өчен сүзләр һәм грамматик чаралар системасы» дигән мәгънәсен файдаланган:

*И туган тел, и матур тел,*
*Әткәм-әнкәмнең теле!*

**Тел** сүзенең телебездә сүзьясалыш потенциалы югары. Бу Тукай әсәрләрендә дә чагылыш таба (*теләк, теләү, теләнү, телем, теләнче, телләнү, телле, телсез*):

*Сиңа теләк теләрем* (Бишек җыруы).
*Бер теләнче керсә йортка,*
*Син бирәлсең бер телем* (Сагыныр вакытлар).
*Йә теләп син, йә фәкыйрь кардәшне көчләргә кереш!* (Толстой сүзләре).
*Ник бүген атлар, сыерлар*
*Сөйләшәләр телләнеп?* (Нәрсәдән?).
*Бездә байтак зур авызлы,*
*Оста телле* бәндәләр (Бәндәләр).
*Ире булса сукыр, ул җитми, –*
*Булсын һәм хатын телсез* (Гаилә тынычлыгы).

Аеруча күп кулланган сомонимнарга **күз** атамасы керә. **Күз** сүзе туры мәгънәдә генә түгел, күчерелмә мәгънәдә дә бик еш кулланылган. Шулай ук бу сүздән ясалган ясалма сүзләр дә очрый:

*Күз һаман булды эренле, йөз дә саф һәм пакъ түгел* (Аң).
*Ихтыярсыз, ди, әбинең йортына ул күз сала* (Казан вә Казан арты).
*Килсә байның ач халыкны күзгә-күз мыскыллысы* (Сайфия).
*Күзне-күзгә текәшеп* (Поезд барган көйгә).
*Түбәнгә күз дә салмыйлар, һаман күкләрне күзлиләр* (Янә).
*Яшьле күзле, моңланганнар вә зарлылар* (Кышкы кич).

Тукай әсәрләрендә өченче төркемгә караган **муен** һәм **гәүдәнең** аерым өлешләре атамалары (**муен, арка, җилкә, бил, күкрәк, корсак**) һәм аларның кайбер синоним вариантлары да урын алган (**сырт, түш, эч**):

*Салган Сабит муенны, оныткан ул уенны* (Сабитнең укырга өйрәнүе).
*Ике туры ат уйныйдыр,*
*Муйны кыйгач буйлыдыр* (Авыл җырлары (дүртенче көлтә).
*Суык чөнки – сызлый арка һәм җилкә дә* (Суык).
*Сөям кысмыйча нечкә биленезне* (Татар кызларына).
*Бере күкрәгенә берсе кылычларын чәнечкәннәр* (Алтын әтәч).
*Күп эчелгән – шартлый язды корсагым* (Туйга бардым)
*Хатын булдым зур корсаклы бер симезгә* (Мактанышу).
*Ләкин ләкми калды сыртым тәртәгә* (Кәҗә тугърысында).
*Йөртәм күзне: калкып чыккан түшен карыйм* (Утырышу).

**Корсак** сомонимына синоним булган **эч** сомонимы бик еш очраса да, туры мәгънәсендә ул берничә тапкыр гына кулланыла. Бу атаманың татар телендә киң семантикага ия икәнлеге Тукай шигырьләре дә ачык чагылдыра:

*Бозарсың ашказаныңны,*
*Килешми эчкә анлар!» – ди*. (Төлке һәм Йөзем җимеше).
*Төлке эчле тун җибәрде күп суыкларны куып* (Өч хакыйкать).
*Эчкәне балдан, шикәрдән, ашлары тик май иде* (Теләнче).
*Гаҗиз булдым эчем-тышым туңганга мин* (Суык).
*Эчемлекләр бөтенләй бесплатный* (Ысуле кадимче).

Югары очлыклар атамаларыннан торган дүртенче төркемгә **кул** һәм аның өлешләрен белдерә торган **беләк**, **бармак**, **тырнак** сомонимнарын да Тукай әсәрләрендә күрергә мөмкин.

*Борнын, аузын, иякләрен, беләкләрен* (Утырышу).
*Шүрәленең бармагы калды кысылды шап итеп* (Шүрәле).
*Көче күп, тырнагы үткен, явыз ул* (Күк сыер).

Әсәрләрдән күренгәнчә, **кул** сомонимы бик еш кулланган. Аннан ясалган дериватлар да бар:

*Матур кыз ханны кулыннан тотып кергезде чатырга* (Алтын әтәч).
*Кулымдагы кулҗаулыгым дүрт почмагы өй хәтле* (Безнең эти аягында).

*Кул-аягы, гәүдәсе килде янә* (Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш).
*Һәм гомерлек ярыны*, *кулдашыны* (Кечкенә генә бер көйле хикәя).

Борынгы татар язма әдәбияты әсәрләрендә **кул** мәгънәсендә, нигездә, *әл/әлег* сүзе кулланылган. Тукай да «Гыйшык бу, йа!» әсәрендә **әл** сүзен куллана:

Әл-аяк багълы, мөхаль кортылмакым, мәсхүреңем.

Сомонимнарның соңгы төркемен **аяк** һәм аның өлешләрен белдергән сүзләр, ягъни түбән очлык атамасы хасил итә. Тукай, **аяк** сүзенә шактый күп мөрәҗәгать иткән:

Утыралар аяк бөкләп каршы утка (Кәҗә белән Сарык хикәяте).

Шулай ук **аяк** лексемасының кызыклы гына дериватларын да күрәбез:

Бөтенләй бәйләнә анда аяк-кул (Өйләнү түгел сөйләнү).
Караңгыга юешкә төште ул нәкъ кыргаяк төсле («Йолдыз» һәм «Кояш»).
Боз өстендә тимераяк белән шуып (Суык).
Яланаяк малайлар йөгерә фәйтун артыннан (Алтын әтәч).

Сирәк кенә булса да **бот, сыйрак, үкчә, тәпи, табан, тез, тубык** кебек лексемалар да очрый:

Бот сузып яттылар (Мужик йокысы).
«Мин беләм»лек дәгъвасын
Кыйлган була, салам сыйрак! (Мияубикә).
Бай калошына табан һәм үкчә булган Мостафа
(Һазиһи касыйдәтен фи мәдхи Мостафа).
Арт аяк һәм ал тәпиләрне идәнгә нык басып (Мияубикә)
Ике ат бер тиен, диңгез тубыктан
Тиң әле аңгар! (Бишектәге бала).

**Тез** сүзе белән бергә аңардан ясалган дериват та бар:

Үзләре ... сүздән түбән, күзләре тездән түбән (Дошманнар).
Кыйл дога, ихлас белән тезлән дә
Кыйбла каршына (Таян аллага).

Анализдан күренгәнчә, шагыйребез Габдулла Тукай үз әсәрләрендә сомонимик лексика һәм аның дериватларын киң кулланган. Бер әсәрдә бер үк сомонимик берәмлекнең күп тапкыр кулланылуы да күзәтелә. Әдип бигрәк тә сомонимнарның икенче төркеменә караган (*баш, тел, күз, бит*) атамалары һәм аларның дериватлары белән еш эш иткән. Шул ук вакытта *кул*, *аяк* сүзләрен дә күп кулланган.

ӘДӘБИЯТ


1. Габдулла Тукай: Шигърият теле: Сүзлек. 2 китапта. 1 кит. / К.Р. Галиуллин, Р.Н. Кәримулина. Казан: Мәгариф, 2009. 503 б.
2. Габдулла Тукай: Шигърият теле: Сүзлек. 2 китапта. 2 кит. / К.Р. Галиуллин, Р.Н. Кәримулина. Казан: Мәгариф, 2009. 527 б.
3. Кочеваткин А.М. Соматическая лексика эрзянского языка: Учеб. пособие. Саранск: Тип. «Крас. Окт.», 2001. 208 с.
4. Мугу Р.Ю. Полисемантизм соматической лексики (на материале русского и немецкого языков): дис. … канд. филол. наук: 10.02.01., 10.02.20. / Адыгейс. гос. ун-т, Майкоп, 2003. 189 с.


## КОНЦЕПТ *ГАДЕЛЛЕК* (СПРАВЕДЛИВОСТЬ) В ПОЭТИЧЕСКОЙ КАРТИНЕ МИРА Г. ТУКАЯ


***Сагдеева Ф.К.***



В статье рассматривается семантическая плотность концепта *гаделлек* (справедливость) в поэтической картине мира Г. Тукая. Данный концепт относится к числу концептов, отражающих гипостазированные свойства и отношения (благо, зло, истина, свобода), что подтверждает его ценностную значимость.

This article discusses the semantic density of a concept *gadellek* (justice) in G. Tukay’s poetic picture of the world. This concept refers to a number of concepts that reflect hypostatized properties and relationships (good, evil, truth, freedom), that confirms it’s valuable importance.

Поэтическая картина мира несет в себе черты языковой личности ее создателя. Она является индивидуально-авторской и в значительной степени субъективна. Это образная картина, в которой личность поэта предстает как отражение ее существования. В такой картине мира реальность отображается через призму сознания и языка поэта. Материальным выражением поэтической картины мира является единое текстовое пространство произведений поэта. В поэтической картине мира слово является одним из важнейших средств выражения духовности поэта.

Поэтическое слово имеет сложную структуру. По мнению В.А. Масловой, «…в поэтическом слове есть и рациональная и эмоциональная семантика. Рациональная часть семантики слова – это та часть лексического значения, функцией которого является манифестация экстралингвистической реалии или ситуации, ее рациональная оценка. Эмоциональная часть семантики – это та часть значения, функцией которой становится языковая манифестация или вызывание эмоций и эмоциональных отношений» [3, с. 21].

В поэтическом тексте функционирование лексики подчинено конкретным идейно-художественным задачам. Между словами образуются новые семантические отношения.

Понятийная составляющая концепта выявляется через компонентный анализ значений базовых номинаций и словарных дефиниций, актуализирующих данный концепт, и, прежде всего имени концепта. Содержательный минимум понятия *гаделлек* (справедливость) в «Этимологическом словаре татарского языка» Р.А.Ахметьянова передается при помощи арабского слова *гадәләт, гадаләт* кит. «справедливость, равноправие» [2, с. 228]. В трехтомном Толковом словаре татарского языка зафиксированы следующие значения слова *гаделлек*: 1. Дөреслек, хаклык, хакыйкать. 2. Гадел булу, тугрыклы булу.

Творчество Г. Тукая пронизано кораническими мотивами [1].

В исламе понятие *гаделлек* (справедливость) имеет особую значимость. Данное понятие включается в область морально-нравственной аксиологии. В Священном Коране сказано: «О те, которые уверовали! Свидетельствуя перед Аллахом, отстаивайте справедливость, если даже свидетельство будет против вас самих, или против родителей, или против близких родственников. Будет ли он богатым или бедным, Аллах ближе к ним обоим. Не потакайте желаниям, чтобы не отступить от справедливости. Если же вы скривите или уклонитесь, то ведь Аллах ведает о том, что вы совершаете» [«ан-Ниса»: 135].

Идея справедливости затрагивается и в суре «ан-Нахль»: «Воистину, Аллах повелевает блюсти справедливость, делать добро и одаривать родственников. Он запрещает мерзости, предосудительные деяния и бесчинства. Он увещевает вас, – быть может, вы помяните назидание» [«ан-Нахль»: 90].

Быть несправедливым – харам и большой грех. Особенно следует быть справедливым тому, кто вершит правосудие среди людей: «Воистину, Аллах велит ... судить по справедливости, когда вы судите среди людей» [«ан-Ниса»: 58]. Всегда следует помнить, что самый справедливый судья – это Аллах. Он все видит, слышит и знает.

В текстовом пространстве поэтических стихов Г. Тукая особенно заметно формирование понимания личности как отдельного Я, как носителя социальных и субъективных признаков и свойств. В поэзии автора одним из понятийных компонентов справедливости становится социально детерминированная иерархическая структура, закрепленная в сознании в виде статусно-ролевой оппозиции. Внутренний конфликт нарастает по мере усиления противопоставления социальных слоев: *бай – хәерче, бай – фәкыйрь, бай – теләнче* и др.

Концепт *гаделлек* (справедливость) в поэтических текстах Г. Тукая представлен множественностью смыслов, которые передаются при помощи слов *дөреслек, хаклык, хакыйкать, гадил* и др. В своих основных значениях они являются синонимами, характеризуются тождеством денотативного компонента значения. Это проявляется в том, что эти слова имеют одинаковую референциональную соотнесенность: значение *гаделлек* как *истины.*

По мысли Г. Тукая, по отношению к бедным необходимо поступать справедливо. Богатый должен вовремя заплатить своему работнику и плата за выполненную работу должна быть достойной. Хотя само по себе отношение к деньгам, золоту и богатству у

поэта довольно негативное. Он считает, что все беды от золота. Люди перестают различать правду, потому что золото занавешивает истину. Например: Күрмиләр хакны, чөн алтын һәр хакыйкать пәрдәсе [т. 1, с. 174 ].

Представление о несправедливости жизни в поэзии автора объективируется антонимической оппозицией *чын – ялган*. В данном случае ложь (зло) побеждает правду (добро):

Әүвәле дөнъда җир юк, су гына булган, диләр;
Анда йөзгәннәр имеш тик *Чын* белән *Ялган*, диләр...
Көчле кулы берлә Ялган Чынны бер суккан ди дә,
Чын батып киткән, ди, чыкмаска җиһанга мәңгегә! [т. 1. с. 213].

Осмысление несправедливости жизни по отношению к бедному человеку передается при помощи языковых единиц, имеющих в своей семантике отрицательную коннотацию: *золым, көчләү, золым зарары и др.*

В поэтических стихах Г. Тукая образ несправедливого человека – *бая* представлен отрицательно: ленивый, пользуется чужим трудом, необразованный, лгун, не умеющий вести дела, обижающий своего работника и и сироту. Среди слов, которые характеризуют несправедливого человека, как человека обладающего какой-либо властью, выделяются антропонимы: *мулла, ишан, рухани* и др. При этом поэт духовенство отождествляет с животными. Так, например, происходит в стихотворении «*Муллалар»*:

Йөриләр бу кешеләр сөйрәлеп һәрдәм бәлешләргә;
Теләнми нишләсеннәр:кабилият беткән эшләргә.
Күнелдә утлары сүнгән, вә вөҗдан майга капланган:
«Әгүзе» дип кенә төшмәс, муенга шайтан атланган.
Менә шул чаклы ялкау, шундый хәйваннар да рухани!
Түбәнлек бу, кабул итмәс үзенә изге рух аны! [т. 2, с. 28]

В данном тексте употребление автором лексемы *хәйваннар* наряду с лексемами *муллалар, бу кешеләр, рухани* как бы расшатывает денотативные границы данного синонимического ряда, расширяя тем самым исходный смысл «несправедливый человек». Данные слова употребляются в значении «люди, ведущие неправильный образ жизни, совершающие неблаговидные поступки».

В поэтической картине мира Г. Тукая типология поведения, связанная с поисками справедливости, представлена в виде оппозиции - *богатые – бедные*, *свой – чужой*. Собирательный образ *чужого* формируют представления, касающиеся материальных, социальных и политических благ. Портрет *чужого* формируют значения слов, характеризующие богатого человека:

Күрдем әле синең *залимеңне:*
Һаман кәеф сөрә, типтерә;
Рәхәтләнә, *кяфер*! Сине шулай
Баганага сөяп киптерә [т. 2, с. 36].

*Свой* соответственно синонимическим рядам, характеризующим справедливого человека, праведен, человечен,совестлив, образован. Однако в действительности среди образованных таких людей мало:

Татар халкы арасында хисапсыз күп *зыялылар,*
Сирәк ләкин, дөрест әйтсәм, *кешелекле, хәялылар* [т. 2, с. 37].

Для поэтической картины мира Г. Тукая очень важными являются вопросы справедливости и несправедливости, отстаивание правды: принципов и убеждений. Жалкое положение обездоленных вызывает в душе поэта сильное чувство сострадания и сопереживания. Например:

Сизмисең бит син дә синең яннан
Нечкә күнел шагыйрь узганын,
Синең болай мискинләнгән хәлең
Аның күңлен ничек өзгәнен! [т. 2, с. 36].

Для Г. Тукая нравственные ценности являются практическим воплощением морали. Их особенность заключается в том, что они определяют сознание и мировидение автора, у которого понятие *справедливости* тесно связано с понятием *совесть*.

По определению В.И. Даля, «совесть – нравственное сознание, нравственное чутье или чувство в человеке; внутреннее сознание добра и зла; тайник души, в котором отзывается одобрение или осуждение каждого поступка; чувство, побуждающее к истине и добру, отвращение ото лжи и зла; невольная любовь к добру и к истине; прирожденная правда в различной развития» [4].

Представление о совести в поэтических стихах Г. Тукая передается следующими лексемами: *вөждан, намус, оят* и др.

Согласно морали, основанной на религиозных заповедях, совесть у человека должна быть чистой. В представлении поэта у маленького ребенка совесть чистая. Такое понимание связано с тем, что в душу ребенка еще не проникло что-то нечистое. Чистая совесть ассоциируется с чистой душой, чистым языком (в значении « неоскверненный ненужными словами»), чистым телом.

Следуя наивным представлениям, любой анатомический орган, покрытый жиром, плохо функционирует.В поэтическом образе Г. Тукая нематериальная субстанция совесть покрылась жиром: *вөҗданы майга капланган.*

Поэт понимает, что поступать по справедливости значит поступать по совести. С точки зрения языка, совесть представляет собой высшую нравственную ценность – добродетель. Отсутствие совести – нравственное падение.Совесть является своего рода мерилой правильных поступков. Поступки, противоречащие моральным принципам, вызывают неодобрение. Данное представление передается отрицательной формой: *вөҗданы юк, намусы юк, намуссыз* и др.

И в то же время Г. Тукай четко осознаёт, что совесть наносит ущерб: *вөҗдан зарары*, иметь совесть – тяжелая ноша, которая потянет тебя ко дну:

Вәләкин йөкләмә арканда *вөҗдан,*
Авыр ул бу йөзүдә кургашындан.
Батарсың син, сине ул төпкә тартыр;
Бу чын сүз: тыңладисәң, фәһмең артыр [т. 2, с. 29].

Из вышеизложенного видно, что концепт *гаделлек* (справедливость) в поэтической картине мира Г. Тукая представлен многогранно и затрагивает различные аспекты морально-нравственной аксиологии.

ЛИТЕРАТУРА


1. Абдуллина Д.М. Габдулла Тукай иҗатында Көръән мотивлары. Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. 191 б.
2. Әхмәтъянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге: Ике томда. Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015.
3. Маслова В.А. Поэтическая картина мира и роль в ней этимологической составляющей // Мир языковых форм. СПб., 2015. 277 с.
4. Даль В.И. Толковый словарь живого великорусского языка: В 4-х т. М., 1989.
5. Тукай Г. Әсәрләр: Биш томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985.


## ТУКАЙ ИҖАТЫНДА ФОЛЬКЛОРИЗМНАР


***Садыйкова А.Х.***



Тукай в 1910 году выступил с лекцией «Народная литература». Она затем была напечатана. Здесь он дает оценку фольклору, приводит легенды татарского народа о Шурале. В народном творчестве находятся истоки его поэм «Шурале», а также «Водяная». Фольклоризмы характерны для его поэмы-пародии «Сенной базар или новый Кисекбаш», где поэт использует как злую, враждебную силу персонаж народных сказок Дию-Див. Или в «Казань и Закабанье» – Убырлы карчык (Ведьма) Особое внимание он обращает песням, называет их чистым, нетускнеющим зеркалом народной души. Он сам записал около 30 старинных татарских песен, и они вошли в сокровищницу фольклора. Он писал стихи в духе народных песен. Много в его произведениях мотивов мунаджатов, освещающих тоску по матери, одиночество. Его стихотворение «Разбитая надежда» дала импульс многим народным мунаджатам о расставании.

Tatar poet Gabdulla Tukay in 1910 lecture "People's Literature". It was published in an article. This is the first work on the Tatar Folklore. Tukay examines such works, like fairy tales, legends, songs, folk art images. The poet uses folklorism in the poems "Shurale", "Water" and "Kazan and Zakabane". He writes about the old songs – clear mirror of people's souls, their uses in verse rhythms and rhymes of Bait – a unique genre of Tatar folklore. The popular image of a diva entered the poem "Hay market or new Kisekbash". Folk motifs constantly heard in his talented works.

Габдулла Тукай иҗатының фольклоризмы – аның үз иҗатында халык иҗатының сюжет-образ, мотивларын куллануы, борынгы татар әдәбиятының халыктан күчкән әсәрләрен файдалануы. Халык иҗаты турында иң беренче теоретик хезмәтне язучы шулай ук бөек Тукай. Башта «Халык әдәбияты» дигән лекциясен Тукай Шәрыкъ клубында укыган, 1910 елда ул аерым китап булып басылып чыккан. Тукай болай яза: «халык әдәбияты, халык шигырьләре дип иншан итүче шагыйре беленмәгән яки уйлап чыгаручысы вә әүвәл кем тарафыннан сөйләнгәнлеге мәгълүм булмаган хикәя вә масалларга әйтәләр» [5, б. 170]. Ул бу лекциясендә күбрәк халык җырларына туктала, башка жанр әсәрләрен искә ала – бәет, хикәя (әкият), бәет турында әйтеп үтә.

Аның атаклы «Шүрәле» поэмасының этәргече халык иҗатыннан икәнен күрсәткән язма да бар. «Халык әдәбиятының ничек булуын күрсәтер өчен, мин монда халык авызындагы кыска гына бер хикәяне язып алдым», – дип яза шагыйрь: Бер кешенең аты һәркөн хәлдән тая. Авыл карты атка сумала сыларга куша. Хуҗа шулай итә, сумалага Шүрәле каткан була. Аны кыйнап үтерәләр, керосин сибеп яндыралар. Ул җаны чыкканчы бу авылны каргый, авыл утыз өйдән артмасын иде, ди. Шулай була да. Болар халык хыялы, халык хикәясе. «Хикәя» не ул биредә әкият мәгънәсендә куллана. Шушы фольклор әсәрләре шагыйрь фантазиясе белән кушыла, аңа җирлек һәм гүзәл әсәр – «Шүрәле» поэмасы языла.

Шүрәле образы авыл егетенә антипод, зыян итүче образ булып, нәкъ халык әкиятенә охшаш булып, Тукайның поэмасында урын алган. Халык әкиятендәге кебек, аны батыр егет җиңә, явыз көч көлкегә кала. Әкият уңай тәмамлана.

Тукай Үзенең атаклы «Туган тел» дигән шигырендә әкиятне искә ала.

Иң элек бу бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән,
Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән [2, б. 65].

Аның хикәят дип билгеләгән жанры әкиятне аңлаткан. Г. Тукайның «Кәҗә белән сарык хикәясе» дә әкият жанрында иҗат ителгән. Мәсәлән, 1887 елда Казанда «Хикмәтле тутый хикәяте»н әкиятләр җыентыгы дип, «Тутыйнамәне» бастырып чыгаралар [6, б. 225]. Балачакта ишеткән шүрәле, су анасы турында әкиятләр Тукай әсәрләренең нигезендә ята, аның иҗатының фольклоризмнарын билгели. «Су анасы» дигән поэмасы шулай ук татар халык мифларындагы, әкиятләрендәге су анасы образына ияреп язылган. Тукай таланты аны мәңгеләштергән һәм педагогик мәгънәсен тирәнәйткән. Бала бу әсәр аша намуслы булырга өйрәнә, су анасының алтын тарагын алып качу аңа бик кыйммәткә төшә. Анасы аны нык орыша:

Мин дә шуннан бирле андый эшкә кыймый башладым,
«Йә иясе юк!» – дип, әйберләргә тими башладым [1, б. 284].

Тукайның фольклорны иҗади куллануы әсәрләрнең фольклоризмын тәшкил итә. Алар әдәбиятның гүзәл әсәрләре булып, дан алды.

Татар халык әсәрләренең тулы сюжетын файдалану белән беррәттән Тукай әкиятләрдән образлар, мотивлар алып файдалана. Мәсәлән, «Казан вә Кабан арты» дигән әсәрендә ул Кабан күле артында яшәгән убырлы карчыкны искә ала [6, б. 242]. Халык әкиятләрендә убыр үзенә очраган кешене хәйләләп көрәккә утырта һәм мичкә тыга. Тукай да шуны күрсәтә. Шушы образ аша татар кызларын фәхеш юлына тартучы явыз карчыкны тасвирлый, ул нәкъ әкият убыры булып күз алдына килеп баса.

Халык иҗатының тагын бер популяр образы аны борынгы «Кисекбаш» китабына назирә – пародия язарга этәрә.

Бу пародия Тукайга заманның тискәре күренешләрен тәнкыйтьләргә ярдәм итә. Ул елларда «печән базарчылары» Карахмәт дигән төрек көрәшчесен күрергә циркка йөриләр. Бу образны Тукай поэмада диюгә каршы көрәшче итеп күрсәтә. Дию татар әкиятләренең иң популяр персонажы. Ул күбрәк тылсымлы әкиятләрдә урын алган. Бу образ борынгы татар фольклорына иран мифологиясеннән кергән дип саныйлар. Ул 30 лап татар әкиятендә урын алган. Батырлар турындагы әкиятләрдә геройлар башлыча дию белән көрәшәләр һәм аны җиңәләр. Бу көрәш «Әйгәли батыр», «Таңбатыр», «Зөлкәрнәй батыр», «Турай батыр» һ.б. бик күп әкиятләрдә бар. Дию анда кешеләргә зыян китерүче булып сурәтләнә. Ул урлаучы дию, патша кызларын, патша хатынын, я алтын алмаларны урлый [2, б. 133]. Кешеләрне урлый, үтерә, ашый.

Г. Тукайның әйтелгән «Печән базары, Яхуд яңа Кисекбаш (1908) дигән поэмасында шушы урлаучы дию сурәтләнгән. Поэмада Пәһлеван Карахмәт, диюнең өненә

төшкәч, анда Кисекбашның урланган хатынын һәм тагын 500 мөселманны күрә. Диюнең гамәлләре әкияттәге кебе явыз. «Дию һәркөн бишәр адәмне» суя диләр әсирләр. Билгеле инде Карахмәт, әкияттәгечә, диюне җиңә [7]. Тукай дини эчтәлекле әсәргә заман сулышы өрә, әкиятне тормыш реалиясе белән кушып, оригиналь әсәр иҗат итә.

Тукай иҗатында үзе мөнәҗәт дип атаган әсәрләр очрамый («Бер шәехнең мөнәҗәте» дигән дигән сатирик шигыре бар). Әмма шагыйрьнең аерым әсәрләренең мотивлары аларны мөнәҗәт жанрына кертергә мөмкинлек бирә. Аның Аллаһыга мөрәҗәгать итеп, инанып язган шигырьләре бар, аерым дини бәйрәмнәр халык мөнәҗәте рухында тасвирлана: мәсәлән, «Васыятем» (1909), «Кадер кич» (1911), «Миграҗ» (1910) һ.б. Аның Пушкиннан үзгәртелгән «Тәүбә вә истигъфар» шигыре шаян рухта булса да, мөнәҗәт вәзенендә иҗат ителгән. Алааһыга багышланган әсәрләр белән беррәттән, мөнәҗәт туган илдән китү, балалардан аерылу, үлем көтү, якын кешеңне югалту кебек мотивларны үз эченә ала.

Тукайның «Өзелгән өмид»е (1910) классик мөнәҗәт темасына язылган: Ана үлеме, ятим баланың бәхетсезлеге, кабер өстендә күз яшьләре:

Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең каберең ташы, –
Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы! [2, б. 150]

Халык иҗаты исә үзе шагыйрь әсәренә мөрәҗәгать итә. Бу әсәр мотивларына татар халкы берничә мөнәҗәт иҗат иткән, алар һаман да халыктан язып алына. Болар «Анам кабере янында», «Үги бала зарый», «Егълыйм кабереӊ өстендә», «Ал мине, әнкәй, яныӊа» [8, б. 275] һ.б. Тукай шигырьләре мөнәҗәт жанрын баетуга зур өлеш керткән, яңа әсәрләр язуга этәргеч булган.

Тукай халык иҗатына көнчыгыш авторлары иҗатыннан, төрки шигырьләр иҗатыннан күчкән борынгы әсәрләрдән алып аерым мотивларны куллана. Бу да фольклоризмга үз өлешен кертә. «Мөхәммәдия», «Бакырган», «Бәдәвам»га нисбәтле язылган шигырьләре бар. «Таһир – Зөһрә», «Йосыф» китапларының тәэсир зур. «Дусларга бер сүз» (1905) дип аталган шигырендә Тукай бу турында бик ачык яза:

Менә, дуслар, мин сезләргә бер сүз сөйлим,
«Юсеф-Ягъкуб китаб»ының көен көйлим» [2, б. 42].

«Иттифак хакында» (1905) дигән шигыренең рифмасы «Бәдәвам» китабыннан алынган.

Ачыйк иттифакъка юл:
Ушбудыр иң тугъры юл;
Сыңар җиңнән ике кул
Чыгарыйк без, бәдәвам [1, б. 45].

Мондый иярүләр аның башлаангыч чор иҗатына хис. «Хәтирәи Бакырган» (1906) дигән шигырен ул «Бакырган китабы» (XII гас.) дигән шигъри җыентыктагы бер шигырьнең формасын (ритм һәм рифмасын) файдаланып язган. Борынгы әдәбият әсәрләренә ул житди әсәрләрендә дә, пародия өчен дә мөрәҗәгать итә.

Фольклорга турыдан-туры зур өлеш керткән әсәрләр Тукайның җырлар дәфтәренә кергән. Ул гасыр башында татар халкында популяр булган җырларны теркәп калдырган, 30 җыр кергән бу дәфтәргә. Аларның күп юллары халыкта һаман йөри, әмма күбесенең исемнәре дә онытылган. Г. Тукай, фольклор әсәрләрен җыеп, теркәп, аларны бөтенләй юк булудан саклап калган. Бу гүзәл әсәрләр XX гасыр дәвамында чыккан җыр җыентыкларында урын алган, билгеле. Аларның хронологиясен Тукай дәфтәрләре төгәл билгеләп калдырган. «Әдәбият ахшамы яки литературно-музыкальный вечер» (1906) дигән мәкаләсендә ул үзенең максатын билгели: «...карт аталарыбызның чын йөрәгеннән чыккан «Тәфкилеф», «Әллүки», «Сакмар суы» көйләрен үлгән җирләреннән яңадан терелтү». Тукай әйтүенчә, «алар милләт балаларының үлгән күңеленә... рух өрәчәктер» [3, б. 225].

Иҗатының башлангыч чорында ук ул алдына зур максат куя – милләтне агарту, рухын күтәрү.

Моның юлын шагыйрь халык иҗатын җыю, саклау, үз иҗатында чагылдыруда күрә. Шушы идеалларын ул тормышка ашырырга һәрдаим тырыша. Җырларның әһәмиятен атаклы «Халык әдәбияты»нда (1910) ачык чагылдыра: «...халык җырлары – халкыбыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә рәүшан көзгеседер» [4, б. 174].

ӘДӘБИЯТ

1. Тукай Г. Әсәрләр: биш томда. 1 том. Казан. Татар. кит.нәшр., 1985.
2. Тукай Г. Әсәрләр. 2 том. Казан, 1985.
3. Тукай Г. Әсәрләр. 3 том. Казан, 1985.
2. Тукай Г. Әсәрләр. 4 том. Казан, 1985.
3. Тукай Г. Әсәрләр. 5 том. Казан, 1985.
6. Татар әдәбияты тарихы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985.
7. Җамалетдинов Л. Татар әкиятләрен барлау юлында. Казан: ТӘҺСИ, 2015.
8. Садыйкова А.Х. XII–XX гасыр башы татар әдәбиятында дини фольклор. Казан: ИЯЛИ, 2014.

## ОТРАЖЕНИЕ В ГАЗЕТЕ «ТЕРДЖИМАН» МАТЕРИАЛОВ ТУРЕЦКОГО ЖУРНАЛА «ТЮРК ЮРДУ» О ГАБДУЛЛЕ ТУКАЕ

***Салихов А.Г.***

Газета «Тарджиман», издававшаяся Исмаилом Гаспринским в Бахчисарае, сыграло неоценимую роль в культурном просвещении тюркских народов. Она являлась духовным мостом, связывающим многие народы, проживавшие на широком географическом пространстве. Издание также публиковало обзоры и материалы из зарубежной печати. Материалы, посвященные памяти Габдуллы Тукая, опубликованные в турецком журнале «Тюрк юрду» (1913, № 16), не остались без внимания редакции газеты. В связи с этим на ее страницах появились небольшие обзорные статьи «“Тюрк юрду” и Габдулла Тукаев» и «Тукаев и стамбульские тюрки».

Newspaper *Tardzhiman* published by Ismail Gasprinsky in Bakhchisaray has played an invaluable role in the cultural education of the Turkic peoples. It is a spiritual bridge between the many peoples who lived in a vast geographical area. The newspaper also published reviews and materials from the foreign press. Materials, dedicated to the memory of Gabdullah Tukay published in the Turkish journal *Turk Yurdu* (1913, No 16) did not go unnoticed in the newspaper. In this regard, it carried small review articles *Turk Yurdu and Gabdullah Tukay* and *Tukaev and Istanbul Turks*.

Газета «Терджиман», издаваемая Исмаилом Гаспринским в Бахчисарае, сыграло неоценимую роль в культурном просвещении тюркских народов. Оно являлось духовным мостом, связывающим многие народы, проживавшие на широком географическом пространстве. Газета имела своих читателей и корреспондентов во многих отдаленных регионах России, иногда даже в небольших населенных пунктах, в том числе и Урало-Поволжье. Издание также публиковало обзоры и материалы из зарубежной печати. Печатались в ней и статьи, посвященные творчеству выдающегося поэта Габдуллы Тукая [4, с. 236, 254].

В 2011 году на Международных конференциях, посвященных 125-летию со дня рождения Габдуллы Тукая, которые были проведены в Казани и Анкаре, турецкий ученый Шюкрю Халюк Акалын выступил с докладом «Габдулла Тукай и Турция», в которых достаточно подробно описал статьи и публикации турецких изданий начала XX века, посвященных памяти Габдуллы Тукая [3]. Данная статья будет посвящена отражению в газете Исмаила Гаспринского «Терджиман» материалов о Тукае в турецком журнале «Тюрк юрду».

Публикации о Габдулле Тукае, появившиеся в турецких изданий не остались без внимания газеты «Терджиман». 8 июня 1913 года в редакцию газеты нового номера стамбульского журнала «Тюрк юрду» (1913, № 16), в которой был опубликован материал, посвященный памяти Г. Тукаю. В связи с этим в газете появилась заметка ««Тюрк юрду» и Габдулла Тукаев». В статье описывается, что наряду со статьей в журнале опубликована элегия «Тукаев» на крымско-татарском языке. Также говориться, что в литературном разделе вышли стихи Саида Сюнчелея с обращением к тюркскому миру, статья «История тюркской культуры» известного автора Ахмета Агаева. К данному номеру журнала в качестве подарка для читателей была приложена и фотография Тукая, отпечатанная на хорошей бумаге. В конце сообщалось о стоимости и условиях подписки на журнал из России [1].

12 июня 1913 года на ее страницах появилась новая статья «Тукаев и стамбульские тюрки», посвященная появлению в журнале «Тюрк юрду» большой статьи Мехмета Фуада Кёпрюлю. Автор, которым возможно является сам редактор, сообщает в ней, что материал Ф. Кёпрюлю является достаточно объемным, поэтому здесь

приводиться лишь небольшую часть, содержащая сравнения северных и южных тюрков, представляющую большую ценность для всех.

В своей статье Фуад Кёпрюлю сказал, что ему кажется, что наши соплеменники, проживающие в белом необъятном холодном бассейне реки Волги, напоминающей снежное море, более тепло, более искренне относятся к памяти своих покойных. Он сообщает читателям, что после смерти Тукая страницы всех тюркоязычных изданий в России неделями, месяцами были завалены письмами мастеров пера и слова, молодых парней и девушек, статьями о жизни и творчестве поэта, что ярко показывает о существовании в Поволжье более сильных национальных чувств чем в Турции. Он также описал, что мгновенно были распроданы все произведения поэта. По мнению автора, лучше этого ничто не способно показать наличие сильных национальных чувств [2].

Указанные материалы, опубликованные в газете «Терджиман» донесли до своих многочисленных читателей своевременную информацию о Тукае, опубликованные в Турции. Они также еще раз демонстрирует большую роль газеты в культурном просвещении тюркских народов России.

Приложение 1.

### «Türk Yurdu» ve Abdulah Tukayev

İstanbul'da on beş günde bir çıkan «Türk Yurdu» dergisinin sevgili şairimiz Abdullah Tukayev merhumun ruhuna ithaf etmiş olduğu ve kırk sekiz sayfadan ibaret olan on altıncı numarası idaremize geldi. «Yurdu»n bu numarasında Türklerin genç ediplerinden Köprülüzâde Mehmet Fuad Beyin, Abdullah Tukayev'in hayatına ve eserine dair bir makaleyi tenkidiyesi ile Kırım Tatarcası şivesinde «Tukayev» merhûma bir mersiye var. Şairlerimizden Seyit Sünçeley'in Türk dünyasına hitap eden pek meraklı bir şiiri de «Türk Yurdu»nun edebiyat kısmını tezyin etmektedir. Bunlardan başka meşhur muharrirlerimizden Ahmet Ağayev'in «Türk Medeniyeti Tarihi» serlevhalı makalesi ve şair yazıcılarımızın makaleleri de herkes için mütalaa şayandır. «Türk Yurdu» bu numarasıyla karilerıne Tukayev'in iyi kağıtta tab olunmuş bir kıta resmini de hediye etmektedir. «Türk Yurdu»nun Rusya için senelik bedeli 3 Ruble 50 Kopeyek, yarım yıllığına 2 Rubledir. Müracaat için adres: İstanbul'da Nuru Osmaniye'de 40 numaralı «Türk Yurdu» idarehanesi.

*«Tercüman» gazetesi, 1913. 8 Haziran.*

### «Тюрк юрду» и Габдулла Тукаев

В нашу редакцию поступил шеснадцатый номер сороковосьмистраничного журнала «Тюрк юрду», выходящего в Стамбуле один раз в пятнадцать дней и посвященный памяти нашего любимого поэта Габдуллы Тукая. В этом номере «Тюрк юрду» содержится критическая статья молодого турецкого писателя господина Кёпрюлюзаде Мехмета о Габдулле Тукаеве, его жизни и произведениях, элегия «Тукаев» на крымско-татарском диалекте, посвященные покойному. В литературной рубрике журнала опубликованы очень интересные стихи нашего поэта Саида Сюнчелея, в котором он обращается тюркскому миру. Кроме этого, статья «История тюркской культуры» известного редактора Ахмета Агаева и статьи других известных представляют интерес многих. Этот номер «Тюрк юрду» дарит своим читателям фотографию Тукая, отпечатанную на хорошой твердой бумаге. Стоимость годовой подписки на «Тюрк юрду» в России стоит 3 рубля 50 копеек, а за полугодие – 2 рубля. Адрес для обращения: Стамбул, Нуру Османийе, № 40, редакция «Тюрк юрду».

*«Терджиман», 1913 г. 8 июня.*

Приложение 2.

### Tukayev ve İstanbul Türkleri

İstanbul'da neşr olunan «Türk Yurdu» mecmuası muharrirlerinden muhterem Köprülüzade Mehmet Fuad Beyin Şair merhum Abdullah Tukayev'e dair mecmuai mezkûrede yazmış oldukları uzun bir makalenin bir parçasını aşağıda aynen nakl ediyoruz. Bu parça Şimal Türkleri ile Cenup Türkleri arasında ilk bir safhai münasebet olduğundan hepimize pek kıymetlidir. Mehmet Fuad Bey diyor:

«Mazlum İdil (Volga)'in beyaz ve nihayesiz bir kar denizine benzeyen soğuk havzasındaki urukdaşlarımız, öyle görüyorum ki ölülerine bizden daha sıcak, daha samimi bir âğuş

açıyorlar. Büyük şairleri Abdullah Tukayev'e karşı Şimali Türk matbuatının, Türk erbab-ı fikir ve kalemin, bilhassa genç erkek ve kızların gösterdikleri muhabbet, merbutiyet Volga boyunda İstanbul'dan daha fazla milli bir vicdan mevcut olduğunu anlattı. Gazeteler, risaleler, mecmualar, haftalarca, aylarca Tukayev'den, onun hayatından, eserlerinden bahsettiler. Gazete idarehanelerine her yerden binlerce taziye telegrafları geldi. Şair merhumun matbu eserleri kâmilen satılıp bitti, hatta Tukayev namına bazı eseri hayriyeye bile teşebbüs olundu...

Milli bir vicdan varlığını bundan daha vazıh gösterecek hiç bir şey yoktur».

«*Tercüman*» *gazetesi. 1913. 12 Haziran*

### Тукаев и стамбульские тюрки

Ниже мы перепечатываем часть большой статьи одного из уважаемых авторов стамбульского журнала «Тюрк юрду» Кепрюлюзаде Мехмета Фуада, посвященного покойному поэту Габдулле Тукаю. Этот отрывок ценен для всех нас тем, что в нем имеется первое сравнение северных и южных тюрков. Господин Мехмет Фуад говорит:

«Мне кажется, что наши соплеменники, проживающие на холодном бассейне Волги, напоминающей белую и бескрайнюю море, более тепло, более искренне относятся к своим покойным. Любовь, показанная на страницах печати северных тюрков, тюркскими мастерами мысли и пера, особенно молодыми парнями и дувушками показывает о наличии в Поволжье по сравнению со Стамбулом еще более сильных национальных чувств. Газеты, журналы, сборники неделями, месяцами писали о Тукаеве, его жизни и произведениях. В редакции газет со всех мест поступили тысячи телеграмм с соболезнованиями. Все изданные произведения покойного поэта были распроданы. Некоторые даже предприняли попытку издать от имени Тукая некоторые труды с целью милосердия...

Нет более ясного выражения чем это, более лучше показывающего наличие национального сознания».

«*Терджиман*». *1913 г. 12 июня*


ЛИТЕРАТУРА

1. «Тюрк юрду» ве Абдулла Тукаев // Терджиман. 1913. 8 июнь.
2. Тукаев ве Истанбул тюрклери // Терджиман. 1913. 12 июнь.
3. Информационный ресурс: http://gabdullatukay.ru/rus/index.php?option =com_content&task=view&id=1237&Itemid=71. Дата обращения: 12.03.2016 г.
4. Керимов И.А. «Живая история» Гаспринского. По материалам газеты «Терджиман» 1883–1914 гг. Симферополь, 1999. 408 с.


## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ И СОВРЕМЕННЫЙ ТАТАРСКИЙ ТЕАТР


***Салихова А.Р.***



Жизнь и творчество Г. Тукая находит отражение в современном театральном искусстве Республики Татарстан. В статье рассматриваются спектакли, посвященные этой теме.

The life and work of G. Tukay is reflected in the contemporary performing arts of the Republic of Tatarstan. The article concentrates on the analysis performances of devoted to this problem.


Как известно, Габдулла Тукай не писал пьес. Он был поэтом, публицистом, фольклористом. Тем не менее, его богатое творческое наследие по сей день служит источником для театральных постановок. Хотелось бы отметить спектакли, с успехом идущие на современной сцене, в которых присутствуют тукаевские мотивы, сюжеты, высказывания.

Одним из таких спектаклей является искрометная лирическая комедия «Душечка». Поставленная Фаридом Бикчентаевым с выпускниками первого экспериментального актерско-режиссерского курса Института культуры и искусств в 1995 году, она уже более двадцати лет не сходит со сцены Татарского государственного академического театра им. Г. Камала. Пьеса была специально написана для этого курса выдающимся татарским драматургом Туфаном Миннуллиным. В ней активно используются мотивы поэтической сказки Г. Тукая «Шурале». Комедия в легкой, занимательной форме поднимает актуальные нравственные проблемы. В ней приземленному, обывательскому миру людей противопоставляются лесные обитатели – шурале. Они элегантно, со

вкусом одеты, разговаривают архаичным высокопарным стогом, подчеркнуто церемонны и живут высокими идеалами. Эта кампания напоминает современное Г. Тукаю татарское общество: в нем есть свой знаменитый на весь лесной татарский мир поэт, галантные кавалеры, кисейные барышни. Законсервированная и опоэтизированная эпоха национального возрождения выступает жестким контрастом нашему бездуховному времени. Шурале воплощают в себе национальную культуру, язык, традиции, духовную красоту. Они приходят на помощь молодым жителям вырождающейся татарской деревни, возвращая им веру в чудо и стремление к прекрасному… [5, с. 285].

Пьеса была очень свежо и интересно поставлена. Все преимущества студийной работы молодых исполнителей с режиссером-педагогом сполна проявились в этом спектакле. Органичность и сыгранность творческой команды, атмосфера легкости и раскованности, смелого творческого эксперимента и искреннего, теплого юмора придают ему особую прелесть. Спектакль и сейчас радует зрителей, собирает полные залы [2].

Мотивы сказок Г. Тукая присутствуют также в творчестве молодого, но уже известного драматурга Ильгиза Зайниева. Образы Шурале, Русалки обыграны в его фантастической пьесе «Игра с монстриком». Поставленный с размахом и выдумкой режиссером Радиком Бариевым детский спектакль-феерия стал большим событием для камаловского театра (премьера состоялась 26 декабря 2012 года). Он смотрится на одном дыхании, завораживает яркостью выразительных средств. Велика заслуга в этом всей постановочной группы: художника Сергея Скоморохова, композитора Радика Салимова, хореографа Наили Фаткуллиной. Интересны и актерские работы. Спектакль получился очень современным как по своему сценическому языку, так и по заложенным в нем мыслям. Не отрываясь от своих корней, татарский театр постепенно расширяет свои традиционные границы, впитывает в себя актуальные эстетические, ментальные и стилистические тенденции [3].

Настоящее раздолье персонажам тукаевких сказок в новой пьесе И. Зайниева «Коза, овца и другие». На малой сцене ТГАТ им. Г. Камала ее поставили Салима Аминова и Ильдус Габдрахманов. Премьера состоялась 7 ноября 2015 года. Это эксцентричная музыкальная постановка, с танцами и песнями, наполненная энергией молодых актеров. Она не оставляет равнодушными ни детей, ни их родителей. Спектакль поставлен с учетом психологии современного ребенка, герои активно вовлекают зрителей в действие. Интересно, что наравне со сказочными героями: Шурале, Водяной, Козликом, Барашком и другими, выступает и деревенский пес Акбай. Видимо, популярный персонаж Т. Миннуллина уже тоже вошел в золотой фонд национальной детской литературы и стал почти фольклорным персонажем.

Своеобразная постановка по мотивам творчества Г. Тукая имеется в репертуаре Татарского театра драмы и комедии им. К. Тинчурина. Взяв за основу стихи Г. Тукая и его автобиографическую повесть «Что я помню о себе», режиссер Рашид Загидуллин поставил камерный спектакль «Люби жизнь» (март 2009 года). В нем он попытался воссоздать атмосферу характерных для начала XX века литературно-музыкальных вечеров, которые проводились в Казани, Уфе, Оренбурге и других городах компактного проживания татар. В центре внимания оказалась сама эпоха зарождения светской национальной культуры, просвещения, общественного подъема. Большое значение придается чистоте стиля: костюмам, манере актерского исполнения. Лаконичность выразительных средств выдвигает на первый план саму поэзию Габдуллы Тукая, его внутренний мир и неповторимую творческую личность. Молодые актеры Резеда Саляхова, Гузель Галиуллина, Артем Пискунов, Ильфак Хафизов с успехом справляются со своей творческой задачей. Как указывает Е. Садирова, большое значение имело и музыкальное оформление постановки: «наряду с документальной точностью в соблюдении костюмного решения, аристократичным, и несколько отстраненным, как того требует жанр, способом актерского существования, одной из черт постановки стало присутствие музыкальных знаков, символов того времени. Возникающие по ходу действия знакомые мелодии «Туган тел», «Эллюки», «Тафтилэу», волнующие душу пронзительные народные напевы, вызывая чувство прикосновения к живительным родникам национальной культуры, добавляют емкий, выразительный штрих в создание антуража тукаевской эпохи, чему немало способствует живое звучание курая, фортепиано и гитары в исполнении самих актеров» [4, с. 298].

К 120-летию Г. Тукая Казанский татарский театр юного зрителя им. Г. Кариева представил на суд зрителей свою постановку «Сенной базар». Интересно, что режиссер Ренат Аюпов выступил и в роли драматурга, объединив в композиции спектакля произведения Тукая и факты его биографии. Наряду с реальными историческими персонажами: Ф. Амирханом, С. Рамиевым, Х. Ямашевым и другими, здесь представлены и герои произведений Тукая: Кисекбаш, Шурале, Водяная, Коза и Баран. Сам Тукай показан одновременно в трех ипостасях: маленький Апуш, тяжелобольной Тукай на закате жизни и обобщенно-философский образ народного Поэта, мыслителя и провидца. Переплетая судьбу писателя и созданные его творческим воображением образы, режиссер создает на сцене особую, духовную реальность, раскрывает сложный и противоречивый внутренний мир Г. Тукая, истоки его художественного мироощущения. Постановка вызвала широкий общественный резонанс. В 2006 году на II международном фестиваля «Арт-Ордо» в г. Бишке она была удостоена диплома «За лучший спектакль». Сыграли свою роль новизна и непривычность художественных приемов, а также проникновенность исполнения и воодушевление артистов. Жюри оценило спектакль так: «В этой постановке форма и актерская игра представляли собой единое целое. Это были две волны, которые помогли раскрыть метания поэта и его жизнь» [1]. После некоторого перерыва, 15 марта 20016 года постановка «Сенной базар» возобновлена на новой сцене театра им. Г. Кариева.

Заслуживает внимания еще один спектакль этого театра – музыкальная драма Р. Батуллы «Зайтунакай» (режиссер – Р. Аюпов). Поставленная в 2011 году, она является как бы ответвлением «Сенного базара», играется в тех же декорациях, теми же артистами. Даже некоторые диалоги повторяются. Здесь в центре внимания – история красивой, но трагичной любви известного поэта и Зайтуны Мавлюдовой. Их взаимоотношения преподносятся возвышено, приподнято-романтично, трогательно. Взаимное и сильное чувство, которое не могло иметь продолжения, стало для обоих серьезным испытанием. Небольшой по продолжительности спектакль стал гимном духовной красоте, мужеству, стойкости, самоотверженности. Большую роль в спектакле играет замечательная музыка Эльмиры Галимовой, очень точно передающая и национальный колорит материала и все оттенки душевных переживаний героев.

Тенденция передачи художественного своеобразия поэтического творчества Габдуллы Тукая средствами яркой музыкальной выразительности нашла продолжение и в спектакле по пьесе Т. Миннуллина «Расскажи мне, бабочка!». Театр определил жанр постановки как музыкальная мистерия. Огромную роль в ней, помимо музыки, играют пластика и мимика действующих персонажей (режиссер по пластике – Рустем Фаткуллин). Композитор, лауреат республиканской премии им. М. Джалиля, кандидат искусствоведения Эльмира Галимова очень тонко и динамично передает разные состояния души главного героя – маленького Апуша, который воспитывает в себе силу воли и преодолевает чувство страха благодаря своим мифическим друзьям – Водяной, Шурале, Козла, Овцы, Соловья и Чёрной птицы. Спектакль получился необычным, ярким, эмоциональным.

Поэтические сказки Габдуллы Тукая служат неиссякаемым источником для всевозможных детских представлений. Спектакли с его героями идут и в Татарском Государственном Театре кукол «Экият», и на сцене Театра оперы и балета им. М. Джалиля. Творчество поэта является нашим бесценным национальным достоянием, и еще долгие годы оно будет питать татарское театральное искусство.

ЛИТЕРАТУРА:

1. Абдуллина Г. Достойный спектакль // Татарские края. 2006. № 18.

2. Габаши А. Т. Миннуллин «Свет моих очей» // Татарский государственный театр имени Галиаскара Камала. Сто лет. В двух томах. Первый том. Спектакли. Казань: Заман – Татар. кн. изд-во, 2009. С. 493–494.

3. Габаши А. Игра с монстриком // Казань. 1913. № 3. С. 58–61.

4. Садирова Е. Н. Образ Тукая в татарском драматическом театре и средства музыкальной выразительности // Материалы конференции «Наследие Габдуллы Тукая в контексте национальных культур». Казань, 2011. С. 283–285.

5. Салихова А.Р. Образ Шурале в татарском искусстве // Материалы конференции «Наследие Габдуллы Тукая в контексте национальных культур». Казань, 2011. С. 283–285.

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ҺӘМ МӘХТҮМКОЛЫЙ ФРАГИ ШИГЫРЬЛӘРЕНДӘ УРТАК СИМВОЛЛАР

*Тезислар*

***Сарлы Араз Мәхмәт***

В фольклоре и письменной литературе родственных народов не последнее место занимает общая символика. В выступлении рассматриваются общие символы в творчестве национальных поэтов татарского и туркменского народов Г. Тукая и М. Фраги.

In folklore and written literature of related peoples recently took the overall symbolism. The presentation discusses the general characters in the works of the national poet of the Tatar and Turkmen peoples G. Tukay and M. Fraga.

Теге яисә бу халыкның милли мәдәниятен ул халыкның тарихыннан башка аңлап булмый. Мәгълүм булганча, үз вакытында төрекмән һәм татар халкы зур авырлыклар кичергәннәр. Аларның икесен бер-берсе белән ачы язмыш берләштерә. Бу билгеле бер дәрәҗәдә төрекмән һәм татар әдәбиятында да чагылыш тапкан. Аерым алганда, әлеге ике халыкның бөек шагыйрьләре Габдулла Тукай һәм Мәхтүмколый Фрагинең әсәрләрендә күп кенә уртак символларны очратырга мөмкин. Әдипләрнең әсәрләрен өйрәнү барышында без аларның түбәндәге төрләрен аерып чыгардык:

1. Милләт һәм ватан төшенчәләре белән бәйле символлар.
2. Әхлакый төшенчәләр.
3. Иҗтимагый тормыш өлкәсенә караган күренешләр белән бәйле символлар.
4. Дини ышанычлар белән бәйле символлар.

Төрки дөньянын бу ике бөек шагыйрен бер-берсеннән бер гасырдан артык вакыт аралыгы аерып торса да, Габдулла Тукай һәм Мәхтүмколый Фраги әсәрләрен бер-берсенә бәйләп торган уртак бер үзенчәлек бар: ике шагыйрь дә туган халкын Урта гасырлардан бирле килгән артталыктан һәм төрле хорафатлардан азат итеп күрергә теләгәннәр. Бу яктан Габдулла Тукай үзенең гаҗәеп таланты һәм иҗаты белән татар милләтенә генә түгел, ә бәлки төрки телләрдә сөйләшкән барлык халыкларга да хезмәт иткән.

## ТУКАЙ ЧОРЫ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА ДИНИ ЭЧТӘЛЕКЛЕ СҮЗЛӘР КУЛЛАНЫЛЫШЫ

***Саттарова М.Р.***

В статье анализируется употребление лексики религиозного содержания в татарской литературе эпохи Г. Тукая.

In this article is analyzed the using of the vocabulary of religious content in the Tatar literature of the era of G. Tukay.

Габдулла Тукай – бүгенге көндә татар халкын дөнья күләмендә таныткан шәхесләрнең берсе. Ул яшәгән, иҗат иткән еллардан соң инде бер гасырдан артык вакыт узган. Җәмгыятьнең үзгәрүе, глобальләшү, рухи һәм матди тормышта шактый яңалыклар барлыкка килү нәтиҗәсендә, бу вакыт аралыгында татар телендә, беренче чиратта аның сүзлек составында кайбер үзгәрешләр барлыгы күзәтелә. Тел берәмлекләренең кулланылышын тасвирлауда шактый кызыклы нәтиҗәләр бирә торган лингвокультурология күзлегеннән карасак, бу үзгәрешләр халык менталитетында бара торган үзгәрешләр белән дә бәйле. Әлеге мәкаләдә Тукай яшәгән дәвердә иҗат ителгән татар әдәбиятында татар халкының рухи мәдәнияте ни рәвешле урын алуы тасвирлана.

Билгеле булганча, әдип иҗатында аның тормыш тәҗрибәсе, яшәү тирәлеге, шәхси карашлары урын ала һәм үзенчәлекле автор картинасы формалаша. Бу мәсьәлә берьяклы гына түгел, әлбәттә. Әсәр телендә күтәрелгән төп проблема, темага бәйле дә үзенчәлекләр чагылыш таба. Шулай да, һәр авторның үз стиле, гомумиләштереп караганда, һәр чорга хас кыйммәтләр бар.

Татар әдәбияты бик бай һәм күпкырлы әдәбият. Тукай чоры да үз кыйммәтләре, үз проблемалары белән танылган. Ул дәвер – күтәрелеш, яңалыкка омтылыш, мәгърифәт-

челек идеяләренә нигезләнә. Кайнап торган тормыш шартларында иҗат ителгән әсәрләрендә әдипләр татар теле, милли үзаң, ислам диненең чисталыгы проблемаларын күтәрә, җәмгыять яшәешенең алга барышына каршылык тудырган күренешләрне тәнкыйтьли.

Рухи мәдәният яшәешнең барлык өлкәләренә дә кагыла. Әмма халыкның бердәмлеген, бөтенлеген тәэмин итә торган күренешләрнең беренчесе тел булса, икенчесе – аның дине. Билгеле тарихи сәбәпләр аркасында, XX гасыр дәвамында мең елдан артык инанган ислам диненең көндәлек кулланылышы күләгәдә калып килгән. Бүгенге көндә исә, бигрәк тә рус тел белемендә, дини эчтәлекле берәмлекләрне фәнни яссылыкта өйрәнү яңа сулыш белән күтәрелеп килә. Татар теле сүзлек байлыгы бу нисбәттән бигрәк тә кызыклы. Моның сәбәбе – татар халкының төп диннәрдән ислам динен дә, христиан динен дә тотулары, шул ук вакытта татар халкында электән калган ышануларның дини кануннарга кушылып, җирле колорит барлыкка китерүе.

Татар телендә күпсанлы дини эчтәлекле сүзләр кулланыла. Аларны берничә тематик төркемгә берләштерергә мөмкин:

– «теге дөнья»да тормыш булуга ышану белән бәйле төшенчәләр: *ахирәт, ахыр заман, кабер газабы, иман нуры, сират күпере, җәннәт, җәһәннәм* һ.б.;

– дини әхлак белән бәйле төшенчәләр:*гөнаһ, зина, тәкъдир, тәүбә, хәрәм, шәригать* һ.б.;

– дини бәйрәм атамалары һәм календарь исәбе белән бәйле сүзләр: *гашурә, зөлкагъдә, изге ай,кадер киче, мәүлед,рәҗәп* һ.б.;

– Аллаһ Тәгаләгә мөрәҗәгать итү сүзләре: *Аллаһ Тәгалә, раббе, тәңре, Хак Тәгалә, Ходай Тәгалә* һ.б.*;*

– төрле корылмаларны һәм аларның өлешләрен белдерә торган сүзләр: *Алла йорты, госел бүлмәсе / госелханә, гыйбадәт йорты / гыйбадәтханә, Кәгъбә, манара, михраб, мәчет, мөнбәр* һ.б.;

– төрле затларны белдерә торган сүзләр: *Газраил, Газазил, дәҗҗәл,җен, иблис, Исрафил, фәрештә,шайтан* һ.б.;

– дин әһелләрен һәм алар белән бәйле кешеләрне белдерә торган берәмлекләр: *абыстай, Адәм, азанчы, ахун, вәгазьче, дин башлыгы, имам, казый, коръән хафиз, кяфер, мөфти, Нух, пәйгамбәр, Хава, хаҗи* һ.б.;

– дини ритуалларга бәйле кулланыла торган предмет атамалары: *ахирәт күлмәге, дисбе, комган, намазлык* һ.б.;

– төрле ритуал атамалары:*азан, намаз, вәгазь, госел, руза, тәяммем* һ.б.;

– дини текст яки аның өлешен белдергә сүзләр: *аять, Библия, Инҗил, Коръән, Тәүрат* һ.б.;

– абстракт төшенчәләрне белдерә торган сүзләр: *атеистлык, буддизм, диндарлык, мәҗүсилек, суфыйлык* һ.б. [5].

Моннан тыш күпсанлы фигыльләр ярдәмендә дини эчтәлек җиткерелә:

– ислам дине тарафыннан фарыз саналган гамәлләрне башкару белән бәйле төшенчәләр: *авыз ачу, азан әйтү*, *госел алу / госел коену*, *гыйбадәт кылу, дога кылу / дога уку, зекер әйтү, иман китерү, ифтар ашау, ихрамга керү, Коръән чыгу / уку*, *намаз уку, намазга басу,никах уку/ никах укыту*, *сәҗдә кылу / итү, сәҗдәгә китү, сәхәр ашау, сәхәргә тору, тәкбир әйтү, тәравих әйтү / уку, тәсбих тарту*, *тәяммем кылу / сугу, тәүбә итү, тәүбәгә килү, тәһарәт алу, тәһарәт яңарту, тәһарәтләнү, ураза тоту, уразага керү, хаҗ кылу, хөтбә уку* һ.б.;

– кешенең табигате белән бәйле эшләнә торган гамәлләр: *Аллага тапшыру*, *гөнах кылу / гөнаһ эшләү*, *зина кылу*, *иман сату*, *иман яңарту*, *иманга килү*, *никах яңарту,нәзер әйтү*, *өшкерү*, *потка табыну*, *савап эшләү*, *талак итү / талак кылу*, *христианлашу*, *чукыну*, *ырымлау* һ.б.;

– төрле гореф-гадәтләр, йолалар белән бәйле гамәлләрне белдерә торган төшенчәләр: *аш уздыру / Коръән укыту / Коръән ашы уздыру*, *бабага бирү*, *нәфел намазын уку*, *нәфел уразасын тоту*, *хәтем кылу*, *сөннәткә утырту* һ.б.;

– төрле түләүләр белән бәйле төшенчәләр: *гошер түләү*, *зәкят бирү*, *сәдака бирү / хәер бирү*, *сәдака җыю / хәер җыю*, *сәдака тарату / хәер тарату* һ.б.;

– нинди дә булса вазыйфа башкару белән бәйле төшенчәләр: *имамлык итү*, *ишанлык итү*, *монахлыкка китү*, *муллалык итү*, *мәзинлек итү / мәзин булу*, *мөфти булу*, *хәлфәлек итү* һ.б. [4].

Нинди генә әдип иҗатын карасак та, әсәр телендә дини эчтәлекле лексика кулланылышын очратырга мөмкин. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы аралыгында бу тема бигрәк тә ачык яктыртыла.

Төрле язмыш белән яшәп, иҗат иткән әдипләрнең әсәрләрен чагыштырганда, бу аеруча тирән эчтәлеккә ия. Мәсәлән, Г. Ибраһимов һәм Г. Исхакый кебек танылган әдипләрнең дин белән бәйле мәсьәләләрне ничек яктыртуын карыйк. Бу шәхесләрнең көндәлек эшчәнлеге, үзе яшәгән чорны тасвирлавы кыйммәтле.

Г. Ибраһимов үзе казах далаларында укытучы булып эшли. Тормышының бу этабы белән бәйле тәҗрибә аның «Казакъ кызы» әсәрендә урын ала [2]. Автор алда китерелгән классификациягә бәйле саналган берәмлекләрдән шактый сүзләр куллана. Шулай да, арада үзенчәлекле булганнары да бар. ***Ясаган тәңрем*** *мондый җылкыларны Байтүрәләргә биреп бетереп, безне мәхрүм калдырды. Көннәрнең берендә, Тынычбай атаның елы тулганда,* ***бата кылырга*** *(фатыйха сүзеннән, искә алу дигәнне аңлата. – М.С.) дип илнең өлкәннәре җыелган зур бер кымыз мәҗлесендә, күп уен-көлкедән соң, заманның авыраюыннан, дошманның җәфасыннан зарланып, әңгәмә ачылды.Мәдрәсәдә укыган казакъ җегетләре, далада муллалыкта торган татар шәкертләре, вак ишаннар, суфилар,* ***бәдәлчеләр****, төрле яктан йөгерешеп, Байтүрәнең мәете яткан өлкән ак тирмәгә агылдылар. ...күкрәккә медаль таккан калын биләр,* ***бәдәл****(кеше акчасына хаҗ кылу – М.С.) эзләп йөргән, тар, нечкә чалмалы, сырган кызыл җөббәле гарәп хәерче хаҗилары... Молдалар, теләгәнегез* ***дәвергә****(ике мулла кара-каршы утырып, мәет янында дога уку. – М.С.) керегез! Мәетнең сул ягы буйлап, ишектән түргәчә ике рәт булып, дин әһеле –* ***дәверчеләр****, фидиячеләр сафланганнар. Ул яман җегет үз кылганының* ***обалын*** *(гөнаһ – М.С.) табар, мәгәр илнең өлкәннәре акылга салсыннар, озын чәчле бер аял өчен талаш кузгалып кан түксәк, дусларыбыз җылар, мәңгелек дошманнарыбыз – ак, симез найманнар бәйрәм итәрләр, безгә рәхмәт әйтерләр, ашыкмагыз, уйлап эшләң, диде.* ***Ялган*** әсәрдә бер генә тапкыр кулланылган, автор аңлатмасы белән бирелгән һәм *бу,* дигәнне белдерә: *– Бу* ***ялганда*** *(вакытлы, фани дөнья. – М.С.), – диде, – яхшылыгым күп булды, мәгәр яманлыгым да аз имәс. Дөньяныкы дөньяда бетсен...*

Үзенчәлекле, бүгенге татар телендә бөтенләй дип әйтерлек очрамый торган бу төшенчәләр авторның чор һәм урын үзенчәлекләрен тулы ачуы, казах халкының милли менталитетын тасвирлау өчен кулланылган.

Г. Исхакыйның мөһаҗирлеккә кадәрге иҗатында мәдрәсә, дин әһелләре белән бәйле кичерешләрен, аларга кагылышлы вакыйга-күренешләрне тасвирлый. Әдәби әсәр эчтәлеген бирүдә авторлар еш кына дини эчтәлекле сүзләр куллана. Аның геройлары гади татар кешеләре, шуңа күрә дини эчтәлекле сүзләрнең дә халык сөйләмендә актив кулланылышта булганнары еш очрый. Бу фактны да күпсанлы мисаллар белән дәлилләргә була. Мәсәлән, *Ул* ***ахшам****га барганда хәзрәткә хәлләрен аз гына аңлатты* (Остазбикә). *Авылның картлары, ир уртасылары, яшьләре – һәммәсе дә үзләре белә башлаганнан бирле аны* ***Сөннәтче*** *бабай дип таныйлар, Сөннәтче бабай дип йөриләр иде* (Сөннәтче бабай). *Мин,* ***тәһарәт*** *алып, әтинең пәкесене алып,* ***сөннәткә*** *чыктым* (Сөннәтче бабай). *Җыелган икмәкне сатып, карчыгына күлмәк, алъяпмалык, үзенә күлмәк-ыштан, рамазан никадәр ерак булса да, «санаулы көн үтәр» дип, мәсҗедтә* ***авыз ачтырырга*** *дип, ике кадак хөрмә алып, мөәзингә бирә иде* (Сөннәтче бабай). *Чынында, ничек мулла булмаенча, иртәдән кичкә кадәр ашка йөрмәенчә,* ***руза гаете****ндә* ***фитыр*** *җыймаенча,* ***корбан гаете****ндә тире алмаенча, иген өлгергәч* ***гошер*** *җыймаенча яшәргә кирәк?* (Тормышмы бу?)

Шул ук вакытта Г. Исхакый иҗатында да бүгенге көн күзлегеннән караганда активлыгын югалткан берәмлекләр бар. Мәсәлән, *Икәүләп*, ***Чәһарьяр гыйзам*** (Мөхәммәд пәйгамбәрдән соң килгән бөек дүрт хәлифә: Әбүбәкер, Гомәр, Госман, Гали. – *М.С.*) *рухына багышлап җиде көн руза да тоттылар* (Остазбикә) [3].

Мисаллардан аңлашылганча, Тукай чорында иҗат ителгән әсәрләрдә дини эчтәлекле лексика киң файдаланылып, чорның рухи халәтен тасвирлауга хезмәт иткән. Тукайның үз иҗаты да дини мотивлар белән сугарылганлыгы монографик өйрәнелгән [1]. Язучы шәхесе, аның тел үзенчәлекләре милли үзаңны ачарга ярдәм итә. Автор әйтергә теләгән фикер әсәрнең лексик байлыгы белән турыдан-туры бәйле. Шул рәвешле авторның тел картинасы, дөньяга карашы гәүдәләнеш таба, тел шәхесе буларак характеры ачыла. Бу исә чорның психологик, эмоциональ төсмерен билгели һәм милли үзаң үсешен анализларга мөмкинлек тудыра.

ӘДӘБИЯТ

1. Абдуллина Д.М. Коранические мотивы в творчестве Габдуллы Тукая: автореф. дис. ... канд. филол.наук. Казань, 2005. 32 с.

2. Ибраһимов Г. Казакъ кызы. [Электронный ресурс]. Керү режимы: www.kitap.net

3. Исхакый Г. Зиндан. Сайланма проза һәм сәхнә әсәрләре / төзүчесе, текст һәм искәрмәләрне хәзерләүче Л. Гайнанова; кереш һәм ахыр сүз авторлары И. Нуруллин, Һ. Мәхмүтов, Л. Гайнанова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. 671 б.

4. Саттарова М.Р. Глагольная лексика как средство выражения религиозных понятий в современном татарском литературном языке // Вестник ЧГПУ. 2014. № 8. С. 294–302. http://cspu.ru/uchenomu/magazines/2014_8.pdf

5. Саттарова М.Р. Сакральная лексика современного татарского языка (на материале толкового словаря) // Современные проблемы науки и образования. 2014. № 6. URL: http://www.science-education.ru/120-15301

## Г. ТУКАЙ ШИГЪРИЯТЕНДӘ ОРНИТОЛОГИК ОБРАЗЛАР

***Сафина Э.И.***

Статья посвящена изучению образа птицы в поэзии Г. Тукая. На примере стихотворений поэта анализируются разные образы птиц (соловей, ворона, ворон, ласточка и т.д.). На формирование семантики образов птиц существенное влияние оказала система религиозных взглядов («ходай кошлары» – божественные птицы, т.е. птицы бога и т.д.). Анализ образов птиц помогает не только раскрыть характер отдельного персонажа, но более полно представить духовные ценности и приоритеты жизни татарского народа.

The article is devoted to the analysis of images of birds in the poetry of G. Tukay. By the example of the poems, different images of birds (the Nightingale, crow, Raven, swallow, etc.) are analysed. The formation of the semantics of the images of birds was significantly influenced by the system of religious views («Jody collary» – divine birds, i.e. birds of God, etc.). Analysis of images of birds not only helps to reveal the nature of individual character, but to more fully represent the spiritual values and priorities of life of the Tatar people.

Орнитологик образларга мөрәҗәгать итү төрки, рус, көнчыгыш һәм европа әдәбиятларында бик еш күзәтелә. Теге яки бу орнитологик образның өстенлек итүе географик факторлар, шул тирәлектә аеруча күбрәк очраган кошларның биологик үзенчәлекләре, фольклор, мифологик һәм әдәби традицияләргә бәйле.

Тукай шигъриятендә орнитологик символика гаять бай һәм күптөрле. Моңа шагыйрьнең кош исемнәре белән аталган шигырьләренә («Карга», «Фатыйма белән сандугач», «Карлыгач», «Кошларга», «Кошчык», «Күгәрчен» һ.б.) күз салсак та инаныр идек.

Шигырьләрдә, нигездә, кошларның физик үзенчәлекләре (*Үрдәк оча, каз йөгерә, боты озынга күрә;* «Авыл җырлары», *Һавадин очкан аккошның аузы тулы балавыз*; «Безнең эти аягында») һәм кошларның үз-үзен тотышына, холык-фигыленә хас билгеләр чагыла (*Ала карга, кара козгын әрсезләнә, тук була*; «Авыл җырлары. Дүртенче көлтә») чагыла.

Орнитологик образлар уңай, тискәре һәм нейтраль итеп сурәтләнергә мөмкин. Анализ күрсәткәнчә, Г. Тукай шигырьләрендә кошлар:

– сизгер, акыллы: *Билгеле, кош алдавын байның белә* («Өч хакыйкать»).

– өлгер: *Әтәч бикли аларның юлларын алдан да, арттан да* («Алтын әтәч»).

– ышанычлы: *Гомергә дәүләтеңдә бу әтәч булыр сиңа сакчы* («Алтын әтәч»).

– алдан белеп торучы, хәбәр итүче: *Әтәч кычкырды тагын да – килә бугай явыз дошман* («Алтын әтәч»).

– ирекле, шат: *Очты бөркет киң һавада хөр вә шат* («Тәмсил»).

– көчле: *Бу лачын нинди көчле кош, күрәмсең?* («Күгәрчен»).

– әрсез: *Ала карга, кара козгын әрсезләнә, тук була* («Авыл җырлары. Дүртенче көлтә»).

– мәһабәт, горур: *Күктә очкан солтанат* (мәһабәт, горур – авт.) *кошны күреп...* («Тәмсил»).

– моңлы: *Кычкырма, күке, моңайтып, – безнең күңелләр китек* («Безнең эти аягында...»).

– асыл: *Асыл кошлар килеп чүпләсен* («Җырласаң да, җегет»).

– күңел кошы: *Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы* («Өзелгән өмид»).

– ходай кошы: *Яктылык! Рәхәт! Бәхет! Сайрый ходай былбыллары* («Кичә һәм бүген»).

Г. Тукай шигырьләрендәге орнитологик образларның күбесе, нигездә, башка язучы-шагыйрьләр иҗатындагы образлар белән тиңдәш диярлек. Чөнки бу шагыйрьнең фантазиясенә генә түгел, ә кошларга хас сыйфатларга бәйле. Шулай да, башка иҗатчыларныкыннан аермалы буларак, Г. Тукай шигъриятендә кошларга табыну, аларны илаһилаштыру, изгеләштерү белән бәйле орнитологик образлар зур урын алып тора. Шуларга киңрәк тукталырбыз да.

Иҗатында дини мотивларны чит итмәгән шагыйрь бу очракта тәңре, ходай, оҗмах сүзләрен актив куллана: *Без оҗмах кошлары булдык бу җирдә, Бөтен бүлмә тулып китте сәвапка* («Ысуле кадимче»), *Җырлагыз сез күңелегезгә тәңре нәрсә салганын, Мылтыгым да юк янымда, юк, шулай ук, ауларым* («Кошларга»), *Миңа, санки, азат иткән өчен, изге дога кылды* («Кошчык»), *Ходай кылган мине көчсез кошыннан* («Күгәрчен»), *Бервакыт чук-чук итеп сайрый ходайның кошлары* («Шүрәле») һ.б.

«Өзелгән өмит» шигырендә фани дөнья белән хушлашучы җан, кошка әверелеп, киң җиһаннан үзенә ирек эзли. Автор, дини мифология мотивларын күзаллап булса кирәк, җанның тәннән аерылып кош булып очуын сурәтли:

*Очты күңелем читлегеннән тарсынып күңелем кошы,*
*Шат яратса да, җиһанга ят яраткан раббысы.*

«Фатыйма белән сандугач» шигырендә читлектәге кошны азат иткәч, Фатыйма аннан изге дога сорый. Димәк, мәгънә тагын да киңәя, кош изге җанга әверелә:

*Йә, алайса, мин ишек ачтым сиңа,*
*Бар, азат бул, кыйл миңа изге дога...*» [3, б. 5].

Кошны иреккә очыру вакыйгаларын сурәтләгән «Кошчык» шигыре бу теманы тагын да үстерә:

*Кичә мин читлек ачтым, андагы кошчыкны коткардым,*
*Күңелсез тоткынымны киң яшел урманга кайтардым.*
*Аңар бирдем азатлык мин, үзем дә шул вакыт күрдем:*
*Тынычлап калды, никтер, һәм тәмам иркенләде күңлем.*
*... Очып киткәндә, ул шундый матурлап сайрады моңлы:*
*Миңа, санки, азат иткән өчен, изге дога кылды.*

Бу – кеше җаны күбәләккә, кошка әверелә дигән ышануларның тәэсире булса кирәк [3, б. 5].

Кошлар ходай яраткан могҗиза итеп кабул ителгәнгә күрәдер дә, Г. Тукай шигырьләрендә лирик герой аларга карап соклана, сакчыл һәм кайгыртучан мөнәсәбәт күрсәтә. Кошларга булган җылы хисләр һәм кайгыртучанлык түбәндәге юлларда ачык чагыла: *Тәрәзәләр ачтым, гөлләр чәчтем, Асыл кошлар килеп чүпләсен* («Җыр»), *Юк, сөекле сандугачым, уйнасам, дәресем кала* («Эш беткәч уйнарга ярый»), *И кошым, син мескенем, син чыпчыгым* («Өч хакыйкать»), *Ни өчен син сайрамыйсың, Сандугач? Шат була күңлем минем, син сайрагач* («Фатыйма белән сандугач») һ.б.

«Кошларга» шигыренең һәр юлында җырчы дусларга җылы, матур мөнәсәбәт ярылып ята:

*...Курыкмагыз, кошлар, күреп сез янча мин барын,*
*Мин тимәм сезгә, фәкать сайравыгызны тыңларым.*
*... Бик тынычлап сайрагыз сез, мин тимим, сезгә тимим,*
*Әллә иркендә торуның кадрене белмимме мин?!*
*Курыкмагыз, яхшы беләм, мин һич тә сезне ауламам,*
*Сайрагыз, тыңлап торырмын, тын да алмам, шауламам.*

Һәр кешегә мәгълүм булган кошлардан һәм «ходай кошларыннан» тыш, Г. Тукайда фантастик кошны да очратырга була. Бу – ахмак, акылсыз итеп сурәтләнгән һәм *ганка* итеп исемләнгән кош: *Җиһанда хиссе инсият озак кәрратлә Ганкадан* («Хөррияте»), *Бу дөньяда табалмассың аның төсле ганканы* («Авыл җырлары»).

Авыл җирлегендә, йорт тирәләрендә күренә торган кошлардан Тукай шигырьләрендә сандугач, чыпчык, карга, тургай, күркә, әтәч һ.б. белән бәйле образлар еш очрый.

Аларның уңай, тискәре яки нейтраль мәгънәдә кулланылганнары бар. Габдулла Тукай аеруча борынгы чорлардан ук фольклорда да, язма әдәбиятта да киң таралган былбыл образын яратып кулланган. Былбыл – халык иҗатының мәкаль һәм җыр кебек халык күңеленә якын төрләрендә дә, поэзиядә дә иң актуаль орнитологик образларның берсе. Ул «төрки-татар мифологиясендә һәм фольклор әсәрләрендә тирән эчкерсез саф мәхәббәт, кавышу-аерылышу, кайгы-хәсрәт, үлем һәм үлемсезлек символы» [7, б. 247] булып санала. Габдулла Тукай әлеге асыл кошларны хәтта «ходай былбыллары» дип атый:

*Әй, кояш нурлы, ачылган бакчаларның гөлләре;*
*Яктылык, рәхәт, бәхет! Сайрый ходай былбыллары!* («Кичә, бүген»).

Мифологиядә һәм халык иҗатында былбыл һәм сандугачлар изге хәбәр китерүчеләр буларак сурәтләнгәннәр. Халык та былбылларны изге итеп санаган, Җырларда, шигъриятtә былбыл образы сагыну, саргаю, көрәшү, өмет итү кебек мотивларны чагылдырганда ярдәмгә килә. Шул ук вакытта, былбыл – матурлык, мәхәббәт, ирек символы да. «Бер татар шагыйренең сүзләре» шигырендә «*Очырмакчы булсаң былбыл күкрәгемнән, Әллә ничек, мыр-мыр итеп, мәче чыга»,* дип, былбыл образына Тукай да матурлык, нәфислек кебек символик мәгънәләр салган.

Кошларга хас булган уңай яки тискәре сыйфатларны тагын да ачыграк чагылдыру өчен автор еш кына кош образларын бер-берсенә каршы куеп сурәтли. Шагыйрь аеруча былбыл (сандугач) – карга образларын капма-каршы куярга ярата: *Сиңа соң сандугачча сайрамак мөмкинме, и карга*! («Мөтәшагыйрьгә»). *Билгеле, һәрбер агачлар да корырга башлыйлар,Былбыл урнына оя тоткач башында каргалар*! («Дин вә гавам») дигән юлларда каргаларны кимсетеп, былбылларны олылап фикерен оста һәм образлы итеп җиткерә алган.

Лирик геройда кошларга карата төрле хис-тойгылар уяна. Мәсәлән:

– ошату, соклану, горурлану: *Барча кошның да үзенчә сайравы бар, шигъре бар* («Карга»), *Очып киткәндә ул шундый матурлап сайрады моңлы* («Кошчык»), *Сайрагыз, тыңлап торырмын, тын да алмам, шауламам.* («Кошларга»).

– кызгану: *И кошым, син мескенем, син чыпчыгым*. («Өч хакыйкать»);

– кайгырту, алар өчен борчылу: *Кичә мин читлек ачтым, андагы кошчыкны коткардым* («Кошчык»), *Бик тынычлап сайрагыз сез, мин тимим, сезгә тимим* («Кошларга») һ.б.ш.

Кошлар сайраган, кычкырган һ.б. тавышларны куллану күп вакытта образны тулыландырырга, баетырга ярдәм итә. Г. Тукай да бу алымнан оста файдалана: *Кошчыгым чиксез кыю, чыррр-чырр килә* («Өч хакыйкать»), *Әтәч прых! Прых! итеп ханның баш түбәсенә кунды* («Алтын әтәч»), *Син очып йөргәнче, кошчык, прр да прр!* («Өч хакыйкать»), *Сайрый тартар «тар-тар-тар»* («Тартар кошы сайрый»), *Бервакыт чук-чук итеп сайрый ходайның кошлары* («Шүрәле»), *Әтәч тавышлана тагын да: «Кикрикүк!» тә «күк!» «күк!» ди*; *Бәла күргәч тә сайрый, кычкырадыр: «Кикрикүк-күк!» – ди* («Алтын әтәч»); *Азык эзли – оча тургай да пыр-пыр* («Көз»); *Шул урындук, гөнаһ шомлыкка, бер чыпчык / Йөри иде азык эзләп пыр-пыр очып* («Һәркемнең ашыйсы килә»), *Барча кошның да үзенчә сайравы бар, шыйгре бар, / Карга мескен җырлый белми, кычкыра тик: «Кар» да «Кар!»* («Карга») һ.б.

Кошлар белән бәйле образлар төрлелеген түбәндәге мисаллар тагын да ачык раслый. Әлеге шигырь юлларында шагыйрь төрле әйберләрне, күренешләрне кошларга охшатып тасвирлый. Мәсәлән,

– табигать күренешләрен, әйләнә-тирәдә очрый торган предмет һәм күренешләрне: *Туктаганнар күрмәгә иртүк табигать күркене Күктә аккошлардай ак, күчмә болытлар төркеме* («Җәйге таң хатирәсе»). Игътибар итсәк, бер шигырендә Г. Тукай кошларны болытка, икенчесендә, киресенчә, болытларны кошларга охшата: *Һаваларда кошлар оча болыт-болыт* («Яз галәмәтләре»).

– кешеләрне: *Атылган кош, адаштырган эттәй* («Эштән чыгарылган татар кызына»), *Йоклый шунда йолдызлар да өелешеп, Оядагы йоклап яткан кошчыклардай* («Ай һәм кояш»), *Салган Сабит ихласын, кош бәбкәседәй җимгә* («Сабитның укырга өйрәнүе»), *Нигә тулган чалмалы козгын зиярәт өстенә? Бер сыраның мичкәсе, бел, боз булып каткан бүген.* («Нәрсәдән?»), *Азатлык кошлары без, әйдә, әйдә* («Мәхбүс»), *Без оҗмах кошлары булдык бу җирдә* («Ысуле кадимче») һ.б.

– территориаль җирлекне: *Төркия күктә очар бөркет иде* («Тәмсил»).

– җансыз предметларны: *Приемның, ай, ишеге тар ләхеттән тар икән; Әчтерханда «Борһан», «Идел» – ике әтәч бар икән* («Авыл җырлары. Беренче көлтә»). Биредә «Борһан» һәм «Идел»гәзитләре арасында барган тарткалашуга ишарә ясап һәм әтәчләрнең сугышырга маһирлыгын күздә тотып, Габдулла Тукай әтәчне күчерелмә мәгънәдә кулланган.

Мисаллардан күренгәнчә, Г. Тукай шигырьләрендә йорт тирәләрендә күрергә мөмкин булган, халык белгән кошларның барысы да диярлек образ тудырырга ярдәм итә.

Габдулла Тукай юкка гына орнитологик образларга еш мөрәҗәгать итмәгәндер. Шагыйрь үзе, аның җаны да гел кошлар кебек иреккә омтылган бит. Әлеге урында бөек шагыйребезнең язмышына, иҗатына багышлап язылган ике әсәрне телгә алып, параллель уздыру урынлы булыр кебек. Гаҗәп, әмма Ә.Баянов та, И. Юзеев та, Тукай трагедиясен «ачар» өчен орнитологик образларга мөрәҗәгать иткәннәр. Ә. Баянның Габдулла Тукай гомеренең соңгы еллары хакындагы «Каракош» шигъри трагедиясендә Каракош ике башлы бөркет кыяфәтендә сурәтләнә. Автор әлеге образ ярдәмендә Россия империясен, ул алып барган сәясәтне тасвирлый. Илдар Юзеевның «Очты дөнья читлегеннән» шигъри трагедиясендә Тукай:

«Дөнья зинданында кылган
Иң соңгы догам шушы:
Очсын дөнья читлегеннән
Тарсынып күңелем кошы...», –

ди [10, б. 304]. Әсәрдә түбәннән, халыкның төбеннән күтәрелгән шагыйрь Кояшка кадәр менеп җитә һәм шунда югала [9, б. 187]. Үзенең шигырьләрендә дә Тукай кайбер кошларны җир белән күк арасындагы, исәннәр белән үлгәннәр арасындагы арадашчылар дип сурәтли. Орнитологик символлар һәм алар белән бәйле чагыштыру-метафоралар, һичшиксез, Г. Тукай шигърияген баеткан, андагы образлар системасын тулы һәм күп төсмерле иткән.

ӘДӘБИЯТ


1. Баян Ә. Каракош. Сайланма әсәрләр: 5 томда. II т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002.
2. Җәләлиева М.Җ. Әдәбиятыбызның җырлы чишмәләре. Казан: Мәгариф, 2001. 200 б.
3. Җәләлиева М.Җ. Шагыйрьнең миф дөньясы // Мәгърифәт. 1996. 3 май.
4. Татар мифлары: ияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, им-томнар, сынамышлар, йолалар. Казан: Тат. кит.нәшр., 1996. Т. 1. 118 б.
5. Тукай Г. Сайланма әсәрләр: шигырьләр, мәсәлләр, поэмалар. Казан, 1996. 191 б.
6. Тукай Г. Шигырьләр, әкиятләр, поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. 510 б.
7. Урманче Ф.И. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда. Казан: Мәгариф, 2008. 1 т. А–Г. 303 б.
8. Хань У. Орнитологические образыв русской и китайской поэзии первой трети XX века: автореф. дис. … канд. филол. наук. Волгоград, 2015. 23 с.
9. Шәехов Л.М. Г. Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар // Г.Тукай тууына 125 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. Казан, 2011. Б. 186–189.
10. Юзеев И. Очты дөнья читлегеннән. Сайланма әсәрләр: 5 томда. III т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002.


## ТУКАЙНЫҢ ОСТАЗЫ – МОТЫЙГУЛЛА ТӨХФӘТУЛЛИН


***Сафина Э.Р.***



Мутыгулла Тухватуллин – татарский просветитель. Он основал в городе Уральске медресе «Мутыгия», открыл в своем доме типографию. В 1905 году его старший сын Камиль и Габдулла Тукай стали издавать татарскую газету «Фикер» и журнал «Уклар». Также здесь был издан журнал на татарском языке арабским шрифтом «Аль-Гасруль-Джадидъ» («Новый век»).

Mutygulla Tukhvatullin a famous Tatar scientist-theologian, graduate of the Cairo islamic University, was born in the village of Malye Kaybitsy of Kazan province. Being a versatile talented person, Mutygulla knew the poetry of the East, Arabic and Russian literature, and spoke fluently in several languages, loved music, highly appreciated the poetry of Pushkin and Lermontov. In the Tatar settlement of Uralsk city he founded the madrasah «Mutygiya», in which studied the Tatar poet Gabdulla Tukay. The Tukhvatullin house occupied an important place in Tukay is life here he made use of the library of his teacher, and in 1905 together with his son M. Tukhvatullin Kamil Tukhvatullin began publishing the Tatar newspaper «Fiker» and the magazine «Uklar». Some time the printing shop was in the Tukhvatullin house.

*Һәр үткән көн,*
*Һәр мәдәни атланган адым*
*Тукайны зур итәчәк,*
*Үстерәчәк кенә.*
*Тукай яши, Тукай яшәячәк.*
*Татар милләте яшәгәнчә кадәре Тукай яшәячәк!*
Г. Исхакый

1886 елның 27 нче апрелендә, моннан нәкъ 130 ел элек Казан артындагы Кушлавыч авылында, Мөхәммәтгариф мулла гаиләсендә татар халкының иң сөекле, бөек шагыйре Габдулла Тукай дөньяга аваз сала. Ләкин ни кызганыч, бу бала, дүрт яшен дә тутырмый эти-энисез калып, күп михнәтләр чигә.Малай туып дүрт ай ярым үткәч, этисе Мөхәммәтгариф хәзрәт үлеп китә. Тол калган Мәмдүдәне (Габдулланың энисен) Сасна мулласына кияүгә бирәләр. Габдулланы авылның Шәрифә исемле фәкырь бер карчыгына вакытлыча асрамага калдыралар. Шуннан соң сабыйның газаплы, авыр тормышы башланып китә. Соңрак аны энисе яңа гаиләсенә үз янына алдыра. Ләкин бу рәхәт озакка бармый: энисе дөнья куя, Габдулла дөм ятим кала. Сасна мулласы бу ятимне Өчилегә – Габдулланың энисенең атасына кайтарып бирә. Монда үги әби, күп балалы гаилә. «Үги әбинең алты күгәрченнәре эчендә мин бер чәүкә булганга, мине җыласам – юатучы, иркәләнәм дисәм – сөюче, ашыйсым-эчәсем килсә – кызганучы бер дә булмаган, мине эткәннәрдә төрткәннәр...»

Бәләкәй Габдулла монда ятимлекне генә түгел, ачлыкны да татый. Бабасы, күрше авыллардан икмәк сыныклары теләнеп алып кайтып, балаларны ач үлемнән саклый. Ә бервакыт баланы, Казанга баручы бер ямщикка утыртып, ерак, билгесез сәфәргә озаталар. Ямщик Печән базарына килгәч: «Асрарга бала бирәм, кем ала?» – дип кычкырып йөри.

Халык арасыннан бер кеше чыгып малайны үзләренә алып кайта. Яңа бистә һөнәрчесе Мөхәммәтвәли абзый белән Газизә абыстай шулай итеп малайлы булалар. Бәләкәй Габдулла бу гаиләсендә ике ел буена ярыйсы гына яшәгәч, эти – энисе авырып китә һәм: «Без үлсәк, бу бала кем кулына кала, ичмасам, авылына кайтарыйк...» – дип, аны яңадан Өчилегә озаталар. Тырыша торгач, малайны Кырлай исемле авылдан ир-баласыз Сәгъди абзыйга уллыкка озаталар.

Оядан ояга күчеп җылылык эзләп йөргән бу сабыйга Кырлай мәрхәмәтлерәк булып чыга. Габдулла монда башка урыннарга караганда озаграк яши, хәтта сабакка йөри башлый.Шулай рухи яктан авыл, крестьян тормышын тәмам күңеленә сеңдергән Тукайны көннәрдән бер көнне Кушлавыч авылының Бәдретдин исемле кешесе эзләп таба да Уральскига алып китә. Тукай барып урнашкан нигез: апасы Газизә, җизнәсе Галиәсгар Госманов. Галиәсгар Габдулланы үз баласы кебек каршы ала, русча укырга рус мәктәбенә, татарча гыйлем алырга «Мотыйгыя» мәдрәсәсенә урнаштыра. «Мотыйгыя» мәдрәсәсенең мөдәррисе Мотыйгулла Төхватуллин – хәзерге Татарстан Республикасының Кайбыч районында урнашкан Кече Кайбыч авылында XIX гасыр урталарында мулла булган Төхватулла хәзрәт гаиләсендә дөньяга килә. Ул нәни чагыннан ук ятим кала, башта энисе, ике яшенә җиткәндә этисе үлеп китә. Мотыйгулла кечкенәдән сәләтле, зиһенле бала була. Авыл халкы, аның укуга сәләтен күреп, Кече Кайбыч мәдрәсәсендә берничә ел укыганнан соң, Кышкар мәдрәсәсенә укырга җибәрә.

Кышкар мәдрәсәсендә укыган чагында Мотыйгулла Мөхәммәтгариф исемле шәкерт белән якыннан дуслаша. (Мөхәммәтгариф Габдулла Тукайның этисе була). Алар сабакларны бергә зур тырышлык белән өйрәнә. Мөхәммәтгариф үз авылына Кушлавычка ата-аналары янына кайтып йөргәндә, Мотыйгулланы да «ятим бала» – дип, үзе белән бергә алып кайткан.

Ике дус малай Кышкар мәдрәсәсен уңышлы гына тәмамлый. Мөхәмматгариф туган авылы Кушлавычка муллалык хезмәтенә билгеләнә, ә Мотыйгулланы Кече Кайбыч халкы үз теләге белән янәдән – Каһирәдәге «Әл-Әзһәр» университетына укырга җибәрәләр.

Мотыйгулла ерак илләргә китеп барганда да, үз дустын – Мөхәммәтгарифне онытмаска сүз биреп китә.

Еллар үтә. Мотыйгулла 10 елга якын укуын тәмамлап кайтыр вакыт та җитә. Ул Гарәбстаннан туган җиренә кайтып барышлый, апасын күрү өчен Уральск шәһәренә туктала, Таугайни бай мәчетенә бара. Мәчеттә Мотыйгулла үзенең матур тавышы белән

Коръәнне нәкъ гарәпчә көйләп укыганда, мәчет картларын таң калдыра. Алар Мотыйгулланы Уральск шәһәрендә калдыруны сорап, мәчет хуҗасы Таугайни байга вәкил булып бара. Бай Мотыйгулланы үз мәчетенә икенче мулла итеп калдырырга ризалыгын бирә. Шулай итеп, Мотыйгулла авыл халкының рөхсәте буенча мәчет мулласы хезмәтендә урнашып кала. Мотыйгулла биргән вәгъдәсе буенча яшьлек дустын – Мөхәммәтгарифне дә, Кушлавычтан үз янына Уральскига чакыртып алырга теләп, аңа хат җибәрә. Әмма юл арасы ерак булып, бер-берсенең хәл-әхвәлләрен белешеп торырга кыен булганлыктан, дустына соңгы чакыру хәбәре барып җитешми. Гариф дусты үлеп киткән була.

Мотыйгулла Мөхәммәтгариф дустының бердәнбер 8 яшьлек ир баласын, ятим калган бала, авыр көннәр кичерә дип, җизнәсе Галиәсгар аша үтенеп, үз иленә – Кушлавычтан Уральскига чакыртып ала.

Яшь Апуш (Габдулланың кушаматы) Мотыйгулла мәдрәсәсендә үзенә карата җылы мөгамәлә сизә. Мотыйгулла малайның күңелен күреп, үзеннән читләштермичә, бар күңеле белән якын итә. Дәрес вакытында аны, башка шәкертләрдән аерып, үзе янына утырткан. Дәрес беткәч, Габдуллага әтисе турында, аның белән дуслыклары турында сөйли. Сабый атасы турындагы истәлекләрне зур кызыксыну белән тыңлаган.

1898 елда 12–13 яшьлек сабыйны, Мотыйгулла, кулыннан җитәкләп, мәдрәсә тулай торагыннан Таугайни биргән яңа йортка алып кайта. Тормыш иптәше Гыйззинаска бу баланың кем икәнен аңлата. Гыйззинас, баланы күргәч, аның йөзенә, серле ятим күз карашларына күз төшереп, вафат булган балаларын да искә алып, Габдулланы җылы кочагына ала. Баланың күңелләрен күтәреп, өс-башларын алыштырып Мотыйгулла янына чәй эчәргә алып керә. Мотыйгулла баланы күреп: «Менә безнең Габдуллабыз инде бу!», – дип чын күңеленнән сөенә. Чәй янында аңа үз киңәшләрен бирә, мәдрәсәдәге тәртипләрне сөйли, улы Камил һәм башка балалары белән якыннан таныштырып, алар белән дус тату булырга киңәш бирә. Менә шул көннән Мөхәммәтгариф дустының ятим калган баласын яңа күчкән йортына китереп, җылы кочагына ала Мотыйгулла. Мәдрәсәдә биргән сабакларын үз янында, үзе тикшереп хәзерләтә, укырга, язарга дәфтәр-китаплар бирә, өс-башын карый.Баланың рус теле аксамасын дип, улы Камилгә бөркетә. Соңрак «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә дәресләр рус телендә дә укытыла башлый. Габдулла мәдрәсәдә тырышып укый.

«Мотыйгыя»мәдрәсәсендәрус телендә дәресләр өстәлү белән башка уку системалары да елдан – ел үзгәрә бара. Мотыйгулла яңа йортында кызлар мәдрәсәсе ачу теләге белән йөри башлый. Буйга җитеп килгән Мотыйгулланың улы Камилнең күңелендә китап-журналлар чыгару теләге кузгала. Аны чынга ашыру өчен Мотыйгулла Камилне үзе укып кайткан Гарәбстан якларына укырга җибәрә. Өч ел үткәч, Камил укып кайту белән типография ачуны үз өстенә ала. Әтисенең булышлыгы белән мәдрәсәдә укучы һәм укып чыккан шәкертләрне, башка ышанычлы дусларын җыеп, тизрәк кайтуын көтеп йөргән Габдулласын үз янына алып, барысы белән бергәләп, төрле шәһәрләрдән язучылар табып, алардан җавап килгәнен дә көтмичә, 1903–1904 елларда газета-журналлар чыгара башлыйлар.

Камил Мотыйгый Гарәбстаннан укуын бетереп кайткан вакытка Габдулла яңа әсәрләр иҗат итә. Мотыйгулла улы кайткач, аны Габдулланың язмалары белән таныштыра: «Хәзер безнең Апуш язуга остарды инде», – дип мактап, үзе дә горурлана. Габдулла Тукай язу эшенә зур дәрт белән керешә. Аның һәрбер язган әсәре, шигырьләре газета-журналларда басылып, халык алдында зур мәхәббәт казана. Типографиядә язу эшләре уңышлы бара башлагач, ике үсмер йөрәкнең күңелләре күтәрелә, төрле әдәби кичәләр уздыра башлыйлар. Камилнең җырга сәләте зур булуы Габдулланы шигырьләр язарга дәртләндерә. Бу шигырьләргә Камил төрле милләт: гарәп, төрек, рус, татар, поляк, еврей музыкаларыннан көйләр сайлап, аларны үз тавышына яраштырып, гаиләсе һәм типография эшчеләре каршында җырлый, ә Габдулла үз шигырьләрен сөйли торган була. Габдулла Тукайның әдәбиятка килүе Уральскида Мотыйгулла хәзрәтнең олы улы Камилнең йогынтысы зур була.

Габдулла Тукайның тормыш юлына күз салсак, ул 12 ел гомерен Уральск шәһәрендә Мотыйгулла хәзрәт гаиләсендә үткәрә, «Мотыйгия» мәдрәсәсенең талантлы шәкертләреннән берсе, Камил Мотыйгыйның якын дусты була. Мәдрәсәдә укыган вакытта гаруз теориясен үзләштерә. Шигърият, гаруз дәресләрен Мотыйгулла хәзрәт үткәрә. Димәк, Мотыйгулла Төхватуллин үзе дә бу теорияне яхшы белгән, Каһирәдәге «Әл-Әзһәр» дә белем алганда үзләштергән.

Габдулла Тукайның бөек татар шагыйре булуында Мотыйгулла Төхватуллинның өлеше зур. Әлбәттә, ятимлектән килгән яшьүсмер бала гаруз теориясенең нигезләрен белмәгәндер. Мотыйгулла хәзрәт Габдуллага һәрдаим: «Әтиеңне яраткан күк, сине дә якын күрәм» – дип әйтә торган була. Дәрес вакытларында, дустымның баласы дип, Габдулланы башка балалардан якын итеп, үзе янына утыртып дәрес биргән. Бу «Тукай – Тукай булмас иде, Мотыйгулла булмаса», дигән сүзләрне тагын бер кат раслый.

1907 елда Габдулла Тукай үз остазының киңәше буенча Казанга китә. Шушы елның көзеннән Тукайның Казан чоры башлана. 1911 елның ахыры – 1912 елның башында Өчиледә яшәп ала, авыл халкының авыр, газаплы тормышын чагылдырган әсәрләр яза. 1913 елның башында шагыйрьнең сәламәтлеге бик нык какшый, 15 нче апрельдә Тукайның гомере өзелә.

Үз канаты астында ныклы белем, тәрбия биреп, татарны мәгърифәтле, мәдәниятле, Тукайлы иткән бөек зат ул Мотыйгулла Төхватуллин.

ӘДӘБИЯТ

1. Габдулла Тукай: Фотоальбом / төз. һәм фот. З. Бәшири; текст авт. М. Мәһдиев. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 303 б.

2. Галия Кайбицкаяның «Тормыш хәлләрем» истәлек дәфтәре. 1990 ел.

3. Кайбыч таңнары гәҗите. 2014. 25 апрель. № 31.

## КАДИМ ҖӘМИТОВНЫҢ КАБАТЛАНМАС ТУКАЕ

***Сәетова В.Р.***

Без халкыбызның Бөек шагыйре Габдулла Тукайның бик күп портретларын беләбез. Алар арасында салкын мәрмәрдән, авыр бронзадан эшләнгәннәре дә бар. Үтә осталык һәм төгәллек белән коелган булсалар да, алар шагыйрнең чын образын, сурәтенең нечкәлекләрен бер стереотипик калыпта тоталар кебек. Сынчы Кадим Җәмитовның Тукае исә бөтенләй башка. Аннан уй-хыяллар, күтәренке шигърият сирпелә. Безнең алда шагыйрьнең җылы карашлы образы җанлана. Әнә шулай итеп Кадим Җәмитов сынчылык сәнгатендәге иске канунарны җимереп, Тукайны үзенчә күзаллый алган. Моннан 11 ел элек, 1995 елда, сынчы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, якташыбыз Кадим Җәмитов Саба Туган якны өйрәнү музеена үзенең иҗат җимешләрен бүләк итеп тапшырганнан соң, музеебыз кунаклары Габдулла Тукайны әнә шундый яңа калыпта, үзгә образда ачты. Тукайны гына түгел, сабалылар Сәгыйть Сүнчәләй, Галиәскәр Камал, Фатих Әмирхан, Камил Мотыйгый кебек шәхесләрнең сыннарын күреп, алардан яктылык һәм илхам алып, таң калгандыр. Юкса, әлеге сыннар музей ишекләрен ачып кергән һәркемне үз янына бу кадәр җәлеп итмәс иде.

«Казан» милли мәдәни үзәге каршындагы «Хөррият» монументы, Оренбургтагы Муса Җәлил һәйкәле, Вена шәһәрендәге галәмәт зур мәйданның бизәге булган «Савыктыру» сыннары – болар бар да Кадим Җәмитовның иҗат үрнәкләре. Аларны әле тагын Мәскәүнең атаклы Третьяков галереясында, Австрия, Германия, Бөекбритания, Япония, Америка, Канада, Төркия кебек илләрнең музейларында күрергә мөмкин.

Саба районының Олы Арташ авылында дөньяга килгән, күрше Икшермә урта мәктәбендә белем эстәп, аннан Ижау педагогия институның сәнгать факультетын тәмамлаган, соңрак Мәскәүдә танылган сынчы В. Табах остаханәсендә скульптура серләренә төшенгән егет әнә шулай дөньякүләм танылган шәхес кенә түгел, ә иң беренче чиратта үз халкына, аның тарихына, татарлыгына тугъры калган милләтпәрвәр улы да әле. Чөнки Кадим Җәмитов иҗатының төп юнәлешләреннән берсе – татар зыялылары арасыннан акыл иясе, остаз булырлык шәхесләрне, шагыйрь образларын сынландыру-җанландыру. Шул образлар аша ул үз халкының язмышын гәүдәләндерә, аның рухи омтылышларын сурәтли. Иҗатында сынчы Тукай, шагыйрь яшәгән чорга аеруча игътибар бирә. Алты сыннан торган «Тукай һәм аның чордашлары» скульптуралар сериясенең барлыкка килүе дә шул нисбәтне дәлилли. Габдулла Тукай, Галиәскәр Камал, Фатих Амирхан, Камил Мотыйгый, Сәгыйть Сүнчәләй – дуслар, чордашлар, үз заманының зыялары. Кадим Җәмитовның әлеге алты олуг затның һәркайсына үзенә генә хас холык характер салырга тырышкан. Бу эштә ул шамот ташыннан үтә дә оста файдалана. Бу үзенә күрә ясалма таш, әмма сынчы кулында ул гүя җанланган, һәр

сынга ниндидер мәгънә белән яткан кебек. Ә бит сын койганда оста алдында образга характер өстәр алдыннан чамалны дөрес куллану бурычы тора. Бу очракта да шамотны төгәл шартларда, ягъни дөрес температурада, формада тоту зарур. Җәмитов бу технологиянең асылын, тәмен белеп эшли, хәтта сыннары суынып, кибеп өлгергәнче аларга җан да өреп куйган диярсен: аларда инде ниндидер сизелер-сизелмәс кенә төс чалымлана. Бусы сынга аны янырып койганчы буяу салу, осталар телендә ул салкын ысул дип атала. Кайнар ысул исә яндырганнан соң төс кертү. Әмма, нигездә Кадим Җәмитов сынның аерым детальләренә генә төсмер өстәп җибәрә, шуның белән образның характерлы үзенчәлеген ача. Мәсәлән, «Тукай» сынында ул төсләр белән шагыйрьнең чәчләре, күзләре һәм күкрәгенә сыланып яткан шарфына сизелер-сизелмәс кенә кагылып үткән. Шуның белән Тукай ничектер җанланып киткән, аннан инде шигъри бер җылылык бөркелеп тора сыман. Тукайның калган биш чордаш-сынына да кытыршы-шадра шамотның контраст булып ятуы тетрәндергеч мәгънә салган. Безнең алда – дөньяда бик иртә киткән тарихи шәхесләр. Шул рәвешле оста алты сынны да кабатланмас образ итеп тудыруга ирешкән. Шул ук вакытта иҗатчы кулында аларның җыелма образга әверлгәнлеге бәхәссез, чөнки сынарның алтысын да берләштергән уртак сыйфатлар да бар: бу асыл затларның үз халкына-милләтенә тоташкан тамырлары нык-тирән, тормышка карашлары ачык-максатчан, ә күңелләре һәрчак эзләнүдә. Шуңа да Кадим Җәмитовның бу скульптуралар сериясен лаеклы рәвештә драматик һәм трагик шәхесләләр галереясе дип атарга мөмкин.

Алда әйтеп үтелгәнчә, Кадим Җәмитов иҗатында Г. Тукай һәм аның әйләнәсендә булган замандаш-шәхесләргә зур урын бирә. Саба туган якны өйрәнү музеенда саклаучы «Дуслар» композициясе шуның чираттагы мисалы. 1990 елда иҗат ителгән әлеге әсәр беренче мәртәбә Мәскәүдәге шәхси күргәзмәдә күрсәтелгән һәм зур бәя алган, ул чакта ук тамашачылар бу композицияне бик яратып кабул иткән. Габдулла Тукай белән Фатих Әмирханнын дуслыгын чагылдыручы бу әсәр алда әйтеп үтелгән шамот салу ысулы белән эшләнгән. Иҗатчы аларны төсле шамот кулланып койган: чәчләр, күз, кашлар, битләре, хәтта костюмнарына да җинелчә төс кунганлыгын тиз генә абайлый алмассың, чөнки кузгә иң элек сыннарнын лирик-эстетик чагылышы ташлана.

Г. Тукай өчен Ф. Әмирханнан да ышанычлы якын дус булмаган. Әнә шул мөнәсәбәтне күрсәтү өчен сынчы Ф. Әмирханның гәүдәсен куышлап эшләгән һәм Тукайны шул куышка сыендырган. Тукай шулай итеп дусты тарафыннан үзенә яклау һәм җан тынычлыгы таба. Фатих Әмирхан исә Тукайны иңнәреннән кочып алган. Әнә шулай итеп үз эченә бикләнгән, күбрәк ялгызлыкка омтылучан Тукай белән җор, аралашучан Ф. Әмирхан алтын урталыкны тапкан кебек, Җәмитовның кулларында тулы бер композициягә әйләнгән, чын дуслыкның, кардәшлекнең өлгесенә әверелгән.

Кадим Җәмитовның иҗат үрнәкләре – гадәти булмаган иҗат әсәрләре генә түгел, алар безнең мәдәни мирасыбыз, тарихи ядкарьләребез буларак киләсе буынга васыять ролен үтәячәк кыйммәтләр. Алар тынып калган музей диварларына җан өрүче, һәркемнең күңеленә, аңына характерлары белән үтеп керүче сыннар. Музеебыз ишекләрен ачып керүчеләргә осталыкның камил үрнәген генә түгел, тәрбияви, әхлакый мәгънәләрне төшендерүчеләр дә алар. Җәмитовның һәрбер сыны – ул үзе бер тарихи дәвер кебек. Аларның үз асылы, үз кыйммәте, сагышы һәм омтылышлары, максатлары, тынгы белмәс замана шаукымы чагыла.

## ИБРАҺИМ БИККОЛОВ ЗАМАНДАШЛАРЫ Ф. ӘМИРХАН ҺӘМ Г. ТУКАЙ ТУРЫНДА

*Сәйфуллина Ф.С.*

В статье анализируются публицистические статьи известного в начале XX века педагога-просветителя, журналиста, общественного деятеля Ибрагима Биккулова, посвященные деятельности Ф. Амирхана и Г. Тукая. Являясь их современником, близким другом К. Бикколов высоко ценил творчество этих неординарных представителей татарской литературы начала XX века.

This article analyzes the journalistic articles known in the early twentieth century, the teacher-educator, journalist and public figure Ibrahim Bikkulov on activities F. Amirhan and G. Tukay. As their

contemporaries, a close friend of I. Bikkolov highly valued work of these extraordinary representatives of the Tatar literature of the early twentieth century.

Бикколов Ибраһим Җамаледдин улы (1884–1938) – җәмәгать эшлеклесе, педагог, XX гасыр башында актив әдәби-публицистик эшчәнлек алып баручы журналист, тәрҗемәче. XIX йөзнең соңгы чирегендә татар дөньясына мәгърифәтчелек идеаллары иңә, зыялыларның прогресс-тәрәккъыят хакында хыял-өметләр белән яши башлаган елларда Сембер губернасы Буа өязе, Суыксу волосте, Яңа Тинчәле авылында (хәзерге Татарстанның Буа районы) үз заманында танылган руханилар гаиләсендә дөньяга килә.

И. Бикколовның язмышы һәм эшчәнлеге хакында мәгълүматлар әлегә бик аз. Үз вакытында аның журналистика өлкәдәге эшчәнлегенә Г. Ибраһимов югары бәя бирә [1]. 1930–1937 елларда шәхес культы корбаннары булган бик күпләр кебек, аның исеме дә озак заманнарга тарих битләреннән алып ташланды. XX гасыр ахырында гына Ибраһим һәм аның бертуган абыйсы – шагыйрь, мәгърифәтче язучы, гасыр башы мәктәп-мәдрәсәләре өчен дәреслекләр, уку китаплары төзүче Касыйм Бикколов турында кайбер мәгълүматлар дөнья күрде. Ибраһим Бикколовның эшчәнлеге, тормыш юлыннан аерым сәхифәләр Фатыйма Ибрагимованың XX гасыр ахырында «Казан утлары» журналы битләрендә басылган мәкаләсендә урын алды [2, б. 188].

Яңарыш чоры татар тормышында, туган җирләре – Яңа Тинчәле авылының ике гасыр арасы хәятендә Бикколовлар нәселе кылган изге гамәлләр, калдырган мәдәни мирас киңкырлы. Ш. Мәрҗани мәдрәсәсендә белем алган этиләре Җамаледдиннең дә, Казан мәдрәсәләренең берсендә укыган олы улы – мәгърифәтче, дин белгече, шагыйрь, язучы Касыймның, атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлап, гомерен укытучылык эшенә багышлаган, публицист булып танылган улы Ибраһимның да төрле төбәкләрдә таралып яшәгән татар кавемен белем-мәгърифәтле итү юлындагы хезмәтләре бәһәләп бетергесез. Бабалары – Габделлатыйф хәзрәт вә аның гаиләсе хакында Ш. Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар...» китабының «Шәхесләр һәм истәлекле вакыйгалар» бүлегендә [3, б. 283], Р. Фәхреддиннең атаклы «Асар» китабында [4, б. 136] шактый киң мәгълүматлар бирелгән.

Башлангыч белемне Буа мәдрәсәсендә алганнан соң, Ибраһим Бикколов Казанга килеп, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый. Шунда ул татар әдәбиятының булачак классигы Фатих Әмирхан белән таныша, аларның дуслыгы Ф. Әмирханның вафатына кадәр дәвам итә. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә Ф. Әмирхан җитәкчелегендә оештырылган һәм 1905 елга кадәр эшләп килгән әдәбият түгәрәге әгъзалары арасында И. Бикколов исеме дә телгә алына [5, б. 554]. Казанда татар шәкертләре тарафыннан оештырылган «Ислахчылар» хәрәкәтендә (1905–1906) актив катнашучылар буларак та Ф. Әмирхан, И. Бикколов исемнәре янәшә телгә алына. Б. Әхтәмов җитәкчелегендә социал-демократлар партиясенең татар группасы оешу турында мәгълүматларда да бу ике исемнең янәшә булуы, чыннан да, И. Бикколовның Ф. Әмирхан белән шактый тыгыз, дустанә мөнәсәбәтләрдә булуын дәлилли.

1906 елның 5 маенда Казанда приказчиклар клубында Н. Кямалның «Кызганыч бала» (Г. Камал тәрҗемәсе) һәм «Гыйшык бәласе» (Г. Кәрам тәрҗемәсе) пьесалары куелганнан соң И. Бикколовның «Бөек язучы Фатих Зариф угылы Әмирхан» исемле мәкаләсе басылуы бу фикерне тагын да көчәйтә. Мәкалә авторы спектакльләрдә Ф. Әмирханның баш рольләрне башкаруы хакында яза.

«Фатих Әмирхан турында истәлекләр» китабының төзүчеләр тарафыннан тәкъдим ителгән «Халык хәтерендә» дип аталган кереш сүзендә Ибраһим Бикколовның шәхесен ачуда гаять әһәмиятле булган түбәндәге сүзләр язылган: «“Мөхәммәдия” мәдрәсәсендә бергә укыган дуслары Р. Алуши, В. Бәхтияров, И. Бикколовның тирән эчтәлекле истәлекләрендә әдипнең иҗтимагый эшчәнлеге алгы планга чыгарыла. <...> Сүз уңаенда И. Бикколовның Ф. Әмирханны аеруча якын күрүен әйтергә кирәк. Әдип үлем түшәгендә ятканда ул гел аның янында була, вафатыннан соң җирләү эшендә башлап йөри, калган кулъязмаларын җыештырып, тәртипкә салып куя» [6, б. 13–19]. Бу язма И. Бикколовның татар әдәбияты классигы Ф. Әмирхан тормышында гаять зур урын тотуын, ахыр көненә кадәр дусты һәм фикердәше булуын раслый. Шуның белән бергә, Ф. Әмирхан даирәсе белән дә аралашкан булуы хакында фикер йөртергә мөмкинлек бирә.

Әлеге истәлекләр китабына И. Бикколовның «Бөек язучы Фатих Зариф угылы Әмирхан» һәм «Мәрхүмнең авыруы» дип аталган ике мәкаләсе кертелгән. Мәкаләләрнең беренчесе бу китапка кыскартылып тәкъдим ителүенә карамастан, шактый зур һәм тирән эчтәлекле, яшьлек дусты – Ф. Әмирханның иҗтимагый эшчәнлегенә, аның дөньяга карашларының формалашуында, язучы булып җитлегүендә әһәмиятле урын тоткан мәдрәсә чорына, иҗатына шактый җитди бәя бирә: «Үзенең җитдилеге, үзен мөстәкыйль һәм хөр тотуы белән үзенә һәр дәмдә яшерен бер ихтирам тоттырган Фатихның шәкертләр арасында ихтирамы зур иде. Ул шул вакыттагы шәкерт хәрәкәтенең авторитетлы юлбашчысы булып китә алырлык бер хәлдә иде һәм иҗтимагый, сәяси тәрбиясе ягыннан да шуңар хәзерлекле иде. Шуңар күрә дә бик җиңеллек белән шәкерт хәрәкәтенең башында була алды. Ул шул томан хәлендә булган хәрәкәтләргә билгеле бер тон биреп торды, шәкертләрнең теләкләрен билгеле бер калыпка салды» [7, б. 14–20]. Шунда ук И. Бикколов 1903–1904 елларда Ф. Әмирхан җитәкчелегендә әдәби түгәрәк төзелүе хакында яза һәм үзе дә шушы түгәрәк әгъзасы буларак, шунда катнашучы дуслары Миргазиз Укмасый, Кашшаф Патый, Габдулла Сөләймани (казый), Гарифҗан Мостафа, Муллахмәт Бәдигый, Ибраһим Әмирхан, Вафа Бәхтияр исемнәрен телгә ала.

И. Бикколовның Ф. Әмирханга багышланган икенче мәкаләсе («Мәрхүмнең авыруы») язучының соңгы көннәре хакында бәян итә. «Мәрхүм, үләргә ун-унбиш минут калганчыга кадәр тәмам аңында булып, килгән кешеләрне танып һәм һәркайсы белән берәр сүз генә булса да сөйләшеп ятты. Соңгы өч-дүрт көн эчендә инде үзенең калуына өмиде бетә башлаган, үлемне җиңеллек белән каршы алырга хәзерләнгән иде... Мәрхүмнең күңел сизүе күп ялгышмады, сәгать ун тирәләрендә «Әйдә, киттек, күңелем рәхәтләнсен» сүзләрен әйткәч, озакламады – җан бирде» [8, б. 147–148]. Язучы турында истәлекләрнең беренче басмасында мәкаләнең авторы И. Б. рәвешендә инициаллары белән генә тәкъдим ителсә, икенче басмада автор исеме тулысы белән «Ибраһим Бикколов» рәвешендә бирелә. «Хәбәрче» имзасы белән язылган мәкаләдә мәрхүмне озату мәрасимендә классик язучының тәрҗемәи хәле турында чыгыш ясаучы да дусты И. Бикколов булуы хакында мәгълүмат бирелә[9, б. 151].

Журналистның 1915 елда «Кояш»та басылган «Татарча театр» [10] дип аталган мәкаләсе Ф. Әмирханның яңа пьесасы – «Тигезсезләр»нең беренче тапкыр сәхнәдә куелуына мөнәсәбәтле языла. Мәкалә, бер яктан, әсәргә идея-эстетик кыйммәте ягыннан бәя бирергә омтылыш, икенче яктан бу фикернең сәхнәдә актерлар уены аша тормышка ашырылу дәрәҗәсен бәяләү ягыннан якын килгән булуы белән игъибарга лаеклы. Мәкалә авторы башта шушы вакыйганың халык тарафыннан ничек кабул ителүе – ягъни гасыр башы укучысы-тамашачысының яңа әсәргә, театр куелуга карата фикерен дә ачыклый. И. Бикколов бу мөһим вакыйганы журналистлык төгәллеге белән чагылдыра, замана атмосферасын тудыра, театр сәнгатенең үзенчәлекләрен исәпкә алып, анализ-бәяләмә бирә. Мәкаләнең төп өлешен, әсәрнең сәхнәдә куелышы һәм сәхнә шартларында идея-эстетик мәгънәсенең ачылу дәрәҗәсен бәяләү алып тора. Сәхнәдә яңа куелган әсәрнең геройлары белән таныштыру барышында И. Бикколов аларга автор тарафыннан салынган фикер, персонажларның әсәрдә башкарган рольләре турында мәгълүмат бирү белән бергә, теге яки бу образга үзенең мөнәсәбәтен дә җиткереп бара. Мисалга, төп героиня Рокыяны «...гимназиядә укый, аны өй эчендә дә, өй тышында да һәммәсе яраталар. Ул үзе милләтче, чын-чын татар кызы» дип бәяләсә, студент Габдулла турында «татарларга бик түбән караучы, татардан бер эш тә чыкмаячак, татар милләте бетә торган халык, шуның өчен аңа хезмәт итеп, аны тәрәккый иттерергә тырышу да габис эш дип йөрүче татар Иванушкасы. Ул үзе татарча яза да белми, татарлар арасына да катнашмый, аларның мөхәррирләренә вә әдәбиятларына да бик түбән генә карыйдыр» дип бәя бирә. Шушы геройларга мөнәсәбәтле автор һәм Ф. Әмирханның, һәм үзенең милли идеаллары, татар халкының киләчәге хакында уйланулары белән бүлешә. Рокыя шикелле кызлары булган татар милләтенең киләчәге өметле дигән фикер әсәрнең үзәк фикере булуына басым ясый.

И. Бикколов актерларның уенына да шактый өзлекле, тәфсилле бәя бирә. Мәкалә авторы «Тигезсезләр» шикелле «хәрәкәт вә тирән рухка бай» пьесаларны уйнау бик җиңел эш булмавына басым ясый. «Сәяр» труппасының яңа гына сәхнәдә уйный башлаган яшь артистлары өчен бу спектакльдә уйнау җитди сынау булуын да искәртә. Аерым артистларның гримнары, мимикалары, киемнәре туры килмәү, кайберләренең

артык тупас уйнавы «шундый нәфис вә матур пьесада ... сәхнәнең бөтен гармониясен бозып торды» дип бәяләнә.

Бу мәкаләсендә автор оста журналист буларак кына түгел, тирән белемле әдәбият тәнкыйтьчесе, әдәбият белгече буларак та ачыла.

Русиянең төрле төбәкләрендә яшәгән татарларга милли белем тарату уе белән янып яшәгән бер төркем яшьләр арасында «Мөхәммәдия»не тәмамлаган И. Бикколов та була, ул ерак Себер шәһәрләренең берсе – Томскига мөгаллим булып китә (1906–1913). Ф. Ибраһимова язмасына караганда, Томскида нинди кыенлыклар белән балалар укытуы турында ул Ф. Әмирханга хатлар язып тора. И. Бикколовның журналистлык эшчәнлеге дә шушы елларда башланап китә. 1913–1916 елларда чыгып килгән вакытлы матбугат битләрендә И. Бикколов имзасы белән басылган шактый мәкаләләрне очратырга мөмкин. «Шура», «Мәктәп», «Аң», «Ак юл», «Сөембикә» журналларында аның үз чорының актуаль мәсьәләләрен күтәргән мәкаләләре дөнья күрә; актив журналист буларак И. Бикколов «Әл-Ислах», «Сибирия», «Йолдыз», «Ил» кебек газетәләр белән дә хезмәттәшлек итә. «Әл-Ислах» газите һәм бу вакытлы матбугат басмасында язышкан татар прогрессив эшлеклеләре исемлегендә И. Бикколовны Михаэль Фридерих та телгә ала: «Почти все татарские литераторы и интеллектуалы того времени, проживавшие в Казани, сотрудничали в этой газете. Назовем для примера лишь некоторых – Фатих Амирхан, Галиасгар Камал, Галимджан Ибрагимов, Сагит Рамиев, Кабир Бакир, Миргазиз Укмаси, Ибрагим Биккулов, Султан Рахманкулый, Хусаин Ямашев» [11, б. 41]. Ф. Әмирхан белән берлектә И. Бикколовның «Кояш» газитенең төп хезмәткәре булуы да мәгълүм. Аның исеме бу газетада язышучылар – Г. Тукай, Г. Ибраһимов, С. Сүнчәләй, С. Рәмиевлар белән беррәттән телгә алына.

Шушы заман татар әдәбиятының йөзен билгеләүчеләрдән Г. Тукайга мөнәсәбәтле мәкаләләре шундыйлардан. «Тукай “Әлислах” идарәсендә» [12] дигән истәлегендә аның белән ничек танышуы хакында яза: «Тукай белән «Әл-ислах» идарәсендә таныштым һәм аның белән бик тиз дуслаштык, бергә эшли, бергә яза торган идек».

И. Бикколовның Г. Тукай иҗатына мөнәсәбәтен ачыклау ягыннан караганда шул заманда Томск каласында нәшер ителә башлаган «Сибирия» газитендә дөнья күргән «Габдулла әфәнде Тукаев» [13] мәкаләсе игътибарга лаеклы. Тукай вафаты хакындагы авыр хәбәрне И. Бикколов Томскта ишетә. Берничә ел Себер якларында мөгаллимлек иткән татар интеллигенты, журналист, әлбәттә, Тукай үлеме белән бергә татар әдәбиятының зур югалтуы хакында язмый кала алмый. Мәкалә, беренче чиратта, дустанә интонация, рухи якынлык белән язылган булу ягыннан игътибарны җәлеп итә. (Газитнең бу санында мәкалә белән бергә шагыйрьнең фоторәсеме дә бирелә) Мәкалә авторының Г. Тукайга мөнәсәбәте, аның вафатын иң якын кешесен югалткан кебек кабул итүе, шагыйрьнең үз иҗаты кебек бер үк вакытта гади һәм тирән әрнү белән язылган булуы беренче юлларыннан ук аңлашыла. Мәкалә бөтен татар халкы исеменнән язылa: «Башыбызга бәхетсезлек килә генә тора, бер кайгыны онытырга өлгермибез, аңардан куркынычрак вә аңардан да күңелсезрәк булганнары килеп торадыр. Тәкъдир бер кешегә яки бер халыкка каһәрен салса, сала да сала гына, аны изгәннән изә генә бара.

Менә иң талантлы шагыйребезне, иң беренче әдибебезне дә югалттык. Габдулла Тукаев – бу зат бит һәрбер татарның иң сөйгәне вә иң якын күргәне бер зат иде. ... Менә явыз тәкъдир шушы бөтен милләтнең чын күңеле илә сөеп тоткан иң кадерле бер кешесен күзен дә йоммыйча алды да китте. Яшь кенә сабый хәлендә булган татар әдәбияты вә татар теленең бик яшьли үксез калам бит, диеп елавына да илтифат итмәде, миллионнарча рухларның гали татар поэзиясе илә гыйзаланудан[1] мәхрүм калуларына да игътибар итмәде. Аларны акыртып-бакыртып үксез итеп калдырды».

И. Бикколов бу мәкаләсендә замандашы, иҗатташы, күңеленә, рухына якын булган шагыйрь иҗатының бөтен татар дөньясы өчен кыйммәтле, якын булуын, аның мәңге укылып туймаслык «Печән базары», «Шүрәле», «Бәйрәм бүген» кебек әсәрләре халык хәтерендә саклануын яза. Мәкаләдә авторның Г. Тукай шәхесенә мөнәсәбәте, аның татар әдәбиятында тоткан урынына югары бәясе чагылыш таба. «Габдулла әфәнденең болай безне иртә ташлавы, аңарда киләчәктә бик зур өметләрнең булуы бу матәмне

---

[1] Гыйзалану – ризыклану, туклану.

безгә ике өлеш авыр итәдер. Ул әле бик яшь, аңарда киләчәктә бик зур өметләр бар иде. Хосусан, Габдулла әфәндинең рухындагы еш алышынулар һәм бу алышынуларның көннән-көн Габдулла әфәндедә шигърият куәтенең арта баруына хезмәт итүе бу өметләрне куәтлидер иде». Шул заман вакытлы матбугатында лейтмотив буларак яңгыраган «бик яшьли дөньядан китсә дә, шагыйрьнең исеме татар халкының күңелендә мәңге сакланачак» фикер И. Бикколов мәкаләсенең дә төп аһәне тәшкил итә.

Мәкаләсен йомгаклап, автор түбәндәгеләрне яза: «Хәзер безгә Габдулла әфәндинең Толстой хакында әйтдеке «Тәсбих өзелде» сүзләрен тәкърарлап, Гаяз, Әмирхан, Сәгыйтьләр вә Гафурилар кебек мөхтәрәм затларыбыздан төзелгән тәсбих өзелде, шушы тәсбихнең иң кыйммәтле бер төймәсе дә җиргә төшеп югалды, мәңге табылмаска югалды, диеп тәкъдирнең бу каты золымына баш кына ияргә калды».

Бу мәкалә И. Бикколовны заман сулышын, әдәби хәрәкәтне нечкә тойган, талымлы, белемле журналист һәм тәнкыйтьче буларак таныта. Матбугат битләрендә И. Бикколовның атаклы шәхесләребез Исмәгыйль Гаспралы, Шиһабеддин Мәрҗаниләр эшчәнлеге, гомумән, гасыр башы татар әдәби хәрәкәте, вакытлы матбугат торышы, илдәге сәяси һәм икътисадый тормыш хакында саллы, гомумиләштерү характерындагы мәкаләләре дөнья күрә. «Петербургта мөселман съезды» [14, б. 250–252], «Гомумауропа сугыш алдында» [15, б. 267–268], «Бөтен дөнья сугыш алдында» [16, б. 285–286] мәкаләләрендә авторның шушы вакыйгага мөнәсәбәте чагылыш таба. И. Бикколовның аналитик характердагы, вакытлы матбугатның ел нәтиҗәләре буларак тәкъдим ителгән «Үткән 1914 ел» [17, б. 19–24.], «Үткән 1915 ел» [18, б. 51–54] мәкаләләрен күрсәтергә мөмкин.

Шул рәвешле, алдынгы карашлы рухани гаиләсеннән чыгып, ике гасыр арасы кебек катлаулы чорда үз юлын укытучы эшеннән тыш, журналист, публицист буларак билгеләгән, шушы юнәлештә шактый күләмле хезмәтләр калдырган Ибраһим Бикколовның XX гасыр башы татар милли хәрәкәтендә, иҗтимагый тормышында, вакытлы матбугат үсешендә тоткан урыны гаять зур, әһәмиятле. Бу юнәлештәге башкарган эшебез төгәлләнгән булуга дәгъва итми. Исеме үз заманы татар җәмәгатьчелегенә шактый киң мәгълүм булган укытучы, шул заман әдәби барышының асылын тәшкил иткән әдипләр белән бергә кулына каләм алган, соңрак шәхес культы корбаны булган И. Бикколовның әлеге чор вакытлы матбугаты битләрендә дөнья күргән публицистик мирасын барлау, аны замана әдәби торышы кысаларында тәфсилләп өйрәнү, һичшиксез, дәвам иттерелергә тиеш.

ӘДӘБИЯТ


1. Ибраһимов Г. Яңа имзалар вә яшь куәтләр // Йолдыз. 1915. 29 апрель.
2. Ибраһимова Ф. Тарих сәхифәләрендә – татар шәхесләре. Ибраһим Бикколов // Казан утлары. 1994. № 6. Б. 188.
3. Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 283.
4. Фәхреддин Р. Асар. Казан: Рухият, 2010. Б. 136.
5. Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. 3 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. Б. 554.
6. Фатих Әмирхан турында истәлекләр / төз. Ф. Ибраһимова, Р. Әмирхан (тулыланд. икенче басма). Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. Б. 13–19.
7. Бикколов И. Бөек язучы Фатих Зариф угылы Әмирхан // Фатих Әмирхан турында истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. Б. 14-20.
8. Бикколов И. Мәрхүмнең авыруы // Фатих Әмирхан турында истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. Б. 147–148.
9. Хәбәрче. Фатих Әмирханны соңгы юлга озату // Фатих Әмирхан турында истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. Б. 151.
10. Татарча театр // Кояш. 1915. № 627. 11 февраль.
11. Фридерих М. Габдулла Тукай как объект идеологической борьбы. Казань: Татар. кн. изд-во, 2011. Б. 41.
12. Бикколов И. Тукай «Әл-Ислах» идарәсендә // Ак юл. 1914. 2 апрель.
13. Бикколов И. Габдулла әфәнде Тукаев // Сибирия. 1913. 7 апрель (№ 96).
14. Петербургта мөселман съезды // Аң. 1914. № 13. Б. 250–252.
15. Гомумауропа сугыш алдында // Аң. 1914. № 14. Б. 267–268.
16. Бөтен дөнья сугыш алдында // Аң. 1914. № 15. Б. 285–286.
17. Үткән 1914 ел // Аң. 1915. № 1. Б. 19–24.
18. Үткән 1915 ел // Аң. 1916. № 3. Б. 51–54.

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ПОЭЗИЯСЕНДӘ АЛЛЮЗИЯ

***Сәлахетдинова З.Ф., Миргалимова З.Ф.***

Аллюзия в творчестве Г. Тукая еще не была объектом специального исследования. Данная статья посвящена исследованию аллюзии в его поэзии. В работе определяется статус термина аллюзия и выявляются ее стилистические функции и особенности как выразительное языковое средство на богатом фактологическом материале.

The allusion in the works of G. Tukay has not yet been the object of special study. This article is a study of the allusions in his poetry. In the work is determined by the status of the term allusion and identify its stylistic functions and features as expressive language feature on a rich factual material.

Гасырдан артык өйрәнү дәверендә Тукай иҗатының барлык жанр, тематик һәм проблематик тарафлары әдәбият фәне күзлегеннән карап чыгылган, тикшерелгән, анализланган һәм гомумиләштерелгән. Шушы иҗатны төрле яклап яктырту өчен күпме диссертация, монография, күмәк җыентык һәм мәкалә язылган һәм языла тора.

Бөек сәнгатькәрләр иҗаты – гомумән, мәңгелек тикшеренү объекты. Чөнки тормыш алга бара, җәмгыятьнең белеме камилләшә һәм ихтыяҗлары үсә, фән дә яңара һәм үсә тора. Яңа шартлар яңа таләпләр куя. Тукай иҗатын яңача укып карау бигрәк тә үткен актуальлеккә ия. Чөнки ул әдәби тел яңарышының бөтен ашкын процессын үзендә чагылдырган, шушы кыска гына үсеш дәверендә урта гасырчыл традицион әдәби телдән яңа чор әдәби теленә күчешне теркәп калдырган, аның каршылыкларын гәүдәләндереп, ниһаять, халыкка аңлаешлы рәвешкә китереп калыпландыруда хәлиткеч рольне дә үзе уйнаган. Шунлыктан Тукай шигырен төшенү дигән мәсьәлә һич тә эш юктан уйлап табылган шөгыль түгел. Димәк, тикшеренүче каршында һәрдаим Тукай иҗатына төшенү зарурлыгы тора. Икенчедән, без өр-яңа иҗтимагый-идеологик шарларда яшибез. Тикшеренүче алдында идеологик басым һәм сәяси цензура тормавы әдәби күренешләрне объектив яктыртырга мөмкинлек бирә. Тарихи контекстны истә тотып тикшергәндә, Тукай иҗатының күп кенә яклары ачылып бетмәгән килеш кала бирә.

Мәгълүм булганча, төрки-татар әдәбиятының озын тарихы бар. Аның зур өлешен, ягъни якынча XIX йөзгә кадәрге чорын Урта гасыр әдәбияты тәшкил итә. Бу чорда әдәбиятыбызның ислам, фарсы дөньясы һәм гомумән, Шәрык, рус һәм Аурупа әдәбиятлары белән бәйләнеше көчле була. Ә соң бу дәвернең рухи, барыннан да элек язма әдәби мирасы белән, Шәрыктән килә торган традицияләр, рус һәм Аурупа әдәбияты белән Тукай нинди мөнәсәбәттә? Бу сорауга инде фәндә, Х.Г. Госман, Р.К. Ганиева, Ш.Ш. Абилов, Н.Ш. Хисамов, Х.Й. Миңнегулов, Н. Исмәгыйлев һәм кайбер башка галимнәрнең мәкалә-хезмәтләрендә теге яки бу күләмдә җаваплар бар. Әмма, безнең карашча, Тукайның башка әдәбият белән багланыш мәсьәләсе, шагыйрьнең алардан теге яки бу күләмдә файдалану юнәлешендә эшләү кирәк. Чөнки күп гасырлык татар әдәбияты Урта гасыр әдәбияты белән, Шәрык, Рус һәм Аурупа дөньясы белән тыгыз бәйләнештә яшәгән һәм яши. Хезмәтебезнең актуальлеге шуның белән аңлатыла. Максатыбыз – Габдулла Тукай иҗатында кулланылган аллюзияләрне барлау һәм тикшерү.

Аллюзия (латыйнча *allusio* – шаяру, ишарә) – өземтә китерүнең бер төре, киная ярдәмендә автор тексты һәм чыганак-текст арасында элемтә урнаштыру [1, б. 19]. Аллюзия турында башка әдәбият белемендә мондыйрак билгеләмәләр яшәп килә: Аллюзия – сөйләмдә яки язмада нindидер мәгълүм шәхескә, вакыйгага, ситуациягә ишарәләү [2, б. 5]. Аллюзия – теге яки бу әдәбият яки сәнгать әсәренә, шәхескә яки вакыйгага киная ясау [3, б. 25].

Компаративистикада аллюзия әдәбиятара рецепциянең бер формасы: «башлыча, дөнья әдәбияты корифейлары иҗатында кулланылган билгеле бер әдәби алымга, мотивка, идеягә мөрәҗәгать итү» кебек билгеләнә. Шулай ук аллюзия менталь-типологик охшашлык күренеше итеп каралырга мөмкин. Әдәбиятара аллюзияләр, гадәттә, бер милли әдәби иҗат системасына икенче бер милли әдәбият өчен әһәмиятле күренеш булган «ачкыч» текстларны урнаштыра. Шул ук вакытта чит әдәби материалны үзләштерү һәрчак аның нindидер универсаль семантик комплекс хәленә килүен таләп итә. Ул укучы тарафыннан чыганакның идея-эстетик үзенчәлегенә карап кына түгел, бәлки, аерым бер милли традициягә йөз тотудан килеп чыккан гомуми мәгънәви

сыйфатлар берлеге кебек тә кабул ителә. Әйтерсең аллюзия әдәби текстның һәм үзе формалашкан тарихи-мәдәни система тибының (милли, зональ, региональ) үзенчәлекле сыйфатларын үзенә туплый һәм көчле эстетик киеренкелеккә, мәгънәви тирәнлеккә, эмоциональ тәэсирлелеккә ия була. «Чит сүзне» кабул итү принциплары аллюзияләрне төркемләүдә үк бик ачык күренә.

Әдәбиятта метафорик һәм метонимик аллюзияләр аерып карала. Беренче очракта кем тарафыннандыр кабатланган тексттан өзекләр китерелә, икенчесендә автор, чит текстка яки аның өзегенә ишарә ясаганда, аның тирәсендәге элементларны да күздә тота. Аерым бер төркем булып номинатив аллюзияләр аерылып чыга: персонажның, әсәрнең, авторның төрле ассоциацияләр уятырлык, язучының биографиясе һәм иҗаты белән бәйле исеме – шундыйлардан. Алар элгәрге текстка карата «метонимик алмаштыручы символ» вазифасын башкара. Аллюзияләрне текстара мөнәсәбәтләрнең төрләренә карап та төркемләргә мөмкин. Интертекстуаль аллюзияләр – чыганакны яки авторны турыдан-туры күрсәтү, аерым бер укучылар даирәсендә мәгълүм өзекләр китерү, парафраза (элгәрге әдәби чыганак темасын композицион бәйләнешләрне саклап һәм аерым бер элементларны алыштырып куллану); гипертекстуаль аллюзияләр – пародия, персонажларны сурәтләүче сатирик алымнар һ.б.; паратекстуаль аллюзияләр – текст эчендә аерым бер элементларны тоташтыру: исемдә, эпиграфта аллюзияләр һәм башкаларны аерып чыгара. Галимнең фикерләү логикасын дәвам иткәндә, архитекстуаль, ягъни нинди дә булса традициягә, жанрлык хасиятенә кагылучы аллюзияләрне аерып чыгарырга була.

Аллюзия ярдәмендә тормышка ашырыла торган әдәбиятара бәйләнешләрнең эчке логикасы, әсәрләрнең төр һәм жанрына карап, үзенчәлекле чагылыш таба.

XX йөз башы татар әдәбиятында тизләтелгән үсешнең куәтле факторы булып Көнчыгыш-Көнбатыш синтезы тора [8, б. 273]. Бу процесста Шәрыктән килә торган традиция төп нигезне, үзәк чишмәне тәшкил итә. Күпгасырлык татар классик шигърияте дә шул ук мәдәни төргә, шул ук культура даирәсенә керә.

Аңарчы тулысынча шәркый традицияләр эчендә үскән татар шигърияте, үзенең борынгы нигезен һәм тамырларын нык саклаган хәлдә, Аурупа әдәбиятына, аның фәлсәфи-эстетик һәм иҗтимагый фикер мәктәбенә йөз белән борыла [8, б. 273]. Бу күренеш шул чор шигъриятенең барлык күренекле вәкилләрендә дә, иң беренче нәүбәттә Тукайда күзәтелә [8, б. 268].

Шәрык, Рус һәм Аурупа әдәбияты һәм Тукай, төрки-татар сүз сәнгате. Бу төшенчәләр бер-берсенә шактый нык керешкән. «Мондый якынлыкның бер өлеше типологик яисә генетик-типологик характерда, икенчесе – үзара тәэсир, күчеш, алыну нәтиҗәсе» [4, б. 40], – дип ассызыклыклый әдәбият галиме Х.Й. Миңнегулов. Димәк, иң беренче чиратта, нәкъ менә Тукай иҗатында төрки-татар, Шәрык, рус һәм Аурупа әдәбиятыннан алынган әдәби үрнәкләрне, аларга охшаш мотивларны, ягъни аллюзияләрне табарга мөмкин.

Тукай татарның элек-электән укылган, балачактан ук хәтеренә сеңгән борынгы классик әдәбиятына еш мөрәҗәгать итә [5, б. 14–15]. «Кыйссаи Йосыф», Рабгузыйның «Кыйссаи-әнбия»се, Хуҗа Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакырганый, Суфый Аллаһыяр шигырьләре һәм бигрәк тә «Мөхәммәдия», «Бакырган»нан алынган аллюзияләр Тукайда еш очрый. Шагыйрь һәммә татарга таныш, сөеп укылган шигырьләрнең аерым сүзләрен, өзекләрен алып үз чоры кешеләрен, тормыш картиналарын, заман проблемаларын бөтенләй көтелмәгәнчә ачып бирә. Күп вакытта ул борынгы җитди шигырьдән бөтенләй киресен – я бер көлке, я бер ачы сатира китереп чыгара. Болар гади пародия генә түгел. Менә «Һәзиһи касыйдәтүн фи мәдхи Мостафа» («Бу – Мостафаны мактау шигыре») дигән сатирасында ул XIV йөз шагыйре Рабгузыйның «Пәйгамбәрләр тарихы»ндагы Мөхәммәд пәйгамбәрне мактауга багышланган шигыреннән аллюзияләр китерә, аны үз заманындагы мәгълүм шәхескә – әзәрбәйҗанлы Мостафа Лотфый Ширванскигә багышлый, мәдхия урынына мыскыллау шигыре килеп чыга. Рабгузыйда ул:

Дин, шәригать рәйәтене гали кылган Мостафа,
Көфер, золмәт туларыны җиргә салган Мостафа!
Каумена дин күрсәтмичә күккә ашкан –
Гайсә ул, Өммәтенә булышубән җирдә калган Мостафа!

Габдулла Тукайда исә бу юллар икенче төрле, түбәндә китерелгәнчә яңгырый:

Төркиядә бер теләнче сухтә булган Мостафа;
Монда кайтып, ил казасы, фетнә булган Мостафа.
Юп-юан, муйнын бөгеп йөргән сарыклы бер сарык, –
Монда кайткачтын симергән, чучка булган Мостафа.

*Монда: рәйәт* – байрак, *гали кылган* – биеккә күтәргән, *ту* – байрак, әләм, *сухтә* – мескен.

Рабгузыйдагы Мостафа (Мөхәммәд пәйгамбәр) белән Тукайдагы Мостафа арасында шундый зур аерма булуына карамастан, бу гиперболик аерма, гротеск, ирексездән, укучыда көлке тойгысы, мыскыл, хәзерге заман Мостафасына нәфрәт уята.

Татарда бик популяр булган «Мөхәммәдия» китабын да Тукай еш файдаланган. XV гасырда төрек телендә шигырь белән язылган зур күләмле бу әсәр, элеккеге кадими мәктәпләрнең программаларына кертелеп, аерым алганда, кызлар өчен дәреслек вазифасын башкарган. «Шул заманда бу китапны укып яки тыңлап, еламый калган хатын-кызлар, карчыклар сирәк булгандыр» [8, б. 273], – дип яза атаклы әдәбият тарихчысы Г. Рәхим. Тукай «Ысуле кадимче»дә «Мөхәммәдия» китабының кереш өлешеннән автор Мөхәммәд Чәләбинең үзе турында язган гаять җитди юлларын алып, шул ук шәкелне, шул ук сүзләрне бөтенләй икенче якка борып, һич көтелмәгән урынны – трактирны, сыра эчеп, мәлҗеп утыручы татарны сурәтләгәндә куллана. «Мөхәммәдия»дәге шигырь юллары түбәндә китерелгәнчә яңгырый:

Мәгәр көннәрдән бер көн әмре тәкъдир
Утырмышдем Кәлибүлидә сирра.
Әлеме чикмешдем җөмлә халыктан.
Телемдә зикер иде, кальбемдә зикра.
Кәлибүлинең ул гашыйкларындин
Тезелделәр килеп катыма торра...

Монда: *әмре тәкъдир* – язмышның кушуы буенча, *сирра* – яшеренеп, *әлеме* – кулымны.

«Ысуле кадимче»дә исә Тукай шул ук шәкелне, шул ук сүзләрне бөтенләй икенче якка борып җибәрә:

Мәгәр көннәрдән бер көн, әмре трахтир,
Утырмыштым ки бер пивнойда сирра.
Кулымны селтәдем фани җиһаннан,
Агызда папирос, алдымда сырра.
Трахтирларның ул гашыйкларыннан
Тезелделәр килеп катыма торра [6, б. 241].

Шулай итеп, күренешне бөтенләй икенче заманга, икенче урынга күчереп, «Мөхәммәдия»гә ишарәләгән аллюзияләр аша Тукай һәркемне елмаерга мәҗбүр итәрлек мәзәк эффект тудыра.

Шагыйрь бигрәк тә «Бакырган» китабындагы әсәрләрне яратып файдалана. Ни өчен дигәндә, «Бакырган» китабы халыкчан телдә, гади, самими, шул ук вакытта гаҗәеп тәэсирле язылган. Шуңа да ул киң таралган, укылган, ә Тукай исә аның яратып укылуыннан үзенчә файдалана. «Бакырган»да шундый шигырь юллары бар:

Нә кылырсың, мескен адәм.
Тотса Газраил якаң?
Ничек җавап бирерсең –
Тотса Газраил якаң?!

Тукай исә XII гасырдагы «Бакырган»ны XX йөз башына алып керә, «Тотса мәскәүләр якаң» шигырен шул рефренга кора:

Ни кылырсың, хаҗи абзам, тотса мәскәүләр якаң?
Как ты будешь отвечать там, тотса мәскәүләр якаң?
Сыгмас ирдең киң җиһанга, малыңа мәгърур булып:
Даже в тюрьму сыярсың, тотса мәскәүләр якаң [6, б. 240]?

Безнең чор кешесе «Бакырган»ны белми диярлек, әмма Тукайның «Тотса мәскәүләр якаң» гыйбарәсе канатлы сүзгә, әйтемгә әверелеп, бүген дә киң кулланышта йөри; ни өчен дигәндә, Мәскәүнең каты кулы әле дә якадан җибәрми...

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә кирәк: Тукайның иҗаты борынгы әдәби мирастан һич аерылгысыз. Шагыйрь халыкның элек-электән укылган: «Кыйссаи Йосыф»,

Рабгузыйның «Кыйссаи-әнбия»се, Хуҗа Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакырганый, Суфый Аллаһыяр шигырьләренә һәм бигрәк тә «Мөхәммәдия», «Бакырган»нга ишарәләгән вакыйга, сюжетларга мөрәҗәгать итә. Бигрәк тә халык арасында бик тә яратып укылган «Мөхәммәдия» китабына кинаяләнгән аллюзияләрне Тукай иҗатында күрергә мөмкин. Шулай ук шагыйрьнең «Бакырган»га таянганлыгы да иҗатында сиземләнә.

Тукай шигъриятендә Шәрыктән килгән традицион аллюзияләрнең семантик потенциалы киңрәк ачыла. Аларның иң күбесе Мөселман Көнчыгышының дөньяга карашын, яшәүгә, әхлакка мөнәсәбәтен билгеләгән ислам дине төшенчәләреннән тора. Иң беренче урында, әлбәттә, илаһиятне гәүдәләндергән төшенчәләр: Алла, Коръән төшенчәләре кулланыла. Аннары фәрештәләр, пәйгамбәрләр килә.

«Коръән» – Шәрык, төгәлрәк әйткәндә, гарәп сүз сәнгатенең бөек ядкәре, мөселман дөньясының рухи кыйбласы. Ул үзендәге байлык, хәзинә белән әдипләрне даими азыкландырып килгән һәм килә. Шулай ук Урта гасыр әдәбиятының башка бик күп ядкәрләре теге яки бу дәрәҗәдә «Коръән» белән бәйләнешле. Тукай да бу изге китапны камил белгән, аны үзенең рухи таянычы, маякчысы рәвешендә караган.

Гомернең иң читен, җайсыз, уңайсыз бер минутында,
Әгәр янсам каты хәсрәт вә кайгының мин утында.
Укыйм тиз-тиз күңелдән бер гаҗаиб сүрә Коръәннән,
Газаплар мәгънәви бер кул илән алынадыр җаннанн.
Оча дилдән бөтен шик-шөбиәләр, һәм мин җырлый башлыйм:
Яңакларны мөкаддәс күз яшемлә энҗели башлыйм.
Бөтенләй сафлана күңлем, укыйм иман, булам мөэмин;
Килә рәхәт җиңеллекләр: хәлас булам авыр йөкдин.
Ходайа! син тыйган эшләр тәмам экътакъ вә әбтә, дим;
Иям баш сәҗдәгә: «Аллаһехак! Аллаһеәкбәр!» – дим [6, б. 208].

Бу юллар – шагыйрьнең 1908 елда иҗат ителгән «Тәэсир» («Тәәссер») шигыреннән. Аллюзия чыганагы буларак Тукай «Коръән»дәге идея-мотивларны, образ-сурәтләрне турыдан-туры да, башка әсәрләр аркылы да кулланган.

Тормышның кызу казанында кайнаган, иҗтимагый һәм фикер көрәшенең үзәгендә хәрәкәт иткән шагыйрь өчен XX йөз башының трагик коллизияләрен йөрәгә аша уздырганда, дини әдәбиятның негатив символлары – Иблис, шайтан сурәте калкып чыга. Алар үзләренең табигый контекстында кулланылу белән бергә, бөтенләй көтелмәгән, парадоксаль контекст та хасил итә, үз чиратында метафорик аллюзия туа. Менә Тукай лирикасының җитлегеп кристаллашкан дәвереннән бер үрнәк.

Туйса Иблис тормышыннан, яд итә оҗмахларын, –
Яд итәм, бизсәм үземнән, мин сабыйлык чакларын.
И күңелнең шаулап аккан чишмәдән сафрак чагы!
И гомернең нурланып үскән яшел яфрак чагы!
Чәчмәгән җир күк – күңелнең һәр гүзәлгә бушлыгы,
Тик кояшны һәм табигатьне сөюдән хушлыгы! [7, б. 224]

Бу шигырьдә ассоциатив аллюзия рәвешендә алынган Иблис һәм тормыш авырлыклары, борчулар һәм гөнаһ баскан лирик каһарман шәхесе – аның ваемсыз, саф балачагына параллель итеп гөнаһ һәм вәсвәсә гәүдәләнеш ала. Дөресрәге, шагыйрьнең, лирик каһарманның халәте шушы модель, шушы сурәт нигезендә ачыла.

Әдәбиятка ислам аша кергән төшенчәләр шагыйрьнең мәхәббәт лирикасында киң урын ала. Мәсәлән, гашыйк кешенең сөеклесе каршындагы халәтен ул намазга оеган гыйбадәтче рәвешендә сынландыра. Әйтик, әле генә уен-көлке сөйләп утырган гашыйк каршына җанашы керә һәм егет шундук җитдиләнә, үзгәрә:

Нишләсен, җанаш хозурында аңар лазем намаз;
Бер азан әйткәч, колак каккач, мөселман уйнамас [7, б. 41].

Тукайның мәхәббәт шигырьләрендә сөеклесенең сурәте иң изге биеклеккә күтәрелә. Чагыштырулар да дини тәкъвалык күзлегеннән гафу ителгесез күренерлек тәвәккәлләр. Шагыйрьнең бу өлкәдә кыюлыгы шул дәрәҗәгә барып җитә ки, ул «Коръән»дәге «ля шәркыя, ля гарбия» (Шәрекътә дә, Гаребтә дә юк) гыйбарәсен сөеклесенә мәдхия, дип шәрехли, һәм аллюзия итеп файдалана:

Күргәнең бармы әле Коръәндәге мәдхияңи?
Ул синең васфеңдә: «ля шәркыя, ля гарбия», – ди [6, б. 226]

Мәхәббәт – гомумән, Тукай өчен илаһи хис. Ул аның чыганакларын, урынын гел күктән эзли. «Йолдыз ул күктән атылган җиргә, Генрих Гейнәчә!» [7, б. 241], – ди «Мәххәбәт шәрхе» шигырендә. Эйе, Генрих Гейне шигъриятенең рухын, аңардагы «мәхәббәт шәрхен» Тукай дөрес төшенгән. Шагыйрьнең лирик сурәтләре, чагыштыру һәм метафораларының илаһи төшенчәләр даирәсеннән алынуы әлеге хискә әнә шушындый карашыннан килеп чыга. Аның яшьлек шигырьләре арасында «Дәрдемәнд дәгелмием?» дигән камил бер әсәре бар. Анда мондый юлларны укыйбыз:

Тәңре гьйшкында шәһадәт итсәләр дәр Гәрбәла,
Бән шәһидем дәр мәхәббәт, дәр бәлаем, нәйләем?

(Әгәр Гәрбәлә тәңре гыйшкында булсалар шәһит,
Мин мәхәббәт-бәла юлында шәһитмен, ни эшлим?) [6, б. 82–83]!

Гәрбәла – Гыйрактагы бер шәһәр. Анда өмәвиләр кулыннан хәзрәте Галинең уллары – Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныклары Хәсән-Хөсәен һәлак булалар. Шигыйләр анда хаҗга йөри. Тукай мәхәббәт юлында корбанга әзерлеген менә шушы шәһитләр язмышына һәм ихтыярына тиңли. Шул рәвешчә, ислам тарихы фактлары аның шигъри фикерләвендә югары әхлакый-эстетик кыйммәткә ия чагыштыруга, мәгълүм дәрәҗәдә шигъри аллюзия элементына әверелә.

Тукай мирасында Шәрыкның «Кәлилә вә Димнә», «1001 кичә», «1001 көн» кебек бөек ядкәрләренә мөнәсәбәтле, Гаттар, Румый, Низами, Сәгъди, Мәгарри иҗатларына бәйләнешле күренешләрне дә очратырга мөмкин. «Туган тел» авторы тәрҗемә иткән мәсәлләрнең шактые, мәсәлән, «Кәлилә вә Димнә»гә барып тоташа. Тукайның Толстойга нисбәт ителгән *«Кирәк анчак яшәр микъдар ашарга, Кирәкми тик ашарга дип яшәргә»* [7, б. 272] дигән юлларындагы фикер Сәгъди, Сараи һәм башка авторларның әсәрләрендә очрый.

Югарыда әйтелгәннәргә нәтиҗә ясап шуны әйтергә кирәк: Тукай иҗатында шәркый аллюзияләр шактый. Алар нигездә дини мотивта, гуманизм идеяләре белән язылган һәм мәхәббәт турындагы шигырьләрендә мул кулланылган.

Рус һәм Аурупа шигъриятеннән кызыклы тәрҗемәләрдән башлап, тәкълид (тәрҗемә) рәвешендә барлыкка килгән әсәрләр һәм мәгълүм мотивлардагы аваздашлык Аурупа шигъри традицияләренең Тукай поэзиясендә көчле кайтаваз таба баруын күрсәтә. Әлеге процессның ике тенденциясе игътибарга лаек. Беренчесе – Аурупа дөньясына аваздашрак тема һәм мотивларны сайлап алу булса, икенчесе – шушы шигърият тәэсирендә үз шигъри аһәңнәрен баету һәм әкрен-әкрен үзгәртеп кору. Тукайда шундый аллюзион күренешләрнең куәтле булуын күрергә мөмкин.

Шагыйрьнең «Байроннан», «Гетедән», «Шиллердән», «Шекспирдән», яки «Пушкиннән», «Лермонтовтан» дип куйган искәрмәле шигырьләрендә доминант аллюзияләр шигырьләренең исемендә үк чагыла һәм лейтмотивны ачуда катнаша.

Искәрмә рәвешендә әүвәл шуны әйтергә кирәк ки, русчадан, башка әдәбияттан аллюзияләр алу өчен дә бу телне һәм шул шагыйрьләрне яхшы белү зарур. Тукайның Уральскида, шәһәрдә алган белеме, һичшиксез, бу юлда җитди таяныч булган дип әйтә алабыз.

Шагыйрьнең «Пушкиннән» дип куйган 1906 нчы елгы бер шигырендә Шәрык татар шартлары өчен күпмедер дәрәҗәдә актуаль яңгырашлы күпхатынлылыкныгаепләү фикере уздырыла. Лирик шагыйрь шундый язмышлы яшь хатынга теләктәшлек белән мөрәҗәгать итә. Пушкин шигырендәгечә, аңа, фонтанга барып, су чәчрәтеп уйнарга куша, әмма агымсуга карап, гомернең дә тиз һәм әрәмгә үтәчәген киңәш итә.

XX йөз башы татар шагыйрьләре арасында Тукайның Аурупа шагыйрьләреннән сайлаган әсәрләре башлыча шуның белән аерыла ки, аларның үзәгендә җәмгыять белән шәхес арасындагы тирән конфликт һәм азатлык мотивы ята. Ул Пушкинның «Узник» шигырен аллюзион рәвештә файдаланып, «Мәхбүс» шигырен иҗат итә. Төп мотивларны Пушкиндагыча саклый: тоткын һәм хөр бөркет мисалында сүрелмәс азатлык омтылышы чагыла. Шагыйрь һәр күренешне детальләп җәя, ягъни шәрехли.

Лермонтовның «Пророк» шигырендәге җәмгыять һәм шәхес, томана һәм консерватив тирәлек белән гали, игелекле җан – шагыйрь конфликты шул нигездә эшләнгән «Пәйгамбәр» әсәрендә аеруча кискенлек белән гәүдәләнгән.

Шулай ук Тукай Лермонтовта гомумиләштереп бирелгән деталь һәм мотивларны җәя төшә, әсәрләрендәге фаҗига төсмерен көчәйтә. Картлар, бармак төртеп, балаларга пәйгамбәрне тасвирлыйлар:

Күрәмсез, нинди беткән һәм арыкланган, фәкыйрьләнгән,
Зәгыйфьләнгән, таланган, өсте-башы нинди керләнгән [7, б. 14].

Тукайның: *«Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым»* [7, б. 270]; *«Син үзеңчә изге эш эшлим дигәндә кыңа, әллә нинди былчырак баулар салалар гакълыңа»* [7, б. 222], *«Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы»* [7, б. 150] дигән юллары «Пәйгамбәр» каһарманының халәтенә бик нык авазлашлар.

Аурупа шагыйрьләренә аллюзияләр Тукайның «Мәхәббәт» шигырендә аеруча үзенчәлекле чагылыш таба. Кешелекнең шушы бөек хисен татыганда аның күз алдына Аурупаның иң мәшһүр шагыйрьләре баса:

Бер гүзәлдән кайсы шагыйрь, әйтеңез, рухланмаган?
Байронның, Лермонтовныңмы, Пушкиныңмы – кайсысы [6, б. 257]?

Һенрих Һейне иҗаты XX йөз башы татар шагыйрьләренең зиһенен шактый нык биләгән. Тукайга исә Һәйненең мәхәббәтне гали хис буларак данлавы якын:

Мин: «Мәхәббәтсез», – дидем, ләкин мәхәббәт төрлечә:
Йолдыз ул күктән атылган җиргә. Генрих Гейнечә [б. 241].

Тукай үзенең шигъри фикерләвендә Аурупа мохитенә, Аурупа реалийларына керә бара. Мәсәлән, татарның милли уянышын сәламләгән «Тартар кошы сайрый» дигән шигырендә шундый юлларны укыйбыз:

Сайрасын былбылларың.
Чалынсын сазлар, татар.
Чыксын шәмсең, эрсен кар.
Шалтырап аксын ермаклар:
Ятмасын мәңге, җитәр –
Мисле сәлеҗ Сангатар [б. 144].

«Сен-Готард, ягъни Альп тавындагы кар кебек» дигәнне аңлата. Чорының иҗтимагый шартлары Тукайны Аурупага тарта. Буржуаз мөнәсәбәтләрдән ризасыз романтик Рус һәм Аурупа әдипләре – Пушкин, Лермонтов, Байрон, Һейне һ.б. шагыйрьләр аңа якын.

Шулай итеп, рус һәм Аурупа дөньясы белән аллюзион авазлашлык, тема һәм мотивлар берлеге Тукайның «Байроннан», «Гетедән», «Шиллердән», «Шекспирдән», «Пушкиннән», «Лермонтовтан» шигырьләрендә чагылыш таба. Бу шигырьләрнең исемнәре үк аллюзия тудыруда катнаша.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә кирәк: Тукай иҗатында кулланылган аллюзияләрнең (нindидер әсәргә, шәхескә яки вакыйгага ишарәләү, киная) идея-эстетик кыйммәтен билгеләгәндә шагыйрьне формалаштырган, шәхесенә тирән йогынты ясаган сәбәпләр турында фикер йөртергә була. Шагыйрь буш урында барлыкка килми. Аның иҗтимагый-фәлсәфи һәм эстетик карашларына үзе яшәгән тирәлек, мәдрәсә елларында укыган китаплары, мөгаллим-остазлары, җәмгыятьтәге сәяси, тарихи, мәдәни шартлар тәэсир итә. Тукай иҗатының бай, катлаулы, күп төсмерле булуы да шулар белән аңлатыла. Шуңа мөнәсәбәтле рәвештә шул чорда барган күренешләрне киңәйтеп тасвирлаган, агымдагы фикерләр – аллюзияләр ярдәмендә Тукайның эстетик карашларын билгеләргә мөмкинлек туа. Билгеле, аллюзияләр исәбенә шагыйрьнең нинди традициягә таянганлыгын да билгеләргә мөмкин.

Тукай һәм халык иҗаты. Эшебездә бу як читтә калса да, әлеге ике төшенчә һәрвакыт бергә яши. Шуңа күрә дә шагыйрь иҗатында халык авыз иҗаты бәйләнешле традицион образлар һәм сурәтләр (шүрәле, су анасы, җен, пәри, дию) турыдан-туры метафорик аллюзия буларак урын ала. Тукайның «Шүрәле», «Су анасы», «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш», «Япон хикәясе»нең төп нигезе халык фольклоры белән бәйле вакыйга барып тоташа һәм аллюзияләр барлыкка китүдә катнаша.

Димәк, борынгы әдәбиятыбыз, Шәрык, рус һәм Ауропа, халык авыз иҗаты белән бәйләнешле аллюзияләрне Тукай иҗатында шактый булуы күренә. Әлбәттә, Тукай тудырган аллюзияләр моның белән генә чикләнми. Аллюзия теориясе галимнәр та-

рафыннан эшкәртелеп җиткерелмәгән, шуңа күрә Тукай иҗатындагы аллюзияләр турында, аның теге яки бу әдәбият белән бәйләнеш кысаларында гына фикер йөртергә мәҗбүрбез.

ӘДӘБИЯТ


1. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. Казан: Мәгариф, 2007. 231 б.
2. Евсеев А.С. Основы теории аллюзии: автореф. дис. ... канд. филол. наук. М., 1990. 22 с.
3. Козицкая Е.А. Смыслообразующая функция цитаты в поэтическом тесте. Тверь, 1999. 120 с.
4. Миңнегулов, Х. Тукай һәм Урта гасыр әдәбияты // Мирас. 1997. № 1. Б. 39–50.
5. Нәккаш-Исмәгыйль, Н. Иман берлә Коръән тулган садремә! // Мәдәни җомга. 1996. № 21. Б. 14–15.
6. Тукай Г. Әсәрләр. Биш томда. 1 т.: Шигырьләр. Поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 400 б.
7. Тукай Г. Әсәрләр. Биш томда. 2 т.: Шигырьләр. Поэмалар (1909–1913). Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 398 б.
8. Хисамов Н.Ш. Хәтер сандыгында: Әдәби-фәнни мәкаләләр, иҗат портретлары һәм публицистика. Казан: Мәгариф, 2004. 641 б.


## Г. ТУКАЙНЫҢ БАШЛАНГЫЧ ЧОР ИҖАТЫНДА НАТУРАЛИСТИК ТЕНДЕНЦИЯЛӘР


***Сәлахова З.Г.***



Натурализм, широко развернувшееся литературное течение в 60–80-х годах XIX века в литературе Европы и Америки, – явление, характерное для всех времен мировой литературы. Несмотря на то, что натурализм не смог сформироваться как самостоятельное течение в татарской литературе, его элементы можно найти в каждой эпохе татарской литературы. Познакомившись с поэзией Тукая, мы видим, что и во времена просвещения он уделяет место натуралистическому описанию.

Naturalism as a widespread literary movement of 60–80th years of XIX century of Europe and American literature is a style which specific for all times of world literature. Despite the fact that naturalism can not be formed as a separate trend in the Tatar literature, its elements can be found in every epoch of Tatar literature. With an acquaintance with the poetry of Tukay, we see that in the time of enlightenment, he gives place for naturalistic description.


Бай мираслы татар әдәбияты ике мәртәбә Яңарыш дәвере кичерде. Беренчесе – Урта гасырларда, икенчесе – Яңа заманда – XIX йөзнең икенче яртысыннан башлап, Октябрь инкыйлабына кадәр дәвам итте. Бу чорда татар әдәбиятында Аурупа һәм рус әдәбиятларындагы кебек, жанрларның иҗадилыкка корылуы, алымнар иреклелеге, хәрәкәтчәнлеге өчен киң мөмкинлекләр ачылды. Бу сыйфат үзгәрешләренең нәтиҗәсе буларак, татар әдәбиятында өр-яңа жанрлар, реализм һәм романтизм кебек Аурупа тибындагы әдәби юнәлешләр, иҗат ысуллары барлыкка килде. Өстәвенә, алар моңарчы әдәби барышта күрелмәгән «модерн» күренешләре, француз, рус әдәбиятлары аша үтеп кергән символизм, импрессионизм, экспрессионизм, экзистенциализм, натурализм өчен хас стильләр, алымнар белән мөнәсәбәткә керде [2, б. 172].

Әдәбиятыбызның яңаруына, реализмның баюына «натурализм» дигән әдәби-эстетик күренеш тә үз өлешен кертте.

Нәрсә соң ул натурализм? Бу төшенчә латинча «natura» сүзенән алынган, татарча «табигать» дигән мәгънәне аңлата. Ул әдәби юнәлеш буларак XIX гасырның 60–80 нче елларында Европа һәм Америка әдәбиятларында үсеш ала.

Натурализм – дөнья әдәбиятының бөтен чорлары өчен дә хас күренеш. Аның тенденцияләрен борынгы грек һәм латин прозасында ук табалар.

Натурализм элементлары романтик әдәбият, XX гасыр прозасы һәм драматургиясе тарихында да зур урын ала. Яңа заман Аурупа һәм рус әдәбиятларында натуралистик тасвирлар аеруча мул күзгә ташлана.

Натуралистлар мораль укудан баш тарталар, фәнни объективлык белән сурәтләнгән чынбарлык болай да ачык һәм тәэсирле дип санныйлар. Алар фикеренчә, фән кебек үк, әдәбиятның да материал сайлау хокукы, язучы кулланырга мөмкин булмаган сюжетлар яки яктыртылырга лаек булмаган темалар да юк.

Натурализмның ике канаты бар. Бер яктан, натурализм фактларны түкми-чәчми фотография ысулы белән тасвирлаучы юнәлеш буларак мәйданга чыга. Натуралистик романда документализм, фактография, яшәешнең вак детальләрен мөмкин кадәр объектив чагылдыру омтылышы чынбарлыкны сурәтләүдә дөреслекнең әһәмиятле терәге итеп карала. Икенче яктан, бу әдәби күренеш биологик детерминизм һәм кешенең физиологик үзенчәлекләре белән бәйләп аңлатыла.

Татар әдәбиятына күз салсак, анда натурализм аерым бер агым рәвешендә формалаша алмады. Ләкин натуралистик элементларның татар әдәбиятының һәр чорында да табылуын кире кагып булмый. Борынгы һәм Урта гасыр татар әдәбиятында да натуралистик алымнар күпмедер дәрәҗәдә яшәгән, ләкин әлегә алар татар әдәбият белемендә махсус өйрәнелмәгән.

Натурализмның ерак тамырлары фольклорга, урта гасыр Шәрык һәм Гареб әдәбиятларына барып тоташа. Шәрык әдәбиятында натуралистик деталь - элементлар көчле булып, суфыйчылык әдәбиятында алар аеруча калку бирелделәр. Мәсәлән, суфыйларда мәхәббәт темасы, хәтта тән мәхәббәте дә Алла белән бергә кушылу, анда эреп югалу буларак аңлатылды.

Дини әдәбиятта да натурализмга мисаллар табып була. Мәсәлән, ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләрне көйләү өчен хатын – кызның иренә каршы дәшүе, аңа карата начарлык кылу катгый тыелган. Киресен эшли икән, аны куркыныч җәза көтә. Тәненең черүе, муенына еланнар уралуы кебек күренешләр натуралистик элементлар белән җанлы итеп сурәтләнә.

Натурализмның иҗат ысулы буларак кулланылуы XIX гасыр мәгърифәтчелек әдәбиятында да күзгә ташлана.

Билгеле булганча, мәгърифәтчелек реализмы – реализм үсешендә бер этап, мәгърифәтчелек идеологиясе нигезендә мәйданга килгән иҗат методы. Мәгърифәтче язучылар халык массаларын бәхетле, таза тормышка чыгарырга омтылып, моның өчен халыкны агартырга, җәмгыятьне акыл, белем һәм югары әхлак нигезендә үзгәртеп корырга тырышалар. Бу карашлар язучыларның иҗат практикасында тормышка ашырыла. Әсәрләрдәге персонажлар гадәттә әхлаклы һәм культуралы булу-булмау ягыннан капма-каршы рәвештә ике төркемгә бүленә. Язучының уңай идеалын гәүдәләндергән геройлар бар яктан да килгән, укымышлы, югары әхлакый сыйфатларга ия, тискәреләре исә аңгыра, надан, әхлаксыз кешеләр.

Шушы заманда иҗат иткән Каюм Насыйри иҗатына тукталсак, әлеге мәгърифәтче галимнең дә бу әдәби юнәлешне читләтеп узмавы күренә. Мисалга «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият»ын (1884) алыйк. Әлеге әсәр Уральскига бару юлында Г. Тукай кулына килеп керә. Г. Тукай «Фавәкиһел-җөләса фил-әдәбият»та Кандалый шигырьләрен, җыентыктагы хикәяләрдәге ирләр белән хатыннар арасындагы җенси мөнәсәбәтләр турында укыгач, мондый оят нәрсәләрне ничек ачыктан-ачык язарга мөмкин икән, дип таң кала.

Шул ук вакытта бөек шагыйребез Г. Тукайның үз иҗатына күз ташласак та, анда сизелер-сизелмәс кенә бирелгән натурализмга тартым тасвирлар белән очрашабыз. Тәнкыйтьче И. Нуруллин да шагыйрьнең «Кечкенә генә көйле бер хикәя» сенә карата: «Әсәр башлыча натуралистик планда язылган дисәк тә хата булмас» [3, б. 58], – дип искәртеп үтә.

Натуралистик тенденцияләр Тукай иҗатына да килеп керә. Г. Тукай белән Г. Кандалыйның шигырьләрен чагыштырып карасак, иҗатларында охшаш натуралистик юллар берничә урында күзгә ташлана. Мәсәлән, Тукайның «Фөрьяд» шигырендә мондый юллар бар.

Кич булгачдин үзе тагы эчеп кайта,
Аузы-борны сасып, өст-баш тынчып кайта [3, б. 203].

Ә Кандалый исә болай ди:

Кичен ятыр сасып, тынчып… [1, б. 392]

Гомумән, Тукай шигърияте белән танышып чыккач та, анда натурализмның аз булуын күрәбез. Шулай да шагыйрьнең мәгърифәтчелек чорында натурализмга да урын бирүен әйтми мөмкин түгел. Мисалга «Японияне мөселман итәчәк геройлар кайда?» дигән шигыреннән ике юлны китереп үтик.

Безгә зур эш күрсәттегез: ашка йөрдегез хайван кебек,
Ашау-эчүгә бирелеп, тыгындыгыз бирән кебек [3, б. 87].

Г. Тукай биредә тамак колы булуны тәнкыйтьләү өчен натуралистик эчтәлекле бәяләмәләрдән файдаланса, тиешле белем бирә алмаган мәдрәсәләрнең эчке тормышын бирү өчен дә шушы ук алымга мөрәҗәгать итә. Анда укучы шәкертләрне тирес эчендә гамьсез генә яшәүче кыргаяклар белән чагыштыра.

Шагыйрьнең башлангыч чор иҗатында кеше физиологиясе белән бәйле шигъри юллар да күренгәли. Мисалга «Сорыкортларга» дан бер куплетка күз салыйк.

> Аристократ сорыкортлар, калын корсак, кечек башлар;
> Ашыйлар соң бирән булган кешеләр, ну гаҗәп, ай-яй!
> Вә һәрберсе – губернатор, кикерәләр дөбер-шатыр;
> Тамак туйгач төкер-какыр, бөтен эч май гына, май-май [3, б. 131.

Димәк, бөек шагыйребез халыкка хезмәт итәргә тиешле муллаларның корсак колы гына булып калулары белән килешми, аларның бу кимчелеген натуралистик бәяләмәләр белән үрелгән публицистик шигырь юллары ярдәмендә тәнкыйть итә. Ягъни Тукай да кешенең әхлакый сыйфатларын натуралистик сурәтләр аша күрсәтә. Шулай итеп, Г. Тукай үзенең шигырьләрендә җәмгыятьтәге җитешсезлекләрне, наданлыкны, әхлаксызлыкны һәм тамак колы булу кебек кимчелекләрне тәнкыйтьләү өчен натуралистик иҗат алымын сайлый.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Тукай мәгърифәтчелек реализмы рухында иҗат ителгән кайбер әсәрләрендә натуралистик алымнар да куллана. Биредә натуралистик детальләр бирелешендә Кандалый белән беркадәр уртаклык та сизелә. Мондый уртаклыкның сәбәбе – Кандалыйның да, Тукайның да башлангыч чор иҗатында мәгърифәтче булуы. Мәгърифәтчеләр исә, гомумән, натуралистик деталь, тасвирларга мөрәҗәгать итәргә яраталар. Димәк, бу хәл күпмедер дәрәҗәдә аларның дөньяга карашлары белән бәйле.

Гомумән алганда исә, Г. Тукай үзенең иҗатында натуралистик тенденцияләргә бик аз урын бирә.

ӘДӘБИЯТ

1. Кандалый Габделҗәббар. Шигырьләр һәм поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. 558 б.
2. Ганиева Р.К. Татар әдәбияты: традицияләр, багланышлар. Казан: Казан ун-ты нәшр., 2002. 272 б.
3. Тукай Г. Шигырьләр. Биш томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 1 т. 407 б.

# ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬЧЕ И.Г. ПЕХТЕЛЕВ ХЕЗМӘТЛӘРЕНДӘ ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИҖАТЫ

***Сәлахова Р.Р.***

Статья посвящена анализу ряда литературно-критических работ, созданных одним из литературных критиков И.Г. Пехтелевым. В статье анализируются труды, посвященные изучению творчества великого татарского поэта Г. Тукая, в которых И.Г. Пехтелев дает высокую оценку-духовно-нравственной и эстетической ценности его произведений. Данное исследование позволяет не только определить позицию И.Г. Пехтелева, но существенно дополнит общую картину развития отечественной литературы в начале XX века.

This article analyzes a number of literary and critical works, created by one of the literary critics I.G. Pehtelevym . The article analyzes the works devoted to the study of the great Tatar poet G. Tukay in which I.G. Pehtelev praised the spiritual, moral and aesthetic value of his works. This study allows us not only to determine I.G. Pehteleva position, but significantly complement the overall picture of the development of Tatar literature in the early twentieth century.

Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай иҗатының зурлыгы, аның шигъри әсәрләрендә генә түгел, бәлки тәнкыйть һәм әдәбиятка, тарихка караган фәнни хезмәтләрендә дә күренә. Ул үзенә кадәрге шагыйрьләр иҗаты белән яхшы ук таныш булган һәм аларга карата шәхси мөнәсәбәтләрен әйтеп барган. Бөек шагыйребез замандашлары Г. Камал, М. Гафури, С. Рәмиев, С. Сүнчәләй, Н. Думави, Г. Ибраһимов, Г. Исхакый иҗатларны карата үз фикерләрен белдергән. Аларның әсәрләрендә үзен канәгатьләндерерлек яклар турында кинәнеп язса, кимчелекләрен, Г. Тукайга хас булганча, кылычтан үткен теле белән камчылаган.

Г. Тукай үз иҗатына битараф булдылар дип әйтә алмагандыр, чөнки һәр әсәре, китабы җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итә, аларны укыйлар, язганнары белән килешәләр, яки бәхәсләшәләр, авторын мактыйлар яисә ачуланалар. Танылган халык шагыйренең әдәбият өлкәсендә казанган уңышларын, гүзәл әсәрләрен бөтен барлыгы белән укучыга җиткерү, аның иҗатына объектив бәя бирү эшен зур җаваплылык белән башкарган әдипләрдән Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Г. Гали, Г. Халит, Г. Сәгъди, Г. Рәхим, Ф. Бурнаш, Г. Нигъмәти, Җ. Вәлиди, Г Галил,М. Җәлил, Я. Агишев, И. Пехтелев, Р. Башкуров, Р. Ганиеваларны атый алабыз.

Шагыйрьне халкыбызга якынайтуда һәм танытуда Р. Гайнанов, Ә. Исхак, Х. Госман, М. Бакиров, Х. Курбатов хезмәтләре аерым игътибарга лаек. Шулай ук И. Нуруллин, Ә. Фәйзи, Р. Ишморат, Т. Миңнуллин, Р. Батулла кебек күренекле әдипләребезнең әсәрләрендә, С. Хәким поэмаларында, күп санлы шигырьләрдә, хикәяләрдә Г. Тукай образының төрле яклап, шактый тулы гәүдәләндерелгәнлеген билгеләп китү мөһим.

Г. Тукай иҗатына тәнкыйди караш төрле булган. Араларында тискәре тәнкыйтьләр дә юк түгел. Әмма тәнкыйтьчеләрнең күбесе Г. Тукай иҗатына югары бәя биргән, аны олы шагыйрь, талантлы шагыйрь дип санаган. Шундыйларның берсе – И.Г. Пехтелев.

Иван Пехтелевнең исеме журналистика өлкәсендә генә түгел, ә әдәби тәнкыйтьче һәм публицист буларак та яхшы таныш. Әдипнең әдәбият белгече буларак дистәләгән әдәби тәнкыйть мәкаләләре хәзерге көндә дә теге яки бу язучының иҗатын өйрәнүдә зур кыйммәткә ия. Аның әдәбият дөньясыннан хәбәрдарлыгы, тирән белемле әдәбиятчы булуы, теге яки бу язучының иҗатына карата язылган тәнкыйть мәкаләләренең эчтәлегеннән үк аңлашылып тора. Үзенең фәнни эшчәнлеген ул Белинский, Герцен кебек шәхесләрнең иҗатларын өйрәнүдән башлап җибәрә. И.Г. Пехтелев иҗатының зурлыгы «Рус әдәбияты тарихчысы буларак Белинский» (1957), «Әдәбият һәм заман» (1964), «Герцен – әдәби тәнкыйтьче» (1967) кебек тәнкыйть һәм әдәбиятка, тарихка караган фәнни хезмәтләрендә күренә. Әдип башка халыклар әдәбияты белән дә яхшы ук таныш була. Татар әдәбиятында И. Пехтелевне кызыксындырган шәхеснең Габдулла Тукай булганлыгын, аның Тукай иҗатына багышланган күпсанлы тәнкыйди хезмәтләре дәлилли. И.Г. Пехтелевне әдәбият белгече буларак, бер яктан Тукайның поэзиясе кызыксындырса, икенче яктан, аны бигрәк тә Тукайның публицистик мәкаләләре, журналистика үсешенә керткән хезмәтләре игътибарын җәлеп иткән булса кирәк. Нәрсә генә булса да, И.Г. Пехтелевнең Тукай иҗатына карата язылган хезмәтләре, әдипнең бу олы шәхескә олы ихтирам белән каравы турында сөйли.

Тукай иҗаты белән бәйле эшчәнлеген барлап чыкканнан соң, И. Пехтелевнең Г. Тукай иҗатын өйрәнүгә багышланган түбәндәге хезмәтләре булуы ачыкланды: «Эстетические идеи в поэзии Г. Тукая» (1946), «Пушкин, Лермонтов, Тукай» (1949), «Литература и время. Вдохновленное служение Родине и народу» (1964), «Поэт и его время» (1957), «Книга о Тукае» (1958), «Русская литература и Тукай» (1966). Моннан тыш, Якуб Агишев белән берлектә язылган «Габдулла Тукай» исемле биографик очерк та бу исемлекне тулыландыра.

И.Г. Пехтелевнең «Габдулла Тукай шигъриятендә эстетик идеяләр» хезмәтендә, мәсәлән, автор Г. Тукайның шәхес буларак югары эстетик үзаңга ия булуын һәм бу сыйфатның Тукайның бөтен иҗатында чагылыш табуын конкрет шигырьләрдән китерелгән өзекләр һәм аларга ясалган анализлар ярдәмендә дәлилли. Әдип бу хезмәттә Тукайның татар халкы эстетикасын күрсәтеп торучы идеяләрен рус язучыларының сәнгатькә карата булган идеяләре белән бәйләп өйрәнүне максат итеп куя һәм безнең карашка, бик уңышлы башкарып чыга. И.Г. Пехтелев биредә Тукай поэзиясе, аның тормышка мөнәсәбәте, әдәби иҗат хаклыгы, әдип поэзиясенең интеллектуаль һәм эмоциональ башлангычы, әдәби тәнкыйте мәсьәләләрен күтәрә. Татар әдәбиятында эстетик идеяләрне алга куеп иҗат итүче Тукайны И.Г. Пехтелев яңалык кертүче шагыйрь (поэт-новатор) дип атый [3, с. 14].

И. Пехтелевне Тукайдан соң килгән буын шагыйрьләренең әсәрләрендә тормышның тышкы картинасын гына сурәтләве борчый, ул мондый рухта иҗат итүчеләргә Тукайның эстетик идеяләрен өйрәнүне киңәш итә. Пехтелев фикеренчә, Тукайның эстетик идеяләре шулай ук белемгә, мәгърифәткә омтылуда күренә. Автор «Ата илә бала» (1909), «Китап» (1909), «Сабыйга» (1909) кебек әсәрләре мисалында бу фикерен аңлаешлы итеп дәлилләп бирә.

Кайбер тәнкыйтьчеләр, 1905 елгы революциядән соң, Тукайның пессимистик рухта иҗат итә башлавы турында язалар. Әмма И. Пехтелев бу фикер белән килешми һәм Тукайның иҗатында пессимистик мотивларның алдагы чорларда иҗат иткән шигырьләрендә дә күзәтелүен, пессимистик рухтагы шигырьләре белән беррәттән иҗат ителгән оптимистик характердагы шигырьләреннән өзекләр китерә. Мәсәлән, 1906 елда язылган «Халкыма» (И. Пехтелев бу шигырьгә югары бәя бирә һәм аны «Тукай талантының бөек һәйкәле» дип аталырга хаклы икәнен искәртә) шигыре реакция елларында язылган булуга карамастан, халык бәхете өчен көрәшкә өндәүче бөек идеаллар белән сугарылганлыгын күрсәтә. Гомумән, Пехтелев фикеренчә, аның пессимистик рухта иҗат итүе теге яки бу вакыйга белән бәйле түгел. Бер яктан, Тукай сәнгатьнең зур социаль-файдалы ролен аңлап, халыкка үз иҗатының кирәкле дип саный һәм күтәренке рухтагы шигырьләр иҗат итә. Икенче яктан, үзенә ясалган авыр басымны сизеп, ул яшәгән чорны кайгылы һәм михнәтле елларга туры килүен ассызыклый. Әмма Тукай беркайчан да шигъриятттән баш тартмый. Пехтелев түбәндәгечә яза: «Тукай признает необходимость поэтического творчества, но только во время своих печальных размышлений о поэте и поэзии он призывает поэта скрывать свои внутренние тайны, не рассчитывать на похвалу и сочувствие, чувствовать себя независимым от посторонних мнений. Иначе говоря, Тукай создает своеобразную теорию «автономности» искусства и поэзии, имевшую место и у других поэтов» [3, с. 42].

Татар халкының иң намуслы һәм вөҗданлы улларының берсе булган Габдулла Тукай да халык әдәбиятына зур ихтирам белән каравы һәм бу аның халык шагыйре булып формалашуында зур роль уйнаганлыгы И. Пехтелев хезмәтләрендә бер генә тапкыр искәртелми. Ул Тукайның шагыйрь һәм әдәби тәнкыйтьче буларак, чын халыкчанлыгын Тукай иҗатыннан китерелгән күп фактлар ярдәмендә дәлилли. Аның «Халык әдәбияты» дип исемләнгән мәкаләсен исенә төшерә, әһәмиятле урыннарыннан өзекләр китерә [5, с. 3].

И. Пехтелевнең «Русская литература и Тукай» хезмәте дә игътибарга лаек. Биредә тәнкыйтьче Тукайның рус әдәбияты белән яхшы ук таныш булуын, аеруча Пушкин һәм Лермонтов иҗаты белән тирән кызыксынуын билгеләп үтә(39). Пушкинның «Поэт», «Чернь», «Поэту» шигырьләрендәге төп идеалар Тукайның «Киңәш»(1908) шигырендә чагылыш таба дип яза. Пехтелев Тукай белән Пушкинны бер югарылыкка куеп бәяли, моңа әдип хезмәтеннән алынган түбәндәге юллар шаһит: «Габдулла Тукай да Пушкин кебек милли шагыйрь иде. Ул үз халкын, аның гореф-гадәтләрен, тел һәм культурасын, шатлык һәм хисләрен, теләк һәм өметләрен яхшы белә иде. Ул, Пушкин кебек үк, тирән интернациональ теләкләр белән яшәде һәм аны тормышка ашыру өчен көрәште» [ 4, с. 29].

Пехтелев фикеренчә, Тукай үз халкының азатлыгын рус халкы белән дуслыкта күрә һәм шигырьләрендә дә моңа басым ясый. Үзенең әдәби тәнкыйть мәкаләләрендә дә Тукай һәрвакыт татар әдәбияты үсешендә рус әдәбиятының олы тәэсирен ассызыклый. Габдулла Тукайның Пушкин, Лермонтов, Жуковский, Дмитриев, Майков, Кольцов, Фет, Тютчев, Суриков, Ушинский, Цыганова шигырьләрен тәрҗемә итеп үзшигъриятендә аларның иҗатларыннан файдалануын искәртә автор.

«Пушкин, Лермонтов, Тукай» дип аталган башка бер хезмәтендә «Пушкин һәм Тукай», «Лермонтов һәм Тукай» кебек бүлекләр бар. Бу бүлекләрдә И.Г. Пехтелевнең һәр өч шәхеснең дә иҗатын яхшы белеп эш иткәнлеге күренә. Алай гына да түгел, әдип алар турында язылган тәнкыйть мәкаләләреннән дә хәбәрдар. Пехтелев фикеренчә, Тукай үзе дә рус әдәбиятчыларының әсәрләре белән генә чикләнмичә, аларның иҗатына булган мәкаләләр, аерым хезмәтләр белән танышып баруны кирәк дип санаган. Мәсәлән, Белинскийның Пушкин иҗатына карата язылган тәнкыйть мәкаләсенә Тукай югары бәя бирә һәм Белинскийны бөек тәнкыйтьче дип саный. И. Пехтелев хезмәттә Тукайның әлеге мәкаләсеннән өзекләр тәкъдим итә [7, с. 24].

«Пушкин һәм Тукай» дип исемләнгән бүлектә автор Пушкинның Тукай шигъриятенә тәэсире турында түбәндәгечә яза: «Пушкин үзенең эшчәнлегенең бөтен ягы: фикер тирәнлеге, кабатланмас шигъри рух көче, тормыш чынбарлыгын күрсәтә белү, эстетик үзаң үткенлеге, халык иҗатының саекмас көченә зур ышанычы, гомумән гениаль иҗатчыга нинди сыйфатлар кирәк, барысы белән дә Тукай иҗатына зур йогынты ясаган шәхес». Тукай үзенең беренче шигырьләрен язганда шигъриятькә куелган бурычларны аңлап эш итә. Аны «Шагыйрьнең җәмгыятьтәге урыны нинди?»,

«Шигъриятнең халыкка хезмәт итүенә кайсы юллар белән ирешергә?», «Шагыйрь алдында торган каршылыкларны ничек җиңәргә?» кебек сораулар борчыган. Пехтелев фикеренчә, Тукай шигъриятнең халыкка кирәклеген яхшы аңлаган, үз иҗатында ул халыкның якты киләчәгенә зур ышанычын белдергән. Әмма шагыйрь нинди чыганакларга нигезләнгән? Мондый ышаныч аңа кайдан килгән? Автор хезмәттә шундый сораулар күтәрә һәм шул сорауларга үзе үк җавап та бирә. Әдип карашынча, беренчедән, 1905 елгы революция Тукайга сүз сәнгате ярдәмендә дөрессезлеккә юл куярга мөмкин булачагын ышандыра. Бу уңайдан Пехтелев Тукайның «Дусларга бер сүз» (1905) һәм «И, каләм» (1906) кебек шигырьләреннән өзекләр китерә. Икенчедән, Тукайга мондый ышаныч рус язучылары иҗатыннан килә дип саный әдип һәм аның беренче укытучылары булып, әлбәттә, Пушкин торуынассызыклый. Моның шулай икәнлеген Тукайның «Пушкинга»(1908) дип аталган шигыре ярдәмендә исбатлап та бирә.

Бу хезмәттә И. Пехтелев тагын бер әһәмиятле моментка туктала: Пушкин шигырьләрен тәрҗемә иткәндә, Тукай кайбер шигырьләргә үзгә мәгънә бирә. Мәсәлән, Тукайның «Пушкиннан» дигән шигыре Пушкинның 1824 елда язылган «Пока супруг тебя, красавицу младую» бер эчтәлектәге шигырьләр. Пушкинның бу шигыре көнчыгыш темасын яктырткан беренче тәҗрибәләреннән санала. Биредә җиденче хатын булып килгән кызның михнәтле язмышы сурәтләнә. Тукай бу шигырьне тәрҗемә итү барышында аңа башка мәгънә өсти: хатын-кыз язмышын шундый халәкәткә алып бара торган ислам белән килешмәвен белдерә. Тукай фикеренчә, хатын-кызның авыр язмышы әле моның белән генә чикләнми, аның азатлыгын чикләүче күп төрле фактлар бар, Тукай шуларны да өсти һәм нәтиҗәдә Пушкинның бу шигыре тагын да тәнкыйди килеп чыга. Гомумән, хатын-кызның җәмгыятьтәге урыны, аның хокуклары турында язу – Тукай иҗатының аерым бер тематикасы. Шулай ук Пушкин иҗатында да хатын-кыз темасына зур урын бирелгәнлеген беләбез. Тукай Пушкин кебек үк үз иҗатында эгоистлык һәм индивидуальлекне фаш итә. Бу урында ике шагыйрьнең дә шул рухта язылган шигырьләреннән өзекләр китерелә. Тукайның «Халкыма» (1906) шигыре, Пушкинның «Вольность», «Чаадаеву» һәм башка шигырьләре. И. Пехтелев ике бөек шагыйрь иҗатындагы әлеге уртаклыкларга байтак мисаллар китерә. Һәр ике шагыйрьнең иҗатын өйрәнгәннән соң, Пехтелев, Тукай Пушкинның көньяк сөрген чорында язылган әсәрләренә күбрәк игътибар биргән дигән нәтиҗәгә килә. Бу чорда язылган шигырьләрдәге лириканың Тукай күңеленә аеруча якын булуы хезмәттә берничә урында телгә алына. Пушкинның «Я пережил свои желания» (1821), «Узник» (1822) кебек шигырьләрен Тукай образлар бөтенлеген саклап тәрҗемә итә, бу әсәрләр тәрҗемә иткәннән соң да үзенең Пушкинча сәнгатьчәнлеген югалтмаганнар», –дип искәртә И.Г. Пехтелев [4, с. 27].

Хезмәттә Пушкинның Тукай тәрҗемә иткән «Любопытный» (1828), «Веселый пир» (1819), «Сказки о золотом петушке» (1834) шигырьләре турында сүз бара. Алардагы уртак һәм аермалы яклар, тәрҗемәнең сәнгатьчәнлеге кебек мәсьәләләр белән танышып чыкканнан соң, бу әсәрләр Пехтелев тарафыннан чагыштырма планда тирәнтен өйрәнелгәннәр һәм яхшы әдәби тәнкыйтькә ирешкәннәр дигән нәтиҗәләргә килдек.

Пехтелевнең «Лермонтов һәм Тукай» исемле бүлеге «Рус әдәбиятында Тукайның икенче авторитеты булып Лермонтов тора» дигән фикерләр белән башланып китә. И. Пехтелев фикеренчә, Тукай Лермонтов иҗаты белән бик җитди һәм нигезле итеп кызыксына. «Үгет» (1907), «Алданган» (1908) кебек шигырьләре Лермонтовтан тәрҗемә ителгәннәр. Автор искәртүенчә, Тукай Лермонтов шигырьләренең исемен үзгәртеп бирә, әмма шигырь башында «Лермонтовтан» яки «Лермонтовка ияреп...» кебек искәрмәләр биреп куя. Моннан тыш, тәрҗемә эше булып тормасалар да, татар шагыйренең күп кенә шигырьләрендә Лермонтов иҗатына хас мотивлар күзәтелүен билгеләп уза И. Пехтелев. Бу шигырьләрне һич кенә дә тәрҗемә эшләре дип атарга нигез юк дип саный әдип һәм, мәсәлән «Шагыйрьгә» шигыреннән өзекләр китереп, түбәндәгечә яза: «Беренче карашка бу шигырьдәге фикерләрне Лермонтовка кайтарып калдырырга мөмкин. Әмма бу Тукай иҗатына карата гаделсезлек булыр иде, чөнки бу шигырь тәрҗемә нәтиҗәсе түгел, ә Тукайның Лермонтов тәэсирендә язылган үзенчәлекле оригиналь әсәре булып тора. Тагын шуны да әйтергә кирәк: Лермонтовның «Поэту» шигырендә конкрет адресат бар, ул – танылган язучы Николай Филиппович Павлов [4, с. 98].

Лермонтов һәм Тукайның шигъриятен чагыштырып, Пехтелев тагын бер әһәмиятле фикерен белдерә: ике шагыйрь дә үз хисләренең коллары түгел. Алар икесе дә

шагыйрь алдына куелган бурычның киңәйтеп, шагыйрь – ул көрәшче һәм халыкны хакыйкатькә өндәүче икәнлеген аңлап иҗат итәләр. Лермонтовның «К...» («Я не унижусь пред тобою») һәмТукайның «Аңа» кебек шигырьләре әлеге фикернең дөреслеген дәлиллиләр. Пехтелев һәр ике шигырьдән дә өзекләр китерә [6, с. 32].

Автор әлеге хезмәтендә шулай ук Пушкин, Лермонтов һәмТукайның бер үк исемдәге «Пәйгамбәр («Пророк») шигырьләренә игътибар итә. Тукай, мәсәлән, бу шигырен Лермонтовныкыннан тәрҗемә итә, әмма Пушкин шигырендәге кайбер элементлар белән тулыландыра, ди автор. Тукайның «Пәйгамбәр» әсәренең рус варианты булмаганга, И. Пехтелев әлеге әсәрнең сүзгә-сүз тәрҗемәсен дә тулы вариантта бирә.

Тукайны аңлау өчен аның әсәрләрен уку гына да җитә кебек, әмма аның иҗатын карата язылган төрле тәнкыйди хезмәтләр, Тукай иҗатының без аңлап бетерә алмаган нечкәлекләрен, яңа үзенчәлекләрен ачарга ярдәм итә. Иван Пехтелев ГабдуллаТукай иҗатын тирәнтен өйрәнеп язылган хезмәтләрендә әнә шул максатны күздә тоткан, алай гына да түгел, әдәби тәнкыйтьче татар әдәбияты һәм рус әдәбияты өчен дә кызыклы һәм мөһим булган нәтиҗәләргә дә килгән.

Гомумән алганда, И. Пехтелев хезмәтләрендә Габдулла Тукай иҗаты безнең алдыбызга үзенең яңа яклары, кызыклы үзенчәлекләре белән ачылды. Бу хезмәтләрдә Тукайның шигъри юлларга салынган хис-кичерешләре, үз халкына карата булган мәхәббәте, халкының авыр язмышы турындагы уйлары, үзенә бер осталык белән, тәнкыйть күзлегеннән чыгып бәян ителгәннәр.


ӘДӘБИЯТ

1. Агишев Я., Пехтелев И. Габдулла Тукай. Казань: Татгосиздат, 1946. 13 б.
2. Нуруллин И.З. XX йөз башы татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. 268 б.
3. Пехтелев И.Г. Эстетические идеи в поэзии Г. Тукая. Казань:Татгосиздат, 1946. 146 с.
4. Пехтелев И.Г. Пушкин, Лермонтов, Тукай. Казань: Татгосиздат, 1949. 116 с.
5. Пехтелев И. Поэт и его время // Советская Татария. 1957. 12 март. С. 3.
6. Пехтелев И.Г. Литература и время. Статьи и очерки. Казань, 1964. 124 с.
7. Пехтелев И. Русская литература и Тукай. Казань: Татгосиздат, 1966. 126 с.


# ТЕМАТИЧЕСКОЕ СВОЕОБРАЗИЕ ЛЕКСИКИ ПРОИЗВЕДЕНИЙ ГАБДУЛЛЫ ТУКАЯ И АМДИ ГИРАЙБАЯ


***Селендили Л.С.***



Доклад посвящен сравнительному описанию тематической лексики произведений татарского поэта Габдуллы Тукая и крымскотатарского поэта – носителя северного (кыпчакизированного) диалекта – Амди Гирайбая. В процессе исследования выявлено 12 групп тематической лексики, приводятся примеры произведений, посвященных родине, народу, женщине, религиозным проблемам, родному языку, молодежи, друзьям и врагам.

The articles focuses on a comparative description of the thematic vocabulary of Tatar poet Gabdulla Tukay and Crimean Tatar poet – the carrier of the northern (Qypchaq) dialect – Amdi Giraybay. The study identified 12 groups of thematic vocabulary, examples of works devoted to the homeland, the people, women, religious issues, the native language, youth, friends and enemies.


Авторы произведений выбраны нами не случайно. Молодые, красивые татары, жившие в разных тюркских землях, но безумно любившие свою родину, свой народ, они ушли рано, оставив неизгладимый след в истории тюркского мира.

Родные места Габдуллы Тукая – Заказанье, Амди Гирайбай родился в Крыму. Заказанье – сказочные дремучие леса, Крым – безграничные степи, горы, полынь поля половецкого, запах моря, жгучий песок, липучая грязь, пронизывающий ветер и крепость Ени-Кале, придающая мужество и отвагу. Язык Г. Тукая относится к поволжско-кыпчакской подгруппе кыпчакской группы тюркских языков, Амди Гирайбай носитель северного (кыпчакизированного) диалекта крымскотатарского языка, относящегося к огузо-кыпчакским языкам. Язык стихов наполнен архаизмами и диалектизмами.

Поэты родились в разное время в тюркских семьях, глубоко исповедовавших ислам. Безгранично чуткие и внимательные они глубоко понимали богатую тюркскую культуру, ее радости и печали, трагедии и несмолкаемую боль.

В одном из своих стихотворений 1912 г. Тукай писал:

«Лишь значительные темы славу вечную приносят
– Только так я обессмертил имя скромное свое» [1].

Так какая же тематическая лексика связывает татарского поэта Габдуллу Тукая и крымскотатарского поэта Амди Гирайбая?

Разделяя сиротскую судьбу Г. Тукая, Амди Гирайбай пишет о своем «Хорлуке» (сиротских страданиях):

Такъдир булай язгъан магъа Ярадан.
Инсан болып тувмагъайдым анадан.
Хорланаман огей ана элинден.
Чыкъмай давуш джарты сазым телинден.
Мен сюзюлип къалдым инсан селинден[1].

Ключевые слова: судьба, бог, мать, человек, страдания, мачеха, истерзанная душа.

Тукай наставляет татарскую девушку, восхваляет ее красоту, возмущается ее рабским положением:

Җиһанда, санки, бер сатлык таварсыз,
Имамнар кайда аударса – аварсыз.

Вә сез әнгам дәгелсез бөйлә хаксыз,
Хокука мөстәхак, бәлки әхаксыз*.

Вакыт кортылмага бу пәнҗәләрдән,
Вакыт ычкынмага эскәнҗәләрдән.

Ышанмаңыз, бабай Сәйдәш** надан ул,
Түгел надан гына – анларга хан ул.

Ключевые слова: глаза, брови, красота, мир, товар, без права выбора, мир в чужом окне.

А. Гирайбай, в свою очередь, расширяет тему «Татар къызнынъ къара бахты ве я анайымнынъ козьяшлары»: девушка – товар, бесправное положение женщин в обществе, безответственность и алчность отцов, покорность и бесконечная выносливость и терпение тюркских женщин. В его стихотворении из уст матери мы слышим ее горькую судьбу:

Бир фидандай къыз эдим он едиде...
Бабанъызны къартбабанъ «бай» деди де,
Бир афтада эм нишан, эм той этти,
Джаш девраным къушдайын учты кетти.
Бабанъ элли яшына кельген эди,
Бир ай эвель къарысы ольген эди.
Къалгъан оксюз етишкен беш баласы...
Мени огъа ясады бир аласы.
Тюштим бир уй огюйнинъ арасына...
Не кунь корьдим мен анда, ах, не чектим...
«Ай, бабайым, къыздынъ да парасына,
Мени джакътынъ» – дедим де, боюн эгдим.

Ключевые слова: юность, муж-старик, чужаки, алчность отца, горькая судьба дочери, без права на жизнь, адское пламя огня, покорность, без права выбора.

Г. Тукай обращается к своему «Милләтә» словами «мөкаддәс, мөхтәрәм, бәхтиярым, «милли»и сәвәр кальбем».

Үзем үлсәм дә, гаҗиз исмем үлмәсен, югалмасын;
Минем тырышлыгым һәм эшләрем бушка китмәсен.

Әгәр милләт мине, илтифат итеп, искә алса,–
Шул минем максатым, теләгем һәм бәхетем.

Мин сиңа яратуымны сөйләдем, и милләтем;
Мин ышанам ки: син дә мине дус күрерсең.

Ключевые слова: святой, великий, дарующий счастье, сердце, условие, цель, вера в будущее.

---

[1] В качестве примеров работе использованы произведения Амди Гирайбая из библиотеки сайта «Alem-i-medeniye». Режим доступа: http://medeniye.org; а также произведения Габдуллы Тукая с сайта «ШигърияТ.ру». Режим доступа: http://shigriyat.ru/authors/tukai

Гирайбай также безгранично любит свой народ, не видит смысла жизни без любви к народу.

**Миллет сюйгюси болмагъайды**

Ич яшамаз дюньяда атар эдим дерьягъа!..
Юрегимде «Миллет» деген сюйгю болмаса...
Дёкмез эдим сырымны шиир диккен керьягъа,
«Озь миллетим» дегенде.

Видя боль и страдания крымскотатарского народа, поэт дает клятву:

«Ант эткенмен миллетимнинъ ярасыны сармагъа»,
Деп багъырсам, бу кенъ дюнья, бошлукълар да тар магъа.
Айткъан сайын айтаджагъым келе, къальбим къалтырай,
Эмеллерим тёпесинде бир алтын ай джалтырай.
«Ант эткенмен!» айтылгъанда мен бир шаир боламан,
Тамарларым джанлана да кизли кинге толаман.
Гонълюм джоша, джурек таша, миллий джырлар язаман,
Эскирмеген тазе дертни чёпмен тюбюн къазаман.

Для А. Гирайбая – народного заступника – народ – это любовь, смысл жизни, тайна, река, условие его бытия, цель, состояние души, то, во имя чего он готов на все:

**Татар ичюн**

Татар ичюн джеэннемде янарман,
Татар ичюн къызыл откъа атарман,
Татар ичюн кольмегимни сатарман,
Мен Алтайнынъ бир чечеги татарман!

Народ без языка, что песня без слов. Родной язык как часть души воспета Г. Тукаем: И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле! И это неудивительно: нельзя не любить язык народа с такой богатой историей, с такой теплой душой его людей:

И туган тел! Һәрвакытта ярдәмең берлән синең,
Кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем.
И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, Ходам!

Амди Гирайбай переживал за судьбу родного языка. К сожалению, это вопрос актуален и в настоящее время, поэтому его строки как острие ножа впиваются в сердце:

**Тувгъан тилим**

Эй, джаныкъ сёзлермен толу озь тувгъаным, озь тилим,
Дердимнинъ, къальбимнинъ къулу озь тувгъаным, озь тилим.
Сенмен тувдым, сенмен осьтим, сенмен кирсем мезаргъа,
Сен яздырдынъ, сен джоштурдынъ, къойдынъ мени бу заргъа…
Сен тургъанда, токътамайджакъ козьлеримнинъ яшлары
Козьайдынгъа баш котерди эски мезар ташлары.
Джырласам бир мунъ джырынъны, джурегим къайнап таша!
Эй, тувгъан тиль, эй, ана тиль, бинъ яша, юз бинъ яша!

Несмотря на молодость, оба автора понимали, что фундамент и будущее народа – это его молодежь. Габдулла Тукай с гордостью обращается к «Татар яшьләре»:

Дикъкатә лаек хәзерге көн татарның яшьләре:
Аңламак, белмәк, тәрәкъкый, мәгърифәт, хикмәт белән
Әйләнеп һәм нурланып тормакта һәрдәм башлары.

Ключевые слова: гордость, молодежь, смелость, ум, знание и просвещение, святая борьба, вера народная, свобода.

Амди Гирайбай в «Джашлыкъкъа» призывает молодежь встать плечом к плечу и защитить свой народ, свое будущее, но оружием в их руках должна быть не только винтовка, но книга, цель, дипломатия, прогресс, смелость и отвага, наставляет их стать надежной опорой и сменой старому поколению:

Мына бизим борджумыз иште джашлар,
Бугунь энди ишлемей эски башлар.

Джанъылыкъкъа татарны тартмакъ керек,
Арамызда джигитлер артмакъ керек.

Наставляя друзей, не забывают авторы и о врагах. Так, Амди Гирайбай, обращаясь к «Джигитке», говорит, чтобы тот, несмотря на снег и стужу, не пугаясь происков врагов, помнил о своей чести и достоинстве:

Дерьялар буз болып устюнъе джавса,
Парланса бу дюнья, бошлукъкъа авса,
Душманынъ сюлюкдай къанынъны савса,
Ичинъде джангъан од сёнмесин, джансын,
Артынъдан къалгъанлар «джигит» деп анъсын.

Г. Тукай говорит о врагах, как о змеях, которые завидуют его счастью, таланту, успехам его жизни. «Дошманнар» – это не только те люди, кто мучил бедного сироту, кто заставил его страдать, но события его жизни «мрак и нищета». Однако, покоряясь судьбе, поэт пишет:

Зур җаным сөйми җиһанны, чөнки бар дөнья фәна;
Анда тормакка һәвәслек берлә ваклар мөбтәля.

Якты йөз берлән алам каршы авырлык, ауруын;
Чүпкә дә саймыйм йөрәккә кап-кара кан саулуын.

Азмы какканны вә сукканны күтәрдем мин ятим?!
Азрак үстерде сыйпап тик маңлаемнан милләтем.

Два тюрка-кыпчака ушли слишком рано. Г. Тукай умер в возрасте 27 лет после продолжительной болезни, повинуясь судьбе:

Принимаю без укора и болезни, и труды,
Не ропщу на огорченья и превратности судьбы [2].

Амди Гирайбай в 1928 г. был обвинен в «национализме» и арестован. В 1930 г. он был зверски убит в Бутырской тюрьме. Ему было всего 28 лет.

Приведенные выше ключевые слова, а также лексика, изученных нами произведений Г. Тукая и А. Гирайбая, может быть представлена следующими общими тематическими группами: 1) портрет женщины, соматизмы; 2) город и его окружение; 3) слова, характеризующие тюркский мир; 4) общественно-политическая лексика; 5) религиозная лексика; 6) этическая лексика; 7)лексика наглядно-зрительного, обонятельного и слухового характера; 8) лексика оценки человека, его поведения и поступков; 9) лексика, описывающая отношение к социально-исторической ситуации; 10) лексика социально-образовательной сферы; 11) эмотивная лексика; 12) диахроническая лексика.

ЛИТЕРАТУРА


1. Магдеев М. Путь в бессмертие [Электронный ресурс]. Режим доступа: http://gabdullatukay.ru/rus/index.php?option=com_content&task=view&id=30&Itemid=38 (дата обращения 03.03 2016).

2. Тукай Габдулла. Избранное / Перевод с татарского В.С. Думаевой-Валиевой. Казань: Магариф, 2006. 239 с. Режим доступа: http://gabdullatukay.ru/rus/index.php?option=com_content&task=view&id=540&Itemid=37 (дата обращения 11.03 2016).



*При финансовой поддержке РГНФ по проекту №15-34-10116 «Электронный словарь диалектов крымскотатарского языка»*


## Г. ТУКАЙ ТӘРҖЕМӘСЕНДӘ БИРЕЛГӘН И.А. КРЫЛОВ МӘСӘЛЛӘРЕНЕҢ ТЕЛ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ


***Сибгаева Ф.Р.***



Великий татарский поэт Г. Тукай хорошо знал русскую классику, много занимался переводом русской литературы на татарский язык. В своих переводах он донес до читателя мятежные стихи М. Ю. Лермонтова, поэзию А.Н. Майкова, И.С. Никитина, великие творения Л.Н. Толстого, А.С. Пушкина и И.А. Крылова. При переводе произведений русских классиков Г. Тукай основывался на учения В.А. Жуковского. При переводе басен И.А. Крылова использовал такие методы и приемы, как: творческий, эквивалентный, адекватный перевод и т.д.

The great Tatar poet G. Tukay well knew the Russian classics, was engaged in the translation of the Russian literature into Tatar much. In the translations he has informed the reader of rebellious verses of M.Yu. Lermontov, A.N. Maykov's poetry, I.S. Nikitin, L.N. Tolstoy, A.S. Pushkin and I.A. Krylov's great creations. When translating works of the Russian classics of G. Tukay was based on doctrines V.A. Zhukovsky. He at the translation of fables of I.A. Krylov used such methods and receptions as: creative, equivalent, adequate translation, etc.

Г. Тукай иҗаты озак еллар әдәбият белгечләренең, тәнкыйтьчеләрнең, тел-әдәбият галимнәренең игътибарын үзенә тарта, күптөрле киңкырлы фәнни тикшеренү объекты булып тора. 1950–60 нчы еллардан башлап һәм бүгенге көнгә кадәр аның турында аерым монографияләр (Г. Халит, Я. Агишев, И. Нуруллин, И. Пехтелев хезмәтләре) дөнья күрә. Шулай ук Г. Тукай әсәрләренең тел үзенчәлекләрен тикшергән хезмәтләр дә байтак. Шагыйрь иҗатына багышланган хезмәтләрдә рус әдәбияты белән иҗади бәйләнеш мәсьәләләре күтәрелә. Рус һәм татар әдәбиятының бәйләнеше турында махсус мәкаләләр дә күпләп языла (К. Нәҗми, Г. Кутуй, М. Гали, М. Гайнуллин, Җ. Вәҗиева, И. Нуруллин һ.б.) языла. Аларда Г. Тукай иҗатына караган мәсьәләләр яктырыла. Шуның белән бергә турыдан-туры Г. Тукай иҗатының рус әдәбияты белән бәйләнешен тикшерүгә багышланган кайбер хезмәтләр басыла.

И.А. Крылов мәсәлләрен Г. Тукай социаль һәм сатирик мәгънәсен тирән төшенеп, татар халкының көнкүреше, әдәп-әхлагы, күзаллавына яраклаштырып, төрле трансформацияләр кулланылып тәрҗемә итә. И.А. Крыловның Г. Тукай тарафыннан тәрҗемә ителгән мәсәлләре оригиналның адекватлыгына зыян салмый.

Тәрҗемә әдәбиятта трансформацияләр тәрҗемәчедән зур осталык таләп итәдипассызыклана. Л.С. Бархударов классификациясе буенча, трансформацияләр түбәндәгечарарлар ярдәмендә башкарыла: *конкретлаштыру; нәтиҗәне сәбәп яки, киресенчә, сәбәпне нәтиҗә белән алыштыру; антонимик тәрҗемә; компенсацияләү; сүзләр өстәү; сүзләрне төшереп калдыру.*

Лексик трансформацияләрнең әлеге чараларын галим чыганак телнең лексик берәмлекләрен тәрҗемә теленең лексик берәмлекләре белән алмаштыру буларак билгели һәм аларның сүзлек эквивалентлары булмавына да басым ясый [1, с. 68].

Г. Тукай тәрҗемәләренә мөрәҗәгать иткәндә, *конкретлаштыру, өстәмәләр кертү, төшереп калдыру* һәм *алмаштыру* кебек трансформацияләр аерым игътибарга лаек. Беренче итеп, *конкретлаштыру* ярдәмендә тәрҗемә ителгән мисалларга күз салыйк.

Мәсәлән, И.А. Крыловның «Гуси»мәсәлендә *«Предлинной хворостиной Мужик Гусей гнал...»* җөмләсе Г. Тукай тәрҗемәсендә: «*Мужик озын тал чыбыгы илә Казларны сөреп куалап...»*дип бирелә («Казлар»); «Насилу наконец их розлили *водой*» («Собачья дружба») – «...дустларның өстләренә *салкын су* сибеп...» («Этләрнең дуст булышуы»); «Петух нашел Жемчужное Зерно и *говорит*…» («Петух и Жемчужное Зерно») – «Әтәч... бер Энҗе бөртеге тапты да *үз-үзенә сукранып сөйләргә тотынды...*» («Әтәч илә Энҗе бөртеге»).

Мисаллардан күренгәнчә, Г. Тукай мәсәлдәге күренеш-вакыйганы тулырак, сурәтлерәк итеп күзалдына китерү максатыннан тәрҗемәдә предметларны, хәрәкәт һәм кичерешләрне конкретлаштырып, төгәл итеп тасвирлый.

Мәсәлләрне тәрҗемә иткәндә Г. Тукай өстәлмәләр кертеп җибәрә. Г. Тукай текстның сурәтлелеген оригинал тексттагыча саклап калу өчен*чагыштыру, синоним, антоним, фразеологизмнар, образны ачу (развертывание)* кебек чаралар кулланып, мәгънәне мөмкин кадәр көчәйтү өчен тырыша.

И.А. Крыловның «Механик» мәсәлендә «какой-то молодец купил *дом*» диелә, Г. Тукай тәрҗемәдә бу йортны падишаһлар сарае белән чагыштыра: «*падишаһлар сарае кеби зур бер йорт* сатып алды» («Мөһәндис»);

И.А. Крылов «Вороненок» мәсәлендәге «вороненок когтей не вытетербил вон, *вцепившись когтями* в шерсть барана» дип сурәтләсә, «Бала козгын» мәсәлендә Г. Тукай түбәндәге чагыштыру белән бирә: «тырнаклар бик тирән баткан, *кадаклап куйган шикелле*»;

«Егет сайлаучы Кыз» мәсәлендә Г. Тукай «От пленников её бывало тесно...» җөмләсендәге чагыштыруны нәзберек кәләшнең кияүләре «ут янында әйләнгән күбәләкләр шикелле» дигән чагыштыру аша тәрҗемә итә.

Тәрҗемә мәсәлләрдә шагыйрь тарафыннан алынган үзенчәлекле чагыштырулар да бар. Мәсәлән, шул заман өчен яңа күренеш булган киноны «томанлы картинка»

белән тиңли тәрҗемәче. И.А. Крыловның «Ике күгәрчен» мәсәлендә бирелгән «...представишь все так живо, как будто б сам летал ты по свет со мной...» җөмләсен Г. Тукай «...Һәммәсе куз алдында *томанлы картинка кеби* күренер...» дип бирә.

Г. Тукай И.А. Крылов мәсәлләрен тәрҗемә иткәндә фразеологик берәмлекләрдән дә оста файдалана. «Мактанчык Куян» мәсәлендә тәрҗемәче контекст эчтәлегеннән чыгып *«уянмаслык йокыга киткән», «таш йөрәк»* («Мәрхәмәтле Төлке») һ.б куллана. Тәрҗемәче оригиналда булмаган фразеологизмнарны тәрҗемә ителә торган текстның сурәтлелеген, яңгырашын арттыру максатыннан гына түгел, шулай ук рус фразелогик берәмлекләрен татар теленә күчерү чарасы итеп тә куллана. Мәсәлән, «Мәрхәмәтле Төлке» мәсәлен тәрҗемә иткәндә *«жужжать в уши»* фразеологизмына *«колак тондыру»*, «Аккош, Кысла һәм Чуртан» мәсәлендә «*лезть из кожи» – «тиредән чыгарлык булу»* татарча фразеологик эквивалентларын тәкъдим итә.

Оригинал текстны тирәнтен ачу һәм киңәйтү максатыннан, Г. Тукай И.А. Крыловның фикерен дәвам итә, үзеннән өстәп куя. «Кот и Повар» мәсәлендә «А дома стеречи суестное *от мышей* Кота оставил» җөмләсен Г. Тукай: «*Тычканнан, Күседән* сакларга Мәчене калдырган иде» дип тәрҗемә итә. Алга таба «на полу объедки пирога» – үстерелеп, «инде бәлеш төпләре, каз ботлары, паштет эчләре аунап яталар» дип тулыландырыла («Аш пешерүче»).

И.А. Крыловның фикерен көчәйтү, тирәнәйтү өчен шагыйрь тарафыннан иҗади тәрҗемә алымы да киң файдаланыла: «Тогда вползут сюда за доброю Змеей одной, *сто* злых...» («Крестьянин и Змея») – «..синең яныңа *йөзләп, меңләп*, усал Җыланнар җыелып» («Бала караучы»).

И.А. Крыловның «Разборчивая невеста» мәсәленең ахыры болай бирелә: «И рад, рад уж была, что вышла за *калеку*». Г. Тукай тәрҗемәсендә ул түбәндәгечә яңгырый: «Матур кыз.. *агач таяк белән йөри торган сиксән яшьлек бер Картка* куана-куана барды». Нәкъ менә шушы образ шагыйрь тарафыннан мәсәлнең логик азагы булып тәкъдим ителә.

Г. Тукайның тәрҗемә эшчәнлеген өйрәнгән күп кенә галимнәр (Р. Башкуров, Л. Бәйрәмова һ.б.) тәрҗемәчененңтатар тормышы, көнкүреше өчен хас булмаган предмет, күренеш, детальләрен белдерә торгансүз һәм сүзтезмәләрне төшереп калдыруын билгеләп үтәләр. Мәсәлән, «Мәче илә Сандугач» мәсәлендә «пастушка» сүзе тәрҗемә ителми: «Что от твоих прелестных песен все пастухи, *пастушки* – без ума» – «урмандагы Көтүчеләр, ат *ашатучылар* – һәммәсе биһуш булганнар имеш...». Билгеле, бу сүзнең татар телендә эквиваленты юк, бушлыкны тулыландыру өчен *көтүчеләр* лексик берәмлеге аша бирә.

И.А. Крылов мәсәлләрендә очраган *тризна* («Аш пешерүче»), *фимиам* («Оракул»), *свирель* («Ишәк илә Сандугач»), *бостон* (бию) («Егет сайлаучан Кыз»), *кума, кум, куманенок, кумушка* («Мәче илә Сандугач» һ.б.) кебек лакунар берәмлекләр матди эквивалентсызлыкның ачык мисалы булып тора.

Г. Тукай шулай ук татар халкында булмаган метафорик берәмлекләрне дә тәрҗемә итми, ул аларны бары тик төшереп калдыра. Мәсәлән, Сандугач – Борынгы римлыларда таң алиһәсе Авроараның сөекле кошы, аерылмас дусты; Орест һәм Пилад – Борынгы Грециядә дуслыклары белән дан казанган атаклы геройлар, Флора – Борынгы Римда яшьлек һәм чәчәкләр алиһәсе һ.б. Тәрҗемәче әлеге гыйбарәләрне «Ишәк илә Сандугач», «Этләрнең дуст булышуы», «Бытбылдык» кебек формаларда укучыга тәкъдим итә.

Г. Тукай И.А. Крыловның мәсәлләрен тәрҗемә иткән вакытта стилистик эквивалентсызлык кебек тәрҗемә алымыннан да файдалана. Мәсәлән, «Егет сайлаучан Кыз» мәсәле тәрҗемәсендә «женишонки» сүзен тәрҗемә итмичә төшереп калдыра: «Такие женихи другим невестам клад, а ей они на взгляд, не женихи, а*женишонки*!» («Разборчивая невеста»). Объектка кимсетеп биргән бәяне күрсәткече буларак, *-онк-* суффиксына татар телендә тәңгәл сүз табылмый.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, И.А. Крылов мәсәлләрен тәрҗемә иткәндә Г. Тукай, беренчедән, татар халкының көнкүрешенә, яшәү рәвешенә якынайта, икенчедән, иҗади тәрҗемә алымын кулланып, яңа әсәр тудыра.

Г. Тукай үз заманы өчен алдынгы карашлы, кыю, батыр тәрҗемәче булып танылa. Ул тәрҗемә алымнарын һәм принципларын рус классигы В.А. Жуковский хезмәтләрен укып өйрәнә. В.А. Жуковскийның тәрҗемә итүгә карата әйтелгән «склонение на наши нравы» гыйбарәсен үзенең тәрҗемә эшчәнлегендә Г. Тукай үзенә девиз итеп ала.

Укучыга тәкъдим ителгән тәрҗемә мәсәлләрнең дә халык тарафыннан яратылып, үз ителүе шул хакта сөйли.

Шунысы бәхәссез: Г. Тукай эшчәнлегенең алдынгы рус әдәбияты белән аерылгысыз бәйләнгән булуы, аның гүзәл үрнәкләрен тәрҗемә эшчәнлеге ярдәмендә үз халкына һәм төрки кардәш халыкларга җиткерүе Г. Тукай иҗатының кыйммәтен тагын да арттыра һәм югары күтәрә.

**ӘДӘБИЯТ**

1. Бархударов Л.С. Язык и перевод. М.: Международные отношения, 1975. 284 с.

2. Байрамова Л.К. Трансформация в переводах тукая басен И.А. Крылова // Тукай һәм XX гасыр мәдәнияты. Шагыйрьнең 110 еллыгына багышланган халыкара конференция материаллары. Казан, 1997. Б. 249–254.

И. Нуруллинның аерым хезмәтләре Тукай иҗатындагы жанрлар мәсьәләсенә кагылышлы. Ул «Тукайның әдәби пародияләре» дип исемләнгән беренче мәкаләсен инде 1948 елда ук яза. Әлеге хезмәттә ул Г. Тукай пародияләрен халык авыз иҗатында булган шундый жанрга караган әсәрләр һәм рус әдәбияты пародияләре үрнәгендә иҗат итә, дип белдерә, чөнки әдәби бәйләнешләрне алгы планга куеп эш йөртә. Ул, шагыйрь рус пародистлары Буренин һәм Измайловлар иҗатыннан хәбәрдар булып кына калмаган, алар үрнәгендә «Япон хикәясе», «Баскыч» кебек шигырьләр дә иҗат иткән, дип яза. Галим Тукай пародияләренең төрле булуын күрсәтә һәм аларны ике төргә: иҗтимагый һәм әдәби пародияләргә бүлеп карый.

1954 елда И. Нуруллин «В вопросе о развитии идейно-эстетических и литературно-критических взглядов Габдуллы Тукая» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. Телгә алынган хезмәтендә Г. Тукайның идея-эстетик карашларын үсеш-үзгәрештә анализлый. И. Нуруллин, нигездә, Тукайның әдәбиятның тоткан урыны, халыкчанлыгына караган карашларына таяна. Ул шагыйрьнең иҗатын тормыш юлына бәйле рәвештә этапларга бүлә, һәр бүлектә теге яки бу мөһим әсәрләрен махсус тирәнтен анализлый.

Диссертациянең тәүге бүлегендә шагыйрь иҗатында мәгърифәтчелек идеяләре чагылыш таба. Тукай әдәбиятның максатын гыйлемне зурлап, наданлыкны яманлау, аның зыян китерүен күрсәтүдә күрә, дип саный И. Нуруллин. Чираттагы бүлектә Г. Тукайның тәнкыйди эшчәнлеге, революцион-демократик эстетикасы турында сүз йөртелә. Шагыйрьнең Җаек чорындагы мәгърифәчел һәм дидактик карашлары тоемлануы төрында белдерелә. Соңгы өлешендә исә шагыйрьнең Казан чорына бәйле эстетик карашлары билгеләнә. Реализм һәм халыкчанлык ягында торуы билгеләнә. И. Нуруллин тарафыннан Тукайның Казан чоры иҗатының иң югары ноктасы буларак билгеләнә.

И. Нуруллин «Тукай эстетикасы турында мәкаләләр» китабында (1956) мәшһүр шагыйрьнең эстетик карашларының үсеш-үзгәрештә тикшерә. Тукайның эстетик карашларын ачыклауга аңа кадәр, беренчеләрдән булып, И. Пехтелев («Тукай поэзиясендә эстетик идеяләр») һәм М. Гайнуллин алына. И. Нуруллин исә әлеге мәсьәләне чишүдә яңа юллар таба, тулыландыра, темага үзенчә якын килә. Галим Г. Тукайның идея-эстетик карашларын югары бәяли, халык шагыйренең иҗат мирасы эстетик идеяләргә, әдәби иҗатның теге яки бу мәсьәләләренә караган фикерләргә гаять бай, дип белдерә. И. Нуруллин үзе бу хезмәтен шушы юнәлештә бер тәҗрибә итеп кенә карый һәм фәнни эзләнүләренә соңгы ноктаны куярга ашыкмый, үз хезмәтләренә карата: «зур проблеманы хәл итүдә соңгы сүз булудан әле ерак тора» [2, б. 4], – дигән фикер әйтә.

Тукай әсәрләрендәге халыкчанлык, реализм, әдәбиятның иҗтимагый роле, әдәби тәнкыйть принциплары, форма һәм эчтәлек, әдәбият һәм халык иҗаты, рус әдәбияты һ.б. мәсьәләләр дә – галимнең игътибар үзәгендә. Аеруча Г. Тукайның революцион-демократик карашлары күз уңында тотылган. Габдулла Тукайның иҗат юлында XIX йөз татар әдәбияты, татар фольклоры һәм рус классик әдәбияты идея-эстетик үзенчәлекләре зур йогынты ясый, дип билгели галим һәм дәлилли дә. Әлеге фикерләргә «Халык әдәбияты» (1910) дип исемләнгән мәкаләләрен мисал итеп китерелә.

«Тукай иҗаты (Беренче рус инкыйлабы чоры)» (1964) дип исемләнгән хезмәттә Тукайның идея-эстетик карашлары Беренче рус инкыйлабы илдә тудырган иҗтимагый-сәяси шартлар белән бәйләнештә карала һәм Тукай революцион-демократ шагыйрь буларак бәяләнә. Галим аның шундый булып өлгерүендә Кырлайдагы тормышы зур роль уйный дип саный. Китапта Тукайның хатар халык авыз иҗатына булган мәхәббәте, аерым алганда халык җырларын яратуы ана назыннан мәхрүм булган балачак нәтиҗәсендә барлыкка килгән дип нәтиҗә чыгарыла.

Моннан тыш, И. Нуруллин тарафыннан Г. Тукай иҗатының идея-эстетик үзенчәлекләре XIX гасыр татар әдәбиятына хас булган мәгърифәтчелек карашларына йөз тотып формалашкан дигән фикер әйтелә; иске карашлы дин әһелләрен, артталыкны яклаучыларны фаш итүне, наданлыкны артка өстери торган көч итеп күрсәтүне шагыйрьнең бер максаты итеп алуы языла.

И. Нуруллин «Тукай эстетикасы һәм рус әдәбияты» (1955) мәкаләсендә рус әдәбиятындагы идея-эстетик үзенчәлекләрне шагыйрьнең якыннан белүе һәм аның карашлары формалашуга моның зур йогынты ясавын ассызыклый; аның реализм, халыкчанлык, әдәби тәнкыйть, шагыйранә осталык һәм башка эстетик идеяләр белән иҗатының башлангыч чорында ук таныш булуын сөйли. Иҗатына бигрәк тә Крылов, Кольцов кебек рус әдәбияты вәкилләренең йогынтысы зур булуын күрсәтә. Алда телгә алынган ике рус әдипләренең әсәрләрен тәрҗемә итү Г. Тукайда турылыкка, хаклык тойгыларына юл ача, чынбарлыкны реалистик сурәтләргә алыну омтылышы уята, ди. Шагыйрьнең әлеге омтылышларына галим уңай бәя бирә:

«Тукайның рус әдәбиятыннан алып эшләнгән тәрҗемәләре, файдаланып язылган әсәрләре, рус әдәбияты һәм аның классик язучылары, әдәбия шедеврлары турында әйткән фикерләре - болар барысы да татар әдәбиятын рус язучылары һәм тәнкыйтьчеләре тарафыннан эшләп чыгарылган алдынгы эстетик идеяләр белән сугару кебек максатка хезмәт иттеләр» [2, б. 68].

Рус әдәбияты идея-эстетик карашларының Габдулла Тукай иҗатына ясаган йогынтысын тикшергәч, И. Нуруллин мондыйрак нәтиҗәләр чыгара:

– шагыйрь рус әдәбияты белән якыннан таныш булганга күрә, идея-эстетик карашлары тиешле югарылыкта һәм шуларныкына охшаш формалаша;

– Тукайны өйрәнгән хезмәтләрдәге фикерләр дәлилле, тормышчан фактлар белән расланырга тиеш;

– иҗат эшендә Тукай кебек чын талантлар гына калырга тиеш;

– татар әдәбияты рус әдәбияты белән тыгыз бәйләнештә үскәндә генә уңышлы юл алыр;

– рус дәүләте җитәкчелеге булганда гына, татар халкы үсешкә ирешә ала.

Соңгы бәхәсле фикерне чор идеологиясенең басымы, социалистик җәмгыятьтә фән белән шөгыльләнү, аның таләпләренә буйсыну белән генә аңлатып була. И. Нуруллинның Үзгәртеп кору елларындагы чыгышлары асылда аның башкачарак караштa торганлыгын күрсәтте.

Тукай фәненә шагыйрь турында хикәяләр язу аша кереп, алга таба Тукайчы галим буларак үскән И. Нуруллин әлеге өлкәгә үзеннән бәяләп бетергесез зур өлеш керткән. Бүгенге көн галимнәре өчен дә И. Нуруллин хезмәтләрен тирәнтен өйрәнү, шәхси, фактик, чор йогынтысында формалашкан фикерләрен аерып алып тикшерү әһәмиятле.

ӘДӘБИЯТ

1. Нуруллин И. Тукай эстетикасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1956. 68 б.
2. Нуруллин И. Шагыйрьне өйрәнү юлында // Казан утлары. 1977. № 7. 155 б.

## Г. ТУКАЙ ӘДӘБИ МУЗЕЕНДА ЯҢА ЭКСПОЗИЦИЯ – ЗАМАН ТАЛӘБЕ

***Төхфәтова Г.Ф.***

Статья посвящена проблемам создания новой экспозиции Литературного музея Г. Тукая, ее теоретическим и практическим аспектам.

The report is devoted to the problems of creation of the Gabdulla Tukay Literary Museum new exhibition, its theoretical and practical aspects.

Г. Тукай әдәби музее, шагыйрьнең тууына 100 ел тулу уңаеннан, Татарстан Республикасының Дәүләт берләштерелгән музее (хәзерге Татарстан Республикасы Милли музее) филиалы буларак 1986 елда ачыла. Музейның ачылышына кадәр үк татар халык шагыйренең тормышы һәм иҗаты төрле музей экспозицияләрендә чагылыш таба: ТАССРның Дәүләт музеенда (хәзерге вакытта ТР Милли музее), М. Горький музеенда, Ш. Камал музей-фатирында, ТР Арча районы Яңа Кырлай авылындагы музей комплексында, Кушлавыч авылындагы Тукаевлар йортында**.**

Шагыйрьнең Казандагы әдәби музее берничә гасырлар дәвамында Казан татарларының шәһәр мәдәниятен саклаган, аның социаль-икътисади, сәяси һәм мәдәни тормышы кайнаган Иске Татар бистәсендәге «Шамил йорты»нда оештырыла. Бинаны ремонтлау, шагыйрь белән бәйле экспонатларны туплау, экспозиция төзү өлкәсендә Л.Г. Вәлиева, Д.Б. Баһаветдинова, В.М. Глазков, В.З. Дәүләтшина, Н.Х. Тур, Н.П. Нефедова, Э.П. Хәмидуллина һ.б. актив эш алып бара. Г. Тукайның тууына 110 ел тулу уңае белән – 1996 елда һәм 120 ел тулу уңае белән 2006 елда музей экспозициясенә үзгәрешләр кертелә.

Экспозициядә Г. Тукайның тормышы, иҗат юлы киң һәм мул яктыртылган. Музей заллары хронологик тәртиптә урнаштырылган. Экспозициядә шагыйрьнең шәхси әйберләре, фоторәсемнәре һәм үзе исән чагында дөнья күргән басмалары, шагыйрь хезмәттәшлек иткән газета-журналлар, Г. Тукай даирәсеннән булган шәхесләрнең документлары, алар белән бәйле предметлар урын алган.

Музей, үз ишекләрен ачкан көннән башлап, бөек шагыйрь Г. Тукай иҗатын сөючеләрне берләштерүче үзәк кенә булып калмыйча, хәзерге татар сәнгате һәм мәдәнияты вәкилләренең иҗатын тәкъдим итүче үзенчәлекле мәдәни учак вазифасын үти. Биредә даими рәвештә әдәби-музыкаль кичәләр, очрашулар, концертлар, лекцияләр оештырыла. Татар әдәбияты, мәдәнияты һәм сәнгатенә багышланган төрле күргәзмәләр ачыла.

Бүгенге көндә Г. Тукай әдәби музеенда яңа экспозиция булдыру – заман таләбе. Бер яктан, музей чараларының үсеше, экспонатларны тәкъдим итү юлларының киңәюе, электрон, интерактив технологияләрнең бу өлкәдә актив кулланыла башлавы үз таләбен куйса, икенче яктан, шагыйрьнең тормышына һәм иҗатына багышланган яңа экспозиция төзү иҗтимагый, мәдәни, әдәби, фәнни шартлар белән билгеләнә.

Бу, беренчедән, XX гасыр ахырында илебездә булган иҗтимагый, сәяси, икътисади үзгәрешләр, демократик үзгәртеп корулар. «1990 еллар башында Тукай феноменын, шагыйрьнең шәхесен, әдәби мирасын аңлауда яңа чор башлана» [1, б. 83]. Экспозиция төзелгән чорның сәяси нормалары, идеология белән тыгыз үрелгән принциплары Тукай иҗатының тирән катламнарын актарып бөтен тулылыгы белән фәнни өйрәнүне һәм музей залларында чагылдыруны чикли. Кызганычка каршы, «читтә торырга омтылса да, музей һәрвакытта да билгеле бер сәяси караш тәгълиматына буйсына» [3, с. 33]. Хәзерге экспозициядә Г. Тукайның дини һәм сәяси карашларының чагылмавы, цензура белән бәйле материалларның урын алмавы заман, идеология тәэсире дип карарга

җирлек бирә. Шушы уңайдан, яңа экспозициядә шагыйрьнең дөньяга карашын, Коръән тәгълиматына мөнәсәбәтен, иҗатында Шәрык классикасының күпгасырлык бай традицияләрен иҗади үстерү юлларын, милли поэтик фикерләү үзенчәлекләрен көнбатыш эстетикасы һәм рус әдәбияты белән кушу үзенчәлекләрен һ.б. чагылдыру таләп ителә.

Икенчесе – Тукай фәненең үсеше. Г. Тукайның тәрҗемәи хәле, әсәрләренең язылу-басылу тарихы, төрле тарихи чорларда фәнни өйрәнелеше белән бәйле фактлар, шагыйрьнең сәнгатьчә фикерләве, иҗат ысуллары һ.б. мәсьәләләр соңгы өч дистә елда Т. Галиуллин, Х. Миңнегулов, Р. Ганиева, Н. Хисамов, З. Рәмиев, Д. Заһидуллина, Р. Исламов, Ж. Миңнуллин, Ф. Яхин, Ә. Алиева, Ф. Ибраһимова, Т. Гыйләҗев, Н. Гафиятуллина һ.б. галимнәрнең хезмәтләрендә тирән өйрәнелә, яңа мәгълүматлар белән тулыландырыла. Әдәби экспозицияне баетуга Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тарафыннан Г. Тукайның алты томлык академик басмасы, «Г. Тукай энциклопедиясе» әзерләнү дә, башка бик күп фәнни хезмәтләрнең нәшер ителүе дә, фәнни-гыйльми эшләр алып барылу да йогынты ясый.

Г. Тукай образының, иҗатының XX гасыр – XXI гасыр башы әдәбиятында, мәдәниятында яктыртылышы, бу өлкәнең, бер урында таптанмый, алга таба үсүе, киңәюе яңа экспозиция булдыруның актуальлеген тагын бер кат раслый. Тормышның төрле өлкәсендә бөек шагыйрь исеменә, иҗатына, образларына мөрәҗәгать итү аларның музей экспонатлары сыйфатларында саклануын һәм халыкка җиткерелүен дә таләп итә. Чөнки музей үлемсезлекне, хәтердә яшәүне тәэмин итүнең бер юлы булып тора. «Шагыйрь тормышы белән бәйле һәр урын, аның истәлеген саклаучы һәр музей аны безгә тагын да якынайта» [2, б. 16]. Бу уңайдан яңа экспозициядә Татарстан Республикасы Милли музее фондында саклана торган бай тупланмалардан файдалану планлаштырыла. Тукай образы һәм аның геройларының театр, музыка, рәсем һ.б. сәнгать өлкәләрендә чагылышын тәкъдим итүдә заманча электрон технологияләр дә ярдәмгә килә. Аларны экспозиция кысаларында куллану тәэсирлелекне арттыра, күрсәтелә һәм бирелә торган мәгълүматның күләмен киңәйтергә ярдәм итә.

Тукай исемен мәңгеләштерү мәсьәләсе аның төрле телләрдә, планетабызның төрле почмакларында яңгырашы белән дә бәйле. Бүгенге көндә музей тамашачыларының географиясе киңәю бу өлкәнең әһәмиятлелегенә басым ясый. Татарстанлыларда Тукай исеменең төрле телләрдә, төрле шәһәрләрдә, илләрдә яшәвен белү горурлык хисләре уятса, туган илгә, туган телгә мәхәббәт тәрбияләсә, ә килгән кунакларга музейда үзенең шәһәре, өлкәсе белән бәйле материал тәкъдим ителү татар әдәбияты белән кызыксыну уята. Бу уңайдан яңа экспозициядә интерактив глобус куллану планлаштырыла. Биредә Тукай китаплары нәшер ителгән өлкәләр, аның һәйкәлләре урын алган шәһәрләр, шагыйрь исеме бирелгән географик объектлар хакында мәгълүмат алып булачак.

Г. Тукай әдәби музее Татарстанның туристик картасында да әһәмияте урын алып тора. Тукай исеме Татарстан Республикасының бренды буларак тәкъдим ителергә тиеш. Тукай образы, әсәрләре, ул иҗат иткән геройлар – татар халкының милли горурлыгы.

Г. Тукай әдәби музеенда яңа экспозиция булдыруның актуальлеген истә тотып, музейның фәнни хезмәткәрләре тарафыннан яңа концепция әзерләнде. Яңа экспозициянең төп максаты – Г. Тукайны татар әдәбиятында, мәдәниятында тирән эз калдырган бөек шагыйрь буларак тәкъдим итү. Монда Г. Тукайның иҗатын тирәнрәк ачу таләп ителә: әсәрләре аша шагыйрьнең дөньяга карашын күрсәтү, эшчәнлегенең киңкырлылыгына, күптармаклылыгына, аларның тематик киңлегенә басым ясау, иҗатының фольклорга бәйләнешен күрсәтү.

Экспозициянең эчтәлеге Г. Тукайның әдәби әсәрләренә нигезләнә, ягъни шигырь һәм поэмаларының образлар системасы, сурәтләнгән вакыйгалар, тарихи шәхесләр һәм чор күренешләре аша ачыла.

Г. Тукай әдәби музеенда даими эспозиция дүрт залда урнашачак. Һәр зал шагыйрьнең бер әсәренә багышлана һәм сайланылган шигырь яисә поэма аша Г. Тукайның тормышы һәм иҗат үзенчәлекләре, шул чор татар халык мәдәнияте һәм тарихы күрсәтелә.

«Исемдә калганнар» залы, шагыйрьнең шул исемдәге автобиографик повестенә багышланып, Г. Тукайның тууы һәм балачагы белән бәйле вакыйгаларны, күренешләрне үз эченә ала. «Шүрәле» залында Г. Тукайның Җаек шәһәрендәге тормышы, бу чордагы әдәби һәм журналистлык эшчәнлеге сурәтләнә. Биредә ул беренче әсәрләрен иҗат итә, үзен әдәби мәйданда сынап карый. Г. Тукайның иң мәшһүр әсәре «Шүрәле» дә бу чорда языла. Шагыйрьнең Казандагы тормышы һәм иҗаты «Печән базары, яхуд

Яңа Кисекбаш» залында тәкъдим ителә. Биредә XX гасыр башындагы Казан мохите күрсәтелә. Казан шагыйрьнең татар мәдәнияты һәм әдәбияты күгендә, беркем белән дә чагыштырып булмаслык, үз урынын тапкан җире буларак бирелә. Тукайның исемен мәңгеләштерү темасы «Ашкынамын мәңгелеккә» залында аның китаплары, әсәрләренең иллюстрацияләре, шагыйрь образын гәүдәләндерүгә багышланган фильм, спектакльләр белән бәйле материаллар аша ачыла. Шулай ук балалар өчен «Тукай экиятләре» дип исемләнгән интерактив зал, Тукай китаплары һәм аңа багышланган басмалар, газета-журналлар, аудио-видио материаллар тупланган «Тукай үзәге» оештыру планлаштырыла.

Г. Тукай әдәби музееның яңа экспозициясе тиз арада тормышка ашырылыр һәм музей әдәбият сөючеләр тарафыннан уңай кабул ителер дип уйлыйбыз.

ӘДӘБИЯТ

1. Гыйлаҗев Т.Ш. Ике гасыр чигендә Тукай фәне // Гыйлаҗев Т.Ш. Әдәби мирас: тарих һәм заман. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 206 б.

2. Карташева Е.И. Татарстанда Габдулла Тукай музейлары. Сәяхәтнамә. Казан: Заман. 16 б.

3. Шулепова Э.А. Взаимодействие музея и общества как социокультурная проблема // Материалы Международного музейного форума в Казани «Музей и общество: современные модели интеграции. 14–18 сентября 2010 г. В 2 т. Т. 1. Казань: Фолиант, 2011. 324 с.

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ҺӘМ КЫЯМ КАРЫЙ ЗӨЛФОКАРОВ

***Тябина Л.И.***

Даются сведения о современнике Габдуллы Тукая, каллиграфе, педагоге и фотографе Кыяме Карый (Кывамметдине) Зульфокарове (1870–1921), который сделал первые фотографии тукаевских мест.

The article is dedicated to Gabdulla Tukay’s contemporary, calligrapher, pedagogue and photographer Kyyam Kary (Kyvammetdine) Zulfokarov (1870–1921), who made the first photos of Tukay’s places.

Габдулла Тукай әдәби музее экспозициясендә күренекле татар шагыйренең тормышы һәм иҗатын яктырткан экспонатлардан тыш, аның замандашлары һәм фикердәшләренә кагылышлы документлар, фотосурәтләр, предметлар да урын алган. Музейга килүчеләргә Ф. Әмирхан, Г. Камал, С. Сүнчәләй, С. Рәмиев, Г. Коләхмәтов, Х. Бәдыйги, К. Мотыйги, М. Бигиев, Г. Кариев, Ә. Хәсәни, З. Хәсәни һ.б.лар турында мәгълүмат бирелә. Экспозициядә XX гасыр башы татар җәмгыятенең һәм мәдәниятенең яңарыш чоры чагылдырылган. Шул җәһәттән чыгып, бу чорда татар балалар әдәбиятына нигез салыну, алар өчен татарча китаплар чыгару, татар телендә вакытлы матбугат һәм татар журналистикасы барлыкка килү, татар_фольклорын җыю һәм өйрәнүгә кагылышлы материалларга урын бирелгән. Ләкин экспозиция кысаларында гына XX гасыр башы татар мәдәниятен тулысынча күзалларга мөмкин түгел. Г. Тукайның замандашлары һәм чордашлары, аның тормышы, иҗаты һәм эшчәнлеге белән бәйле күп шәхесләрнең исемен музейга килүчеләр экскурсия барышында гына ишетә алалар. Экспозициядә әдип Зариф Бәшири, нәширләр Иван Харитонов һәм Гыйльметдин Шәрәф, цензор, галим, тәрҗемәче Николай Ашмарин белән бәйле экспонатлар булмаса да, аларның Тукай иҗаты һәм тормышындагы роле, шәхсән үзләре турында экскурсоводлар тирән мәгълүмат бирә ала. Шундый шәхесләрнең тагын берсе – каллиграф, педагог һәм фотограф Кыям Карый (Кывамметдин) Камаледдин улы Зөлфокаров (1870–1921).

Безнең көннәрдә Кыям Карый Зөлфокаров исеме халыкка кайтарылды. Бу өлкәдә филология фәннәре докторы, профессор, Г. Ибраһимов исемендәге ТӘһСИнең баш фәнни хезмәткәре Марсель Әхмәтҗанов зур эш башкара. Ул Кыям Карый Зөлфокаров тормышын һәм эшчәнлеген тирәнтен өйрәнүчеләрнең беренчесе. М. Әхмәтҗанов аның татарлар арасында беренче фотографларның берсе буларак ролен ассызыклый: «К. Зөлфәкаровның фотограф буларак революциягә кадәр танылган булуын белүчеләр әлегә бар микән? Аның балаларында ул төшергән негатив пластинкалар әле дә саклана. Бу кешенең безнең культура өчен иң игелекле хезмәте, Тукай үлгәннән соң Казан арты авылларына чыгып, бөек шагыйрь шәхесе белән бәйле истәлекле урыннарны рәсемгә төшереп алуы булган Шуның хезмәте аша инде менә ничә еллар татар укучылары

Кушлавычның, Өчиленең һәм Кырлайның Тукай дәверендәге күренешләрен күз алдына китерәләр» [1, б. 33].

Шулай ук Кыям Карый Зөлфокаров тормышы һәм эшчәнлеге өстендә фәнни тикшеренүләр алып барган И. Рәми, Р. Даутов, Р. Абзалина, Н. Исмәгыйлев, Н. Гәрәева, Р. Шәмсутов, Л. Латыйпованы атап узарга кирәк [5, б. 81].

XX йөз башы гарәп каллиграфиясенең күренекле остасы Кыям-карый Зөлфокаровка багышланган беренче басмага тукталмый мөмкин түгел. Рус телендә 2011 елда «Издательство Еникеевой» нәшриятында басылган «К. Зульфакари. Тюркская касыда "Мавлид ан-Наби"» китабында К. Зөлфокаров һәм аның мирасы хакында сүз башы, «Мәүлүд» китабының рус теленә тәрҗемәсе, 1912 елда аның тарафыннан әзерләнеп һәм каллиграфик бизәлеп басылган җыентыкның факсимиле басмасы, искәрмәләр урын алган. Шулай ук китапка кушымтада К. Зөлфокаровның фотопортреты, гаиләсе белән төшкән фотосурәтләре, Г. Тукай белән бәйле урыннарның фотографияләре, аның китаплары, дәреслекләре һәм матур язу дәфтәрләренең тышлыклары бирелгән. Китап К. Зөлфокаровның оныкчыгы Рөстәм Латыйповның матди ярдәме белән басылган.

Бу шәхес белән Г. Тукайның таныш булу-булмавы, аларның очрашуы турында чыганаклар юк. Ләкин шагыйрьнең әсәрләрендә К. Зөлфокаров исеме берничә тапкыр очрый. Шулай ук Г. Тукайның «Мәҗмугаи әсәрләр»е басылу тарихын өйрәнгәндә дә бу шәхес белән бәйле мәгълүматларга тап булабыз.

Кыям Карый Зөлфокаровның эшчәнлеге турында Г. Тукай Казанга килгәнче үк хәбәрдар була. Җаек шәһәрендә чыга торган «Фикер» газетасының 1906 ел 3, 21 июль (24, 27) саннарында Г. Тукайның «Алай-болай» дип аталган фельетоны басыла. 24 нче сандагысына «Биик усал» дигән имза куелган, 27 нчедәгесе имзасыз бирелгән [9, б. 341]. Тукай матбугат дөньясында барган бәхәсләрне сурәтләү аша шул чорның күп кенә проблемаларын ача: дин әһелләренең чын йөзе, хөр фикерле һәм реакцион карашлы татар газеталарының бер-берсенә каршы торышы, дин, шәригать һәм милләт турында уй-фикерләрнең вакытлы матбугатта чагылышы. Фельетонда нәшир һәм мөхәррир Әхмәтҗан Сәйдәшев, Беренче Дәүләт Думасы депутаты Сабир Хәсәнов, әдип Садыйк Иманколый һ.б. конкрет шәхесләр искә алына [3, б. 294]. Тукай, исемен атамаса да, Кыям Карый Зөлфокаров турында да үз фикерен әйтеп үтә: «Эш «дәһри вә динсез» дип кычкырышырга калса, без Садыйк мулла әл-Иманколыйны сүтәбез дә, урынына Кязиб мулла әл-Имансызыйны утыртабыз да куябыз; бу бигайниһи «Лап-лап-лап»тагы Золмәтетдин әл-Ноксаный шикелле була да кала» [11, б. 69]. Бу урында берничә искәрмә биреп үтү урынлы. «Лап-лап-лап» – «Бәянел-хак» газетасы. Золмәтетдин – диннең явызлыгы. Әл-Ноксаный – кимчелекле. «Золмәтетдин әл-Ноксаный» дип язганда Тукай Кыям Карый Зөлфокаровны «чеметкән». Фельетон беренче тапкыр дүрттомлыкның 3 нче томына кертелгән [9, б. 41]. Бу басмада Кыям Карый Зөлфокаров турында бернинди дә искәрмә юк. Бары 1985–86 елгы биштомлыкта гына Тукайның нәкъ К. Зөлфокаровны күздә тотуы турында мәгълүмат бирелә [13, б. 332].

Дүрт елдан соң, Казанга килгәч, Г. Тукай тагын бер әсәрендә К. Зөлфокаров образына мөрәҗәгать итә. Бу шагыйрь тарафыннан 1910 елда язылган «Керешү хотбәсе» исемле фельетон-пародия. Ул «Ялт-йолт» журналының 1910 елгы 5 нче санда (15 май) «Яңа хотбә» исеме астында «Имам хатиб» имзасы белән басылган. «Ахыры бар» дип куелган булса да, ахыры барлыгы билгеле түгел. Бу памфлет мәчетләрдә укыла торган хотбәләргә (вәгазь) пародия рәвешендә язылган. «Яшен ташлары»нда (1 кисәк), кайбер үзгәртүләр кертеп, «Керешү хотбәсе» исеме белән урнаштырылган. Шулай ук «Яңалиф» басмасының 3 нче томына (1931) кертелгән [8, б. 59].

«Керешү хотбәсе» («Керешү сүзе») эчтәлеге, юнәлеше һәм әдәби алымнары белән «Алай-болай» фельетоны белән яңгырашлы. Икесендә дә Тукай сатирасы утына XX йөз башындагы татар мохите алына. Шул ук шәхесләр, шул ук проблемалар. «Керешү хотбәсе»ен «Кешене таш һәм туфрактан яраткан, аны баш, борын һәм колак белән зиннәтләгән затка мактау» дип башлый шагыйрь. Алга таба ул шайтан башкарган гамәлләргә күчә, аларны атап үтә, аңа ләгънәт укый. Шайтанның күпсанлы гамәлләре арасында тагын берсен атый: «Гавам Зөлтатари дигән маймылга төрле мәкамнәр (Коръән укый торган көйләр) өйрәтте» [12, б. 115]. Г. Тукай фельетонда «Ялт-йолт»-ның 1910 елның 15 апрель санында басылган игъланнан файдаланган күрәсең. Игъланның тексты мондый: «Фәкать 15 ел эчендә яшь татар балаларын мәүлүд укырга һәм үземчә маймылланырга өйрәтеп йиткерәм. Баласын укыткан кешеләргә бер шешә

маэ зәмзәмел шәриф тә буш биреләдер. Әлкари Гаваметдин Зөлкафари» [12, б. 315]. 1956 елгы дүрттомлыкта «Мәймүнәл-гавамәз-зөлтатария – Казандагы Кыйвам Зөлфөкари исемле надан бер кари, Коръәнне төрле көйләргә салып укыган кеше. Надан булганга күрә, Тукай аның исемен “гами, надан” мәгънәсендә йөри торган “гавам” сүзе белән алыштырган, башкаларга ияреп (маймулланып), төрле көйләр көйләгәнгә күрә, “мәймүн” дип атаган» дигән искәрмә бирелә [10, б. 237]. 1985–86 елгы биштомлыкта да шул мәгълүмат кабатлана.

2015 елгы академик басмага «Алай-болай» фельетоны [14, б. 76] һәм «Керешү хотбәсе» памфлеты [15, б. 119] кертелгән. Кыям Карый Зөлфокаров турында «Керешү хотбәсе» белән бәйле рәвештә искәрмә бирелә: «Казанда яшәгән, Коръәнне яттан төрле мәкам белән укыган, педагог, хаттат» [15, б. 354].

...Тукай надан дип санаган, берничә тапкыр сатира утына алган, «Коръән» укуыннан көлеп, иронияле сүзләр кыстырып мәкаләләрендә «Золмәтетдин әл-Ноксаный» «Зөлтатари» дип атаган Кыям Карый Зөлфокаров кем булган соң? Бу шәхес турында соңгы елларда басылган төрле чыганаклардан түбәндәгеләрне беләбез. Зөлфокаров Кыйвамкарый Камалетдин улы – каллиграф, педагог, дин эшлеклесе, дәреслекләр авторы, һәвәскәр фотограф. 1870 елда Төгәлбай авылында (Татарстан Республикасы, Әлки районы) туган, Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә белем алган. «Төрле һөнәрләр белүе, музыкага һәвәслеге белән аерылып торган. Аның каләме белән ташбасма китапларның текстлары язылып бастырылган. К. Зөлфәкаров заманында каллиграф-художник буларак та танылган» [1, б. 32]. Аның тарафыннан каллиграфик рәвештә язылган һәм бизәлгән «Үтәк шәҗәрәсе», «Мәүлед китабы», «Әмали гакыйдәсе», «Хөсни хат» китаплары, шамаилләр басылган [1, б. 115]. Кызганычка каршы, З. Гыйләҗевның XX гасыр башында басылган татар китапларына багышланган «Татарская литература начала XX века в книжных изданиях» дигән хезмәтендә аның бу китаплары турында мәгълүмат бирелмәгән [4].

Кыям карый Зөлфокаров басмалары арасында иң кызыклысы – хаттат үзе әзерләгән, 1912 елда Казанда В.В. Вараксин типографиясендә Хөсәенов вәрәсәсе тарафыннан бастырылган «Касыйдәи мәүледен-нәби саллалаһи галәйһи вәсәлләм» китабы. Үз вакытында популяр булган китапның төзүчесе дә, бизәүчесе дә К. Зөлфокаров. Татар телендәге иң кыйммәтле басмалар – татар басма китабының җәүһәрләре турындагы 2013 елда дөнья күргән «Татар китабы.Татарская книга» каталог-альбомына Зөлфокаровның «Мәүлед-нәби» китабы да кертелгән [7, б. 126]. XX йөзнең беренче чирегендә бу җыентык казан татарлары арасында популяр була. Безнең көннәрдә дә Мәүлет бәйрәмендә текстлар ул төзегән шушы җыентыктан укыла [5, б. 7].

К. Зөлфокаров Казанның 17 нче мәхәллә мәчетендә мөәзин булып торган, «Коръән»не төрле мәкамнәр белән укый белгән. Замандашлары аның кубызда һәм курайда яхшы уйнавы, берничә тапкыр хаҗга баруы турында искә ала [5, б. 4]. XIX гасырның соңгы чирегендә, «Касыймия» мәдрәсәсендә эшләү дәверендә Зөлфокаров Галимҗан Баруди йогынтысында була, үз заманының иң алдынгы һәм актив кешеләре белән аралаша. Татарлар арасында беренче фотографлардан берсе булуы аның яңалыкка тартылуын исбат итә. Зөлфокаров төшергән берничә фотография Габдулла Тукай исеме белән бәйле. Шагыйрьнең үлеменнән соң өлкән улы Салих белән ул Кушлавыч, Кырлай һәм Өчилегә барып Тукайның балачагы белән бәйле урыннарны фотога төшерә [5, б. 8]. Фотографияләр 1914 елда басылган «Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре» китабында дөнья күрә. Китапта барысы 9 фотография бирелгән. Өчесе – Г. Тукайның 1908, 1911 (Әстерхан) һәм 1913 (Клячкин хастаханәсе) елларда төрле фотографлар тарафыннан алынган фотосурәтләре. Алтысы – Зөлфокаров ясаган фотолар: Г. Тукай туган Кушлавыч авылы; Кушлавычта Г. Тукай туган йорт; Кырлай авылында Фәтхрахман хәзрәт йорты (бу йортта Г. Тукай абыстайдан дәресләр ала); Өчиле авылында Зиннәтулла хәзрәт йорты (бу йортта Г. Тукайның әнисе Бибимәмдүдә туган; әнисе үлгәч бәләкәй Габдулла бу йортта торган; 1912 елда Өчилегә кайткач та, Тукай бу йортта булган); Кырлай авылында Г. Тукай укыган малайлар мәктәбенең ике фотосы (берсендә мәктәп Кырлай мәчете фонында). Бу фотосурәтләр Г. Тукай белән бәйле күп басмаларга, шул исәптән юбилей альбомнарына да кертелгән.

Г. Тукай әдәби музее экспозициясендә К. Зөлфокаров төшергән шул фотоларның күчермәләрен «Шагыйрьнең балачагы» залында күрергә мөмкин. Залда өч фотография – Кушлавычта Г. Тукай туган йорт, Кырлай авылында Г. Тукай укыган малайлар

мәктәбе, Өчиле авылында Зиннәтулла хәзрәт йорты фотографияләре урын алган. Зиннәтулла хәзрәт йорты төшерелгән фотода алгы планда өч кеше: Г. Тукайның әнисенең энесе (Тукайның абзасы) Кәшфелкәбир Әмиров, аның кызы Нурания (Г. Тукайның туганнан туган сеңлесе) һәм фотографның улы Салих [5, б. 99]. (Кәшфелкәбир Әмиров йорты янында төшкән К. Зөлфәкаровның улы Салих (1900–1981), озын гомер кичереп, Шевченко шәһәрендә вафат була [1, б. 33]).

Кушлавычта Г. Тукай туган йорт фотосурәтендә шулай ук шагыйрьнең замандашын күрәбез. 1913 елда, фотога төшерер өчен бу йортның шул вакыттагы хуҗасын, махсус киендереп, кулына көрәк тоттырып йорт каршына бастыралар. Тукай туган йорт бушап калгач, анда Тукаевларга якын туган тиешле 11 балалы ишле гаилә кереп урнашкан. Фотография тарихы турында ул гаиләнең нәсел дәвамчысы Ләлә Яруллина «Түгәрәк уен» журналында «Нәсел башыбыз – Кушлавычта» дигән хәтирәләре белән уртаклаша [17, б. 32].

Кызганычка каршы, бу фотографияләрнең төп нөсхәләренең саклану урыны билгесез. К. Зөлфокаров мирасын Татарстан Республикасы Милли музее һәм Татарстан Республикасы Милли китапханәсе фондларында очратырга мөмкин. Милли музейда К. Зөлфокаров эшләгән берничә шамаилнең берсе саклана. Ул «Коръәннең шифа аятьләре» дип атала. Шамаилдә барысы 6 аять кулланылган. Милли китапханә фондында исә К. Зөлфокаровның югарыда искә алынган «Касыйдәи мәүледен-нәби саллаллаһы галәйһи вәсәлләм» китабы урын алган [7, б. 126].

XIX гасыр ахыры – XX башы татар мәдәниятында каллиграф, педагог, фотограф, дин эшлеклесе Кыям-карый Зөлфокаров, һичшиксез, билгеле бер урын алып тора. Г. Тукай әдәби музееның яңа экспозициясендә шагыйрь замандашлары арасындагы үзенчәлекле бу шәхескә дә урын бирелергә тиеш дип саныйбыз.

ӘДӘБИЯТ


1. Әхмәтҗанов М. Археографик экспедицияләр һәм Габдулла Тукай хәтирәләрдә. Казан: Множительный центр Института истории АН РТ, 2015. 131 б.
2. Габдрафикова Л.Р. Татарское буржуазное общество: стиль жизни в эпоху перемен (вторая половина XIX – начало XX века). Казань: Татар. кн. изд-во, 2015. 368 с.
3. Габдулла Тукай әсәрләре: сүзлек-белешмәлек. Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. 479 б.
4. Гилазев З. Татарская литература начала XX века в книжных изданиях. Казань: Алма-Лит. 2005. 160 с.
5. Зульфакари Кывам-карый. Тюркская касыда «Мавлид ан-Наби» / составитель Р.И. Еникеева. Казань: Издательство Еникеевой, 2011. 168 с.
6. Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре (XX йөз башы): Биобиблиографик сүзлек. Казан: Алма-Лит, 2005. 275 б.
7. Татар китабы = Татарская книга: альбом / төз.-авт.: Р.Ф. Мәрданов, И.Г. Һадиев. Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. 504 б.
8. Тукай әсәрләре. 4 томда. 3 том. Казан: Яңалиф, 1931. 208 б.
9. Тукай Г. Әсәрләр. 4 томда. 3 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 1956. 359 б.
10. Тукай Г. Әсәрләр. 4 томда. 4 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 1956. 288 б.
11. Тукай Г. Әсәрләр. 5 томда. 3 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 392 б.
12. Тукай Г. Әсәрләр. 5 томда. 4 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 352 б.
13. Тукай Г. Әсәрләр. 5 томда. 5 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 368 б.
14. Тукай Г. Әсәрләр. Академик басма. 6 томда. 3 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 415 б.
15. Тукай Г. Әсәрләр. Академик басма. 6 томда. 4 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 431 б.
16. Шамаили из коллекции Национального музея Республики Татарстан (Конец XIX – начало XX вв.). Собрания профессоров И.М. Покровского и Н.Ф. Катанова / автор-составитель Р.А. Абзалина. Казань, 2003.
17. Яруллина Л. Нәсел башыбыз – Кушлавычта // Түгәрәк уен. 2015. № 3. Б. 32–33.


## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИҖАТЫНДА ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ МИЛЛИ ФОЛЬКЛОРЫ ҺӘМ МИФОЛОГИК КАРАШЛАРЫ


***Фазлетдинов И.К.***



Данная статья посвящена исследованию влияния национального фольклора и мифологических воззрений татарского народа на творчество Габдуллы Тукая, а также изучению деятельности поэта в области фольклористики. Научному анализу подвергается его лекция «Халык әдәбияты» («Народная литература»), исследуется преемственность фольклорных традиций в поэзии Габдуллы Тукая в образах, мотивах, художественных средствах. Особый интерес представляет изучение влияния мифологических воззрений на творчество поэта, в котором тесно перепле-

лись как исконно тюркские, так и арабско-мусульманские мифологические образы, обретшие новое смысловое значение.

This article investigates the reflection of national folklore and mythological beliefs of the Tatar people in the works of Gabdulla Tukay and the study of the poet in the field of folklore. Scientific analysis is his lecture «Folk literature». We investigate the continuity of folk traditions in the poetry of Gabdulla Tukay in the images, motifs and artistic means. Of particular interest is the study of the influence of mythological views on the work of the poet, which is closely intertwined as originally Turkic, and Arab-Muslim mythological images, which gained a new semantic meaning.

Бөек әдибебез Габдулла Тукайның поэтик талантының тамырлары халык авыз иҗатына килеп тоташуы – бәхәссез хакыйкать. Татар халык дастаннары, әкиятләре, җыр-бәетләре тәэсирендә тәрбияләнгән Тукай үзе дә милли фольклорыбызны өйрәнүгә, аны үз әсәрләрендә файдаланып, популярлаштыруга зур өлеш кертә.

Безгә калса, Габдулла Тукай белән милли фольклор мөнәсәбәтләрен тикшерүне ике юнәлештә алып барырга кирәк. Боларның беренчесе бөек әдипнең фольклористика өлкәсендәге эшчәнлеген өйрәнү булса, икенчесе – аның иҗатында фольклор традицияләренең, сюжетларының һәм мотивларының күчемлелеген ачыклау.

Беренче мәсьәләгә ачыклык кертер өчен, әдипнең 1910 елда Казанның «Шәрык клубы»нда укылып, Харитоновлар типографиясендә аерым китап булып дөнья күргән «Халык әдәбияты» лекциясенә, шул ук елда «Сабах» нәшрияты тарафыннан «Милләт» типографиясендә басылып чыккан «Халык моңнары» җыентыгына һәм Тукай тарафыннан Уральскида яшәгән чорында төзелгән «Җырлар дәфтәре»нә мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Күренекле фольклорчы Хәмит Ярми билгеләвенчә, «Халык әдәбияты» лекциясе «татар халык иҗатын фәнни тикшерү өлкәсендә беренче зур хезмәт буларак саналырга хаклы» [8, б. 46]. Монда әдип «халык әдәбияты» төшенчәсенә төгәл билгеләмә бирә, аның эчендә классификация ясап, халык хикәясе, әкият, җыр, бәет, мәкаль кебек мөстәкыйль жанрларны аера. Шунда ук әлеге фольклор жанрларына хас төп үзенчәлекләр, халык әдәбияты әсәрләрен язма әдәбияттан аерып торучы үзәк сыйфатлар билгеләнә. Тукай халык җырларының формасына, төзелешенә, фольклордагы вариантлашу күренешенә аерым игътибар бүлә [5, б. 259–273]. Хезмәттә тарихта беренче тапкыр «Тәфкилев», «Ашказар», «Сак-сок», «Касимский Ибрай», «Җизнәкәй», «Башмак» көйләренең барлыкка килүен тасвирлаучы риваятьләр китерелүе [5, б. 257–258] аның фәнни әһәмиятен тагын да артыра.

«Халык моңнары» җыентыгына исә шагыйрь үзе халыктан туплаган такмак һәм лирик озын җыр үрнәкләрен кертә. Шунда ук 72 юллык «Сак-сок» бәете дә урын ала [5, б. 277–292]. «Җырлар дәфтәре»ндә әдип әлеге жанрга караган 28 әсәрне урнаштыра [5, б. 295–340]. Милли фольклористикабыз тарихында Г. Тукайның роле зур булса да, Хәмит Ярми билгеләвенчә, ул «халык иҗаты әсәрләрен туплау, аларны язып алу эше белән махсус рәвештә, ягъни фольклорчы буларак шөгыльләнмәгән булырга тиеш» [8, б. 51].

Икенче мәсьәләгә, ягъни әдип иҗатында фольклор традицияләренең күчемлелегенә килгәндә, «Г. Тукайның шигырьдә халык иҗаты әсәрләренә мөрәҗәгать итүе аның 1907 елда язылган “Ишек бавы” әсәреннән башланып китә» [8, б. 53]. Әлеге шигырь туй йоласындагы «Ишек бавы» җырлары тәэсирендә иҗат ителә. Шагыйрьнең шушы ук елда язылган «Авыл хатынының бала тибрәткәндәге өметләре» [4, б. 119–120] әсәрендә дә бишек җыры традицияләре дәвам иттерелә. Ягъни фольклорның әдип иҗатына йогынтысы нәкъ шушы йола поэзиясенә хас алымнарының, сурәтләү үзенчәлекләренең Тукай шигъриятенә берегеп китүеннән башлана.

Бөек әдибебез иҗатына милли мифологиянең тәэсирен ачыклау аерым әһәмияткә ия. Белүебезчә, Г.Х. Гыйльманов, Л.Ә. Кәриева кебек белгечләрнең соңгы елларда дөнья күргән хезмәтләрендә мифологияне фольклордан аерып карау, аны борынгы кешенең художестволы фикерләү җимеше булудан бигрәк, аның аңындагы Дөнья моделе итеп исәпләү омтылышы ачык күренә [3, б. 3; 2, б. 31–33]. Без дә әлеге караш белән тулысынча килешәбез һәм «мифология – жанр түгел, ә фикерләү рәвеше» [2, б. 32] дигән сүзләргә кушылабыз.

Күренекле галим Ф.И. Урманче татар мифологиясендә өч катламны: борынгы төрки һәм борынгы көнчыгыш, гарәп-мөселман һәм көнбатыш Европа пластларын аера; болардан башка аңа һинд-иран мифологиясенең көчле йогынтысын билгеләп үтә [7,

б. 300–301]. Шул ук вакытта галим «татар фольклоры художество системасы чыганакларында борынгы төрки катлам һәр чорда да хәлиткеч һәм иң мөһиме булып кала» дигән нәтиҗәгә килә [7, б. 323].

Габдулла Тукай иҗатына без борынгы төрки һәм Ислам белән кергән гарәп-мөселман мифологик катламнарының җимешле тәэсирен күрәбез. Мәсәлән, үзенең «Чын вә Ялган» (1908) шигырендә ул дөнья яралу турындагы борынгы төрки мифны файдалана һәм шуның белән Хакыйкать һәм Гаделсезлек арасындагы көрәшнең мәңгелеген расларга омтыла [4, б. 136].

Белүебезчә, төрки мифологиясенең нигезен тәшкил иткән Тәңречелек динендә Кояш һәм Ай образлары үзәк урыннарны тота. Халык аларны агалы-энеле бертуганнар итеп күзаллый. Галимҗан Гыйльманов мондый караш чаткыларын татар халык табышмакларыннан табып, түбәндәге мисалларны китерә:

Агасы энесенә кунакка килә,
Энесе агасыннан кача...

яки

Иртән чыга,
Кичен югала,
Аның урынына
Энесе кала [3, б. 59].

Бу табышмакларның җавабы бер – Кояш белән Ай.

Габдулла Тукай шигырьләрендә дә Кояш һәм Ай образлары, аларның бертуганлыгы турындагы караш аеруча еш очрый. Мәсәлән, үзенең «Ай һәм Кояш» (1910) шигырендә шагыйрь аларны турыдан-туры «Кояш һәм Ай – ике туган агай-эне», – дип атый [5, б. 108]. Кояш һәм Ай берлеге әдип өчен, нәкъ борынгы мифологик карашлардагыча, Дөнья гармониясен аңлата. Аларны күңел күгеңнән җую үзеңне югалтуга, фаҗигагә тиң. Шуңа күрә дә Тукай «Үкенеч» (1910) шигырендә:

Әсирмен, ычкыналмам инде мәңге,
Күңелсез һәр ягым, нурсыз, караңгы.
Монафикълар камап һәр дүрт ягымны,
Күрәлмим мин кояшым һәм аемны, –

дип яза [5, б. 80–81].

Бөек әдибебез үз әсәрләрендә «түбән мифология» каһарманнарына, алар турындагы миф-экиятләргә аеруча еш мөрәҗәгать итә. Аның атаклы «Шүрәле», «Су анасы» кебек шигъри экиятләре тулаем халкыбызның әлеге тылсымлы затлар турындагы мәҗүси ышануларына, мифологик хикәятләренә нигезләнгән. Тукай өчен Шүрәле образы аеруча якын. Шагыйрь аңа багышлап, 1912 елда «Көтмәгәндә» шигырен яза, хәтта үзенең бер псевдонимы итеп тә «Шүрәле»не ала [5, б. 212–213, 277].

Ислам белән кергән һәм татар халкының рухи тормышының аерылгысыз бер өлеше булып киткән гарәп-мөселман мифологик традицияләре дә шагыйрь иҗатында зур урын били. Тукай аерым дини образларга, мотивларга иҗатының буеннан-буена мөрәҗәгать итеп килә. Мәсәлән, үзенең «Бер рәсемгә» (1908), «Милләтчеләр» (1908), «Нәсыйхәт» (1910), «Көзге җилләр» (1911) кебек шигъри әсәрләрендә әдип Газраил, Адәм, Хәүва, Һарут, Марут, Хозыр-Ильяс, Ибраһим вә Исмәгыйль образларын, йота торган балык турындагы дини легенданы файдалана [4, б. 163, 177; 5, б. 62, 163]. Шунысы кызык: гарәп-мөселман катламына караган мифологик образлар еш кына Тәңречелеккә бәйле персонажлар, мотивлар белән үрелеп китеп, кабатланмас синтез, поэтик күренеш тудыралар. Моның ачык мисалы итеп, шагыйрьнең «Казан вә Кабан арты» (1912) шигырен китерергә мөмкин [5, б. 223–224]. Биредә Кабан күле хәзинәләре турындагы риваять, мәҗүсилектән калган убырлы карчык образы, экиятләрдәге тылсымлы йомгак турындагы мотив, Кисекбаш турындагы дини легенда белән бергә үрелеп киләләр һәм әсәрнең идея-эстетик йөкләмәсен, аның заман чынбарлыгына карата тәнкыйди пафосын укучыга тулырак җиткерү өчен хезмәт итәләр.

Габдулла Тукай үз иҗатында халык җыры традицияләренә аерым игътибар бүлә, аларның төзелешен җентекләп өйрәнә. Моның нәтиҗәсе буларак, аның тарафыннан «Авыл җырлары» [4, б. 166, 167; 5, б. 15–16, 69, 153] дип исемләнгән биш көлтә такмак языла. Аларда шагыйрь үз заманына хас җитешсезлекләрне халык сатирасына, фольклордагы көлке тудыру алымнарына таянып, аяусыз рәвештә тәнкыйть итә. Шагыйрь-

нең «Бичара Бибиҗиһан» (1908), «Государственный Думага» (1906) кебек әсәрләре дә сатирик такмак традицияләрендә иҗат ителгән [4, б. 51–52, 139–140].

Гомумән, шагыйрь халык җырларының эстетик кыйммәтен, милли рухиятебездәге урынын гаять югары бәяли, аларны «халкыбыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә рәүшан көзгеседер», – дип атый [5, б. 262]. Шагыйрь иҗаты тамырлары белән халык җырына барып тоташа, шуннан көч ала. Тукай шигырьләренең фольклорлашып, милләттәшләребез репертуарына кереп китеп, әле дә яратып башкарылуы шуның белән аңлатыладыр, мөгаен. Мисал өчен, мәшһүр «Әллүки», «Туган тел», «Туган авыл», «Тәфтиләү», «Зиләйлүк» кебек әсәрләрне генә дә китерү җитә.

Бөек әдибебез халык акылының, меңьеллык тәҗрибәсенең образлы чагылышы булган мәкаль-әйтемнәргә еш мөрәҗәгать итә, аларны персонажларының сөйләмендә, я булмаса фәлсәфи гомумиләштерүләр өчен уңышлы файдалана. Мисалга мондый афористик иҗат үрнәкләренең берничәсен генә китереп үтик:

«Һәр ялтыраган алтын түгел»
(*«Һәр ялтыраган алтын түгел», 1910*);

«Үткән эш кайтмый»
(*«Өч хакыйкать», 1912* );

«Бүрек ташлап, котылмыйлар бүредән»
(*«Катиле нәфискә», 1910*) һ.б.

Аерым очракларда, шагыйрь әсәре алдында куелган идея-эстетик йөкләмәне тулырак ачар өчен, халык мәкальләрен ирекле үзгәртүгә дә бара, яисә үзе яңа афоризмнар уйлап чыгара. Мәсәлән:

«Берәү үз халкына кое казыса, үзе үк шул коега төшә»
(*«Габделхәмит», 1909*);

«Үз төбенә төшми, ди, шәм-лампочканың һичбер нуры»
(*«Казан вә Казан арты», 1912*)

«Мәңгегә очалмас, йортта күп асралса кош»
«Акча барда бар да дус шул, бар да яр»
*(«...гә», 1908)*

Акча исе чыкмый торса, бар да яныңнан таяр!»
(*«Теләнче», 1907*)

Күренекле галим Х.Й. Миңнегулов соңгы гыйбарәнең безгә Көнчыгыштан кергән «1001 кичә» кысалы кыйссасындагы акчага карап кына дус булу мотивына аваздашлыгын билгели [6, б. 116]. Чыннан да, Тукай иҗатында татар халык иҗатының энҗе-мәрҗәннәре генә түгел, ә башка Көнчыгыш халыкларының фольклорына һәм язма әдәбиятына хас традицияләр дә чагылыш таба. Мәсәлән, аның проза белән язылып, 1906–1907 елларда «Әлгасрел-җәдит» журналында «Мәҗмүгаи мөфидә» («Файдалы җыентык») исеме астында басылып чыккан мәсәлләрендә татар, төрек, урыс фольклор чыганакларыннан тыш, һинд һәм гарәп халыкларыннан милли мохитебезгә үтеп кергән «Кәлилә вә Димнә» кыйссасы файдаланыла [6, б. 23–24]. Бу кыйссадагы сукыр тычкан мәхәббәте турындагы сюжет сызыгы белән Тукайның 1909 елда язылган атаклы «Япон хикәясе» арасында да типологик охшашлык бар [6, б. 45].

Болар һәммәсе дә бөек әдибебезнең туган халкының поэтик иҗатына гына түгел, ә дөньяда яшәүче башка милләтләрнең фольклорына карата да булган тирән кызыксынуы, мәхәббәте турында сөйли. Безгә калса, Тукай иҗатының халыкчанлыгы шуның белән аңлатыла да. Филология фәннәре докторы Ф.Г. Галимуллин сүзләре белән әйтсәк, «фольклорга мәхәббәт әсәрләренең телен халык сөйләменә якынайтты, образлылыгын көчәйтүгә китерде. Әнә шулай үзеннән-үзе җырлап торучы Г. Тукай теле белән халык теле аерылмас бербөтенне тәшкил итте» [1, б. 141]. Шагыйрь халык гамен бар нечкәлекләре белән үз йөрәге аша кичереп, аның тормышы белән яшәде һәм милләттәшләре күңелендә үз исемен мәңгегә уеп калдырды. Тукайның әдәби мирасын төрле аспектлардан чыгып, гыйльми тикшерү моннан соң да һәркайсыбыз өчен изге бурыч булып саналырга тиеш.

ӘДӘБИЯТ

1. Галимуллин Ф.Г. Эзләнү вакыты: укытучылар, педагогия колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма. Казан: Мәгариф, 2005. 247 б.

2. Кариева Л.А. Татарская мифология (в историко-сравнительном и типологическом аспекте): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1999. 34 с.
3. Татар мифлары: ияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, им-томнар, сынамышлар, йолалар. Беренче китап / Г. Гыйльманов хикәяләвендә. Казан: Татар. кит. Нәшр., 1996. 388 б.
4. Тукай Г. Әсәрләр. 4 томда. Т. 1: 1905–1908 еллар. Казан: Таткнигоиздат, 1955. 453 б.
5. Тукай Г. Әсәрләр. 4 томда. Т. 2: 1909–1913 еллар. Казан: Таткнигоиздат, 1955. 447 б.
6. Миңнегулов Х.Й. Шәрык һәм татар әдәбиятында кысалы кыйссалар. Поэтика һәм әдәби бәйләныш мәсьәләләре. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1988. 200 б.
7. Урманчеев Ф.И. Развитие татарского фольклора в контексте «Запад-Восток» // Очерки по истории татарской культуры (в контексте «Запад-Восток»). Казань: Фикер, 2001. С. 300–348.
8. Ярми Хәмит. Татар халкының поэтик иҗаты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1967. 271 б.

## «БЕЗ КИТӘБЕЗ, СЕЗ КАЛАСЫЗ» СПЕКТАКЛЕНДӘ ТУКАЙ ОБРАЗЫ

***Фардеева Д.Р.***

Г. Тукай по праву считается первым профессиональным татарским поэтом. Образ поэта вдохновил писателей, поэтов, художников, композиторов на создание произведений искусства. В данной статье показан образ Тукая в спектакле «Мы уходим, вы остаетесь» по пьесе Т. Миннуллина, поставленный на сцене Татарского государственного академического театра имени Г. Камала в 1986 году. Т. Миннуллин взял за основу своей пьесы малоизвестный период жизни Г. Тукая, в котором отчетливо выявилось мировоззрение поэта, его отношение к окружающей действительности.

G. Tukay is considered to be the first professional Tatar poet. The image of the poet has inspired writers, poets, artists, and composers to create works of art. The paper describes the image of Tukay in the play "We're leaving, you're staying" by T. Minnoullin staged by the Tatar State Academic Theatre n.a. G. Kamal in 1986. T. Minnoullin took as the basis for his play the little-known period in G. Tukay's life, which clearly revealed the worldview of the poet, his attitude towards the surrounding reality.

Бөек Тукаебызның язмышы кыска һәм көенечле иде. Әмма ул калдырган иҗади мирасның байлыгы чагыштыргысыз. Аның образына күпләр мөрәҗәгать иттеләр һәм мөрәҗәгать итәләр. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә Г. Тукайның тормышын һәм иҗатын чагылдырган спектакльләр өч тапкыр куела – 1939, 1961, һәм ниһаять, 1986 елда. Соңгысы (Т. Миңнуллинның «Без китәбез, сез каласыз» пьесасы буенча) шагыйрьнең 100 еллык юбилее уңаеннан куела (режиссеры М. Сәлимҗанов, рәссамы – Р. Газиев, композиторы – Ф. Әбүбакиров).

Т. Миңнуллин үзенең пьесасы өчен яхшы һәм уңышлы тема сайлап ала. Пьеса өчен ул Тукай тормышының аз билгеле булган чорын ала, әмма монда шагыйрьнең дөньяга, аның тирә-яктагы чынбарлыгына карашы ап-ачык күрсәтелә. Әлеге пьесада Тукай биографиясенә һәм иҗатына караган кызыклы яңа фактлар ачыла. Шагыйребезнең образын драматург хасиятләп, кадерләп, саклык белән иҗат итә. Вакыйгалар Сембер губернасында фабрикант Акчуриннар йортында бара. Билгеле булганча, Тукай анда 1909 елда бара (кайбер истәлекләрдә 1908 елда диелә). Тукай һәм фабрикантлар... «Һич янәшә куеп булмаслык факт. Акча, байлыкка аз гына да исе китмәгән, җае чыккан саен туклардан әче итеп көлгән кайнар йөрәкле Тукай һәм берничә дистә ел эчендә гади сәүдәгәрдән атаклы капиталистка әйләнгән нык куллы, салкын акыллы, булдыклы Акчуриннар» [3]. Авторны нибары 27 ел яшәп, үз җилкәсенә авыр йөк күтәргән, татар халкының язмышын йөрәге аша үткәргән шагыйрь образы кызыксындыра. Уйлануларының кайберләрен Миңнуллин Тукай тормышындагы бер эпизодта күрсәтә. Драмада шагыйрь образын яңача сурәтләргә омтылыш көчле.

«Без китәбез, сез каласыз» пьесасы театр җәмәгатьчелеге тарафыннан зур хөрмәткә ия була. Режиссер М. Сәлимҗановның постановкасы чынлыгы һәм дөреслеге белән үзенә җәлеп итә. Сәлимҗанов авторның уйларын тамашачыга җиткерү өчен әсәргә күп кенә җанлылык кертә: барлык күренешләрне Тукай образы тирәсендә җыя, ялган эффектлардан кача, һәрбер образга үзенә генә хас буяу бирә. Р. Таҗетдинов, Ш. Биктимеров, Н. Дунаев, Ә. Шакиров, А. Гайнуллина, Н. Ихсанова һ.б. актерлар катнашуында бик матур ансамбль оеша, ә Илдус Әхмәтҗанов һәм Рамил Төхвәтуллин ышандырырлык итеп Тукай образын иҗат итәләр. Спектакльдә Тукай төрле: тышкы яктан яшь, әмма рухи яктан җиткән кеше. И. Әхмәтҗанов һәм Р. Төхвәтуллин йомшак күңелле,

шигъри җанлы, әмма шул ук вакытта таләпчән, куркусыз һәм үзсүзле кешене тамашачыларның күз алдына бастыралар.

Һәр образның үз үзенчәлеге булган кебек, бөек Тукайны башкару җиңел бирелмәгәндер, мөгаен. Актер Илдус Әхмәтҗанов болай дип искә ала: «Шагыйрьнең 100 еллыгы уңаеннан Камал театрында Туфан Миңнуллинның «Без китәбез, сез каласыз»спектаклендә Тукай ролен һич тә икеләнмичә миңа бирделәр инде. Марсель Сәлимҗанов тулысынча ышанды, уйнавы да җиңел булды. Рухым белән мин Тукай белән бербөтен булдым. Кайберәүләр тышкы кыяфәтең белән охшаган ди. Рухың бер булса, тышкы кыяфәтләр охшый башлыйдыр инде ул. Мин бик бәхетле кеше, чөнки сәхнәдә йөзгә якын образ тудырсам да – ә арада яхшылары дә бар бит – миңа бүген дә «Тукай!» дип сәлам бирәләр [2, б. 5]. Яшьтән үк Тукай образы белән хыялланып йөргәнгә күрә, актер чын образ тудыруга ирешә.

Актер Р. Төхвәтуллин да бу рольне гаять оста башкара. Төхвәтуллинга да Тукай образы шулкадәр якын иде ки, хәтта тамашачылар аларның тышкы охшашлыклары турында да сөйли иде. Тукай роле аның дебюты иде. «Миңа унтугыз яшь иде. Ул минем беренче ролем булды, тамашачы шунда беренче тапкыр күрде мине. Һәм мин аны Тукайның хәерһахлы фатихасы дип кабул иттем», – дип искә ала актер [1, б. 59].

Актерлар үзләре күзаллаганча, үзләре аңлаганча уйнарга тырышты. Тукай – Әхмәтҗанов һәм Тукай-Төхвәтуллин лирик та, йомшак күңелле дә, әмма шул ук вакытта туры сүзле, куркусыз кеше; зыялы, сәләтле, горур, илтифатлы, туры сүзле, һәрнәрсәгә үзенең ныклы карашы булган кеше.Ул үз фикерен ихластан әйтә, яшереп калдырмый. Спектакльдә аның шәхес булып өлгереп җиткән вакыты күрсәтелә. АктерларТукайны искиткеч эчкерсезлек белән, тәэсирле, дулкынландыргыч итеп уйныйлар, аның эчке дөньясын ышандырырлык, тирәнтен итеп күрсәтәләр, характерын, рухи халәтен тулысынча ачалар. Уйга калып, түбән карап, салмак йөрүләре, тыныч табигать белән сөйләшүләре белән дә Тукайны нык хәтерләтәләр һәм тамашачыларда җылы тойгылар уяталар.

Г. Тукай – милләтебезнең моң-сагышы, һәм шул ук вакытта горурлыгы да, ул һәр кешенең күңеленә якын.Аның әсәрләре генә түгел, үз язмышы да фаҗигадән тора. Спектакльдә бу аеруча түбәндәге юлларда сизелә:

Хыялларым олы иде, теләкләрем изге иде, инде хәзер...
Теләү бетте хәзер миндә теләк соңра теләкләрне;
Кире сүттем хәзер күп эшкә сызганган беләкләрне.
Күралмыйм, мин азатмын бер дә чиксез ихтыярымнан;
Гаҗәп ләззәтле, тәмле булса да, туйдым хыялымнан.
Фәкыйрь калдым хәзер: тормыш үзенең биргәнен алды;
Күңел буш: анда калды тик авыр хәсрәт, ачы кайгы [3].

Тукай мәңге яшь шагыйрь булып калды. Спектакльдәге Тукай монологының һәр юлы хәзерге заманга да аваздаш. Т. Миннуллин үзе әйтәсе килгән фикерләрне шагыйрь образы аша ачык җиткерә.

Яраткан шагыйре белән очрашу оештырганнары өчен, барлык тамашачылар да «Без китәбез, сез каласыз» спектаклен куючыларга бик рәхмәтле булды. Халык шагыйре Габдулла Тукайның тормышын һәм һәлакәтен чагылдырган бу спектакльне тамашачы җылы кабул итте.

ӘДӘБИЯТ


1. Әбүдәрова Л. Әнә, Тукай килә // Идел. 2011. № 4. Б. 58–61.
2. Әхмәтҗанов И. Мине бүген дә «Тукай!» дип сәләмлиләр // Мәгърифәт. 2011. 22 апрель. Б. 5.
3. http://www.gabdullatukay.ru/index.php?option=com_content&task=view&id=2622&Itemid=61


В переводе с марийского языка они обозначают следующее: шылше – беглец; водыж – «дух, название низшего божества» [15, с. 255]; юзо – волшебник; вувер – «ведьма» [15, с. 294]. Соответственно эти образы ближе для марийского читателя. Как Г. Тукай показал связь своей поэмы «Шурале» с фольклором татарского народа, так и В. Колумб отразил элементы фольклора марийского народа. Таким образом, переводчик сблизил две культуры и обогатил марийскую литературу.

Итак, в переводе В. Колумба проявились «черты национального своеобразия воспринимающего сознания» [25, с. 147]. Таким образом, «Шурале» Г. Тукая органично вошел в национальную культуру народа мари. Переводчиком сознательно подчеркнуто свое авторское начало. Это подтверждается еще и тем, что марийский поэт включил свои строчки в поэму-сказку. Когда Таргылтыш зовет своих братьев и с мольбой просит парня освободить, В. Колумб объясняет, почему на крик о помощи не пришел никто:

| | |
|---|---|
| Но иктат ок кол, огеш тол, | Но никто не слышит, не идет, |
| Очыни, тыгак нунат | Видимо, точно так же и они |
| Йӱдым еҥым ваҥен коштыт, | Подстерегают ночью людей, |
| Эр велеш гына ярсат [23, с. 159]. | Лишь к утру освобождаются. |
| | (Подстрочный перевод наш – *Н.Ф.*). |

В начале XXI века на марийский язык С. Григорьевой переведено 20 стихотворений Г. Тукая, которые вошли в сборник стихов, представленных на 6 языках. Книга издана в 2011 году к 125-летию со дня рождения классика татарской литературы. В переводах С. Григорьевой ощущается лиризм поэта, его интонация и своеобразие философских раздумий.

Переводы произведений Г. Тукая позволили состояться межкультурному диалогу, они обогатили марийскую литературу новыми художественными ценностями. Читатели получили возможность ознакомиться на своем родном языке не только с татарской классикой, но и соприкоснуться с тюркским миром.

ЛИТЕРАТУРА


1. Васин К. Г. Тукай // Марий коммуна. 1961. 26 апрель.
2. Васин К. Г. Тукай и марийская поэзия // Габдулла Тукай. Казань: Татар. кн. изд-во, 1968. С. 143–154.
3. Васин К. Г. Тукай и марийская поэзия // Слово о Тукае. Писатели и ученые о татарском народном поэте / Составление и комментарии Ф.М. Зулькарнаева. Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. С. 157–167.
4. Васин К. Мемнан Тукайна (Наш Тукай) // Ончыко. 1966. № 3. С. 96–99.
5. Васин К. Тукай и марийские писатели // Габдулла Тукай: Материалы научной конференции и юбилейных торжеств, посвященных 90-летию со дня рождения поэта. Казань: Татар. кн. изд-во, 1979. С. 208–214.
6. Васин К. Тукай с марийцем по-марийски говорит // Молодой комунист. 1961. 27 апреля.
7. Витрук Н.В. Этнокультура: русско-удмуртские связи. Избранные труды. Ижевск: Удмуртия, 2007. 594 с.
8. Иванов И.С. Габдулла Тукай и марийская поэзия // Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар. Казан, 2011. С. 82–83.
9. Казаков М. Все ярче и ярче // Габдулла Тукай: Материалы научной конференции и юбилейных торжеств, посвященных 90-летию со дня рождения поэта. Казань: Татар. кн. изд-во, 1979. С. 235.
10. Казаков М. Габдулла Тукай // Казаков М. Волгыдо кече (Светлые дни). Йошкар-Ола: Марийский государственный издательство. 1948. С. 138.
11. Казаков М. Тукай деке – унала (В гости к Тукаю) // Марий коммуна. 1966. 13 июль.
12. Марийцы. Историко-этнографические очерки Марий калык. Историй сынан этнографий очерк-влак. Йошкар-Ола: МарНИИЯЛИ, 2013. 480 с.
13. Нигматуллина Ю.Г. Своеобразие художественного мышления Тукая // Слово о Тукае. Писатели и ученые о татарском народном поэте / Составление и комментарии Ф.М. Зулькарнаева. Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. С. 298–309.
14. Осмин Йыван. Эрык ден пиалын мурызыжо (Певец свободы и счастья) // Марий комуна. 1946. 27 октябрь.
15. Словарь марийского языка, т. I, А – З / А.А. Абрамова, И.С. Галкин, И.Г. Иванов и др.; гл. ред. И.С. Галкин. Йошкар-Ола: Марийское кн. изд-во. 1990. 488 с.
16. Словарь марийского языка. Т. 4: М – Ӧ (ма - ӧрчыктарымаш) / А.А. Абрамова, Л.И. Барцева, В.Н. Васильев и др.; Гл. ред. И.С. Галкин. Йошкар-Ола: Марийское кн. изд-во, 1998. 384 с.
17. Словарь марийского языка. Том VII: Т / сост.: В.И. Вершинин, В.Н. Максимов, С.С. Сибатрова, Е.А. Черашова. Йошкар-Ола: МарНИИ, 2002. 432 с.
18. Тимиркаев А.Т. Тукайын юбилейыштыже // Марий коммуна. 1986. 16 май.
19. Ток А. Татар калыкын поэт-классикше Габдулла Тукайын шочмыжлан 80 ий (Поэту-классику татарского народа Габдулле Тукаю 80 лет со дня рождения) // Марий коммуна. 1966. 26 апрель.
20. Ток А., Майн М. Габдулла Тукай // Марий коммуна. 1946. 27 октябрь.
21. Ток. А. Г. Тукай // Марий коммуна. 1961. 26 апрель.
22. Тукай Г. Тӱкан овда (Шурале) // Ончыко. 1966. № 3. С. 99–102.
23. Тукай Г. Таргылтыш // Колумб В. Ойырен чумырымо ойпого. Тӱнямбал да руш классике, рушлаш кусарые сборник-влак. III том. Йошкар-Ола: Центр-музей им. Валентина Колумба, 2007. С. 151–160.
24. Тукай Г. Шурале // Тукай Г. Стихи и поэмы. М.: Гослитиздат. 1946. С. 110–118.
25. Хабибуллина А.З. Из истории переводов произведений М.Ю. Лермонтова в тюркоязычных литературах // Ученые записки Казанского государственного университета. Гуманитарные науки. 2009. Т. 151, кн. 3. С. 144–153.
26. Эман С. Габдулла Тукай // Марийская правда. 1961. 26 апрель.

# ТУКАЙ – ХАЛЫКНЫКЫ, ХАЛЫК – ТУКАЙНЫКЫ

***Филиппова К.М.***

...апрель, 1966 ел. Габдулла Тукайга 80 яшь тулган көн, юбилей кичәсен илебез күләмендә зурлап, туган җирлеге Арча районында билгеләп киткән вакытлар иде бу. Шушы вакыттан алып зур бүләк – Г. Тукай премиясен бирә башлау турында хөкүмәтебез карары кабул ителде.

Дөньякүләм танылу алган каләм ияләре: Үзбәк халык шагыйре Гафур Гүләм, төрекмән язучысы, Социалистик Хезмәт Герое Берды Кербабаев, әзәрбайҗан халык шагыйре Сөләйман Рөстәм, кыргыз халык язучысы Камчы Җунусов һәм башка бик күпләр иң җылы хисләрен Тукаебызга багышладылар, бик күп рус һәм башка милләт язучылары, шул исәптән Рувим Моран, Анна Ахматова, Семен Липкин һ.б. Г. Тукай әсәрләрен тәрҗемә иттеләр.

Бу шәхесләребез, Тукаебызның туган җиреннән ерак торсалар да, Г. Тукай әсәрләре аларның иҗат юлында зур илһам чыганагы булган, алар аннан күңел һәм рухи җанны кузгатырлык көч алганнар, аның шигырьләрен тирәнтен өйрәнгәннәр, өстәл КИТАБЫНА әверелдергәннәр.

Ләкин... җанда бу юбилейдан нindидер салкынлык калган иде. Болар 60 нчы еллар хатирәсе булса да, бүгенге көндә дә күңел җылытырлык рухи күтәренкелек бик үк куанычлы димәс идем мин, чөнки Г. Тукай, Казанга кайткач, 1907–1913 елларда яшәгән «Болгар» кунакханәсен дә бүгенге буын яшьләребезгә күрсәтә алмыйбыз. Ул юк инде, ә без бар! Ә мәгънәбез кая? Соңгы сәгатьләрен уздырган Клячкин больницасында 1913 елның 26 февраленнән 15 апрельгә кадәр дәваланган бинада да җанга җылылык алу бик шикле.

...1966 елның 5 августында мине Минзәлә районыннан Арча районына мәдәният бүлеге мөдире итеп җибәрделәр. Бу – Габдулла Тукай белән «күрешү», бөек шагыйребез туган җиренә – Кушлавыч авылына беренче командировкам иде. Аннары Тукай-Кырлай авылындагы Сәгъди абзый йорт-җирләре белән танышу, ләкин борчуларым артты гына.

Иң беренче Арча районы башкарма комитеты председателе Тимерхан Борһанович Борһанов янында булып, үзем төзегән эш планымны тәкъдим иттем. Аннары КПСС райкомының беренче секретаре Усман Шаһиевич Җиһаншинга кереп (бик акыллы, булдыклы җитәкчеләр иде, икесе дә мәрхүмнәр инде), Тукаебызга булган «хөрмәт»нең җитеп бетмәвен тасвирлап аңлатканнан соң, мин икенче көнне бар зиһенемне туплап, изге планнарым белән Татарстан Язучылар союзы председателе Мирсәй ага Әмир янында булдым, анда:

– Габдулла Тукайның әсәрләре Татарстанда һәм күп кенә тугандаш халыклар басмаханәләрендә әледән-әле чыгып тора бит. Шул китапларга гонорар өлешеннән туган төбәгендәге ике авылда – Кушлавыч һәм Тукай-Кырлайда мемориаль-музей төзеп булмасмы? – дигән сорауны куйдым.

Алар инде яшь кызга (миңа да ул вакытта Тукай яше – 27 белән бара идем) каршы килмәделәр. Алай гына да түгел, Мирсәй ага Әмиров мине үсендереп җибәрде.

– Бу безнең республика күләмендә игътибар үзәгендә торган иң изге һәм беренчел эшебез санала. Әлеге мәсьәлә Мәскәү язучылары берлеге алдына да куелган, – диде ул.

Күп тә узмады, Мәскәүдән комиссия килеп, Тукай-Кырлай авылындагы барлык йортларны фотога төшерделәр, мемориаль-музейның генераль планын эшләүгә керештеләр. Иң беренче эш, Бакый ага Урманченың урманда «үсеп» утыручы агачлардан иҗат иткән «шүрәле»ләрен күреп кайту өчен, асфальт юл салудан башланды. Бу эшне Арча районы югары оешмаларының махсус карарларын кабул итеп һәм башкарылачак эшләргә контроль булдырырга дигән бурыч та куелды. Халкыбызны Тукай рухлы итәсем килү көчле булганлыктан, халык белән турыдан-туры мәдәниятне күтәрү өлкәсендә дә зур гына иҗади отчетлар белән мәдәният айлыгы башланды. Монда яктыртыла торган мәгълүматлар әдәби-музыкаль бизәлештә күрсәтелә. Ә шушы чыгышларның сәнгать ягыннан иң югары дәрәҗәдә булганнарын сайлап алу да оештырылды, чөнки җәй көне июнь аеның беренче якшәмбесендә, чәчүләр беткәч, Тукайга багышлап уздырылган чаралардан соң, район күләмендә һәр елны «Җыр бәйрәме» уздырыла иде. Бәйрәмдә 2 меңгә якын үзешчәннәр катнаша һәм тынлы оркестр җитәкчелегендә

төрле җырлар башкарыла. Менә шулай итеп, беренче мәртәбә 1967 елда «Җыр бәйрәме» зур уңыш белән узды.

Шушындый зур чараларда беренче тапкыр халык алдына чыгып, зур сәхнәгә аяк баскан Ринат Гыйлаҗев, Рабига Сибгәтуллина, Гөлзадә Сафиуллина, Арчадан Вәлиевлар гаиләсенең гармунчылар ансамбле, Фәйзерахмановлар, Габрахмановларның гаилә ансамбльләре халыкның иң яраткан чыгышлары булып, бәйрәмебезне тагын да ямьләндерә иде.

Айдар Фәйзерахманов 11–12 яшьлек малай буларак, 1967 елгы «Җыр бәйрәме»ндә бик матур җырлап таң калдырса, ә 1970–74 елларда бала тавышыннан күчү чорында тавышы бозылмасын өчен мин үзем җырлавына каршы чыктым һәм ялгышмадым, ул хәзер татар халкының иң яраткан җырчысы һәм яшьләргә музыка дөньясындагы сихри нечкәлекләрнең серенә төшендерә. Ринат Гыйлаҗевның ансамблен кемнәр генә тыңлап хозурланмый икән, ә Гөлзадә Сафиуллина халкыбызны югары дәрәҗәдәге сәнгать тормышына өндәүдә бик уңышлы гына эшләп килә. Гөлчирә белән Нәҗип Бәдретдиновларның куйган хезмәтләренә кемнәр генә сокланмый икән. Айдар Фәйзерахманов һәм Нәҗип Бәдретдиновлар алып барган «Җырлыйк әле» тапшыруы халкыбызның моң дөньясында тирән эз калдырды.

Арча районы 70 нче елларда мәдәният хезмәте күрсәтү буенча республика күләмендә бирелә торган күчмә Байракка хуҗа булуга иреште. Үзешчәннәрнең активлыгы, китапханәләрдә китап укучыларның саны арта торды. Төрле кызыклы чаралар уздыру, әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә сыйфатлы чыгышлар, мәдәният учакларының төзелеше буенча, материаль-техник базасы, үзешчәннәр өчен костюмнар булдыруда, һәрхәлдә, югары һәм махсус урта белемле кадрлар әзерләүдә дә республикада беренчеләр булып торды... Аннан инде Яшел Үзәндә... Бүгенге көндә Яшел Үзән ТУКАЙ ҺӘЙКӘЛЕН КӨТӘ.

Яшел Үзән районы башкарма комитеты мәдәният бүлеген озак еллар буена уңышлы һәм оста җитәкләгән Әслах Нурлыгаян улы Баязитовның әлеге өлкәдә өлеше зур булды.

1995 ел... Бәчек авылы тарихында гомерлеккә калырлык изге эшләрнең башында торып, Габдулла Тукайның яраткан Бибисаҗидә тутасы һәм аның кызы Өммеһания каберләре өстенә истәлек ташларын ясатып урнаштыручы олы җанлы бу кеше исән булса, шәһәребездә Тукайга һәйкәлне дә әллә кайчан төзетеп куйдырган булыр иде дип сагышлы уйларга чумдым. Бүген мәдәният белән җитәкчелек итүче түрәләр ансат кына: «Акча юк», – дигән сылтау табып, бу эшкә нокта куярга тырышалар. Узган гасырның 60–70 нче елларында куелган һәйкәлләр җимерелеп бара, ә яңаларын төзетергә, искеләрен ремонтларга акча юк.

Узган гасырның 80–90 нчы елларында районыбызда зур үзгәрешләр булды. Татарча укыта торган мәктәпләр дә юк иде. Районда чыга торган газетаның да урысчадан татарчага тәрҗемәсен укып кына канәгатьләнмәүчеләр күбәйде. Менә шул вакытта милли-мәдәни үзәк булдырып, милли мәгарифнең язмышы турында сөйләшүләр башланды.

1990 нчы елларда Татарстан Республикасы мәгариф министры булып эшләгән Васыйл Гайфуллинның зур ярдәме белән шәһәребездә татар телендә укыта торган мәктәп-гимназия ачарга рөхсәт бирелде.

Нәтиҗәдә, 1991–1992 уку елында, халык теләге белән татар гимназиясен ачтык, ә 1995 елда татар телендә мөстәкыйль район газетасын укый башладык. Бүгенге җитәкчеләрнең дә ярдәм итәчәкләренә ышанып, Г. Тукаебызның 130 еллык юбилеен лаеклы каршы алачагыбызга өметебез зур. Шәһәр халкы Г. Тукайга һәйкәл ачылуын түземсезлек белән көтә, чөнки 2012 елдан бирле Яшел Үзән муниципаль районы башлыгы безне ышандырып килә. Үз сүзләрендә торырлар шикелле.

Вакытлар узган саен Тукай иҗатының тормышчан тирәнлеге, дөреслеге һәм фәлсәфи фикерләвенең кадере артканнан-арта гына бара.

Аның бик кыска гомерендә иҗат иткән әдәби әсәрләренең күләме 7 млн. тиражны эченә ала. Шушы зур мирасны халыкка җиткерү йөзеннән Г. Тукайның Казан, Яңа Кырлай музейлары 1976 елда, әдипнең 90 еллык юбилеенә ачылса, ә 1986 елда Г. Тукайның 100 ел тулу көненә ачылган музей бинасы, халыкта «Шамил йорты» дип аталып йөртелгән XIX гасыр ахырына караган архитектура үрнәге буларак билгеле. Эшләп торган музейларның барысында да, Г. Тукайның фаҗигале балачагы киң якты-

ртыла, иҗади эшчәнлегенең күпкырлы булуын тасвирлый торган шигырьләре, чәчмә әсәрләре, әкиятләре дә иллюстрацияләнеп тасвирлана. 1996 елда Г. Тукайның 110 еллык юбилеен каршылаганда, туган авылы Кушлавычта «Тукаевлар утары» эшләнеп, 7 буын мулла нәселе булуын исәпкә алып, әдәби-этнографик музей-усадьба төзелеп эшкә тапшырыла. Бу музей шунысы белән кызыклы һәм әһәмиятле дә – музей-усадьба «Ак өй», «Кара өй», «Мәдрәсә»өлешләрен үз эченә алган.

2006 ел Г. Тукайның 120 еллык юбилее уңаеннан Татарстанда сәнгать һәм мәдәният елы буларак билгеләнеп узды. Шул чаралар арасындагы иң саллысы – Тукай музеена 20 ел тулуына багышланганнары булгандыр. Габдулла Тукайның юбилейлары һәрвакыттагыча, әдипнең бөеклеген раслаучы буларак, яңалыклар белән өстәлеп торган саен, төрки дөнья халыкларында да гына түгел, башка халыкларыбызның да рухи хәзинәсенә әверелә баруын аңлата.

Инде яңадан Яшел Үзән муниципаль районына кайтсак, анда Г. Тукай юбилеена өч еллык комплекслы эш планы кабул ителеп, 2012 елдан ук хәзерлек эшләрен башлап җибәрде. Алда язылганча, һәр юбилейга ниндидер яңа Тукай маршрутлары, экспозицияләре барлыкка килеп, халыкны шатландырырса, андый истәлекле урыннарыбыз Яшел Үзән районы җирлегендә дә саклана:

**Яшел Үзәндә Тукайның өч сукмагы**

Яшел Үзән районында Габдулла Тукайның эзләре калганын галимнәр раслап торсалар да, халык бу хакта аз белә. Бөтенләй белми, дисәк тә, дөрес булыр, чөнки аңлату, сөйләшү җитми.

Ногман бай Габдрахманов кем ул? Габдулла Тукай белән нинди бәйләнеше бар? Монда Яшел Үзәннең ни катнашы бар соң? Бар икән шул!

Әтнә районы Түбән Көек авылына Яшел Үзән районы Ачасыр авылыннан Ногман тимерче булып килгән дә, биредә төпләнеп калган. Беренче гильдия сәүдәгәр дәрәҗәсенә җитеп, үз хисабыннан 10 мәчет, 5 мәдрәсә төзеткән. Инкыйлабка кадәр ул – Казанның капиталлары 10 мең сумнан арткан 56 татар бае арасына кергән, шул чорның атаклы баена әверелгән һәм, игелекле, күркәм эшләр эшләп, якты эз калдырган. Икенче гильдия сәүдәгәр Мөхәммәтсафа Галикәев кызы Рабигага өйләнеп, аларның алты баласы туган. Казанда туган Ногман байның кызы Зәйнәп Олы Әтнә егете Әхмәтгәрәй Хәсәнигә кияүгә чыккан, ә Әхмәтгәрәй Казанда 1912–1918 елларда нәшер ителгән «Аң» журналының мөхәррире булса, хатыны Зәйнәп басманың сәркатибе булган. «Аң» журналында Габдулла Тукайның шигырьләре һәм башка язмалары еш басылганлыктан, Хәсәниләр гаиләсенең җан дустына әйләнгән.

Габдулла Тукайның иң яраткан апасы Бибисаҗидә турында да Яшел Үзән аз белә. Чөнки 2016 елда, Габдулла Тукайның тууына 130 ел тулу көненә һәйкәл салдыру мәшәкате белән йөргәндә, Бибисаҗидә апасының Бәчек авылында яшәгәнен аз белүләре ачыкланды. Габдулла Тукайның әнисенең башка анадан туган бертуган апасы Бибисаҗидә турында да белүебез кирәктер.

Бибисаҗидә Арча районы Өчиле авылында 1877 елда туа, аны 1893 елның 25 декабрендә Казанда мәдрәсә тәмамлаган 24 яшьлек Әхмәтсафага кияүгә бирәләр. Туйларын Арча районы Өчиле авылында уздыралар һәм апасының туена Кырлайдан Габдулла Тукайны да китертәләр. Җизнәсе белән апасында ул берничә көн кунак була. Туйдан соң Әхмәтсафаны мулла итеп куялар. Алар гомер буе Каенсар авылында яши һәм җиде бала тәрбияләп үстерә.

Бибисаҗидәнең беренче ир малае туа, аңа Габделваһаб дип исем кушалар. Ул Герман сугышына да алына, үз башыннан Гражданнар сугышын да, Бөек Ватан сугышын да кичереп, сигез бала тәрбияләп үстерә һәм 1957 елда бакыйлыкка күчә.

Мәсрүрә, Арча районы Орнашбаш авылында яши. Мәсрүрә Зәбированың дүрт баласы була һәм бүгенге көндә дәвамчылары Республикабызның төрле районнарында яши.

Бибисаҗидәнең өченче кызы (1903–1975) Өммеһания. Арча районы Түбән Көектә укытучы булып эшләгәндә Бөек Ватан сугышы башлана һәм аны Яшел Үзән районы Бәчек авылына укытучы итеп күчерәләр. Озак еллар анда мәктәп директоры хезмәтен башкара, авыл халкының абруен казана. Бу вакытларда дүртенче малае Солтанәхмәтнең сугышта үлү хәбәре әнисе Бибисаҗидәнең хәлен тагын да авырайта. Өммеһания сеңлесе Әкълимә белән әнисен үз куенына сыйдыра. Авыру әнисен тәрбияләп, аларны матди яктан яшәтү мәшәкатьләре Өммеһания җилкәсенә төшә. 1956 елда Бибисаҗидә,

каты авырудан соң вафат булып, җиргә иңдерелә. Шушы авыр газапларны кичрү Өммеһаниянең дә сәламәтлеген какшата. Сеңлесе Әкълимә бик күп көчләр куеп тәрбия кылса да, 1975 елда Өммеһания гүр иясе була. Бәчек халкы янәшә күмелгән ике – әни һәм кыз каберләрен бер чардуган эчендә, кадер-хөрмәттә саклап тоталар.

Дүртенче баласы Солтанәхмәт Каенсар авылында укытучы булып эшләгәндә Бөек Ватан сугышына китә һәм әйләнеп кайта алмый. Каберенең Могилёвта булуын раслаган документлар барлыгы билгеле.

Бишенче кызы – Фатыймабикә Казан заводларының берсендә электромонтёр булып эшләгән. Мәсгуть исемле улы булган. Ул Владивостокта боцман булып хезмәт иткән.

Алтынчы кызы Нурдидә, Казан шәһәре фабрикаларының берсендә тегүче булып эшләп, пенсиягә чыкканнан соң, картлар йортында яши һәм авырып үлә.

Бибисаҗидәнең җиденче кызы Әкълимә турында мәгълүмат аз. Әнисен дә, апасын да Бәчек авылында җирләгәннән соң, кулында бер һөнәре һәм яшәү өчен бер тиен килере булмаган Әкълимә, олы абыйсының улына, дүрт кешелек гаилә өстенә бала караучы булып килеп сыена.

Өченчесе: «Г. Тукай 1910 елда үзенең дусты Гыйззәтулла Галиәкбәровларда – Яшел Үзәндә Мулла Иле авылында кунакта була. Иртәгәсен үк Г. Галиәкбәровның әтисе Хәйрулла абзый аларны Зөя каласына илтеп куйган. Бөек Тукайның үзен белгән мәчет хәзер дә исән-сау, бөтен авылга иман нуры таратып эшләвен дәвам итә», дип яза Рөстәм Равил улы Сәйфетдинов. Өч сукмак, өч авыл, өч истәлекле вакыйгалар артында Г. Тукаебыз рухы онытылмый яши икән, без тирән тарихлы, эзле халык!

Бөек Г. Тукаебыз 27 ел яшәү гомерендә, ятимлектә, әрле-бирле күченеп, күпме рәнҗетелү, кимсетелүләрне күтәреп, авырлыкларны кичерүгә дә карамастан, җиде млн. данә басма мирасын – китапларын калдырып, бик иртә арабыздан китеп бара. Шушы фаҗигале тарихи чынбарлыкны, аз гына булса да йомшарту теләге белән, киләчәк яшь буынга аңлату максатында, Г. Тукай эзләрен һәм аның туганнарын барлап, «әтиле-әниле» зур гаиләсе барлыгына төшендерәсебез килде. «Тукай күпере – дуслык күпере» салып, 130 еллык юбилеена без – Г. Тукаебызны Арча ягы – әтисе кебек, ә Яшел Үзән әнисе рәвешендә, районнар үзара дуслашып, Г. Тукайны онытмыйча, зурлап, аның бөеклеген саклауда, яклауда зур иҗади, рухи хезмәт юлларын салабыз. Г. Тукайның 130 еллык юбилеена яшелүзәнлеләр хөкүмәтебезнең ярдәменә таянып, шундый матур хыялларыбыз белән яшь буыннарга үрнәк итеп, музей-экспозициясен булдырып, Өммеһания укыткан мәктәпне һәм алар 1941–1975 елга кадәр яшәгән ихатаны да нурландырып каршы алсак иде, – дигән теләктә калабыз.

Г. Тукайның нәсел җепләрен эзләү XXI гасырда иң кирәкле башлангыч дип уйлап, киләчәк буынга зур мирас – Тукай дәвамчыларын һәм аларның бәйләнешләрен өйрәнү рухи үсешебезнең нигезен тәшкил итә. Без Тукайсыз бер көн дә яши алмыйбыз. Ул безнең яшәү һәм рухи чыганагы булганда гына матур киләчәккә өметләнә алабыз.

## ПОЭЗИЯ Г. ТУКАЯ И ЭСТЕТИЧЕСКИЙ ОПЫТ СОВРЕМЕННЫХ ТАТАРСКИХ ЧИТАТЕЛЕЙ (рецептивный анализ)

***Хабибуллина А.З.***

В статье проводится анализ научного эксперимента, направленного на понимание того, как современные татарские читатели воспринимают мир русской классики. Предметом исследования стало стихотворение М.Ю. Лермонтова «Молитва». Эксперимент позволил выявить роль поэзии Тукая в формировании эстетического опыта современных татарских читателей и преодолении «сглаженного» восприятия ими произведений русской поэзии XIX века.

The report contains the analysis of a scientific experiment, which was aimed to reveal the level of comprehension of the world of Russian classical literature by modern Tatar readers. The poem “The Prayer” by M.Y. Lermontov has been selected for the research. The conducted experiment has contributed to the evaluation of the significance of G. Tukay's poetry in the formation of the aesthetic experience of modern Tatar readers and changing their “leveled” perception of the Russian poetry of the 19th century.

Творчество Габдуллы Тукая имеет особое значение в формировании *эстетического опыта* современного татарского читателя, оказывая определенное воздействие на восприятие последними произведений русской литературы. Данный аспект исследования, связанный с проблемой эстетической интерференции, является мало разработанным в нашем литературоведении, отчасти это связано с тем, что он предполагает обращение к научному эксперименту.

1. Изучение восприятия татарских читателей русской литературы представляет собой специальную тему исследования, которая сложилась в сопоставительном литературоведении в 90-е годы XX века. В частности, в своей кандидатской диссертации «Русская литература в восприятии татарских читателей (эстетическая интерференция)» мною был поставлен вопрос об экспериментальном исследовании интерференции [3]. Описание данного эксперимента также вошло в содержание пособия по межкультурной коммуникации в 2012 году [4, с. 166–171]. Были выявлены некоторые черты восприятия татарских читателей произведений русской классики (Г.Р. Державина, М.Ю. Лермонтова, Н.В. Гоголя) и инонациональной литературы вообще. Проведение научного эксперимента позволило описать черты их национальной идентичности, особенности их художественного сознания. Так, было установлено, что для татарских читателей нет четких разграничений между этическим и эстетическим. Понятия дружбы, любви, справедливости осмысливаются здесь не отвлеченно (отвлеченное философствование не характерно для национальной литературы), а вызывают чувства восхищения, могут рассматриваться как выражение прекрасного, возвышенного и переживаться внутренне, эмоционально.

2. Одна из задач данного экспериментального исследования – понять, как влияют черты национальной и культурной идентичности современных татарских читателей на восприятие лирики Лермонтова. Предметом исследования стало стихотворение русского поэта «Молитва».

Обращение к творчеству Лермонтову не случайно. В своих размышлениях мы исходим из идеи о том, что в самой структуре сознания русского поэта были такие основания, которые соотносимы с восточной эстетикой и культурой. Об этом, в частности, утверждается нами в статье «М.Ю. Лермонтов и татарская литература начала XX века (к вопросу о межлитературном диалоге)» [2, с. 52–66].

В ходе исследования мы также стремились выяснить, актуализируется ли тот идейно-смысловой потенциал художественных текстов русской литературы, который по-своему раскрылся в переводах татарских поэтов начала XX века. Речь идет, прежде всего, о стихотворении Тукая «Тәэссер» («Впечатление»), которое является вольным переводом на татарский язык стихотворения Лермонтова «Молитва».

3. Тема молитвы в творчестве Лермонтова связана с тем, что поэт, чувствуя свое одиночество, переживая разобщенность миром, светом, стихийно обращался к Богу, в котором он искал понимания и успокоения. Однако религиозный мотив в стихотворении «Молитва» имеет и иной аспект содержания: лирический герой Лермонтова испытывает состояние внутреннего просветления благодаря той силе Слова, которая обретает над ним власть, заставляя вслушиваться не только в смысл молитвы, но и «созвучье слов живых» вообще.

Для Тукая это скрытое составляющее содержания стихотворения Лермонтова оказалось лакуной, т.е. той областью в произведении, которая в силу своей неполной определенности, могла вызвать эстетическую интерференцию. В литературах Востока, а также в татарской литературе, которая, как известно, испытала сильное воздействие со стороны традиций и поэтики восточных литератур, Слово молитвы, как и само понимание ценности произнесенного слова вообще, было другим. Слово здесь наполнялось высшим смыслом, т.к. за ним стояла воля Бога.

Тукай в своем вольном переводе интерферировал это скрытое содержание чисто религиозной идеей. Вместе с тем, его лирический герой, по сравнению с героем произведения Лермонтова, не просто произносит слова молитвы, несущей ему успокоения, он как бы погружается в нее *полностью*, *без остатка*, показывая нам, что же меняется в его душе тогда, когда он твердит суры Корана.

Оча дилдән бөтен шик-шөбһәләр, һәм җылый башлыйм:
Яңакларны мөкаддәс күз яшемдә энҗели башлыйм.

Бөтенләй сафлана күңлем; укыйм иман, булам мөэмин;
Килә рәхәт җиңеллекләр: хәлас булам авыр йөкдин [1, т.1, с. 90].

Исчезают, словно ветер, все тревоги и сомнения – плачу я:
Щеки украшаю, будто жемчугом, священными слезами.

И всецело очищается душа моя, обращаюсь к Богу, правоверным становлюсь;
И блаженное приходит облегчение: ведь от бремени я тяжкого освобожусь.
(Подстрочный перевод наш. – *А.Х*).

Свободный перевод стихотворения Лермонтова на татарский язык по-своему иллюстрирует важнейшую черту восточного миропонимания – обращенность в себя, в свой внутренний, скрытый от постороннего взгляда мир. Такая особенность мышления восточного человека, по-видимому, интуитивно была угадана Тукаем, *идентифицируясь* в переводе как *самоуглубление* лирического героя в момент произнесения молитвы. В таком аспекте перевода (который возник в результате наполнения семантической лакуны) проявились черты эстетической интерференции, вызванной воздействием ценностей татарской литературы: в ней всегда размышление о молитве соотносилась с идей Бога, Творца.

4. Рассмотрим результаты эксперимента.

Наш анализ подтвердил, что современные татарские читатели (речь идет о студентах отделения татарской филологии Института филологии и межкультурной коммуникации, всего 32 реципиента), увидели в содержании стихотворения «Молитва» схожие с переводом Тукая идеи, что свидетельствует о расхождении их сознания с воспринимаемым произведением Лермонтова. Возникновение *эстетической дистанции* в таком восприятии очевидно: с одной стороны, они наделили художественное содержание стихотворения Лермонтова такими размышлениями, которые исходили из опыта их родной культуры, ценностей татарской литературы, в частности. С другой стороны, в таком восприятии заметной была тенденция «прочитать» данное стихотворение через призму мотивов и образов *поэзии Тукая*, что усилило в их рецепции «другое» видения стихотворения Лермонтова, прочтение его с позиции «своего», а не «чужого».

В первую очередь это связано с тем, что близость творчества Лермонтова к Востоку, которая отмечалась многими исследователями XX века, стихийно *угадывалась* реципиентами, выводя на первый план их размышлений образы и параллели с творчеством Тукая, а также с теми нравственно-художественными представлениями, которыми богата их родная литература.

Выделим некоторые, наиболее полно иллюстрирующие данную тенденцию восприятия, фрагменты рассуждений татарских читателей.

1. Стихотворение Лермонтова оказало благотворное впечатление. В названии сказано, что произведение посвящено молитве. И эта молитва почувствовалась мне. Я вспоминаю молитву, которую я читаю. Она мне показалась светлой, прекрасной, соединяющей меня с Пророком.

2. Стихотворение Лермонтова «Молитва» можно сопоставить с Кораном, т.к. в них есть схожие, созвучные моменты [мотивы].

3. После молитвы становится легко на душе, все сомнения кажутся далеко, [уходят] куда-то вдаль. Это указывает на веру лирического героя в Бога. Если ты не веришь в Бога, то молитвы не приносят такой легкости и очищения.

4. Это стихотворение свидетельствует о сильных переживаниях поэта. Он находит покой только благодаря Богу, с помощью молитвы, а также слов, которые выходят из самого сердца, это простые слова. На мой взгляд, это очень душевное стихотворение, в котором есть обращение к Богу.

5. В стихотворении автор описывает молитву как чудесное явление. Он утверждает, что в молитве есть сила и она созвучна с живыми словами. Молитва для автора является живой, она даже может дышать. <…> Автор в своем произведении показал силу молитвы, веры и Бога.

6. Данное стихотворение можно сопоставить с произведением Тукая «Кичкә теләк» [«Вечернее желание»], в котором поэт также говорит о большой силе молитвы.

7. Данное стихотворение внушает человеку надежду, т.к. в нем говориться о молитве. В молитве есть исцеляющая и чудотворная сила. Просто повторяй ее, верь в ее силу, благодари Всевышнего за все.

Из татарской литературы с данным произведением можно сопоставить стихотворение Тукая «Ана догасы» [«Молитва матери»], «Кадер кич» [«Ночь предопределения»].

Вместе с тем из достаточно большого числа подобных ответов мы обнаружили рассуждение одного читателя, которое свидетельствует о сближении эстетической дистанции последнего с воспринимаемым текстом. Речь идет об идеи воздействия на человека благодатного Слова вообще, а не только молитвы как пути к Богу: «*Стихотворение Лермонтова о молитве, о словах, твердя которые автору становится легче. Эта молитва помогает ему в трудную минуту жизни. Произнося слова, он успокаивается. В них есть благодатная сила, которая помогает. <...> Под словами молитвы автор может иметь в виду молитву реальную, а также какие-либо слова, которые он считает для себя святыми. Например, слова матери или слова учителя, которые трудно забыть. И повторяя их в трудные моменты, человеку становиться намного проще»*.

Вместе с тем этот же читатель сопоставил данное стихотворение с произведением Тукая «Туган тел» – «Родной язык». *«Для Тукая родной язык столь же дорог, как молитва для русского поэта»,* – пишет автор этих размышлений.

По-своему схожие размышления мы нашли и в другом ответе. В нем, в частности, отмечается, что в татарской литературе есть стихотворение Тукая «Китап»: в нем так же, как и в произведение «Молитва», говорится о том, что в трудную минуту, когда горит душа, поэт берет в руки книгу, читает ее, и от этого ему становиться легче.

Таким образом, анализ ответов, полученных экспериментальным путем, показал, что размышления татарских читателей, специально изучающих родной язык и литературу, соответствовали их национальной идентичности. В них заметной была идея понимания стихотворения Лермонтова в свете ценностей татарской литературы, и в первую очередь, поэзии Тукая. Это выводило понимание произведения Лермонтова «Молитва» за пределы его «русскости», обуславливая возникновение *эстетической дистанции* с ним.

Иной характер восприятия и оценки стихотворения «Молитва» Лермонтова проявился в аудитории татарских читателей, получающих смежную с филологией специализацию (всего 15 человек). Нужно отметить, что только в четырех из пятнадцати ответах испытуемых проявилось тенденция к прочтению произведения Лермонтова вопреки его содержанию. Данные рассуждения очень похожи на выше процитированные оценки читателей 1 группы. Приведем отдельные фрагменты, характеризующие подобную тенденцию восприятия.

1. В стихотворении Лермонтова «Молитва» говориться о том, молитва имеет некую силу, которая помогает человеку в любые моменты его жизни. Когда человек читает молитву, на душе его становится спокойно, хорошо. «С души как бремя скатиться», – пишет поэт. Я думаю, что идея стихотворения в том, что в любых жизненных трудностях и радостях, в любые моменты жизни, человек должен молиться. Молитва имеет благодатную силу, она обязательно поможет найти верный путь.

2. Стихотворение Лермонтова «Молитва» написана с легкой душой. Слова молитвы таятся у нас в сердце. И та душевная легкость течет как ручей, превращаясь в чудесное стихотворение.

С молитвой можно прогнать то, что терзает нашу душу. Она возвращает нас к жизни. Почему то, когда я прочитала это стихотворение, мне вспомнилось произведение Тукая о книге. В этом стихотворении говориться о том, что чтение книг успокаивает душу. [Речь идет об известном стихотворении Тукая «Китап»].

3. Главный мотив этого стихотворения – мотив веры. Автор верит в Бога и в самые трудные минуты жизни обращается к нему.

В татарской литературе есть стихотворение Тукая «Ана догасы» [«Молитва матери»], в котором утверждается мысль силе молитвы. Молитва помогает людям в трудные минуты.

4. Стихотворение Лермонтова о важности молитвы, о вере в Бога. Мы верим, что существует высшая сила, и от этой мысли нам становится легко.

Анализ полученных результатов позволяет утверждать, что читатели этой группы рассматривали данное произведение в соответствии с его «горизонтом ожидания». Уравнивание «горизонта ожидания» произведения и «горизонта ожидания» читателей

не позволило последним увидеть в нем иные смыслы, скрытое идейно-психологическое содержание. Лишь в отдельных читательских ответах заметным стало стремление рассмотреть стихотворение Лермонтова «Молитва» через опыт родной литературы и творчества Тукая, в частности. Как известно, в произведениях Тукая сложилось особое отношение к Слову: здесь Слово неотделимо от Слова и воли Бога (Аллаха), который имеет безграничное влияние на человека и его судьбу.

Сделаем предположение, что менее полное и глубокое вхождение данных читателей в мир татарской литературы (повторим, что они, наряду с изучением татарской филологии, постигают основы других специальностей), не позволило им увидеть в произведении русского поэта такие смыслы, которые бы *расширяли* эстетическую дистанцию с воспринимаемым произведением. Понимание ими стихотворения Лермонтова «Молитва» лишь намечало, потенциально обозначало «выход» за рамки привычного, устойчивого представления о нем, который мог бы сложиться в свете опыта татарской литературы, ее национальных и культурных основ.

ЛИТЕРАТУРА

1. Тукай Г. Избранные произведения: В 2 томах. Казань: Татар. кн. изд-во, 2006. Т.1. 271 с. (на тат. яз.)

2. Хабибуллина А.З. М.Ю. Лермонтов и татарская литература начала XX века (к вопросу о межлитературном диалоге) // Ученые записки Казанского университета. Том 157. Серия гуманитарных наук. Кн. 2. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2015. С. 55–62.

3. Хабибуллина А.З. Русская литература в восприятии татарских читателей (эстетическая интерференция): дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1998. 168 с.

4. Хабибуллина А.З. Читатель в межлитературной коммуникации // Межкультурная коммуникация: филологический аспект. Казань, 2012. С. 167–171.

## ТАТАР АНТРОПОНИМИЯСЕНДӘ ЯСАЛМА НОМИНАЦИЯНЕҢ ТӨРЕ БУЛАРАК ПСЕВДОНИМНАР

***Хаҗиева Г.С.***

В статье рассматриваются особенности творчества татарских псевдонимов как один из видов искусственной онимической номинации, направленные на пополнение лексического фонда языка. В когнитивно-прагматическом аспекте автор описывает модель искусственной номинации, характеризует номинативные стратегии, типы моделей имятворчества, актуализируемые при создании антропонимов в татарском языке. В исследовании установлено, что в начале XX века в татарской антропонимической системе прослеживается бурный взлет творчества псевдонимов.

In article features of creativity of the Tatar pseudonyms as one of types of the artificial nomination, directed to replenishment of lexical fund of language are considered. In cognitive and pragmatical aspect the author describes model of the artificial nomination, characterizes the nominative strategy, types of models of a creativity staticized during creation of antroponim in Tatar. In research it is established that at the beginning of the XX century in the Tatar antroponimic systems rough rise of creativity of pseudonyms is traced.

Татар антропонимикасында ясалма номинациянең төре буларак псевдонимнарның ясалу-мотивацияләрен, антропонимик системада урыны билгеләү, әдәбият һәм тел яссылыгында кулланылышын тикшерү эше бүгенге көндә гаять дәрәҗәдә актуаль санала. Билгеле булганча, ономастика– һәрвакыт үсеш-үзгәреш кичереп, һәрдаим тулыланып торган система. Иҗтимагый тормышта һәм әдәбиятта аерым урын тоткан социаль төркемнәргә (язучы, сәясәтче, журналист, артист, рәссам, галим һ.б.) хас антропонимик бирәмлекләр – псевдонимнар да һәрдаим тулыланып торалар. Рус теле белемендә В.Г. Дмитриев псевдонимнарны– псевдономастика яки псевдонимика фәненең өйрәнү объекты итеп карый [3, с. 4]. Ул «Скрывшие свое имя» хезмәтендә рус һәм дөнья әдәбияты классикларының псевдонимнар үрнәгендә псевдономастиканың төп өйрәнү юнәлешләрен билгели, терминологиясен ача. Татар тел белемендә XX йөзнең 60 нчы елларыннан башлап кеше исемнәре, кушаматлар, фамилияләр төрле аспектларда өйрәнелеп, системалаштырылсалар да, псевдонимнар тел белеме яссылыгында җентекле тикшеренүдән читтә кала бирәләр һәм лингвистик яктан гаять дәрәҗәдә кызыклы өйрәнү объектын тәшкил итәләр. Татар псевдономастикасының өйрәнелә башлау тарихы

гомумономастик проблемаларның җанлану чорына – XX гасырның 60 нчы елларына туры килә. Билгеле булганча, бу чорда рус теле белемендә ономастика мәсьәләләренең калкуы, аның объект-предметы билгеләнүе, төп концептологик терминнарның формалашып, кулланылышка керә башлау шаукымы башка милли телләрнең фәнни юнәлешләрендә дә чагылмыйча калмый. Псевдонимнар татар тел белемендә, текстологиядә беренчеләрдән булып Г.Ф. Саттаров, Ш. Абилов, М. Бурнашева, М. Мәһдиев, М. Бөдәйли, З. Рәмиев кебек галимнәр тарафыннан өйрәнелә. Газета-журналларда чыккан әдәби әсәрнең кайсы язучыныкы икәнлеген билгеләү максатында, әдәби әсәрнең тел-стиль үзенчәлекләрен ачыклау белән беррәттән, нинди псевдоним кулланылып иҗат ителүе зур әһәмияткә ия. Шул нәүбәттә татар псевдонимнарын ачыклау, өйрәнү эше нигездә текстологлар, әдәбиятчы галимнәрнең игътибарын җәлеп итә. 1960 елда М. Бурнашева псевдономастиканың фәнни нигезле методологиясен булдырып, өйрәнелергә тиешле фән булуы турында яза, псевдонимнарны беренчел итеп барлау текстологиянең гаять дәрәҗәдә әһәмиятле эш булуын раслый: «бер язучының барлык әсәрләрен туплау өчен, иң башта аның нинди псевдоним белән язылганлыгын» билгеләүне мөһим дип саный [2, б. 175]. Татар ономастикасына нигез салучы Г.Ф. Саттаров та псевдонимнар мәсьәләсенә туктала, аерым бер язучыларның иҗаты мисалында аларның тел системасындагы әһәмиятен раслый. Псевдонимнар әдәбиятчы галимнәр, текстологларның (Ш. Абилов, Х. Госман, А. Әхмәдуллин, З. Рәмиев, М. Мәһдиев, М. Бөдәйли һ.б.) тикшеренүләрендә әдәбият, текстология фәннәренең метод-ысулларына нигезләнеп, әдәби чор, әдәби текст, язучы контекстында каралалар. Әдәбият, сәнгать, журналистика әһелләренең псевдонимнарын аерым бер сүзлек итеп эшләп чыгару эше М. Бөдәйли тарафынна башкарыла. Әлеге сүзлек 1969 елда «Казан утлары» журналының № 1, № 2 саннарында кыскартылган вариантта дөнья күрсә дә, аерым бер сүзлек буларак басылмый [7]. М. Бөдәйлинең псевдонимнар сүзлегенең кулъязмасы Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, сәнгать институтының Мирасханәсендә саклана. Әлбәттә, бүгенге көндә татар псевдонимикасының кулланылыш сферасы киңәя һәм һәрдаим үсеп-үзгәреп тора. Хезмәтендә М. Бөдәйли, кулланылыш үзенчәлекләреннән чыгып, псевдонимнарны өч төргә бүлеп карый: 1) күпләргә таныш булган язучы псевдонимнары; 2) заманында киң җәмәгатьчелеккә билгеле булган, әмма хәзерге көндә аз кешеләргә билгеле псевдонимнар; 3) хәзерге көндә аз билгеле булган псевдонимнар [7, б. 168]. М. Мәһдиев псевдономастиканы әдәбият тарихының әһәмиятле тармагы дип билгели [4, б.182]. Язучыларның шәхесен тану эшендә, аның турында этрафлы информация бирүдә әһәмияте зур булса да, псевдонимнар, беренче чиратта, антропонимик берәмлекләр буларак, лингвистик җәһәттән өйрәнелүне таләп итәләр. Псевдонимнарны өйрәнү тел (этимология, концептология, этнолингвистика, когнитив лингвистика кебек тармаклар белән дә бәйләнеш-мөнәсәбәттә) әдәбият, текстология фәннәренең метод-чаралары ярдәмендә тикшерелеп, системалы-бәйләнелештә өйрәнелергә тиеш дип саныйбыз. Текстология юнәлешендә, әлеге фәннең метод-ысулларны кулланып, әдәбиятчы-текстолог З.З. Рәмиев Г. Тукай псевдонимнарын аерым өйрәнеп, җентекле анализ ясый, Г. Тукайның 67 гә якын псевдонимын аерып күрсәтә [6, б.239].

Билгеле булганча, лексик берәмлекләр һәм, шул исәптән антропонимик берәмлекләр, кешенең тирә-юнен чагылдыру белән бергә, татар халкының үзаңын, теләк-омтылышларын, тормышка карашын, автор позициясен, дөнья тирәлеген анализларга мөмкинлек бирәләр, шул җәһәттән, әлеге мәкаләбездә татар псевдонимнарын когнитив, ономасиологик аспектта тикшерүне максат итәбез.

Псевдоним (грек сүзе «ялган исем йөртүче» дигәнне аңлата) – иҗтимагый тормышта чын исем белән бергә яисә аның урынына кулланылып, уйлап чыгарылган исем [5, с. 117]. Төрки халыкларда псевдоним сүзе урынына *тәхәллүс, махлас, мөстәгар* кебек терминнар кулланылышта йөри. Псевдонимнарның түбәндәге төрләре билгеләнә: *криптоним* – билгеле бер шәхес белән бәйләнешен аеру мөмкинлеге булмаган язучының әсәр ахырына куелган имзасы яки авторның чын исемен яшерүгә корылган атама [3, с. 195]; *гетероним* – әсәрнең эчтәлеген чагылдырган һәм аерым өлешләрендә ахырында кулланылган псевдонимы [3, с. 127]; *аллоним* – автор тарафыннан башка бер шәхеснең исемен куллану [3, б. 127]; *никнейм* – интернет коммуникациясендә кулланылган яшерен исемнәр.

Рус әдәбиятында псевдонимнар язма дини китапларыннан үсеш алалар. Беренче рус инкыйлабы елларында псевдонимнар куеп иҗат итү аеруча киң тарала.

В.И. Ленинның йөздән артык псевдонимы булуы билгеле. Бары тик Октябрь инкыйлабыннан соң гына үзенең чын исемен матбугатта куллана башлый. Русларның исем бирү традициясендә псевдоним фамилияне, исемне, отчествоны, хәтта исем формуласын да алыштыра. Псевдонимнар ясалма номинациянең актив берәмлекләреннән саналалар. Адресатка булган мөнәсәбәт аппелятив лексиканың вазыйфасы белән билгеләнә.

Псевдоним – сүз буларак, телнең аерылгысыз өлеше, лингвистик методлар белән өйрәнелүне таләп итә һәм аның законнарына буйсына. Ул кешенең күзаллауларын, телне тоемлауны гына чагылдырып калмый, юморга да ишарәли. Псевдоним сайлау кешенең иҗади ихтыяҗын реальләштерә. Аның мәгънәсе экстралингвистик реальлекне, шул ук вакытта, телдәге эчке мөнәсәбәтләргә генә бәйле түгел, ә прагматик һәм психолингвистик юнәлеш белән дә бәйлелекне күрсәтә.

Псевдоним уйлап чыгарылган, ясалма, яшерен сүз буларак, номинатив функция башкара. Аның номинатив-эзотерик роле иҗтимагый-бәяләмә, экспрессив функцияләр белән тулылана төшә. Чын исемне яшерүнең объектив һәм субъектив сәбәпләре бар: бер яктан чын исемне яшерү фамилиянең яки исемнең яңгырашы килешле булмавы белән аңлатылса, икенче яктан, цензурадан качу, чын фамилияне полемикага җиткерүдән курку белән аңлатыла.

Исемне яшерү йоласы бик борынгы чорлардан ук килә. Беренче псевдонимнар М.Кашгариның «Дивание-лөгат ит түрк» әсәрендә үк теркәлгәннәр. Китапчылык барлыкка килү чорларында псевдонимнарны куллану тагы да активлаша. XIII – XIX гасырда да әдипләрнең, галимнәрнең псевдонимнар куллануы билгеле: Сәиф Сараи, Мәүлә Колый, Утыз Имәни, Г. Кандалый, Акмулла, Мәрҗани һ.б. Билгеле булганча, Беренче рус инкыйлабыннан соң, татар тормышында җанлануы, татар матбугатының барлыкка килүе әдәби әсәрләр, тәнкыйть мәкаләләре язуга сәбәп була, татар иҗтимагый тормышына тагы да киң перспективалар бирә. Шул нәүбәттә XX гасырда татар псевдономастиконының үсеше күзәтелә. Авторлар цензура тәнкыйтеннән куркып, исемне, фамилияне, кешенең җенесен, милләтен псевдоним астына яшерергә мәҗбүр булалар. Псевдонимнарның семантикасы мәгънә эчтәлегенең күп төрлелеге белән билгеләнә. Алар язучының милләте, туган урыны, характер үзенчәлекләрен чагылдыруда хезмәт итәләр.

Әдәби псевдонимнарны телдә һәм сөйләмдә кулланылган функцияләреннән чыгып: 1) характеристика бирә торган 2) эмоциональ-экспрессив 3) символик 3) комик кебек төрләргә бүләргә мөмкин. Кеше дөньяны, тирә-юньне танып-белүдә төрле когнитив-ономасиологик чаралар куллана. Псевдонимнар кешенең дөньяны танып-белүдә кулланган лексик чаралардан чыгып, түбәндәге төркемнәргә бүленәләр: 1) кешенең физик үзенчәлекләрен чагылдырган псевдонимнар: Ш. Бабич (Кара күз), Т. Гыйззәтуллин (Кечкентәй), Ф. Сәйфи-Казанлы (Батыр күз); 2) кешенең рухи халәтен, эчке үзенчәлекләрен чагылдырган псевдонимнар: Г. Тукай (Тиктормас), (Дугъры), (Сөемсез), (Биик усал), З. Рәмиев (Дәрдемәнд), Ш. Бабич (Чытырман), Г. Кутуй (Утмалай), Г. Сәгъди (Рухи), (Зәүкый), (Фикри); 3) кешенең билгеле бер урынчылыкка, территориягә бәйләнешен күрсәткән псевдонимнар: М. Галиев (Мөхәммәт Олыюлгави), Ф. Сәйфуллин (Фатих Сәйфи-Казанлы), Г. Камал (Г. Казани) һ.б.; 4) хайван һәм үсемлек атамаларына бәйләнелешле псевдонимнар: Г. Тукай (Кырмыска), (Каз), Кәрим Әмири (Карт чаян), (Черки), (Борча), Ш. Бабич (Шөпшә), М. Бөдәйли (Шәрык Кигәвене) һ.б.; 5) мәсләк, профессия атамаларын чагылдырган, кешенең иҗтимагый урынын билгеләгән псевдонимнар (титлонимнар (лат. теленнән titulus – титул): Г. Тукай (Адвокат), (Мөтәрҗим Г. Тукай), Г. Ибраһимов (Мәхбирегез), М. Галиев (Хәбәрче), (Мөхбир), Ф. Бурнаш (Иген игүче); 6) топонимнарга бәйле псевдонимнар: Г. Кутуй (Казбек), (Һималай), Ә. Фәйзуллин (Фәез Идел), Ф. Кәрим (Дим); 7) мифопоэтик мәгънәгә ия псевдонимнар (героним): Г. Тукай (Шүрәле), (Һөд-һөд), (Җен), (Мәҗнүн), (Салам Торхан), (Бичура), Нәҗип Думави (Өй анасы), (Домовой); 8) кешенең билгеле бер социаль катлавын белдергән псевдонимнар: Г. Тукай (Ишан Кирамәт), (Имам Хатыйб), Ф. Әмирхан (Дамелла) һ.б.; 9) кешенең сәяси фикерләрен һәм аерым партияләргә бәйлелеген күрсәткән псевдонимнар: Г. Тукай (Бер Фикерле), М. Бөдәйли (Большевик); 10) милләт, диалект вәкиле атамасына бәйле псевдонимнар: Г. Тукай (Болгар), Ф. Бурнашев (Мишәр), Ш. Бабич (Таулы башкорты), (Башкорт); 11) юмор-сатирага корылган псевдонимнар (пайзоним (грек телендә paizein – көлке): Г. Тукай (Гөмберррт), (Дөбернуш), (Шәкерт угы), Ф. Әмирхан (Ташмөхәммәт), (Зәмзәметдинов), Н. Исәнбәт (Мәлгунь),

(Күкташ), (Башы Бозык), (Дамелла Талпан), Ф. Бурнаш (Номерсыз урындык); 12) тарихи атамаларга бәйләнелешле псевдонимнар: С. Рәмиев (Себектәгин – төрки ханнарының берсе, Һиндыстанда, Әфганистанда яу башлыгы булып дөнья шаулаткан)

Ясалыш-төзелеш ягыннан псевдонимнар берничә төргә бүленәләр: 1) исемнең беренче хәрефләрен чагылдырган псевдонимнар: Гъ.Т. – Габдулла Тукай, Д. – Дәрдемәнд, ШК – Шәриф Камал, ММ – Мәхмүт Галәү; 2) исем-фамилиянең беренче иҗеген кыскарту нигезендә ясалган псевдонимнар (апоконим (грек телендә apokopto – кисү): Сабур – Сафа Борһан, Буф – Фәтхи Бурнаш; 2) исем-фамилиянең ахыргы иҗекләрен кирегә таба үзгәртү нигезендә ясалган псевдонимнар: Феакут – Тукай, Сәләй – Сәлах Атнагулов, Рим – Фатих Кәрим; 3) исем-фамилияне кыскартып атау нигезендә ясалган псевдонимнар (пароним (грек телендә para – янында): Г. Тукаев (Г. Тукай) Г. Алпар (Г. Алпаров), Ф. Бурнаш (Ф. Бурнашев), Җ.Вәлиди (Җ.Вәлидов), Мәҗит Гафури (М. Гафуров), Г. Тукай (Г. Тукаев), Г. Гобәйдуллин (Г. Газиз), Ф. Кәримов (Ф. Кәрим), М. Максудов (Мәхмүт Максуд), Һ. Такташев (Һади Такташев), Кәрим Әмиров (Кәрим Әмири), Муса Җәлилов (Муса Җәлил) һ.б.; Псевдонимнарның әлеге структур-ясалыш төре татар әдәбиятында, сәнгатендә киң кулланыла; 4) Сүзтезмәләрдән торган псевдонимнар: Г. Тукай (Имзасыз Ярәретдин), (Счет төймәсе), (Хәкыйрь Шүрәле), («Хәятел-хәйванат»тан күчерүче) һ.б.; 5) җөмләләрдән торган псевдонимнар: Г. Тукай (Уральск җәмгыяте хәйриясенең бик усал бер члены), (Уральскийда Г. Тукаев), (Шүрәле дию белгәйсез), (Сәяхәте көбралар ясаучы Шүрәле) һ.б. 6) инкарь җөмләле псевдонимнар: Г. Тукай (Мин язмадым), (Мөхәррир мин түгел)

Татар псевдономастикасында коллектив псевдонимнар да очрый. Коллектив псевдоним бер яки берничә авторның бергә язылган әсәренә куелган атамасы (полионим (грек телендә poly – күп): Әүлия һәм компаниясе – Г. Камал һәм Вәли Шәфигуллин, Шагыйрь трест – Кави Нәҗми һәм Һади Такташ, Канәзагел – Кави Нәҗми һәм Закир Гали һ.б.

Әдәбиятта псевдонимнар язучының әсәрнең җанры, эчтәлеге белән тыгыз бәйләнеш-мөнәсәбәттә кулланыла: сатирик әсәрләрдә кулланылган псевдонимнар: Ф. Әмирхан (Ташмөхәммәт), (Т.-д.), әдәби критик әсәрләрдә кулланылган псевдонимнар: Ф. Әмирхан (Марксист), (Дамелла), Г.Ибраһимов (Габди) һ.б.

Язучылар аерым бер псевдоним белән бастырылган әсәрләрен бергә туплап чыгара һәм шул җыентыгына язган сүз башында псевдонимының мәгънәсен ача: Г. Тукай, мәсәлән, Яшен журналында чыккан барлык әсәрләрен «Яшен ташлары» исемендә бер җыентык чыгара [2, б. 152].

Татар әдәбиятында псевдонимнарның функциональлелеге төрлечә чагылыш таба. Кайбер псевдонимнар кулланылыш ягыннан чикле булып, кеше үз фамилиясенә кире кайта (Разин – Г. Бәширов, Бичура – А. Таһиров), кайбер псевдонимнар халык арасында киң кулланылыш алар: Кандалый (Габделҗаббар Габделмәҗит угылы, Акмулла – Мифтахетдин Камалетдин углы, Х. Туфан – Хизбулла Гөлзизин).

Псевдонимнар апеллятив һәм ономастик модельләр нигезендә барлыкка килә. Аларның үз ясалыш модельләре бар һәм бирелү традицияләре формалаша. Псевдонимнар антропонимнарга хас үзенчәлекләргә ия: тел һәм сөйләм яссылыгында информатив үзенчәлекләре фонетик, сүзьясалышы, лексик, грамматик яссылыкларда ачыла. Әдәби уйдырма буларак псевдонимнар экстралингвистик шартларның тәэсирендә дә барлыкка киләләр. Чор, аңа хас үзенчәлекләр, әсәрнең эчтәлеге, адресаты һ.б. күренешләр дә псевдонимнарның барлыкка килүенә этәргеч ясый. М. Мәһдиев фикеренчә, псевдонимнарны алуда приципиаль закончалыклар юк, чөнки язучының манерасы, шәхесенә бернинди мөнәсәбәттә булмаган псевдонимнар да шактый. Шулай да, антропонимиканың төп метод-ысуллары белән эш иткәндә, һәрбер псевдонимның семантикасында, структур-төзелешендә лингвистик яки экстралингвистик сәбәпләрне ачыклау мөмкин дигән фикердә торабыз. Чөнки һәрбер антропоним (бу очракта псевдоним) лингво-, этно- культура яссылыгында знак (билге) вазыйфасын башкара, ә бу очракта һәрбер знак телдә дөнья картинасын чагылдыруда мөһим роль уйный.

ӘДӘБИЯТ


1. Бондалетов В.Д. Русская ономастика. М.: Просвещение, 1983. 224 с.

2. Бурнашева М. Псевдонимнар турында // Казан утлары. 1960. № 8. Б. 151–153.

3. Дмитриев В.Г. Скрывшие свое имя (из истории анонимов псевдонимов). М.: Наука, 1977. 309 с.

4. Мәһдиев М. XX йөз башы татар әдәбиятында псевдонимнар // Казан утлары. № 12. Б. 175–182.
5. Подольская Н.В. Словарь русской ономастической терминологии. М.: Наука, 1978. 200 с.
6. Рәмиев З. Г. Тукай псевдонимнары // Нил Юзеев – шигъри җанлы акыл иясе. Казан: Мастер-Лайн, 2000. Б. 239–247.
7. Һади М. Псевдонимнар турында берничә сүз // Казан утлары. 1969. № 1. Б. 168–171.

# ФОЛЬКЛОРНО-МИФОЛОГИЧЕСКИЕ ПЕРСОНАЖИ, ПОКАЗЫВАЮЩИЕ ВЗАИМОСВЯЗЬ МЕЖДУ НАРОДАМИ

***Хакимова В.Х.***

В статье исследуются мифологические представления татарского и удмуртского народов на материале устного творчества (песен, сказок, детских игр, считалок, дразнилок и т.д.) и этнографических реалий. Выявляются мировоззренческие аспекты. Сюжеты произведений развиваются в рамках национальной мифологической парадигмы, сложившихся этнических представлений, связаны с повседневной хозяйственной, бытовой жизнью народа, что составляют мощный пласт фольклорных произведений с элементами мифологии.

The article examines the mythological ideas of the Tatar and Udmurt peoples on the material of oral tradition (songs, tales, children's games, rhymes, teasers, etc.) and ethnographic realities. Revealed ideological aspects. The plots of the works developed in the framework of the national mythological paradigm, existing ethnic perceptions connected with daily economic and domestic lives of the people that are powerful layer of folk music with elements of mythology.

Фольклор – это богатая кладовая народной мудрости многих поколений. Как и все народы, татарский народ имеет богатое устно-поэтическое творчество. В сказках и легендах, песнях и загадках, пословицах и поговорках ярко отразились его взгляды на окружающую природу и жизнь, его отношение к различным историческим явлениям и событиям, его внутренний духовный облик. В фольклоре татар ярко выражены исторические контакты с другими народами, в частности с удмуртами. Об этих связях будет идти речь в данной работе. Особенно сильны связи в сказочных персонажах наших народов. Как известно, сказки создавались тогда, когда жизнь народов была беззащитна и бесправна, когда народ не имел возможности получить образование. Несмотря на эти явления в сказках многих народов, в частности удмуртов и татар, можно найти смелое выступление героев из народа, бессмертие их, уверенность в победе над враждебными силами природы и человеческого общества. К таким героям относятся: Ядыгерь, Эштерек, Шамардан. Особенно интересны социально-бытовые сказки, которые сочетаются у разных народов. Если у удмуртов герой Педунь или Лопшо Педунь, Алдар или Алдар Иван, то у татар Хоза Насыртдин, Алдартаз или Таз плешивый: все эти герои борются с социальным злом и побеждают.

Многие фольклорные персонажи характерны лишь некоторым регионам, в частности удмуртам, проживающим на территории современного Татарстана и Башкортостана. К таким относятся мифологические персонажи – Алангасар, Бечора (Бичура), Шурали (Шурале.) Пери известен как татарам, так и удмуртам. Много спорных вопросов по поводу происхождения этих персонажей. Это и послужило поводом написания данной работы. Очень интересен и песенный фольклор наших народов. Наиболее привлекательны короткие песни и частушки. Об этом жанре также идут споры, с какого языка они переведены; с татарского на удмуртский или с удмуртского на татарский, а может переведены с русскогоязыка.

В последнее время стали популярны переводные песни (обмен песнями). Немало песен переведено с удмуртского на татарский и с татарского на удмуртский. Этому способствовало многовековое общение тюркских народов с удмуртами. Для основательного рассмотрения фольклорных связей татарского и удмуртского народов нужно сопоставлять фольклорные материалы обоихнародов. То, что имеется у чувашей, мари. Ведь в составе татарского фольклора немало отдельных сказок народов Поволжья. И наоборот, в составе марийского и удмуртского фольклора несомненно имеется элементы татарского.

Наблюдаются общие мотивы и в сказочном творчестве наших народов. Особенно они характерны удмуртам, проживающим в южных районах Удмуртии и в Татарста-

не. Схожесть фольклорных персонажей встречается часто в антропонимии, в мифологических и социально-бытовых сказках. Некоторые тюркские антропонимы вошли в удмуртские легенды, как личные имена фольклорных персонажей. Интересны в этом отношении удмуртские герои: Эштерек, Шемордан, Ядыгарь, Иштуган. Эти же имена сохранились и в названиях населенных пунктов Удмуртии и Татарстана. Некоторые из этих деревень были заселены удмуртами. Об этом свидетельствуют многочисленные данные, показывающие процесс тюркизации удмуртов Заказанья. В течение XVIII века отатарились удмурты деревень Поршур, Шамардан, Новое Семен-Головино, Малое Семен-Голотвино, Чура, Малая Чура современного Кукморского района. В переписи 1716 года жители тех селений были записаны удмуртами. По подсчетамН.А. Бобровникова, только в XIX отатарилось 15 тысяч удмуртов Казанской губернии [1, б. 47].

Эштерек – герой в одноименной легенде [2, с. 125] удмуртского народа. Известно, что имя Эштерек (Иштерек) является древним булгаро-татарским антропонимом. По преданию, батыр Эштерек борется против бигеров (татар), побеждает их, но тягаться с вумуртами (водяными) не может. Из-за невыполнения своего обещания вумурту батыр гибнет. В этой легенде не только действуют силы природы, но что-то другое.

«Среди удмуртов жил в древние времена замечательный великан – силач Эштерек, занимался земледелием, на войны не ходил. А войны тогда велись постоянно. Предстояла битва, Эштерек не имел ни боевого коня, ни оружия. Он не был готов к битве. Даже вождем (торо) он стал после Идны и Ожеса. Не убивал, не стрелял – много пришлось ему пережить. Преодолеть эти страдания ему помогли силы природы и мифические существа: клен, вырванный с корнем, водяной подарил лошадь, но в придачу попросил вместо коня татарку. В бою на долю Эштерекадосталась красавица, какую он не встречал у себя. Везет ее домой Эштерек, любуется, думает: “Вот хороша будет жена”. Вдруг забушевала река. Оглянулся Эштерек. Глядит, дивится... Потом бледнеет, заволакиваются глаза: перед ним по пояс в воде стоит вумурт.

– Что, вумурт? – спросил Эштерек.

– Позабыл ты, видимо, уговор. Отдай татарку!

– Э, шалишь, старик! Если хочешь, привезу тебе беззубую старуху, старую каргу.

И расхохотался Эштерек. Ничего не сказал и скрылся вумурт. Вдруг нахлынули волны и Эштерек с прекрасной татаркой и могучим конем исчезли под водой» [3, с. 36].

И в «Легенде о владычестве татар» ясно показано, за что наказывались татары. Видимо, это и есть одна из сторон запрета древних удмуртов и татар не вступать в родственные отношения с другими народами. Второе: не разрешалось брать в жены рабынь, пленниц. Образ Эштерека вошел в удмуртскую литературу. Написали поэму «Эштерек» Кедра Митрей и Николай Байтеряков.

Более древним является герой Ядыгарь. Татары считают этого героя своим. В селениях, носящих имя этого героя (деревня Ядыгарь) живут татары и кряшины.

Происхождение слова Ядыгарь из устаревшего удмуртского слова «Яды». (Удмуртско-русский словарь 1948 года характеризует, что «яды» – южное устаревшее – силач, богатырь) [4, с. 80].

В толковом удмуртско-русском словаре [6, с. 367] отмечено: Яды – происхождение южное – непобедимый, богатырь. В литературу Ядыгарь вошел как национальный герой, предводитель. Если Ядыгарьхарактерен только для южных удмуртов, то Шамардан и Эштерек бытуют среди всех удмуртов. Сохранились названия населенных пунктов с такой огласовкой среди татар и удмуртов. В Татарстане есть железнодорожная станция Шамардан, деревня Шамардан. Как уже упоминалось в переписи 1716 года, жители деревни Шамардан были записаны удмуртами [7, с. 366]. В наше время как в Шамардане, так и в Ядыгере удмурты не живут. Деревня Шамардан имеется в Игринском и Юкаменском районах Удмуртии.

Загадочными остаются мифические персонажи, которые имеют одинаковые характеры в удмуртской и татарской мифологии.

Как мы видим, образ Шурали (Шурале) привлекал учёных разных национальностей: татар (Р.Г. Ахметьянов, Л.Ш. Замалетдинов), удмуртов (В.И. Алатырев, Д.А. Яшин), англичан (Й. Бензинг), венгров (Ю. Мессарош).

Из них лишь Й. Бензинг считает, что происхождение народного мифа про Шурали (Шурале) не татарское. Это исследование опубликовано в «Бюллетене» (1947 год), издаваемом при Лондонском университете.

Немало толкований дают языковеды о происхождении слова «шурали», возможно будут и другие толкования. Этой задачей занимаются лингвисты-этимологи. Нам сейчас важна фольклорная часть. В своих трудах ученые сравнивают «Шурали» с палэсмуртами (половинниками), нюлэсмуртами (лесными), даже и с пери. Шурали по некоторым повадкам, хоть и похож на них, но он — отдельное существо иного типа.

Связь поэмы «Шурале» Г. Тукая с фольклором татарского народа изучена довольно обстоятельно.

Тукай живёт в памяти народов России и становится ещё ближе им. Его «Шурале» интересуются и народы мира. Поэма «Шурале» Г. Тукая переведена на многие языки мира, в том числе Гаем Сабитовым на удмуртский язык, который издан в сборнике стихов «Стихи детям».

Был задан вопрос удмуртскому поэту-переводчику Г. Сабитову, с какого произведения он начал переводить с татарского на удмуртский. Без затруднения ответил, что с поэмы «Шурале».

При исследовании Шурале большинство учёных опираются на поэму Габдуллы Тукая. В основном образ Шурале относят к татарскому фольклору, учитывая только татарские тексты. Но для полного раскрытия образа «Шурале» нужно рассмотреть, сопоставляя сказания об этом персонаже у удмуртского и татарского народов.

Как и в татарской сказке о шурале, удмурты словами шурали или урали называют филина, который гукает в лесу. А марийцы гукающую ночную птицу называют Шур-лого «половина – карлик». Слово шурали вошло в активный словарь удмуртского языка и переводится на русский язык как «филин», в диалектах — сыч.

В татарской сказке «Шурале» дровосек встречается с лесным существом шурале и называет себя Былтыром (буквально прошлый год). Находчивый дровосек просит, чтобы тот помог ему расколоть колоду. «Засунул Шурале пальцы в щель, а дровосек вытащил топор. Тут колода сомкнулась крепко-накрепко и прищемила пальцы Шурале. Только это и нужно было дровосеку. Взял он свои дрова и уехал поскорее в аул». В удмуртских и татарских сказках шурали не убегает – уходит сам человек (дровосек). Это и показано в поэме «Шурале» Г. Тукая.

Поэма «Шурале» является яркой страницей творческой биографии Тукая. Однако не менее интересны и остальные его сказки, связанные с мифическими существами. Например, «Су анасы» («Водяная»).

*«В исполнение приводит хитрый замысел джигит, Топором он бьёт по клину, что в расщелине сидит. Шурале, засунув в пальцы, замер, помня уговор,*

*Видно, хитрости не понял и не взглянет на топор. Вскоре клин, освобождённый, отлетел куда-то прочь. — Хлоп! Бревно зажало пальцы, руку вытащить невмочь... Рвётся, бьётся бедолага, он от боли сам не свой,*

*Между тем джигит с телегой собирается домой. Шурале он знать не хочет, под узды коня ведёт,*

*Вопли громкие он слышит, но и ухом не ведёт».*

(перевод С. Ботвинника)

Характерные сказки встречаются и у других народов: башкир, чувашей, марийцев. Их можно назвать сказки-подражания. В татарской сказке «Шурале» Былтыр — прошлый год, в удмуртской сказке Нюлэс-мурт Мим (миым) – прошлогодний. «Услыхали крики его товарищи, прибежали к нему и спрашивают:

– Что случилось с тобой?

– Застрелил меня.

– Кто? Когда?

– Мим.

– О миым ужезкызьышедьтод? (прошлогоднее дело как найдёшь?)

Шурали далёк от нюлэсмурта. Хотя многие исследователи объясняют, что Шурали не только лесное существо и хозяин леса. Все описания в сказках и поэме Г. Тукая «Шурале» противоречат этому высказыванию. В данный момент человек всегда побеждает Шурали умом, хитростью.

ЛИТЕРАТУРА

1. Алатырев В.И. Этимологический словарь удмуртского языка: Буквы А и Б. Ижевск 1988. С. 76–78.

2. Яшин Д.А. Об удмуртском сказочном персонаже Алангасаре.

3. Проблемы изучения финно-угорского фольклора. Саранск. 1972. С. 97.
4. Ахметьянов Р.Г. Общая лексика духовной культуры народов Среднего Поволжья. М., 1981.
5. Яшин Д.А. Общие мотивы в сказках пермских и тюркоязычных народов «Фольклор народов РСФСР», Уфа, 1974.
6. Удмуртско-русский словарь. М., 1948. С. 367.
7. Борисов Т.К. Удмурткыллюкам (Толковый удмуртско-русский словарь). Ижевск, 1932. С. 366.
8. Уваров А.Н. Художественное своеобразие удмуртской сатиры. Ижевск, 1979.

## МӘКТӘПТӘ ЛИРИК ӘСӘРЛӘРНЕҢ КОМПОЗИЦИЯСЕН ТИКШЕРҮ
### (Габдулла Тукайның «Пар ат» шигыре мисалында)

***Харисова Г.Ф.***

В статье описывается методика изучения языка и композиции лирических произведений в общеобразовательных организациях. На примере изучения композиции стихотворения Г. Тукая «Пар ат» автор показывает способы и приемы анализа стихотворений в школе, отмечая, что это зависит от особенностей построения произведения, от вида и жанра художественного текста.

In article the technique of studying of language and composition of lyrical works in the general education organizations is described. On the example of studying of composition of the poem G. Tukaya "Couple of horses" the author shows ways and receptions of the analysis of poems at school, noting that it depends on features of creation of work, on a look and a genre of the art text.

Мәктәптә лириканы өйрәнү тәрбия процессының аерылгысыз өлешен тәшкил итә, чөнки лирика ул – кешенең иң нечкә күңел кылларына тәэсир итә, үсеп килүче баланың рухи дөньясы формалашуга аеруча нык йогынты ясый торган әдәбият төрләренең берсе.

Лирик әсәр эчтәлеген тәшкил иткән хис һәм кичерешләрнең ни дәрәҗәдә катлаулы булуы һәркемгә мәгълүм. Укучылар белән шигырьне турыдын-туры тикшерү барышында әлеге югары хисләр «түбән төшәргә», ягъни үзләренең төсен җуярга мөмкин. Лирик әсәрләрнең сәнгатьле формасын нәтиҗәле итеп тикшерү укучыларга шигырьдәге поэтик мохитне тоярга, аңа тагын да якынаерга, шуның «эченә кереп китәргә» ярдәм итә. Шигырьнең сәнгатьле төзелеш структурасы элементлары, аларны тикшерү методикасы белән укучыларны «гадидән – катлаулыга» принцибы буенча даими таныштырып барырга кирәк. Лирик әсәрләрне өйрәнү нинди өлешләрдән торганын, аларны нинди тәртиптә башкарырга кирәклеген укучылар ачык итеп күзалларга тиеш. Әлеге эш башлангыч классларда ук башланып, урта һәм югары сыйныфларда системалы рәвештә үстерелә.

Шунысын да искәртеп китү урынлы булыр: лирик әсәр композициясен тикшерү барышында теге яки бу элементны аерып чыгару ул шартлы рәвештә генә була, шул ук вакытта без аны бөтеннең өлеше итеп кенә карыйбыз, чөнки әсәрне тикшерү ул аны аерым кисәкләргә таркатуны түгел, авторның әйтергә теләгән фикерен ачыкларга тырышу барышында аерым тел элементларын шартлы рәвештә аерып алуны гына күз алдында тота. Укучылар да моны яхшы аңларга тиеш.

Поэтик текстны өйрәнү барышында аның композициясен тикшерү шактый әһәмиятле мәсьәлә булып тора. Ни рәвешле тикшерү юлы исә әсәрнең төзелеш үзенчәлекләренә бәйле. Шул ук вакытта мәктәптә әсәрләрнең төзелеш үзенчәлекләрен өйрәнүгә бик үк игътибар да җитеп бетми. Тәҗрибә күрсәткәнчә, әлеге эш еш кына әсәрнең планын төзү һәм андагы өлешләрнең үзара охшаш һәм аермалы якларын чагыштырудан узмый. Шуңа күрә поэтик әсәрне системалы итеп өйрәнүнең беренче этабында ук (5–6 нчы сыйныфларда) шигырьнең композициясен төрле яклап күзәтү нәтиҗәле булыр иде.

Лириканың төп сурәтләү объекты – кешенең күңел дөньясы – гаять катлаулы һәм бай күренеш ул. Аңа тойгы-кичерешләр, кәеф-моң, халәт һәм башка төрле психик кичерешләр сыя. Лирик әсәрләрдә шагыйрьнең әнә шул тормыш күренешләре тәэсиреннән туган күңел дөньясы чагыла да инде. Лириканың эмоциональ, хис-кичерешләргә бай булуы аның формасына да тәэсир итә. Әлеге жанр төгәл, сәнгатьле, аһәңле сөйләүне сорый, анда һәр сүз аерым бер мәгънәви һәм эмоциональ көчкә ия булырга тиеш. Шуңа күрә лирика шигъри сөйләм аша бәян ителә. Бу сөйләмдә сурәт, тойгы, яңгыраш,

ритм, аваз – барысы да әһәмиятле. Лирикада идея шигырьнең нинди дә булса өлешендә, хәтта бик уңышлы сайланган өзекләрдә түгел, ә бөтен әдәби структурада урнаша, чөнки «шигырь ул – катлаулы төзелешле мәгънә. Аның бөтен элементлары, асылда, мәгънә элементлары» [2, б. 88].

Лирик әсәрләрне анализлауда, төр сыйфаты белән бергә, жанр үзенчәлекләре дә әһәмиятле. Лириканы жанрларга бүлү бүгенге әдәбият белемендә шактый бәхәсле мәсьәләләрдән санала. Әдәбият укыту методикасында кабул ителгәнчә, тематик бүленешне файдаланып, өч жанрны билгеләп үтәргә мөмкин, бу – пейзаж лирикасы, гражданлык яки сәяси лирика, мәхәббәт лирикасы [1, б. 55].

Шунысын да ассызыклап үтү мөһим: һәр шагыйрьнең үз тавышы, үз идеалы, үз мәхәббәте һәм нәфрәте, теге яки бу жанрга хас һәвәслеге, сурәтләү чараларының үз арсеналы, ниһаять, һәркайсының бары тик үзенә генә хас лирик «мин»е бар. Шуңа күрә, лириканы өйрәнгәндә, укытучының төп бурычы – шагыйрьнең менә шушы үзенә генә хас лирик дөньясын барлык буяулары, төсмерләре белән укучыларга җиткерү.

Программа буенча, 5 нче сыйныфта лирик шигырьләр белән танышу Г. Тукайның «Пар ат», «Туган җиремә» шигырьләре белән башланып китә, алга таба Ш. Галиевнең «Һәркем әйтә дөресен», Ф. Яруллинның «Сез иң гүзәл кеше икәнсез» шигырьләре белән үстерелә [3, б. 16].

«Пар ат» шигыре мәгърифәт, фән, мәдәният үзәге булган Казанга белем эстәргә чыгып киткән шәкерт – лирик герой исемен сөйләнелә. Беренче кат шигырьне укытучы яки сәнгатьле сөйләм осталары башкаруында тыңлату тәэсирлерәк була. Укыр алдыннан, укучыларга шигырьнең гомуми эчтәлеген аңлардай сорау бирергә кирәк:

– Укучылар, хәзер сез Г. Тукайның «Пар ат» шигыре белән беренче кат танышасыз. Бик игътибар белән тыңлап утырыгыз: әсәрдәге лирик герой нинди хис-кичерешләр белән Казанга юл тота? Аның өмет-хыяллары нинди?

Шигырьне укып чыккач, укучылардан аларның аны ничек итеп беренче кат хәтергә алулары тикшерелә. Аннан һәр строфасын укып тикшерү эше башлана.

Беренче строфада ук лирик герой үзенең Казанга юл тотуы турында әйтә. Биредә укучыларның игътибарын билгеле бер авазларның – [к], [т], [р], [п], [къ] тартыкларының тәртипле рәвештә кабатлануларына игътибар иттерергә кирәк.

– Укучылар, сез ничек уйлыйсыз: әлеге авазларның шул рәвешле чиратлашып килүе сөйләмгә нинди аһәң өсти? (таш юлдан барган пар атларның тояк тавышлары ишетелгәндәй була).

Икенче һәм өченче строфаларны тынычрак тавыш белән укырга кирәклеген искәртәбез, чөнки бу юлларда лирик герой тынычланып, уй-хыялларга бирелеп утыра, аны «тәмам баскан йокы».

– Әлеге юллардан сизелгәнчә, лирик герой нинди хис-тойгылар белән юлга чыга? (өмет катыш курку, шатлык-куаныч хисләре).

– Ни өчен? (чөнки шагыйрь «Шатлык белән нурлар чәчеп ай ялтырый; Искән әкрен җил белән яфрак, агачлар калтырый», – дип яза).

Тора-бара (4–12 нче строфалар) бу хис сагышлану, эч пошу, хәсрәтләнү белән алышына, чөнки лирик герой үзенең торган-яшәгән шәһәре, якыннары, туганнары белән мәңгегә аерыласын күңеле белән сиземли. Әлеге хисләрне тагын да калкурак итеп күрсәтү өчен, шагыйрь, мәгънәләре белән үзара охшаш сүзләрне – синонимнарны бербер артлы тезеп китеп, синонимик градация барлыкка китерә. Укучылардан әлеге урыннарны табып, укып күрсәтүләрен сорарга кирәк: «Сау бул инде, хуш, бәхил бул, и минем торган җирем». Тагын шунысына да игътибар итәргә кирәк: «сау бул» сүзе бик озак вакытка аерылмаганда кулланыла, «хуш» дигәне – ераграк араларга киткәндә, ә инде «бәхил бул» сүзе мәңгегә аерылганда әйтелә. Шагыйрь, мәгънә төсмерләренең көчәюе рәвешендә үсә барган әлеге сүзләрне бер-бер артлы тезеп, лирик герой хис-кичерешләренең ни дәрәҗәдә катлаулы, тирән икәнлеген күрсәтергә теләгән. «Эч поша, яна йөрәк, хәсрәт эчендә, уйда мин»; «җайсыз, уңгайсыз тору; Бу тору, әйтергә мөмкиндер, кояш-айсыз тору» кебек алдагы строфаларда очраган мондый синонимик градацияләр билгеле бер мәгънәви функция дә үтиләр: укучыларга әсәрнең идеясен тирәнрәк аңларга ярдәм итәләр. Әлеге юлларда кулланылган сурәтләү чараларының мәгънәләрен аңлату эше дә шигырь үзәгендәге лирик геройның уй-хисләрен аңларга ярдәм итә. Мәсәлән, туганнарыннан аерылуны шагыйрь «кояшсыз, айсыз тору» белән чагыштыра; әлеге уйларын «таштай катты китте башларым; чишмә төсле ихтыярсыз акты-китте яшьләрем»

метафоралары белән җиткерә. Укучылардан әлеге сүзтезмәләрнең мәгънәләрен ничек аңлауларын мисаллар нигезендә исбатлап күрсәтүләрен сорарга була.

Алдагы строфаларда лирик геройның күңел төшенкелек халәте яңадан күңел күтәренкелеге, шатлык-куаныч, алдагы тормышы белән бәйле өмет-хыяллар хисе белән алмашына. Әлеге хисләрне ул «бу тавыш бик ачты күңлем, шатлыгымнан җан яна» гыйбарәсе белән җиткерә. Шагыйрь Казанны аң-белем, мәгърифәт, мәдәният үзәге дип атый:

Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан, монда нур;
Монда минем нечкә билем, җәннәтем һәм монда хур.

Әлеге шигырьдә кулланылган «И Казан! дәртле Казан! моңлы Казан! нурлы Казан!» эпитетлары бүгенге көндә, афоризмга әверелеп, татарларның мәркәзе, ягъни «безнең бабайлар түрләре, почмаклары» булган Казан шәһәрен тасвирлаучы матур бер бизәккә әверелде.

Әлеге шигырь белән танышып чykkannan соң, укучыларга Габдулла Тукайның лирик геройны сурәтләүдә яратып кулланган алымы – эчке дөньяны сурәтләү аша тышкы дөнья күренешләрен тасвирлау алымы әсәрдән алынган мисаллар нигезендә аңлатыла.

Билгеле булганча, шигырь – билгеле бер ритмга корылган тәэсирле сөйләм ул. Әсәрне укып тикшергәч, укучыларның яшь үзенчәлеген истә тотып, аларга шигырь төзелеше буенча да башлангыч мәгълүматлар бирелә. «Шигырь» сүзе гарәпчәдән алынган, ул «тәртип, рәт» дигәнне аңлата. Шигырьдәге һәр юл төгәл үлчәмгә буйсына, димәк, шигырь ул – хис һәм фикер берлеген белдерүче көйле сөйләм. Аңа музыкальлекне шигъри ритм бирә. Шигъри ритм гадәти ритмнан аерылып тора. Ул басымлы һәм басымсыз иҗекләрнең билгеле бер үлчәмдә килүен таләп итә.

«Пар ат» шигыренең төзелеше икешәр юллык унҗиде строфадан тора. Һәр строфадагы беренче һәм икенче юллар рифмалашып килəләр. Һәр юл 15 әр иҗектән тора; бер үк сандагы иҗекләр, кабатланып килеп, ритмик сөйләм тудыралар:

Җиктереп пар ат, Казанга туп-туры киттем карап;
Чаптыра атларны кучер, суккалап та тарткалап...

...Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан, монда нур;
Монда минем нечкә билем, җәннәтем һәм монда хур...

5 нче сыйныф укучыларын лирик әсәрләр, аларның төзелеше белән әнә шул рәвешле таныштыра башлыйбыз. Алга таба аларга «интонация», «басым», «шигъри ритм», «рифма» терминнарының мәгънәсен башка шигырьләрне өйрәнү барышында аңлатабыз. Шулай итеп, лирик әсәрләрнең телен, композициясен тикшерү эше ул укытучыдан мәктәп анализы барышында һәр жанр төрләренең үзенчәлекләрен, аларны укыту методикасын белүне таләп итә.

ӘДӘБИЯТ

1. Заһидуллина Д.Ф. Лирик әсәр һәм аны мәктәптә укыту // Гыйльми язмалар. Казан. 1997. № 1. Б. 49–80.
2. Лотман Ю.М. Природа поэзии. М.: Гнозис, 1994. 123 с.
3. Татар телендә төп гомуми белем бирү мәктәпләре (V–IX сыйныфлар) өчен татар әдәбиятыннан үрнәк программа / Төзүче-авторлары: Д.Ф. Заһидуллина, Н.М. Йосыпова. Казан, 2013. 18 б. http://mon.tatarstan.ru/rus/file/pub/pub_263459.docx

## ТУКАЙ ФОЛЬКЛОРДАН БАШЛАНА

***Харрасова Р.Ф.***

Статья убедительно и на примерах доказывает, что элементы фольклора в публицистике Тукая проявляются на всех уровнях художественного текста: в языке, в системе и структуре образов, в сюжетно-композиционном пласте, жанровых характеристиках, текстовых вкраплениях, а также в проявлениях авторского идеала.

Article convincingly and with examples proves that folklore elements in Tuqay's journalism appear at all levels of literary text: in language, in the system of the images and in the images-structure, in the scene-composite layer, in genre characteristics, in text inclusions, as well as in the manifestations of the author's ideal.

Тукай иҗатында фольклоризм, ягъни халык авыз иҗатын өйрәнү, яңадан торгызу һәм һөнәри мәдәнияткә, бу очракта үз әсәрләренә трансформацияләү күренеше XXI гасырда да тикшерелергә тиешле фәнни объект булып кала бирә. Әлбәттә, әлеге проблеманы ачкан хезмәтләр шактый, әмма аны чишүгә моңа кадәр теге яки бу чара кысаларында тар тематик планда гына якын килende, тирәнтен, махсус һәм Тукай мирасын тулаем иңләгән комплекслы тикшерүләр багышланмады. Галимнәр күбрәк Тукай тезмәгә салган әкиятләргә, мәсәлләргә, аларда кулланылган образларга игътибар итте, аның халык әдәбияты хакындагы хезмәтләрен, фикерләрен бәяләде, аерым шигырьләренең халык җыр текстларына якын торганлыгын, бигрәк тә поэтик иҗатының фольклор белән бәйләнешләрен тасвирлады.

Тукайның әдәби бәйләнешләрен анализлаган язмаларда бигрәк тә публицистикасы һаман читтәрәк калып килә, шул сәбәпле бу чыгышта нәкъ менә аның фольклорга якын үзенчәлекләрен билгеләү үзәктә торыр. Әлбәттә, минем язмам да комплекслылыкка, тулылыкка дәгъва итми, әмма ул авторның аерым мәсьәләләргә үзенчәлекле мөнәсәбәтен чагылдыра, әйтик, Тукай публицистикасының башка жанрларга караганда да фольклор белән бәйләнешләре ныграк икәнлекне күрсәтеп тора. Күпчелек галимнәр, проза һәм публицистика фольклорның йогынтысына шигърияткә караганда азрак бирелә, дип санаса да, аерым чорлар һәм шәхесләр әдәбияты, шул исәптән Г. Тукай иҗаты моның хакыйкатькә бик туры килмәвен күрсәтә. Каләм иясенең, мәсәлән, проза белән публицистика арасында торган фельетоннарына фольклор тәэсире бинигаят зур, бәлки китаби башлангычы да бик көчле шигъриятенекенә караганда да зуррактыр.

Унтугызынчы гасырның икенче яртысында татарларда халык авыз иҗаты белән кызыксыну көчәйгәнлек хакында К. Насыйри һәм башка галимнәрнең эзләнүләре генә түгел, прозабызда ярымфольклор характерындагы әсәрләр, тәрҗемәләр арту да сөйли. XX гасырга аяк баскач, фольклорның матур әдәбиятка үтеп керүе тагын да тирәнәя, ныгый. Элегрәк бу, беренче чиратта, нәфис текстларның халык авыз иҗатыннан килгән образлар системасында, тезмә калыпларда, идеяләрдә, әкият яисә әкияткә тартым хикәяләр, повестьлар күп язылуда чагылыш тапса, андый әсәрләр прозаның зур өлешен тәшкил итсә, хәзер исә барлык талантлы каләм ияләренең фольклор материалларын аңлы куллануында, сәнгати эшкәртеп, зур әдәбият таләпләренә җавап бирерлек сыйфатта халыкка җиткерүендә күренә. Шул ук вакытта фольклор сюжетлары яисә ярымфольклор әсәрләр заман прозасы каршында үз позицияләрен торган саен ныграк бирә, поэзиядә шулай ук – китабилык һаман да ныклы, заман яңачалыгы дә көчәя бара. Бу аерым бер язучылар иҗатында да, гомумән әдәбиятта да сан-сыйфат мөнәсәбәтләрендә ачык чагылыш таба.

Фольклорны ныклап өйрәнгән, өлешчә җыйган Тукай аның стихиясен бигрәк тә публицистикасына ныклап алып керә. Әдәбиятның беренчел элементы булган сүз, аның ярдәмендә тормыш төрлелеген аңлатып бирү җиңеллектән, фольклорда да төп материал чыганагы булып тора. Сөйләмнең, иҗтимагый баскычлардан югарырак күтәрелгән саен, ритуалларга ныграк уза баруы шуның белән аңлатыла да. Әлеге дә баягы сүз теләсә кем иҗатына, шул исәптән Тукайныкына да фольклорның универсаль сыйфатларын күчерергә булыша.

Тукай – XX гасыр башы иҗтимагый-сәяси тормышын, татар яшәешен бөтен вакыйклары белән тулаем тасвирлап калдырган бердәнбер каләм иясе. Аңа бу очракта нәкъ менә фольклор формалары ярдәмгә килә дә. Ул фольклоризмнарны халык акылын, тәҗрибәсен аның алдынгы катламнары фикерен укучыга ирештерү максатында куллана. Фольклор материалын поэзиясендә башка әдипләр белән бер рәвешчәрәк файдаланса да, публицистикасында алардан югары дәрәҗәдә интенсив файдалана, әлеге төр әсәрләренә кайвакыт аллюзия һәм реминисценцияләрне шыплап тутыра, бу вакытта укучының тасвирланган вакыйгалар һәм үзе белгән күренешләр арасында ассоциацияләр уздыруына өметләнә.

Заман тудырган сорауларга җавап биргәндә дә, социаль-этик-эстетик идеалын эзләгәндә һәм чагылдырганда да, Тукай, беренче чиратта, гасырлар дәвамында үз халкы сөйләмә иҗатта туплаган тапкырлыкка, гыйбрәтлелеккә, күзаллауларга нигезләнә. Андый төр байлык мәсәл, мәзәк, мәкаль, әйтем, табышмак кебек җыйнак һәм тыгыз кече формаларда ачык чагылыш таба, әнә шуңа күрә әдипнең вакытлы матбугат өчен язылган төрле тип мәкаләчекләренең байтагы мәзәкләр структурасына нигезләнә дә («Яңа дәгъва», «Тимерчыбыксыз телеграмм хәбәрләре» һ.б.).

Фольклор элементлары мәзәкләрнең сәнгати бөтенлеген барлыкка китерүче һәр яссылыкта – телдә, образлар структурасында, текст төзелешендә, лейтмотивта, идеалда очравына да карамастан, Тукай иҗат иткән заманча мәзәкләренең поэтикасы инде ул ассимиляцияләнгән һәм эволюция кичергән фольклор поэтикасы булып тора. Халык авыз иҗатында көлкеле хикәячекләрдә юморга өстенлек зуррак бирелсә дә, Тукайда үтергеч көлү алга чыга. Шулай итеп, әдип татарда сатирик рухтагы мәзәкләрне көчәйтеп җибәрә, иҗтимагый-сәяси мәзәкләрнең алга таба үсешенә юл яра.

«Тәҗрибәле сүзләр» исеме астындгы тупланманы искә төшерик. Габдулла Тукай анда байлар белән муллалар катламын һәм җәмгыятьтәге алыш-бирешкә, бу очракта сәдакага корылган мөнәсәбәтләрне, мәкаль структурасын файдаланып, көчле сатирага ала. Мәкальләрнең һәр юлы байлар сүзе белән башлануга карамастан, үзәк тәнкыйть объекты руханилар булып тора. «Байларның кулы кесәсенә керсә, муллаларның авызына тел керә» дип башланган тәүге тәҗрибәдәге фикер чираттагылары белән тирәнәйтелә, киңәйтелә һәм әкренләп укучыны муллаларның, ишаннарның хәерчегә булган мөнәсәбәтенә алып чыга: «Байлар авырый башлагач, каберен казып куялар, фәкыйрьләрне, үлгәч тә, өч көн ишетмиләр».

Тукай шулай ук халык мәзәкләренең бер геройның сүзне аңламавына нигезләнгән юморын да файдалана:

«Шәкерт илә надан ишан.

– Тәэсир, сез… сез әйтәсез: без – вәрәсәтеләнбия һәм шәһәриярлар нәселе, дип. – дөрестме?

– Дөрест, без – без – чәһарҗиярләр нәселе шул».

Барлык әдәбиятларда да театр тууда фольклор зур роль уйный дип санала. Күп кенә халыкларда ул урам тамашаларына барып тоташа. Сәхнәләштерелгән беренче пьесаларга, әйтик, русларныкында халык авыз иҗаты әсәрләреннән төрле эпизодлар үтеп керә. Бу әдәбиятның халыкчанлыгын көчәйтеп җибәрә. Тукай публицистикасында һәм прозасында диалог рәвешендә оештырылган әсәрләр шактый, алар аша әдип шулай ук әдәбиятка халык стихиясен, ягъни милли эчтәлек, татар тормыш-көнкүрешен алып керә. Алар арасында сәхнә әсәрләренә якын торганнары, сәхнәләштерергә мөмкиннәре дә юк түгел.

Габдулла Тукайның 1906 елда «Фикер»дә басылып чыккан һәм жанр формасы «Сырой егет» дип билгеләнгән әсәр, мәсәлән – асылда кече күләмле скетч ул. Бер герое йөзендә Мортаза бай Гобәйдулинны тәнкыйть утына алган әлеге әсәр рухындагы һәм үзләре уйлап чыгарган пьесачыкларны совет чорында үзешчән коллективлар сәхнәгә даими рәвештә менгезә торган иде. Димәк, аларның тамырларын Тукай иҗатыннан да эзләргә кирәк. «Сырой егет»нең башында катнашучылар исемлеге, скетчның нәтиҗәсен, халык алдына чыгып, укучыга җиткерүче автор булу әлеге әсәрне сәхнәләштерергә мөмкинлек барлыгын сөйли.

Тукайның шулай ук аерым риваятьләре архаик фольклорда ук очраган «Коръән» текстларына таянып язылган «Кыямәт көне» һәм башка сәяси эчтәлектәге әсәрләре, сатирик-тәнкыйди-аналитик рухта булуларына карамастан, билгеле бер дәрәҗәдә күтәрелеш чорларында халык арасында таралган, сөйләнелгән сәяси-агитацион чыгышларны да искә төшерә. Әйтик, «Кыямәт көне»ндә шундый юллар бар: «Адәмнәр, тетрәңез, тетрик! Менә хакимнәр хакиме вә судьялар судьясының мәхкәмәсе: монда камил гаделлек вә тигезлек бардыр. /…/ И явызлар! Монда киленез. Ничә йөз, ничә мең еллардан бирле көтелгән җәза таңы атты. Динне хурладыгыз, мөселманлыктан көлдеңез! Галимнәрне танымадыңыз, тугры сөйләгәннәрне кысытыңыз, изденез. Шәкертләрне иң түбән теләнчедән дә яман күрдеңез… Алла гафилмени? Җавап биреңез!».

Борынгы чорларда базарчылар махсус текстлар ярдәмендә үз товарларын мактаган, сарай хәбәрчеләре урамнарда, бигрәк тә кешеләрне бергә туплаган мәйданнарда төрле игъланнар укыган, халыкка хаким даирәләрнең фәрманнарын җиткергән. Тукай бу форманы да үз сатирасында отышлы файдалана. «Алырга ашгыңыз!» язмасында, мәсәлән, Курган өлкәсенең, татарлар һәм алар янәшәсендә бигрәк тә борынгыча дәвалау бик көчле булган кыргыз-кайчаклар һәм казаклар да яшәгән Звериноголовски станицасында (саласында) вакытлы аптека ачылу мөнәсәбәтеннән аның товарларын рекламалау кебек аңлашыла. Тексттан аптекачыларның татар прототиплары барлыгы төсмерләнә. Әдип игътибарны әлеге йортта чын дарулар сатылмыйча, мәҗүсилек заманнарында кулланылган имнәр, боздыргыч тылсымнары һ.б., башлыча халык

медицинасы товарлары сатылганлыкка юнәлтә. Әсәрне тормышчан итә торган тәгаен тәнкыйть объекты булуга карамастан, билгеле, ул татарлардагы җаһиллек күренешләрен кире кагуга хезмәт итә.

Тукай публицистикасын оригинальләштереп җибәргән сыйфатларның тагын берсе шулай ук халык авыз иҗатына мөнәсәбәтле. Публицист үз әсәрләренә фольклор эпизодлары китереп кертә, аларны заман материалы белән куша, актуаль фикерләрен яңгырату максатыннан файдалана. Әйтик, «Шәһәремездәге зур тәмгылы муллаларә бер-ике сүз»дә «Качыр илә Үрмәкүч» кыйссасы урын алган. «Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?» язмасында Тукай милләтнең торгынлык – стагнация халәтен шушы рәвешчә фаразлый башлый: «... борын заманнарда безнең милләт, үзенең иптәшләре вә аркадашлары булган башка милләтләр илә, фәкыйрь генә, тыныч кына, күңелсез генә яшәгән. Берничә гасырлар безнең милләт алар илә ызандаш һәм чәйдәш булып, барчасы бергә ачлы-туклы гына булса да тыныч кына, тату гына гомер иткәннәр. Шулай тыныч кына торганда ни хикмәттәндер, башка милләтләр һәрберсе бер Сөләйман мөлкен алып, үзләренә җирләрне, апрларны, утларны, һаваларны хезмәтче иткәннәр...» Күрәбез ки, өзек әкият башламына бик тартым. Текст, гомумән алганда, үзе дә әлеге форманың һәм структур, һәм эчтәлек элементларын шактый мул алган.

Тукайның «Мөхәммәтгали бабай» исемле ахыры тәмамланмаган проза әсәре, географик атамаларга, торак пунктларга (гап-гади бабайда зиннәтле вә солтанатлы сарай), аларның төзелешенә (идән кебек тигез түбә), лексик катламга (миһман, хәлифә, сәргаскәр) геройларның көн итү үзенчәлекләренә караганда һәм гомуми эчтәлек ноктасыннан чыгып фикер йөртсәң, көнчыгыш повестьларыннан тәрҗемә икәнлеген аңлыйсың. Әлеге әсәренең дә сюжет корылышы гаять әкияти. Сүзебез дәлилле булсын өчен, аның башлам өлешен генә китереп узыйк: «Мусыл шәһәрендә һәркем тарафыннан игътибар вә тәгъзим ителгән Мөхәммәтгали исемле бер карт бар иде.»

Алга таба автор әлеге картның ил эчендәге мөнәсәбәтләрен, холкын, байлыкларын тасвирлый. Мөхәммәтгали бабай әкиятләрдәгечә төрле холыкка, һөнәрләргә, максатларга ия ике угыл үстерә. Шулардан Җәгъфәр исемлесе аталары һәм ил каршында танылу, данлану өчен, ниләр генә эшләми, әмма ахыр чиктә боларның мәгънәсезлек, Аллага коллык итүдән дә зуррак гамәлнең булмавы турында фикергә килә. Әсәрнең ахыры бар дип язылса да, аның үзәк идеясе инде ачылып беткәнгә охшаган, шул сәбәплеме, алга таба газетада дәвамы күренми. Шул ук вакытта әсәрдә Нуретдин образы, аның туганы белән мөнәсәбәтләре ачылып бетмичә калганлык турында да әйтергә кирәк.

Тукай публицистикасына кече берәмлек сыйфатында үтеп кергән фольклор текстлары – мәкальләр («Мәкальләр») фразеологизмнар, җыр-шигырьләр, бәетләр («Фәлсәфи сүзләр»; «Алай-болай»), такмазалар («Чүкеч»тән) бар. Ул шулай ук публицистик язмаларын нәсихәт (Бюрократлар нәсихәте), кара-каршы әйтешләр («Идел буендагы шәһәрдә»), табышмак («Табышмак»), әкият («Аю һәм ссыльный»), мәзәк («Камыт бавы илә мулла корсагы»), игълан һәм халыкта киң таралган мәхәббәт хаты (« «Гыйшык» уты») калыпларында иҗат итә; ул, аерым әсәрләре белән – фал ачу, төш сөйләү һәм юрау («Словарьдан фал ачу; «Төшемдә күргәннәрем»), кебек борынгыдан килгән гореф-гадәтләрне дә, халыкның фараз рәвешендәге фикер калыпларын да («Ну-ну!») искә төшерә. Габдулла Тукай тәгаен мифологик топосларны, сюжет элементларын туып кына килгән татар публицистикасында иҗтимагый-сәяси тормыш контекстында яңача интерпретацияли.

Тукай публицистикасының урын-урын шагыйрәнә яңгыравында төрле тип кабатлаулар мөһим роль уйный. Белгәнебезчә, нәкъ менә кабатлаулар поэтик юлларның беренчел чыганаклары булып тора да. Бигрәк тә кемнәргәдер мөрәҗәгатьләрне, бер үк яисә төрле үтенечләрне янәшә санау каргышларга, ырымнарга, им-том текстларына шагыйрәнә яңгыраш бирә. Әгәр Тукайның журналистик мирасына мөрәҗәгать итсәк, әлеге әдәби алымның гаять актив кулланышта икәнлеген күрербез. Мәсәлән, «Мөһим эш – имамнар җәмгыяте» аналитик язмасының урта бер өлеше «Фикер» газетасы исеменнән әйтелгән түбәндәге юллар белән башлана:

«– Әй, бичара иммамнар!

– Вай, бичара җир фәрештәләре!»

Тукай иҗатындагы күпчелек сынландырулар, эпитетлар, әлбәттә, фольклор текстларында моңа кадәр дә очраган сүзләрнең семантик үзенчәлекләренә бәйле. Без, ша-

гыйрь поэзиясе контрастлылыкка корылган, дибез. Капма-каршылык каләм иясенең теге яки бу әсәр өчен сайлаган персонажлар системасында да, теге яки бу сүз төркемнәренә караган антонимик парларны мул куллануында да, фикер оппозицияләрендә дә, структур төзелештә дә ачык чагыла. Галимнәр әйтүенчә, дуалистик мифология нәкъ менә ас-өс, кыз-егет, ак-кара кебек семантик каршы куюларга нигезләнә дә.

Фольклор һәм әдәбият бәйләнешләре турында сөйләгәндә, метафораның мифологик генезисы турында да онытырга ярамый. Димәк, Тукайның, никадәр генә үзенчәлекле метафораларга нигезләнмәсен, поэтик стиле ахыр чиктә, башка шагыйрьләрнеке кебек үк, дөньяны мифологик күзаллаулар аркасында килеп чыккан тропларга барып тоташа. Шул ук вакытта, инде алда әйткәнебезчә, шигъри юлларның да беренче чыганагы дога, каргыш кебек фольклор жанрлары белән бәйлелеген беләбез.

Тукайның үзендә сакраль сүзләр ни дәрәҗәдә һәм аларның кай төрләре кулланылган соң, дигән сорау туа. Әлбәттә, дини-дөньяви тәрбия алган Тукай шигъриятендә тар эзотерик төркемнәргә генә аңлаешлы төшенчәләр була алмый, аларның төп чыганагы Изге китап, бу очракта Коръән үзе булып кала. Шул ук вакытта Аллага гына түгел, сынландырылган теге яки бу предметларга эндәшеп язулар һәм алардан ни дә булса үтенүләр Тукай шигъриятен еш кына ритуал текстларына якынайта:

И Каләм! Китсен әләм, син әйлә безне шадыман;
Без дә саяңдә улалым тугры юла кадыман.

(И каләм! Китсен газап, ит син безне шат;
Без дә синең аркаңда тугры юлга басыйк аяк).

Бу төр эндәшләр Тукай публицистикасы өчен артык характерлы түгел, шул ук вакытта анда дәвалау, ырым текстларындагыча кат-кат тәкърарлау зур урын алып тора:

«Әгәр ир башмакчы йә кәвешче булса, ул – хатыны табан астында ятыр.
Әгәр ир гармунчы йә скрипкәче булса – хатыны дудкасына биер.
Әгәр ир сәгатьче булса – хатыны бору белән генә йөрер…»
(«Ир, хатын).

Тукайның публицистик каләменә шулай ук, ырым-имнәрдәге кебек, һәр нәрсәне тәфсилләп, текстны тыгызлау, ашкынулы язу, темпны һәм накалны арттыра бару хас:

«Аһ, ярабби, бу төсләре бозылган һавалар, бу зынҗырдан ычкынган төсле, бер-берсенә һөҗүм иткән җилләр җир балаларына яратылмышларының актык минуты җиткәнен хәбәр бирәмени? Сурның ачулы вә каһәрле нәгъръсеннән асты өстенә килгән мохит диңгезе үзенең ярларыннан ачу илә атылып чыкмыш. Дөньяны куркынычлы тавышлар илә шаулатып, ул тау-тау дулкыннарны гяһ вакытта үзенә тартырга, күтәрергә гадәтләнгән күкләр илә сугышырга бара микән? /…/» («Кыямәт көне»)

Тукайның сүзлекләр рәвешендә иҗат ителгән әсәрләрендә, мәсәлән, «Яңа камустан берничә лөгать»тә бер үк төшенчәләр, сүз төркемнәре, формулалар тезелеп-кабатланып килә:

«Казый – ришвәт вә вакыфлар ашаучы дигән сүз.

Мөфти вазифа ашаучы дигән сүз. Бай – кеше талап, корсак үстерүче дигән сүз /…/»

Тукай кайвакыт бер үк җөмләләрне дә кабатларга мөмкин:

«Мәгариф – хәяттыр. Мәгариф – хәяттыр. Мәгариф – хәяттыр.» («Тәкърар әйтәмез»). Семантик һәм фоник-синтаксик янәшәлекләр – архаик текстларның гына түгел, «классик фольклор»ның да нигез сыйфаты булып тора. Кайбер әсәрләрдә ул теманы торган саен ныграк киңәйтә һәм тирәнәйтә барган вариатив җөмләләр, абзацлар тезмәсе рәвешен алырга мөмкин:

«Бер татар приказчигы:

– Тамчы, тамчы тамар да күл булыр,– дип әйтте дә ди, байның кассасын аз-азлап чиерттерергә тотынды; күп тә үтмичә, самвырчы малайлыктан «Печән базары бае»лыкка тәрәкъкый итте ди.

Бер татар бае:

– Асылынсаң асылын агачның асылына, – дип әйтте дә ди, Мәскәүгә барып, йөз меңлек бурычка чумды ди; шул елда ук шарт итте ди /…/» («Акыллы башлар»)

Фольклорда көнкүреш яисә йола ситуацияләре, даими сөйләм формулалары – текст стабилизаторлары, ягъни аны тотрыклы итүче көйләгечләр булып тора. Әлеге формулаларның саны арткан саен, текстның тәэсире дә көчәя генә бара. Г. Тукай

публицистикасында да бу шулай. Фольклор әсәрләрендә дә, даими очраучы калыплар муллыгына карамастан, сөйләм төзелешенә һәм шулай ук сүзләр кулланышына карата да катгый куелган таләпләр юк. Нормалардан тайпылышлар да Тукай иҗат иткән текстларның бер үзенчәлеге санала ала. Әдипнең вакытлы матбугатка хәзерләгән язмаларында диалектизмнар, сүзне бозулар еш очрый, әмма алар күбесенчә әдәби алым рәвешен ала, текстны халыкчанлаштыра, тормышка якынайта.

Сүзебезне гомумиләштереп әйткәндә, Тукай публицистикасына фольклор тәэсире бинаһая зур һәм ул жанр формалары, идея эчтәлеге, образлар системасы, әдәби алымнар кебек һәр кайсы яссылыкларда бара. Шуны күздә тотып, халык авыз иҗаты элементларын, берәмлекләрен вакытлы матбугат язмаларына кертеп җибәрүне Тукай публицистик стиленең бер алымы сыйфатында өйрәнергә һәм аның поэтикасын да тулы ачарга кирәк, дип әйтә алабыз. Тукай фольклоризмны үз чорының этик-эстетик ихтыяҗларына җавап бирүе өчен генә кулланмый, ул аларда гасырлар дәвамында халык аңында формалашкан сорауларга да җавап бар дип саный, болардан тыш, нәкъ менә халык авыз иҗатына хас поэтиканың әдәбиятны гына түгел, публицистиканы һәм аңа киң урын биргән вакытлы матбугатны да халык массаларына якынайтучы җепләр дип таный.

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ӘСӘРЛӘРЕ ТЕЛЕНДӘ СИТУАТИВ ҺӘМ МОТИВЛЫ ХӘЛ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ

***Хәбибуллина Л.Г.***

Обстоятельственные отношения являются сложными и многоплановыми. В условиях антропоцентризма современной лингвистической науки исследование языковой реализации разных семантических отношений представляет несомненный научный интерес. Данная статья посвящена описанию структурных особенностей конструкций, выражающих обстоятельственные отношения в языке произведений Габдуллы Тукая, и установлению характера взаимосвязи этих семантических отношений.

Adverbial relations are complex and multifaceted. In the conditions of anthropocentrism of modern linguistic science research of language realization of the different semantic relations represents undoubted scientific interest. This article is devoted to the description of structural features of the constructs representing adverbial relations in the language of the poems by Gabdulla Tukay, and establishment of the nature of interrelation of these semantic relations.

Габдулла Тукай – татар милли әдәби телен формалаштыруга зур өлеш керткән шагыйрь. Әсәрләренең тел үзенчәлекләре галимнәр тарафыннан төрле яклап өйрәнелүгә карамастан, Тукай калдырган мирас әле бүген дә яңа фәнни тикшеренүләр объекты булуын дәвам итә. Әлеге мәкаләдә шагыйрь әсәрләре телендә хәл мөнәсәбәтләрен белдерүче конструкцияләрнең структур-семантик үзенчәлекләре күзәтелә.

Тел күренешләренең мәгънә төсмерләрен тикшерү телнең коммуникатив асылын ачарга мөмкинлек бирә, шуңа бәйле рәвештә хәзерге лингвистикада семантиканы өйрәнүгә зур кызыксыну күзәтелә. Фикерләү категорияләре бөтен тулылыгында телнең синтаксик төзелешендә ачыла, шуңа күрә синтаксик берәмлекләр арасындагы мәгънә мөнәсәбәтләрен өйрәнү тел белеменең хәзерге торышы өчен, һичшиксез, актуаль.

Тюркологиядә сөйләмнең семантик ягына мөрәҗәгать итү XX гасырның 60 нчы елларыннан башлана. Тел галимнәре Л.К. Бәйрәмова, М.В. Зәйнуллин, М.З. Зәкиев, С.М. Ибраһимов, М.А. Сәгыйтов, Ф.С. Сафиуллина, А.Н. Юлдашев тел конструкцияләрен функциядән формаль якка юнәлешендә тикшерәләр.

Хәл мөнәсәбәтләре башка синтаксик мөнәсәбәтләр арасында үз эченә кергән мәгънә бәйләнешләре күплеге белән дә, телдә кулланылыш ешлыгы ягыннан да зур урын алып торалар. Семантикасы буенча алар мотивлы һәм ситуатив пландагы хәл мөнәсәбәтләренә бүленә.

Ситуатив пландагы хәл мөнәсәбәтләре эш-хәл үтәлүнең тышкы якларын күрсәтә. Монда, компонентлары арасындагы синтаксик мөнәсәбәтләрнең характеры буенча, пространство һәм вакыт мөнәсәбәтләре керә. Тышкы мөнәсәбәт булып саналуларына карамастан, алар катлаулы эчке структурага ия. Пространство һәм вакыт мөнәсәбәт-

ләре, синтаксик бөтеннең вакыйгалылыгын барлыкка китерүдә катнашып, синтаксик берәмлек төзүдә мөһим роль уйныйлар. Ситуатив пландагы хәл мөнәсәбәтләре, бигрәк тә пространство мөнәсәбәте, башка хәл мөнәсәбәтләренә караганда күбрәк конкретлыкка ия. Ул лексик-синтаксик категория, чөнки бик еш төрки телләрдә лексема буларак аерым сүзләр түгел, ә сүзләрнең синтаксик формалары пространство мөнәсәбәтләре системасын тәшкил итә.

Мотивлы мөнәсәбәтләргә сәбәп-нәтиҗә, максат, шарт һәм кире шарт керә. Әлеге мөнәсәбәтләр бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә торалар, шуңа күрә тел белгечләренең аларны классификацияләүгә төрле карашлары бар.

Хәзерге тел белемендә күп кенә галимнәр кире шарт мәгънәсен белдерә торган катлаулы төзелмәләрнең генезисы мәсьәләсен күтәрәләр. Лингвистик әдәбиятта кире шарт мәгънәсенең үсешенә карата төрле карашлар очрый. Алар формасы белән дә, мәгънәсе буенча да каузаль, кондициональ, темпораль мөнәсәбәтләр белән бәйләнгәнлектән, комплекслы семантикага ия, башка хәл мөнәсәбәтләре арасында аларны иң катлаулысы дияргә була.

Кире шарт мөнәсәбәтен белдерүче конструкцияләр ике ситуациядән – билгеле бер эш-хәлнең үтәлүенә киртә булган һәм әлеге каршылыкка карамастан үтәлгән вакыйгалардан тора. Әлеге төзелмәләр семантикаларында модальлек булу белән үзенчәлекле, чөнки аларда, чынбарлыкны чагылдыру белән беррәттән, сөйләүченең позициясе дә белдерелә. Кире шарт мөнәсәбәте ике ситуацияне капма-каршы куюга нигезләнә, сәбәп-нәтиҗә, шарт-нәтиҗә һәм каршылык мәгънәләренең үзара мөнәсәбәте йогынтысында формалаша: *Селкенмәдек Таш төсле без, Җилбер-җилбер Җил бәрсә дә; Юрган ябып Йоклап яттык, Уйганмадык, Таң атса да; Уйланмадык! Бәхтемезнең Крояшы баеп батса да* («Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр»).

Үзендә шарт һәм вакыт мәгънәләрен берләштергән конструкцияләргә карата да фикерләр төрле. Нигездә алар я шарт, я вакыт мөнәсәбәтләре кысаларында каралалар. Бер үк бәйләүче чараларның төрле мәгънә мөнәсәбәтләрен белдерү өчен кулланылуы семантиканы билгеләүне кыенлаштыра. Әйтик, ***Булмаса** дуслык, җитә бит сугышырга бер юк эш* («Чын вә Ялган»), *Мәңгегә очалмас, йортта күп **асралса** кош* («...гә») җөмләләрендә *-са* шарт фигыль күрсәткече вакыт төсмерле шарт мәгънәсен аңлата.

*Нишләсен? – Бар бер угыл, бер кыз бала, Әнкәсе **киткәч**, болар үксез кала* («Кечкенә генә бер көйле хикәя») мисалында *-кәч* формалы хәл фигыль бар. Ул, гадәттә, вакыт мәгънәсен белдерүдә кулланыла. Әлеге очракта контекстта, вакыт белән беррәттән, шарт мәгънәсе аңлашыла (*Әнкәсе **китсә**, болар үксез кала*). Гомумән, күренешләрнең эчке бәйләнеше булган хәл мөнәсәбәтләренең семантикасы җөмлә яки контекстның мәгънәви эчтәлеген логик анализлау юлы белән ачыклана. Төрки телләрдә бик еш мәгънәви мөнәсәбәтләрнең үзара керешүе күзәтелә.

Гадәттә, вакыт мөнәсәбәтен белдерә торган *-гач/-гәч, -кач/-кәч* формалы хәл фигыль (мәсәлән, *Мин әле, **күргәч** сине, шатланганымнан үкерәм* («Шүрәле») сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтен белдерү өчен дә шактый актив кулланыла. Бу очракта фигыль, кагыйдә буларак, юклык формасында була. Мәсәлән: *Хатының, балаң ач, Ашарга бул**магач**...* («Мужик йокысы»); *Һич уенда юк кызык, дәрсем хәзерләп куй**магач*** («Эш беткәч, уйнарга ярый»); *Мин күзеннән аның күземне ал**магач**, Һәр сүзенә «чын, чын» димичә кал**магач**, Мин гашыйкны сүз аңлый дип уйлый инде, – Кадап куйган һәйкәл төсле күзгал**магач*** («Утырышу»).

Сирәгрәк очракта әлеге форма, фигыль барлыкта булганда да, сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтен белдерә: *Син, ялкау, йокла**гач**, Янчыгың сай булды* («Мужик йокысы»).

Сүзтезмәләр яки җөмләләр арасында бәйләүче чара булып хәл фигыльнең юклык формасы (*-мыйча, -мый, -ми*) килгәндә, шарт мөнәсәбәте дә, сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәте дә бирелә ала: *Җир яшәрмәс, гөл ачылмас – **төшми** яңгыр тамчысы...* («Мәхәббәт»). Әлеге мисалда компонентлар арасында шарт мөнәсәбәте урнаша. Хәл фигыль формасы белән башка эш-хәлнең үтәлешенә кирәк булган шарт белдерелә. Җөмләне үзгәртү семантиканы бозмый: *Җир яшәрмәс, гөл ачылмас – **төшмәсә** яңгыр тамчысы.*

Шарт фәлсәфи планда сәбәп категориясе белән тыгыз бәйләнгән. Шарт, сәбәп кебек үк, нәтиҗәдән алда булган вакыйганы белдерә. Сәбәп-нәтиҗәнең тормышка ашырылуы билгеле бер шартларга бәйле. Шарт үзе нәтиҗә тудыра алмый, ә аның барлыкка килүе өчен фон ролен генә үти. Шарт белдерүче конструкция ике компоненттан тора һәм берсенең тормышка ашуы яки ашмавы тулысынча икенчесенә бәйле була.

Габдулла Тукай әсәрләре телендә каузаль семантика шактый еш имплицит рәвештә белдерелә: *Акмый тышка мәгънәләр – кипкән күңелнең чишмәсе* («Хәстә хәле»); *...Үтми бармак – тун калын* («Көтмәгәндә»); *Җиргә нык басмыйм – аяк астымда йомшаклык күрәм* («Хәстә хәле»); *Кичтән йокың кала да, Егълап үтә көндезең* («Авыл хатынының бала тирбәткәндә өмидләре»).

Урын-вакыт килешендәге *-ган* формалы сыйфат фигыль, гадәттә, вакыт мәгънәсен белдерә: *Очып **киткәндә**, ул шундый матурлап сайрады моңлы...* («Кошчык»); *Шигырь **язганда** һәр юлга минем мәгънәне урлыйлар* («Урланган мәгънә»); *Җырлый-җырлый үләрмен мин **үлгәндә** дә...* («Шагыйрь»).

Кайбер очракларда әлеге форма вакыт һәм шарт яки кире шарт мәгънәләре арасында торучы мөнәсәбәт барлыкка китерә: *Юк янымда чын кеше, бул**ганда** да – мин чит күрәм* («Хәстә хәле»).

Хәзерге тел белеме фәненең кешегә юнәлгәнлеге (антропоцентризм күренеше) белән бәйле рәвештә тел системасында кешегә мөһим урын бирелә. Телдә барлык вакыйгалар, күренешләр, процесслар, хәтта кеше үзе дә вакыт һәм пространство яссылыгында карала. Пространство, үз чиратында, каузаль, кондициональ һәм башка мөнәсәбәтләрнең барлыкка килүе өчен фон ролен үти.

Пространство мөнәсәбәтләре турыдан-туры фәлсәфә белән бәйләнгән. Фәлсәфи аңлатма буенча, пространство – материянең яшәеш формасы. Тел структурасында исә пространство төшенчәсе, кагыйдә буларак, вакыйганың үтәлү чикләрен билгеләүче урынны атау формасында белдерелә. Пространство лексикасыннан тыш, урын мәгънәсен юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килеше формасындагы сүзләр, бәйлек сүзле конструкцияләр, рәвешләр, алмашлыклар белдерә ала.

Әйтик, предметның билгеле бер пространствода урнашуы, эш-хәлнең үтәлеш урыны күп очракта урын-вакыт килеше формасындагы исемнәр, бәйлек сүзле исемнәр, рәвешләр белән белдерелә: *Җылы **өйдә** утырасыз якын мичкә...* («Кышкы кич»), *Утырам мин тимер **читлек эчендә**...* («Мәхбүс»); ***Монда** бульварлар, клуб һәм танцевальня, цирк та шул; **Монда** оркестр, театрлар да шул, концерт та шул* («Шүрәле»).

Хәрәкәтнең гомуми юнәлешен күрсәткәндә, иң продуктив чара булып юнәлеш килеш формасындагы исемнәр тора: *Җиктереп пар ат, **Казанга** туп-туры киттем карап* («Пар ат»).

Габдулла Тукай әсәрләре телендә, пространство мөнәсәбәтен белдерү өчен, парлы мөнәсәбәтле сүзләр дә актив кулланыла: *Вә **шунда, кайда** диңгезләр төтен күк Булып күренәдер күзләргә күм-күк* («Мәхбүс»), *Вә **шунда, кайда** аулак, җил дә мин тик, йөрербез бергә-бергә – син дә мин тик* («Мәхбүс»).

Хәл мөнәсәбәтләре күренешләрнең тышкы һәм эчке логик-мәгънәви бәйләнешләрен тәшкил итәләр, семантикалары җөмләнең яки контекстның гомуми эчтәлеген анализлау юлы белән ачыклана. Еш кына бер үк бәйләүче чаралар берничә семантиканы белдерү өчен кулланылалар һәм конкрет мәгънә маркеры булып хезмәт итә алмыйлар.

ӘДӘБИЯТ

1. Валиева Л.Г. О классификации обстоятельственной семантики между синтаксическими единицами // Вестник Дагестанского научного центра. 2015. № 59. С. 94-96.

2. Тукай Г. Сайланма әсәрләр: шигырьләр, поэмалар һәм чәчмә әсәрләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 480 б.

## Г. ТУКАЙНЫҢ МИЛЛӘТ ЯЗМЫШЫ ТУРЫНДАГЫ УЙЛАНУЛАРЫ

***Хәйбуллина Г.Х.***

В статье рассматриваются некоторые статьи и стихотварение Г. Тукая, где отражается судьба татарского народа.

This article discusses some of the articles and stihotvarenie G. Tukaya, which reflects the destiny of the Tatar people .

XX йөз башында татар җәмгыятендә милләтне алга җибәрү, аң-белемне арттыру төп максат булып тора. Г. Тукай – халык язмышы турында кайгырткан, гомерен, иҗатын шуңа хезмәт итүгә багышлаган бөек шагыйрь. Аның «Хөррият хакында» (1905),

«Дустларга бер сүз» (1905), «Иттифакъ хакында» (1905) кебек шигырьләрендә халыкның белемен, мәдәниятен үстерүгә, иҗтимагый үзгәрешләргә чакыру алгы планга чыга. Мәсәлән, «Алла гыйшкына» (1905) шигырендә автор милләтне әхлаклылыкка, мәгърифәткә чакыра. «Шагыйрьгә», Мәхбүс», «Шагыйрь» кебек лирик әсәрләрендә шагыйрьлек милли хөрлек өчен көрәш мотивы белән үрелеп килә.

Татар халкының язмышы, милләт буларак яшәеше, гореф – гадәтләре ерак гасырлардан алып бүгенге көнгә кадәр күп кенә язучылар иҗатында зур урын алып тора. Ф. Галимуллин язганча: «Г. Тукай – шагыйрь генә түгел, бәлки халкыбызның теле, моңы, рухы, язмышы да. Ул чын мәгънәсендә халыкның үз улы, шуңа күрә аның хасиятләрен, мәнфәгатьләрен тирән белүче һәм шуларны сәнгатьлелекнең иң югары кимәлендә сурәтләп бирүче иде»[1, б. 5]. Халык язмышын, аның киләчәген кайгырту язучының публицистик мәкаләләрендә, шигырьләрендә урын ала. Г. Тукайның «Безнең милләт үлгәнме, йоклаган гынамы?» мәкаләсендә мәсәлән, Г. Тукай: «Борын заманда безнең милләт башка милләтләр белән тигез булган. Әмма башкалар алга киткәннәр, татарлар һушы китеп егылган. Милләтнең күзен ачыйк, әдәбият гөл сулары сибик..., милләтне ашаган Бохара “козгыннарын” куып җибәрик. Безнең милләтнең һушы гына киткән», дип яза [3, б.12]. Мәкалә авторы татар милләтенең йокыда булуы өчен борчыла. Әлеге катлаулы хәлдән чыгу юлын ул әдәбиятны, мәдәниятны үстерүдә күрә. «Хиссияте миллия» мәкаләсендә Г. Тукайны татарларда укыту системасының артталыгы борчый. «Бәхетсез мәдрәсәләребез укытучы битлеге кигән мөдәррисләр кулында. Шәкертләр үзләрен наданлык урманына кертеп адаштырганнарын аңладылар. Алар шул мөдәррисләрдән котылырга тырышачаклар, үзләренең милләт эчендә кадерле затлар икәнлекләрен аңлатачаклар. Милләт белемле, халык файдасын үзенекеннән өстен тотучыларга мохтаҗ. Моның юлы – уку, ягъни халыкка хезмәт итү. Үзебезгә кирәк кадәр динебезне һәм әдәбиятыбызны өйрәнгәч, руслар кайда укыса, шунда укырга кирәк» [3, б. 39].

Күренә ки, мәкалә авторы милли мәгариф мәсьәләсен күтәрә. Тукай милләтнең хәлен җиңеләйтү өчен көрәштә бердәмлеккә чакыра. Әлеге фикерләр аның шигырьләрендә дә урын ала. Бердәм булганда гына халык үз бәхетенә ирешәчәк ди. Мисал итеп «Иттифакъ хакында», «Мужик йокысы», «Көз» шигырьләрен китерергә була.

Итик, дустлар, иттифакъ,
Бетсен, кадалсын нифакъ.
(«Иттифакъ хакында»)

«Мужик йокысы» шигырендә дә:

Тор, уян, күтәрел!
Үз- үзеңә кара:
Кем идең, кем булдың?
Нәрсә бар милкеңдә? –

дип, йоклап ятмаска, үз мәнфәгатьләре турында кайгыртырга, алга киткән милләтләрнең хәленнән үрнәк алырга өнди. Халкының инкыйразга баруына борчыла:

Кояш та яктысын киметте шактый;
Тәссеф! (Үкенеч!) Басты золмәт (караңгылык), китте якты.
Колакны шаулата инде суык җил,
Тулып эчкә, өрә мисле куык, җил.
(«Көз»)

Г. Тукай үз бәхетен, дөньяда яшәвенең мәгънәсен халкына тугрылыклы булуда күрә:

Бар уем кичен-көндезен сезнең хакта, милләтем;
Саулыгың – минем саулык, авыруың – минем авыруым.
(«Милләткә»)

Тормыш фаҗигасе «Милли моңнар», «Өметсезлек», «Көзге җилләр», «Өзелгән өмид», «Көз», «Милләт» кебек лирик әсәрләрендә бөтен тулылыгы белән ачыла. Шагыйрьнең хокуксызлыкларга, гаделсезлекләргә тәнкыйди мөнәсәбәте тирәнәя. «Государственная думага», «Сорыкортларга», «Пыяла баш», «Алтынга каршы» әсәрләре иҗтимагый гаделсезлеккә, изүгә байлык алдында баш иючеләргә нәфрәт хисләре белән сугарыла. Тукай «Милли моңнар» шигырендә дә милләтнең үткәне, киләчәге, аның аянычлы язмышы турында уйлана:

Өзелеп-өзелеп кенә әйтеп бирә
Татар күңеле ниләр сизгәнен;
Мескин булып торган өч йөз елда
Тәкъдир безне ничек изгәнен.

Г. Тукайның «Дустларга бер сүз» шигырендәге лирик героеңында хис-кичерешләре милләт язмышына барып тоташа. «Хиссияте миллия» мәкаләсендәге кебек автор халык яшәешен башка милләтләр тормышы белән чагыштырып карый, алар дәрәҗәсенә күтәрелү кирәклеген белдерә.

Башка милләтләрнең хәлен карап карыйк;
Мәдәният мәйданына урын алыйк, –

Җитәкчелек итүне укымышлы шәхесләргә тапшыргач гына, татар халкының милли азатлыкка, мәдәни үсешкә ирешәчәген белдерә:

Барып керик хөрриятнең кочагына,
Тәрәкъкыйнең күкләренә очмагына;
Бу егетләр безне дөнья оҗмахына
Кулдан тотып җитәклиләр, белең имди!

Гомумән, аның «Көзге җилләр» (1911), «Золым» (1911), «Сайфия» (1911), «Авыл халкына ни җитми?» (1912), «Олуг юбилей мөнәсәбәте илә халык өмидләре» (1913) һәм башка әсәрләрендә халыкның, нинди милләттән булуларына карамастан, капиталистик җәмгыятьтә юлыккан фаҗигаләре ачыклана.

Шулай итеп, Г. Тукайга, ил күләмендәге, халык тормышындагы вакыйгалар көчле йогынты ясый. Җәмгыять тәртипләренә, сәяси хәлләргә үз мөнәсәбәтен белдерә. Ул лирик герой, бер милләт вәкиле буларак чыгыш ясый.

ӘДӘБИЯТ

1. Галимуллин Ф. Халыкның үз шагыйре. Мәктәп китапханәсе сериясе. VII том. Казан: Тарих, 2002. 228 б.
2. Нуруллин И. Тукай турында истәлекләр. Казан. Татар. кит. нәшр.,1986. 256 б.
3. Тукай Г. Сайланма әсәрләр: 2 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 271 б.

## Г. ТУКАЙ ИҖАТЫНДА МИЛЛӘТ ЯЗМЫШЫ

***Хәйруллина Ә.С.***

Поэзия Тукая никогда не теряла и не потеряет свою актуальность. Каждый получает от его творчества духовное наслаждение, находит ответы на интересующее вопросы. Понятиям «жизнь народа» буквально пропитаны стихи Тукая. Тукай – особо чуткий поэт. Он передает все переживания народа и его стремление. Для поэта дороги его прошлое и сегодняшнее, поэтому он ценит нацию, во всем этом и есть его величественность и мастерство.

Tukay's poetry never lost and does not lose its relevance. Everyone gets from his work a spiritual pleasure, finds answers to questions. The concept of people's life is literally saturated Tukay verses. It is reflected in every figurative thinking. Tukay – very sensitive poet. It transmits all the experiences of the people and his desire. For the poet of the road his past and today, so he appreciates the nation, in all of this is his majesty and skill.

Тукай иҗатын диңгез дибез, шагыйрьне бөек дибез. Ләкин ул бөеклекне конкрет рәвештә нәрсәдә күренгәнен аерып әйтә алмыйбыз. Чөнки ул иҗатта һәр кем һәм һәр чорда үзен борчыган сорауларга җавап таба алган, шуңа аны кисәкләргә бүлгәләү мөмкин дә түгелдер.

Галимнәр Тукай иҗатын икегә бүлеп карыйлар. Әдәбият галиме, тәнкыйтьче Т. Галиуллин аны болай күрсәтә: «Хәзер әдәбият галимнәре, тарихчылар аның иҗатын ике дәвергә – Җаек һәм Казан чорларына гына бүлеп өйрәнү концепциясенә өстенлек бирәләр. Шартлылык биредә дә бар. Тукайның халыкчан, реалистик поэзиясе бербөтен. Шул ук вакытта аның Казан чорын өлгергән, җитлеккән, югары баскыч дип бәяләп, Җаек дәверен кимсетеп, түбәнәйтеп, өйрәнчек, корама телле чор дип карау очраклары да бар. Хәлбүки мондый караш бик үк дөреслеккә туры килми» [1, б. 5].

Һәр күренештә һәм вакыйгада бер генә факторны исәпкә алып җиткермәү дә ялгыш нәтиҗәләргә китерә. Ә Тукай кебек олы талантның эзләнү юнәлешләрен һәм аңа йогынты ясаган көчләрне, гомумән, исәпкә алып бетерү мөмкин түгел. Шулай да И. Нуруллин тәэсир иткән төп факторларны: 1) традицион дини-әхлакый әсәрләр;

2) К. Насыйри, З. Бигиев, Акмулла кебек мәгърифәтчеләр;

3) рус әдәбияты, беренче чиратта Пушкин һәм Лермонтов;

4) кайчандыр «Мотыйгия» мәдрәсәсендә укыган, ел саен килеп, Тукай белән озын-озак аралашкан шагыйрь – мулла Мирхәйдәр Чулпаный һәм төрек эмигранты Габделвәли Әмрулла;

5) «Мәгариф», «Әлгасрелҗәдит» кебек кулъязма газета-журналлар чыгарып, «гыйльми мәҗлесләр» оештырып, әдәби атмосфера булдырган Камил Мотыйгый;

6) халык авыз иҗаты [3, б. 7], дип билгели.

Рәсми рәвештә беренче әсәре дип танылган «Мужик йокысы» шигырендә үк югарыда санап үтелгәннәренең берничәсе чагылыш тапканын күрергә мөмкин. Беренчедән, ул А.В. Кольцовның «Что ты спишь, мужичок?..» шигыренә ияреп язылган. Икенчедән, проблема халык мәкале «Тырышкан табар, ташка кадак кагар»дагы кебек хәл ителә:

Тик яткач, Ходаем
Бирмимал сәбәпсез:
Бишмәтең таланган,
Күлмәгең сәдәпсез.

Шигърияtнең көче – берничә юл белән зур мәгънәне бирүдә Тукай иҗатында ул чорның вәзгыятен дә, татар милли – иҗтимагый проблемаларны да, тарихны да күрергә мөмкин. Шагыйребез әлеге проблемаларны гаять үткен итеп күтәреп кенә чыкмый, аны халыкка җиткерүнең үтемле юлларын да эзли. Мәсәлән, бүгенге көн тарихчылары, дин белгечләре алып бара торган мәсьәләләрен ул мондый юллар белән калкытып кына куймый:

Ханнарга иреште хизан,
Җылый – җылый бирделәр җан:
Сөембикә дә Чыңгыз хан;
Нә дәүләт калды да нә шан!
Һич калмады шаннан нишан
Калды дингә дошман ишан!

«Кичке азан» шигырен беренче тапкыр автор үзе сәхнәдән укый. Бу көн «Казан» миһманханәсенең залында шәһәремездә дәфга уларак рус-мөселман концерты булачактыр...»; «Г. Тукаев исә Сиражетдин Билюков әфәнделәр чыгып, шәрекъ ысулынча тезләнеп, милли кием исә «Кичке азан» шигырен укыдылар...» [4, б. 249].

Тукай милләткә шигъри таланты белән генә хезмәт итми: ул публицист та, газета хезмәткәре дә... Ләкин хисләре бар яктысында, тирәнлегендә, шигырьләрендә чагылыш тапкан. Аны бар нәрсә дә борчый, бер генә вакыйга да игътибарыннан читтә калмый. «1908 елдан соңгы сулышына чаклы Тукай милләт хәсрәтен, – дип яза Т. Галиуллин, – халык язмышын арык иңнәренә салып, тарихыбызга, үз чоры проблемаларына караган самимилекләре белән нәфис, гүзәллекләре белән камил шигъри энҗеләрен иҗат итә. Тукайның бөеклегенә ышану өчен, бөтен иҗатын күзаллау мәҗбүри түгел. Биредә һәркайсы өч шигъри юнәлешкә караган – «Шагыйрь», «Милләтчеләр» һәм «Милли моңнар» кебек шедеврларына гына тукталып үтәсе килә. Бер ел дәвамында гына мең төрле хис үтеп керә: икеләнү, эзләнү, борчылу, сагыш белән беррәттән кискенлек, кичереш, шатлык та кичерә шагыйрь» [4, б. 30].

«Шагыйрь» шигырендә Тукайның шагыйрьлек миссиясе хакында уйланулары, үзендә дә шагыйрьлек таланты барлыгын танучы гына түгел, ә мактанмыйча гына, объектив рәвештә, аңа бәя бирүе чагылыш тапкан. Шигъри сүз – аның коралы һәм ул аны халык мәнфәгатьләренә хезмәт иттерергә тиеш. Шагыйрьнең – Тукай фикеренчә – мескен булырга хакы да, хокукы да юк, ул бары мәңге яшь һәм көчле генә була ала. Шул ук вакытта гомер агышы, яшьлекнең тиз үтүчәнлеге хакындагы фәлсәфи уйланулары, теләсә нинди аерылушы-саубуллашуда була торган вакыт та урын алган:

Җырлый-җырлый үлəрмен мин үлгәндә дә,
Дәшми калмам Газраилне күргәндә дә;

«Без китәрбез, сез каласыз!» – дип җырлармын,
Җәсәдемне туфрак берлә күмгәндә дә.

Милләт өчен үз-үзен аямаган Тукай башкалардан да шуны таләп итә, шуның өчен аның «Милләтләр» шигыре гаять усал;

Татар халкы! Син үләргә мәхкүм инде
Дару үтмәс дәрәҗәдә мәсмүм инде»

дигән сүзләр белән башлана. Юк, бөтенләй терелүенә өмет өзми ул, ләкин тырышырга, яшәешнең бөтен өлкәсен – дингә мөнәсәбәттән алып сәясәткә кадәр үзгәртеп корырга кирәк. Ишан булып, корсак тутырып йөрүдән, депутат кәнәфиен биләп, җайлы яшәешне тәэмин итүдән туктап, халкыңның хакын яклый башларга кирәк:

Лябез сиңа терлер өчен корбан кирәк,
Җитми мыр-мыр хәтем – чын, саф Коръән кирәк;
Көймә бата; йота торган балык өчен
Фида булган мөрәввәтле бер җан кирәк.

Милләт авыру – моның белән килешә шагыйрь, шуңа аның өмете фидаи ул һәм кызларында: «Биһүдәдер! – сорыкорттан көтләк гыйлаҗ / Син бер гади, сатылмаслык иргә мохтаҗ».

Авыру булуында халык үзе гаепле түгел, аңа моны читтән такканнар. Тарих дөнья тетрәтеп торган һәм ахыр чиктә сәхнәдән китәргә мәҗбүр булган бик күп халыкларны белә. Билгеле; татарның да данлы вә шанлы вакытлары булган, ләкин дөнья үзгәрә, кемдер килә, кемдер китә. «Берәү үлми, берәү көн күрми», ди халык. Кайдадыр булган байлык һәрвакыт икенчеләрне ымсындырган, яу чабарга котырткан, инде яулап алынган халык ассимиляцияләшүгә мәҗбүр ителгән. ләкин… канга сеңгән Дәрдемәнд тарафыннан «сөт» дип билгеләнгән үз йөзең, дөньяга үз мөнәсәбәтең, менталитетың булу һәр басымга – һәм милли һәм дини – каршы торырга ярдәм итә икән, «Милли моңнар» әсәре әнә шул хакта. Чөнки, колониаль шартларда дөньяви институтлары булмаган халык, хөкүмәтнең руслаштыру сәясәтенә динне һәм моңны гына каршы куя алган:

Күпме михнәт чиккән безнең халык,
Күпме күз яшьләре түгенгән;
Милли хисләр белән ялкынланып,
Сызып-сызып чыга күңелдән.

Әнә шулай күпкырлы Тукай иҗаты, шуңа халыкчан һәм шуңа көчле дә, һәм аның иҗатында чын мәгънәсендә халык язмышы, милләт язмышы чагылыш тапкан.

ӘДӘБИЯТ

1. Галиуллин Т. Шәхесне гасырлар тудыра. Казан. Татар. кит. нәшр., 2003.
2. Галиуллин Т. Әдәбият – хәтер хәинәсе. Казан: Мәгариф, 2008, 30 б.
3. Нуррулин И. XX йөз башы татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982.
4. Тукай Г. Сайланма әсәрләр. 2 томда / төзүчеләр: Н. Хисамов, З. Мөхәммәтшин; искәрмәләр һәм аңлатмаларны әзерләүче: М. Әхмәтҗанов. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. Т. 1. 249 б.

## Г. ТУКАЙ ӘСӘРЛӘРЕ АКАДЕМИК БАСМАДА (бишенче том мисалында)

***Хөснетдинова Г.А.***

В статье речь идет об Академическом издании собрания сочинений Г. Тукая, в частности о пятом томе. Рассматривается структура и содержание тома, особое внимание уделяется на те новшества, которые внес Г. Тукай в тематику и художественные особенности произведений жанра басня. Также в статье анализируются впервые включенные в данное издание два новых произведения, которые написаны для детей, но не вошли в ранние многотомники Г. Тукая.

In the article we are talking about academic publication collection of "Essays" by G. Tukay, in particular, about the fifth volume. Describes the structure and contents of the volume, special attention is paid to those innovations that have made G. Tukay in the theme and artistic features of the works of the genre fable. The article also analyzes the first included in this edition two new works written for children, but was not included in early multivolume G. Tukay.

XX гасыр ахырында илебезнең иҗтимагый тормышында килеп чыккан кискен үзгәрешләр әдәбиятыбызның үткәнен бернинди чикләүләрсез өйрәнү, әдәби мирасыбызны тулы рәвештә халыкка кайтару мөмкинлеген бирде. Бу юлда Габдулла Тукай әсәрләренең Академик басмасын төзү зарурияте туды.

Алты томлы Академик басманың бишенче томында Г. Тукайның «Исемдә калганнар» (1909) автобиографик повесте, «Кечкенә сәяхәт» (1911), «Мич башы кыйссасы» (1912), «Казанга кайтыш» (1912) һәм «Мәкаләи махсуса» (1912) исеме белән басылган юльязмалары урын алды. Аларның һәммәсе дә автобиографик характерда, документаль фактларга, вакыйгаларга, конкрет шәхесләрнең эш-гамәлләрен яктыртуга корылган.

Әсәрләрнең барысын да төп герой язмышы берләштерә. Аларның үзәгендә шагыйрь образы тора. «Исемдә калганнар»да Тукай талантлы язучы буларак авыр балачагын сурәтләсә, «Мәкаләи махсуса»да (юлъязма Казан – Самара – Уфа – Петербург–Уфа–Троицк буйлап сәяхәт тәэсирендә язылa) Казан губернасыннан читтәге шәһәрләр тормышы, алардан алган тәэсирләрен, «Кечкенә сәяхәт»тә исә Тургенев пароходындагы күренеш-вакыйгаларны, аларга үзенең мөнәсәбәте хакында төрле буяулар белән тасвирлап бирә. «Мич башы кыйссасы»нда, «Казанга кайтыш»та сатира аша татар авылының реалистик картинасын сурәтли, төрле милләт вәкилләрен күзәтеп, үзенең нәтиҗәләрен ясый.

Юлъязмаларның тәэсир көчен арттыру өчен Г. Тукай шигърияткә дә мөрәҗәгать итә. Монда мисал итеп «Мич башы кыйссасы»ндагы «Бәйрәм бүген», «Шагыйрь», «Мәкаләи махсуса»да «Валлаһи», «Казанга кайтыш»та «Гыйбрәт вә нәсыйхәт» шигырьләрен һәм бәйтләрне күрсәтү урынсыз булмас. Юлъязмаларда пейзаж да билгеле бер урын тота. Монда Уфа шәһәренең табигатен, җырларда җырланган Агыйдел елгасын сурәтләгән, Петербург шәһәренең гүзәллеге һәм шагыйрьдә яшәү өмете уяткан казакъ далаларының тасвирларын мисал итеп санап китү урынлы булыр. Чөнки алар геройның рухи халәтен тулырак гәүдәләндерү чарасы булып тора.

Әлеге әсәрләрдә төп герой язучы үзе булуы, сурәтләнгән вакыйгаларга турыдан-туры катнашуы аның тәрҗемәи хәлен, шәхес буларак формалашу тарихын өйрәнгәндә, яшәү һәм иҗат итү рәвешен күздән кичергәндә бу әсәрләр зур кыйммәткә ия тарихи чыганак булып тора.

Тукай иҗатының бер юнәлеше булган мәсәлләр бишенче томның иң зур өлешен тәшкил итә. Тукайның И.А. Крылов мәсәлләре тәрҗемәләре беренче мәртәбә 1906–1907 елларда чыккан «Әлгасрелҗәдид» журналы битләрендә басыла. Уральскида нәшер ителгән бу журналда Г. Тукай җаваплы сәркәтиб вазифасын башкара; һәр санда диярлек аның я шигыре, я публицистик әсәре яки тәрҗемә әсәре дөнья күрә. 1906 елның 2 нче (15 февраль), 3 нче (15 апрель), 7 нче (20 июль), 10 нчы (15 октябрь) һәм 1907 елның 2 нче (15 февраль) саннарында «Мәҗмугаи мөфидә» дип исемләнгән бүлектә Г. Тукайның барлыгы 77 әсәре басыла. Бүлек: «Рус мөхәррирләрендән әдибе нәҗиб Крылов шәһирнең асаре мәргубәләрендән мәалән тәрҗемә улынмыш (*Зирәк һәм мәшһүр язучы Крыловның кызыклы әсәрләреннән иркле рәвештә тәрҗемә ителде)* вә госманлы әдәбиятындан әхез иделмеш кыска-кыска гыйбрәтле хикәялердер. Мөмкин кадәр татар мәгыйшәтенә борыбрак язылмышдыр. Асаре Габдулла Тукаев» дигән сүзләр белән башлана. 1907 елгы 2 нче санда ахыргы әсәр итеп урнаштырылган «Локман Хәким сүзләре»ннән соң «Ахыры бар» дип куелган булса да, алга таба басылган саннарда әлеге әсәрләрнең дәвамы күренми.

Моңа кадәр Г. Тукай күптомлыкларында «Энҗе бөртекләре», «Яңа кыйраәт» җыентыкларында басылган мәсәлләр генә басылып килә иде. Әлеге күптомлыклардан аермалы буларак, алты томлы Академик басмада беренче тапкыр «Әлгасрелҗәдид»тә «Мәҗмугаи мөфидә» («Файдалы җыентык») исеме белән басылган мәсәлләр бишенче томның «Кушымта» өлешендә тәкъдим ителде. Әлеге мәсәлләр Тукай тарафыннан тәрҗемә ителгән И.А. Крылов мәсәлләренең беренче варианты. Шигырь белән язылган бу мәсәлләр Тукай тарафыннан проза әсәре итеп бирелә. Язучы Крыловтагы образлар системасын саклап, мәсәлләрне татар тормышыннан алынган күренешләр белән баета. Крыловтагы нәтиҗәләр үзгәртелә, яисә бөтенләй төшерелеп калдырыла. Мәсәлләрнең беренче варианты гади укучы өчен бик үк кызык та булмаска мөмкин, ә менә шагыйрь иҗатын тирәнтен өйрәнүчеләр өчен кыйммәтле материал. Чөнки алар Тукайның иҗат лабораториясен, тәрҗемә эшендәге үсешен күзалларга мөмкинлек тудыра.

Тукайны мәсәлләрнең формасы түгел, ә эчтәлеге, андагы образларда гомумиләштерелеп бирелгән мәгънәви, тәрбияви ягы кызыксындыра. Крылов образларын Тукай башлыча, кайбер дин әһелләреннән, үзен мин интеллигент дип йөрүче бер файдасыз кешеләрдән көлү коралы итеп куллана. Г. Тукайның мәсәлләре фикергә бай һәм үтемле булулары белән дә игътибарны җәлеп итә, аларга тирән акыл, тапкырлык хас.

Соңрак Г. Тукай «Мәҗмугаи мөфидә»дә басылган мәсәлләрнең 70 ен редакцияләп, кирәкле урыннарда рус исемнәрен татар исемнәре белән алмаштырып, аерым мәсәлләрдә үзенең гыйбрәтле нәтиҗәсен ясап, телен-стилен әдәбиләштереп, яңа мәсәлләр өстәп, барлыгы 77 мәсәлне эченә алган «Энҗе бөртекләре» исемле җыентыгын бастыра. 1909 елда Казанда «Үрнәк» матбагасында чыккан җыентык наширләренең кереш сүзендә («Бер-ике сүз») болай диелә: «...Әдәбиятның бу нәүгысы (*төре*) – ягъни мәгыйшәткә даир зур-зур фәлсәфи мәгънәләрне төрле кыска хикәяләр васитасы белән тәлкыйн итү (*аңлату*), мөтәмәддин (*алга киткән*) милләтләрнең әдәбиятындан бик күпдән бирле мәкъбүл булып (*кабул ителеп*) килгән һәм бик искедән бирле истигъмаль ителгән (кулланылган) рәвешдер... Моңар кадәр яшь әдәбиятымызда бу нәүгының тәрәкъкый таба алмавы зур кимчелек иде; менә шул кимчелекне тутыруда өлге адым булсын фикере белән без халыкның мәхәббәтен үзенә караткан вә гали шигырьләре белән күңелләрне хисият уяткан шагыйрь мөхәрриремезнең бу кыска-кыска хикәяләрен «Энҗе бөртекләре» исеме белән нәшер итәмез» [1, б. 2]. Соңыннан бу мәсәлләрнең кайберләре «Яңа кыйраәт» (1909, 1910) дәреслек-хрестоматияләренә дә кертелә.

Академик басманың бишенче томында Г. Тукайның балалар өчен язган хикәяләре дә урын алды. Әдәбият галиме, балалар өчен әкият-хикәяләр иҗат иткән Гали Рәхим билгеләвенчә «Тукай бер яктан татар шигыренең атасы булса, икенче яктан, шөбһәсез, татар телендәге балаларга махсус әдәбиятның да башлап тудыручыларыннан хисапланырга тиеш» [3, б. 9]. Чыннан да Тукай шагыйрь генә түгел, иҗат гомерендә балалар өчен хикәяләр язган, уку китаплары төзегән язучы да. Ул балалар күңелен нечкә тоемлап, дөньяны танып белүләрен хикәяләрендә матур бизәкләр, гыйбрәтле сүзләр белән сурәтләп бирә. Шагыйрьнең балалар өчен язган кайбер хикәяләре, мәсәлән, «Тургайлар ашыйбыз!» «Җуаныч» исеме белән басылган җыентыгында, «Рәхәт йокы» хикәясе «Әлгасрелҗәдид» журналы битләрендә урын ала. Ә инде «Яңа кыйраәт» исеме белән басылган дәреслек-хрестоматияләрдә алар бергә тупланып дөнья күрә. Башлангыч мәктәпләр өчен шагыйрьнең үзе тарафыннан төзелгән «Яңа кыйраәт» китабының беренче басмасы 1909, ә икенче басмасы яңа әсәрләр өстәлеп кабат 1910 елда басыла. «Кыйраәт»ләрнең төп максаты – балаларның күңелен, әхлакларын тәрбия итү була.

Академик басманың бишенче томы текстологиясен эшләү этабында безнең тарафтан Г. Тукайның моңа кадәр бер күптомлыгына да кертелмәгән балалар өчен язылган «Табигать һәм инсан» һәм «Казан шәһәре» хикәяләре барлыгы ачыкланды. Бу хикәяләр Казанның «Үрнәк» матбагасында 1910 елда чыккан «Яңа кыйраәт» китабының яңа әхлакый мәкаләләр һәм яңа шигырьләр кертелеп төзелгән икенче басмасында урын алганнар. Әлбәттә, совет чорында күптомлыкларга кертелергә лаек табылмаган әлеге текстлар безгә кадәр эшләүче галимнәргә дә билгеле булгандыр. Чөнки шундый рухта язылган әсәрләр турында булса кирәк, 1986 елда нәшер ителгән биштомлыкның бишенче томында бер җөмлә белән генә «...әһәмиятсез һәм искергән әсәрләр төшерелеп калдырылды» [2, б. 292], дип әйтелгән. Чыннан да совет җәмгыятендә хөкем сөргән коммунистик идеологиягә туры килмәгән милләт, дәүләтчелек, дин хакында язу түгел, сөйләү дә тыелган заманда Аллаһы Тәгаләне мактаган, Казан шәһәре образында чагылыш тапкан дәүләтчелек, милләт хакында язылган әсәрләрнең Г. Тукай «Әсәрләр»енә кертелми, төшерелеп калдырылуы гаҗәп түгел.

Г. Тукайның бу ике «Табигать һәм инсан» һәм «Казан шәһәре» хикәяләре дә яшь буынны чын милли җанлы, белемле һәм динле итеп тәрбияләүне максат итеп куя. Беренчесендә Аллаһы Тәгаләнең кодрәте, барлык тереклек бары аның «әмеренә буйсынып үз эшләрен эшләмәкдәдер» дигән фикерне ассызыклый. Ислам динен яхшылыкка өйрәтә торган изгелек һәм мәрхәмәтлелек дине дип атый, үзең инанган динне башка диннәрдән өстен күрүне алга сөрә. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә куанып, каһәреннән куркып яшәргә кирәклеген дә әйтә.

Ә инде «Казан шәһәре» хикәясендә шагыйрь горурлык хисе белән татар халкының борынгы, данлыклы шәһәре Казаны, каһарманлык һәм гүзәллек символы булган

Сөембикәсе, гүзәл мәчетләре хакында сөйли. Шагыйрь Казанның «шул көе калуын, шул хәлдә һаман алга баруын!» теле.

ӘДӘБИЯТ

1. Габдулла Тукаев. Энҗе бөртекләре. Казан: Үрнәк, 1909. 72 б.

2. Габдулла Тукай. Әсәрләр. Биш томда. 5 том (Истәлекләр. Юлъязмалар. Хатлар. Мәсәлләр һәм балалар өчен хикәяләр (1902–1913). Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 368 б.

3. Гали Рәхим. Тукай һәм балалар әдәбияты // Мәгариф. 1923. № 3–4 (март-апрель). Б. 9–12.

## Г. ТУКАЙ ШИГЫРЬЛӘРЕНДӘ МАТДИ МӘДӘНИЯТ ЛЕКСИКАСЫ (савыт-саба атамалары мисалында)

***Хөснуллина Г.Н.***

В своих стихотворениях каждый поэт отражает определенную эпоху. Для этого он использует лексику, отражающую материальную и духовную культуру народа. Лексика материальной культуры татарского языка включает такие жизненно-важные лексико-тематические группы, как жилище, одежда, еда, посуда и т.д. Статья посвящается изучению наименований посуды в стихотворениях Г. Тукая.

Each poet reflects a certain era in his poems. For this purpose he uses the lexicon reflecting material and spiritual culture of the people. The lexicon of material culture of Tatar includes such vital lexical thematic groups as the dwelling, clothes, food, ware etc. Article is devoted to study of names of ware in poems G. Tukay.

Г. Тукай – татар шигъриятен бөтен дөньяга таныткан, бөек, талантлы шагыйрь. Ул шәхес буларак та, иҗаты белән дә күпьяклы, тирән фикерләүче һәм сизгер җанлы әдип. Аның шигырьләре милли әдәбиятыбызның, мәдәниятебезнең барлык тармакларына диярлек көчле, тирән йогынты ясый. «Шигъриятебез үсешенә ул ясаган этәргеч һәм йогынты шундый тирән булды ки, татар поэзиясе бүген дә шушы маякның тиңсез колачын үзләштерү һәм үстерү дәрте белән яши», дип яза Н.Хисамов [6, б. 79]. Чыннан да, Г. Тукай кыска гына гомер итүенә карамастан, ул татар әдәбиятында үз урынын ала, якты йолдыз булып калка. Әлеге йолдыз бүгенге көндә дә балкып тора, яшь буын шагыйрьләренә юл күрсәтә. Г. Тукайга багышлап музейлар ачу, аның сыннарын эшләү, район һәм урамнарга аның исемен кушу, ел саен Г. Тукай премиясен тапшыру – һәммәсе дә аның бөек шәхес икәнен раслый. Илебездәге төрки телле халыкларның әдәбиятын үстерүдә дә тирән, нәтиҗәле, бәрәкәтле эз калдырган. Галим фикере белән әйткәндә, «Төрки халыклар өчен дә Г. Тукай – аларның үз шагыйре, язма мәдәнияте» [6, б. 79].

Тукай халкыбызның тел хәзинәсеннән искиткеч оста файдалана белгән. Әлбәттә, шагыйрьнең теле гади түгел, бу бигрәк тә аның башлангыч чор иҗатына карый. «Тукай теле, гомумән, шулай ук аның шигырь теле дә лексик яктан бик катлаулы», дип яза күренекле тел галиме Ш. Рамазанов та [2, б. 70].

Г. Тукай шигырьләрендә кулланылган лексик байлыкны берьюлы колачлау мөмкин булмаганлыктан, әлеге хезмәтебездә бер төркем савыт-саба атамаларын гына барлап чыгу максат итеп куела.

Тукай шигырьләрендә кулланылган савыт-саба атамаларын өч төркемгә бүлеп карарга мөмкин. Болар – аш-су әзерләү; аны саклау, йөртү-ташу һәм ризыкны табынга бирү өчен кулланыла торган савыт-саба атамалары.

*Ничектер, белмимен, бер көн идән асты кошы – Тычкан*
*Егылган да келәттә бер **табак** сөткә килеп төшкән.*
(«Сөткә төшкән тычкан»)

*Табак* – зур түгәрәк һәм чагыштырмача сай савыт [3, б. 503].

*Әнә **чүлмәк**: аңар катык тутырган;*
*Менә хәлфә: башы мантыйк тутырган.* («Әнә-менә»)

*Чүлмәк* – балчыктан яндырып ясалган корсаклы савыт (сөт-катык һ.б.ш. сыеклыклар өчен) [3, б. 672].

*Йә сихерле **шишәдән** әбелхәят (тереклек суы) эчмәктәме?*
*Мәст улып (исереп), аляме дөньядан (дөнья газапларыннан) тәмам кичмәктәме?*
(«Ләззәт вә тәм нәрсәдә»)

*Шишә (шешә)* – сыекчалар салу өчен тар бугазлы пыяла савыт [3, б. 682].

Алтын ***паднуслар*** күтәрдем,
*Чын **чынаяк** түнтәрдем.*
*Сез дусларым килә дигәч,*
*Сырхау башым күтәрдем.* («Халык моңнары»)

*Чынаяк* – чәй эчү өчен файдаланыла торган фарфор яки фаянс савыт [3, б. 664].

*Торса анда иштелеп «эч, эч» дигән сүз таңгача,*
***Кясәләр** булса тулы без мәст булып (исереп) аугангача.* («Мәҗлес»)

*Кясә (касә, кәсә)* – кисек конус формасындагы пыяла яки фарфор савыт, тоткасыз чынаяк [3, б. 240].

«Тукай татар теленнән башка тагын гарәп, фарсы, төрек һәм рус телләре белән дә яхшы таныш. Кирәк булганда, бу телләр белән үзе теләгәнчә файдаланган да» [2, б. 70]. Мисал өчен, алдагы өзектәге *поднос* сүзе. *Паднус (поднос)* – савыт-саба, аш куеп йөртә торган, аз гына кайтарылган читле, түгәрәк яки озынча калай яисә пластмасс савыт [3, б. 420].

*Җөрмә монда, кайт илеңә –*
*Илеңдә иген игәрсең;*
***Ыстаканыңны** ат итеп,*
***Бутылкаңны** җигәрсең.* («Халык моңнары»)

*Ыстакан (стакан)* – чәй, су эчү, сыеклык алу-салу өчен кулланыла торган, нигездә, цилиндр формалы, сапсыз, үтә күренмәле пыяла, бәллүр һ.б.ш. материалдан эшләнгән савыт [3, б. 481].

*Шешә* лексемасының рус теленнән кергән *бутылка* варианты тагын очрый:

*Хулиганнар груһлана казенкага,*
*Суык чөнки – сызлый арка һәм җилкә дә;*
*Ушбу халык, кабак ничек ачылгач та,*
*Бик нык суга гөнаһы юк **бутылкага**, – ... .* («Суык»)

Г. Тукай шигырьләрендә савыт-саба атамалары нигезендә ясалган фразеологизмнарны да уңышлы файдалана. Мәсәлән, *пычак* берәмлеге (*пычак* – кисү, турау өчен бер башына сап куелган, бер ягы үткен яссы металл кисәге [3, б. 435]) нигезендә ясалган фразеологизмнар:

*– Ни кирәк? Кем бу? Кара төндә вакытсыз кем йөри?*
*Нәрсә бар соң төнлә берлән, и **пычагым** кергери!* («Су анасы»)

*Пычагым (пычак) кергере* – суелгыры, пычакка кадалгыры, эченә пычак кереп үлгере, янәсе [1, б. 55].

*Кактым-суктым – әчелде,*
*Тәңкәләре чәчелде;*
*Эте чыкты өрмәгә,*
*Кызы чыкты күрмәгә;*
*Этен алдым **пычакка**,*
*Кызын алдым кочакка.* («Күк сыер»)

*Пычакка алу* – кемгә дә булса пычак белән һөҗүм итү [1, б. 55].

Г. Тукай шигырьләрендә савыт-саба атамалары белән беррәттән матди мәдәният лексикасының башка төркем сүзләре дә зур урын алып тора, чөнки ул халыкның көнкүрешен, гореф-гадәтләрен, яңача яшәү рәвешен һ.б. сурәтләгәндә телнең лексик байлыгын бөтен тулылыгы белән файдалана. Тел белеменең лингвокультурология фәне өчен дә Г. Тукай шигырьләре кызыклы тикшеренү объектын тәшкил итә.

ӘДӘБИЯТ

1. Исәнбәт Н.С. Татар теленең фразеологик сүзлеге. Ике томда. II том. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. 365 б.

2. Рамазанов Ш.А. Г. Тукай һәм хәзерге татар әдәби теле // Татар теле буенча очерклар. Казан: Таткнигоиздат, 1954. Б. 58–92.
3. ТТАС – Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан: Матбугат йорты, 2005. 848 б.
4. Тукай Г. Әсәрләр. 4 томда. 2 т.: шигырьләр, поэмалар (1909–1913). Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. 400 б.
5. Тукай Г. Сайланма әсәрләр: 2 томда. 1 т.: Шигырьләр, поэмалар / төз.: Н. Хисамов, З. Мөхәммәтшин. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 271 б.
6. Хисамов Н.Ш. Татар шагыйрьләре: монографик мәкаләләр, иҗат портретлары һәм этюдлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. 287 б.

## ФОЛЬКЛОРНАЯ ОСНОВА ПОЭМ Г. ТУКАЯ «ШУРАЛЕ» И «ВОДЯНАЯ ВЕДЬМА» КАК ОБЪЕКТ КУЛЬТУРОЛОГИЧЕСКОГО ПЕРЕОСМЫСЛЕНИЯ

***Хуббитдинова Н.А.***

В статье поэмы «Шурале» и «Водяная ведьма» видного татарского поэта и общественного деятеля Габдуллы Тукая рассматриваются с совершенно новой точки зрения с применением инновационного метода исследования – с использованием культурологического подхода в рассмотрении фольклорных основ. Культурологическое изучение известных поэтических произведений во многом позволит выявить семантику используемых мифических образов в их новом историко-культурном, художественно-эстетическом прочтении. Демонологические персонажи – Шурале, Водяная ведьма – Су-анасы – пережили культурное наслоение благодаря мировоззрению и социально-политическому взгляду поэта.

The article poem "Shurale" and "Water Witch" prominent Tatar poet and public figure Gabdulla Tukay dealt with a whole new perspective with the use of innovative research method – using a cultural approach in examining the foundations of folk. Culturological study known poetic works in many ways will reveal the semantics used by the mythical images in their new historical, cultural, artistic and aesthetic reading. Demonological characters – Shurale, Water Witch – Sioux Anasy – experienced a cultural layering due outlook and socio-political views of the poet.

В начале XX века национальная словесность, как и литература других народов России, переживала новый виток в своем развитии, сопряженный с тяжелой социально-политической обстановкой в стране, а также зарождением и усилением в последующие годы национального самосознания народов. Известно, что в этот период Российская империя находилась на самом сложном и противоречивом этапе своей истории: Русско-японская война, первая революция 1905–1907 гг., начало «реформации» в мусульманском обществе, катастрофа Первой мировой войны, которые усугубили социальное расслоение в обществе, породили социально-политические противоречия и т.д. Тем не менее, в этот период культура вообще, национальные литературы в особенности развивались и вступали в новый этап своего развития. Например, башкирская литература как никогда сблизилась с жизнью народа, которая ярче всего отразилась в его устно-поэтическом творчестве. «С одной стороны, она отстаивала общенациональные интересы башкир, их право на духовную и национальную самобытность, призывала народ к борьбе против незаконных захватов и расхищения башкирских (вотчинных. – *Н.Х.*) земель, с другой – довольно ярко стала отражать классовую дифференциацию в обществе, поднимала острые социальные вопросы» [4, с. 207]. Эти и другие насущные проблемы, касающиеся жизни башкирского и татарского народов, их будущего, обостренные революцией 1905–1907 гг., нашли широкое отражение в творчестве национальных поэтов Мажита Гафури, Шаихзады Бабича, Сафуана Якшигулова, Фазыла Туйкина, а также Г. Исхаки, Г. Тукая, Г. Камала, Ф. Амирхановя и многих других писателей, которые пришли в литературу в эти годы. Связь между фольклором и литературой проявлялась во всей своей многообразии: одни писатели напрямую обращались к устно-поэтическому народному творчеству, фиксировали и публиковали отдельной книгой или в различных газетных, журнальных изданиях, в своих публицистических выступлениях призывали к борьбе за чистоту родного языка путем обращения к фольклору, другие творчески осваивали фольклорные традиции – мотивы и сюжеты сказок, эпоса или кубаира в своих произведениях, создавали на их основе собственные произведения и т.д. (С. Якшигулов, Д. Юлтый «Положение башкир», М. Тангатаров, С. Як-

шигулов «Обращение к братьям башкирам», Ф. Туйкин «Башкирская женщина», написал поэму «Идельбай», драму «Сыновья Отчизны» и т.д.).

В этот период художественная башкирская словесность становится на путь самостоятельного развития. Подобную картину можно было наблюдать и в творчестве татарских писателей, которые также обращались к устно-поэтическому наследию своего народа, «обозначив тем самым главной своей целью поиск и идеологическое определение дальнейших путей развития нации, сохранение ее конфессиональной и культурной самобытности» (Г. Исхаки, Г. Тукай, Дэрдмэн, Г. Камал, Ф. Амирханов, Ш. Камал, Г. Ибрагимов и др.) [5, с. 10]. Например, в поэмах великого татарского классика Габдуллы Тукая «Шурале» (1907), «Водяная ведьма» (1908) нашли художественное воплощение демонологические образы. Проведя их сквозь призму иронии и юмора, поэт изобразил картину верования тюркских народов, татарского в частности. Эти поэмы в равной степени близки не только татарскому народу, но и башкирскому, так как их сюжеты, образы также знакомы и близки мировоззрению последнего и т.д. С усилением национального самосознания среди татарского народа в начале XX в. также активизировалась деятельность по собиранию и популяризации устного народного творчества. На страницах печати в разные годы издавались статьи и материалы по теме («О татарских песнях» Максютова (Шура, 1911), «О наших песнях» А. Валиди (Шура, 1911), «Песни края (иль)» Г. Юлдаша (Шура, 1911) мн. др.) [6, с. 28].

В очередной юбилейный год видного татарского просветителя и поэта, единомышленника и брата башкирских писателей современности Габдуллы Тукая, конечно, хочется еще раз остановиться на его незабвенном поэтическом наследии, поэмах «Шурале» и «Водяная ведьма», написанных в высоко художественном романтическом духе на основе устного народного творчества. В данной статье мы сделали попытку рассмотреть эти произведения в контексте их культурологического переосмысления. Это позволит взглянуть на них с улучшенной, как сегодня модно еще называть, инновационной точки зрения.

Как видно из перечисленных исторических событий и культурных перемен, происходящих в дореволюционной России, литература продолжала развиваться, усовершенствоваться, переходя из беллетристики, графоманства к более профессиональному творчеству, переплетаясь с устно-поэтическим народным творчеством, входя с ним в тесную интертекстуальную связь и т.д. Изучение того или иного произведения невозможно осуществить без культурно-эстетического, культурологического подходов. Поэтому сегодня, в век глобализации назрела необходимость исследования национальной словесности именно в аспекте культурологического анализа, что даст возможность получить более полную картину развития национальной литературы, в целом, художественно-эстетических особенностей произведений, в частности, как части мировой литературы, мирового культурно-исторического процесса.

Г. Тукай, создав поэмы «Шурале» и «Водяная ведьма», тем самым сформировал целостную картину мира татарского народа, не чуждой также и башкирской. В мифологии и фольклоре многих тюркских народов, башкир и татар в том числе, мифические персонажи шурале и водяная (ведьма, русалка – Хыу эяхы (Су анасы, Су бабасы), Хыухылу (Су-сылу) получили широкое распространение. В ряду языческих пантеонов этих народов они занимали одно из центральных мест, активно соприкасаясь с жизнью и бытом людей.

Раньше верили, что природа в сознании древнего человека оживлялась, персонифицировалась, каждая местность – лес, луг, поля, рощи, горы, реки, озера и т.д. имели своего хозяина – эйа: урман эйахы, тау эйахе и т.д. Одним из подобных хозяев дремучих лесов, куда не ступала нога человеческая, считался шурале (возможно произошел от шурляу – бояться чего-либо. – *Н.Х.*). В то время как хозяйкой (им являлось существо именно женского пола. – *Н.Х.*) водоема – хыу инахе, дословно «мать воды», Хыу-эйахе – «хозяйка воды». В башкирской мифологии и эпосотворчестве она представлялась как дева вод Хыухылу, соответствующая русской русалке, но без указания на существование рыбьего хвоста. В татарском мифотворчестве Су анасы представляется девой с длинными волосами и большими глазами, без бровей [7, с. 25].

Вследствие мифологического мышления наши предки наделяли их устойчивыми чертами. Многих считали антропоморфными существами. К примеру, бэрей (или бире), как и люди, играли свадьбу, женились между собой, заводили детей. Но нельзя было

их путать с людьми, так как некоторые из них были однополые: албасты, убыр, шурале – носители женского начала; бисура, бире, ен, шайтан – мужского. А юха-оборотень имела способность оборачиваться в любой вид, в том числе в животных [2, с. 12].

Поэтизация этих демонологических образов во многом восполнила и гармонизировала суеверное представление этих народов, их единую картину мира, целостную духовную культуру.

Согласно мифическому верованию башкир и татар шурале обитает в дремучих лесах, при встрече с людьми своими длинными пальцами любит щекотать их до смерти. В народе известны существования своеобразных правил поведения при встрече с подобными демонологическими существами.

У Г. Тукая наблюдается эксплицитная отсылка на эти общепринятые верования и предрассудки:

…Джинн, разбойник или призрак – этот скрюченный урод?
До чего он безобразен, поневоле страх берет!
Нос изогнут наподобье рыболовного крючка,
Руки, ноги – точно сучья, устрашат и смельчака.
Злобно вспыхивая, очи в черных впадинах горят.
Даже днем, не то, что ночью, испугает этот взгляд.
Он похож на человека, очень тонкий и нагой,
Узкий лоб украшен рогом в палец наш величиной.
У него же пол-аршина пальцы на руках кривых, –
Десять пальцев безобразных, острых, длинных и прямых…
…Каждый палец приспособлен, чтобы злее щекотать,
Убиваю человека, заставляя хохотать, –

так обращается он к егету. Однако герой оказался смекалистым и решил проучить лесного духа, согласившись на его предложение «поиграть». В культурологическом аспекте здесь высвечивается интертекстуальная связь с народной сказкой, а именно с традиционным мотивом «за оказанную услугу или выполненное условие следует достижение желаемого». Так, этот культурный феномен можно обнаружить в башкирской народной сказке «Абзелил». В ней при встрече с ен-шайтаном герой также проявляет смекалку и ставит перед лесным чудом ряд условий. Конечно, хитрость срабатывает, и демоническое существо остается ни с чем [1, с. 28–30].

Конечно, Тукай, сам являясь представителем прогрессивного культурного сообщества, мог знать данный сюжет (записать во время своих поездок либо среди татар, либо башкир), и художественно вплести в структуру своей поэмы. В результате, герой поэмы, в лесу встретившись с шурале, также не испытывает никакого страха, также показывает образец сообразительности и хитрости (потому что хорошо знает, как себя вести в подобных случаях):

«…Дух лесной! Давай сначала поработаем вдвоем,
На арбу с тобою вместе мы бревно перенесем.
Щель большую ты заметил на другом конце бревна?
Там держи бревно покрепче, сила вся твоя нужна!..»
…И джигиту не переча, согласился шурале.
Пальцы длинные, прямые положил он в пасть бревна…
…Вот и вылетел со свистом толстый клин, исчез во мгле…
Прищемились и остались в щели пальцы шурале.
(«Шурале»)

В другой башкирской народной сказке об Алдаре также повествуется о том, как в лесу герой избавляется от встретившегося шурале сходным образом: обманом прищемляет его длинные пальцы в расщелине бревна. Также, назвав себя именем Былтыр (т.е прошлый год), уходит восвояси. Так егет, следуя народному обычаю, верованиям, обманув и удручив лесного духа, благополучно избавляется от него и отправляется домой.

Этот сюжет, можно сказать, полностью нашел свою поэтизированную версию в поэме Тукая, что способствовало достижению целостности образа культурной антропологии. Именно поэтому поэма очень близка башкирам, история и духовная культура которого имеет общие корни и вносит вклад в целостность культурного мира тюркских народов и мировой культуры в том числе.

В другой поэме Г. Тукая «Водяная ведьма» центральное место занимает другое демонологическое существо водяная или хозяйка речки – хыухылу, хыу-эйахе. В башкирском народном творчестве существуют эпические сюжеты, связанные с образом хыухылу: «Акбузат», «Заятуляк и Хыу-хылу». Но в них она не выполняет функцию отрицательного героя, зловредной водяной, которая топит своих жертв. Видимо, причина этого кроется в том, что перечисленные эпические произведения были созданы в более ранние времена, еще до широкого внедрения ислама. Согласно языческим верованиям, древний мифический пантеон был возведен в ранг положительных святых, обожествленных каноном древних народов, являлись хранителями рода, его традиций и обычаев, детей и околодомашнего мира.

С внедрением ислама начинается уничтожение основ старой религии и её традиции. О том, что джины, пэри в тюркском мифологическом мире еще до принятия ислама также представлялись носителями положительного характера писал Х.Г. Короглы [3]. Положительные, добрые доселе мифические силы – хозяева гор, рек, лесов, околодомашнего хозяйства также превращались в злых гениев, им навязывались отрицательный характер, демонические черты.

В поэме Г. Тукая «Водяная ведьма» изображается исламизированная мифическуая водяная. Другими словами на данный мифический древний образ в поэме накладывется другой кудьтурный слой – элемент исламской традиции, наиболее близкой мировоззрению современников.

Эпизод, изображающий в поэме Водяную, сидящую на мостках у речки с золотым гребнем в руке, интуитивно отсылает нас на башкирское народное творчество:

...Растрепавшиеся косы чешет ведьма над водой,
И в руке ее сверкает яркий гребень золотой [8, с. 332].
(«Водяная ведьма»)

Так, в эпосе «Заятуляк и Хыухылу» на берегу озера Асылыкуля герой также встретил Хыу-хылу, расчесывающую свои волосы золотым гребнем. Заятуляк, влюбившись в нее, соглашается отправиться за нею на дно озеро и остаться там на всю жизнь. Образы девы вод Су-сылу и земного егета Туляке также известны татарскому народу из дастана «Туляк и Су-сылу». Согласно повериям башкир, хыухылу на рассвете выходит из воды и расчесывает свои волосы золотой расческой [3, с. 58]. Подобные верования и поверья можно встретить и у татарского народа, в мифологическом представлении которого известны верования в существование Хозяйки воды – Су апасы, которая выходила на берег, чтобы расчисать свои длинные волосы [7, с. 25].

В данном случае наблюдается аллюзорная интертекстуальная связь авторской поэмы с эпосом родственных народов. В художественно-эстетическом плане поэт тепло поэтизировал известный ему с детства этот мифический образ, чем дополнил галерею литературных демонологических образов.

Из поэмы также известно, что герой выкрадывает у водяной забытый ею золотой гребень. За что она за ним погналась. И успокоилась лишь тогда, когда вернули назад ее вещицу. Оправданное недовольство водяной ведьмы объясняется в тех же народных верованиях и суеверных представлениях.

А в обрядовом фольклоре башкир, например, есть сведения о том, что цветы кувшинки или лилии, цветущие на воде, считались цветками водяной-хыу-инахе и запрещалось их срывать [2, с. 58]. Следовательно, строгий запрет накладывался на предметы, принадлежащие хыухылу, хыу-эйахе. У татарского народа существовал запрет на нанесение обиды или вредительства по отношению этого демонического существа вообще.

В поэме Водяная ведьма была сильно рассержана на егета, который посмел взять ее вещь.

«Не беги! – кричит бесовка – Погоди, воришка! Стой!
Ты зачем украл мой гребень, чудный гребень золотой?»
(«Водяная ведьма»)

То, что мама героя приняла «волшебный гребень» молча, «Но сама дрожит, боится, а чего – нельзя понять» указывает на тревогу и страх перед содеянным сыном поступком. Ей-то уж известно, что ничего нельзя брать у водяной-хыу-эйасе, касаться ее вещей. Поэтому ночью, когда она вновь пришла за своей гребешком, мать тут же вернула его назад.

Таким образом, в поэмах Г. Тукая «Шурале» и «Водяная ведьма» нашли художественное применение мифические образы, суеверные верования и мифологические воззрения народа. Они представляются не в первозданном виде, а как явления культурной антропологии в их новом прочтении. Демонологические персонажи пережили культурное наслоение, но узнаваемы по сохранившемуся характерному облику и выполняют в произведениях идейно-художественные функции согласно фольклорным традициям. Г. Тукай, как поэт сам уже являясь источником для поэтических вдохновений, может стать объектом изучения в разрезе культурологического исследования. А мифо-фольклорные образы, суеверные верования как культурная антропология нашли художественно-эстетическое переосмысление в его известных поэмах, в которых также выражались духовная культура и мировоззрение народа. Общность историко-культурного наследия и тесная вазимосвязь татар и башкир отразилась в общих мифо-фольклорные традициях, в способах интерпретации и функционирования в культурной жизни общества.

ЛИТЕРАТУРА

1. Башкирское народное творчество: Шуточные сказки и кулямасы / сост. А.М. Сулейманов, вступ. статья Л.Г. Барага и А.М. Сулейманова. Уфа: Башк. кн. изд-во, 1992. 464 с. (на баш. яз.).
2. Башкирское народное творчество: Обрядовый фольклор / сост., авт. предислов. ком. А.М. Сулеймановв, Р.А. Султангареевой. Уфа: Китап, 1995. 557 с. (на баш. яз.).
3. Короглы Х.Г. Взаимосвязи эпоса народов Азии, Ирана и Азербайджана. М.: Наука, 1983. 355 с.
4. Кунафин Г.С. Культура Башкортостана и башкирская литература XIX –начала XX века. Уфа: Китап, 2006. 280 с.
5. Миннуллин К.М. Поэзия и песенное творчество. Казань: Магариф, 1998. 287 с. (на тат. яз.)
6. Миннуллин К.М. Песня сквозь года. Казань: Магариф, 2003. 400 с. (на тат. яз.).
7. Мифология татар. Энциклопедический словарь: в 3-х т. / Сост., авт. предисл. Ф. Урманче. Казань: Магариф, 2008. 1 т. 303 с. (на тат. яз.).
8. Тукай Г. Стихи. Поэмы. Сказки: Избранные / сост. М. Садри, переводы с татар. яз. на рус. яз. С. Липкина. Казань, 1969. 420 с.

## РОЛЬ МУЗЕЯ МАЖИТА ГАФУРИ В СОХРАНЕНИИ КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ НАЧАЛА XX ВЕКА

***Шаяхметова И.Д.***

Мемориальный дом-музей классика башкирской и татарской литературы, первого Народного поэта Башкортостана Мажита Гафури был открыт в 1948 году. Мажит Гафури жил в Республике Башкортостан в период подъема своей творческой деятельности. Пропагандируя творчество известного поэта, прозаика, драматурга и публициста, музей способствует развитию интеллектуального и эмоционального проникновения в прошлое, служит не только целям просвещения и пропаганды знаний, но и становится местом воспитания, приобщения к культурному наследию Республики Башкортостан.

The Memorial Dom-museum of the first national poet of Bashkortostan Mazhit Gafuri – the classic of Bashkir and Tatar literature, was opened in 1948. Mazhit Gafuri lived in the Republic of Bashkortostan in the period of rising career. By promoting the creativity of the famous poet, novelist, playwright and essayist Museum contributes to the development of intellectual and emotional penetration into the past, not only serves to educate and promote the knowledge, but also becomes a place of education of the general culture, and the place of cultural heritage of the Republic of Bashkortostan.

В Уфе есть приветливый зеленый домик, в котором все дышит памятью. Это музей народного поэта Башкортостана Мажита Гафури.

Мемориальный дом-музей первого народного поэта Башкортостана продолжает выполнять задачу сохранения наследия поэта и гражданина республики, поставленную еще в 1940 году Башкирским правительством при принятии решения об организации музея.

Классик башкирской и татарской литератур Мажит Нурганиевич Гафуров (Мажит Гафури) родился 20 июля 1880 г. в деревне Зилим-Караново Стерлитамакского уезда Уфимской губернии (ныне Гафурийский район Республики Башкортостан). Он рано осиротел. В 1898 г. поступил учится в медресе знаменитого Зайнуллы-ишана. Позже М. Гафури учит детей в казахских степях, занимается сбором образцов народного творчества, проявляет в эти годы интерес и к русской литературе. С 1904 г. М. Гафури

учится в Казанском медресе «Мухаммадия». Однако, он в конце 1906 г. возвращается в Уфу и продолжает учебу в знаменитом на весь Восток медресе «Галия». После революции и в 20-е г. удостоен звания «Герой труда». Много усилий М.Гафури прилагает для организации периодической печати автономной Башкирской республики – газет «Наш путь», «Свобода», «Борьба», «Красный путь», «Бедняки Востока», «Урал», «Башкортостан», «Новая деревня».

Уже первыми произведениями М. Гафури завоевал всеобщую любовь народа. Жизнь народа поэт испытал на своих плечах, на своей судьбе испытал всю тяжесть жизни, горе и страдания, выпавшие на трудового человека. У М. Гафури появляются социальные, политические стихи. В первой книге стихов Гафури «Сибирская железная дорога или Положение нации» (1904) противопоставляются прогрессивные веяния времени и отсталости родного народа в духе просветительского реализма, то в рассказе «Жизнь, прошедшая в нищете» отчетливо выражена классовая позиция автора, критика старого мира. Этот рассказ знаменателен и введением в мир литературы неизвестного до этого времени героя – деревенскую бедноту.

Поэт создает произведения, достоверно раскрывающие острые противоречия времени, беспощадно критикующие классовое неравенство, всякое угнетение («Я вышел на базар»).

Под влиянием событий 1905 года поэзия М. Гафури обогатилась новым содержанием. В годы революционных потрясений написаны «Аурупа-Азия», «Завет 1906 года 1907 году», «Ответ 1907 года». За эти стихи Гафури попал под надзор полиции, его книги были изъяты из библиотек и магазинов.

Критикой классового неравенства, социальной несправедливости проникнуты и рассказы М. Гафури «Голодный год, или Проданная девушка» (1906), «Дети-сироты» (1907). Правдивостью реалистического изображения характеризуется повесть «Бедняки» (1907). Противоречия времени высвечиваются и в повести М. Гафури «Жизнь Хамита, или Лейла и моя жизнь» (1911), написанная после поражения революции 1905 года.

Известно, что одним из первых обратил внимание на творчество Мажита Гафури великий поэт татарского народа Габдулла Тукай. В статье «О наших стихах», опубликованной в газете «Фикер» («Мысль») в 1907 году, Тукай, не указывая его имени, назвал М. Гафури одним из великих поэтов, появившихся на литературной арене после 17 октября 1906 года и продолжающих традиции Акмуллы, оставившего след в поэзии трех братских народов – башкирского, татарского и казахского.

Несколько позже, в 1911 году, в астраханской газете «Идель» Тукай выступил с рецензией на повесть М. Гафури «Жизнь Хамита», в которой он увидел реалистическое отражение жизни и судьбы национальной интеллигенции того времени.

Вершиной их творческой дружбы явилась встреча двух поэтов весной 1912 года в Уфе. Безнадежно больной Тукай приезжал в Уфу за год своей безвременной кончины, в первый и в последний раз. С глубоким горем пережил кончину собрата по перу Гафури и написал стихотворение «На смерть Тукая» (1913). Спустя годы известный уфимский художник Габдулла Мустафин создал картину «Встреча двух поэтов» (1948).

После Февральской революции 1917 г. Гафури написал «Утро свободы», «Не бойтесь», «Долой войну», «Дракон» и другие стихи, в которых выражалось активное отношение к событиям в стране. М.Гафури пишет реалистические повести, стихи и поэмы, пьесы («Горячее сердце» (1918), «Красные гроздья» (1925). О широте изобразительных средств свидетельствуют и его лирические произведения, воспевающие природу («Луч», «Вышел я в поле»), оды, прославляющие любовь, красоту, жизненную гармонию («Увядший цветок», «Странно ли?», «Я пьян»). Стихотворение «Красное знамя» (1917), опубликованное в Уфе в газете «Ирек» в апреле 1917 года, по праву можно называть большим поэтическим явлением не только в масштабах башкирской и татарской литератур, но и всей нашей многонациональной страны.

В двадцатые годы XX в. определилось основное направление в творчестве Гафури – реалистическое. Программными произведениями, утверждавшими реалистические принципы поэта, стали стихи «Вырванные страницы», «Песни неба» (1923).

В середине 20-х гг. в творчестве Гафури усилились гражданские мотивы, большое место заняла политическая лирика («Траурные мелодии», «Он навсегда в нашей памяти»).

Во второй половине 20-х гг. и в начале 30-х гг. Гафури создал ряд повестей «Черноликие» (1927), «Ступени жизни» (1928), «На золотых приисках поэта» (1930), закладывающие основы башкирской прозы советского периода и оказавшее огромное влияние на первых башкирских романистов.

Драма М. Гафури «Красная звезда» (1925) была первым в башкирской драматургии произведением, показавшим образы крестьян в годы гражданской войны. В 1928–1929 гг. М. Гафури пишет либретто оперы «Труженик», оказавшее влияние на развитие национальной музыкальной драматургии.

Публицистика Мажита Гафури отличалась широтой взгляда и умением поднять злободневные проблемы.

**Мажит Гафури** проявил свой талант почти во всех жанрах литературы, оставив ценное творческое наследие. Творчество Мажита Гафури, как творчество каждого большого художника, отличается богатством и разнообразием жанров. В его произведениях слышится голос поэта-гражданина, борца, в них звучит и пленительная, чарующая глубиной чувств лирика любви.

Тридцать лет продолжалась творческая работа Мажита Гафури. По его стихотворениям, повестям, поэмам и рассказам можно было бы составить социально-нравственную биографию, историю потрясений и возвышений его Родины. Ни одно событие не осталось вне интересов и волнений писателя. Когда началась формироваться башкирская советская литература, поэт оказался в центре творческого процесса.

Имя Мажита Гафури присвоено району Башкортостана, в котором поэт родился и провел детские годы. Его имя носят парк культуры и отдыха, Башкирский государственный академический театр драмы. Неотъемлемой частью нашего города стал памятник Мажиту Гафури перед зданием театра, носящего его имя. Пятиметровая скульптура создана народным художником СССР, лауреатом Ленинской премии Львом Кербелем и архитектором Львом Хихлухой, создан музей на малой родине поэта в деревне Зилим-Караново.

Мемориальный дом-музей народного поэта Башкортостана Мажита Гафури в Уфе был одним из первых литературных музеев России, организованных после Октябрьской революции.

Летом 1923 года отмечалось 20-летие литературной деятельности М. Гафури. Решением Башкирского Центрального Исполнительного Комитета Мажиту Гафури за выдающиеся заслуги в деле развития башкирской и татарской литературы было присвоено почетное звание народного поэта Башкортостана. И тогда же правительством был подарен дом, где поэт жил 11 лет в 1923–1934 гг. Это был большой дом с подвалом, который состоял из восьми комнат, с четырнадцатью окнами и семью отопительными печами.

В январе 1948 года в этом доме был открыт музей. В 1953 году дом Гафури получил статус Мемориального дома-музея. Здание музея является памятником архитектуры XIX века. Музей, созданный первоначально для хранения, изучения и показа экспонатов из жизни и творчества первого народного поэта Башкортостана Мажита Гафури, постепенно приобрел статус хранилища социальной памяти.

Сегодня посетителям открыты шесть залов. В гостиной, спальне и рабочем кабинете – восстановлена обстановка квартиры поэта, детали интерьера дома начала XX века. Основная экспозиция рассказывает о жизни и творчестве народного поэта Башкортостана Мажита Гафури. В фондах музея хранятся мемориальные вещи, рукописи и документы, принадлежавшие Мажиту Гафури.

В этом доме Мажит Гафури написал драму «Красная звезда (1925), повести «Черноликие» (1927), «Ступени жизни» (1928), либретто к опере «Труженик» по мотивам своей одноименной поэмы (1928–1929), повесть «На золотых приисках поэта» (1930).

Бесценные реликвии дома-музея помогают представить Мажита Гафури не только как поэта, но и как замечательного человека – отца, мужа, друга.

В этом доме каждый экспонат связан с моментами жизни и творчества поэта. Например, пианино, подаренное в 1923 году Народным комиссариатом просвещения, рассказало бы о многом. В доме часто звучали музыка, песни. Клавиш инструмента касались руки Газиза Альмухаметова, Султана Габаши, Загидуллы Яруллина, Салиха Сайдашева, вдохновляя поэта. Мажит Гафури любил музыку, народные песни и сам хорошо пел. На пианино хорошо играли жена поэта Зухра-ханум и сын Анвер.

Часто в этом доме бывали известные писатели, поэты А. Тагиров, Д. Юлтый, Ш. Худайбердин, Б. Ишемгул, С. Кудаш, Г. Гумер, Г. Ибрагимов, Ш. Камал, молодые писатели и поэты С. Кулибай, Г. Амири, М. Тажи, Г. Салям, С. Агиш. Дом превращался в литературную гостиную, они читали свои новые произведения, внимательно прислушивались к советам Гафури.

Мемориальный дом-музей Мажита Гафури — является филиалом Государственного бюджетного учреждения культуры и искусства Национальный литературный музей Республики Башкортостан. Сотрудники музея продолжают вести собирательскую работу, всеми формами своей деятельности способствуют пропаганде наследия основоположника башкирской литературы. Дом-музей является основным хранилищем духовного и культурного достояния народов Башкортостана и играет важную роль в культурной жизни республики.

В музее функционирует отдельный выставочный зал, в котором периодически организовываются выставки об известных личностях в области литературы и искусства, литературно-музыкальные вечера, различные конкурсы и викторины.

Большим событием прошлого года стало открытие виртуального центра Всероссийского музея А.С. Пушкина в Мемориальном доме-музее Мажита Гафури. Данный проект реализован в рамках подписанного соглашения о сотрудничестве между Всероссийским музеем А.С. Пушкина и Национальным литературным музеем Республики Башкортостан. Из фондов Всероссийского музея А.С. Пушкина представлена выставка «Путешествие поэта», а также состоялась презентация виртуального центра и медиаресурсов.

Широкий общественный резонанс вызвал Республиканский Форум литературных музеев «Литературные музеи: проблемы, задачи, перспективы» состоявшийся на базе Национального литературного музея РБ, в Мемориальном доме-музее М. Гафури. На Форуме обсуждались вопросы о роли литературных музеев в сохранении культурного наследия народов Республики Башкортостан и их проблемы, были заслушаны доклады и подведены итоги республиканского конкурса «Мой музей».

Сотрудники музея участвуют в конференциях и форумах (Первый Международный фестиваль молодых тюркоязычных писателей, открытые городские Гафурийские чтения «Дети Уфы – Мажиту Гафури», Международная научно-практическая конференция «Литература и художественная культура тюркских народов в контексте Восток-Запад» (Казань), VII литературный фестиваль «Голоса молодых» (Уфа).

Музей практикует неординарные методы и формы музейной работы (открытие выставок музея-заповедника «Древняя Уфа» «Городище Уфа – II: украшения и предметы быта». Экспозиция посвящена украшениям и предметам быта жителей средневекового города. Они получены в ходе раскопок памятника археологии федерального значения «Городище Уфа-II»; третьей передвижной выставки рукотворных кукол и игрушек «Всюду ангелы» Благотворительного фонда «Мирас» и тд) .

Основными формами работы в музее являются экскурсии и лекции, используются и современные методы работы с посетителями-инвалидами: тактильные выставки, музейные игры, разнообразные музейные праздники. Детство Халита Гафури, внука народного поэта Башкортостана Мажита Гафури прошло в этом доме. Уважаемым и постоянным гостем Мемориального дома-музея был Халит Анварович – инвалид I группы по зрению. Он с удовольствием посещал культурные мероприятия музея. Сотрудники музея читают лекции и проводят мероприятия для незрячих детей. Частыми гостями музея бывают дети из малообеспеченных семей, ветераны, отдыхающие детских оздоровительных лагерей, воспитанники объединений детских, подростковых клубов и молодежных центров г. Уфы, дети из коррекционных школ-интернатов.

Мемориальный дом-музей М. Гафури проводит многочисленные благотворительные акции для привлечения посетителей льготных категорий. Разрабатываются экскурсии и лекции (Разработка тактильных лекций о писателях), занятия для разных групп населения и льготных категорий.

В 2015 году республика торжественно отмечала 135-летие со дня рождения первого народного поэта Башкортостана Мажита Гафури (1880–1934).

Мероприятия были организованы Министерством культуры РБ и Национальным литературным музеем РБ. Торжества начались перед памятником М. Гафури у БГАДТ им. М. Гафури. Состоялось возложение цветов к могиле поэта.

В формате литературно-музыкального вечера торжества продолжились в Мемориальном доме-музее Мажита Гафури. Перед собравшимися зрителями, учащимися, студентами выступили известные поэты, земляки поэта – гафурийцы. Учащиеся инсценировали басню М. Гафури «Бык и Волк». Прозвучала ария Нигмата из оперы «Эшсе» М. Гафури. Были подведены итоги викторины «Кто лучше знает поэта?», организованной Республиканской общественно-политической газетой «Башкортостан» и Национальным литературным музеем РБ. В заключение вечера состоялся поэтический флешмоб: все присутствующие на празднике одновременно прочитали стихотворение М. Гафури «Я и мой народ».

Таким образом, современный музей первого народного поэта Башкортостана Мажита Гафури выступает преобразователем и транслятором духовных и материальных ценностей, проецируя сохраненные ценности в будущее, воспитывая новые поколения, реализуя единство прошлого, настоящего и будущего в истории человечества.

Жизнь поэта продолжается, пока жива память о нем.

## «НУР» ГАЗЕТАСЫ ҺӘМ ТУКАЙ

***Шәйхелисламов З.Р.***

В статье приводятся краткие сведения о первой татарской газете «Нур», издававшийся в С.-Петербурге, и освещается взаимоотношение газеты с Тукаем.

The article provides a brief information about the first Tatar newspaper "Nur" which had been publishing in St. Petersburg and highlights the newspapers` relationship with Tukay.

«Нур», 1905 елның 2 сентябреннән 1914 елның 22 июненә кадәр С.-Петербургта чыккан беренче атналык әдәби, иҗтимагый-сәяси газета. Нашире һәм мөхәррире ахун Гатаулла Баязитов (1846–1911), соңыннан аның улы Мөхәммәтсафа Баязитов (1885–1937) була.Үз заманында дәүләт хезмәтендә коллежский асессор булган,тышкы эшләр министрлыгының тәрҗемәчесе(драгоман) вазифасын үтәгән, 22 ел буена «хакимияткә турылык белән» хезмәт иткән, бай тормыш юлы үткән, укымышлы, тәҗрибәле Гатаулла хәзрәт газетада үз чорының актуаль мәсьәләләрен күтәрә, татар халкын милли-патриотик, дини, мәгърифәт рухында тәрбияләргә тырыша. Газета Гатаулла Баязитов акчасына чыгарылган. Аның әүвәлге саннары Ильяс мирза Бораганский ширкәтенең басмаханәсендә, аннары (1906 елның 29 мартыннан) үзенең шәхси типографиясендә нәшер ителә. «Нур» халыкның иҗтимагый аңын уятырга, күзен ачарга, яңалыкка йөз белән борылырга өнди. Зыялыларның, имамнарның халык алдындагы бурычларын билгели. Милли бердәмлек,килешү, хезмәттәшлек идеяләрен алга сөрә. Тукай татар телендә иң беренче газета дөньяга чыгуына куанып, «Шигырь» («Шималь яктан...») исемле мәдхиясен яза (1905, 6 дек.). Шушы уңайдан «Нур» газетасы мөхәрриренә хат та юллый. Эчтәлеге түбәндәгечә: «Шәһри Петербургда мөхәррире «Нур» әфәнде хәзрәтләренә! Безем шу ашагыдагы әбъяте гаҗизанәмези косурына бакмаярак, җаридәңезен почмагына сыгдырсаңыз, кәмале һиммәтеңездән гад идәр идем» (хәзерге телгә күчерсәк «Петербург шәһәрендә «Нур» мөхәррире әфәнде хәзрәтләренә! Безнең шул түбәндәге зәгыйфь бәетләребезне, җитешсезлекләренә карамастан, газетагызның бер почмагына сыйдырсагыз, камил тырышуыгыздан санар идем). «Шигыр»нең азагына «Үтенеп: Уральскидә мәдрәсәи «Мотыйгыя» шәкерте Габдулла Тукаев, тарих 15 октябрь, 1905 сәнә» дип куелган [1]. Мәдхия «Нур»ның 1905 елгы 6 декабрь (16 нчы) санында басыла. Газета да яшь шагыйрьгә хәерхаһлык күрсәтә. Аның «Пар ат» шигырен «Фикер» газетасыннан алып, «халык телендә язылган әдәбиятыбызны баетучы уңышлы шигырь» дип укучыларга тәкъдим итә (1907, 6 май). «Әлислах»та (1908, 13 окт.) басылган «Бәйрәм бүген» шигырен «Габдулла Тукаев диваны»ннан күчереп баса (1909, 29 ноябрь). Газетаның беренче саннарында ук Русия Дәүләт Думасына сайлаулар темасы күтәрелә, сәяси хокуклардан тулысынча файдаланырга чакыру яңгырый. Оренбургтагы Диния нәзарәтен таркатып, җирле вак мөфтиятләр ясауга каршы булган мөселманнарның протест хатларын бастыра. Мөхәррир цензураның беренче татар газетасына нинди күз белән караячагын, әлбәттә, бик яхшы белгән. Шуңа күрә газетада мәгариф белән мәдәният кысаларыннан әлегә артык читкә тайпылуны

мәгъкуль күрмәгән. Г. Баязитов фәлсәфәсе нигезендә мәгърифәткә, камиллеккә, прогресска омтылыш, үзара аңлашып гамәл кылу, тигезлеккә кешелеклелек принципларын үстерү аша бару идеясе ята. XX йөз башының яшь кайнар башлары, шул исәптән Тукай да аның карашларын кабул итмиләр.Аны искелектә, хакимияткә ярашуда, сыйнфый көрәш идеясенә игътибар итмәүдә гаеплиләр. Тукай бу газетаның еш кына патша хөкүмәте карарларын, дини эчтәлектәге мәкаләләр бастыруын ошатмыйча, тәнкыйтьли, көлә башлый. Мәсәлән, «Авыл җырлары (беренче көлтә)»дә (1908): «Баязитов «Нур» гәзитен ничек язып өлгертә?» – дип чәнчеп ала. «Хәзерге заманча сөйләшүләр» (1908) сатирасында аның өзеклек белән тәртипсез чыгуына «Нур»мыни ул чыкмаска?» дип төрттерә. Тукайның Баязитов «Нур»ын чеметкән, мөхәрриренә карата әйтелгән башка чәнечкеле сүзләре дә бар. Әмма Гатаулла хәзрәт тә, аның варислары да, газета хезмәткәрләре дә аннан үч алмыйлар, шагыйрьгә ихтирам саклыйлар. Тукай, 1912 елда Петербургка килгәч, Сафа Баязитов акчасына кунакханәгә (аерым номерга) урнаштырыла. Аның кушуы буенча, «Нур»ның хезмәткәре К. Бәкер, вакытлыча эшеннән азат ителеп, фәкать шагыйрьне тиешенчә кунак итү мәсьәләсе белән шөгыльләнергә тиеш була. Тукай «Нур» редакциясенә көн саен килеп йөри. Анда ул элекке иптәшләре К. Бәкер, К. Сәгыйть, Ш. Мөхәммәдъяровлар белән очраша. Сафа Баязитовның чакыруы буенча аның өенә кунакка бара. Анда граммофоннан Пушкин, Лермонтов әсәрләрен, «Евгений Онегин» операсыннан арияләр яратып тыңлый. «Нур» идарәсендә утырганда яңа килгән газеталарны укып таныша, алардан аерым кызык мәкаләләрне кисеп алып тиз генә газетаның яңа санын хәзерләү юлын өйрәтә. Үзе белән килгән моңарчы басылмаган берничә шигыре булса да, шуларның берсен басарга уйлагач, дингә тел тидергәнгә, «Нур»да басарга җөрьәт итмиләр. Тукай идарәгә килгән шигырьләрне караштырып, Тозтүбәдән бер мөгаллимнең шигырен бераз төзәтеп газетада бастырырга киңәш бирә. «Нур» газетасы мөхәррире С. Баязитовка «Йолдыз»да Садыйк мулла Иманкуловның Муса Бигиевкә каршы язган «Ифрат» исемле мәкаләсен алып, «Нур»да күчереп басарга тәкъдим итә. Хәтта кереш сүзне дә үзе язып бирә. Тукайның Петербургтан китәсе билгеле булгач, иртән Сафа әфәнде Баязитовның квартирында аш мәҗлесе ясала. 6 май төнендә аның ук акчасына өченче класстан плацкарт белән билет алынып, К. Бәкер Тукайны Мәскәүгә кадәр озата китә. Озатучылар арасында дуслары, зыялы мөгаллимнәр, байлар, мөселман приказчиклары белән бергә имамнардан «Нур» газетасы мөхәррире Сафа ахун Баязитов, Лотфый әфәнде Исхаков та булалар [4]. Алга таба да шагыйрьнең язмышына «Нур» битараф калмый. Аның авыруы, Казаннан китүенә көенеп, «Габдулла Тукаев» дигән хәбәр бастыра (1912, 25 окт.). Шагыйрьнең үлеме уңае белән, 1913 елгы 12 апрель санының бер битен тулаем диярлек Тукай вафатына багышлый [5]. 21 апрельдәге санда да шагыйрь рухына багышланган материалларга ярты бит урын бирелә. «Нур» мәрхүм Тукайның якты истәлегенә 1914 елгы апрель саннарын да багышларга онытмый. Язмалар шагыйрьне югалтуның татар милләте өчен зур фаҗига икәненә кат-кат басым ясый. «Нур»ның милләт тарихында, мәдәни үсешендә үз урыны бар. Т.ның исеме дә аның белән тыгыз бәйләнгән икәнлеге ачык күренеп тора.

ӘДӘБИЯТ


1. Алты томлы Академик басма. Т. I. Б.329.
2. Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. Казан, 1926. Б. 5.
3. Гайнуллин М. Татарская литература и публицистика начала XX века. Казань, 1983. С. 12–13.
4. Тукай турында истәлекләр. К., 1986. Б.180–200.
5. Әмирхан Р. Милли матбугатыбыз карлыгачы // Татарстан. 1996. № 9. Б. 72–81.
6. Нуруллин И.З. (11). Б.259–267.
7. Габдулла Тукай: Тормыш һәм иҗат елъязмасы. Казан, 2003. Б. 215–220.
8. Вәлиев М. Баязитов «Нур» гәзитен ничек язып өлгертә // Казан утлары. 2015. № 10. Б. 153–156.


## Г. ТУКАЙНЫҢ ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫ ТУРЫНДА УЙЛАНУЛАРЫ


***Шәкүрова М.М.***



Наследие Г. Тукая всегда находилось в центре внимания татарских писателей и поэтов. В первое десятилетие XX в., особенно после выступления Габдуллы Тукая в Казани с лекцией о народной поэзии, где он призывал беречь драгоценное народное наследие прошлого, среди татарской интеллигенции оживляется интерес к национальному фольклору, особенно к народным

песням. «Народ велик и силен, он жизнерадостен и музыкален, он писатель и поэт, – отметил Тукай. – И потому, что народные песни дороже яхонтов и бриллиантов, надо уделить им пристальное внимание, чтобы не потерять их, надо приложить старание».

Heritage G.Tukaya has always been the focus of Tatar writers and poets. In the first decade of XX century., Especially after the speech of Gabdulla Tukay in Kazan with a lecture on folk poetry, which he called to protect valuable national heritage of the past, among the Tatar intelligentsia enlivened interest in national folklore, especially folk songs. "The people are great and strong, it is resilient and musical, he was a writer and poet – said Tukay. – And because folk songs expensive rubies and diamonds, it is necessary to pay attention to them, so as not to lose them, you have to make the effort.

1905 елда булган инкыйлаб җилләре нәтиҗәсендә Россия империясенең төрле төбәкләрендә (Казан, Уфа, Оренбург, Мәскәү, Петербург һ.б.) татар телендә газета-журналлар чыга башлый («Тәрбияи этфаль» («Балалар тәрбиясе». Мәскәү), «Тәрбия» (Казан), «Мәктәп» (Казан), «Мөгаллим» (Оренбург) журналлары һ.б.). 1913–14 елларда чыккан «Мәктәп» журналы түбәндәге мәсьәләләрне яктырта: уку-укыту һәм тәрбиягә караган хәбәрләр; мәктәп фәннәре һәм аларның программалары; хатын-кыз мәгарифе; чит илләрдә мәгариф; әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләре, тел белеме; фәнни, тарихи һәм икътисади мәкаләләр; мәктәп-мәдрәсә тарихлары һ.б. [6, б. 5]. Татар зыялыларыннан Г. Баттал, Һ. Атласи, Һ. Максуди, Г. Алпаров, Г. Ибраһимов, Н. Думавый, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан. Г. Мостафа һ.б. мәгариф мәсьәләләренә караган мәкаләләрен атап үтәсе килә. Бу елларда шәкертләр уку-укыту программасына, надан хәлфә һәм ишаннарга ризасызлык белдерәләр, мәдрәсәләрне ташлап китәләр, фәннәрне киңрәк өйрәнүне таләп итәләр [3, б. 56].

Г. Тукай кадими укыту системасын тәнкыйтьли, бердәм, мәгърифәтле булырга чакыра («Туган тел», «Дустларга бер сүз», «Шәкерт, яки бер очрашу», «И каләм», «Беренче мәртәбә мәктәпкә бару», «Әлифба» һ.б.). Шагыйрь «Исемдә калганнар» дигән автобиографик әсәрендә Кырлай авылында башта бер ел кызлар белән бергә абыстайга дини китаплардан «Иман шарты»н өйрәнергә йөрүе, аннары икенче елны мәдрәсәгә баруы турында болай дип яза: «Мин мәдрәсәдә, «Һәфтияк» иҗеген вә сүрәсен бик тиз белгәч, «Бәдәвам», «Кисекбаш»ларга кердем. Үземнең сабагымны тиз белеп, миңа күп вакыт тик торырга туры килгәнгә, миңа өйрәтергә үземнән наданрак балаларны да бирә башладылар» [1, б. 21].

Г. Тукайның укыту-тәрбия өлкәсендәге карашлары, методик уйланулары барлыкка килә («Яңа кыйраәт» (1909), «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» (1910) һ.б.) [2, б. 37].

Г. Тукай «Халык әдәбияты» исемле лекциясендә укучыга никадәр бай мәгълүмат бирә: кечкенәдән җырларга яраткан, хисле, моңлы шагыйрь күңелендә йөрткән халык җырлары, аларның тарихы, халык әдәбияты турында бик кызыклы материал урнаштыра. Татар теле дәресләрендә, бәйләнешле сөйләм үстерү сәгатьләрендә әлеге лекциянең стилен, сүз байлыгын тикшерергә, күпме яңа төшенчәләрне ачыкларга була. Нәкъ моннан 106 ел элек 1910 елның 15 нче апрелендә Казанда «Шәрыкъ клубы»нда Г. Тукай үзенең «Халык әдәбияты» дигән лекциясен укый. Шушы елны ул «Халык әдәбияты»н аерым китап итеп бастыра. «Нәрсә соң ул халык әдәбияты?» дигән сорауга болай дип җавап бирә: «*Халык әдәбияты, халык шигырьләре дип инша итүче шагыйре беленмәгән яки уйлап чыгаручысы вә әүвәл кем тарафыннан сөйләнгәнлеге мәгълүм булмаган хикәя вә масалларга әйтеләдер*» (189 б.).

Г. Тукай үзе ишеткән халык җырларыннан «Тәфкилев», «Ашказар», «Сак-Сок», «Касимский», «Ибырай», «Җизнәкәй», «Башмак» көйләренең тарихын бик тәфсилле итеп, гади итеп сөйләп бирә. Сөйләм теленә, белгәнебезчә, кыскалык һәм фикерне төгәл итеп бирү хас. Теле бик үтемле, бай, мәкаль-әйтемнәр (*Уеннан уймак чыгара; Җырның җыртыгы юк; Эт симерсә, иясен тешләр; Керпе үз баласын йомшагым һәм аю үз баласын аппагым дип әйтә, ди (соңгысы гарәп халык мәкале)*), фразеологик әйтелмәләрдән (*колаклар тору, салкын кан белән тыңлау, аркаларга кан йөгерү* һ.б.) оста файдалана, кушма җөмләләр белән күбрәк эш итә яки аерымланган рәвеш хәлле гади җөмләләр куллана (*Кызлар төрлечә көйләр чыгарып карыйлар, ләкин берсе дә түрә кызының күңеленә ошамыйлар* (188 б.); *Бу җырчы кызлардан бернәрсә дә чыкмагач, түрә кызы, бертөрле рух вә илһам белән рухланып, хәзерге «Ашказар» көен җырлап җибәрә* (188 б.) һ.б.).

«Халык әдәбияты»ның төп лексикасын төрки-татар чыгышлы сүзләр тәшкил итә, шулай да алынмалар да бар, аларның күбесе гарәп чыгышлы сүзләр (*халык, әүвәл, мәсьәлә, вакыт, хәтер, гаҗәеп* һ.б.), икенче урында – рус сүзләре (*сумала, келәт, гәзитә, мужик, сука, гармун, гуләйт* һ.б.), аннары – фарсы (*өмет*, *хуш*, *һәм*, *дустанә, палас* һ.б.), шулай ук латин (*оригиналь, форма*), грек (*оркестр*), француз (*пьеса*), итальян (*мандолина*) һәм төрек (*әфәнде*) сүзләре. Аерым бер сүзләрнең фонетик тышчасына игътибар итү зарури: *бабаларымыз* (бабаларыбыз), *үземезнеке* (үзебезнеке), *укыдыгым* (укыдым), *уңгайлап* (уңайлап), *яңлышу* (ялгышу). Болар – искергән (архаиклашкан) формалар, хәзерге татар әдәби телендә алар актив түгел. Диалекталь сүзләр дә очрый: *аты* ***шапырма*** *тиргә баткан* (шабыр тиргә бату), *дөньяда язу сәнгате булмаган* ***чактук*** (чакта ук), ***җыру***, бер кадак ***симәнкә***, кирәк ***дия*** сүзне бетердем һ.б.

Г. Тукай төгәл итеп халык җырларына да билгеләмә бирә: «*Халык җырлары – безнең бабаларымыз тарафыннан калдырылган иң кадерле вә иң бәһале бер мирастыр*» (192 б.). Бередә укучы «Халык җыры нәрсә ул? Ул нинди булырга тиеш?» дигән сорауларга төгәл җавап таба ала:

1) халык җыры күңелгә хуш килергә тиеш;

2) аның үз көе, үз вәзене (шигырь үлчәве, ритмы) була;

3) аны салкын кан белән тыңлап булмый, ул дулкынландыра, хисләндерә;

4) халык җырларында хис, мәгънә була;

5) халык җырларын тыңлаганда, аркаларга кан йөгерергә тиеш (хис кешегә шул дәрәҗәдә тәэсир итә!);

5) халык җырларының беренче ике юлында юк кына сүзләр әйтелә, аннары соңгы икесендә *мәгънәле, көтеп алынган сүз* кулланыла;

6) халык җырлары җәүһәр вә якутлардан да кыйммәтле булганга, аларга әһәмият бирергә, аларны югалтмаска кирәк;

7) «...халык җырлары – халкымыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә рәушан көзгеседер» (192 б.);

8) халык җырлары – «сихерле көзге», «...сихерле көзгедән каралса, ягъни халык җырларын дикъкать белән укылса, халыкның күңелендә нәрсәләр сакланганын барчасын күреп буладыр»(194 б.);

9) җыр чын-чын халык халәте рухиясен күрсәтә; алар чын үзебезнеке булырга тиеш;

10) халык үз хиссиятен үзе мәйданга чыгара (җыр-бәетләр, кара-каршы җырлашулар һ.б.), җырлый бирә. Халык җырлары (җитешсезлекләре белән) безгә сөекле булырга тиеш;

11) «Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятымызга, бер дә шөбһәсез, нигез булачактыр» (195 б.).

Җыр халык рухынча язылырга тиеш. Г. Тукай «*рух*» сүзен күп мәртәбәләр кабатлый: *рух вә илһам* (188 б.), *рухлану* (188 б.), *халык халәте рухиясе* (192 б.) һ.б. Чын халык рухын бары тик халык җырында гына табып була, ди ул. Шагыйрь һәр халыкның үз моңы, үз көе булуын да ассызыклый: «*...һәрбер кош үз тавышы белән ләззәтләнә*» (195 б.). «*Безнең бер көйне руслар арасында бик яхшы тавышлы саналган бер кешедән җырлатсаң, әллә ничек, шуның безнең күңелгә охшарына* (ошау. – *М.Ш.*) *күңел ышанмый. Көемезнең алтынын кояр шикелле тоела*», – ди Г. Тукай [1, 202]. Бу гына да түгел, халык җырын рус теленә тәрҗемә дә итеп күрсәтә:

| | |
|---|---|
| Калфагым бар, шәлем юк, | У меня колпак есть, но нет шали, |
| Шәл алдырмый хәлем юк; | Необходимо мне купить шаль. |
| Синнән башка сөйгәнем юк, | По мне нет любимой, кроме тебя, |
| Сине алмый хәлем юк. | Необходимо мне жениться на тебе |

(195 б.).

Чыннан да тәрҗемәдә телнең бөтен нечкәлекләрен биреп бетереп булмый, ул коры. кытыршы чыга.

Г. Тукай халык җырларын башкару серләре белән дә уртаклаша: *калын тавыш белән, көчләнеп җырламаска кирәк, авызны бик зур ачып җырларга ярамый, тавышның йомшак булуы кирәк, бераз уен коралы авазына охшатып башкарырга, иреннәрне мөмкин кадәр аз ачарга кирәк (каты кәгазь сыярлык кына итеп)*. Әлеге лекция бай, фәнни, шул ук вакытта халыкчан булуы белән аерылып тора. Шагыйрьнең «*җыр яра-*

*туым аркасында туган телгә сөю туды*» дигән фикерләре белән бик килешәсе килә. Дөрестән дә, халык телен, халык рухын, халык моңын җырда табып булганны укучыга кечкенәдән сеңдерергә кирәк [5, б. 216]. Г. Тукай сүзләре белән әйткәндә, «бала янында күбрәк булырга, аның берлә шөгыльләнергә, йөрергә, бигрәк тә аның белән күбрәк сөйләшергә» кирәк. Бүгенге көн татар теле дәреслекләрендә тәкъдим ителгән текстларда, күнегү-биремнәрдә Г. Тукайның «Халык әдәбияты» дигән лекциясеннән укучыга никадәр бай мәгълүмат биреп булыр иде: халык җырлары, аларның тарихы, халык әдәбияты турындагы материалны тел гыйлеменең теләсә кайсы бүлеге белән бәйләп өйрәтергә мөмкин.

ӘДӘБИЯТ

1. Габдулла Тукай Әсәрләр биш томда / төз. Р. Гайнанов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986.
2. Заһидуллина Д.Ф. Урта мәктәптә татар телен укыту методикасы: Метод. кулланма. Казан: Мәгариф, 2000.
3. Шәкүрова М.М. Татар телен укыту методикасының фәнни мирасы (XVIII гасыр ахыры – XX гасыр). Казан: Ихлас, 2012. 144 б.
4. Шәкүрова М.М. Татар халык әкиятләре һәм бәетләренең лексик-семантик һәм стилистик үзенчәлекләре // Фәнни Татарстан. 2014. № 3. Б. 32–40.
5. Шакурова М.М. Лингвистический анализ фольклорного текста (на материале сказок и баитов) // Филология и культура. Philology and culture. 2014. № 4 (38)/ С. 216–220.
6. XX йөз башы татар тәгълим-тәрбия журналларының библиографик күрсәткече / төз. Р.Ф. Мәрданов һ.б. Казан: Милли китап, 1997.

## СИРИННЕҢ ТУКАЙГА ШИГЪРИ ҖАВАБЫ

***Шәрипов Ә.М.***

В статье в идейно-тематическом плане сопоставляются стихотворение Г. Тукая «Молодежь» со стихотворением Сирина «Наша молодежь». Показывается разница между пафосами этих произведений: в стихотворении Тукая (1910 г.), написанном в условиях реакции после революции 1905–1907 гг., критикуются слабость и безволие современной поэту молодежи, стихотворение же Сирина, написанное в период становления советского государства (1923 г.), пронизано твердой верой в силу и способности молодежи, неутомимо трудящейся для построения нового общества. Отмечается, что такое убеждение Сирина к 1930–1933 годам сменяется его негативным отношением к несправедливостям советского строя.

The article engages with the idea and subject matter collating of *The Youth* a poem by G. Tukay and *Our Youth* a poem by Sirin. The author demonstrates the pathos difference of these works: Tukay's poem (1910) written within the reactionaries running after 1905–1907 revolution criticizes the weakness and unwillingness of the poet's contemporary youth, while the poem by Sirin, written within the soviet state development (1923) is marked by the firm confidence in the youth strength and abilities working hard to build a new society. Sirin's that belief is claimed to be replaced by his negative attitude to unjust soviet government.

Тукайның вафат булуы милләттәшләребез тарафыннан зур югалту буларак кабул ителә. Әлеге хәбәрне татарлар яшәгән төбәкләрдә чыга торган барлык газета-журналлар бастырып чыгара. Кайгыны уртаклашкан язмалар дөнья күрә. Шагыйрьләр үзләренең хис-тойгыларын шигырь юллары белән аңлаталар. Газета-журналларда Тукайга багышланган С. Сүнчәләй шигырьләре, Ш. Фидаиның «Тукай», Ш. Бабичның «Тукай үлгәч», Г. Сөнгатинең «Милләтебезнең сандугачы китте», М.Фәйзинең «Габдулла әфәнде», К. Патииның «Тукайга» исемле һәм тагын Гайнуллин-Чокалый, Я. Кизләви, И. Хәйруллин, Х. Габидов, Р. Ибраһимова һәм башкаларның шигырьләре басылып чыга. Н.М. Гафиятуллина күрсәтүенчә, «шагыйрьгә багышлап, илледән артык шигырь иҗат ителә» [2, с. 36].

Ләкин тормыш дәвам итә, әкренләп еллар уза. Тукайның үлеменә ун ел тулган 1923 ел килеп җитә. Кайгылы булса да, бу датаны әле гарәп хәрефләре белән чыгарыла торган «Татарстан» газетасы да билгеләп үтә. Газетаның 1923 ел, 15 апрель (якшәмбе) саны шушы датага багышланган. Анда «Ун ел тулганда» дигән баш мәкалә, Тукайның зур рәсеме бирелгән, шагыйрь Сириннең «Хәзерге яшьләр (Тукайның «Яшьләр»енә ияреп, җавап урынында)» һәм Муса Җәлилнең «Тукай кабердә» дигән шигырьләре басылып чыккан.

Әйтергә кирәк, бер үк газетада бер үк темага Сирин белән Муса Җәлил шигырьләренең янәшә басылып чыгуы очраклы хәл түгел икән. Соңгы вакытта язучы Афзал Шамовның кызы Әлфия Шамова тапкан материаллар буенча, 1923 елда Сирин белән Муса Җәлил рабфакта бергә, бер төркемдә укыганнар. Әлбәттә, араларында ун яшь аерма булса да (Сирин 1896 елда, ә Муса Җәлил 1906 елда туган), бу ике шагыйрь, бер төркемдә укыгач, бер-берсе белән таныш булган һәм үзара аралашып та яшәгәннәрдер, дип уйларга була. Һәм икесе дә әлеге дата уңае белән үзләренең хис-тойгыларын белдергән шигырьләр иҗат иткәннәр.

Тукайдан егерме яшькә кечерәк булган Муса Җәлил «Тукай каберендә»[1] шигырендә үзенең Тукайга булган хөрмәтен:

Кабер!
Сиңа килдем гөлләр белән,
Сәлам белән, изге уй белән. –

дип сурәтли. Яңа тормыш, ирекле, матур җәмгыять төзибез дип рухланган Җәлил остазыТукайга тормышның инде үзгәргәнлеген, үзенең хәзер ирекле, матур, ямьле илдә яшәгәнлеге хакында сөйли:

Әйе. Монда синең өстеңдә дә
Ал чәчәкләр үскән; һәммәсе –
Алар инде матур,
Киң илдә дә –
Хәзер шундый ирек, ямь яши.
Ул илдә дә хәзер шулай ирек,
Шатлык, дуслык туен итәләр.
Барлык эш дуслары бергә җыелып,
Мәңгелек ямь суын эчәләр.

Җәлил Тукайга «Синең яшь йөрәгең алдан сизгән иркен ил язы килде», ди һәм 1920 еллардагы җәмгыять тормышын болай итеп сурәтли:

Син җырлаган бәхет, дус-туганлык,
Син теләгән батыр эш көне,
Синдә булган хаклык, миһербанлык,
Илгә килде хәзер бөтене.

Әсәр ахырында Җәлил тагын бер тапкыр үзенең Тукай каберенә чәчәкләр белән килүен һәм ул чәчәкләрнең Тукайга (Җәлил аны «изге» дип атый) үзеннән сәлам әйтәчәкләрен белдерә:

Кабер!
Куан, синдә менә гөлләр,
Гөлләр белән бизим мин сине.
Бу гөлләрем аңар сәлам сөйләр,
Куандырыр алар изгене.

Тукайның үлеменә ун ел тулган көнне М. Җәлил үзенең Тукайга булган хөрмәтен әнә шулай тасвирлаган..

Ә яшь ягыннан Тукайдан ун гына елга яшьрәк булган Сирин исә үзенең остазына багышланган «Безнең яшьләр» шигырен Тукайның «Яшьләр» әсәренә җавап дип атаган. Бер уйласаң, Сиринне Тукайның чордашы дип тә атарга мөмкин бит. Аларның тормыш юлларында да беркадәр уртаклык бар шикелле: икесе дә мәдрәсәдә укыганнар һәм мәдрәсәдә чакта иҗат итә башлаганнар. Ә әлеге шигырьләренә килгән вакытта, менә гаҗәп: Тукайныкы да, Сиринneke дә бер үк формада, бер үк жанрда – Шәрыкъ әдәбиятларында киң таралганкасыйдә жанрында иҗат ителгән. Ике әсәр дә классик касыйдә жанрына куела торган барлык таләпләргә җавап бирә: икесе дә – аа, ба, ва, га... тәртибендә рифмалашып килә торган икеъюллыклар, ягъни бәетләр белән язылган. Хәтта күләмнәре дә бер үк диярлек – Тукайныкы ун бәеттән торса, Сиринneke тугыз бәеттән тора. Аермалары бары шунда: Тукай шигырендә өметсезлек, яшьләрдә егетлек, кешелек сыйфатларының юклыгына зарлану фикерләре өстенлек итсә, Сирин

[1] Шигырьнең исеме дөрес куелмаган: «Тукай каберендә» түгел, ә «Тукай кабере янында» булырга тиеш иде.

шигырендә киресенчә –әсәр үзәгендә революцион романтика, өр-яңа бәхетле тормыш төзүгә ныклы ышаныч, алган юлдан һичкайчан тайпылмау, ахырга кадәр җиңеп барырга омтылу кебек хис-тойгылар һәм ниятләр сурәтләнә. Хәзер шул шигырьләрне үзара чагыштырып карыйк.

Тукайның «Яшьләр» шигыре 1910 елның 15 июлендә «Ялт-йолт» журналында басылып чыккан. Бу, билгеле булганча, 1905 елгы революциядән соң реакциянең үзенең кара канатын җәйгән чор була. 1906–1908 еллар аралыгында чыгып килгән «Милләт», «Азат», «Өлфәт», «Әхбар», «Ватан хадиме», «Азат халык», «Таң йолдызы», «Таң мәҗмугасы», Тукай яратып эшләгән «Әл-ислах» һәм «Яшен» кебек газета-журналлар ябыла. Илдәге вазгыять үзгәрү сәбәпле, яшьләр дә милләтнең үсеше өчен көрәштән читләшә. Мондый хәлләр Тукайда да төшенкелек, киләчәккә өметсезлек тудыра. «Яшьләр» шигырендә Тукайның нәкъ әнә шундый рухи халәте чагыла да инде.

Шигырьнең беренче юлларында ук Тукай болай ди:

Бара милләт зәгыйфь, абныр-абынмас,
Сүнә яшьләрдә ут кабныр-кабынмас.
Кичә якты вә милли бер күңелдән
Бүген тычкан утыдай нур табылмас.

Ә Сириннең «Безнең яшьләр» шигырендә исә бөтенләй икенче пафос.Тукайдан ун гына яшькә кечерәк булса да, Сирин инде бөтенләй башка җәмгыять кешесе. Тукайның «Яшьләре» язылган дата (1910) белән Сирин шигыре иҗат ителгән дата (1923) арасында бары 13 кенә ел үткән. Әмма инде бөтен ил күләмендә, җәмгыятьтә гаҗәеп зур үзгәрешләр булып узган. Үзенең башлангыч белемен Сирин, Тукай кебек үк, мәдрәсәдә алуына һәм үз гомеренең 21 елын Тукай кебек үк инкыйлабка кадәрге «иске» җәмгыятьтә яшәвенә дә карамастан, 27 яшьлек Сирин (ә Тукай «Яшьләр»не 24 яшендә иҗат иткән) үзен инде бөтенләй башка җәмгыять кешесе итеп хис итә: шул еллардагы пропагандага бирелеп, үзен яңа җәмгыять, бәхетле, ирекле тормыш төзүче итеп исәпли. Шуңа күрә ул, Коммунистлар партиясе идеяләренә ышанып, шул идеаллар белән рухланып үзенең шигырен дә революцион, романтик пафос, Тукай фикерләренә капма-каршы булган фикерләр белән башлап китә:

Йөрәккә ут кабынган, мәңге сүнмәс,
Яна күкрәктә дәртләр, һич суынмас.
Көч алдык, калтырау юк юлыбызда,
Диябез яшьләр: «Бу күкрәк мәңге туңмас!»

Шуннан соң Тукай үз чорындагы яшьләрнең, вак, көндәлек идеаллар белән рухланып, милләт проблемаларын читкә ташлап, акча-байлыкка табынып яшәүләрен тәнкыйтьли; аларның үз юлында тәти уенчык тапкан сабый бала кебек, байлык белән мавыгуларын яза:

Вә кем бар, йөз чөерми милләтеннән,
Көмеш, алтын санәмнәргә[1] табынмас?
Тәти тапса сабый барган юлында,
Йомыш истән чыгар, һич айрылалмас.
Шулай яшьләр дә: юлда күрсә алтын,
Баюдан башкага күңлен дә салмас.

Сирин дә Тукайның фикер сөреше артыннан бара, әмма, Тукай чорындагы яшьләрдән аермалы буларак, «яңа яшьләрнең» алтын-көмешләргә табынмыйча, халыкка хезмәт итүләрен, искелекләрне җимереп, яңа тормыш төзүләрен һәм шул алган юлларыннан читкә тайпылмаячакларын әйтә:

Күңелдә кайный хезмәтләр халыкка,
Чын ир алтын-көмешләргә табынмас.
Җимердек искелекләрнең барын да,
Аларга инде артык кайту булмас.
Ышандык без кызыл көчкә, юл алдык,
Турайдык сафка, нык юл, һич таелмас.

---

[1] Санәм – статуя, сын (акча).

Тукайны хәтта кайбер язучы-шагыйрьләрнең дә, байлыкка алданып, акча эшләү юлына кереп китүләре борчый. Шигырен ул болай дәвам итә:

Сатучылык итә бездә мөхәррир[1],
Әдип исме аңар таглыр-тагылмас.

Монда Тукай үзенең дусты С. Рәмиевны күздә тоткан булса кирәк, дип фараз итәргә мөмкин. Чөнки Әнисә Алиева күрсәтеп үткәнчә, «1909 ел, 14 март. Публицист һәм шагыйрь буларак та хөрмәт иткән якын дусты С. Рәмиев, «Таң йолдызы», «Таң мәҗмугасы» һәм «Әл-ислах» та ябылгач, «Бәянелхак» газетасына хезмәткә керә. Бу хәлне Тукай авыр кичерә, демократик позициядән чигенү дип бәяли. Алар арасында киеренкелек барлыкка килә. Һәм ул матбугатта да чагылыш таба»[1, с. 121].

Тукай үз чорындагы яшьләр күңеленә егетлек, олпатлык, кешелек сыйфатлары салынмаганлыкка зарлана, яшьләрнең үзләренең тарихтагы шанлы һәм данлы бабалары эшчәнлекләренә лаек булган эш-хезмәтләр майтара алмаганлыклары, көчсез булулары турында әйтә:

Яралганмы бу яшьләр күңле әллә
Мөрәүвәт маддәсе[2] яглыр-ягылмас?
Ышанабыз халык көчсезлегенә,
Бабайлар шөһрәтен сагныр-сагынмас.

Ә Сирин Тукайга яңа яшьләр – һәрберсенең күңеленә иман нуры тулган, ярлы ил бәхете өчен көн-төн эшли торган яшьләр образын китереп куя:

Иман күкрәктә һәммәбездә тулган,
Табылмас, безгә көчсезләр тагылмас.
Көрәштә без ныгыйбыз көн дә, көн дә,
Эшлибез ярлы ил бәхте юлында,
Кылыч, балта, чүкеч кулдан салынмас[3].

Тукай үзенең шигырен «Милләт байрагын тотып юлга чыксак та, ерак китә алмадык, егылдык» дигән фикер белән тәмамлый:

Тотып милләт ливасын[4], юлга чыктык,
«Бу куллар мәңге, дип, җиргә салынмас».
Җыгылдык без, икөч чакрым да китми, –
Җегетләр! Бездә көч юк, – ахры булмас!

Тукайга җавабында Сирин, үзләренең милләт байрагы түгел, ә революцион эчтәлектәге кызыл байрак тотып юлга чыгуларын һәм үзләренең соң-ахыргача барырга ният кылуларын каршы итеп куя. Яшьләрнең нык, көчле икәнлекләрен күрсәтү өчен, үзләренең кулларын «тимер куллар» дип атый:

Яңа дөнья төзибез, һәркем эшләр,
Тимер кулларга шәйтаннар сарылмас.
Кызыл байрак тотып без юлга чыктык,
Барырбыз соңгача, һичкем абынмас.

Бу юллар, әлбәттә, 1923 елда Сириннең әле чын күңелдән яңа, гаделсезлекләр булмаган җәмгыять төзибез дип, Коммунистлар партиясе идеяләренә ышанган чагын күрсәтеп торалар. Әмма мондый ышаныч, мондый ирелгәнлек аның бөтен гомере буена бармый. 1930–1933 елларда инде ул совет җәмгыятендә дә гаделсезлекләрнең күп булуына төшенә, аларны тәнкыйтьли, сатира утына ала башлый. Нәтиҗәдә репрессиягә эләгеп, биш ел буе гаҗәеп рәхимсез, кеше ышанмаслык тәртипләр хөкем сөргән Сиблаг лагерьларында җәфаланырга мәҗбүр була. Ә Тукайга җавап рәвешендә язылган «Безнең яшьләр» шигыре исә әдәбият тарихына Сирин иҗат юлының башлангыч этабын характерлый торган әсәр булып кереп кала. Аны көч-энергиясе ташып торган 27 яшьлек Сириннең Тукай белән әңгәмәсе дип тә кабул итәргә мөмкин.

---

[1] Мөхәррир – язучы
[2] Мөрәүвәт маддәсе – егетлек, кешелек сыйфаты.
[3] Күренә ки, Сирин монда өчъюллыкны файдалана, шуның исәбенә бер икеъюллыкны кыскартып, шигырьне бары 9 бәеттән генә төзи.
[4] Лива – байрак.

